Әдәбияттан хрестоматия

10

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбияттан хрестоматия 10

Бар уем кичен-көндезен
сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың — минем саулык,
авыруың — минем авыруым.

Г. Тукай

Әдәбияттан хрестоматия

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән

Өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:821.512.145*10
ББК 84(2Рос=Тат) я721
Ә26

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем
Ә26 бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен / Төз. А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин.— 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 511 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1452-7

ISBN 5-7761-1452-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2000,
үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

СӨННӘТЧЕ БАБАЙ

Авылның картлары, ир уртасылары, яшьләре — һәммәсе дә үзләре белә башлаганнан бирле аны Сөннәтче бабай дип таныйлар, Сөннәтче бабай дип йөриләр иде. Угыллары, кызлары җиткән карчыклар да яңа төшкән яшь килен чакларда аны Сөннәтче бабай итеп таныганнар, алар да, бу көнге яшь киленнәр кеби, урак өстендә кызу-кызу урак урганда да, көз көннәрендә, төшмәенчә башны әйләндерә торган гөбе язганда[1] да, бәйрәм алдында ашыга-ашыга өй юганда да, егълаган угылларыны туктатыр өчен, «Сөннәтче бабай килә!» дип куркытканнар иде.

Аның яшене[2] белгән кеше юк иде. Яше күпме дип уйлаган кеше дә юк иде. Һәм дә, әллә ничек, бөтен авыл халкы шул Сөннәтче бабай берлән яшь арасында мөнәсәбәт барлыгыны уйлый алмый иде. «Сөннәтче бабай сиксән яшендә, туксан яшендә» дигән сүз анларның колагына ят килер кеби, «ата таш, ана таш» дигән шикелле мөнәсәбәт булыр кеби тоела иде.

Сөннәтче бабай — сөннәтче бабай иде. Ул, авылның өч сайлануында да староста булып торып, хаҗга барып кайткан Ашаяк Шәрифе бабайның да сөннәтче бабае булган кеби, авыл хәзрәтенең тимер юллар, пароходлар берлән үтеп барып, Казан шәһәрендә укый торган мәхдүменең дә сөннәтче бабасы иде.

---

[1] *Гөбе язу* — май язу (гөбедә).
[2] *Яшене* — яшен.

Авылның бу ел төшкән яшь киленнәренә дә ялгыз калып уйлап ятканда яисә, эштән соң каенанасыннан яшеренеп, иске чүпрәкләрдән искеләр хәзерләгәндә дә, угылы булуыны уйлап бетерүе берлән, Сөннәтче бабай хәтеренә төшә, угылы булуы берлән сөннәт ясавы Сөннәтче бабайдан һич аерылмый иде.

Кечкенә кызлар курчак уйнаганда курчакларының туе иттереп, кодалар, кодагыйлар чакырып маташканда, иске чүпрәкләрдән ямьсез генә иттереп һәрвакыт бер курчакны «Сөннәтче бабай» атыйлар, «сөннәт туйлары» ясап, аның исеменнән әллә никадәр сүзләр сөйләнәләр, ир балаларны егълаттыралар иде. Бөтен авыл, «сөннәт» дигән сүзне ишеткәндә, шул картаеп, искереп беткән Сөннәтче бабайны хәтеренә китерә, сөннәт туе хакында сүз ишетсә, аның кайда булганыны да уйламаенча, мотлакан[1]: «Сөннәтче бабай булган»,— дип утыртып куя иде.

Аның яше югалган кеби, исеме дә югалган иде. Көлдергечрәк картлар, эшләр бетеп кырдан кергәч, җомга көннәрне кояш җылысында җыелышып, сөйләшеп ятканда: «Сөннәтче бабайның метрикәсене кәҗә ашаган икән. Аның исеме югалгач, Газраил фәрештә аны оныткан икән дә, шуның өчен авылда ике зур холерада ул исән калган икән»,— диләр иде. Газраилнең онытуы сүзе дөрест булса булыр, ләкин Сөннәтче бабайның исеме югалган икән хәбәре ялган иде. Аның исеме бар иде. Исеме генә түгел, аның бөтен нәселене язган, аның бабаларыны, бабаларының бабаларыны язган «Сөннәтче шәҗәрәсе» бар иде. Ул шул шәҗәрәсе берлән, үзенең сөннәт кисәргә мирас тарикы[2] берлән хакы барлыгыны читтән килгән һәрбер шарлатан алдында исбат итә алырлык булса да, авыл халкы аның үткен чалгы пәкесе берлән сап-сары агач черегенә[3] шәҗәрәсеннән дә нык ышанганга, ул шәҗәрәнең кирәге дә булганы юк иде.

Авылның кырыеннан сан буенча икенче исәпләнә торган Сөннәтче бабайның йорты да, дөрестене[4] әйткәндә, өе дә, үзе кеби, бөтен авылның өйләреннән аерым иде. Ул, авылның сатучысы Әхмәдинең кызылга буяган өенә охшамаган кеби, авылның иң фәкыйрьләреннән хисаплана торган капка кара-

---

[1] *Мотлакан* — һичшиксез.

[2] *Тарикы* — юлы, ысулы.

[3] *Черек* — кан туктату өчен җәрәхәткә сибә торган тузан сыман нәрсә, череп көл хәленә килгән агач оны.

[4] *Дөрестене* — дөресен.

вылчы Садриныкына да охшамаган иде. Ул Сөннәтче бабайның өе иде. Бөтен җире, бөтен төсе Сөннәтче бабайга охшаган иде. Авыл тарихыны белми торган вакытта такта берлән ябылган түбәсе, вакыт үтә-үтә каралып бетеп, анда-монда кәкрәеп торулары берлән Сөннәтче бабайның битенә бөтенләй охшый иде. Түбәсенең кырыйларына солы, борай[1], алабута катышыннан үскән үләннәр дә, берсе анда таба, берсе монда таба карап, Сөннәтче бабайның рәтләп тарамаган сакалыны хәтергә китерә иде. Өйнең сулга да, уңга да таба кәкрәйгән диварлары Сөннәтче бабайның төрле тарафка таба бөкрәйгән аркасыны искә төшерә иде. Аның пыяласыннан күп рамлы тәрәзәләре үзенең яшәргән пыялалары берлән бабайның һәрвакыт яшьле күзенә бик охшый иде. Өйнең берәм-берәм агачларыны таратудан саклап тора торган, өсттән сылаган күк балчык та Сөннәтче бабайның да шул картайган тәнене бер кеше иттереп җыеп йөртү вазифасыны кыла торган киемнәренә төсе-нисе берлән дә бик охшаган иде. Монда һәрнәрсә Сөннәтче бабайга охшаган. Сөннәтче бабай үзе дә һәрнәрсәгә охшаган иде. Кем белсен, бәлки Сөннәтче бабай чынында шул өйнең балчыгы берлән бер балчыктан яратылгандыр. Мал иясенә охшамаса хәрам була, диләр. Аның дөрестлегене белмим, ләкин иясенә охшаса, мал берлән иясе арасында аерма бетә. Менә монда да кай җирдә Сөннәтче бабайның үзе башлануы, кай җирдә аның әйберенең чиге булуы әллә кайчан хәтерләрдән себерелгән иде, әллә кайчан бу чик баганалары авып беткән иде. Дөресте генә, Сөннәтче бабай шул Сөннәтче бабай үзе генә түгел иде: ул шул киемнәре берлән, шул өе берлән, шул үткен чалгы пәкесе берлән, шул әллә ничә кат кәгазьгә төргән череге берлән бергә Сөннәтче бабай иде. Бөтен авыл халкы шуны шулай уйлый, бөтен авыл халкы шуның шулай икәнлегенә ышана иде. Шуның өчен авылдагы ике зур утта да Сөннәтче бабайның йорты янмый калуын да Сөннәтче бабайдан аерым бер эш иттереп сөйләнмиләр. Сөннәтче бабайның өе янмый калды, аны ут оныттыфәлән дә димиләр иде. «Газраил дәфтәреннән югалды»га шуннарның һәммәсене бергә кертәләр иде.

Сөннәтче бабайның «сөннәтче бабай»лыгы әле моның берлән генә тәмам булмый иде. Аның тагы берничә кисәге, кәбестә теле берлән сөйләсәң, тагы берничә яфрагы бар иде.

---

[1] *Борай* — бодайның бер төре.

Аның өенең алдында, юкә агачлар берлән бастырып тоттырган кечкенә бакчада, бер караганда, һаваланганнан күкрәгене чыгарып, кукраеп тора кеби, бер караганда, картайганнан арып, билене тота алмаенча бөкрәеп тора кеби күренә торган миләш агачы да бар иде. Көзгә таба аның кып-кызыл миләш сабаклары, кызыл ахак кеби салынып, сөялеп, яшь кызларның муены, кулыны, колагыны бизәкли торган төймәләр, алкалар кеби. Сөннәтче бабайның өене бизи иде; аның искелектән туеп беткән йөзенә көләчлек бирә, битенә кызыл йөгертә иде. Сөннәтче бабай, шул үзе берлән бергә картайган миләш агачының телене белгән кеби, һәр көн иртә берлән чыгып, агачка таба карый, һәр көнне аның берлән сөйләшергә тотына:

— Нихәл, суык булмадымы? Кырау төшмәдеме? Чәчәкләреңне өшетмәдеңме? — дип сорый иде.

Миләш тә, шуны гына көткән кеби, офицеры алдында басып тора торган солдатның офицерының сәламенә каршы кычкырып: «Исәнлегеңне телим!» — дигән кеби, миләш тә әллә кайдан килгән җил берлән шаулап җавап бирә; Сөннәтче бабай да, аның сыгылып-сыгылып килә торган ботакларыны, чәчәкләрене тотып карап, туңмаганына, өшемәгәненә ышанып, агачның тамырларыны карарга: «Җир корымадымы? Су кирәкмиме?»— дип, туфракны кулы берлән изәргә тотына иде. Ул күп вакытны: «Су сибәргәме, юкмы,— дип уйлап тора-тора да: — Майдан ботка бозылмас»,— дип, чиләкне күтәреп, артындагы инешкә төшә дә, анда үзе ясаган басмадан су алып менеп, миләшенең төбенә сибә иде. Аннан соң салыныбрак төшкән ботакларыны бер-бер җеп берлән бәйләп куя, иелгәнрәкләрене агачлар берлән терәтә, миләш вакытында урамга якынракларыны бакчага таба борып куя иде. Ләкин монысы кирәкмәс бер эш кенә, Сөннәтче бабайның картлыгыннан килгән артык бер саклану гына иде. Аның миләшләре ерактан караганда никадәр малайларны кызыктырса да, урамның теге ягыннан үтеп баргандук үзенең ачылы-төчеле тәме берлән никадәр анларның авыз суыны агызса да, килеп басып алырга берсенең дә көче җитми иде. Түбән оч, югары оч бакчаларында кыярга рәхәт йөзе күрсәтми торган Гата малае Касыйм да, юлаучы Кәмалинең күршеләрендә йомыркаларына көн күрсәтми торган ирдәүкә кызы Мәрфуга да шул миләшләргә таба тугъры килә алмый иде. «Сөннәтче бабай» дигән сүз анларның да күңеленә әллә нинди бер курку төшерә, анларның да күз алдына шул Сөннәтче бабайны, карт Сөннәтче бабайны пәкесе,

череге берлән китереп бастыра; аның авызыннан Сөннәтче бабай һич сөйләми торган бер тавышта «Кисеп алырмын!» дигән сүзне ишеттерә иде. Шул «кисеп алырмын»нан Касыйм да куркып кача, никадәр ирдәүкә булса да, киселәчәк артык бер нәрсәсе дә булмаган Мәрфуга да якын килми иде.

Миләшкә башка[1] да бабайның байлыгы юк түгел иде. Аның өенең артында канау берлән әйләндереп алган суга кадәр сузылган йорты бар иде. Читтән караганда никадәр кечкенә генә төсле күренсә дә, бу йортның бер почмагы уҗым кыры, бер почмагы сабан ашлык кыры, суга якын җире печәнлеккә бүленгәнгә, башка урта җире шалкан, кыяр, кәбестә, чөгендер, борчак, бәрәңге түтәлләрене дә эченә ала алган иде. Шул ферма, урам ягыннан кечкенә генә җилкапка берлән авылга чыккан кеби, пөхтә генә такта ишек, тар гына, матур гына басма берлән суга таба да сузылган иде. Шул су ягындагы ишектән Сөннәтче бабай түтәлләрене, ашлыгыны сугара, урам ягындагы капкадан шул ашлыкларны чит дөньяга чыгара, җәгърафиячә әйтсәң, чит мәмләкәтләргә җибәрә иде. Җәйнең һәр вакытында аның шул бакчасы ямь-яшел тора, илдәге корылык аның арышыны саргайтмый, җәйге эсселек аның карабодаены көйдерми иде. Һәр елны кояшка карап тора торган каш җирендә[2] аның бодае уңа; уйсу җиргә чәчкән аның солысы кара туткыллы булып гөрләп үсә; карабодае, миләш кеби, сабаклары берлән тулы була; арышы, сары ука кеби, башыны күтәрә алмаенча сузылып ята иде. Аның кыяры, шалканы, кишере хакында сөйләмә дә инде — алар бөтен авылның авызыннан суыны агыза, бөтен авылны кызыктыра иде.

Сөннәтче бабайның кош-корты да юк түгел иде. Ләкин болары, ни өчендер, Сөннәтче бабайныкы дип сөйләнмәенчә, аның карчыгы Гөлйөзем әбинең исеме берлән йөри иде. Мәсәлән, аның бүрекле тавыгы, кызыл әтәче «Гөлйөзем әби тавыгы», «Гөлйөзем әби әтәче» дип йөртелә; аның зур җилемле, һавалы мөгезле, көтүнең артыннан килә торган кәҗәсе дә «Гөлйөзем әби кәҗәсе» дип сөйләнә иде.

Бу тавыклар, әтәчләр, кәҗәләр — һәммәсе дә Сөннәтче бабай кеби карт булсалар да, Сөннәтче бабай күрше картларыннан аерылган кеби, анлар да күрше тавыкларыннан, әтәчләреннән аерылсалар да, һәммәсе дә холыклары, табигатьләре берлән

---

[1] *Миләшкә башка* — миләштән башка.

[2] *Каш җире* — калку җир.

Сөннәтче бабайга бик охшасалар да, күрше-фәлән, ни өчендер, бу мәсьәләдә Сөннәтче бабайның хакыны кабул итмәенчә, Гөлйөзем әбигә нисбәт биргәннәр иде. Кем белсен, өй, бакча, миләш Сөннәтче бабайга никадәр охшаса, тавык, этәч, кәҗә, бәлки, Гөлйөзем әбигә шулкадәр охшагандыр. Шулай дигәч тә, сез Гөлйөзем әби белән Сөннәтче бабай арасында аерма бар иде: берсе кара туткыллы, берсе сарырак; берсе каты табигатьле, берсе йомшак; берсе матур, берсе ямьсез, дип, бер хата фикер чыгармагыз. Бонларның төсләрендә, йөзләрендә, кылынышларында, табигатьләрендә дә һичбер аерма юк иде. Дөресте генә, бонлар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде. Бонларның берсене күреп, икенчесене күрмәгән кеше иттифакый[1] күрмәгәнене, икенче авылда яисә кара урманның ялтыраган аланында җиләк җыйганда күрсә, мотлака, моның кем икәнлегене таныячак иде.

Бонларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде. Мәсәлән, Сөннәтче бабай: «Карчык, түтәлләргә сибәргә вакыт түгелме?» — дияргә өлгерә алмый иде, Гөлйөзем әби чиләкне күтәреп чыга башлый иде. Көз җитеп, «сөннәт туйлары» җитә башларга вакыт җитеп, Гөлйөзем әби: «Карт, «сөннәтләр» җитә»,— диярга өлгерми. Сөннәтче бабай, тәһарәт төзеп[2], чалгы пәкесене кайрарга тотына иде. Алай булса да, бонлар үзләре бер-берсене аералар иде. Гөлйөзем әби бер вакытта да Сөннәтче бабайга «карчык» дип дәшми, бабай да, онытып җибәреп, карчыгына «картым» дип эндәшми иде.

Ул гына да түгел, бонлар арасында эштә дә аерма бар иде: кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самавыр кую Гөлйөзем әбинең эше булган кеби, миләшкә су сибү, йортны себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Онытканмын икән әле, өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. Ул һәр көнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атна кич ком белән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларыны ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур белән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде.

Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт, карчык белән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән

---

[1] *Иттифакый* — очраклы.
[2] *Тәһарәт төзеп* — тәһарәт алып.

бушамый иде. Ул кай вакытлар мич ягып күмәч сала, кыстыбый пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде. Өйдәге бөтен әйберләр, җиһазларда һич артык нәрсә булмаса да, бонлар арасында берсе дә кыйммәтле, кыйммәтсезлек берлән аерылмаса да, өч нәрсә бонларга һич охшамаган, бөтенләй башка дәрәҗәдә иде: аның берсе — Сөннәтче бабайның мирас юлы берлән сөннәтчелеккә хакы барлыгыны исбат итә торган шәҗәрәсе, икенчесе — сөннәт кисә торган чалгы пәкесе, өченчесе сөннәткә сибә торган, шешәгә тутырган сары череге иде. Бонларның өчесе дә өйнең иң кадерле җирендә, Гөлйөзем әбинең кыз чагыннан калган «Һәфтияге», бөтиләре саклана торган түрдәге шүрлектә, кечкенә сандыкта тора иде. Бонларның һичберсе дә гади көндә алынмый, һичберсе андый-мондый эшкә тотылмый иде. Хосусән[1] шәҗәрәнең кыйммәте әби берлән бабай алдында бик зур иде. Ул һәрвакыт карындыкка төрелгән көенчә, берничә кат кәгазьгә сарылып[2], чүпрәкләр берлән бәйләнеп куелган иде. Аның эчендә ни язылганыны Сөннәтче бабай укый белмәсә дә, шул кәгазьнең бик зур кәгазь икәнене белә, әллә нидә бер зур кунак-фәләнгә күрсәтергә тугъры килсә, ул, шәҗәрәнең бер җирендәге исемгә бармагы берлән төртеп:

— Менә монысы — Сәлман Фарси разый Аллаһе ганһе, менә монысы — мин,— дия иде.

Ул шул сүзне әйткәндә бераз һаваланып та киткән кеби була; теге кешегә гади кеше берлән эш итмәгәнене, «Сәлман Фарси» нәселеннән бер кеше берлән эш иткәнене белдерер өчен кеби:

— Сәлман Фарси хәзрәтләре безнең бабамыз булган,— дип куя иде.

Аннан соң ул шәҗәрәнең тарихыны сөйләргә тотына иде. Сөйләгәндә, гади сүз сөйләмәгәнене белгәнгә, сүз араларында салаватлар әйтә, «Разый Аллаһе ганһе, рәхмәтуллаһи галәйһи»ләр берлә бизәкли иде.

— Бабай ул шәҗәрәне әтисеннән мирас тарихынча алган иде. Шуннан соң аңар үзенең исемене яздырыр өчен мәрхүм, Алла рәхмәтендә булсын, Түнтәр (Гали ишан) хәзрәткә барган иде.

Сөннәтче бабай шул вакыйганы менә ничек сөйли иде:

---

[1] *Хосусән* — бигрәк тә.

[2] *Сарылып* — б и р е д ә: төрелеп.

— Кышның көне иде. Әти мәрхүм, Алла рәхмәт итсен, вафат булды. Үләр алдыннан мин берничә ел әти берлән читкә сөннәткә чыгып йөрсәм дә, иҗазәт[1] ала алмаган идем. Менә бер көнне тегермәннән кайтсам, әти: «Угылым, хәзрәтне алып кил, хәлем начар»,— диде. Мин хәзрәткә киттем. Хәзрәт мәрхүм, Алла рәхмәтендә булсын, ул вакытта Кәбир хәзрәт иде. «Хәзрәт бабай, әти авырый»,— дигәч: «Машалла!» — диде дә, мәдрәсәдән чыгып, чанамга утырды. Өйдә этине телсез таптык. Хәзрәт ясин укырга тотынды. Әти һаман телгә килмәде. Ясиннан соң хәл җыйган кеби булды. Хәзрәткә күзене тутырып карап, телене кыймылдатырга тотынды. Хәзрәт, әллә ни әйтергә теләгәнене күреп: «Алла!»— диде. Әти акыртын гына: «Алла!» — диде дә, кулыны селкеп, әллә ни сөйләмәкче булды. Бик авырлык берлән кулыны күтәреп, шүрлектәге сандыкны күрсәтте. Аннан ары күзене миңа борды. Хәзрәт: «Сиңа сөннәтче бабай булырга иҗазәт бирә»,— диде. Хәзрәт шул сүзне әйтеп өлгерә алмады, әти тагы: «Алла!»— дип әйтеп, җан бирде. Алла рәхмәт итсен, бик яхшы кумдек. Гүр садакасына зур бер сарык бирдем; фидиясенә[2] өй тумасы[3] кашка кырыкмыш[4] бар иде, шуны бирдем, кырыгына кадәр өстенә йөрергә алты тәкәдән теккән тунны бирдем. Менә көн үтте, кыш үтте, җәй булды, көз булды — сөннәт вакыты җитте. Мин, тәһарәт алып, этинең пәкесене алып, сөннәткә чыктым. Малайлар минем артымнан йөри башладылар. Алар: «Корбанколый сөннәтче бабай булган»,— дип көлә башладылар. Ул вакытта әле яшь идем. Бер өйгә кердем. Үзем берлән үскән Гадиләнең өе икән. Угылы сөннәтлек булган, яхшы каршы алдылар, белен берлән чәй эчерделәр. Ләкин: «Быел әле сөннәткә бирмәскә телимез, баламыз үссен дип уйлыймыз»,— диделәр. Икенче җирдә тагы шулай. Мин бөтен авылдан бер малай да таба алмадым. Үткән ел бай ел булганга, сөннәтлек малай күп иде. Мин уйладым, уйладым да, яңа тун киеп, кияү булып кергән казакины киеп, мәрхүм Кәбир хәзрәткә киттем. Хәзрәт мине өенә алып керде. Кергәч тә, тулы ният бирдем. Хәзрәт дога кылып сорашырга тотынды. Хәзрәткә бәйнә-бәйнә хәсрәтне сөйләдем. Хәзрәт уйлап торды-торды да: «Син, Корбанколый, Түнтәр (Гали) ишанга

---

[1] *Иҗазәт* — рөхсәт.

[2] *Фидия* — үлгән кеше өчен бирелә торган садака.

[3] *Тума* — теге яки бу урында торган, шуннан чыккан.

[4] *Кырыкмыш* — бер яше тулган тай.

бар, аннан иҗазәт ал»,— диде. «Хәзрәт, ул кая соң?»— дидем. Хәзрәт, фәлән җирдә, фәлән җирдә, дип сөйләп бирде. Шул арада булмады, авылга әллә кайдан, «сөннәтче» дип, бер карт килде. Миңа «баламыз кечкенә» дигән бөтен кешеләр сөннәткә бирә башладылар. Атам мирасының әллә кемнәргә китүенә ачуым килде. Атны җигеп, хәзрәткә дип бер савыт кәрәзле бал алып, юлга чыктым. Унике көн бардым. Менә хәзрәтнең авылына барып җиттем. Иртә намазга кердем. Ул халык, ул халык! Сакаллы шәкертләр берлән мәсҗед тулган. Намаз бетте. Хәзрәтнең намаздан чыкканын көтеп торып күрештем. Хәзрәткә серне аңлаттым, үземезнең хәзрәттән алган хатны бирдем. «Өйлә намазына тәһарәт төзеп кил»,— диде. Килдем. Дерелдәп кенә намаз укыдым. Коръәннән соң хәзрәт мине чакырды, иманны сорады, җавап бирдем. Намазларны сорады, җавап бирдем. Шәҗәрәне сорады, әтинең, бабайның исемене әйттем. Шуннан соң хәзрәт кул күтәреп дога кылды. Шундагы бер зур шәкерткә: «Шуның шәҗәрәсене күчереп, исемене яз»,— диде. Шатлыгымнан, язган шәкерткә бер талир тәңкә бирдем. Унике көн барган җиремне уналты көн кайттым. Менә җиңел генә түгел, шулай алдым,— дия иде дә шәҗәрәне күрсәтә иде.

Шәҗәрәне укый белгән кеше, башыннан әллә никадәр аятьләр, салаватлар укыганның соңында: «Корбанколый бине Уразколый, Уразколый бине Миңлеколый, Миңлеколый бине Габдулла, Габдулла бине Мөхәммәдсалих, Мөхәммәдсалих бине Мулламорад баба*, Мулламорад баба бине Хан Гәрәй, Хан Гәрәй бине хәзрәти Аксак Тимер, Аксак Тимер бине хәзрәти Гали, хәзрәти Гали бине Сәедбаттал, Сәедбаттал бине хәзрәти Хәнәфи, хәзрәти Хәнәфи бине Мөхәммәд, Мөхәммәд бине Габделсәлам, Габделсәлам бине Мамай, Мамай бине ибн Габбас, ибн Габбас бине Габделмөталиб, Габделмөталиб бине Һашим, Һашим бине Хәсән, Хәсән бине хәзрәти Билал, хәзрәти Билал бине Сәлман Фарси, разый Аллаһе ганһе»,— дип бетергән бер шәҗәрә күрә иде. Укучы Сәлман Фарси берлән бабай арасындагы шул мең дә өч йөз елның шулкадәр тиз кичеп, биш-алты буында Сәлман Фарсига барып җитүендә дә, шундагы кергән тарихи исемнәрнең тугърылыгында да шөбһәләнми иде.

---

* *Мулламорад баба* — Кырым ханнары Гәрәйләрнең угылларыннан. Ни сәбәптәндер, Русиянең уртасына күчеп килеп, гыйлем юлында хезмәт иткән. Чистай вә Бөгелмә уездларында зур исеме бар. Шонталы авылында, Чистай уездында күмелгән. *(Г. Исхакый искәрмәсе.)*

Пәке шәҗәрәгә караганда шәфкатьсезрәк булса да, ул бик мөкатдәс иде. Бабай аны да салаватсыз тотмый, аны да күрсәткәндә атасыннан калганыны сөйләп кенә калмаенча, аның да шул буыннардан үтеп, хәзрәти Сәлман Фарсидан килгәненә кадәр барып җитә, аңар хәзрәти Рәсүлнең үз кулы берлән бирүене дә әйтеп куя иде. Пәкене караган кешенең күңеленә: «Ул вакытта чалгы бар иде микәнни?» — дигән фикер килми, бабайның башына да андый шөбһәләр керми иде. Замана бозылмаган иде. Халык бер-берсенә ышана, язылган сүзләргә Коръән кеби игътикад[1] итә иде.

*

Көннәр кыскара башлап, кичләр суыгая башлагач, киленнәр киндер урыннарыны чормадан төшереп кора башлагач, кызлар киергеләренә киереп, балтыр чүпрәкләр челтәрли, якалар чигә башлагач, Сөннәтче бабайларда да хәл үзгәрә, анларның өйләре дә әллә нинди зур эшкә хәзерләнә башлый иде. Шул көн якынлашуы сизелә башлагач та, Гөлйөзем әби керләр чайкый, өенең идәннәрене юа, самавырны тагы көзге кеби иттереп ачып куя, шул көнгә дип җәйли җыйган каймагыннан гөбе яза иде.

Менә көтәр көн килеп җитә, көннәр салкынланып җитеп, чебеннәр, күбәләкләр үлеп бетә иде. Сөннәтче бабай, иртә намазга алдан ук барып утырып, ниятләрене укый, намаз беткәч, ишракъ[2] намазыны да бетереп, хәзрәткә килеп: «Безгә фатиха биреп чыкмассыз микән? Карчык самавыр куеп торырмыз дип әйт дигән иде»,— дип, хәзрәтне ашка чакыра. Хәзрәт тә, чакырыласыны әллә кайчан белеп торганга, вәгъдә бирә. Сөннәтче бабай, сүз беткәч кенә: «Хәзрәт, остазбикә берлән,— дип, тагы ныгытып әйтеп: — Алай булса сез, хәзрәт, тәһарәт яңартыңыз да барыңыз. Мин карчыктан кайтып сөенче алыйм»,— дип, кызу-кызу кайтып китә, кайнаган самавыр, яккан мич берлән көтә торган карчыгына хәбәрне сөйләп, үзе киенергә тотына иде. Ул бу көнне үзе кияү булып кергән вакытта бикәч бүләге иттереп бирелгән чиккән якалы күлмәкне, аның өстеннән бу хәзрәттән элгәреге хәзрәт биргән кыска җиңле, алды теткәләнгән булса да, арты өр-яңа тора торган әдрәс[3] казакины, башына хәзрәтнең кияүгә чыккан кызының угылыны

[1] *Игътикад* — ышаныч.

[2] *Ишракъ* — иртәнге, кояш чыккан вакыттагы.

[3] *Әдрәс* — ярым ефәк тукыма.

сөннәткә утырткач биргән чиккән кәләпүшене кия иде. Ул шул киемдә матураеп, шул көндә яшәреп китә иде. Ул шул көенчә хәзрәтләрне көтәргә капка төбенә чыга; күзне кытыклый торган көзге кояшның йөдәтүеннән сакланыр өчен, күз өстенә кулыны куеп, хәзрәтләргә таба карарга тотына иде. Хәзрәтләр капкадан чыгу берлән, ул: «Карчык, карчык!»— дип, Гөлйөзем әбигә кычкыра; Гөлйөзем әби дә, мичтәге коймагыны алга тартып, самавырына тагы бер күмер салып, каршы чыга иде. Хәзрәтнең сәламенә каршы Сөннәтче бабай сәламне алгач та, Гөлйөзем әби: «Әй рәхмәт, хәзрәтем, остазбикәмне алып килә! Кил, остазбикәм!» — дип, остазбикәнең аркасыннан кага. «Әй канатым, рәхмәт! Олугъ башыңны кече итеп килүең өчен Аллаһе Тәгалә җиде оҗмахның ишегене ачык кылсын! Безнең ярлы йортымызга аяк баскан өчен, Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре алтын-көмештән сарайлар бирсен!»— дия иде.

Абыстай да, хәзрәт тә: «Амин!» — дип, өйгә керәләр иде. Гадәтнең тышында[1], абыстай, Сөннәтче бабайдан качмаенча, хәзрәт берлән бергә утыра иде. Шул гадәткә, шәригатькә сыймый торган эшне бертөрле тәэвил итәр[2] өчен, хәзрәт догадан соң да:

— Ие, Сөннәтче бабай, гадәтем остазбикәне алып йөрү булмаса да, Гөлйөзем әби күңеле өчен алып килдем инде. Сездән качмаса да гаепләмәңез инде,— дия иде.

Шул сүзне ул утыз елдан бирле әйткән кеби, Гөлйөзем әби дә шул сүзгә каршы:

— Әй рәхмәт, хәзрәтем! Әй рәхмәт! Бөтен илдән аерып, безне үз итүеңезгә рәхмәт! Сәлман Фарси хәзрәт шәфагатьчеңез[3] булсын! — дия иде.

Шул «Сәлман Фарси» дигән сүзне әйткәндә, Сөннәтче бабай тагы бераз үсеп киткән кеби була, аның күзенә нур керә, аның йөзе тагы яшәрә иде. Хәзрәт — эчә торган чәйдән бүләк итеп китергән чирек чәйне Сөннәтче бабайга үлгән угылы «Габдерахман өлеше» дип суза, абыстай да Гөлйөзем әбигә дә, «үлгән кызым өлеше» дип, чиккән күкрәкне төртә иде. Тагы дога башлана. Гөлйөзем әби:

— Аллаһе Тәгалә сезгә оҗмах хөлләләре кидерсен, кыямәт көне йөзеңезне ак кылсын! — дип дога кыла иде дә, чәй мәҗ-

---

[1] *Гадәтнең тышында*— гадәтне сакламыйча.

[2] *Тәэвил итү* — аңлату.

[3] *Шәфагать* — арадашлык, яклау, арага керү.

лесе башлана; Гөлйөзем әбинең мичендә пәрәмәчләр, коймаклар кызу-кызу чатырдый башлый иде.

Хәзрәт тә, абыстай да кыстатмаенча эчәләр, ашыйлар, тәмле сүзгә кереп китеп, чынаякларны санарга оныталар, самавырда су беткәч кенә: «Туйдык, туйдык инде»,— дип тартынсалар да, Гөлйөзем әби тагы кайнаган су берлән самавырны яңарткач, тагы эчәләр иде. Өченче мәртәбә самавырны яңартырга хәзрәт тә каршы килә дә, остазбикә дә разый булмый иде. Гөлйөзем әби: «Минем, хәзрәткәем, эчәсем килә, мин дә сезнең мәҗлесеңез берлән шәриф («мөшәррәф»[1] дигән сүзне шулай әйтә иде) буласым килә»,— дигәч, хәзрәт тә дәшми, остазбикә дә разый була: тагы самавыр килә, тагы Гөлйөзем әби берлән бергә чәй эчелә, тагы су бетерелә иде. Дүртенче самавырга хәзрәт кенә түгел, абыстай да каршы килә, Гөлйөзем әби дә, тиресләнмәенчә[2], чәй урынны җыеп ала иде дә, Сөннәтче бабай: «Хәзрәт, әрвахлар өчен...»— дип, сүзене әйтеп бетерә алмаенча туктый иде. Хәзрәт тә, шундый вакытта укыла торган кыска аятьләрне укымаенча, «Иннә фәтәхна»ны бөтенләй укып чыга, бик озын иттереп, гарәпчә, фарсыча катыштырып дога кыла иде. Сөннәтче бабай, хәзрәт дога кылып бетергәч тә, әллә кайчан хәзерләп куйган пич буендагы зур биш тиенне — хәзрәтнең кулына, биш тиен дип язса да, хәзер бер тиен ярымга йөри торган зур акчаны да остазбикәнең кулына баса[3] иде. Акчалар кызган булса да, хәзрәт тә, абыстай да кулыннан төшермәенчә дога кылалар иде. Догадан соң хәзрәт, гадәте буенча: «Аллаһе Тәгалә озын гомер бирсен, дәүләтеңезне киң кылсын!»— дияргә өлгерми, Гөлйөзем әби, әллә кайдан чыгарып, хәзрәткә зур ике тиен, абыстайга бер тиенне төртеп: «Падишаһ хезмәтендә үлгән угылым өчен»,— дип, сүзне бетерә иде. Тагы дога башлана иде. Шуның артыннан Гөлйөзем әби: «Гаеп итмәңез инде, сыйлый алмадым»,— дия иде. Хәзрәт: «Бик рәхмәт, бик сыйладың»,— дип тора башлагач, Гөлйөзем әби: «Аш хәзерли алмадым инде, хәзрәт, аз гына шурпа бар, шуны ашап китеңез инде»,— дия иде. Шуның артыннан тавык итендә пешкән шурпа китерә иде. Ул бетәргә өлгерә алмый, каз аягы-бүтәкәсеннән пешкән, чыгыр-чыгыр кайнап тора торган шурпалы бәлеш ашъяулыкка куела иде. Шул арада ишегалдына чыгып, Сөннәтче бабай да,

---

[1] *Мөшәррәф* — кадер-хөрмәтле.

[2] *Тиресләнмәенчә* — киреләнмичә.

[3] *Кулына баса* — кулына тоттыра.

зур аякларда[1] сосла[2] күтәреп кереп: «Бәлки, хәзрәт, яратырсыз»,— дип, хәзрәтләр өчен ясаган сосласыны суза иде. Бәлеш ашала, сосла эчелә иде. Бәлешнең эче бетеп, төбе киселергә җиткәч, хәзрәт тә, абыстай да: «Кисмә, кисмә!» — дисәләр дә, кискәч, төбеннән дә берәр кисәк ашыйлар иде. Ул бетеп өлгерми, Гөлйөзем әби: «Хәзрәт, менә безгә доганны аз кыласың, быел бер үрдәгем качып салды, үрдәкләрем аз булды»,— дип, пешкән үрдәк чыгара иде. Хәзрәт: «Сез безне бигрәк сыйладыгыз»,— дия, абыстай да: «Туйдык инде, кирәкмәс, бозма»,— дия иде. Ләкин, бозылгачтан, үрдәктән дә, кечкенә мәхдүмгә дип алып куелган боттан башка, бернәрсә дә калмый иде. Үрдәктән соң Гөлйөзем әби: «Бернәрсә дә хәзерли алмадык»,— дип, йомырка бәлеше чыгара иде. Тагы: «Кисмә, кисмә!» — дигән сүзгә карамаенча, ул да киселә, ул да ашалып бетә иде. Шуннан соң Гөлйөзем әби: «Гаепләмәгез инде, хәзрәт»,— дип, гозер үтенергә тотына. Сөннәтче бабай да, әллә кая югалып, шактый гына зур карбыз күтәреп керә иде. Хәзрәт, абыстай тагы: «Урынымыз калмады инде»,— дисәләр дә, ашый башлагач, карбызны мактый-мактый, урын калмаганлыгы онытыла иде. Шуннан соң Гөлйөзем әби никадәр самавыр китерергә теләсә дә, хәзрәт разый булмый, ул, шул арада капка төбенә ашка алырга килгән кешене күрсәтеп: «Остазбикә калсын, без Корбанколый агай белән бергә китик инде»,— дия иде. «Корбанколый» дигән сүзне хәзрәт үзенә кан алдырганда гына, мәхдүмгә сөннәт кистергәндә генә әйткәнгә, Сөннәтче бабай тагы кәефләнә, Гөлйөзем әби тагы шатлана иде. Шуннан соң Сөннәтче бабай: «Алай булса, хәзрәт, безгә фатиха бир инде, бүген баш көн, башламакчы булам»,— дия иде. Хәзрәт тә кулыны күтәреп дога кыла иде дә Сөннәтче бабай белән чыгып китә иде. Гадәттә, абыстай, Гөлйөзем әби янында калып, тагы бераз чәй эчә, тамагы туйган булса да, калдык-постык пәрәмәчләр, коймаклар, бәлешләрдән тагы бераз авыз итә иде.

Шул көнне өйләдән соң Сөннәтче бабай, һаман шул кунакча киеменнән, черегене салават әйтеп кәгазьгә төреп, пәкесене күкрәк кесәсенә тыгып, күрше Мифтах малаены янына алып, эшкә чыгып китә иде. Иң әүвәл, хәзрәтнең угылы булса —

---

[1] *Аяк* — савыт, җамаяк.

[2] *Сосла* — үрдереп киптерелгән арышны, арпаны пешергәндә алына торган татлы куерык.

хәзрәткә, аның угылы булмаса —мөәззингә, анда булмаса — илдәге хаҗига, анда да булмаса — намаз карты Гобәй бабайга, анда да булмаса — башка берәр намазлы-ниязлы картның йортына бара иде. Аталары күтәреп чыгара торган, чыкмас өчен тыпырчына-тырмаша торган зуррак малайларны өйрәтер өчен, ул, кесәсеннән чыгарып, бер алма бирә, аның берлән сөйләшеп, аңар чыбыркы ишеп бирергә дә вәгъдә итә иде. Шулай итеп, аны ышандырып җиткергәч, аңар: «Кызыл ыштан, тәти ыштан тегәмез, менә үлчик әле,— дип яткыра да, янындагыларга тотарга кушып, салават әйтеп: — Бисмилла, Аллаһе әкбәр!» — дип кисеп ала да акыра-бакыра торган малайның җәрәхәтенә черегене сибеп чыгарырга куша иде. Шул эшене эшләп бетергәч, кулыны юып, тагы салават әйтеп, пәкесене, черегене куеп, хәзерләнеп торган чәй янына менеп утыра, элгәреге сөннәтләр хакында сөйләп, чәй эчә иде. Сөннәт садакасыны алып, гадәттәге бер икмәкне янындагы малайга күтәртеп, ул күңел тынычлыгы берлән өйгә кайтып китә, бу көнгә шуның берлән эшене туктата иде. Ул шул көнне үзене бөтенләй егетләрчә хис итә, бөтенләй башка кеше булып китә иде. Йокысыны да тыныч йоклый, вак-төяк төш тә күрми, күрсә дә — бабаларыннан Сәлман Фарси хәзрәтне яки Сәетбаттал Газины гына күрә иде.

Иртәгесене ул иртүк чыгып китә, көн буе дүрт-биш җирдә сөннәт кисеп, биш-алты икмәк күтәреп кайта иде. Ашлык булган елларда зур авылда шул хезмәт бер-ике атнага бара иде. Шул вакытта Гөлйөзем әбинең өе икмәк берлән, Сөннәтче бабайның кесәсе зур бакыр акча берлән тула иде. Сөннәт беткәч, бабай тагы, хәл белер өчен, тагы әүвәлге йортка бара, тагы акырып-бакырып чыкмаска теләгән малайларны чыгартып карап: «Менә тәти булган, угылым»,— дип, акырган балага тагы черегене сибеп, тагы чәй эчеп, тагы икмәк алып китә иде. Шулай итеп, тагы бер мәртәбә йөреп чыга иде.

Сөннәтче бабай шул эшене тәһарәтле көенчә кылганга, һәрвакыт салават, бисмилла берлән эш башлаганга, балаларның җәрәхәтләре тиз бетәшә, тиз төзәлә иде. Кай вакытларда гына бетәү ярага әйләнеп китсә дә, чебен-черки чыкканча төзәлми калмый иде. Иң актык сөннәт беткәч, Сөннәтче бабай, зиярат өстенә барып, Коръән укый, хәзрәткә кереп садака бирә, остазбикәгә дип җимеш илтә иде. Шуннан соң, күршедән ат алып, сөннәт булган йортлардан сөннәт ашлыгы җыеп йөри, капчык-капчык карабодай, борай, арыш, солы төяп өйгә кайта, өй алдының бөтен өсәкләрене ашлык, он берлән тутыра иде. Җыелган

икмәкне сатып, карчыгына күлмәк, алъяпмалык, үзенә күлмәк, ыштан, рамазан никадәр ерак булса да, «санаулы көн үтәр» дип, мәсҗедтә авыз ачтырырга дип, ике кадак хөрмә алып, мөәззингә бирә иде. Шуннан соң ул тагы иске торышы берлән, тагы киләсе елның сөннәт вакытыны көтү өмете берлән яши иде.

Шулай итеп, еллар үтә, яшьләр өйләнә, яңа балалар, яңа сөннәтләр җитә, анлар үтә; анлар артыннан килә торган буынның баласы-чагасына рәт җитә иде. Яшьләр картая, картлар үлә, еллар үтә иде. Ләкин бу үткән еллар, аның яшене.картайтмаган кеби, аның битенә яңа җыерчыклар да чыгармый вә аның билене тагы бөкрәйтми иде. Ул, дөнья үтүене сизмәгән кеби, һаман элгәреге Сөннәтче бабай булып тора иде.

*

Тыйб[1] гыйлеменчә мәгълүм: кешенең тәнендәге канының куелыгы вә сыеклыгы, вә ул канның агуы елның фасыллары берлән бик зур мөнәсәбәте бар. Кыш көннәрендә инсаннарның каннары бөрешкән, куеланган хәлдә була. Ул тамырлар буенча акыртын гына, һаваланып кына ага. Кыш көнендә бер-бер әгъза киселсә яисә тамыр өзелсә, кан, касәдән авыр-авыр чыга торган куе каймак кеби, акыртын гына ага; җәрәхәт тиз бетәшә. Көннәр озая башлап, кояш күбрәк җылыта башлагач, урамнарда сулар җыела башлагач, адәм тәнендәге кан да, кояш җылысында эрегән кар кеби, языла башлый. Көн җылынган саен ул сыегая-сыегая килә. Май числосында ул тәмле-татлы язгы сөт кеби була. Шуның өчен ул вакытта кешеләр үзләрене яшәргән кеби хис итәләр, аркаларыннан бик зур йөкне ташлаган кеби, җиңеләеп калалар. Бу вакыт кан үзеннән-үзе кыш буе җыелган бозык, начар каннарны куа башлый. Җәй җитеп, көн кызуланган саен кан сыекланганнан-сыеклана бара. Кеше тәнендә торасы килмәгән кеби, адәмнең эчендә кайный, яңлышлык берлән кул-баш киселсә, бик күп кан әрәм була. Һавалар суыгая башлап, яшел үләннәр кырау күргәч, кан тагы, сөт өстенә утыра торган каймак кеби, акыртын гына утыра, куера башлый. Кыш якынлашкан саен аның куеруы арта, шуның өчен гыйльми тыйб ияләре кан алдыру, мөгез салдыруның вакытларыны елның фасылы берлән тәгъйин итәләр[2].

---

[1] *Тыйб* — медицина.

[2] *Тәгъйин итү* — туры китерү

һичбер вакытта, аерым бер авыруы булмаса, канның сыекланган вакытында тамырыны кисеп, адәмнең шашкан, чыгарга көтеп кенә торган каныны әрәм итмиләр. Шуның кеби үк, кыш көнендә, куерган, утырган канны йокысыннан уятып, аның ага торган юлыны бозмыйлар, аның буасыны җырмыйлар. Анлар кан алдыру өчен һәрвакыт кыш буе җыелган начар, бозык каннарны, канның үзенең чыгарып-иркенләнеп калырга теләгән яз көнене ихтыяр итәләр. Шул яз көнендә, көннәр җылынып җиткәч кенә, тамырдан кан алалар, мөгез салалар.

Елның фасылларының канның агуына, канның куелыгы-сыеклыгына тәэсире булган кеби, айның, көннең дә тәэсире юк түгел. Айның тулысында кан тулы булганга, кан алу өчен куркынычсыз түгел. Канны туктату авыр булып, теләр-теләмәс, күп кан чыгу ихтималы бар. Айның башында яшь тамырга өйрәнеп бетмәгән каннар китүләре ихтималы булганга, таза канның чыгып, карт канның калу шөбһәсе бар. Шуның өчен канны алдыруны тулы ай кителә башлагач муафикъ күргәннәр. Айның унтугызынчы, егерме беренче көннәрене бигрәк мәслихәткә санаганнар.

Көннең исеме берлән, көннең вакыты берлән дә канның агуының, әлбәттә, мөнәсәбәте бар. Ләкин көннәр һәммәсе дә Аллаһе Тәгаләнең көне булганга, бу мөнәсәбәтләрне тәгъйин итәргә тыйб галимнәре ирешә алмаганнар. Аллаһе Тәгалә бу серне анлардан яшергән. Шулай булса да, көннәр өчен дә сәбәпләре мәгълүм булмаса да, сишәмбе вә якшәмбе көннәрне артык күргәннәр.

Безнең Сөннәтче бабай Сәлман Фарси хәзрәтләреннән мирас тарикы берлән сөннәтчелекне алса да, Әбугалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйльме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә[1] иҗазәт алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйльменең бу кадәр нечкәлекләрене белми иде. Ләкин исәпсез-хисапсыз еллар хәзрәтләр, муллалар, мөәззиннәр берлән катнашу, анларга исәпсез-хисапсыз мәртәбә мөгез утырту, иксез-чиксез анларның каннарыны алу аңар зур тәҗрибә биргән иде. Ул да һичбер вакыт көз кан алмый, кыш мөгез салмый иде. Ул да һичбер вакыт айның тулысында мөгезене истигъмаль итми[2], җәйнең кызуында кан балтасыны тамырга сукмый иде. Ул да һичбер вакытта баш көнендә яисә шимбә көнендә кан эшенә тотын-

---

[1] *Симия, кимия* — алхимия, химия.

[2] *Истигъмаль итү* — куллану, файдалану.

мый иде. Ул кан өчен вакытыны, көнене исәпләп, аены, сәгатене саклап тора иде.

Менә шул көн җитә башлагач, хәзрәт мәхдүм аркылы яисә хезмәтче аркылы Сөннәтче бабайга, буш көн (сишәмбе көн) кан алырга керсен, дип хәбәр иттерә иде. Сөннәтче бабай мөгезләрене җылы суда кат-кат юа, кан тамырына чаба торган балтасыны үткәрә, мөгез астына суга торган пәкесене ныграк очлый иде. Ул шул көн җиткәч, тагы, кияү булып кергәндәге күлмәкене, Кәбир хәзрәттән калган әдрәс камзолыны, мәхдүмәдән килгән кәләпүшене киеп, ап-ак чүпрәккә төргән мөгез салу әйберләрене күтәреп, иртәге чәйне эчкәч тә, хәзрәткә китә иде. Хәзрәт аны үзе каршы ала, остазбикә тасларга җылы суларны үзе хәзерли иде. Хәзрәт, тәһарәт алып, кан алу хакындагы хәдисләрне укып, салават әйтеп, килеп утыра иде. Сөннәтче бабай, тагы бисмилла әйтеп, салават әйтеп, хәзрәтнең арт чигәсене бик йомшак кына иттереп кыра иде дә, тагы бер салават, тагы бер бисмилла әйтеп, пәкесенең очы берлән чиртергә тотына иде. Каннар агып, хәзрәтнең муенына төшә башлагач, ул, мөгезне куеп, аның башындагы тишегеннән һаваны суыра да, шуның тишегенә ябар өчен бәйләтелгән сарык имчәкене юешләтеп, тишекне ябып куя иде дә икенче чигәгә чиртергә тотына, аны да шул юл берлән эшләп, мөгез утырта да, шунларның тулганыны көтеп тора иде. Шул вакытта хәзрәт Сөннәтче бабайдан элгәреге заман хәзрәтләре хакында сораша; ул да элгәреге Кәбир хәзрәт, Сафа хәзрәтләрнең кан алдырулары хакында, бер мәртәбә тәбәрәк Кәбир хәзрәтнең кан алдыргач һушы китү кыйссасыны, шуннан абыстай мәрхүмәнең хәзрәтенә кан алырга рөхсәт бирмәвене сөйли иде. Һәрвакыт шул хәбәр сөйләнеп бетүгә мөгезләр кан берлән тула иде дә, тагы бисмилла, салават әйтеп, Сөннәтче бабай, мөгезләрене акыртын гына алып, әүвәлдән хәзерләнгән савытка сала да, катык кеби каткан кара канга карап: «Сөбханалла, хәзрәт, күз тимәсен, каныңыз бик бозылган, кап-кара!» — дия иде. Сөннәтче бабай, тагы мөгезне утыртыр өчен, урыныны карый, теге җәрәхәтләрнең кайсыберсе бетәшкән булса, тагы чалгы пычагының очы берлән аркылы-торкылы чиртә иде дә тагы мөгезне утырта, тагы иске заман кешеләре хакында сүзгә керешә иде. Монысында да кан кара чыкса, Сөннәтче бабай: «Машалла, хәзрәт!» — дип, тагы хәзрәтнең канының бозылуы хакында сөйли, хәзрәт тә, шул бозык канны чыгарып бетерер өчен, тамырдан кан алдырырга уйлый башлый, ләкин һәрвакыт шул

мәсьәләгә килгәч: «Мөгез салдыру сөннәт булса да, кан алдыру бидгать[1] түгелме?» — дип, пәйгамбәремезнең кан алдыруы хакында ачык ривайәт күргәне юкка, шөбһәләнеп, торып, шүрлектән китап алып, китап карарга тотына, шуның хакында ривайәт тапканча маташып, шуннан соң гына разый була иде. Сөннәтче бабай, сул яки уң кулының терсәкене бөкли торган җиреннән кара тамырыны табып, тагы: «Бисмилла!» — дип, салават әйтеп, балтасы берлән чаба, кан чәчрәп чыгып, фонтан булып түшәмгә таба ата башлагач та, җиз тазга хәзрәтнең кулыны бора, үзе тагы, чыккан бер канның суынып-каралып катканыны күргән саен: «Машалла, машалла, хәзрәт, каның бик бозылган икән, кап-кара!» — дип, хәзрәткә сөйли; хәзрәт, шул бозылган каннан котылыр өчен, һаман агыздырганнан-агыздыра бара иде. Гадәттә ике-өч чүмеч кадәр агызсалар да, кайсы елларны хәзрәтнең каны бик бозылып киткәнгә, күбрәк тә агызалар, агарга куйган җиз таз тулгач кына тамырны нык-лап бәйләп туктаталар иде. Шуннан соң хәзрәт юынырга тотына. Сөннәтче бабай каннарны күтәреп чыгып, мәхшәр көнне азып-тузып, ияләрене эзләп йөрмәсеннәр өчен, һәр елны күмелә торган, бала-чага маташмый торган почмакка чокыр казый иде дә салават әйтеп күмә иде. Шуннан соң абыстай хәзерләгән самавыр янында чәй эчәләр иде. Сөннәтче бабай хәзрәткә, канны йомшартыр өчен, пешкән каймак ашарга, канны сыеклатыр өчен, лимон берлән чәй эчәргә мәслихәт итә иде. Замана башка булганга, халык ул вакыт таза булганга, хәзрәткә шул кан алдыру начар тәэсир итми иде. Ләкин күп вакытта шул кан алу аңар әллә нинди файдалы булып, җиңеләйтеп тә җибәрми иде. Әүвәл көннәрне бераз башы әйләнеп йөрсә дә, ул бик тиз элгәреге хәленә керә, аз гына да куәте кимегәнене сизми иде. Кан алганнан соң һушы китеп егылу-лар-фәләннәр хәзрәт берлән булмый иде. Чәйдән соң Сөннәтче бабай, дога кылып торып, чәйгә рәхмәт укый, хәзрәт тә, мәшәкатьләнүенә рәхмәт укып, Сөннәтче бабайга берәр бүләк бирә иде. Сөннәтче бабайның мәшәкатьләнүе «бә ризаи Аллаһе Тәгалә» булган кеби, хәзрәтнең да бирүе «бә ризаи Аллаһе Тәгалә» иде. Бу бирүләр, алулар, хәзерге, безнең замандагы кеби, докторга яисә акушеркага бирү кеби, эш хакы түләү түгел, бүләк бирү иде. Шуның өчен күп вакыт хәзрәт Сөннәтче бабайга акча бирмәенчә, йә бер-ике генә юган күлмәк бирә,

---

[1] *Бидгать* — ярамый торган, тыелган эш-гамәл.

яисә моннан дүрт кенә ел элек алынган читегене тоттыра, яисә Әхмәди хаҗи бүләк иттереп хаҗ мөбарәктән алып кайткан мисвәк[1] шәрифне бирә иде. Сөннәтче бабай бонларның һәммәсене дә бик зур разыйлык берлән алса да, мисвәк шәрифкә аның кәефе тагы күбрәк килә иде. Ул аны Гөлйөзем әбигә кайтып мактаткан кеби, бик саклап кына тота, аны мич янындагы иң кадерле җиргә куя иде.

Сөннәтче бабайның бу бәйрәме дә үтеп китә, ул, тагы иске киемнәрне киеп, иске тормыш берлән яши башлый иде. Ул вакытта җәдиде-кадиме, гәзите-мәзите, думасы-бумасы юк; ул вакытта мәктәп, мәдрәсә мәсьәләсе, тел мәсьәләсе, муллалар, яшьләр мәсьәләсе юк иде. Һәр мәсьәлә хәл кылынган, һәр агымга юл билгеләнгән иде. Һәр кешенең вазифасы бер-берсеннән аерылган иде.

Яңа эш, яңа хәбәр юк иде. Аның юклыгы да хис ителми, аның кирәклеге дә сизелми иде. Тормыш һәммә җирдә бер форма алган, шул формасыннан бара, шул алган китешендә, җәйге җилсез көнне ашъяулык кеби, тип-тигез ага торган Идел кеби ага иде. Аңар каршы торган буа юк, аның агымыны тирескә сөрергә теләгән һавалы җил дә юк иде. Тын иде, тыныч иде; тынычлыкның очы юк иде.

*

Шул тынлыкта гомер үтеп килгәндә, шул тынлыкның очы, төбе күрелмәгәндә, бер көнне иртә берлән хәзрәт йоклап ятканда, Сөннәтче бабай, ишекне кагып, хәзрәтне уятты. Калтыраган, каушаган тавыш берлән, бабай:

— Хәзрәт, хәзрәт, карчык авырып китте. Ясин укырга рәхим итмәссеңме? — диде.

Хәзрәт, Сөннәтче бабайны юатып: «Иншалла, кичәр, суык тигәндер»,— дисә дә, күңеленнән чыннан да куркып китте. Тиз генә тәһарәтләнеп, бабай берлән китте. Гөлйөзем әбине яктан якка бәрелә-сугыла торган, «Алла, Алла!» дип ыңгыраша торган рәвештә тапты, бик ихлас берлән ясинны укыды, бик озын иттереп дога кылды. Сөннәтче бабайны тагы юатып, чыгып китте.

Кайтып җитү берлән, самавыр берлән көтеп тора торган остазбикәгә хәлне сөйләгәч, ул да курыкты. Ул, чәене эчәрэчмәс, хаҗ шәрифтән килгән, балалар авызландырырга тотыла

---

[1] *Мисвәк* — теш чистарту өчен махсус таякчык.

торган хөрмәне алып, кечкенә генә савытка пешкән каймак салып, хәл белергә китте. Күрше Гадилә әби берлән бергә самавыр куеп, мәтрүшкә дә эчертте. Салават шәриф укып, хөрмәдән дә авыз иттерде. Үзе дә дога кылып өшкереп, Гөлйөзем әбине рәтләп яткырды. Өйлә тәһарәте берлән хәзрәт тарелкага зәгъфран берлән аяте шифа да язып җибәрде. Күрше хатыннары берлән абыстай, Гөлйөзем әбине тәһарәтләндереп, аны да эчерде.

Ләкин Гөлйөзем әби җиңеләймәде. Ул икенде намазыны тәяммем[1] берлән генә, хәзрәтнең рөхсәте вә фәтвасы[2] берлән утырып кына укый алса да, ахшам намазыны бөтенләй кыла алмады. Ул, башыны күтәрә алмаенча, кай вакыт иссез, хәлсез булып киткәнгә, Сөннәтче бабай, башына җыелган бозык каннарны чыгарыр өчен, кан алмакчы да булды. Ләкин шундый зур эшне эшләүдә көне, ае тугъры килмәенчә, гөнаһлы булмас өчен, ахшамнан соң хәзрәтне күреп сорады. Җәйнең эссе ае булганга, хәзрәт баштан ук: «Ярамый, канның сыекланган чагы»,— дип рөхсәт бирмәде. Бабай бик йөдәткәнгә: «Тагы бер-бер ривайәт булмасмы, китапта бер-бер кыйль вә каль[3] булмасмы, яравына ривайәт юкмы»,— дип, бик озак китап караса да алдыруның файдасына һичбер дәлил таба алмады.

Хәзрәт ясту намазына тәһарәт алып бетерергә өлгермәде, Сөннәтче бабай килеп, егълаган тавыш берлән:

— Хәзрәт, бик авырайды, телдән калды,— диде.

Хәзрәт, аның авыраюында, телдән калуында үзене гаепле итеп хис иткән кеби булганга, тиз-тиз китеп киенде. Абыстай да, тагы бераз зәмзәм, кипкән инҗир, имбир алып, аның артыннан калмады.

Ясинны хәзрәт никадәр ихлас берлән укыса да, абыстай да никадәр ихлас берлән шул дарулары берлән даруларга тырышса да, Гөлйөзем әби берсене дә каба алмады. Ул кәчкә-кәчкә генә бер-ике тамчы зәмзәм суыннан башка берсене дә йота алмады. Күршенең Мәрфуга әби, Гадилә әбигә төнләргә калдырып, хәзрәт берлән абыстай кайтып киттеләр.

Ләкин иртә берлән таң атар-атмас Сөннәтче бабай килеп, хәзрәтләрне уятып:

---

[1] *Тәяммем* — су булмаганда кулларны туфракка сугып тәһарәт алу.

[2] *Фәтва* — нинди дә булса бер эшне эшләү дини яктан дөресмегүгелме икәнен күрсәтеп бирү.

[3] *Кыйль вә каль* — имеш-мимеш, төрлечә юраулар.

— Карчык дөньяны куйды! — диде.

Сөннәтче бабай шул сүзне әйткәндә һәм дә иртә берлән мәсҗедтә намаздан соң халыкка: «Җәмәгать, карчык дөньяны ташлаган иде, кабер казырга ярдәм итешсәңез лә»,— дигәндә дә тавышында, кылынышында әллә нинди кайгылылык беленмәде. Кылынышларында хәтта бер бәйрәмгә хәзерләнү кеби әллә нәрсәдер сизелде.

Бөтен авыл кабер казырга китте. Бөтен авыл хатыны Гөлйөзем әбинең өстенә җыелдылар. Иртәнге чәйне эчкәч үк, абыстай да китап сөйләргә китте. Бик озын иттереп, үлем хакында, кабер газабы хакында, оҗмах, тәмуг хакында китап сөйләгәннең соңында, Гөлйөзем әбигә үзе кәфен кисте. Карт мөәззин хатыны, су коеп, үзе Гөлйөзем әбине юды. Хаҗ җиреннән килгән Мәрьям аңа чәчене (хөрмә агачының мунчаласыны) зәмзәм суына үзе манып биреп, кәфенне тектерде.

Җеназа да өлгерде. Бөтен авылның картлары тәһлилгә[1] җыелды. Гөлйөзем әбинең әллә кайчан хәзерләп куелган унике тастымаллары тәһлилгә өләшелде; кәфенне бәйләргә куелган кызыл башлы өч сөлгесе хәзрәтләргә бирелде. Сандыгыннан чыккан илле баш берәр тиен ярымлыклар, егерме биш баш өч тиенлекләр җыелганнарга таратылды. Мәсҗед янына җыелган дүрт-биш йөз кеше җеназасыны укып озатты. Җомгага кадәр күмелеп бетеп, хәзрәтләр Сөннәтче бабайның өендә актык фатиханы да кылдылар. Җомга намазыннан соң хәзрәт бөтен мәсҗедтән һәүл[2] намазыны да укытты. Сөннәтче бабай барысында да бик нык кылынып, үзенең кайгылылыгыны артык сиздермәде йә сизенмәде. Җомгадан чыгуга ул хәзрәтләр берлән ашка да барды. Анда да шактый ашады, эчте.

Менә өенә кайтып китте. Әллә никадәр күрше карчыклары берлән тулган канәфер мае исле өй аны бердән башына суккан кеби кабул итте. Ул, ишекне ачып керү берлән, шул канәфер мае исе борынга керү берлән, карчыгының, Гөлйөземенең, шул, үзе берлән илле, алтмыш, җитмеш ел яшәгән карчыгының юклыгыны, аның тагы бер мәртәбә кайтмый торган җиргә киткәнлегене, аның үлгәнене белде. Ул, шундагы сандык өстенә утырып, бик озак дога кылырга тотынды. Аның карт йөзеннән мөлдер-мөлдер яшь агарга тотынды. Ул, бик озак дога

---

[1] *Тәһлил* — «Лә иләһә иллаллаһ» («Аллаһтан башка гыйбадәт кылырлык зат юк») дигән җөмләне күп тапкыр кабатлап әйтү.

[2] *Һәүл* — мәет күмелгән көнне кичен укыла торган намаз.

кылып: «Ярабби, карчыгымны гафу ит, гөнаһларыны кичер!» — дип, йөзене сыйпады. Шуның берлән ул үзенең күз яшьләрене дә тәмамларга теләсә дә, яшьләр туктамады. Ул, аның үлүенә ышанмаган кеби, өйнең бөтен җирләрене карап бетерде; бер кемне дә [күрә] алмады. Бакчасына чыкты. Анда да бер әсәр-галәмәт күрмәде.

Ул, шунларның һәммәсенә ышанып, өенә кереп утырырга өлгермәде, ишекнең тышкы ягында әллә нәрсә тырмаша башлады. Ул: «Гөлйөзем әбинең рухы килде»,— дип куркып китеп, ишекне ачты. Үзләренең соры мәчеләре килеп керде. Ул, «мәү, мәү!» дип, әле анда барып, әле монда килеп, әллә нәрсә эзләп йөри башлады. Бик озак маташканның соңында ул Сөннәтче бабайның янына килде дә, күзенә карап: «Мәү-ү!» — диде. Сөннәтче бабай мәченең шул кычкыруында аерым ачык: «Әби кайда?» — дигән сүзне аңлады. Сөннәтче бабайның каткан күзеннән тагы яшь агарга тотынды. Ул мәче берлән сөйләшергә тотынды:

— Әбиең үлде, үлде. Оҗмахка китте, дога кыл,— диде.

Мәче, әллә нәрсә аңлаган кеби, тагы: «Мәү-ү!» — диде.

Сөннәтче бабайга карчыгы төсе — шул мәче бик якын кеби тоелды. Ул аның савытына сөт салды. Ләкин мәче берәр генә кабып караса да ашамады.

Сөннәтче бабай, мәченең дә кайгырганыны күреп, шуннан котылыр өчен, йортка чыкты. Аның күзенә, берсе артлы берсе тезелеп, ана үрдәкнең командасы астында менеп килә торган үрдәкләр күренде. Ул, анларны ашатыр өчен, анларга әбиләре үлгәнене белдермәс өчен, өйалдыннан ярма алып чыгып сипмәкче булды. Моны күргәч, үрдәкләр тагы: «Бак, бак!..» — диярргә тотындылар. Сөннәтче бабай бонларның бакылдауларында да: «Әби кайда?» — дигән сүзне аңлады. Шул уйдан котылыр өчен, ул капка төбенә таба чыгарга өлгермәде, хәзрәтнең угылы килеп, аны чәй эчәргә чакырып алып китте.

Анда да бербуйдан Гөлйөзем әби сөйләнсә дә, остазбикәнең тәмле чәене эчеп, татлы ашларыны ашап, Сөннәтче бабай азрак күңелене юатты.

Ул, икенде намазыны укып, өенә кайтты. Зур мөгезле карт кәҗә аны кычкырып каршы алды. Ул аның мөгез арасыны кашыды, аны сөйде. Ләкин кәҗә, җилененә сөт тутырып кайтканга: «Савыңыз!» — дип, әбисенә кычкыра башлады. Сөннәтче бабай тагы чыдый алмады: тагы күзеннән яшь акты. Менә күрше килене килеп, кәҗәне саварга тотынды. Кәҗә,

саудырмаска теләмәсә дә, бик ямьсез тавыш берлән: «Минем сөтемне урлыйлар, минем сөтемне талыйлар, әби, кил!» — дигән кеби, кычкыруыннан туктамады.

Сөннәтче бабай, ахшам намазына барыр өчен, тәһарәт алырга комган эзләргә тотынды. Комганның куйган җирендә булмавы тагы аның исенә карчыгыны төшерде. Ястүгә кадәр ул ялгыз Коръән укып, дога кылып үткәрде. Ястү намазыны укып, гомерендә җәймәгән урынны үзе җәеп ятты. Ләкин түшәк, ястык аңар ят күренде; ул урын каты тоелды. Өе, шул Сөннәтче бабай өйләнгәннән бирле торган өе, үзенеке түгел, кешенеке кеби сизелде. Ул белгән бөтен догаларыны укып йокларга теләде. Тагы янында карчыгы юклыгы аны уятты. Ул бик озак уйлады, үзенең яшьлегеннән алып бүгенге көнгә кадәр уйлады. Көн буе йөреп арыган тән аруына баш аруы да катышты. Ул йокыга китә башлады. Менә кәҗә кычкырды. Аның кычкыруында бабай тагы әбине сагынуын аңлады. Тагы йокы качты; тагы уйлар, тагы кайгылар...

Менә таң якынлашты. Сөннәтче бабай йокыга киттемеюкмы, ансы мәгълүм түгел — ул ап-ак күлмәктән, күлеп кенә, Гөлйөзем әбинең: «Карт, намаздан каласың!» — дигән тавышыны ишетте, төсене күрде. Ул, сикереп торып: «Әлхәмделилла, әһле җәннәттән икән»,— дип, ян-янга карарга тотынды. Чынын да намаз вакыты бик җиткәнене сизеп, торып, тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәткә төшене сөйләде. Хәзрәт:

— Оҗмах әһеленнән икән,— дип, тагы бабайны кәефләндерде.

Ләкин өйгә кайткач, ул тагы ялгызлык хис итте, тагы аны шул киң зур өй кыса, изә башлады. Ул, өендә утыра алмаенча, капка төбендә, күршеләр янында бакчада тора башлады. Кич берлән һаман ялгыз йокларга өйрәнмәде. Шул ялгызлыкның изүенә хәйлә таба алмады.

*

Бер төнне Сөннәтче бабай әллә нинди ямьсез төшләр күреп уянып китте. Бөтен тәненең туңганыны күреп, юрганына тагы бөтереленебрәк ятты. Ләкин ни кылынса да аркасыны җылыта алмады. Ул әйләнде-бәйләнде, урынны төзәтте, ләкин аркасы җылынмады. Әүвәле йокыга киткән кеби булды, тагы аркасы туңып уянды. Тагы калыкты, тагы уянды. Менә аркасының туңганыны белеп, ярты йокы, ярты уяу көенчә: «Карчык,

карчык!.. Арканы җылыт!» — диде. Үзенең тавышыны үзе ишетеп, уянып китте. Шул тавыштан куркып, йокысы качты. Тагы күңеленә Гөлйөзем әбинең үлүе, аның, мәрхүмә, һәрвакыт Сөннәтче бабайның аркасыны җылытып йоклатуы исенә төште. Шул рәхәт көннәрне исенә төшереп, аның аркасы тагы туңа башлады. Ул тагы Гөлйөзем әби хакында уйларга тотынды. Уйлый-уйлый, ничектер, «тагы өйләнергә» дигән фикер башына килеп керде. Элгәре ул шул фикерне башыннан ташламакчы булса да, ләкин уй, бизгәк кеби, аны ташламады. Арканың туңуы шул фикергә куәт бирде. Ул минут саен куәтләнә. «Өйләнергә кирәк, өйләнергә кирәк»,— дип уйлый башлады. Бик озак йоклый алмаенча уйлап торганның соңында, ул өйләнү фикеренә килде. Килде генә түгел, шул уйдан аерыла алмады. Ул, бер күрше малаенда күргән уенчыкны аталарыннан таптыра торган тирес бала кеби, шул уе берлән бөтенләй томаланды. Ул шул карардан соң яшәреп киткән кеби булды, аның искедәге киткән яшьлек көчләре кайткан кеби булды. Ул, урынына ятып, шул өйләнүләрне уйлый башлады. Үзенең әүвәлге өйләнүе, бикәчкә билбавының очыны яшереп баруы, ишек бавына кызыл яулык бирүләре, җилән ябынган яшь бикәч берлән бергә ашка йөрүләре, туйлары, уеннары — һәммәсе бөтен вакларына кадәр күз алдыннан үтте. Ул тагы шунларның ләззәтене яңартып ләззәтләнде. Шул вакыттагы шатлыкларны хәтердән үткәреп, тагы рәхәтләнде. Менә ул тагы өйләнә, тагы аңар шул вакыттагы кеби кызык, күңелле була...

Ул, шул уй берлән җанланып, аркасы туңганыны да хәтереннән чыгарып, вакытыннан иртә тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәт берлән сөйли-сөйли, хәзрәтләргә кадәр барып җитте. Чәй янында да шул сүздән туктамады. Хәзрәткә, абыстайга элгәре шул яше онытылган бабайның «өйләнәм» дип йөрүе көлке кеби тоелса да, Сөннәтче бабайның шул уй берлән саташканыны күреп, каршы килүдә мәгънә юклыгыны сизеп, яткан ягына сыйпарга тотындылар. Сөннәтче бабай, тәмам яшьләр кеби, авылдагы тол хатыннарны санарга тотынды. Бик файдалы, кыйммәтле кияү кеби, әллә никадәр тол хатыннарны яратмаенча үтеп китүе хәзрәт берлән абыстайның элгәре бераз исене дә китәрде. «Әллә гакылдан бераз яздымы?» дигән фикергә дә төшерде. Ләкин башка хәрәкәтләре берлән бик гакыллы күренүе тагы анларны ул фикердән кайтарды. Сөннәтче бабай элгәре яучы булырга хәзрәтне яисә остазбикәне кушса да, бабайның күңеле бик югарыдан бул-

ганга, төрле хәйләләр табып, хәтта хәзрәт, иске әүлияләрнең үзләре өчен үзләре яучы булуларыны сөйләп, үзенә баруны мәслихәт итте.

Бабай да, шул сүзне колагына элеп, белгән догаларыны укып, күңеленә иң яраган иске мөәззин хатынына таба китте. Мөәззин хатыны абыстайның җиткән угыллары барлыгыны да хәтеренә китермәенчә, мөәззин хатынының кияүгә барырга теләү-теләмәвене дә уйламаенча, туп-тугъры барып керде. Сөннәтче бабайны күргәч тә, мөәззин хатынының угылларының угыллары чыр-чыр килеп: «Кисә, кисә!» — дип качыштылар. Анлар артыннан кызлары да: «Кисә, кисә!» — дип, почмакларга постылар. Мөәззин хатынының ялгыз гына калуыны ганимәт[1] белеп, Сөннәтче бабай тугърыдан-тугъры сүз салды. Карт остазбикә, элгәре исе китсә дә, Сөннәтче бабайны азрак гакылга җиңеләйгәндер ахры дип: «Утыр, утыр»,— дип, сүзне башкага борырга теләде. Ләкин карт һаман үз сүзеннән кайтмаганга, «Әлхәмделилла, фәкыйрь түгелмен: арышым да бар, кәҗәм дә бик сөтле, бу ел сөннәт тә шактый күп»,— дип, үзенең яхшы якларыны сөйләп торганга, моның чынлап йөрүене аңлады һәм дә: «Рәхмәт!» — диде дә, ничек иттереп — бабаймы әллә башкачамы әйтергә аптырап торып:

— Минем ул фикерем юк. Ирем мәрхүмгә вәгъдә бирдем. Балаларым да үсте. Менә шуларның балаларыны тәрбия кылып гомер үткәрәм инде,— диде.

Сөннәтче бабай тагы үзенең Сәлман Фарси нәселеннән икәнен сөйләнсә дә, ул да тәэсир итмәде. Сөннәтче бабай ясалган чәйне дә эчмәенчә чыгып китте. Чыккан вакытта күңелендә бер төрле хурлану, ачу килү хисе булса да, шул остазбикәнең сүз кайтаруы Сөннәтче бабайның бәгъзе планнарыны бозса да, ул, урамда уйлый-уйлый, ул фикер берлән да килешеп, түбән очта тегермәнче Фәхринең хатынына китте. Илле-илле бишләрдәге тегермәнче хатынының йортта чебешләр ашаткан җиренә тугъры килеп, хәл-әхвәл сорашып, янына утырды; сүзне бик озаклап, читтән китереп тормаенча, тугърыдан-тугъры:

— Миңлесафа, мин сиңа яучылыкка килдем,— диде.

Шул сүзне ишеткәндә теге хатынның тавыклар, әтәчләрне куарга тоткан чыбыгы кулыннан төште. Шуны гына көтеп торган тавыклар, әтәчләр ябырылып алып, чебешләрнең азыгыны ашарга тотындылар. Теге, аптырап-катып торганның

---

[1] *Ганимәт* — уңыш, бәхет.

соңында, бабайның туктамый сөйләгән сүзләреннән элгәре аның җиңеләюенә хөкем итте. Бара-тора ул фикердән дә кайтты, ләкин ни дип җавап бирергә дә, ничек кайтарып җибәрергә дә сүз таба алмады. Уйлый төшәргә вакыт күбрәк ясар өчен: «Утыр, хәзер киләм»,— дип, лапас астына җәйгән урынга күрсәтте; үзе базга төшеп, каймаклы катык алып чыгып, бабайның алдына куйды. Бабайның ашый-ашый сүзендә дәвам иткәнене дә күреп, карчык ничек шул ямьсез сүзне бетерергә юл эзләргә тотынды. Ул, мөәззин хатыны кеби:

— Угылым, кызым җиткән; ир тәрбия кылырлык хәлем юк,— диде.

Сөннәтче бабай моңар тагы, анда тормыш тормыш түгел — оҗмах икәнлегене сөйләсә дә, ахырдан гына үзенең Сәлман Фарси нәселеннән икәнлегене аңлатып, кыямәт көне Сәлман Фарсиның шәфагате берлән оҗмахка керү мәгълүм икәнлегене белдерсә дә, карчык әйткән сүзеннән кайтмады.

Сөннәтче бабайның шактый ачуы килеп, чыгып китте. Ул хәзер ары яктагы кызында тора торган сөлгече карчыкны сорарга китте. Ләкин сөлгече карчыкның тасма тел кызы, бабайның сүзене ишеткәч үк, бабайны кадерсезләп-кадерсезләп тиргәргә тотынды.

Аннан да бабай бер җылы сүз ишетә алмаенча, күптән түгел генә иреннән аерылып кайткан кырыклы-иллеле бер хатынның энесенә тугъры китте. Хатынның килене, артык тамактан котылыр өчен, Сөннәтче бабайның сүзене бик ипләсә дә, энесе каршы бер сүз дә әйтмәсә дә, карчык үзе якын да килмәде.

Сөннәтче бабай, юл буенда тугъры килгән тагы берничә җиргә кереп, һәммә җирдән җылы сүз ала алмаенча, өметсез өенә кайтты. Иртәгесен дә шуның артыннан йөрсә дә, тагы өметле сүз ишетмәде. Ләкин бонларның берсе дә бабайның эссесене сүндермәде. Киресенчә, аңарда шул фикерне куәтләндергәннән-куәтләндерде. Ул күрше авыллардан сораштыргалый башлады. Күрше карчыкларына-картларына үзенә карчык табарга үтенде.

Менә килеп-килеп карчыклар димләргә тотындылар. Кайсы ул авылда, кайсы бу авылда; бик һәйбәт, бик яшь-фәлән дип мактадылар. Биш-алты сөаль берлән бу карчыкларның һәммәсенең дә торырга урыны юк, фәкыйрь, карт, зәгыйфь, эшкә ярамаган икәнлекләрене аңларга мөмкин булса да, Сөннәтче бабай, өйләнү уе аркасында андый эшләрне онытып бетергәнгә, андый кирәкмәс эш берлән вакыт үткәрмәде — карчыкларның

һәммәсене яратты, һәммәсенә разый булды. Ләкин берсе әллә нигә күңеленә күбрәк ошаган төсле булды.

Баш коданың сүзе берлән килүендә дә шөбһә булмаганга, ул былтыргы сөннәттән калган ике капчык арышны сатып, күршедән ат алып, теге әдрәс камзолны киеп, күрше авылга да китте. Карчык күңелгә бигүк тулып бетмәсә дә, ит юкта үпкә тансык дигәнчә, бабай разый булды. Хәзрәтләр дә чакырылды, никах та укылды. Моннан соңгысыны бабай никадәр әүвәлге туена охшатырга теләсә дә охшамады: карчык берлән сөйләргә сүз табылмады; табылса, әллә нигә ул кадәр кызык булмады. Сәлман Фарсины карчык аңламады, карчыкның җеп җерләвеннән бабай бер ләззәт ала алмады. Карчыкның кардәшләренә кунакка бару да әүвәлге кеби күңелле чыкмады, кич үткәрүнең мәгънәсе элгәрегечә булмады. Бабай, шунларны аңласа да: «Менә үз өемә килгәч Гөлйөзем кеби үк булыр, аның үлгәне сизелмәс тә»,— дип күңелене юатты.

Иртәгесен карчыкның агач сандыгыны, бер комганыны арба артына бәйләп, карчыкның тавык йонынннан ясалган ястыгыны астка салып, карчыкны янына утыртып, бабай туй төшерде. Бөтен шартлары тулсын өчен, ул, тавык суеп биреп, карчыгына аш хәзерләргә кушты. Үзе кибеттән дөгесене, җимешене алып кайтып, хәзрәтләрдән икендегә кадәр фатиха кылып чыгарга вәгъдә алды.

Вакыт җитте. Хәзрәтләр килде. Аш өлгерде. Коръәннән соң бабай бүлмәдән алып шурпа бирде. Шурпаның өстендә йөзеп йөри торган пешмәгән суганнар бабайга әллә нигә мәхәббәтсез кеби тоелды. Хәзрәтләрнең сүзе берлән ул үзе дә утырды. Менә аш башланды. Гөлйөзем әбинең шурпасыны табакның төбенә кадәр ашый торган хәзрәтләр берәр капкач та кашыкны куйдылар. Бабай шөбһәләнде, бисмилла әйтеп, ашны капты. Тозсыз, борычсыз, чи суганлы. Идел суы илле батман иттереп пешерелгән шул аш аз-аз гына костырмады. Ул, халыкны кыстап тагы бер-ике капса да, артык өнди дә, кашыгыны суза да алмады. Аш алыштырылды; бәлеш чыкты, өсте ачылды. Кирпеч төсле каткан ярмага мөәззин никадәр шурпа сипсә дә, ул эремәде. Төбенә кадәр ашалып бетмәгәнгә, мөәззин төбене кисмәде дә. Менә тутырган тавык; ул, туп эченә тутырып дошман гаскәренә атып, аның крепостены ватарга ясаган кеби катырылган; киселгәч, йомыркалар беләү кеби ялтырап торалар; тозлылыгыннан авызга кабарлык түгел. Ул гына булса ярар иде, эче әрчелеп бетмәгән: кабырга төбендә әллә никадәр канлы

былчырак нәрсәләр калган. Сөннәтче бабай, кайнап торган самавырны күрсә дә, тагы мыскыл булмас өчен:

— Хәзрәтләр, шуның берлән тәмам,— диде.

Сөннәтче бабай хәзрәтләрнең: «Алла хәерле гомер бирсен, тигезлек берлән гомер үткәрергә язсын!» — дигән догаларны ишетсә дә, күңеленнән Гөлйөзем әби китмәде. Ул, шул тәмсез ашлар, шул, халык алдында мыскыл иткән карчык — Гөлйөзем әбинең бәддогасы дип ышанганга, өенә кире кайтмаенча, зияратка китте. Бик озак Коръән укыды, бик озак дога кылды. Күңеле бераз урынына утырып, ул өенә кайтты. Баягы ашларның буш табак-савытлары янында, кайнаган самавыр алдында карчыгыны җимешләп чәй эчкән көенчә тапты. Ул, аның янына утырып, чәй эчә башлады. Аның бер сум алтмыш тиенгә алган чәеннән дегет исе, әллә нәрсә тәме сизенеп, ул аз гына сикереп тормады:

— Ник бу кадәр тәмсез? Ашың килешмәгән иде, хәзрәтләр бер дә ашамадылар. Минем мәрхүм карчык заманында тамчы аш калмый иде,— диде.

Карчык, бик зур эш берлән мәшгуль кеби, чәй эчүендә дәвам итте. Картка каршы бер сүз дәшмәенчә, кәҗә сөте алып кереп, чәенә салып эчә башлады. Сөннәтче бабайның әллә ничә еллардан бирле өйрәнгән гадәтләренә илтифат итмәенчә, үзе теләгәнчә кылына торган шул затсыз карчык аны җирәндерде. Ул: «Намаз җитте»,— дип, тәһарәткә су сорап алды. Ни күзе берлән күрсен, комганында лакшәләр йөзеп йөри! Ул, тагы ачуланып, тешене кысып:

— Казанны пакь тотмаган өйдә бәрәкәт булмый,— дип, пакьләргә кушып, намазга китте.

Кич берлән ул тагы карчыгыны кәҗә сөте берлән бәлеш төпләре ашаган вакытта очратты. Аңар ачуы килүе бетмәде — ул самавыр янына бик зур бер табак бәрәңге китереп куеп ашарга тотынды. Бабай шул ашау казаныннан әллә никадәр җирәнде. Икенче чәйнеккә чәйне үзе пешереп, берәр чынаяк чәй эчеп ятты. Ләкин карчыкның мыш-мыш йоклавыннан җирәнеп, ул таң алдына кадәр йокыга китә алмады. Аның туңуы да онытылды.

Ике атна вакыт үтмәде, Гөлйөзем әбинең тарихы онытылган көннән бирле керткән тәртипләре бозылды. Аның заманасында сары гәрәбә кеби ялтырый торган идәннәр мәдрәсә әчелеге хәлене алды. «Английский пыяла»дан ясалган кеби ялтырый торган тарелкалар уңмаган хатынның алъяпкычы

төсенә керде. Әби заманасында йөзендә аллы-гөлле кояш уйный торган самавыры казан төбе кеби катты. Чынаякларның тоткалары, чәйнекнең капкачлары маңка малайның борыны төсле булды. Әби заманасында пөхтә итеп җыелып куелган мендәрләр урынында карчыкның сәләмәләре өстерәлә башлады. Көз якынлашкан булса да, әллә кайдан әллә никадәр чебен тулды. Анлар, «жу-у-у!» итеп торып чәйгә, ашка төшеп бабайны җирәндергән кеби, бөтен диварларны, сөлгеләр, салфетларны былчыратырга тотындылар. Сөннәтче бабай Селкенчек Фәхриләр өендә генә очраткан сасы ис бөтен өйне тутырды.

Йорт эчендә дә элгәреге низам вә интизам[1] бетте. Әби заманасында йомыркасы бар чакта кырылдап хәбәр бирә торган, салып бетергәннең соңында бик озынлап кыткылдап белдерә торган Караколак, Чуар, оя төбе тавыклар да кайсы качып сала башладылар, кайсы читкә киттеләр. Һәр көнне кич берлән көтү кергәндә өйдә була торган үрдәкләр, казлар да су буенда тузылып куна башладылар. Кәҗә дә — әби берлән бабайны ун ел ашаткан, ун ел аларга кәҗә тәкәләре, кәҗә бәрәннәре үстергән кәҗә дә үзгәрде: аның да сөте азайды, сыекланды. Бөтен кышка җитәр дип торган бәрәңгенең яртысы көз кермәс борын бетте. Бөтен кышка дип бабайның хәзерләп куйган утыны эләгеп кенә калды.

Шунларның һичберсе дә Сөннәтче бабайга яхшы тәэсир итмәде. Ул, карчык берлән орышышмаса да, талашмаса да, шул аз вакытта элгәреге, тарихсыз вакытында үткәргән гомереннән картайды. Аның биле тагы бөкрәйде, чәченең агы әллә нинди ямьсез акка әверелде. Ул озын-озын «уф, уф!..» иттереп сулый башлады. Ләкин шунларның барысы да карчыгы Гөлйөзем әбинең хәтерене калдырган өчен Аллаһе Тәгалә тарафыннан җибәрелгән бәла дип ышанганга, шул казага сабыр итте. Бөтен гомерене өендә, йортында үткәргән Сөннәтче бабай ике атнада өеннән, йортыннан бизде: ярты вакытыны мәсҗедтә, ярты вакытыны урамда уздыра башлады; мөмкин кадәр өйдә ашамаска, эчмәскә, өйдә утырмаска тырыша башлады. Ул, оясыны былчыраткан каз кеби, иртәдән кичкә кадәр өенә керергә курыккан кеби, өе тирәсендә әйләнә башлады. Аның бөтен рәхәте, тынычлыгы бетте. Ул һәр көнне, күңелене юатыр өчен, карчыгының каберенә барып, Коръән укырга тотынды. Кабер янында бик озак утырып, һәр көнне карчыгы берлән бергә

---

[1] *Низам вә интизам* — тәртип һәм кагыйдә.

үткәргән гомерләрене уйларга тотынды. Һәр көнне, карчыгы бу көн генә үлгән кеби булып, егъламаенча кайта алмады.

Менә бер көнне карчыгының зияраты азрак басылган кеби булды. Иртәгесен бабай балта-көрәк алып килеп, яңа чирәм берлән өстене япты. Тагы бер көнне барганда әбинең зияраты янында бер бозау ятканны күреп, бабай кабер тирәсене тотарга уйлады. Һәр көнне өйдән акыртын гына агачлар, такталар ташып, зиярат тирәсене чәверде. Ләкин ахырына җиткәндә генә бер-ике такта җитмәгәнгә, бетмәенчә калды. Бабай иртәгесен, күп уйлап тормаенча, җилкапкасыннан сүтеп алып, эшләп бетерде. Шул койманың кадакларыны дүртәр-бишәр мәртәбә какты. Алай да, эш беткәч уйлап торып, өстенә агач утыртырга төшенде. Бакчасындагы кеше буйлык, түгәрәкләнеп килә торган каенны утыртырга уйлап, элгәре ике көн бик һәйбәт иттереп урын хәзерләде. Аннан соң, каенның тамырыны кисмәенчә алыр өчен, ерактан иттереп казып алырга бер-ике көн вакыт үткәрде. Ул да бетте, агач та утыртты. Агач, утыртып бетергәч тә, акыртын гына искән җил берлән иелеп-сыгылып, моң гына тавыш чыгара башлады. Бабай, шуны күреп, шатланып китте; агачның зикерене[1] ишеткән кеби, моңаеп тыңлап утырды. Шуннан соң һәр көнне кич берлән агачка су китереп сибүне гадәт итте.

Менә бер көнне бабайның моңаеп кына су сибеп кайтканын остазбикә күреп, малай йөгертеп, чәй эчәргә борып кертте. Ул, остазбикәдән оялган кеби, тагы бөкрәебрәк кенә килеп керде. Остазбикәнең тәмле чәе, һәйбәт ачы күмәче, балы аңар тагы карчыгыны исенә төшерде. Ул, әллә ничә көн чәй эчмәгән кеше кеби, бик тәмлеләп-тәмлеләп эчте. Эчә-эчә бераз кәефе дә килде. Ләкин шул чәй, шул ачылган самавыр, шул ялтырап тора торган чынаяклар тагы аңар карчыгыны исенә төшерде. Остазбикә дә, хәзрәт тә, бабайның ярты гомерене зиаратта үткәргәннән бабайның карчыгыннан разый түгеллегене белгәнгә, элгәре Гөлйөзем әбине сөйләп картның җәрәхәтене ачмаска теләсәләр дә, остазбикә, әллә ничек:

— Карчыгың исәнме? Нишләп тора? — диде.

Сөннәтче бабай, иң авырта торган җиренә суккан кеше кеби, бердән чырайларыны сытты, кашыны чытты. Әллә нәрсәгә бик зур көч сарыф кыла башлады. Ләкин картның күзеннән яше ага башлады. Бабай кычкырып егълап җибәрде:

---

[1] *Зикер* — Алланы олылауга багышланган доганы әйтү.

— Сөйләмә, остазбикә, карчык бәддогасы...— дип, егълап, кайгысыны тиште.

Берәм-берәм бөтен кайгысыны сөйләп бетергәч, бабай азрак җиңеләеп китте. Ахырдан хәзрәт берлән бу елның сөннәте тугърысында да сөйләште. Бик ихлас берлән кырыгынчы, йөзенче мәртәбә үлем хәлләреннән, Мөнкир, Нәнкир[1] килүләреннән, кабер газабыннан, оҗмах нигъмәтләреннән сорашты. Ахырдан гына, куркып кына:

— Хәзрәт, терек кешегә кабер казырга ярыймы?— дип, хәзрәттән фәтва сорады. Хәзрәт, әллә нинди бер әүлиянең үз каберене үзе казуыны сөйләгәч, бик зур бер мәсьәлә хәл кылган кеби, шатланып кайтып китте.

Иртәгесен ул, карчыгының аяк очында җир табып, акыртын гына эшкә башлады. Шуннан соң һәр көнне килеп, карчыгына Коръән укып, каенына су сибеп бетергәч тә, бисмилла, салават әйтеп казырга башлады. Акыртын гына иттереп, тәмле нәрсә ашаганда аз кабып ашаган кеше кеби иттереп, аз-аз гына казыды. Ләкин никадәр аз казыса да, көн үткән саен тирәнләп, сары балчыкка килеп җитте. Яэҗүҗ-Мәэҗүҗдән бабай бик курыкканга, сары балчыктан тирәнгә төште. Менә эш ләхеткә җитте...

Ул, өйлә намазыннан соң тәһарәте кыстар төсле кеби тоелганга, өйгә кайтып тәһарәтләнеп барырга уйлап, өйгә таба борылды. Күрше йортка көзге ат көтүе бирергә җыелган җыен янына килеп, сәлам биреп, мәсҗед картлары берлән сөйләшеп, акыртын гына өенә юнәлде. Ишекне ачты. Түр башында карчыгының бәрәңге арчып утырганыны күрде. Күзе карчыкның кулындагы былчыранып беткән пәкегә төште. Аның кулында сөннәт пәкесе икәнене күреп, элгәре катып калды, ахырдан ул җенләнгән кеби булды: кычкырырга, бакырырга тотынды, кулы берлән бәреп җибәреп, пәкене алды, үзе кычкырып егъларга тотынды. Аңар әллә кайдан көч керде. Кычкырып-кычкырып тиргәргә, кулы берлән бутанырга башлады:

— Чык өемнән, бәдбәхет, чык өемнән! Сәлман Фарси пәкесе, Сәлман Фарси пәкесе! Ни диермен?! Кыямәт көнне ни җавап бирермен?! — дип, егъларга, карчыкның кулына очраган сандыгыны, комганыны, ястыгыны йортка ыргытырга тотынды, тагы кычкырды, тагы бакырды, тагы егълады. Елан чаккан кеше кеби, кая барырга белмәде, егълап урамга чыкты. Күр-

---

[1] *Мөнкир, Нәнкир* — мәетне күмүчеләр киту белән, үлгән кешедән сорау алучы фәрештәләр.

шедәге халыкка: «Җәмәгать, җәмәгать!» — дип, бик каты иттереп кычкыра башлады. Бөтен җыен, ут-фәлән бар дип, бабайга таба ашыкты.

Бабай:

— Менә, җәмәгать, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе!.. Җитмеш мең мөселманның сөннәткә утыртылган пәкесе!.. Хәзрәти Аксак Тимердән калган пәке ул!..

Ул, шул сүзне әйткәндә, өенә төртеп күрсәтте:

— Шул пәке берлән, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе берлән бәрәңге арчый!..— диде дә тагы егъларга тотынды.

Халык бабайны төрлечә бастырырга теләсә дә, бабай һаман кызганнан-кызды. Ул бөтенләй тилергән кеби булды. Ул, өенә таба барып, йорттагы карчыгыны күреп:

— Кит, шайтан!.. Гөнаһ шомлыгы, иблис сидеге, пәри ташландыгы, күземә күренмә!.. Талак син, талак син!..— дип кычкырды.

Халык тагы бабайны бастырырга теләсә дә, ул кычкырып егъларга тотынды. Тагы әйләнеп карап, карчыкның йорт уртасында торганыны күреп, тиздән сикереп торып:

— Әле китмәде, шайтан! Дәҗҗал! Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ колы! — дип, барып казык алып сугарга күтәрде. Бер кеше, бабайны кочаклап алып, сугудан саклый алды. Карчык урамга чыгып качты. Бабай аның артыннан ястыгыны, сандыгыны, комганыны, туп уйнаган малай кеби, берсе артыннан берсене ыргыта башлады. Ул тагы егълады, тагы:

— Сәлман Фарси, шәфагать кыл! Карчыгым бәддогасы, карчыгым бәддогасы!..— дип, халыкка кайгысыны аңлатырга тотынды.

Ләкин теге карчык тагы йортка керергә өлгерә алмады, ул, тагы сикереп торып, казыкны күтәрде. Бу юлы сугарга да өлгерде, ләкин карчык качып өлгерде. Ул тагы кызды, тагы кычкыра башлады. Кулындагы пәкесене кысып, тагы әллә ниләр сөйләргә тотынды. Картлар, аны бастырыр өчен, төрле сүзләр сөйләргә тотындылар. Ул берсене дә ишетмәде.

Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Ул калтырана башлады. Ап-ак булып авызыннан күбеге агып, һушсыз булып егылды. Хәзрәт килеп Коръән укыганнан соң аның һушы килсә дә, теле ачылмады. Пәкене никадәр алырга теләсәләр дә, кулыннан ычкындырмады. Хәзрәт килгәч, ул күзе берлән әллә нәрсә эзләнә башлады, кунакларга әллә нәрсә әйтергә теләде, ләкин әйтә алмады.

Өченче көнне хәзрәт, Коръән укып бетереп, янында утырып торганда: «Әти, кунаклар килде!» — дип, әтисене чакырып мәхдүм килеп керде. Бабайның күзе нурланды; ул көлгән кеби булды; әллә нәрсә әйтергә теләгәне беленде, күзе берлән мәхдүмне чакырган кеби булды. Мәхдүм акыртын гына әтисе янына килде. Бабай тагы, күзенә әллә нинди мәгънәләр чыгарып, кулыны селкетә башлады. Мең бәла берлән кулыны күтәреп, мәхдүмгә таба төртте. Һәммә кешегә мәхдүмгә пәкесене, үзенчә, иң кыйммәтле булган мирасыннан — Сәлман Фарси пәкесене бирергә теләвене аңлатты. Мәхдүм аптырап калды. Хәзрәт алырга кушты. Алды. Бабайның йөзенә көләчлек чыкты. Ул әллә нигә шатланган кеби булды. Тагы бик авыраеп: «Алла!..» — диде дә үлде.

Үзе казыган кабергә иртәгесен бөтен авыл җыелып күмде. Күрше карты аның өстенә дә каен илтеп утыртты. Ике каен бер-берсе берлән бәрелә-бәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар.

Көзге ягъмурлы җилдә өйнең сылаганы изрәп, ул да җимерелде. Усал сыерлар, канауны җимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты. Кызыл миләшләрне җыяр өчен бөтен урам малайлары миләшнең ботакларыны сындырып бетергәнгә, ул да икенче елны яфрак ярмады. Корыды.

Бер ике-өч елдан Сөннәтче бабайның йорты урынында тормыш галәмәтеннән бернәрсә дә калмады. Ләкин зияраттагы ике картайган, черегән, беткән картларның өстенә ап-ак тузлы, ямь-яшел яфраклы яшь ике каен үсте. Алар зурайды, биекләнде, түгәрәкләнде; тавышлы-тынлы, кешеләр аңламый торган тормыш берлән яши башладылар.

Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды...

1911

УЛ ӘЛЕ ӨЙЛӘНМӘГӘН ИДЕ

Беренче танышу әле һаман аның хәтерендә.

Алар Народный домда «Фауст» куелганда күрше-күршегә тугъры килештеләр, бинокльләр бирештеләр. Иттифакый гына артистлар, уеннар, музыка хакында сүзләр алыштылар. Киемнәр киенгәндә дә бер урынга тугъры килеп, театрның

ишегеннән дә бергә чыктылар. Озату-озатмауны уйлашмаенча гына, театрда башланган сүзләрен дәвам иттереп, бергә дә киттеләр. Урам тулы халык арасында — аннан выжлый, моннан гөжли торган автомобильләр; кычкырыша-талаша торган арбачылар арасыннан үткәндә — берсенә берсе «Сез кая?» дияргә дә өлгермәделәр.

Юлны чыгып, халыктан бераз арынгачтан гына марҗа: «Минеке — уңга таба»,— дисә дә, Шәмсетдин: «Миңа да шулай»,— дигәч, тагын сөйләшүләрендә дәвам иттеләр. Сүзнең уртасында гына Шәмсетдингә аерылып китәргә тугъры килгәнгә, ул, рөхсәт берлә, марҗаны озатырга да китте. Урамның тайгакларыннан үткәндә ул куркып-куркып басканга, Шәмсетдин аны култыклады да, аулак кына тыкрыкка кереп, ике этажлы гына агач өйгә җиткәч тә, марҗа:

— Менә минем өем, рәхмәт озатуыңызга,— дип, кулын сузды.

Юлда сөйләүдән марҗаның театрга шактый йөрүе мәгълүм булганга, Шәмсетдин:

— Бәлки, әле тагы күрешермез, мин еш булам, кичләрне эш юк,— диюенә, марҗа:

— Мин дә театрны сөюче, мин әле менә «Пиковая дама»га барырга йөрим, иртәгәдән арыга куела да икән.

Шәмсетдин:

— Мин шул Александринкага билет алган идем,— диде.

— «Гроза»гамы? — дигән сөаленә «Әйе» дигәч:

— Минем дә бит аңарга билетым бар,— диде.

Шул иттифакыйлык болар арасында тагы әллә нәрсәне, мөнәсәбәттәге әллә нинди бер рәсмилекне җимерде, алар, берберсенә чыгарып, ни өчендер, билетларын да күрсәтештеләр. Урыннар бергә үк булмаса да, билет икесендә дә галерканың сул ягы булды.

Өченче көнне Александринкада икесе дә иске танышларча күрештеләр. Марҗаның кофтасы алсу җирлек өстендә җете кызыл юллы материядән иде. Муенының ачык җиренә эре генә гәрәбә сыман кара нәрсә такканга, аның муеннары, ияк астлары тагы алсурак, аграк күренәләр иде. Кулындагы ридикюль дә әллә нинди материядән чигеп эшләнгән булган кебек, өстендә кия торган әйбер дә теге көнгә башкача иде. Пәрдә араларында бу юлы бербуйдан бергә йөрделәр. Уеннарны тикшерделәр, бергәләп Островскийны мактадылар. Өченче пәрдә арасында, Шәмсинең тәкъдим итүе буенча, лимонад та эчте-

ләр, дүртенче пәрдәдә күрше берлән урын алышып, янәшәдә утырыштылар.

Театрдан чыккач, Шәмсетдин, бу юлы бер дә курыкмаенча, кичке ашка чакырды. Марҗа, бер дә исе китмәенчә генә, гади генә иттереп:

— Минем алай ашыйсым килми, сезнеке килсә, менә гостиницага кереп кенә ашыйк,— диде.

Анда кереп, аяк үрә генә төрле нәрсәләр капкаладылар, аяк үрә генә марҗа шоколад [ашады], Шәмсетдин чәй дә эчте.

Төн матур булганга, иртәгә бәйрәм мөнәсәбәте белән икесенә дә кибеткә чыгарга булганга, Невскийны җәяүләп үтеп, Нева ашасыннан гына арбачы алып, кайтып киттеләр.

Бу юлы Шәмсетдин аның исеменең Анна Васильевна икәнен, үзенең ике ел элек ире үлгәч, ире урынына сатучы булып кереп, хәзер киемнәр кибетендә приказчик икәнен, эче пошканнан театрга йөрергә, вечерларга барырга ярата торган күңелле хатын икәнен белеп кайтты.

Өченче очрашу тагы ярты иттифакый булды. Шәмсетдиннәрнең кибет хуҗасына фәкыйрь балалар тәрбияләр өчен ясалган балалар иртәсенә ике билет көчләп саттылар. «Иртә» булачак көн бәйрәм булса да, шимбә көн тугъры килгәнгә, Шәмсетдиннең хуҗасы, яһүди приказчиклары бармасын өчен, икесен дә Шәмсетдингә бирде. Шул ук көнне Шәмсетдин телефон берлән Анна Васильевнага өченче көнгә билет барлыгын сөйләп, вәгъдә алды.

Шәһәрнең читендәге кечкенә залда тагы очраштылар. «Иртә»дә иң күп халык балалар, бала караучы хатыннар, сирәк-сирәк кенә белеш дустлар булганга, бу ике яшь пар һәркемнең күзендә тотылдылар. «Иртә» озын гына булды. Балалар хоры, балалар оркестры бик күңелле үтсә дә, икесенең дә ашыйсылары бик килде. Пәрдә арасында пирожный берлә эчелгән чәй дә тамак ялгарлык булмаганга, чыгу берлә тиз-тиз ашханә эзләргә тотындылар вә беренче очраган польский столовойга кереп ашарга тотындылар. Ашыйсылары бик килгәнгә, Шәмсетдин берсе арты берсе төрле ашлар күтәртеп ташытып торганга, бик күп ашадылар. Ахырдан, өчәр тиенлек кызыл кесәлдән соң кофе эчәргә тотынгач кына, иренеп кенә, ашыйммы икән, ашамыйммы икән дип икеләнеп, котлет ашый торган курсисткаларны, гәзитәнең тәменә манып кына җиде тиенлек борщ ашый торган студентларны күрделәр. Кофе эчеп бетереп, авызга теге ашларның тәме килә башлагач кына,

кикерткәннең соңында әллә нинди әчкелтем-төчкелтем тәмнәр килеп киткәч кенә, тегеләрнең чырайлары сытылуының мәгънәсен аңлап, өйгә таба киттеләр.

Болар урамга чыкканда Петербургның кыска көне бетеп, эңгер-меңгер вакыт кергән, урамнарга фонарьлар ягылган иде. Бәйрәм булганга, урамның буйларын халык тутырган, төрле бизәкле киемнәрдәге кешеләр, төрле төстә кычкыра торган исерек тавышлары берлән урам тулган иде. Аяк асты тайгак, халык бәрелүчән-сугылучан булганга, Анна Васильевна чыккач ук үзе Шәмсине култыклады. Икесе дә бик авыраеп киткәнгә, акыртын гына, юк-бар сүз сөйләп кенә өйләренә борылдылар. Әллә нигә, һавада торасы килгәнгә, эчтәге ашлар авырайтып басып торса да, юлның зур бер бүлеген җәяү үттеләр, Невский башына барып җиткәч тә, халыкның сугыша-сугыша вагоннарда урын алуларына да бик озак катышмадылар. Ул да ялыктыргач, алар да сугышып, кысылып урын алдылар. Кысыла-кысыла, вагончы белән талаша-талаша бардылар, вагоннан чыкканда икесе дә авызларында әллә нинди күңел болгану, сару кайнау кебек үзгәрешләр сизгәнгә, икесе дә берьюлы лимон берлән чәй эчүне уйладылар. Шәмсинең өе якын булса да, миңа керик дияргә база алмады. Рестораннарның ишегеннән үк исереклек исе, аракы, сыра сасысы килеп торганга, анда чакырырга да кыя алмады. Кич иртә булса да, өйгә кайтып чәй эчәрмен дә бернәрсә укып ятармын дип карар бирде.

Менә Анна Васильевнаның урамына җитә башладылар. Ул борылды да:

— Әйдәгез, миңа чәй эчәргә керик,— диде.

Шәмсетдин рәхәтләнеп кабул итте. Анна Васильевна берлә талашып-кычкырышып кына алма, әфлисун алды. Вареньены, конфетны Анна Васильевна алдырмады. Ишек ачылды. Шәмсетдинне киемнәр салырга калдырып, Анна Васильевна үзе алдан китте. Ул киемнәрне салырга да өлгермәде, Анна Васильевна:

— Рәхим итегез,— дип, коридорның эченнән чыкты.

Шәмси, кереп баскач та, аптырабрак китте. Озын гына, биек кенә бүлмә, тәрәзәсендә ап-ак пәрдә, уң якта ак кына караватка җете ак мендәрләр өелгән, ап-ак юрган белә өртелгән. Сул якта зур гына диван аксыл киемендә һаваланып тора. Тәрәзә янында зур гына өстәл. Аңарга ап-ак эскәтер җәелгән. Сул почмакта кечкенә генә, пөхтә генә комодта зур гына көзге, ислемайлар, савытчыклар, хатын-кыз шара-баралары, диварларда әллә

ничек кызыл материя берлән ясаган чәчәкләр, алар арасында открыткалар. Тынык һава эчендә нечкә генә, пөхтә генә бер ислемай исе. Шәмси акыртын гына кәнәфигә утырды. Шул пөхтәлекләр эчендә аның карынындагы ашлар тагы баса төштеме, йомшак кына, сөеп кенә батуы берлән кәнәфи аз [гына] иркәли төштеме, аның күзенә йокы тыгылды. Аның бөтен тәне ару хис итеп, шул кәнәфидә, әнә шул йомшак, ап-ак урыннарда ятасы, югаласы килде.

Ул арада булмады, Анна Васильевна өстке киемнәрен салып ташлады. Кечкенә генә ак алъяпма бәйләп өлгереп, чәй урыны хәзерләргә тотынды. Комодыннан алып печенье кебек нәрсәләр куйды. Варенье савытына әллә кайдан казынып варенье тутырды. Бер тәрилкәгә дөге сумсалары салды. Матур гына савыт берлән май, сыр утыртты. Самавыр килеп, чәй янына утырганда Шәмсетдин үзенең кайдалыгына хәйран булып калды. Чын, бу шул Анна Васильевна өеме, шул аена утыз тәңкә ала торган приказчик өеме?.. Ник соң ул аена алтмыш сум алса да, өендә ямь юк? Ник соң ул бүлмәсенә Анна Васильевна кебек ун тәңкә түгел, унсигезне түләсә дә, эт абзары кебек күренә? Ул чәй ясый башлады. Чәй тәмле, ашы-суы һәйбәт. Сүз ара сүз китте. Шәмсетдин, белмәенчә дә үзенең тормышын, нәселен битәдән сөйләп, кичкә кадәр утырганын тоймый да калды.

Дүртенче, бишенче очрашулар ике тарафтан да теләшеп, вәгъдәләшеп булды. Берсендә Шәмси, тагы кич берлә, үзе кереп чыкты. Берсендә кич берлән, театрга барыр алдыннан, Анна Васильевна Шәмсине алып чыкты. Шуннан соң да мөнәсәбәтләр һаман дустлык, иптәшлек даирәсеннән узмады.

Көннәр озая төшеп, кояшлар язга таба карый башлагач та, Шәмси берлән Анна Васильевна, кышның матурлыкларын чынлап татып калыр өчен кебек, кавышыр өчен, ачык һавада саф авыл тормышында көнне уздыру өчен, иртәнге поезд берлән Финляндиянең Таулар станциясенә юнәлделәр. Бик озын иттереп, берәмләп-берәмләп, икешәрләп-икешәрләп, башкалар берлән төркем-төркем булып шудылар. Тере куйны ботыннан тотып кимерерлек дәрәҗәгә җитеп ачыккач та, фин ашханәсенә кереп, фин ысулынча ачык өстәлдә ашадылар. Фин хатыннарының тәмле каһвәләрене[1] эчеп, кадерле минутларны бушка үткәрмәс өчен, тагы һавага чыктылар. Чаңгы алып, зур киң

[1] *Каһвә* — кофе.

күл өстеннән бата-чума йөгерделәр, чаптылар. Өйрәнмәгән аякларда чаңгы батты, кыекланып карны кисте. Көйләнеп китеп кенә барганда, ике аяктагы ике чаңгы берсе бер тарафка, берсе бер тарафка киңәеп китеп екты. Берсе көйләнеп киткәндә, икенчесе егылып мәдәри. Аны тотып торгызырга дигәндә, икенчесе артка чүгеп карга чумды. Ботинкаларга кар тулып, оек аша үтеп, аякларга кар кереп тәнне калтыратты. Тән җылысы берлән эреп-агып чиркандырды. Болар тагы тордылар, тагы киттеләр, тагы аудылар, егылдылар. Дәрт берлән, кәеф берлән вакыт үткәнне дә, арыганны да сизмәделәр. Күлнең ар башына барып җитеп хәл җыярга утыргач кына, бөтен өстләре кар-боз берлән катканны белделәр. Кояшның, актык нурларын салландырып, күрешеп, ап-ак кар артындагы урман эченә яшеренгәнене күрделәр. Анна Васильевна арый да төшкәнгә, хатын-кыз киеме үзе дә чаңгыга уңайсызлаганга, кулга-кул тотынып, акыртын гына, тын гына киттеләр. Вә илла Аллаһы гына фин өенә кереп егылдылар. Өйгә кергәч, арыган тән ут кебек яна башлады. Карлар эреп киемнәрне чылатты, юешләтте. Аякларны салып, киемнәрне чишенеп, киптерергә мәҗбүрият туды. Шәмси, фин абзыйның иске чалбарын, катасын киеп, чалбарларын, оекларын, ботинкаларын киптерергә элде. Анна Васильевна, фин хатынының капотын киеп калып, бөтен эчке-тышкы киемнәрен киптерергә куйды.

Арыган-талган көенчә финнең аз гына тозлы май берлән кара икмәге бик тәмле тоелды. Аның куе каймак берлән бирелгән каһвәсе телләрне йоттырды. Алар, озын иттереп эчсәләр дә, киемнәр әле һаман юешлекләрен бетермәгәнгә, суыгаеп киткән тышка юеш киемнәр берлән чыгу куркынычлы булганга, һаман өйдә утырдылар. Финнәрнең начар русча берлән «еще ного ремя»[1] дип ышандыруларына карап, тик кенә хәл җыйдылар. Киемнәр хәзер булгач, салкын һаваны ерып, ап-ак ай яктысында җем-җем елтырый торган карларны үтеп, вокзалга юнәлделәр. Вә салкын һаваның ныгайтуына, тазартуына шатлана-шатлана яшь әгъзалар берлән киерелә-сузыла барганда, поезд килеп тә җитте. Никадәр ашыксалар да, үтеп тә китте. Икенче поезд да тагы 4 сәгатьтән соң гына булганга, үзе Петербургта иртәгә иртә берлән генә булганга, иртәнге поездга чыгарга уйлап, әлеге үк финнәргә кунарга кайттылар. Урын хәзерләргә кушып, ап-ак кар дөньясында тагы бераз йөрергә, шул

---

[1] *Еще ного ремя (еще много времени)* — әле вакыт бар.

мул, тын фин дөньясының тынлыгын, бертөрлелеген тагы бераз суларга, шундагы иркенлек, шундагы кыш матурлыгында тагы бераз ләззәтләнергә булып, тын, мул, ялгыз урманга таба — шул ап-ак кар диңгезендә ямь-яшел булып тора торган урманга таба киттеләр. Аның чыршы-нарат исен иснәп, аның таза нык исенә коенып, өйгә кайтсалар, кечкенә генә кунак бүлмәсенә, зур караватка ике кешелек урын хәзерләнгән, иртәгә юыныр өчен сулар, ап-ак сөлгеләр куелган таптылар. Киң урынга икесенең дә бердән күзләре төште. Икесе дә «бу ни?» дигән кебек карадылар. Берсенең дә күңелендә, гакылында «юк, болай ярамый» дигән сүзне әйтерлек уй вә фикер тумаганга, икесе дә шул иттифакыйлыкка буйсындылар.

Иртә берлән кофе эчкәндә берсенең күзенә берсе карашырга тартынсалар да, поездга өлгерсәк ярар иде, дип ашыгып барганда аны да оныттылар. Шәһәрдә икесе ике вагонга утырышканда да бик дустча күрешеп аерылыштылар. Үзе генә калгач, Шәмсетдиннең башына: «Бу ни булды соң әле? — дигән сөаль килсә дә: — Йә, җитәр инде, бик күп фәлсәфә саттык, берни булмады. Мин өйләнмәгән бер егет, ул хөр бер хатын»,— диде дә куйды.

Вә шуннан соң боларның очрашулары тагы шул юлында дәвам итте.

Көн үтә-үтә вә никадәр бер-берсенә үзләшеп китеп, эч пошканда килү-китүләр рәсмият даирәсеннән күптән чыкса да, Шәмси һәрвакыт үзен өйләнмәгән, җае туры килгәндә өйләнәчәк бер егет итеп хис итүдән туктамады, вә шуның шулайлыгына һичбер вакытта Анна Васильевна да сүз кайтармады. Кыяфәт, кылынышы берлән дә шулай булуына кәефе киткәнен белдермәде. Ләкин ул мөнәсәбәт арткан саен, акча мәсьәләсендә элгәре күк сарыпларга[1] тотынды. Һәр вакытта да трамвай өчен, театр өчен, йөрергә барган җирләрдә ашаган-эчкән үз өлешен мотлак түләүчән булды.

Элгәре бу холкы Шәмсигә ят күренсә дә, ике арадагы мөнәсәбәтне кытыршылаган кебек күренсә дә, ул да Анна Васильевнаның теләвенә буйсынырга мәҗбүр булды.

Яз җитеп, Петербургның иксез-чиксез сасылары, тузаннары дөньяны сарып алгач, зур шәһәрнең бәхетле бәндәләре җәйләүләргә, авылларга китсәләр дә, Шәмси дә, Анна Васильевна да эссе көннәрдә бөркү магазиннар эчендә утырдылар; тузанлы

---

[1] *Сарыпларга* — сарыф итәргә, тотарга.

төннәрдә дүрт ягы дүрт диварлар белән капланган таш капчык кебек бүлмәчекләрдә җәйләрен үткәрделәр. Язның матур көннәрендә, июнь, июльнең чәчәк, үлән, гөлгә баткан көннәрендә, хуҗалары, зур приказчиклары хәл җыйганга, тын алганга, болар икесе дә шәһәрнең ике очында ике магазинда диварлар сакладылар. Икесе дә эссе көндә, куе тузанлы шәһәр һавасында табигатьләре бозылган алучыларның кылынышларына, капризларына ярый-ярый әлсерәделәр, арыдылар. Әллә нидә бер килгән бәйрәмнәрдә генә йә Финляндиягә барып, йә Кронштадт кебек җирләргә пароходта йөреп килеп, җәйнең матурлыгы, яшь тормышның ачык һавада күңеллелеген күреп, теләүләрен генә кытыклап, кызыгып кына кайттылар.

*

Июльнең урталарында хуҗалар, зур приказчиклар кайтып, болар тын алырга вакыт җитсә дә, ике магазин да Мәкәрҗәгә киткәнгә, төне-көне эш китте. Анна Васильевна июльнең егерме бишләрендә котылып калып, беренче сентябрьгә кадәр хәл алырга рөхсәт алса да, Шәмси илла Алла гына Мәкәрҗәгә китмәенчә калып, беренче августсыз бушый алмады. Икесе дә арыган, икесе дә түнәсе бу көнгә охшаган тормыштан туйган булганга, шул бер айны бергәләп җәйләүдә торырга карар бирделәр. Вә Анна Васильевна, үзенең бер ике-өч көн бушлыгыннан файдаланып, Финляндиянең Петербургтан ерак кына бер станциясеннән, тимер юлдан ун-унике чакрымнар бер җирдә, зур бер күл якасында, караңгы тирәк, нарат урманы буенда кечкенә генә, пөхтә генә дача алып та кайтты. Вә көн буе кибеттән кибеткә йөреп, бер айга җитәрлек кирәк-яракны төяп, Шәмсине көтмәенчә күчте дә китте.

Иртәнге поезд берлән Шәмси үзе корзиналар, чемоданнар, мендәрләр төянеп Мустамаки станциясенә килеп төшкәндә, Анна Васильевнаны платформада тапты. Ул хәзер генә килгән булырга кирәк, аның йөзендә әле һаман өлгерәмме-юкмы дип омтылу сызыгы бетмәгән иде. Өстендәге юкадан тегелгән җәйге киеме, башындагы шытырдатып басылган кырым эшләпәсе никадәр ят булса, аның төсе-бите дә шулкадәр үк ят иде. Аның йөзенә әллә нинди кызару чыккан, күзләрендә шатлыкны яшерә алмаенча нур түгелеп тора, селкенүенә, йөрүенә, кылынышына тизлек, егетлек кушылган. Ул Шәмсине:

— Синнән шул, шәһәр исе килә,— дип каршы алды.

Үзенең алып килгән финнең арбасына әйберләрне төятте дә, юлга чыктылар. Түгәрәк кенә, кечкенә генә фин аты юлдан йомгак кебек тәгәрәргә тотынды. Күз ачып күз йомылмады, арба яшел урман эченә чумды. Аз гына юешлек кушылган нарат исе Шәмсинең борыннарыны кытыкларга тотынды. Менә кечкенә генә ялан, тәбәнәк кенә куакларын сырып алган кара җимешләр әлмисактан бирле[1] шуларга тагылган кебек тик торалар. Әнә марланып[2] киткән бер җир; аның түбәсе, тирә-юньдәге суган башлары аерылыбрак, саргаебрак тора, аның уртасында — кып-кызыл яфраклар арасына сибелгән кан кебек кызыл җир җиләкләре.

Урманның кырыенда зур-зур борынлы миләшләр, алар тармакланып, ботакланып бөтен тирә-юньне тутырганнар; аларның бөтен ботаклары алсу кызыл миләш сабаклары берлән бизәкләнгән; аларның яфраклары шул миләш мәрҗәннәреннән оялгангамы, үзләре дә кызылга буялганнар, үзләре дә кызыл тәннәрен кояшка күрсәтеп җемелдәп торалар.

Менә тау, озын гына тау. Фин аты, шуны гына көткән кебек, йомылып-йомарланып тауга таба, ямь-яшел урманнарның өстенә чыгарга теләгән кебек, тауга таба чаба гына. Әнә тау өстендә ялан. Анна Васильевна, сулга таба күрсәтеп:

— Менә без хәзер Финляндиянең иң биек җирендә. Әнә диңгез... Күрәмсең? Еракта-еракта сыек кына, моң гына пәрдәгә төрелгән зур бер аклык... Аның кайбер җирләре кояшка таба ялтырый, кайбер җире, үзенең дәрәҗәсен төшермәс өчен кебек, һаваланып тик ята... Әнә тегене күрәмсең: бормалы-бормалы озын күл. Аның суы, дөнья яратылганнан бирле бер мәртәбә дә селкенмәгән, хәрәкәтләнмәгән кебек, тынлыкка, тынычлыкка баткан. Аның шул һавалы тынлыгына исе киткән кебек, тирәсендә озын наратлар шаккатканнар да калганнар. Бер ягындагы киң ямь-яшел ялан да, шул моңлы матурлыкны бозмас өчен, күбәләген дә, кошын да очырмый... Аның уртасыннан ага торган, көмеш ука кебек ялтырап яткан су да ташка бәрелеп шылтырамый-чылтырамый, ярларына сугылып шауламый-гөрләми; кая барасын әллә кайчан белгән кебек, сузылып кына коела-агыла. Әнә шул яшел дачаны күрәмсең? Шул безнеке... Әнә шул урман эченнән башын гына күрсәтеп

---

[1] *Әлмисактан бирле* — дөнья яратылганнан бирле.

[2] *Мара (диал.)* — калкулык өсте, кашлак җир.

тора торган, әнә шул иртәнге кояшка каршы тәрәзәсе уйный торган. Анда да тынычлык, анда да моңлык.

Ат кызуланганнан кызуланды. Юл урман эченә кергәннән керде. Моңлык, тынлык Шәмсинең бөтен әгъзаларына, тамырларына кадәр үтте, сеңде. Бердән урман авызыннан ат борылды, югарыга таба күтәрелеп куелган киртәләр арасыннан үтеп, курчак өе кебек дача янына килеп туктады.

Анна Васильевна, тәтиләрен күрсәтә торган бала кебек, иң әүвәл Шәмсигә дачаны күрсәтте. Өч бүлмәле дача, астында урманга зур террас карап тора. Югарыда киң зур чарлак, аңардан зур.

Шәмси бер карады, ике карады: шуның үзләренеке булуына ышанмады. Бер карады, ике карады: шул дачада икәүләп, эш эшләмәенчә, тик торырга, хәл җыярга көчләре җитүенә инанмады. Бер карады, ике карады: айның ае буенча кибеткә чыгып, аршинлап үлчәп мал сатмаенча торырга булуга күңел урынлаша алмады.

Күзе җәйрәп яткан күлгә, аның тынлык-моңлыгына төште. Ул, ашыйсы-эчәсе килгәнне дә онытып, коену дәртенә чумды. Анна Васильевнаның корзинадан чишеп күлмәк-ыштаннар алганын да көтмәенчә, суга чапты. Авызына килгән әллә нинди татарча җырны җырлый-җырлый чишенде, сызгыра-сызгыра суга керде.

Әллә ни эшләгән кебек, кычкыра-кычкыра, тавышлана-тавышлана йөзде, чумды, быкырдады, быгырдады.

Шәһәрнең крахмаллы күлмәкләрен салып ташлап, Анна Васильевна хәзерләп куйган җәйге җиңел күлмәкне киенеп, аякка чәпелдәвек киеп, терраска хәзерләнгән чәй янына килеп утыргач кына, чын да, үзен-үзе дачада итеп хис итте. Чәй янына куелган өйдә пешерелгән кара җиләк бәлеше берлән суганлы, йомыркалы сумсалар шул фикерне тагы ныгытты. Шул пөхтә аш яны, шул матур өйне бер мәртәбә күздән кичереп, шул ят марҗага шул кыска гомерне шулкадәр матурлавы өчен ни дип рәхмәт әйтергә белмәенчә, Анна Васильевнаның күзләренә карады — аның үзеннән-үзе разыйлык, бәхетлелек чыккан күзенә карады. Анна Васильевна, шул карашларның ни икәнен аңлаган кебек:

— Син разый? — диде.

Шәмси, сүз берлән әйтеп аңлатырга көче җитмәгәнгә, Анна Васильевнаны бик озын иттереп суырып үпте. Пирогларны мактый-мактый ашый-ашый, иксез-чиксез чәй эчте. Әллә

ниләр сөйләде. Күлдән, чәйдән соң йортка чыккач, әллә нигә уйныйсы, көләсе килеп китте. Ул Анна Васильевна берлән куыш уйнады, качыш уйнады, туп уйнады, таган атынды. Эт булып арып беткәч кенә, хәл җыяр өчен генә ятса да, тиз эрегәнен, йокыга киткәнен сизми дә калды.

Күзен ачып җибәргәндә агачларның шәүләләре озая төшкән иде. Агач яфраклары, агач ботаклары арасында бер җире капланып, бер җире ап-ачык булып челтәрләнеп күренә торган күлнең төсе зөмрәд[1] төсен алган иде. Дачадан башлап күлнең агымына кадәр сузылган яшел үләнгә бик нечкә генә чынлап җентекләгәндә күренми торган сөрен[2] сибелгән иде. Теге якта нарат урманы өстенә кыеклап кына, нечкә пәрдә кебек сыек кына ак болыттан флёр[3] ябылган иде. Күлнең кырыеннан нарат урманының янында ярылып күренгән сап-сары арпа кыры алтын кебек башаклары берлән ялтырап тора иде. Җире, үләне, суы шундагы сагыз исенә исергән иде. Шундагы нарат-чыршының яшеллегенә, яшьлегенә, матурлыгына кызыккан-күнеккән дә тынын-тышын бетереп шаккаткан иде. Эре-эре миләшләрнең кызыл тамчыларына кәефләнә торган, ара-сыра гына күренә торган кош-кортлар да шул ук тынлыкка хәйран калган иде.

Шәмси бик озак күккә карады. Андагы бер-бер селкенә торган ноктаны эзләде. Зөмрәд кебек күгендә дә, сыек ак болытында да кыймылдау таба алмады. Шәмси бик җентекләп урманга күзен текте. Таза егет кебек билен бөкмәенчә тора торган нараты, суыктан куркудан җирдән башлап ук ботакларга чормалган чыршысы, кып-кызыл миләш тамчылары берлән бизәнеп, кырык итәкле күлмәк кигән авыл кызы кебек, тармаклары берлән дөньяга җәелгән миләше дә, үзенең яфрагы ваклыгыннан, чын зифа түгеллегеннән, ботаклары түгәрәкләнеп килеп, зонтикланып, ак тәнен кояштан саклый ала алмавыннан оялып-хурланып, кечерәеп кенә агач арасына яшеренгән каенда да күз кабагы тарткан кадәре дә селкенү дә, хәрәкәтләнү дә күрә алмады. Әйтерсең лә барысы да мәрткә киткән!

Менә Анна Шәмси янына килде. Ул атласа да, аяклары берлән җиргә басса да, аның аягыннан да тавыш чыкмады. Ул

---

[1] *Зөмрәд* — зөбәрҗәт.

[2] *Сөрен* — сөрем.

[3] *Флёр* — үтә күренмәле юка тукыма; берәр нәрсәне каплап тора торган серле нәрсә.

сөйләсә дә, көлсә дә, кычкырса да, аның да тавышын шундагы тынлык бетерде, урлады. Ул, Шәмсинең ялан башын сыйпап:

— Йокладыңмы? Аш өлгерде, тор! — диде.

Шәмси тагы иренеп-иркәләнеп ятарга теләсә дә, Анна Васильевна кулыннан тотып, ярты өстерәп төшерде. Үзе:

— Аш хәзер, тиз бул, әнә су,— дип, өйгә юнәлде.

Шәмси салкын су берлән юынып, тәнендәге ялкаулыкларны өстеннән төшерү өчен кызу-кызу хәрәкәтләр ясап барганда, Анна Васильевна миләш төбендәге өстәлгә аш урыны хәзерләгән, ап-ак ашъяулык өстенә тәрилкәләр, чәнечкеләр, салфетлар куйган иде. Ул барып утыргач та, Анна Васильевна: «Мин сине монда финчә ашатырга уйладым»,— дип, беренчегә салкынча тозлы гөмбә бирде. Шулпа берлән ашар өчен гөмбә кыстырып ясаган сумсалар китерде. Икенче тәрилкә ит шурпасын тутырып салганны күргәч, Анна:

— Ашыкма әле, тагы аш бар, капыл туеп калма,— диде, үзе ашханәдән барып лимон берлән кыздырылган форель балыгы алып килде.— Менә бу шул күлнең балыгы, син йоклагач кына алдым әле. Бер балыкчы үтеп бара иде,— диде.

Шәмси форельдән дә артыграк капкалый башлагач, Анна Васильевна:

— Тагы туеп куйма,— дип, ашханәгә барып, балык, бәрәңге берлән кыздырылган тәкә ите китерде. Аз гына тозлаган кечкенә-кечкенә кыярлар куеп, Шәмсигә үзе салып бирде. Аш ашалып беткәч, тагы күгел сыман каралып тора торган кара җиләктән ясаган кесәл күтәреп кайтты. Шәмсигә зур гына кесәл салып, куе каймак берлән коендырып бирде. Шәмси сөясөя ашап бетергәч, тагы берне салып бирде.

Шәмсигә бу тәмле ашлардан соң тирә-юнь тагы матур тоелды, тагы тормыш тулы кебек сизелде. Ул шул разыйлык берлән тагы гамакка барып ятарга теләсә дә, тәрилкәләр юарга кергән фин кызына әмер биреп бетереп, Анна Васильевна аны тирәюньне күрсәтергә алып чыгып китте. Алар кешесез, кош-кортсыз урман эченнән үттеләр. Өйләр кадәр ярылып ята торган гранит ташларга менеп, тирә-юньне карадылар. Урманның сыеграк җирендә кара җиләк ашый-ашый авызларын каралттылар. Ап-ачык яланга чыгып куыштылар. Тагы ике ярасына кысылган кебек томрап-карасуланып тора торган кечкенә бер күлгә барып чыктылар. Аның ярларында үсә торган зур кәкре миләш агачларыннан миләш җыйдылар. Юлда очраган зур бер бакчага кереп, кура җиләге, карлыган сатып алдылар. Арасына

бер-берен төреп, аннан берничә чүлмәк резеда, башка гөлләр алып, розадан букет эшләттеләр.

Йөри-йөри арып беткәч кенә, ашыйсылары-эчәселәре килгәч кенә урманнар арасыннан, күрелмәгән дачалар яныннан өйгә кайтып киттеләр. Фин кызы кайнатып куйган самавырны Анна Васильевна югары терраска хәзерләде. Әллә кай арада пешереп өлгергән кура җиләге берлән чия җиләк вареньелары китереп чәйгә утыртты.

Югарыдагы күлнең өстенә мәнзарә[1] ачыла иде. Аның өсте элгәреге тигезлек, тынлыкны югалтмаенча да, аның тирәләрендәге агачларның шәүләләре күлгә таба киткәнгә, аның кырые ике яклап яшел яфраклы агачлар берлән каймаланган булып күренә иде. Теге баштагы ак дача, көзге кебек ак шәүлә төшереп, су эчендәге ап-ак зур дачага кушылып китә иде. Уң яктагы дачаның әле бер тәрәзәсе, әле бер тәрәзәсе төбенә төшкәнгә, кояшның нуры берлән чумып, алтынлап күзне чагылдыра иде. Ул бердән кып-кызыл яна торган ут кебек булып кызыктыра, бердән кызылсу көзге кебек булып күзне камаштыра иде; бердән озын кызыл нурларын җибәреп, күлдә шуларны икешәрләтә, өчәрләтә иде. Күлнең теге тарафыннан килә торган кызыл көймәдәге ак кием кигән кыз берлән акрын гына ишә торган егет тә ике көймә кебек селкенәләр; ишкәкләре янындагы энҗе кебек тама торган тамчылары кояш нурында ялтырап-ялтырап җемелдәп китә дә, ишкәк тавышы шул зур тынлыкта югала иде.

Күлнең кырыйларында сикерә-сикерә уйный торган балыклар да үзләреннән соң түм-түгәрәк сызык калдырсалар да, ул сызык киңәеп-зураеп югалганча китсә дә, аларның да көмеш аркалары кояшка каршы ялтырап сәлам бирүләре күренсә дә, аларның да суга чылт итүләре дә шул тынлыкта бата иде.

Менә кояш урманның артына яртылый яшеренде. Күлнең теге тарафындагы дачаларның югарыгы тәрәзәләре, күлдән читтәге фин авылының бөтен күзләре нурга чумды. Еракта гына яшеренеп торган өйләр, дачаларның тәрәзәләре кызыл алтынга манылды, әле генә тып-тыныч күренгән яшел урман, аның арасындагы яланнар ут берлән янарга тотынды. Яшел җирлекнең бөтен урыныннан яшеренеп кенә ята торган тормыш кояшка күз кысарга башлады.

---

[1] *Мәнзарә (манзара)* — табигать күренеше, вакыйга.

Менә акрын гына бер җил исте. Аның артыннан, өстеннән, ерактан гына үтә торган күк күкрәү кебек тавыш моң гына бер үтте. Дача тирәләрендәге агачлар башларын иделәр, буйлары берлән салландылар, китәчәк кояшка сәлам җибәрделәр. Күл кытыршыланды, аның шадралары берсен берсе куа-куа теге очка таба киттеләр. Күлнең тирәсендәге каймалар озайды, сузайды. Дачалардан төшкән шәүләләр дә әле батып, әле чумды, тагы нурларын чәчеп башын күтәрде. Күл буендагы ялтыраган утлар әле берсе, әле берсе сүнә башлады. Урманга яшерелгән дачалар аркылы фин авыллары тагы шул яшеллеккә чумды. Мәңгелек караңгы урман тагы аларның барлыгын-юклыгын яшерде. Еракта-еракта гына урман өстеннән күренә торган ак дачаның гына бер тәрәзәсен кояш сөюеннән туктамады: аерыласы килмәгән яшьләр кебек, ул аңарга нур өемнәре җибәрде, һаман күз кысты. Менә ул да моңайды, ул да сүнде. Шуны гына көтеп торган кебек, өстеннән яшел сыман чәчәкләр таратып, бер йолдыз йөзә башлады. Аңар кызыкты булырга кирәк, күлнең бу башында тагы берсе моң гына нуры берлән йөзә башлады. Алар артыннан икенчеләр, өченче, дүртенчеләре китте. Озак үтмәде, бөтен күл өсте йолдыз берлән тулып, бөтен күлнең буеаркылысында йолдызлар кисешә-кисешә, ярыша-ярыша йөгерешә башладылар. Кайсылары, иптәшләре, кардәшләре килгәнне көткән кебек, шул күлнең эчендәге асыл ташлар, хикмәтле серләрне карап торган кебек, тик бер җирдә катып тордылар.

Менә тагы бер җил үтте. Йолдызлар күлгә чумдылар, баттылар, югалдылар. Тагы башларын күтәреп, өстләрендәге суларын төшерер өчен тирбәлделәр, селкенделәр, нур чаткылары аттылар. Урман да тагы шаулады, тагы улады. Әллә кая гына, ерак кына бер кош та кычкырды. Урман артыннан, мәйданга көрәшергә чыга торган батыр егет кебек, тулып килә торган ай чыкты. Ул, шундагы элек чыккан йолдызларны куып җитәргә теләгән кебек, кызулап йөзәргә кереште, үзенең юлын яктыртыр өчен, күл өстенә ак нурдан озын багана ыргытты. Ул яшь кызларның агарта торган киндерләре кебек яшел урман өстеннән дә сузаеп китте... Күлгә якынрак агачлар тагы юанрак шәүләләр ташладылар. Ап-ак көмешкә әйләнгән яфраклары берлән алар да суда коена башладылар.

Шәмси берлән Анна көймәгә төштеләр. Элек алар зәңгәрсу нур чәчә торган йолдызны күлдән куып җитмәкче булдылар. Алар аның юлын ярып киттеләр. Оста йолдыз, ярып килә тор-

ган көймәне күргәч тә, юлын кызулатты. Ул оста үрдәк кебек күлгә чумды, әле көймәнең бер ягына посты, әле бер ягына чыкты. Алар айның нур баганасына ярып керделәр. Аны бер уңга, бер сулга калдырып үттеләр. Менә койрыкта Анна ай юлында көймәне тотты.

Шәмси акыртын гына ишә-ишә ак киемнән кыегаеп койрык тота торган Аннага күзен ташлады. Аның аз гына кыегайган йөзенә аксыл көмеш төсе йөгергән, аның исе китеп еракка бөгелгән муенына әллә нинди һавалылык төсе йогылган, күзләре зур булып ачылган... Алар, әллә ни күрергә теләгән кебек, әллә ни ашарга теләгән кебек, бер җиргә текәлгән; аның төбе беткән, нурлы бер упкынга әйләнгән... Аның күршесендәге тагы бер көймәдә тагы бер Анна бара. Ул да моның кебек ак киемдә, ул да моның кебек койрык тоткан, ул да моның кебек башын каерыбрак утырган, ләкин аның йөзендә, күзендә моңлык, дәртлелек бар. Моңарда да соң нәрсә бар?

— Син нәрсә уйга калдың?..

— Калмадым... Мин тормышның рәхәте-тәменә баттым. Сөйләү, тавыш, сүз бу матурлыкны мыскыл итә,— диде.

Үзе елмайды. Ап-ак тешләре айга каршы көлде. Үзе тагы уйга, кәефкә чумды.

Шәмсинең теле селкенмәкче, авызы сөйләмәкче, аяклары биемәкче, куллары бутамакчы булды. Һәммә әгъзасы үзе белгәнчә, үзенчә шул матурлык алдында баш имәкче, кычкырып гыйбадәт кылмакчы булды. Ләкин көймәнең артына утырган ак нурга чумган гөнаһсыз шул мәхлукның ишерен гыйбадәтендәге тәмен өзмәс өчен, тавышлаган ишкәкләрне акрын гына алды, акрын гына кыегайтты, сулар тамызып кына батырды, акрын гына иште. Нурлы ай аларны кырыйга илтте. Менә баскычланып-баскычланып агачлар суга бөгелгәннәр.

Юк, түгел, алар тамырлары берлән бер-берсенә кушылышып суның эченә таба, өстенә табан үскәннәр. Эченнән-тышыннан яфраклары, миләшләре ай яктысында агара төшкән. Эченнән-тышыннан сыек кына караңгылык киенеп, ботаклары-чыбыклары юаная төшкән. Әнә ап-ак дача да су кырыена кертеп салынган. Әнә кырыйда да, су эчендә дә ул озаеп, урманга кушылып киткән. Әнә ул су эченнән тәрәзәләрен ачкан. Әнә ул су өстендә дә, су эчендә дә ишекләрен ачып кунак көтә. Әнә аның чарлагында кечкенә генә ут елтырый, киләчәк кунакны каршы алырга хәзерләнеп елтырый. Әнә аның ишеге тагы ачылды, ике якка ике кыз чыгып басты. Әй, бу теге пәри

патшасының сарае бит әле. Бу нурлы юл бит, шуның сихере берлән ясалган, кешеләрне алдап китерә торган юл бит. Әй, аның матурлыгы кызыктырып алдар өчен ясаган җен бит!

Аның күзе тагы Аннага төште, тагы аңарга күрше көймәдәге моңлы Анна күзгә ташланды.

Ул аның йөзендәге моң, күзендәге дәртне аңлады.

Шәмси бердән ятьрәк иттереп ишкәкне батырды, бөтен көчен сарыф итмәсә шул сихерле юлдан чыга алмас кебек иттереп, сул кул берлән җырып ай эзеннән чыкты. Көймә селкенде, су шадраланды. Анна, башын борып: «Ни булды?» — дип карады. Шәмси, үзенең юктан курыкканлыгын сизеп алып, шаркылдап көлде. Аннага яртылый сөйләде дә тагы көлде. Аңарга урман көлеп җавап бирде.

Ул, батыраеп китеп, сызгырып җибәрде. Урман яфракларыннан үтеп, фин ялаларын[1] күреп, сызгыру кире кайтты. Ул әллә кайчан ишеткән бер башкорт җырын хәтерләде. Озын иттереп, моңландырып көйләргә, җырларга тотынды. Тавыш, ачык күл өстендә тәгәрәп китеп, урманга барып керде. Урман «һу» дип сузып җавап бирде. Ул бер көйдән икенчегә, өченчегә күчте.

Үзенең бөтен репертуарындагы җырларын җырлап бетерде. Ләкин бугаз һаман туймады, җырлыйсы килү бетмәде.

Менә Анна Васильевна җырларга тотынды. Ул нечкә генә, моң гына тавыш берлән «Вечерний звон»ны сузды. Аннаның көе, эченең әллә кай җиреннән кабынып чыккан шул тавышның иясе шул шат тормыштан разый Аннаныкы микән дип эзләгәндә, Шәмсинең күзе күршесендәге көймәдәге марҗага төште. Аның авызлары бер ачыла, бер ябыла, йөзе җыерыла, күзләре бер ноктага текәлә иде. Әнә кем җырлый икән, моның тавышы шундый моң булса да булыр шул. Аның төсе дә кайгылы, күз карашы да дәртле шул...

Әнә күлнең кыреенда аксыл-саргылт комнар киптерергә җәелгән тары кебек җемелдәп сузылып ятканнар. Әнә аның ак бөртекләре айга каршы, Зөһрә йолдызга каршы, моң гына нур чәчә торган кайгылы йолдызларга каршы күзләр кысышалар, бүсәләр[2] җибәрешәләр.

Көймә борыны берлән төртелеп комга терәлде. Шәмси, тиз үк сикереп төшеп, һаман җырлый, һаман көйли торган Анна

---

[1] *Яла (ял, җал)* — озынча тәбәнәк калкулык.

[2] *Бүсәләр* — үбешү ымнары.

Васильевнаның торганын көтмәенчә, аны кырыйга тартып чыгарды. Көймә шытырдап комны ярып керүендәге тавышларыннан Анна Васильевнаның тавышына кытыршылык йөгерде. Аның моң көе шадраланып китте. Аның башы тагы иелә төште. Аның сыны, егылмыйм дип куркып, бөгелә төште. Аның тавышы, көе дә сыныклы, бөгелмәле булып чыкты. Көймәдән чыккач, шул матур мәнзарәдән аерыла алмаенча, шул нурга коенган күлнең тәэсире астыннан чыга алмаенча, берсенә берсе тотынышып, бик озак карап тордылар. Бер-берсенә сүз дәшмәенчә, шуның матурлыгын йотып, шуның матурлыгында юанып, шуның матурлыгында оедылар, югалдылар.

Менә акыртын гына бер җил исте, күл кытыршыланды. Биткә сыек кына юешлек сугылды, борынга су исе, юеш исе бәрелде. Шул Шәмсинең, зур су буенда үскән Шәмсинең, бала вакытындагы исәпсез-хисапсыз коенуларын искә төшердеме, әллә Аннага —үзенең хәзер менә теләсә кая бара торган җил кебек хөр, әнә шул күл кебек, иңе-төбе күренми торган, айлар, йолдызлар йөзә торган күл кебек күңеле, очы-кырые күренми, беленми торган күңеле үзенең шул иптәшенә, тиңдәшенә таба өстерәдеме, алар икесе дә бердән:

— Әйдә коенабыз! — диештеләр.

Шәмси киемнәрен салып, пөхтәләп көймәгә куеп өлгергәнче, Анна Васильевна, тын суда эзләр калдырып, күлгә таба атлады. Толымлап үрелгән чәчләрен башына урый-урый тезгә кадәр керде дә алдындагы үзе кебек ак тәнле, үзе кебек ай яктысындагы нурга коенган бер кызны күреп туктады. Ул, бөгелеп, бармагы берлән аңарга таба су сипте. Теге кыз да бөгелде. Ул аңарга таба бармак селекте. Теге дә, сереңне белдем дигән кебек, бармак селкеп җавап бирде. Анна Васильевна, Шәмсигә таба борылып:

— Беттеңме? — диде.

Ай аны нуры белән кочаклап алды. Ул, аның чәченең саргылт икәнен күрсәтеп бетерерлек яктысы булмаганга, аны карагылт буяуга буяды. Аның тәненә үзенең көмеш агын куйды. Шәмси яртылый суга баткан табигатьнең бөтен бизәгәннәре берлән, табигатьнең уртасына килеп, ай берлән, йолдыз берлән үлчәшә торган Аннаны карарга өлгермәде, ул, бөгелеп, нечкә генә куллары берлән су сипте. Су бөртекләре, энҗе кебек ялтырашып, Шәмсинең тәненә тиеп, аны чиркандырды. Аның тамырлары буеннан суыклык йөгертте. Ул: «Әй!» — дияргә өлгермәде, Анна кушучлап су ыргыта башлады. Шәмси, корт

чаккан кеше кебек, бөтен көче берлән дөбер-шатыр сулар актарып, Аннага таба бара башлагач та, ул, ике кулы берлән судан юл ачкан кебек итеп, җиңел тез берлән йөгерергә тотынды; аның өстендә су бөртекләре күбәләк кебек очып, алар, ай нурына батып, тагы күлгә чумды. Икенчесе икенче төстә күтәрелде, бриллиант кебек аллы-гөлле булып ялтырады. Шулар арасында балык кебек оста, фәрештә кебек җиңел Анна суга кергәннән-керә барды. Шәмси никадәр бөтен көчен сарыф итеп алга омтылса да, суның аякны тотуларына карамаенча кулларын бутый-бутый ыргытылса да, ул һаман Аннага якынлаша алмады. Менә су тирәнләнде. Аннаның түгәрәк җилкәсе берлән, кулы берлән эшләүдән кызарыбрак киткән муены, капкара башы гына калды. Шәмси бөтен көче берлән тагы атылды. Җилкәсеннән тотып алдым дигәндә борылып көлеп карады да чулт итеп суга чумды. Шәмси бите алдында аның кечкенә ике аягы ай нурында ялтырады да югалды. Шәмси күзе берлән кая чыгуын эзләргә тотынды. Читтә генә су ачылды. Чәчләреннән энҗе кебек сулар агызып, Анна килеп чыкты. Шуны гына көткән аучы эте кебек, Шәмси тагы ыргытылды. Анна, аңар таба борылып, ике учлап су бәрергә башлады. Шәмси, авызына, борынына, колагына кергәненә карамаенча, тончыгуына, тыны бетүенә карамаенча, һаман якынлашты. Тагы, кулым җитә дигәндә, Анна суга батты. Аягының бармаклары берлән Шәмсинең аркасына тиеп кытыкландырып китте. Шәмси артыннан чумды. Су астындагы тавыш буйлап китте. Анна, судан чыгып, тын алырга өлгермәде, артыннан бик каты баш килеп аягына бәрелде. Ул куркып кычкырып җибәрүенә, Шәмси, судан чыгып, биленнән тотып алды да су өстендә аны выж-выж әйләндерергә тотынды. Аның су ага торган чәче таралды. Ул үзенең юеше берлән әле Шәмсинең битенә сукты, әле кулына ябышты. Ике аяклары су өстендә йөзеп җәзбә[1] сызган кебек түгәрәкләр ясадылар. Чәчрәгән су бөртекләре, энҗе кебек ялтырап, аның аксыл тәнен бизәделәр. Аның таркалган кара чәченә вак тәңкәләр тезгән төсе бирделәр. Аның көмеш тавышы, серле көлүе, аның «җибәр, җибәр» дип кычкырулары берлән бәрелешеп, урманга ингыйкас[2] иттеләр, аннан тагы моңрак көлү алып кайттылар. Шәмси, оста көрәшче кебек, ыргытып җибәрде. Аның тәне судан шактый югары көенчә шул аклыкны ертып

---

[1] *Җәзбә* — циркуль.

[2] *Ингыйкас* — бу урында: кайтаваз булып яңгырау.

алга китте. Аның кара чәчләре суга тия-тия сызык сызды. Аның аяклары, куллары җәйрәп китеп, оча торган кошны хәтерләтте. Ул сикергән балык кебек ярып төште. Аның төшү тавышы ерак китте. Аның тирәсендә күбекләнеп-күбекләнеп сулар очты, энҗеләр ялтырады. Зөһрә йолдызы көлеп карады. Ай вәкарьле нуры берлән тагы яктыртты. Анна, шуларны үртәгән кебек, шуларны кызыктырган кебек, кире аркан йөзеп китте. Шәмси аны барып җиткәч, бик озак бергәләп йөзештеләр. Бергә кайтып хәл дә җыйдылар. Тагы берсен берсе куыштылар. Узышып чумыштылар, узышып йөзештеләр, йөгерештеләр. Тагы су сибештеләр, сугыштылар. Тәннәре кызарды, күзләренә ут йөгерде, сулышлары авырайды, күкрәкләре кысылды, арыдылар. Киткәндә тәннәренә, иреннәренә яшел йөгерде. Аркалары буйлап суык чапты, тешләре шакылдарга керепте. Кибәр-кипмәс, берсенә берсе тотынып, чаба-чаба өйгә менделәр. Салкын аякларны керән берлән тиз-тиз генә ашап, аның өстенә фин катыгы берлән сиплэп йокларга яттылар. Айның күзен текеп юрган астына кадәр керүеннән котылыр өчен, чыбыктан эшләгән пәрдәне төшерделәр. Шул тирә-юньдәге олугъ тынлыкка болар да чумдылар.

Кояшның шактый күтәрелүенә дә карамаенча суның кичке талгынлыгы бетмәгән кебек булса да, Шәмси бердән суга атылды. Аның тазартып-ныгытып җибәрә торган агымнары тәнне, тамырларны үз ихтыярына ала алмасын өчен, ул аякларын сузып йөзеп китте. Кул берлән зур-зур ишеп, йөрәкне тиз-тиз эшләтеп тәнен җылытты, чумды, сикерде, йөзде; кире аркан ятып, сыек кына зәңгәр күккә күзен текте, әллә ни эзләде, әллә ни хәтерләмәкче булды. Менә еракта гына бык-бык иткән үрдәк тавышлары ишетелде. Ул, бик күптән эзләгән, югалткан нәрсәсен тапкан кебек, бөтен көчен колакка бирде. Бык-бык итү икешәрләнде, өчәрләнде. Әнә ерак кына урман эченә кертеп салынган бер йорттан, дачаданмы, фин өеннәнме, үрдәк кәрваны сузылып төшә. Әнә аның беренчеләре күлгә җиттеләр. Әнә алар, гомер буйларына су күрмәгән кебек, муеннарын бөктеләр, борыннарын суга тыктылар. Арттагылары, быкылдауны тагы арттыра төшеп, кызулана-кызулана ярлардан тәгәрәп төштеләр. Менә алдагысы эчеп туйды, менә ул йөзеп китте. Аның артыннан су, ерылып, ике якка ике канатын ача-ача киңәйде. Аның артыннан киткән үрдәк тагы үзенә бер юл алды, ул тагы суны бүлеп китте. Аның канатлары яныннан ярылган эзләр тагы артка таба киңәя-киңәя турайдылар,

олыгайдылар. Тагы шундый юллар берлән суның өстен тутырдылар. Юлларның канатлары берсе берсен үтеп киттеләр, берсенә берсе чәбәләнделәр. Суның өстен төрле якка киткән туры сызыклар берлән тутырдылар.

Шуларның киселүләреннән, өзелүләреннән, кушылуларыннан су өсте бизәк берлән тулды. Төрле төстәге, төрле зурлыктагы чигешләр, каймалар кояшка каршы ялтырарга тотынды. Шәмсинең башы шул бизәкләр, үрнәкләр арасында батты. Ул, шуларның әле берсе, әле берсе артыннан йөгерә-йөгерә, үзен-үзе онытты. Ул кечкенә чакта да тегермән буасында шулай була иде, анда да шулай үрдәкләр суны бизәкли иде, анда да шулай бизәкләр су өстендә йөзә иде. Ләкин анда алар, берсе артыннан берсе бик тиз йөгереп, бик тиз югала иде. Әллә шунда малайлар чулт-чулт сикереп төшеп йөзәләр идеме, әллә ана каз, канатларын суга тиереп, яртылай очып, яртылай йөзеп читләрне куганда аларны югалта идеме?

Анда, буадан югары гына салынган Бәһави мунчасыннан бу чыгып тора иде. Буаның бу ягыннан ук чап-чап чабынганы ишетелә иде. Кайвакытлар ишеге ачылып китеп, сыя алмаган кебек бу дулап чыга. Аның артыннан кып-кызыл ахак кебек булган, тәннәренә каен яфрагы ябышкан Миңлебай абзый яисә аның әнисе, яисә Бәһави бабай үзе үк чулт итеп суга чума иде. Борынга бүрткән-пешкән каен яфрагы исе керә иде. Әйе, шулай иде. Коенып кайткач, әнисе кара богъдай белене берлән чәй эчерә иде. Җомгадан соң яңа бәрәңге берлән, тәкә шурпасы, тәкә тутырмасы берлән сыйлый иде. Инде аңарга әллә никадәр вакыт үтте. Ул чакта Шәмси малай иде. Аннан соң шәкерт булды. Казанның ысул җәдит мәдрәсәсендә, игъдади кыйсьмендә[1] бөтен фәннәрне укып, Җәнүби[2] Америкада ничә мәмләкәт бар? Аргентина, Гватемала, Рио-де-Жанейро, Амазонка, Миссисипи... Зунд... Панама... Панама... Әйе, Панама. Гүзәл Филипп, Кыска Пипин, Папа өченче Пи, солтан Мәхмүд Газнәви, Алып Арыслан, ысул дәфтәре... Мәет үлсә, ибн[3], бинт[4] калса, зәүҗ[5] ибн гам калса, мәсьәлә пичәдән чыга...

---

[1] *Игъдади кыйсьмендә* — башлангыч (хәзерлек) бүлегендә.
[2] *Җәнүби* — көньяк.
[3] *Ибн* — улы.
[4] *Бинт* — кызы.
[5] *Зәүҗ* — ир.

Әйе, өч заид[1] дүрт, биш заид сигез... Уннан ун, берне тарых[2] итәбез...

Менә ул шуларны биш ел укып торганда, тел астына вак сала торган иске шәкертләрдән көлеп, үзе, иптәшләре берлән мәдрәсә башына менеп, авызларны әчетеп-әчетеп тәмәке тартырга өйрәнгәндә, забастовка елы җитте. Урамнарда әллә нинди яңа көйләргә җырлыйлар, әллә кемнәрне тиргиләр, ачуланалар, әллә кемнән үч алмакчы булалар иде. Бөтен дөньяга үч алу, кирәген бирү уе тулган иде. Шәмсиләр дә забастовать иттеләр. Алар да юка гына җәгъърафия китабын, төрекләрнең французлардан урлап ясаганнан урланган тарих китапларын, ысул дәфтәрләрен, нәмүнә[3] хисапларын — барысын да ташладылар да мәдрәсәне дарелфөнүн[4] ясау хакында гариза бирделәр. Шунда ачуны китереп йөргән хәлфәләрдән Чуаш Хәкимне кыйнап алдылар. Бер дә кирәге булмаса да, тәмәке тарта торган чоланның тәрәзәсенә таш бәреп ваттылар. Аш вакытында эмальле тәрилкәләрне өйрә эченә ыргыттылар, кашыкларны сындырып ташладылар. Шуннан соң: «Күп яттык без мәдрәсәдә, уйламадык бернәрсә дә»,— дип, бик каты җырлап таралдылар. Хәзрәт кергәч тә, аның берлән дә бик каты сөйләштеләр. Аның: «Чыгыңыз!» — диюенә карамадылар. Полиция килгәч кенә, «Беренче сада»[5] бәетен җырлый-җырлый, мәдрәсәдән чыгып киттеләр. Шул бернәрсә бирмәгән, гомерләрен әрәм иткән мәдрәсәдән котылуларына сөенә-сөенә киттеләр. Көн үтте, атна үтте. Инде, ни эшләү хакында көн дә мәҗлес ясадылар, киңәш итештеләр. Бер нәтиҗә чыкмады. Ярый әле пароход төште дә, төрлесе төрле якка таралдылар да беттеләр. Кайсылары фәс киеп «милләт хадиме[6]» булырга керештеләр, кайсылары бухгалтерия курсларына киттеләр, кайсылары, кара күлмәк киеп, каеш тагып алып, аттестат зрелостига хәзерләнә башладылар. Шәмси дә шулар арасында булды. Ул да шуларның барысыннан да үтте. Ләкин ул, өйгә кайтса авылга мулла итәргә дип йөри торган әтисе, мулла әнисе булып йөрергә дип утыртып куйган әнисенең кәефләрен бик бозасы булганга,

---

[1] *Заид* — артык.

[2] *Тарых* — алу гамәле.

[3] *Нәмүнә* — өлге, үрнәк.

[4] *Дарелфөнүн* — университет.

[5] *«Беренче сада»* — 1905 елгы революция чорында чыккан җыр, шәкертләр гимны. (*Сада* — тавыш, аваз.)

[6] *Хадим* — хезмәтче.

тунын сатып, самавырны ломбардка салып, Әстерханга төшеп китте. Үзенең ысул дәфтәре белүе берлән, бухгалтер дип, бер галантерейный магазинга конторга керә алды. Ләкин бер атнадан ук белүе эшкә ярамаганга, сатучылыкка күчте. Анда да артык эш эшләргә булмаганга, кыргыз эченә мулдәкәлеккә[1] чыгып китте. Ул да бик тиз туйдыргач, җәйге җыйган акча берлән зур бер шәһәргә килеп, бухгалтерия курсларына керде. Курстагы укучы бер бай баласының димдәляләте[2] берлән Сибириядәге бер мишәр баена приказчиклыкка китте. Ул фирма бер-ике елдан соң сынганга, Шәмси тагы урам уртасында калды. Үзенең бер иптәше берлән кампания булып, ат алып, корал алып, тайгага чыгып, старатель булып алтын казырга кереште. Анда да алга китәрлек эш күренмәгәнгә, кышын вак товарчы булып сатуга тотынды. Сибириядә сату-алуның бетә торган дәверенә тугъры килгәнгә, аннан да мәгънә чыга алмады. Ул, мишәрләр берлән малаерак та булып, язучы да булып, Амур якларына китте. Анда рамазан җитеп калганга, араларында картлар күп булганга, Шәмси мулла да булып, тәравих[3] та укытты. Шунда җыелган таныш-белеше берлән ул Мәскәүгә күчеп килде. Кулына аз-маз каракүл алып, ваклап сатучы булып китте. Ләкин ул, мишәр егетләре кебек уңганлыгы, эшлеклелеге булмаганга, эшендә тәрәккый иттерә[4] алмады. Йөри торгач, кечкенә генә бер мөселман кибетенә приказчик булып җирләште. Вояжерларның[5] ярдәме берлән Петербургка килеп, мануфактурчы руска приказчик булып керде. Анда бер ел торгач, күршегә генә эш ачкан яңа бер яһүд фирмасы, бәһасен ике өлеш арттырып, Шәмсине чакырды. Инде ул менә шунда дүртенче ел хезмәт итә. Дүрт ел менә инде авылына кайтканы юк.

Шундый көз көне иде. Юк, соңрак иде. Халык та кырдан кергән иде. Өч ел йөреп, Шәмси йортларына кайтты. Әтиләре, әниләре сөенделәр, шатландылар. Угыллары урыс булган дип сөйләнгән хәбәрнең дөрест түгеллегенә шатландылар. Тәкә суеп, хәзрәтләр керттеләр, кунаклар чакырдылар. Болай йортҗирдән китеп, азып-тузып йөремәс өчен югары очның Вахитнең кызын алып бирмәкче булдылар. Шәмси разый булмас дип

---

[1] *Мулдәкә* — мөгаллим.

[2] *Димдәляләт* — димләү.

[3] *Тәравих* — уразада кич белән укыла торган намаз.

[4] *Тәрәккый иту* — алга киту, үсү, камилләшү.

[5] *Вояжер* — заказлар җыеп йөрүче приказчик.

уйлаганнар булырга кирәк, моңарга белдермәенчә, яучы җибәрделәр, моңарга белдермәенчә туй көнен билгеләделәр. Моңарга белдермәенчә колак сөенче алдылар. Урамда ишетеп кергән сүз берлән Шәмси зур тавыш куптарды. Атасының орышуына, анасының елавына карамаенча, өйләнмәвен бик ачык сөйләде. Картлар һаман, болай гына әле, үтәр әле дип, үз юлларында дәвам иткәнне күргәч, төнлә торып, җәяүләп тимер юлга чыкты. Шул китүдән менә китте. Әйе, аңарга хәзер күп булды инде, хәзер ул өйдә булса, ни булыр иде икән?..

Дача ягыннан:

— Тиз бул, кофе өлгерде,— дигән тавыш ишетелде; ул, урманга ярылып, чыңлап китте. Шәмсине бердән уяндырып җибәреп:

— Әйе, хәзер менә чит җирдә, ят илдә, башка бер халыкның мәдәнияте эчендә яшим. Белмәгән-күрмәгән бер марҗа берлән дачада хәл җыям, яшьлек үткәрәм. Теге вакытта өйләнгән булсам, әллә хәзер шул рәхәтне, тормышның шул тынуын татар хатыны берлән бүлешкән булыр идем? Вахит кызы Миңлесафа берлән?

Шул тирә-юньдә, шул тормыш эчендә үзенең кырык итәкле Миңлесафа шулкадәр ят булып китте, ул шул фикернең башына килүдән көлеп җибәрде. Шуларның барысыннан берьюлы аруланыр өчен кебек, тагы бер йөзеп, тагы чумды. Суның кырыенарак җиткәч кенә, ике кулы берлән су өстендә булыр ихтималлар, әллә нәрсәләрне этеп җибәрде дә:

— Арулыгым, пакьлегем... исәнлегем, саулыгым,— дип, ул суга утырып чумды. Тагы аруланып җитмәде кебек, тагы шул ук: — Арулыгым, пакьлегем... исәнлегем, саулыгым,— дип чумды. Өченчесендә ул ихтыярсыз итеп, озак итеп чумды. Шул сүзләрне әйткәндә аның тавышы да әллә нинди йомшара төште. Аңарга балалык кушылды, сафлык, гөнаһсызлык буявы бизәлде. Арулыгым, пакьлегем, исәнлегем, саулыгымны... ике-шәрли-икешәрли ул китәргә тотынды.

— Менә бит шул сүзне Анна аңламый. Ә? Аңламый... Русчага тәрҗемә итсәң? Аны ничек тәрҗемә итәсең? Ул марҗа шул... марҗа... Әйе, марҗа...

Күңеленең бер кырые әллә нигә кәефе китте. Әллә нидән разый булмады. Марҗа берлән тору? Әйе, марҗа берлән тору начар инде, кәефсез инде. Ләкин бу бит тору түгел. Иттифакый очрашкан ике яшь кешенең җәйләрен бергә үткәрешүләре, яшьлек рәхәтен бергә бүлешүләре генә.

Фәлсәфә җитәр. Ел буе эшли-эшли эштән чыккан кешенең елының бер генә аенда үзенә үзе хуҗа булып, үзе теләгәнчә гомерен үткәрергә, булдыра алган кадәр тормыштан алачак ләззәт-тәмне тутырыбрак алырга хакы бар.

Әйе, шулай. Аннаның ачыклыгы, тәмле кофены оста иттереп ясап бирүләре вә чәй янындагы сыйлар бик тиз шул фәлсәфәләрне оныттырды. Чәйдән соң ул үзенең җыеп килгән татар әдәбиятына кереште. Финляндиянең тын урманнары арасында нечкә-нечкә татар китаплары эч ягыннан да нечкәсыек кебек күренде, алар югалып китте.

Анна Васильевна ашханәдә эшләрен бетереп, тагы йөрергә киттеләр. Аштан соң көймәгә төшеп, күлнең яр башындагы елга берлән әллә никадәргә барып, андагы балыкчы финдә чәй эчтеләр, балыклар алып кайттылар. Тагы йөределәр, коендылар, уйнадылар, көлделәр. Шәмсинең иртә берлән укый торган китаплары беткәч тә, Анна Васильевна:

— Әйдә, мин сиңа кычкырып русча укыйм. Син Горький берлән танышмы? — диде.

— Ник таныш булмасын, таныш.

Анна Васильевна торып:

— Син аның «Изергиль», «Челкаш», «Мещаннар»ын укыдыңмы? — дип, берәм-берәм сораганда, берсен дә укымаган булып чыкты.

Чеховка килгәч тә мәсьәлә шулай булып чыкты.

— Алай булса, менә нәрсә: мин сиңа үзем сөйгәннәрдән укыйм әле,— дип тотынды.

Иң элгәре ул Горькийның «Изергиль» әсәрен укыды. Шәмсинең батыр фикерләр уйларга төшенмәгән башы аптырап калды — мөхәррирнең[1] фикеренең зурлыгын кочаклый алмаенча, фикернең читеннән үтә алмады. Эче пошты, күңеле тарсынды.

— Тукта әле син, тыңла әле, ул сездәге кебек хатын-кыз өчен күз яше түгүдән рус әдәбияты үткән бит инде.

Аннаның сүзе аның иң авырта торган җиренә тиде.

— Күз яше булса, күз яше начармыни?

Анна, укуында дәвам итеп:

— Күз яше начар түгел. Күз яше тормыш нигезе корырга ярамый,— диде.— Аңарга көч кирәк,— диде дә укуында дәвам итте.

---

[1] *Мөхәррир* — б и р е д ә: язучы.

Шәмси тыңларга, бөтен көчен-куәтен сарыф итеп аңларга кереште. Мөхәррирнең сүз әйләндерүләренә төшенә башлады, аның фикереннең кая таба акканнарын тотып алды. Аннаның бу көмеш тавыш берлән укыган саен китапның эченә керә барды. Ул менә бөтенләй онтылды. Йомшак кына саллана торган көймәгә утырган кеше кебек, китапның язылу музыкасында тирбәнә башлады. Аның фикер агышында, фикер дулкыннарында йөзде, чумды, югалды. Укып бетергәч, бик озак ул үзенә үзе килә алмады. Бик озакка кадәре аның колагында Изергильнең сүзләре чыңлады. Көн буена кадәре Горькийның язудагы музыкасы тавышын моңлады. Әле бер җөмлә килеп чыгып, әле бер мәнзарә күз алдына басып, әле бер фикер чумып чыгып, әле сүз борылмасы тезелеп китеп көн буе башын биләде. Бара-тора шуларның барысы берләшеп, зур, көчле, гөнаһсыз, матур, нәзек бер хатын килеп басты вә шуның авызыннан таза, нык, батыр, матур музыка коела башлады. Берничә көн бербуйдан Шәмси Анна берлән моназарә[1] кыйлышты. Кыен язылуы хакында кычкырышты. Һәммәсендә дә, бик озакка сузып сүз бирмәсә дә, эченнән җиңелгәнен хис итте. Икенчегә Анна Васильевна Чеховның «Настенька»сын укыды. Шәмси аны рәхәтләнеп тыңлап торды. Укып бетергәч, Аннаның:

— Менә бу инде татар хатыны,— дигәч кенә аның белән кычкырышырга тотынды.

Көн үтте. Көн үткән саен яңа-яңа әсәрләр берлән Анна аны сыйлады. Ул «Мальва»ны, «Челкаш»ны укыды. Чеховның кыска хикәяләрен укып, эчен катырды. Ибсеннән, Бернштейннан да берничә әсәрләр укыды.

Шуларның һәммәсен бик оста иттереп бүлгәнгә, ашы-суына да вакыты калды, йөрергә, хозурланырга да сәгать җитте. Иркәләнергә, сөелергә-сөешергә тар булмады. Көн үтте, тулы булып үтте. Тормыш акты. Бөтен почмагы берлән боларны күмеп, бөтен якларына тәэсир итеп, туйдырып акты.

Һәр минутында бертөрле матурлык, һәр минутында бертөрле күңеллелек биреп, сыйлап, рәхәтләндереп акты. Икесенең дә башларында рәхәт падишаһлык сөрде. Иртәсен-кичен белмәенчә, көндезен-караңгысын аермаенча сөрде. Икесе дә, шул кадерле минутларны әрәм үткәрмәс өчен, шул кыйммәтле рәхәтне көфране нигъмәт[2] итмәс өчен, шуны йоттылар, эчтеләр.

---

[1] *Моназарә* — бәхәс.

[2] *Көфране нигъмәт* — аш кадерен белмәү.

Тәме озакка барсын өчен, эссе көндә салкын ширбәтне салам ашасыннан эчкән кеше кебек, нечкәләп-нәзекләп эчтеләр. Тормышның тәмен тәмләп, татын татлап яшәделәр.

Көннәр аяз килде. Көннәр җылысу торды. Әллә нидә бер генә бөтен тирә-юньне болыт каплап, иләктән генә вак яңгыр сибәләсә дә, икенче көнне үк көн ачылды, урманнар, яланнарны яшәртеп, агач араларына ак, кызыл, алсу төсләр чәчеп, урманның эченә ашый торган вә агулы әллә никадәр ятгырыкларны утыртып, үтеп тә китте. Тагы көн элгәреге хәлен алды. Тагы кояш әүвәлге кебек кыздырырга тотынды. Өченче көнен Анна Васильевна Шәмсине иртә үк торгызып, гөмбә җыярга алып чыкты. Аның күңелендә мәдрәсәдә торганда иң җирәнә торган, рус ашханәсенә иң ямьсез төс бирә торган гөмбәләрне җыйдырды. Ашарга ярый торган, ярамый торганын өйрәтте. Аертты. Аш вакытында, шул ятгырыктан, капсаң, телеңне йотарлык ашлар ясады, шулардан бөккәннәр пешерде. Көн үткән саен Шәмси тик ятуга керә барды, көн үткән саен аның табигатендә кунак булып кадерләнү үсә килде. Үзенең эшли торган эшләрен дә берәм-берәм Анна Васильевнага йөкләде. Кием алыштырудан күлмәк-ыштан кию кебек эшләрен дә аның ихтыярына тапшырды. Ул киң яланда, хатыны сауган биянең кымызын эчеп, курай уйнап, дәрт укып кәефләнеп ята торган башкорт кебек, баштанаяк эшсезлеккә чумды. Көн үткән саен Анна Васильевнаның эше күбәйде. Көн үткән саен ул йорт эшенә бата барды. Шәмсинең тегелгәннән бирле инә күрмәгән күлмәк-ыштанын актарып ыргытты. Аларның төзәтәсен төзәтте, ямыйсын ямады, каптырмалар, төймәләр кадады, баулар такты. Һәр көнне йокыдан иренеп торган Шәмсигә:

— Йә әле, башкорт кантоны, рәхим итеп, үзеңезне киендерергә рөхсәт биреңез әле,— дип, Алланың биргән көнендә аның күлмәген-ыштанын алыштырды. Тирги-тирги һәр көнне аны ботинкасын чистартырга утыртты.

Егермеләре үтә башлагач, Аннаның эше тагы күбәйде. Ул, әллә кайдан гөмбәләр китертеп, аларны тозлады, серкәләде. Бакчадан чия, җиләк алып, варенье кайнатты. Күрше фин хатыннарыннан майлар алып, аларны эретеп тәпәннәргә тутырды. Бөтен керләрне юып, артык-портыкны җыя башлады. Китәргә вакыт җиткәч, икесенең дә әйберләрен өзек урынлаштырды. Ай тулып, кайтырга көне җиткәч тә, Шәмси: «Тагы бер генә көн торыйк инде»,— дигәч, Анна Васильевна, тагы көлеп:

«Күчмә башкорт»,— дип, тагы калды. Икенче көнне Шәмси тагы хәйләләр табып калдырырга теләсә дә, Анна Васильевна үзе барып финнән ат алды. Көчләгән кебек иттереп, Шәмсине киендереп, әйберләрне төятте. Китәр алдыннан дачада торткан хисапны күрергә дә онытмады. Ул, өзек кәгазь алып килеп, Шәмсигә тулы бер хисап күрсәтте. Шул цифрлар, шул вак хисаплар шәһәрдә дә башын әйләндереп бетергәнгә, иренә-иренә генә тыңлады. Анна, икегә бүлеп:

— Менә сиңа шулкадәр төшә, миңа шулкадәр,— дигәч кенә ул:

— Хисап нәрсәгә? Бергә торган, бергә беткән,— дип кычкырса да, Анна аның кесәсенә калган акчаны көчләп салган кебек салды вә, шул хакта Шәмсинең озын фәлсәфәләрен тыңламаенча:

— Башкорт дөнья үлчәве берлән Финляндиядә тормыйлар, мин үзем өчен тордым, үзем өчен рәхәт күрдем, үзем расходын тоттым. Син үзең өчен, үпкәләшмәскә теләсәң, озын сөйләмә,— дип, сүзен бетерде.

Шәһәргә кайтып җитеп, тагы шул тар бүлмәгә кергәч кенә, тагы шул әчеле-төчеле шәһәр исен исни башлагач кына Шәмси айнып китте. Ул хуҗа хатыны куйган самавыр берлән, аның үзеннән кунак итеп биргән сохарилары берлән никадәр чәй эчәргә көчләнсә дә булдыра алмады, чәе тәмсез булды. Сохари комнан ясаган кебек тоелды. Борыны әллә нинди авыр бер исне ташламады. Әллә нәрсәсе тулмады, әллә нәрсәне юксынды. Иртәгә иртүк торып магазинга чыгарга булганга, сәгать уннан ук урын җәеп ятса да, йокыга китә алмады, урыны каты күренде. Әллә нәрсәләр ашый кебек тоелды. Әллә нәрсә тар кебек сизелде. Ары әйләнде, бире әйләнде, күзен йомды, уйга чумды, санап карады, йөзгә җитте, үтеп китте. Күзе шар кебек ачык торудан туймады. Ут яндырып, урыныннан кандала, борча юкмы дип тентү ясады, берни таба алмады. Тагы ятарга дигәндә бөтен тәне, бөтен әгъзасы: «Кирәкми лә!» — дип ялынган кебек булды. Тагы анда әллә нинди кандалалар бардыр, борчалар күптер кебек күренде. Тагы бүлмәдәге һаваны тарсынды. Тагы әллә нәрсәнең юклыгы катырак, ныграк хис ителде. Ул, иртәрәк яттым ахрысы, бераз йөреп керим дигән булып, киенеп өйдән чыкты. Үзенә үзе җавап бирмәенчә генә, Анна урамына таба китте. Элгәре, уты булса кереп чыгармын, бик арымадымы икән дигән булса да, үтеп бара торган арбачыны күргәч, тугъры

ук утырып китте. Барып җиткәч тә, уты бармы-юклыгын карарга да онытып, кызулап-кызулап баскычтан менеп китте. Ишек ачкач та, Анна Васильевна каршы чыкты. Йоклый алмадыңмыни дигән кебек, елмаебрак каршы алды. Бүлмәгә кергәч: «Чәй эчәмсең?»— дип сорады. Спиртовкада гына өлгертелгән чәй дә бик тәмле тоелды. Чәй янында вак-төяк, коры-сары гына булса да, бик туклыклы кебек сизелде. Борынга һич азатлык бирми торган теге ис, шәһәр исе бетте. Сөйли-сөйли озак чәй эчелгәннең соңында, кайтып йөрергә соң булганга, шундук кунып та калды.

*

Көн артыннан көн үтте. Эш тагы үзенең хөкемен йөртте. Магазин, Шәмсинең башкортлыгын тагы куып чыгарып, аңардан җитез приказчикны тагы кайтарды. Тормыш үз юлына төште. Икесе дә приказчик, приказчица булып киттеләр. Ләкин быел һәр көнне әле берсендә, әле берсендә кичке чәйне эчүчән булдылар, кыш буе икесе дә Финляндиядәге тормышны төштә күргән кебек кенә сагынып сөйләделәр. Яңа ел бәйрәмнәрендә Анна Васильевна әллә кая Владимир губернасына анасы белән күрешергә китте. Шәмси җәмгыяте хәйрия файдасына куелачак театрның мәҗлесләренә йөрергә, ярдәм итешергә тотынды. Анда ул яңадан әллә никадәр укучы татар туташлары берлән, шәһәрнең ару гына сәүдәгәрләренең кызлары берлән танышты. Шуларның үз дәрәҗәсенә якынракларына җиткән кызлар дип карап, чынлабрак танышу өчен, тугъры килсә, өйләнеп тә җибәрер өчен дикъкать берлән кылынды. Кайсын берсен өйләренә дә озатты. Уен-көлке сөйләде. Белмәмешкә салынып, бер дә өйләнмәгән егет дигән кебек итеп куйгалады. Кара гына кашлы, йомры гына бер мишәр кызының бераз дикъкатен дә җәлеп итте. Аның берлән сөйләп, авызын да ача төшмәкче булды. Җәмәгать мәсьәләләре, әдәбият хакында сүзләр ачты. Тормышның náклары хакында сөйләштерде. Йомры кыз һәммәсен дә көлемсерәбрәк кенә тыңласа да, һәр фикергә разый булуга башка бертөрле дә төс күрсәтә алмады. Һичбер нәрсә хакында фикерен аерым итеп әйтә алмады. Шәмси, менә чын да бу шул Настенька дип, читкәрәк тартылды.

Үз-үзенә охшый төшкән Касыйм кызы артыннан йөребрәк китте. Тукай шигыре, Тукай шигыре дип сөйләгәндә:

— Тукай соң ул кем? — дип, Шәмсине хәйранга калдырды.

Тукайның кемлеген, хәзер кайда торганын белмәгән бу татар кызының кай төшендә татарлыгы яшеренгәнен эзләп йөргәндә, Нурия туташ шундагы бер кыз хакында:

— Аны бит Касыймның фәлән кеше сораган иде, аннан кайтты. Ул кызны үзчирле диләр. Әнә теге кызны күрәмсез, помоему, аның кофтасы материядән эшләнгән. Зур борынлы кешегә килешеп бетми,— дип, татарлык йөзен күрсәтте.

Өченчеләре, дүртенчеләрендә тагы шунда куркаклыкмы, үзенә үзе хуҗа түгеллекме — бер сызык күргәнгә, һәммәсендә Аннада бар хасыятьләр, сыйфатлар күрелмәгәнгә, өстән генә карарга тотынды. Театр алдындагы бер мәҗлестә бер курсистка бер студент берлән яңа бер әсәр хакында кычкырышып, моназарә кылышып киткәнне тыңлап торганда курсистканың сүз йөртүләреннән, мөхакәмәләреннән[1] Анна берлән кычкырышканда татар әдәбияты хакында сөйләргә үзенә әллә никадәр дәлилләр чүпләсә дә вә шул курсисткада әллә ниләр бар кебек күренсә дә, аңарга якынрак барырга базынмады. Сөйләп китеп, күңеле уйлар, фикерләр таба алуына ышана алмады. Театр уйналганда Анна Васильевна да кайткан булганга, Шәмси аны да алып килде вә алдан аңарга үзенең шунда невеста эзләргә теләвен аңлатты вә кичәләрдәге күргән кызлары хакында сөйләде. Анна, бик дикъкать берлән тыңлап:

— Әлбәттә кирәк. Сиңа инде өйләнергә вакыт җиткән. Ләкин карап алырга кирәк, менә мин дә карашыйм әле,— диде. Шул сүзне кыз эзли торган энесенә тутасы әйткән кебек әйтте вә театрга баргач та Шәмсидән аерылып китеп: — Бар, иркеңдә йөр, миңа бәйләнеп торма, кайткандарак күрешербез әле,— дип, читкә китте.

Шәмси пәрдә арасында аңарга чәй эчереп залны бер мәртәбә әйләнсә дә, Анна шундагы кызлар хакында мәгълүматлар алса да вә кайсысын яратуы хакында сораса да, шундагы бик күп татар хатыннарының киенүләре, туалетлары хакында кыска-кыска гына фикерен әйтте дә тиз генә үзе аерылып китте. Шәмси яңадан бик күп кызлар берлән танышты, бик күбесе берлән сөйләште. Бию-танса башланганның соңында берничәләре берлән биеде, тансовайт та итте. Әдәби кыйсьме[2] башланып, татарча җырлар, музыкалар киткәч, Аннаның барлыгын да

---

[1] *Мөхакәмә* — фикер, хөкем йөртү.

[2] *Кыйсьме (кыйсем)* — бүлек.

онытты. Ләкин тансовайт итүче парлар арасында бер татар студенты берлән Аннаны күргәч, күңеленең әллә нинди бер җире жу итеп китте.

Театрда күргәннәр бик озакка сөйләүгә сүз булды. Шундагы уеннар, киемнәр, көйләр, җырлар, биюләр хакында Анна әллә никадәр сүз сөйләде, әллә никадәр йомшак кына тәнкыйтьләр үткәрде. Кыш үтә барды. Шәмси, өйләнәсе иде дип һаман төшенсә дә, үзе эзләгәне табылмаганга, һаман шул юлда тора килде. Шул кадәре үзгәлеге булды: Анна Васильевна театрга йөрү мәсьәләсен бер интизамгарак[1] куйды. Ул, шул эшне үз өстенә алып, төрле театрдагы төрле зур пьесаларны күрсәтергә тотынды вә әдәбият базарында яңарак чыккан мәҗмугаләрне[2] алып, мотлак Шәмсигә укучан булды вә буш вакытларында әдәбият хакында, бер-бер фән хакында лекцияләр булса, Шәмсине алып баручан булды вә, шулай итеп, рус әдәбият тарихы хакында мәшһүр профессорның уникe лекциясен дә тыңлатты. Мәскәүдән килгән бер мөдәрриснең музыка хакындагы лекциясенә, сугышып-кырылышып булса да, билет тапты. Ләкин язга табарак Анна Васильевна, көтмәгәндә, урыныннан чыгарга карар бирүен сөйләде. Шәмси:

— Ник, ник? — дип йөдәтсә дә, сәбәбен әйтмәде.

Менә беркөнне кич берлән Анна Васильевнаны күзе кызарган көенчә тапты, һәм дә урыныннан чыгу хәбәрен ишетте. Шәмси тагы: «Ник?» — дип йөдәткәч, Анна бер хат чыгарып ыргытты. Шәмси, хатның башыннан ук эсселе-суыклы булып китеп, шөбһәләнеп, Аннага карады. Бик йомшак сүзләрдә башланган хат, барган саен тирәнәя-тирәнәя, изһар[3] мәхәббәт юлына барып җитә вә ахырдан дустлык, бергә торуны тәкъдим итү берлән бетә иде. Шәмсинең укып чыгуын көтеп торган Анна Васильевна:

— Аңладыңмы? Бу менә минем хуҗам хаты. Ул бәйләнә башлаганга инде ел тулды. Моңынчы әле уен-көлкегә алып кына килгән булсам да, шул арада тагы оятсызлык юлына кереп китә башлады. Бүген менә конторага кергән җиремнән тотып кочмакчы булган иде, көчкә котылып чыктым да, магазинга чыгуы берлән, халык алдында кайчыларны битенә бәрдем дә чыгып киттем, хәзер мин анда барачак кеше түгелмен,— диде.

---

[1] *Интизам* — тәртип, кагыйдә.

[2] *Мәҗмуга* — җыентык.

[3] *Изһар* — күрсәтү, ачып салу.

Шәмси, аптырабрак калса да, төрле юл берлән ярдәм итүне эзләргә тотынды вә үз тарафыннан берәр яңа һөнәргә яисә телгә өйрәнеп, яңа юл алуны мәслихәт тапты. Вә үзенең жалуниясе тагы быел унбиш сум артканга, икесенә җитәрлекне сөйләде. Ләкин Анна, авызын ачтырмаенча, икенче көнне үк эш эзләргә тотынды. Иртәдән алып кичкә кадәр гәзитә игъланнарына йөрде. Магазиннар, кибетләр, контораларга хатлар язды, телефонда сорады, барып белеште. Никадәр тырышса да, урын таба алмады. Кайсы читкә китәргә булды, кайсысы немецча белергә тиеш булды, кайсысы бухгалтериядә осталыкны шарт итте. Ахырдан кечкенә генә бер мәхкәмәдә[1] машинада язарга егерме биш тәңкәлек кенә бер урын тапты. Жалуниясе азлыгы әлгәре куркыткан булса да, вакыты бик күп буш калганга вә кич язар өчен һәрвакыт эш табылып торганга, әүвәлгегә караганда файдалы да булып чыкты. Ләкин җәен Шәмсинең хуҗалары Сибириягә мал алырга вә андагы мөселман фирмалары берлән мөнәсәбәт бәйләргә озатканга вә Мәкәрҗә вакытында үзләре берлән Мәкәрҗәгә алып барганга, җәй төсе икесенә дә күрелмәенчә генә үтте. Кыш кергәч тә, Шәмси тагы өйләнү уен алга сөрде. Берничә туташлы мөселман гаиләләренә барып йөри башлады. Бер-бер мәҗлесме, кичме булдымы, шунда әләгүгә тырышты вә шундагы кешеләр берлән, хосусән туташлар берлән, әдәби, фәнни мәсьәләләрдә моназарәләргә керешеп китеп танышмакчы, танытмакчы булды. Шәрекъ кичәсендә бик ихлас берлән бер поляк кызы артыннан йөрде. Бер Казан кызы берлән танышып алып, берәр мәртәбә театрга да барды, ләкин һәр юлында да очраган кызларда Шәмсинең теләгәне булып чыкмаганга, эше һаман әле соңайтыла килде. Анна Васильевна берлән мөнәсәбәт һаман иске дустлыгында, иске сукмагында бара бирде. Яз көне март айлары җиткәч тә, күңелне күтәрә торган матур кояшлар алдаштыргалый башлагач та, Шәмси көннең һәйбәтлегенә кызыгып, җәйге пальтодан атауларга китте вә анда кызуланып йөрийөри тирләсә дә, диңгезгә кояш батканны көймә өстендә күрер өчен, көймә берлән суга керде. Кояш баюның матурлыгын карый-карый, аркасы буйлап суык җил үткәнне сизми калды. Көн суыкланып китеп кыса башлаганча, урман араларында юешлек сизелә башлаганга ук, шунда калды.

[1] *Мәхкәмә* — хөкем итә торган идарә, хөкем йорты.

*

Анна Васильевнаның шул арада эшләп бетерә торган, мөддәтләп[1] алган эше булганга, авыруны дүртенче көн генә ишетте вә урында аунала-тәгәри торган Шәмсине күреп коты очты вә, бик тиз доктор китертеп, авыруны белдертте. Шәмсидә плеврит башланганлыгы вә аны бик чынлап карамаганда, тырышып даруламаганда ютәл авыруына күчәчәге мәгълүм булды. Анна Васильевна эшен ташлады. Мәхкәмәсеннән бер атнага миһләт[2] алды. Үзе көне-төне яныннан аерылмады. Авыруны төннәрдә дә ашату-эчертү өчен вә бөтен карау өчен һәрвакыт янында булырга кирәк булганга, Анна Васильевна шул ук өйдә бушаган күрше бүлмәгә күчеп килде. Вә мәхкәмәсеннән тагы берәр атнага миһләт бирмәгәнгә, урынын да ташлады. Бераздан терелә башласа да, бик чынлап карарга кирәк булганга, ашау-эчүдә бик сак булу тиеш булганга, аш-суны Анна Васильевна үзе хәзерләргә, үзе пешерергә тотынды. Май башларында терелгән кебек булса да, үзе бик зәгыйфь, көчсез булганга, докторлар чынлап тазарыр өчен кымызга барырга мәслихәт тапканга, Шәмси никадәр авылга этиләренә генә кайтырга теләсә дә, Анна Васильевна бөтен көчен-куәтен кымызга илтергә сарыф итте. Анда да, үзем генә барам дисә дә, Анна Васильевна көчләп кебек бергә китте. Кулында акчасы аз булганга, җәйге киемнәрне тектермәде. Язу машинасын, вак-төяк алтыннарын ломбардка салды.

Пароходта килгәндә кич җиттеме, аз гына юешлек сиздеме, Шәмсине каютка кертте, аңарга кием кигезде, күлмәген алыштырды. Капризлы бала артыннан йөргән кебек йөрде. Уфага килеп җиткәч тә, анда барып сорашып, монда барып белешеп, чахоточныйлар бармый торган читтәге бер авылны табып, Урал итәгендәге тимер юлдан кырык-илле чакрым, кешесез, кымызчысыз бер урынга алды да китте. Шәмсиләрнең умарта аланы янындагы тора торган өйләре торыр өчен салынмаган иде. Ул элгәре умарта сөюче мөәззин абзыйның умарта рамнарын, кәрәзләрен, битлекләрен, калакларын, тубалларын, корт азыкларын куяр өчен соңыннан ясалган келәт кенә иде. Шуның өчен тәрәзәсе дә бер генә, миче-учагы да юк, җиһазлары да җир сәке берлән баллар куяр өчен ясалган шүрлекләрдән гыйбарәт

---

[1] *Мөддәт* — вакыт, срок.

[2] *Миһләт (мөһләт)* — кичектереп тору.

иде. Тирә-юнендә чолан, өйалдысы да, йорт тирәсе, коймасы, читәне дә юк иде. Ап-ак суенды[1] диварны зур иттереп ачкан ишек тауның өстенә таба караганга, тауның сул итәгенә үскән төрле агачлар арасында ачык калган мөәззин абзыйның умарта аланы күзгә ташлана вә шулар артыннан озаеп югарыга таба менеп киткән зур тау күренә дә, аның башында үскән яшел агачлар берлән күренеше каплана иде.

Каршы яктагы кечкенә тәрәзәдән күз шоп-шома иттереп төшеп киткән хәтфә төсле үләннәр берлән ябылган, аллы-гөлле чәчәкләр берлән бизәкләнгән сырттан түбән таба тәгәри иде. Ул тау итәгендәге тирәкләр, юкәләр, карамалар, имәннәр, каеннарга бәрелә-бәрелә яшеллек уртасыннан бормаланып-борылып ага торган Дим суына туктый иде. Аның теге ягы тагы башка, суның итәгенә челтәр булып тотылган агачлар кетәгенә, киң яланга барып чыгалар. Күз алдына ямь-яшел үлән диңгезе килеп баса. Аның очы-кырые күренми торган, иңе-буе кая барып терәлгәне сизелми торган өсте кызыллы-каралы, аклы-чуарлы, сарылы-сорылы, аллы-гөлле чәчәкләр берлән чигелгән. Аның бер почмагында түгәрәк кенә күл йөзек кашы кебек мөлдерәп тора. Аның бер ягыннан агып килә торган кечкенә генә инеш бер агачлар, үләннәр арасында югалып китә, бер урманнар арасына чумган башын күрсәтеп, тобалары берлән ялтырап куя.

Еракта-еракта, яшел болыннарның теге тарафында, сыек кына сөремгә бөркәнгән таулар күренә. Уңда-сулда Дим суы, куа торган киявеннән качкан башкорт кызы кебек, әле арасына кереп поскан, әле бүредән, төлкедән куркып чаба торган куян кебек, болын буйлап сузылып киткән, әле бик ерак китмәдемме дип курка торган карлыгач кебек, тирескә[2] борылып аккан, әле юлына тугъры килгән һавалы зур тирәккә ачуланып, аның ике ягыннан ерып чыгып, аны камап алган, әле, шул матур киң сахра эченнән китәсе килмәенчә тузылып яткан тук куй көтүе кебек, агачлар күләгәсенә яшеренә-яшеренә, үләннәр арасына чума-чума, җәелеп-сузылып яткан. Аның югарыга табан, түбәнгә табан бормалануларында, озын гына манараларын күккә күтәреп, сыек кына башкорт авыллары сибелгәннәр. Диңгез эчендәге кечкенә-кечкенә утраулар, атаулар кебек, алар акка

---

[1] *Суенды* — сөян (кабыгы салдырылган юкә агачы).

[2] *Тирескә* — кирегә.

буяган озын морҗалардан зәңгәр төтеннәрен чыгарып яталар. Кичкә таба, агачларның шәүләләре озая төшкәч, кояшның үткен күзе зәгыйфьләнә төшкәч, тау башына чыксаң, дөнья тагы киңәя, артта итәкләнеп-итәкләнеп, берсе өстенә берсе менеп, берсе янына берсе үсеп, түгәрәк озынча таулар менеп киткәннәр. Алар кара урманнан ясалган җепләр берлән бер-берсенә бәйләнә-бәйләнә озын иттереп, тәсбих кебек сузылганнар-сузылганнар да, еракка-еракка китеп, карагылт сөрем эчендәге тауларга бөтерелгәннәр. Уңда, сулда тагы берсеннән-берсе кечкенә, берсеннән-берсе зур таулар, түбәләр, агачлар берлән өртәлеп, сулар, күлләр берлән бизәлеп, яшел үлән берлән каплап, тагы еракка-еракка китеп, ачык яланга барып өртелгәннәр; яисә, тар гына суларны сикереп үтеп, кош-корт берлән тулган урманы, яланы, күбәләкләре, бал кортлары, энә караклары берлән тулган болын дөньядагы бөтен тавышларны җыеп сайрыйлар, уйныйлар, дөньяда булган-булмаган бөтен көйләргә нечкә-юан тавышлар берлән җырлыйлар...

Шул музыка тавышлары алып киләме, үзе йөриме, урманы, тавы, яланы, болыны, су яры — һәммәсе нечкә-нәзек күл исенә манчылганнар. Шуларның исе исертәме, әллә айга каршы ялтырый торган Димнең суы исертәме, әллә аның борылышларында, аерылышларында моң иттереп, шылтыр-шылтыр агуы тәэсир итәме, кояш баюга, эңгер-меңгер төшүгә сандугач сайрарга тотына. Иң элек тау итәгендәге берсе башлый, аңарга җавап итеп, күрше таудан хәбәр килә. Аларны ишетеп, тауның югарысында, түбәнендә, болынында, яланында, су буенда, су аръягында сайрау башлана. Бөтен дөнья шуның музыкасы берлән тула. Күге-җире башын иеп, шуның мәхәббәт шигырен тыңлый... Кош-корт туктый, дәрткә, моңлыкка чума, бата. Еракта гына кәккүк кенә үзенең иптәшен сагына, чикерткә генә хиссиятенә сыймаенча сызгыра, чырылдый. Дим шылтыр-шылтыр агуында, сандугачның җырларын озакка-озакка алып китүендә, сөрем итүендә дәвам итә. Акрын гына искән җил берлән урман хәйран булып башын ия. Ул шаулап-гөрләп сандугачка кул чаба, рәхмәт әйтә.

Беренче көннәрдә Шәмси, бигрәк Анна шул һавада исерделәр, шаштылар. Төннәрен йокламадылар. Иртәнге сандугачның сайравы бетмәенчә, тау башыннан иңмәделәр. Чыклы үләннәр өстендә, кояш яктысының беренче нурлануында, яфракларлардагы, чәчәкләрдәге чык тамчыларының кояш-кояшка күз кысышуларында, яланда булдылар.

Кыр чыпчыгының беренче сайрауларын ишетеп, тургайның иртәнге азанын тыңлап бетереп кенә ятакларына киттеләр. Көн сүрелә төшү берлән, кармакларын күтәреп, Димнең томрап торган тобаларына[1] балыкка төштеләр. Агач шәүләләре араларында көмеш сыртлы балыкларны берсе артыннан берсен өстерәп, кәтү кайтканчы, кичке ашка мөәззин кызы чакыра килгәнче шунда калдылар. Тынлыкка бата торган киң яланны, көн буенча кояшка каршы гөлләнеп, чәчәкләнеп, бизәлеп утырудан арып хәл җыярга хәзерләнә торган чәчәкләрне, әлсерәп, сусап, күлгә таба чык сорап кулларын догага күтәргән урманнарны калдырып, тауларының башларына менделәр. Суенды келәт янындагы ачык һавага корылган өстәл өстендә суган, борыч берлән генә пешкән тәкә ботларын куллары берлән күтәреп кимерделәр. Аның хуш үлән исе килеп тора торган шурпасын тустак берлән бәрәңге кабып кына чөмерделәр. Мөәззин абыстае биргән былтыргы карлыган кагы берлән, йолдызлар, айлар берлән генә яктыртылган, кош-кортның кичке сайравы уртасында, әллә нидә бер генә исеп китә торган коры тау җиле эчендә чәйгә утырдылар. Табигатьнең шул буяулары, бизәкләре арасында шәһәрнең якалары, муен баулары килешмәгән кебек тоелганга, күңелнең әллә кайсы җире кытыршыланып торганга, беренче көнне үк Шәмси якаларын, пинжәкләрен салып ыргытты. Икенче көнне үк мөәззин кызыннан тектергән озын ак күлмәк-ыштаннан калды. Аягына яланаяк көенчә генә чүәк киеп алды. Анна да авыл базарыннан алынган ситсыдан ике татарча күлмәк тегеп киде.

Кымыз беренче көннән үк Шәмсигә ошады. Анна никадәр, доктор кушуы буенча, акрынлап өйрәтергә теләсә дә, Шәмси исен сизү белән үк башкарып китте вә мөәззин абзыйның тәмләп карарга гына китергән кымыздан ук дустаклап-дустаклап эчәргә тотынды. Атна үтмәде, Шәмси, башкорт кебек уйламаенча, иртәдән алып кичкә кадәр кымызны чөмерә торган булды. Мөәззиннең бияләре күп булганга вә бу тирәдә кымызчы килеп тору гадәт булмаганга, базарга кымыз чыгарып сату мөәззин өчен хурлык буласы булганга, кымыз мул булды, күп булды, шешәгә сыймады. Стакан кебек юк нәрсәләр берлән аның олугълыгы мыскыл ителмәде, сифон кебек немец хәйләләре берлән аның тәме бозылмады. Кымыз агач савытларда —

[1] *Тоба* — елга, күлләрдә бик тирән урын, упкын, чоңгыл.

сагада гөрләде. Үзе шаулый-шаулый дустакларга бүленеп эчелде. Ашау-эчү дә бик садә корылды. Мөәззин абзый кунакларны һәр көнне яңа суелган тәкә ите берлән сыйлады. Абыстай теләгән вакытта кайнаган каймак, сары май, былтыргы балны кызганмады. Хосусән, атналар үтеп китеп, Анна мөәззиннең кызын русча укыта башлагач, яшь мулла хатынын кул һөнәрләренә өйрәтә башлагач, боларның кадере артты. Кунаклык зурайды. Теләсәләр кай вакыт җигеп чыгарга ат бирелде. Теләсә кая барырга ихтыярларына көймә бирелде.

Шәмси беренче атнада ук тазара башлады. Өч атна тулганда бик күп артып, тәмам авыруын онытты, тау менгәндә арымый башлады. Кылган чәчәк атканда, бөтен тау буйлары юкә чәчәге исенә манчылганда, Шәмси тәмам сәламәтләнеп җитте. Анна Васильевнаның күпләп төяп килгән даруларына ихтыяҗ бетте.

Ул, аз гына суык булдыйсә, Шәмсине казакиләргә төрүдән котылды. Аз гына юеш булдымы, аны бүлмәгә бикләп тотулар бетте. Инде аның вазифасы күргән бер су буеннан эче сыкрамаенча китә алмый торган Шәмсине коендырмауда гына калды.

Менә җыеннар җитте. Мөәззин кызы, мөәззин угылы, Анна, Шәмси, чирекләргә кымызлар тутырып, пар ат җигеп, җыеннарга йөрергә тотындылар. Алар анда ат чапканны, көрәшкәнне карадылар. Кичләрне курай мәҗлесләрендә хозур булдылар. Ашказар буе башкортларының моңлы дәртләрен, шул яланнар, шул болыннар исе чыгып тора торган «Тәфтиләү»ләрен, «Сакмар буйлары»н, озын иттереп йөрәктән чыгарып, авыртусыз җырлый торган, башкортларның иркенлеге, муллыгы бетүгә сыкрый торган Салават көйләрен тыңладылар. Шәмси шуларның эченә кереп китте. Ул башкорт кызлары берлән каршыга-каршы биеде. Тау башында, якты ай астында, курай тавышыны, Әтнә көенә биюне күрсәтте. Җырчыларга кушылып җырлады. Үзеннән-үзе шәһәрдә ишеткән мишәр көйләрен көйләде. Аларны Казанның соңгы көйләренә өйрәтте. Башкортлар берлән ярышып кымыз эчеште, башкорт картларының сөйләгән Гәрди кантон хикәяләрен, Ари майлер экиятләрен, Салаватулла кыйссаларын тыңлады. Шул картлар кебек, ул да, шул хикәяләрне сөйләгәндә, шул иске муллыкны кызганып, «Уһ!» дип куйды. Шул вакыттагы туй-төшем, җыеннарны сөйләгәндә, башкортлар кебек, ул да чүҗеп китте. Атаклы курайчыларның «Ашказар»ын курайлаганда, ул да сизмәенчә, «вас-вас» дип оеп калды.

Ул көне буйлары берлән үзенең ялгыз түгеллеген, шул үз сахрада, шул үз халкы эчендә кунакта торганда моның берлән бергә ят бер кеше — моңарга бик зур хезмәт итүче, моны чахоткадан коткарыр өчен бөтен барын-югын фида итүче Аннаның барлыгын да онытты. Кай вакытларда шундагы курайның озынлап-озынлап көйләүләрендә Шәмсине коендырып, мәгъсумландырып куюларында ул: «Ник мин ялгыз түгел?» — дип куйды. Кайвакыт шул сахралар, шул таулар, шул кымызлыклар, җыеннар, курайларга ят тора торган Аннаны кайтарып җибәрим дигән уйга да керде. Ләкин авырый башлаганнан бирле иткән хезмәтләре, аны белә башлаганнан бирле күргән рәхәтләре хәтеренә килеп төште дә коты очты. Чынлап Анна китмәдеме дип тирә-юнен эзләде. Аны барып тапмаенча күңеле басылмады. Ләкин тагы шул уйга кайтты. Тагы шул Аннаның монда артыклыгы, ятлыгы башыннан чыкмады. Ярый әле хәзер шулай читтә тора, әтисе, әнисе белсә бит котлары очачак! Дуст-иш ишетсә бит дөньяга күренә алмаячак... Аннан бит, инде аңарга өйләнеп, өй ясап, балалы-чагалы булып торырга вакыт! Әйе, вакыт! Петербургка кайткач та аерылышырга кирәк тә өйләнергә кирәк. Анна үзе дә бит бер сүз дә әйтми. Аңарга инде бик рәхмәт, бик зур ярдәм итте, авырудан коткарып калды. Ике ел буенда тулы мәгънәле тормыш бирде. Хәятка каршы күзе ачылуга, рус дөньясын таныргa, рус мәдәниятен белергә хәлфә булды. Тормышның авыр минутларында дуст, иптәш булды. Матур минутларын матур итә белде. Үзен-үзе кызганмаенча, каршысына бернәрсә сорамаенча, рәхәтләрне бүлешә белде. Әйе, бик рәхмәт, гомергә онытмам! Ләкин мин — татар егете, өйләнергә кирәк. Мәсәлән, шул мөәззин кызы кебек бер кызга, ләкин Анна кебек дуст була белә торган, Анна кебек үз хисабын йөртми торган, Анна кебек гомерендә бер каты сүз сөйләми торган, Анна кебек тормышның һәр борылышыннан тәм ала белә вә тәм татыта белә торган бер татар кызына өйләнергә кирәк.

Әйе, ул өйләнә. Чын да, кемгә? Шәмси башыннан кызлар портреты эзләргә тотынды. Үзенең теләгәнен җанландырды, төсләндерде. Аның төсе Аннаныкы кебек йомшак кына, моң гына, аның күзләре хәтфәләндереп карый торган шәфкатьле генә, аның буе Аннага охшый төшкән, зифа гына, холкы-табигате тәмам Аннаныкы кебек йомшак. Төсе нинди?.. Татар кызы булгач, ул инде кара туткыллыррактыр. Юк, түгел. Татар кызларында да бик ак йөзле, саргылт чәчле, зәңгәр күзлеләре

була. Җырлаганда аның тавышы Аннаныкы кебек үк йөрәктән чыкса да, аның көе шул «Ашказар». Ләкин ул, нигәдер, «Ашказар»ны мәдәниләндеребрәк, «Вечерний звон» кебегрәк иттереп җырлый. Сүзе, тавышларының әйләнүе дә Аннаныкы кебек. Әйе, ул менә шундый татар кызына өйләнергә тиеш. Өйләнә, өйләнә... Ләкин, ни өчендер, аның шул татар кызы башына калфак кисә дә, төсендә-битендә Анна булды да килде дә басты. Ул хәтта Анна тавышы берлән русчалап ук сөйләп тә җибәрде. Юк, җитте. Алла сакласын, әллә ниләр булыр! Кушылу бар, аерылу бар. Бала-чага юк. Хуш, дусткай, рәхмәт! Петербургта аерыламыз.

Ул шул уйны уйлады гына түгел, шуңарга хәзерләнде дә. Петербургка баруны кора башлагач, планны да мотлак аерым торуга таба борды да вә шуны ачык иттереп Аннага сөйләде дә.

*

Тазарып, сәламәтләнеп, август башы җитеп Петербургка кайткач, Шәмсинең урынсыз калганлыгы беленде. Җыелган акча даруланырга, дәваланырга беткәнгә, тормышны кечкенә кормый хәл булмады. Аннаның да урыны булмаганга, икесенә бер бүлмә алып тора башладылар. Анна, иске танышларын табып, машинада язарга тотынды. Расход аз чыксын өчен, үзе аш пешерде. Шәмси гәзитәләр аша, дустлар, танышлар аша урын эзләргә керешге. Көн үтте, ай үтте, урын табылмады, эш булмады; икесенә дә Аннаның машинадан алган акчасына торырга тугъры килде. Көз булды, суыклар китте. Шәмсинең туны ломбардта булганга, аның суык тиюе чахотка алуы берлән бер булганга, дәһшәтле булып тун мәсьәләсе туды. Анна көнен эшләде, төнен эшләде. Йокламаенча, хәл җыймаенча зур бер эшне тәмам итеп, Шәмсинең тунын алып кайтты. Үзенең дә көзге киеме булмаса да, мин өшемим дип, ныгыган булды, язгы киемнәрдә йөри бирде.

Менә, Аллага шөкер, Шәмси урын да тапты. Тагы нинди урын! Әүвәлгеләренең һәммәсенә караганда эш аз, һәммәсенә караганда жалуниясе күп. Иң күңеллесе шул: Шәмси бу урында ярты хуҗа. Мөселман сатучы-алучы берлән эш итәчәк. Үзе алыш-бирешне караячак. Тизрәк, жалунияне алдан алып булса да, Аннага кием-салым алырга кирәк. Шәрекъ кичәләре җиткәнче, үзенең өстен-башын төзәтеп алырга кирәк. Беренче эш, әлбәттә, аерым бүлмә тоту. Анна берлән аерылу шактый авыр

булачак... Лəкин мотлака аерылырга тиеш. Анна үзе дə сөйли...

Акрынлап кына башларга кирəк вə шул фикергə акрын-акрын гына өйрəнə-ияләшə башларга кирəк. Лəкин әле берəр ай, ичмасам, Аннаны хəл җыйдырырга, аның атналар буе этлəнеп ятуларын туктатып, иркенчəрəк торырга кирəк. Яңа елларга таба авылларгамы кайтып килер. Болай гынамы, шома гына иттереп үзенə бүлмə тотар. Элгəре барып-килеп йөрерлəр. Акрын-акрын аны сирəклəйтер. Баскыч-баскыч, инə-инə аны тəмамлар. Аннан соң тəмам хөр кеше булып өйлəнер, туй итəр. Үз хатыны берлəн, Анна берлəн торган кебек, тулы-күңелле, мəгънəле иттереп тора башлар. Əйе, шулай итəр, шулай. Карар бирелде. Лəкин хəзергə һичбер ни белгертмəенчə, Аннаны, мескенне, хəл җыйдыру...

Алдан алган егерме биш сумны күтəреп, ул зур мивə[1] кибетенə керде. Алмасыннан, əфлисуныннан, йөземеннəн, вареньесыннан əллə никадəр нəрсə алганнан соң, кондитерга кереп, пирожныйлар, коры-сарылар төяде. Кулын талдыра-талдыра күтəреп кайтканда очраган чəчəк кибетен дə буш калдырмады. Аннан да Аннаның сөйгəн лалəсеннəн, кызыл гөленнəн пөхтə генə бер букет ясатып алды. Һəммəсеннəн күтəреп кайтырлык булмаганга, арбачы алып өйгə юнəлде. Аннаның шатлыгыннан башы күккə тиячəген уйлап, тагы шатлыкка чума-чума баскычтан менгəнен сизми дə калды. Кызу-кызу иттереп ишекне шылтыратты. Ишекне ачу берлəн, бөтен əйберлəрне күтəреп, шатлыгын җыя алмаенча, бүлмəгə килеп керде вə Аннаны язып утыра дип уйлаганга:

— Урын алдым,— дип кычкырды. Тавышның зурлыгыннан үзе дə өркеп китеп, тирə-юньгə каранды да, караватта бөтəрлəнеп яткан Аннаны күреп, бүлмə уртасында катып калды. Ул, əйберлəрен кая итəргə белмəенчə аптырап калып, аның янына килде:

— Ни булды? Ни эшлəдең? — дип, бөтен барлыгы дикъкатькə əверелеп, Аннаны сөзде.

Анна борылды, сузылды, тормакчы булды. Шəмси аның күзенең елый-елый кызарып беткəнен күрергə өлгермəде, ул тагы кычкырып-кычкырып еларга тотынды. Тагы бөтəрлəнде, тагы үксеп-үксеп елады. Шəмсинең кəефе бердəн югалды. Үзе-

---

[1] *Мивə* — җилəк-җимеш.

нең алган шул мивәләре, коры-сарылары, чәчәкләре артык кебек, кирәкмәс кебек тоелды, эчен пошырды. Тунын салмаенча гына:

— Ни булды? — дип, янына утырды. Ул аның башын тотты. Ут кебек яна торган баштан кызулык өреп китте.

Шәмси:

— Син авырыйсың? Суык тидеме? Әйе, шулайдыр. Бу суыкта соң җәйге пальтодан йөреп кара,— дип, үзенең тунлы булуы өчен тагы вөҗданы газапланып алды.

Шәмсинең сүзләре, кыйлынышларымы, күзенең кызганып карауларымы тәэсир итте, ни булса да булды, Анна акыртын гына сабырлана башлады. Ул көчләнеп-көчләнеп үзенә килә язды. Күзен ачты. Хәйрангарак калып карап тора торган Шәмсине күргәч, тагы бер үксеп китеп-китеп елады. Ләкин тиз генә туктады да акыртын гына торды. Шәмси: «Җә, ни булды? Сөйлә!» — дигән кебек, бөтен кыяфәтен сөаль галәмәтенә әйләндерде. Анна бик озак әллә ни әйтергә җыенса да, тагы әйтә алмаенча: «Не могу!» — диде дә үксеп егылды. Шәмсинең күңеленә саташмадымы икән дигән шөбһә төште. Ул, киемнәрен салып, янына килеп утырды. Йомшак иттереп, сөемле сүзләр берлән юатырга кереште.

Анна тагы бераз рәткә килде. Шәмси, тагы бозылып китмәсен дип:

— Эчәсең киләме? Ашыйсың киләме?.. Менә мин никадәр бүләк алып кайткан идем,— диде.

Анна башын игәч, ул хуҗа хатыныннан самавыр сорады. Сабыраеп килә торган Анна янына килеп, үзенең урын табуларын, урынның зурлыкларын мактады. Торырга җыенган Аннаны тотып торгызды. Краннан үзе су алып килеп, салкын су берлән Аннаны үзе юындырды. Анна тәмам кеше кебек булды. Ләкин аның йөзеннән куркумы, кот очумы, әллә нинди ят бер сызык китмәде. Алмалар, виноградлар янына илтеп утырткач, Шәмсинең тагы бер мәртәбә сорыйсы килде. Ләкин Аннаның кызганыч йөзен күргәч, тагы туктады. Күңелендәге куркуын бетерер өчен, тиз-тиз сөйләп, чәй эчәргә тотынды. Аннаның суык кулыннан сыйпады, кадерләде. Үзе чәй ясап бирде. Алманың асылын сайлап алдына куйды. Менә ул чәен күтәрде. Анна, зур бер йөкне ташлый торган кебек, авыр иттереп сулады да:

— Шәмси, мин корсаклы,— диде. Үзе, күзен-битен яшереп, Шәмсинең итәгенә егылды.

Шәмсинең бердән бөтен тәне катты. Йоткан чәе бугазына тыгылды. Бөтен әгъзаларыннан суыклы-әчеле бер агым үтте, кисәктән башына сугылган кеше кебек, иләс-миләс булды да калды; башы уйламады, фикер йөремәде, әллә нәрсә генә, менә хәзер генә өсткә салынган бер ят нәрсә генә басты, изде. Албасты пәрисе баскан кебек басты. Тынын бетерер өчен, тончыктырыр өчен басты. Бүлмә караңгыландымы, ул янындагы елый торган Аннаны күрмәде, колагы саңгырауландымы, аның кычкырып елаганын ишетмәде.

— Нәрсә? — диде.

— Мин корсаклы,— диде.

Әйе, ул корсаклы... Менә бераздан соң аның сары гына, йомшак кына бер баласы була, юк, аныкы түгел, Аннаныкы. Аннаныкы түгел. Юк, аныкы. Ул баланы чиркәү суында коендырып, Вася, Яша дип исем кушалар. Ул бала, ягъни ул Вася, ул Яша, Шәмсинеке була... Шәмсинең баласы була. Белемсез баласы була. Шәмси үзе ничек әтисе Габдулла угылы булса, бу да шулай Шәмсинең угылы була... Ләкин Шәмсинең әтисе — әти. Бу шул сары урыс малаена баба була. Василий Шәмсиевич була... Шәмси үлсә, ул да ягъни Шәмсигә дога кылырга чиркәүгә бара. Аның рухына төртенә, аның котылуы өчен шәм куя...

Бердән шуннан китим дигән уй туды. Ул Аннаның башы кәнәфигә төшкәнен хәтерләмәенчә дә торып чыкты. Идән уртасына җиткәч: «Кая?» — дигән сөаль басты. Чын да, ул хәзер кая китә ала? Ул бит хәзер баба... Кая китсә, бабалыгын бетерә ала, оныта ала?..

Менә Анна сикереп торды. Ул, тилергән кебек, Шәмсигә килеп ябышты, аның кулыннан тартып:

— Тукта, тукта. Син мине тыңла, тыңла!! — дип, һәр сүзенә яшь катыштыртып, яшенә тыгыла-тыгыла башлады.— Син мине гаеплисең. Беләм, ләкин... миндә һич гаеп юк... Кымызда мин бер эш эшли алмадым. Кайтканда, Самарада акушеркага бардым. Бер ярдәм булмады. Монда кайткач, үз таныш акушеркама йөредем. Берни булмый, бетә, бетә дип ышандырды. Төрле юлларда маташты. Ахырдан, шөбһәгә төшеп, таныш докторына җибәрде, ул өйдә булмады. Аны атна көттем, ике атна көттем. Кичә кайтты. Бүген менә ике доктор җыелып карадылар, мөмкин түгел, вакыты үткән, бишенче айлык диделәр. Аңлыймсың, мин һәммәсен кылдым. Һәммәсенә разый булдым. Аякларына ятып ялындым. Бертөрле дә сүз үткәрә алмадым. Хәзер менә синнән бер генә нәрсә үтенәм: син миңа

юри иткән дип шөбһәләнмә. Теләсәң, бүген кит. Баланы үзем тәрбия итәм. Ләкин мине шул ышанмавыңнан коткар,— диде. Тагы муенына асылынып еларга кереште.

Кирәк күз яшьләре, кирәк элгәреге кылган эшләре ялганлый дияргә һичбер юл калдырмаганга, Шәмси әлбәттә ышанды. Тормышның шул фактысы алдында тез чүкте. Ләкин ике арага, әллә нигә бер суыклык катышты. Шәмсинең күңеленең бер кырыенда Анна аның бәхетене урлаучы, аның аталыгын урлаучы, аны мәңгегә өйләндермәенчә, никахсыз калдыручы кебек иттереп килеп басты. Аннаның да күңелендә, аналык күңелендә, әллә нәрсә мыскыл ителде. Үзенең шулкадәр авыр хәлендә Шәмсидән иптәшлек, дустлык күрмәде. Юату, шатлану йөзе күрмәде. Аны да хурландырды, мыскылландырды. Аның күңеленә суыклык сипте. Җылыда беленми торган, кояшта да эреми торган салкын бер боз очратты. Магазиннан кайтканда, хәзер Шәмси элгәреге кебек ашыкмый башлады. Иптәшләре, дустлары берлән бер җиргә барырга тугъры килсә, шатлана-шатлана барды. Анда кичнең ахырына кадәр калды, уен-көлке арасында үз эченә үзе чумып, югалып торгаласа да, ашау-эчү мәҗлесләрендә эчте, көлде, сипте. Тәмам үзен-үзе онытып, элгәреге Шәмси хәленә, дөньяга якты күз берлән карый торган Шәмси хәленә керде. Ләкин, әллә ни эшләп, мәҗлесләр озаеп китепме яисә эчемлек азрак булып китепме, Шәмси вакытыннан иртә айныса, ул тәмам кара җут кебек булды. Салкын боз кебек мәҗлесне суытты. Берни сөйләмәенчә, көлмәенчә, уйнамаенча, бөтен мәҗлеснең өстенә авырлык сипте, күңелсезлек, өметсезлек берлән томалады. Аның шул гадәтен белеп, дустишләре аны күбрәк эчерергә тырыштылар. Үз бәласен үзе белеп, Шәмси, үзе дә тәмам исергәнчә, үзенең эчендәге әллә нинди кытыршылар тигезләнгәнчә, күңеленең бер кырыенда ябылып тора торган уй — Анна, бала мәсьәләләре ябылганча, зур-зур кабып эчүчән булды. Тизрәк исереп, кәефле хәлгә килүчән булды. Күңелендә һаман аерылу дигән мәсьәлә бетмәсә дә, башының буш вакыты һаман төрле-төрле юллар берлән шул уйны уйласа да, ни өчендер, хәзер үзенең Анна берлән булган гаилә хәятын үзгәртүдә, Анна урынына корбан бәйрәм җитә башлаганда корбан чаласы иде дип чубаланып йөри торган, рамазан бәйрәме җитә башладисә, камырларым гына уңармы икән дип, ике атна элек шәһәр буеннан кирәк-яракны эзләп йөри торган Фатыйма берлән алыштыру да, кич берлән магазиннан кайтуы берлән күкрәк кесәсеннән татар гәзитәсен-

журналын алып, чәй янында кычкырып укый торган Гайшәгә алмаштыру дип кенә карый алмады. Тагы шуның өстенә өченче бер матдә, өченче хаклы бер кеше килеп басты. Һичбер кем берлән алмаштырырга мөмкин түгел, һичбер төрле хакыннан чыкмый торган, иң авыры — һичбер төрле юл берлән хакын сакларга тырышмый торган бер бала, Васямы, Яшамы, килеп басты. Шәмси үзе разый булды, Аннаның бирә торган тормыш күңеллелекләреннән, тормыш матурлыкларыннан ваз кичте. Әйе, татар хатыны берлән үз тормышын бүлешер өчен, барын-югын бергә күрер, бергә татыр өчен татар баласы булгач, татар гаиләсе ясап, татар балалары тудырыр, үстерер өчен, үзенең шәхси кызыклыкларын корбан итте. Анна да разый булды. Әйе, ул да шул, бер-берсенә буйсынмый торган, бер-берсенә баш ими торган, бер-берсенә мөмкин кадәр хөрмәт итешеп, бер-береннән мөмкин кадәр күбрәк тормыш ләззәте ала торган хәяттан ваз кичте. Ләкин Яша, Вася ни эшләде? Аны бабасыз калдырырга кемнең хакы бар, аны тәрбиясез калдырырга кемнең көче җитә? Шул чуалчык Шәмсинең башыннан китмәде. Ике арага өченче бер кешене кушып торганга, торганча торамыз әсасенә[1] корылган гаилә хәятына мораль дигән бер матдәне кушты. Шәмси алай бөгелде, болай бөгелде, болай уйлады, тегеләй төшенде. Үзендә шул баланың хакын аяк астына таптарга көч тә, куәт тә таба алмады. Шул эшкә факт булды инде дип ышанып, кабул итәргә вә Анна берлән ирлехатынлы булып торып китәргә вә шул тормышны зурайтырга, менә эзләгән гаилә тормышым дип, шуны матурайтырга, шуны түгәрәйтергә тырышырга тагы әллә нәрсәсе ирек бирмәде. Мәдрәсәдә алган тәрбиясеме, әллә, ничә елдан бирле өйләнәм дип, татар кызына өйләнүне төшенүе, аның туйларына, төшләренә кадәр татар гадәте, татар йоласы буенча иттереп фараз итүеме, гаилә тормышы дигән хәятның фасылын бөтен вакларына кадәр татар исенә буяп, татар төсенә бизәп, уйлап килүеннәнме, шул бергә торуны, шул ике арада балалар тудырып, бергә яшәүне гаилә тормышы дип карый алмады. Уйласа да, төшенсә дә, Шәмси шул дәвә кошлыгыннан чыга алмады. Үзенең күңелендәге шул берсенә берсе тирес килә торган икелекнең сугышыннан, кырылышыннан котыла алмады. Анна да үзгәреп китте. Сөю-сөелүгә башка һичбер уй-төшем катышмаган, һичбер файда, зарар уйланылмаган, сөю-сөелүдә элгәреге

[1] *Әсас* — нигез, төп.

хөрлекне, элгәреге киңлекне бетердеме, әллә анда да шул өченче кеше кереп басып, үзенең хакын ике арага куштымы, әллә Шәмсинең күңелендәге икеләнү аңарга да ингыйкас[1] иттеме, ул да суынды, ул да үз эченә качты. Ул да күңеленең әллә кай бер җирендә кытыклый торган нәрсәсен бетерер өчен күз яшьләре сыгарга тотынды.

Шәмси авырый башлаганнан бирле беткән хисап кәгазе тагы мәйданга чыкты, язу машинасы тагы төне-көне чык-чык эшләргә тотынды. Шәмсинең үгетләре, үзенең авыруы, ябыгуы да аны эштән туктатмады. Ул, күңелендәге әллә нинди бер планны тутырыр өчен, язмыштан килгән бер бурычны түләр өчен эшли торган кеше кебек, баш имәенчә, күңелен төшермәенчә эшләде. Язга таба кояш карый башлагач, бер көнне озын гына тик торганнан соң, Анна:

— Шәмси, миңа хәзерләнергә вакыт җитә. Монда кеше өстендә авыр булачак. Шуның өчен мин фатир алырга карар бирдем. Кечкенә генә фатир да таптым. Җиһаз-фәләнен дә айлап түләргә мөмкин булды. Мин киләсе атнага шунда күчәм. Теләсәң, сиңа да анда бер бүлмә бар. Теләмәсәң, монда кал. Мин ул бүлмәне бирермен,— диде.

Шул сүзләрне никадәр каты иттереп әйтсә дә вә шуннан соң да шул ирлегендә тормакчы булып тырышса да, күзеннән яшьләре мөлдерәде. Сүзен озайта алмаенча чыгып китте. Шәмсинең алдына тагы теге мәсьәлә килеп басты, тагы шул өч елдан бирле бәйләнеп килгән мөнәсәбәтне кисәргә, бер кизәнү берлән өзеп төшерергә көче җитмәде. Күңеленнән разый булмаса да:

— Ник миңа башыннан ук сөйләмәдең? Миндә бит акча бар. Нигә бурычка алырга-фәләнгә,— дип шелтәләнергә тотынса да, Анна өй җиһазларын бергә алырга разый булмады.

Ул үзе хуҗа булып фатир алды. Үзе фатирны җиһазлады. Хезмәтче хатын алып, аны эшкә, ашка өйрәтте. Үзе һаман машинасында булды. Бала туу никадәр якынлашса да, ике арада һаман суыкчарак калды. Менә бер төнне Анна Шәмсине уятты. Ул җыерылган битләре, көзән җыерган куллары берлән бөтен көчен, куәтен кычкырмаска сарыф итеп, фәлән урамда, фәлән йорттагы акушеркага барырга кушты.

Хезмәтче хатынын уятып, коты чыгып, Шәмси акушеркага чапты. Вә алып килгәндә Аннаның йөзендә, битендәге көчләнүдән коты очып, акушерканың:

---

[1] *Ингыйкас* — чагылу.

— Сезнең кирәгеңез юк,— диюенә шөбһәләнә-шөбһәләнә чыгып китте. Урамда озак кына йөргәннең соңында да таң атмагач, арбачылар өчен генә ачылган төнге чәйханәгә кереп чәй эчте. Күңел аның берлән дә басылмагач, тагы өйгә килеп чыкты. Тагы Аннаны әче кисү уртасында табып, акушерканы тагы ачуландырып, хезмәтче хатынга: бер-бер ни булса, магазинга телефон берлән сөйләргә кушып югалды. Өйләгә кадәр сөйләүче булмагач, ул, аш вакытында ат алып, кызуланып кайтты. Тагы Аннаны бик авыр хәлдә тапса да, тагы һичбер нәтиҗәсез көенчә, асраугa сәгать саен күрше аптекарский магазиннан хәбәр итеп торырга кушып китте. Магазинга баргач, йөзе-күзе берлән телефон көтәргә тотынды. Сәгать өчтә телефон булды. Һаман берни юк. Бишенче яртыда тагы телефон булды. Аны акушерка чакырды:

— Хәл бик авыр. Доктор чакырыйкмы?

— Чакырыңыз, чакырыңыз... Кирәк булса, икене чакырыңыз.

Тагы берни дә юк. Тагы ярты сәгатьтән телефон.

— Ләкин Анна Васильевна сезне чакыра.

Шәмси арбачыны кызулый-кызулый кайтып керде. Өй тузган, әллә ни суыгаеп киткән. Бөтен бүлмәләргә әллә нинди дару исе, төче бер ис тулган, борынны ярып керә торган бер ис тулган...

Шәмсинең бүлмәсендә ак җилән кигән бер еврей докторы әллә ниләр язып маташа.

Шәмси тиз генә киемнәрен салды.

— Ни хәл, доктор?

— Хәл начар, бик начар... Өмет бик аз. Менә хәзер үземнең иптәш докторыма хат язам. Операциясез булмас. Хатыныңыз ничә яшендә?

Шәмси аптырап калды. Чын, ничә яшендә икән? Туктап тормас өчен:

— 26 да,— диде.

Доктор:

— Әйе, әйе, егерме алтыда беренче бала тудыру бик авыр, бик авыр, бик авыр,— диде дә язуында дәвам итте.

Йөзләренә, төсләренә аруы чыккан, әллә нинди искә буялган акушерка килеп чыкты. Докторга әллә нинди латин сүзе әйтте дә Шәмсигә:

— Сезне көтә, күп сөйләмәңез,— диде.

Шәмси бүлмәгә керде. Караватка сузылып яткан Анна күзен күтәрде. Аның күзләре көя төшкән, бите бер көн эчендә ике еллык ябыккан, кулы дер-дер калтырый, тешләре шакый. Акыртын гына тавыш берлән:

— Кил,— диде.

Шәмси барган саен ис күбәйде, барган саен аның аяклары калтырады, күңеле курыкты, йөрәге кызганды, күзе йомшады. Акыртын гына караватка барып басты. Анна, күрсәтеп:

— Утыр,— диде. Шәмси идәнгә утырды. Анна йөзе берлән борылды.

— Ни хәл? — диде.

Анна, җавап бирмәенчә, кулы берлән акыртын гына аның башын сыйпады. Акыртын гына бармаклары берлән башын чәпәй-чәпәй итте. Шәмси бармакларның йөрүен генә түгел, шуларның калтыравын да хис итте. Анна, кулы берлә Шәмсинең битен үзенә таба борып, күзе берлән Шәмсигә таба текәлде, бик озак карап торганның соңында:

— Шәмси, мине гафу ит, мин сине сөйдем,— диде.

Үзе тынды. Шул сүз, әллә ничәнче мәртәбә ишетелгән сүз, пычак кебек үткен булып, Шәмсинең киемнәрен, тәнен кисеп йөрәгенә кереп утырды. Үзенең җәрәхәтеннән агыза торган кан берлән тәмле кебек булып исертте, әче кебек булып әрнетте.

Анна, дәвам итеп:

— Мин үләм... Мин үлгәч, әнигә хат яз... Ул килер, аңарга бөтен нәрсәләремне бир. Менә бу йөзекне үзең ки,— диде. Кулыннан акыртын гына салып, кашлы бер йөзек бирде.

Шәмсинең күзенә яшь тыгылды. Тамагына әллә нәрсә аркылы килде. Күзеннән ага торган яшен туктатыр өчен тырышып:

— Мине гафу ит, Анна, мин сиңа соңгы вакыт катылык иттем...

Анна, җавап урынына, кулы берлән башын чәпәй-чәпәй итте.

Йөзенә аз гына елмаю килде. Акушерка артыннан төртте.

Шәмси, торып, Аннаның маңлаеннан үпте. Кулын кысты:

— Терел, Анна,— диде. Тагы әллә ни эшләп бетермәгән кебек булып китте дә Аннаның селтәгән кулын алып үпте... Аннаның күзендә тагы елмаю кебек бернәрсә күренде.

Ул чыгып китәргә өлгермәде, әче тавыш берлән Анна кычкыра-көчләнә башлады. Доктор:

— Сезгә монда булудан файда юк. Безгә мешать итәсез. Чыгып китеңез инде,— диде.

Шəмсигə баскычта карт кына поп берлəн искерəк кенə киенгəн дьякон очрады. Кулларында əллə нилəр, Инҗиллəрме, тəрелəрме күтəреп, алар Шəмсилəрнең ишеклəре төбенə туктадылар.

«Әйе, Анна үлə. Шəмсинең баласыннан Анна үлə. Шəмсинең хатыны үлə. Аны теге дөньяга озатырга, Шəмси баласын каршы алырга болар килделəр...»

Ул, үзен-үзе сизмəенчə, кызулана-кызулана чапты, качты.

*

Шəмсигə кинəттəн мөһим бер эш берлəн Төркстанга китəргə тугъры килгəнгə, ул Аннаның терелеп җитүен дə, баланың яшəрлекме-түгелме икəнен дə белмəенчə сəфəргə чыкты. Эш күп, чуалчык булганга, ул шəһəрдəн шəһəргə йөрде. Андагы базарлар берлəн танышты. Чыга торган малны өйрəнде. Барган җирлəреннəн Аннага кая китүе хакында кыска-кыска гына ачык хатлар гына җибəрсə дə, һəрбер барган шəһəрендə Аннадан озын-озын мəхəббəтле мəктүблəр алды. Анна əүвəлге хатларында терелеп килүе, баланың тазалыгы хакында язды. Бара-тора, авыруны тəмам онытып, Шəмсине сагынуыны язарга тотынды. Ахырга таба алган хат изһар мəхəббəт берлəн тулды. Аның гади җөмлəлəре үзенең садəлеге берлəн Шəмсинең əллə кай җирен кытыклады, əллə нəрсəсен сөендерде. Төркстанда кызулар китте.

Анна да Петербургта җəй булуны, үзенең тимер юл буенда, ерак түгел генə, 25 минутлык җирдə дача алуын, Шəмсине бик көтүен язды. Төркстандагы күчмə тормыш бик туйдыргангамы, əллə Төркстанда хатын-кызсыз тору, яшəү арыткангамы, ялыктыргангамы, Шəмси чын күңеленнəн Петербургны, аның мəдəни уңайлыкларын сагына башлады. Хосусəн Аннаның дача алдым дигəн сүзе аның алдында əүвəлге елгы дача хəятларын күз алдына китереп, һəммəсен бердəн җанландырды. Һəммəсе Шəмсине үзенə чакыра, тарта башлады. Номерның начарлыгы аның күз алдына үзлəренең өенең уңайлыгын хəтерлəтте. Самавырның каралыгы, хезмəтченең тупаслыгы Аннаның мөлаемлыгын, аның тəмле ашларын күз алдына китереп бастырды. Урамдагы капчыкларга тыгылган сарт[1] хатыннарының коточкыч киемнəре нечкə генə, юка гына, оста гына киенə

[1] *Сарт* — үзбəк.

торган Аннаны күз алдыннан җибәрмәде. Ул чынлап та сагынды, чынлап та кайтасы килде. Тагы күңеленең бер кырые, әйтергә ярамый торган бер кырые берлән теге баланы, боларның арасындагы хөрриятне агулаган баланы, сары башлы урыс баласын күрәсе килде. Шуларны барын да Аннага язды. Аңардан тагы кайнар мәхәббәтле хатлар алды. Майның ахырында гына кайтырга чыкты. Июнь башында гына өйдә булды. Анна аны күктән төшкән кебек каршы алды. Өрмәгән урынга утыртмады, балалар кебек кадерләде, хөрмәтләде, сыйлады. Актык мәртәбәсе кебек сөйде.

Шәмсине йомшак, матур, җылы, тулы тормыш берлән каплап алды. Бер атнага алган миһләтендә Шәмсине тагы башкорт кантоны кебек кадерләнергә, ялкауланырга өйрәтеп җиткерде. Бала да, теге сары башлы урыс баласы да, Шәмсине күңелен чиркандырмады. Ул һичбер сары түгел, кап-кара башлы, түгәрәк йөзле булырга хәзерләнеп тора. Авызы, борыны гына аныкы, анасыныкы. Югыйсә көлгән чагында бөтенләй Шәмсинең агасының баласы кебек булып китә. Шәмси акыртын гына аңарга өйрәнде, аңарга каршы әллә нинди үзе аңламаган бер хис биләде. Элгәре эченнән дошман күрү урынына кызганумы, әллә нәрсә биләде. Акыртын гына ул аны тота, сөя башлады. Акыртын гына үзлегенә өйрәнде.

Бу җәендә Анна тагы үзгәрә төште. Ул тагы Шәмсигә якыная төштеме, Шәмсине сөя төштеме, ул бөтен көчен Шәмсигә уңай итүгә борды. Элгәреге кебек үзе теләмәгәндә каршы килүләрне бетерде. Бөтен уен, бөтен тормышын Шәмси өчен генә борды. Мәкәрҗә җитеп, Мәкәрҗәгә барырга вакыт җиткәч, бик күңелсезләнде. Үзенең бара алмавына үкенде.

— Көн дә хат язып тор! — дип тугый-тугый озатты. Киткәндә күзеннән яшен дә яшерә алмады. Мәкәрҗә буе һәр көнне кебек озын-озын хатлар берлән күмде. Сараның исәнлеге-саулыгы хакында тулы мәгълүматлар бирде.

Кыш көне дә тормыш шул юлыннан барды. Рождество бәйрәмнәренә кунакка килгән Аннаның суфи анасы залларына тәре куйдырып, көн дә шәм яндырып торса да, Шәмсинең чырае сытылганын күреп, карчык китү берлән тәрене алып куймаса да, шәм ягуларны бетерде вә, Шәмсинең кәефе китмәсен өчен, Сараны крестить тә итмәде.

Ләкин быел тагы бер үзгәрү хис ителде. Анна Шәмсинең ялгыз йөрүләрен яратмый башлады. Андый-мондый татар театры-фәлән булдымы, мотлакан, үзе дә барды. Әүвәлге кебек

аерылып китмәде. Аның өйләнергә дигән сүзләренә кәефе китүен яшермәде. Вә кай вакытта баланы калкан тотып, ничек булса да ике арадагы мөнәсәбәтне канунландырырга тиешлеге хакында Истанбулга барыпмы, монда башка төрле юл табыпмы, никах ясауны сөйли башлады. Шәмси һаман әле шул тормышны гаилә тормышым дип ышанмаса да, элгәреге кебек, үзен егет иттереп хис итү аңарда да бетте. Мәҗлесләрдә кызлар-фәләннәр берлә дә очрашса, өйләнү, сөю хакындагы сүзләрдән качты. Никах хакында мәсьәләләр ачылса, минем ничеклегемне белә дигән кебек булып читкә китте. Вә агай-эне арасында үзенең ничек торуы хакында ап-ачык сөйләмәсә дә, юк-фәлән дип яшерергә дә алмады.

Шуны гына көткән кебек, Анна, бәйрәм тугъры килгәч:

— Ник сиңа кунаклар килми,— дип йөдәтте. Әллә кайдагы татар гаиләләреннән өйрәнеп, бәйрәм ашлары хәзерләде. Үзе бәйрәмчә киенеп, гаеттән соң Шәмси берлән бергә визитләрдән кайта торган иптәшләрен юлда көтеп алып, өйгә алып керде. Вә һәммәсен тәбрикләп, үзен поляк мөселманы дип таныта, бәйрәмчә киендергән балаларын чыгарып күрештерде. Икенче бер бәйрәмдә Анна Шәмсинең якыннарына, дустларына үзе тәбрикләп барды. Телефон берлән үзе Шәмси кайтуына хәзрәтне чакырды. Шәрекъ кичәсенә дә барып, ачыктан-ачык Шәмсинең хатыны булып йөрде. Кешеләр берлән танышты, сөйләште. Гомуми эшләр хакында фикер йөртте, икенче мәртәбә корсакка калгач, ул хәзер инде Шәмсигә әйтүне кирәк тә тапмады. Шәмси үзе белгәннең соңында гына:

— Мин угыллы буласым килә, угылым синең төсле булыр иде,— диде дә сүзне тәмамлады.

Ай үтте, көн үтте. Шәмсинең марҗа берлән торуы элгәре колактан колакка гайбәт иттереп кенә сөйләнде. Бара-тора мәйданга чыгып, ачык иттереп сөйләнде. Мөхакәмә ителде. Кызганылды, бара-тора өйрәнелде. Дуст-ишенең бик күбесе аны хатынлы иттереп танымады, аны бер вакытта да хатыны берлән бергә мәҗлескә-фәләнгә чакырмады. Яшьләр, иптәшләре әллә ничек аннан тартындылар. Җәмгыять эшләренә чакырмый башладылар. Үзара була торган кечкенә-кечкенә мәҗлесләрдән калдыра башладылар. Ул үзе дә, шуны сизенеп, читкәрәк посты. Әллә нидән оялган кебек, әллә нәрсә күренмәскә теләгән нәрсәсе күренмәсен дигән кебек, яшеренә төште. Җәмгыятьләргә бармады, халык күп очрый торган урыннардан качты. Икенче кызы тугач:

— Тагы менә насыйп булса, диндә иркенлек булыр да мөселман итәрмен, баермын да Истанбулга барып яздырып килермен, зурая башлагач, мөгаллимә алып, мөселманча тәрбия иттерермен,— дип, күңелен юата килде.

Ләкин күңеленең әллә кай бер җире ышанып җитмәгәнгә, кай вакытларны кайгыручан булды. Вә ярдәмчесе, киңәшчесе булмаганга, елап-елап намаз укучан, Алладан сораучан булды.

Аннаның Шәмсигә мөнәсәбәте һаман искечә булды. Ул һаман аны кадерләде. Һаман аның өчен генә яшәде. Һаман аның тормышын мул-тулы иттерергә тырышты. Ләкин аңарда да Шәмсинең китүеннәнме, югалуыннанмы курку бетмәде. Үзенең тормышының нигезенең тазалыгына иманы ныгымады. Һәрвакыт өмет берлән өметсезлек арасында торып, аның күңелен көчсезлек, зәгыйфьлек бер хис биләде. Аның күңелендә әллә нинди, күренми-беленми торган куәткә шул хәлне, шул бәхетле хәлне сакласын өчен сыгыну уе туды. Ул да Шәмси күрмәгәндә чиркәүләргә бара, чукына башлады. Марҗаларның:

— Балаларыңны чукындырмасаң, Алла сакласын, фәлән тәре шәфагать кылмас,— дигәннәренә ышанып бетмәсә дә, аларча булсын әле дип, Шәмсигә әйтмәенчә, аларны чукындырды да вә җиде ел бармаенча торган побына тәүбәгә баргач, аның тәмуг газаплары берлән куркытуына ышанмаса да, сиңа гафу булса, шул: балаларыңны христиан итүдә генә дигән сүзенә дә әһәмият бирмәсә дә, аларны зур бәйрәмнәрдә чиркәүдән калдырмый башлады. Вә этиләре алдында, аш алдында ияр тоттырмаса да, кичләрен яткырганда үзе чукындырып яткыручан булды.

Шәмси, балаларны татарча сөйләтергә өйрәтер өчен, алар берлән үзе татарча сөйләшмәкче булса да, гомеренең иң күп вакытын кибеттә үткәргәнгә, җәйләрен ярминкәгә барып бер-ике ай, кышларын йә Төркстанга, йә Себергә барып бер-ике ай үткәргәнгә, аннан да бер нәтиҗә дә чыкмады. Балалар, шул, татарчадан эти, әнине белеп, әгузе бисмилла әйтүдән уза алмады. Ләкин Шәмси күңеле берлән һаман шуларны мөселманча тәрбия итү уеннан кайтмады. Вә аларның чукындырылмауларын уйлап, Истанбулга илтеп мөселманча тәрбия итәм дигән уй берлән үзен-үзе юата килде.

Менә беркөнне, тиздән аңарга Мәскәүгә барырга тугъры килгәнгә, магазиннан кызуланып, вакытсыз чакта өенә таба китте. Трамвайга өлгерә алмаганга, җәяүләп килде. Яшелчә-

мивә базарына кереп, алма, карбыз алды. Вә балалары берлән актык мәртәбә ашап-эчеп, юлга чыгарга дип өйгә борылды. Кайтканда юлы үзләре тирәсендәге чиркәү яныннан үтәргә туры килгәнгә, урамның теге ягыннан барса да, әллә нигә күзе чиркәүгә таба төште. Аннан сирәк-сирәк кенә картлар, карчыклар, юан-симез марҗалар, балалар чыгып килә иде. Бердән тәненнән әллә нинди суык йөгерде. Ул чиркәү ишеге төбендә ике кулына ике кызын тоткан Аннаны күрде. Ул үзе простой гына киенгән, балаларның икесе дә шул арада гына тегелгән өр-яңа ак киемнәр, ак ленталы эшләпәләр кигәннәр, ак оеклар өстенә — кечкенә-кечкенә сары башмаклар. Шәмси бер карады — ышанмады, икенче карады — ышанмады. Менә Анна ишеккә таба әйләнде, аның берлән бергә балалар да әйләнде. Анна кулын күтәреп акыртын гына төртенә башлады. Аның артыннан балалар да төртенде. Аларның кечкенә куллары бер күтәрелеп, бер төшерелеп һавада уйнады. Шәмсине бердән җен биләде. Ул баскан җиреннән сикереп төшеп, шул балаларны Аннаның кулыннан тартып алмакчы булды. Аннаны сугып егып таптамакчы, измәкче булды. Әллә ни тотты, әллә ни тартты. Ул яшенә тыгылды, аягы катты. Тәнен генә түгел, күңелен дә көзән җыерды. Әллә нинди көч аны куды, балалары чукынган җирдән куды. Зыр итеп борылды да китте. Кая барганын белмәенчә, ни эшләгәнен уйламаенча, карбызын, кавынын күтәреп китте. Петровский паркка барып чыкты. Кызуланып-кызуланып аны башыннан ахырына кадәр әйләнде. Үзен кая илтәргә белмәенчә, аннан да чыкты. Пароходка утырды, ул туктагач, аннан да төште. Тагы кавынын, карбызын күтәреп, Невский буйлап үтте. Шул ук карбыз-кавын берлән, киемсалым, мендәр-фәлән алмаганын онытып, Мәскәү поездына да барып керде. Бик озак вагонның тышында яланбаш басып барганның соңында гына фикерен җыя алды.

Әйе, дөрест, шулай булды, ул Аннаны чиркәүдән чыкканын күрде, балаларын — үз балаларын чукындырып торганда очратты. Шулай булырга тиеш иде, шулай булды.

Бөртек-бөртек яшьләр коелды. Йөрәк әрнеде, күңел сыкрады, гакыл хәйранлыкта калды.

Мәскәүгә килеп җитүе берлән озын итеп Аннага хат язды. Күргәннәрен һәммәсен сөйләде. Үзенең мәңгегә аерылачаган әйтеп, калган сберегательный билеты берлән акча алырга кушты. Вә айлап та биреп торырга да вәгъдә итте.

Мәскәүдәге хуҗаларының эшләрен тәмамлаганның соңында, аларга атасы үлә икән, өйгә кайтып киттем дип хат язып, авылына юнәлде. Юл буе шул мәсьәләне тәмам бетерер өчен үзенә хәзер өйләнергә кирәк дип утыртып куйды вә кайтуы берлән өйләнергә, чибәр генә бер мөгаллимәгәме, мулла кызынамы өйләнергә булып төенләнде.

*

Авылда ул иркенләп киткән кебек булды. Авыл мәчетенең җомгалардагы сасысы да аңарга мөкатдәс сыман тоелды. Авыл мулласының каткан чапан, майлы кулны сөртүдән ялтыраган читеге дә матур, урынлы кебек күренде. Ул зиратка йөреде. Әбиләре-бабаларына хәзрәттән Коръән укытты. Ерактагы Гайникамал остазбикә чишмәсенә корбан чалып, тиресен хәзрәтләргә бирде. Әтисе-әнисенә:

— Өйләнергә кайттым,— дип сөендерде. Үзе күрше авылларның мулла кызлары, мөгаллимәләрен сораша башлады.

— Тегендә инде бит бетте. Инде өйләнергә, үземчә торырга хакым бар, өйләнергә тиеш, өйләнергә. Болай да кайтмыйм да кайтуын. Өйләнгәч бигрәк Аннага таба кайтырга һич юл, урын калмаячак. Әйе, әйе, шулай.

Үзен шул фикердә беркетү өчен, ул хәзрәтенә барып та киңәш итте. Аның фатихасын да алды. Әнисен, Ходайга тапшырып, күрше авыл мулла кызын сорарга да җибәрде. Өзеп җавап бирелмәгәнгә, көтәргә, бераз сабыр итәргә тугъры килде. Әллә нигә эче поша башлады.

Абзыйсының хатынының пычраклыгы җирәндерде. Моңарга сала торган түшәкнең бала исе төн буйлары үзенә йокы бирмәде. Ашлары тәмсез булды. Әтисе-әнисенең сөйләгәне мәгънәсез булды, абзыйсы берлән җиңгәсенең орышулары, берсенә берсе ямьсез сүзләр берлән кычкырышулары ялыктырды. Аңарда юксыну башланды. Әллә нәрсә җитмәү хисе көннән-көн артты.

Ул менә өйләнмәгән, менә мулла кызын ала, туй итә. Бик һәйбәтләп торып китә.

Ләкин ни өчендер ул һәрвакыт мулла кызын Анна кебек иттереп уйлады, аңарга мөгамәләләрен Аннага иткән кебек итәр төсле булды. Юк, Аннаны ул инде онытты, бөтенләй онытты. Аерылды, тәмам аерылды. Менә ул хәзер Шәмсинең өстеннән судка бирә, балаларын ашатырга сорап судка бирә. Шәмси хакында мәхкәмәләрдә әлләниләр сөйли, ялганлый.

Әйе, әйе... Бирсен, бирсен! Ул үз сүзеннән кайтмый. Балаларга ашарга бирәчәк, ләкин бергә торырга бетте инде.

Ул һәр көнне үзен чакырып сорауны көтте. Колоколлар килгәндә, миңа килде, дип хәзерләнде. Менә староста килде.

— Ә, килде,— дип, Шәмси чыкты.

— Менә монда сезгә кәгазь бар, волостьтан бир диделәр. Кул куеп алдым.

Шул, шул!

Шәмси зур гына пакетны кулына алды. Адрес Анна кулы берлән язылган.

— Ачыйммы, юкмы, әллә ачмаенча гына җибәримме?

Ачкач та открыткада Анна ике ягында ике кыз берлән төшкән рәсем төшеп китте.

Әйе, алар. Кара, кызлары нинди матур, күзләре, йөзләре икесенеке бертөсле, абзый кызына охшаганнар, ләкин болар пөхтәләр, нәзекләр, киемнәре нинди күңелле. Аларның өстләрендә ак кием, башларында ак ленталы эшләпәләр, аякларында башмак... Анна үзе, үзе ана кебек, ләкин әллә нигә ул шатланып елмаеп тора. Әнә аның елмайган күзләре Шәмсигә карап тора. Аз гына да ачуы килүе юк. Ул шул яхшы хатын... Чын хатын. Марҗа булмаса, мотлакан, мин шуңарга өйләнер идем... Хәзер мулла кызына өйләнәм...

Ул акыртын гына хатны укырга тотынды. Йомшак сүзләр, йомшак җөмлә аулары берлә ул акыртын гына Аннаның психологиясенә кереп китте.

Әйе, ул балаларны чиркәүгә алып барган иде. Ләкин ул фотографиягә барганда, үзенең әнисенең туган көне тугъры килгәнгә генә кергән иде. Балалар бик сагына. Һәр ашта, чәйдә «әти» дип көтеп тора. Сарасы бик озак ашамый. Әнисе егълаганын күрсә, әллә нәрсә сизенеп елый. Киемче яңа киемнәреңне китерде. Ни эшлим? Җибәримме, кайтуыңны көтсенме? Бер үпкә, бер шелтә юк...

— Угылым, сөенче! Муллалар бирергә разый, ди. «Үзе, Шәмсетдин килсен әле, үзе берлән күрешеп сөйләшик»,— дип әйтәләр, ди.

Нәрсәне сөйләшәләр? Әйе, ул бит яучы җибәргән иде. Ул бит инде Аннаны ташлады, ташлады. Ул, тәмам егет булып, яңадан өйләнә. Яңадан түгел, беренче өйләнә. Кыңгыраулар тагып, туй-төшем ясап өйләнә... Өйләнә... Барырга кирәк, барырга.

— Кайчанга соң барасыз, угылым, иртәгәдән арыгамы, аннан арыгамы?

— Барамыз, барамыз...

Балаларның төсләре, йөзләре Шәмсине ташламады. Аннаның көлеп карап торуы һаман күз алдыннан китмәде. Җиңгәсе берлән абзыйсының бәрәңге урлаган өчен балаларын кыйнаулары: «Тык, бирән, аша, кадалгыры!» —дип, каргый-каргый кыйнаулары тагы үз балаларын хәтерләтте.

— Аларга да шулай булмасмы икән? Юк, булмый. Ул үз балаларын алай иттерергә?..

Ашы тагы тәмсез булды. Әтиләре тагы юкны сөйләде. Эч пошты. Җиңгәсе юган күлмәктән сабын исе килеп торып борынны җәфалады. Зиярата барып килде, Коръән укыды, күңеле басылмады. Кич берлән йокыга китә алмаенча йөдәде. Төшендә балаларны, Аннаны күреп алҗып чыкты. Иртә берлән әтисе:

— Угылым, бару кирәк иде. Олугъ кешеләр. Мин трантасны майладым,— диде.

Әнисе, бүләккә дип, әллә нинди сасы катыклар чыгарып, баш кабартып йөрде.

Өйләдән соң волостьтан тагы хат килде.

«Сара авырый, өйдән чыкмый... Бикябыкты. «Мин әти кайткач тереләм»,— дип ята... Үзем исән. Кайчан кайтасың?..»

— Кайчан кайтам? Бер дә кайтмыйм. Әйттем бит, мин өйләнәм!..

Баш тагы чуалды. Балаларын, Аннаны сагынганлыгын икърар итмәсә дә, шуларны күрәсе, бергә утырасы килгәнгә, еш-еш карточканы чыгарып карады.

— Угылым, иртәгәдән калмаенча барырга кирәк. Муллалар көтәләр.

Әйе, көтәләр: тегендә Анна, балалар көтә. Монда муллалар көтә...

— Әйе, өйләндем, ди, мин инде ул кызга: «Мин сине бик сөям», димме?.. Әйе, шулай шул... Мин аңарга тыныч, бай тормыш бирәм, мин аңарга бүленмәенчә, тулы көенчә гаилә хәяты бирәм... Шулаймы?.. Әйе, шулай. Бу карточканы ертып ыргытаммы? Ыргытмасам соң. Ул бит аны күрми. Әйе, күрми... Аннаны онытам... Ул җиңги кебек каткан булса, җиңги кебек тупас, дорфа булса? Юк, ул Анна кебек уңган, пөхтә була. Аны мин Аннаны сөйгән кебек сөям... Мин Аннаны сөйдеммени? Юк, юк, ул болай гына. Күңеленең бер кырые көчләнә-көчләнә килде. Ул: «Юк, сөйдең, буны сөясең»,— диде. Ул тагы

карточканы карады: «И, бик искитәрлек инде. Безнең татарларда мондый кызлар беткәндер инде». Юк, ул өйләнә...

Әнисе төн буе камыр берлән маташты. Түшәктән сасы килүе бетмәде. Җиңгәсе берлән агасы тагы балаларын кыйнадылар. Менә йокыга китте. Төшендә Анна, балалар, шулар арасында — шәлгә бөркәнгән бер хатын. Бер мөгаллимәме, бер туташмы? Ул:

— Болар кем балалары? — ди.

— Болар, туташым, минеке... Әйе, минеке. Менә син дә минеке.

Шәмси икесен дә ярата, имеш. Маңлаена басып, песи баласы сикереп мич башына менде. Шәмси коты очып уянып китте. Сизәр-сизмәс:

— Анна,— дип куйды. Үзенең дә күзе шар кебек ачылды. Аннаны күрәсе килү, сызланып-сызланып күрәсе килү башланды.

— Син соң, әфәндем, ничек иттереп, бер хатынны сөйгәндә, һичбер белмәгән, сөймәгән, сөю ихтималың булмаган хатынны алмакчы буласың?

— Юк, мин үземне үзем коткарыр өчен. Татар гаиләсе ясар өчен,— дигән кебек булды. Күңеле ышанмады. Йөрәге карар тапмады. Күзен йомды. Тагы балалар, тагы Анна.

— Әнисенең сумсалары да уңган. Угылым, барып кил. Әйе, барып кил. Аннары туй итәрмез.

Шәмси тагы зиярәткә барды. Әтисенең җиккән атына бер сүз әйтмәенчә утырды. Абзыйсының ундүрт яшьлек малаен ат башына алды. Китте. Авылга барып җиткәндә тагы бер мәртәбә карточканы чыгарып карады. Балалар елый төсле, Анна кайгыра-сыза төсле булды. Авылга керделәр. Шәмси икеләнеп-икеләнеп килсә дә, муллалар янына җитә төшкәч:

— Үтеп кит,— дип, энесенә әмер бирде. Ул аптырап калганга: — Муллаларга кермә. Үтеп кит,— диде.

Муллаларга карамаенча гына авылдан чыкты. Сәгатенә карап стансага таба кызуларга тотынды. Анда барып җиткәч, әнисенең мулла хатынына кодагыйлык бүләге дигән сумсалары берлән урыска кереп чәй эчте дә, поезд килә башлагач, энесенә:

— Менә кәләпүш алырсың,— дип, акча бирде дә, үзе поездга утырып, Петербургка китте.

*

Анда аны берни булмаган кебек Анна каршы алды. Тагы Шәмсине кадерләвен арттырды. Тагы аның тормышын тулырак иттерергә бөтен көчен сарыф итте. Өченчегә авыры барлыгын әйткәндә дә:

— Монысы угыл була инде, төшемдә күрдем,— диде.

— Чыннан да, угыл булса ярар иде инде. Аннары өчесен дә Истанбулга бергә илтеп мөселман тәрбиясе бирдерер идем. Әле бит диндә хөррият тә була, диләр.

Ул тагы тора бирде. Тагы шул тормышка керә бирде. Тагы, хөррият диния була бит дип, үзен юата килде.

Көн үтте, ел үтте. Угыл да булды, кыз да булды. Ул һаман хөррият диния көтте. Һаман, байый төшкәч, Истанбулга илтеп мөселман тәрбиясе бирүне төшенде.

— Әйе, ул мотлакан Истанбулга илтә. Хөррият диния дә бит тиз булыр. Алар үскәләгәнчә булыр, булыр...

1916

Фатих Әмирхан
(1886—1926)

ХӘЯТ[1]

1. АХ, ХӘЯТ, НИНДИ МАТУР СИН!..

Майның бер якшәмбесе, көндезге сәгать өчләр иде. Бер сәгать кенә моннан әүвәл явып киткән җиңел яңгыр шәһәр урамнарының тузанын баскан һәм, һавадагы кызулыкны җиңелчә язгы җылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде. Әле һаман һавадан җуялып бетмәгән яз җиле, кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык вә тынычлык белән исә дә, дөньяга яңару вә яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы вә җансыз нәрсәләрне үзләренә бертөрле тереклектә коендыра иде.

N шәһәренең уртарак бер урамындагы Гыймадовлар йортының капкасы төбенә килеп туктаган кечерәк кенә тарантастан гимназия формасында киенгән 16—17 яшьлек чандыррак (ябыграк) кына гәүдәле, уртача буйлы, зәңгәрсу күзле, кыскарак, ләкин бик куе сары чәчле бер кыз төште дә җиңел адымнар белән ашыкмый гына капкадан кереп китте һәм, ишегалдына кергәч тә, каршысына очраган, искерәк вә шапшаграк киенгән, калын йөзле асрауны туктатып:

— Биби, Хаечка дома?[2] — дип сорады.

---

[1] Кыскартып алынды.

[2] — Биби, Хәят өйдәме? — *Ф. Ә.*

Биби, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, бик киң итеп елмайды һәм, җәһәт кенә адымнар белән ишегалды түрендәге бакчаның челтәрле коймасы янына килеп:

— Хәят апа, Лиза килде! — дип кычкырды.

Бер минуттан соң бакчадан Хәятның йөгереп чыкканлыгы күренде. Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсуак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде. Ул:

— О, Лиза! Менә гакыллы[1], дустын онытмаган! —дип, шатлыклы йөгереп, гимназистка янына килде. Дуслар бик күптән күрешми торган шикелле үбешеп күрештеләр дә өйгә кереп киттеләр.

Лизалар моннан ун көн әүвәл N шәһәреннән 2—3 чакрым ераклыктагы бер җиргә дачага чыкканнар вә аның бүгенге килүе дачага чыкканнан соң әүвәлге килүе иде.

Кунак кыз Хәятның анасы Газизә абыстай белән ике куллап күреште дә хәзер Хәятны үзләренә кунакка алырга килгәнлеген сөйләде. Газизә абыстай Лизаны бик хөрмәтләп кабул итте, ләкин ватык кына русча тел белән, Хәятны атасы рөхсәтеннән башка андый «ерак» җиргә җибәрергә яхшысынмый икәнен аңлатты. Лиза Газизә абыстайның бер дә ай-ваена карамады:

— Борһан Ахмедович ачулана башласа, мине гаепле итеп күрсәтерсез, мин аннан үзем гафу үтенермен,— дип, Газизә абыстайны ярым көчләп, рөхсәт бирергә ирексез итте.

Кызлар Хәят бүлмәсенә керделәр. Хәятка өстен алыштырырга һәм чәчен прическаларга кирәк иде. Ул озын, куе вә үзүзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк келтәсе шикелле чәчләрен тараганда, Лиза дача хәлләрен сөйли торды. Башкалар арасында дачада егетләрнең күплеген, хәзер инде аларның һәммәсе белән үзенең танышып җиткәнлеген Лиза үзенә бертөрле кәеф белән сөйләде.

Хәят прическасын ясап бетергәч, дуслар ничек киенү турысында кызу гына сөйләшеп алдылар да, Хәят киенергә, Лиза аңа булышырга тотынды. Хәят әле бары уналтынчыда гына булса да, быел кыш ул, кинәт үсеп китеп, буе-сыны белән инде «җиткән» кызлардан аермасыз булган иде. Аның яшь икәнлеген күрсәтә торган бер билге булса, ул да, бу яшьтә кинәт үсеп

[1] «Вот умница» дигән сүзләрнең тәрҗемәсе.

киткән кызларның һәммәсендә була торганча, әгъзаларның гомуми күренеше белән бик үк мөтәнасип[1] булмаган нечкәлек кенә иде. Аның быел тектергән ал ефәк декольте[2] күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән иде.

Хәят Лизаларга барырга шул күлмәген киде һәм, дустының киңәше буенча, күлмәге белән бер төстәге кечкенә генә калфагын да прическалы чәчләре арасына кадап куйды. Бу калфак ефәк көлтәсенә чолганган гөл чәчәге (роза) шикелле көлеп тора иде.

Ал кием безнең Хәятка бик килешә: ул аның эчендә ал фәрештә шикелле була. Бүген дә ул шулай ук булды. Моны күргән беркатлы (садә) Лиза:

— Ах Хәят, нинди матур син! Син бәхетле, бик бәхетле! — дими чыдый алмады.

Дуслар киттеләр... Кояш, алар өстенә ак болытлар арасыннан карап, оялчан гына көлеп тора иде.

2. ИКЕ ТОРМЫШ

Хәят белән Лиза бала вакытларыннан ук бергә уйнап үскән дуслар иде. Хәятның атасы Борһан абзый Гыймадов күбрәк рус купецлары белән эш итә торган сәүдәгәр булганга, Гыймадовларның йорты «Рус урамында» иде. Шунлыктан Хәят бик яшь вакыттан ук рус балалары белән уйнап үсте һәм яшьтән үк бик яхшы русча сөйләшергә өйрәнде.

Лиза Гыймадовлар белән бер үк урамда торучы Мясников фамилияле бер гаскәри кызы булып, бу ике кыз, кечкенә вакыттан ук бергә уйнап үскәнгә күрә, бер-берсенә бик ияләнгәннәр иде.

Борһан абзый үзе дә интендантствога гаскәр кирәк-ярагыннан кайбер нәрсәләр хәзерләттерүче һәм Мясниковның яхшы белеше — приятеле булганлыктан, бу ике яшь кызның дуслыклары гаиләләр арасындагы катышу белән тагын бер кат ныгыган иде. Шул кадәресе бар, дусларның алган тәрбияләре бер-берсенекенә охшамый иделәр.

---

[1] *Мөтәнасип* — тигез, туры килгән.

[2] *Декольте* — муен, беләкләр һәм күкрәкнең бер кыйсемен (өлешен) ачык калдыра торган күлмәк.— *Ф. Ә.*

Лиза, сигез яшеннән быелга кадәр гимназиядә укып, хәзер урта тәхсыйльне[1] тәмам итә иде. Хәят, җиде яшеннән ундүрткә кадәр Мәлихә абыстайда укып, үткән кыш «Дөррәтеннасыйхин»[2]нең яртысын тәмам итеп, сабак абыстаена йөрүдән туктаган иде. Хәят үскән бу чорда әле татарлар аз тора торган мондый шәһәрләрдә кызлар өчен ысул җәдит[3] мәктәпләре дә юк иде.

Гимназия Лизага, бер яктан, рус милләтчелеге рухы биреп чыгарырга тырышса, икенче яктан, рус әдәбияты белән таныштырып, аның җанына нәрсәдер эзләнү оеткысы сала иде.

Мәлихә абыстай Хәятны бөтенләй икенче юл белән тәрбия итте. Әүвәл ул аңар бик озаклык вә читенлек белән язу таныткты, аннан соң мөселман кеше тормышы өчен борынгыдан эшләнеп килгән берничә кагыйдәләр өйрәтте.

Боларны кат-кат өйрәтте, төрле якларыннан өйрәтте. Мәлихә абыстайның тырышлыгы бушка җуялмады: Хәятка — каршы сөйләү һәм шик итүне күтәрми торган, дини вә дөньяви бер караш бирде дә шушы нәрсәдән дөрес, болардан туры вә болардан кирәкле нәрсәләр дөньяда юк инде дигән фикер урнаштырды. Хәятның иң соң укыган китабы «Дөррәтеннасыйхин» абыстайның бу тәрбиясен бигрәк нык беркетә бара иде. Бу китапны шәкерт тә, мөгаллимә үзе дә ярым-йорты гына аңлап барсалар да, аңлаган кадәресеннән кирәкле нәтиҗәне чыгару Хәятка артык читен булмады. Ул бу китаптагы изгеләр вә аларның тормышлары хакында язылган хикәяләрне чын бер дәрт белән укый, җәннәт рәхәтләрен, җәһәннәм газапларын язган җирләрне ихлас белән күңеленә салып кала иде. Аңа бу китап нык бер идеал (гаяте хыялые) ясап бирде: ул изгеләрне вә аларның тормышларын иң зур максут итеп күрә, «явызлар» вә аларның эшләреннән бик курка торган булды. Шулай итеп, аның карашында адәмнәр ике, бер-берсенә бер дә охшамый торган, аермачык билгеле бүлекләргә аерылдылар: тегеләре җәннәттә, болары җәһәннәмдә!..

Ләкин алган тәрбияләрнең болай бер-берсенә капма-каршы булучылыгы да бу яшь кызларның якынлыгын боза алмады: Хәят белән Лиза һичбер вакытта артык чынлыклы (җитди)

---

[1] *Тәхсыйльне* — белемне.

[2] *«Дөррәтеннасыйхин»* — дини китап исеме.

[3] *Ысул җәдит* — яңа метод (укытуда).

мәсьәләләр турысында сөйләшмиләр, бер-берсенең тормышка карашларын тикшермиләр иде. Хәятның рус телен бик яхшы белүе һәм, кечкенәдән үк рус гаиләләренә, вә хосусан[1], Мясниковларга катышып килеп, рус җәмгыятендәге гореф вә әдәпләрне яхшы ук өйрәнгән булуы да тәрбияләр арасындагы бу зур аерманы каплап тора иде.

Гыймадовларның гаилә тормышлары да Мясниковларныкына бер дә охшамый иде. Борһан абзый гади бер татар купецы вә гади татар бае тормышы белән тора торган кеше иде. Шуңар күрә аның йортындагы һәр кеше, үз теләге вә үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсынырга вә шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш иде. Әмма Мясниковлар гаиләсендә, берничә генә нәрсәне истисна белән[2], һәркемнең үз теләге, үз тойгылары бик күп урында, бик күп нәрсәләрдән алда тотыла иде.

Шулай итеп, безнең Хәят ике, бер-берсенә бөтенләй каршы тормыш агымнары уртасында үсте. Рус җәмгыятенең күңелле тормышы аның яшь йөрәген үзенә тарта да, ул Мясниковлар вә башка кайбер рус гаиләләренең күңелле вечерларында[3] төнге сәгать өчкә кадәр танцевать итә ала иде. Икенче яктан, үз гаиләләрендәге тормыш вә кечкенәдәге тәрбия аның җанын чолгап ала да, ул, шундый кызыклы вечерлардан арып-талып кайтып, урынына яткач, икешәр сәгать тоташ төрле догалыклар вә салаватлар укынып та ята ала иде. Хәят тормышны ике төрлегә аера: мөселман тормышы — монысы Гыймадовларныкыча булырга тиешле; рус тормышы — монысы Мясниковларныкыча булырга кирәк дип ышана иде. Менә шул игътикат[4] нәтиҗәсе — Хәят, бу ике тормышның икесе белән дә торса да, аларның бер-берсенә кушылып, үрелеп китүләреннән курка, икесен йөрәгенең ике почмагына яшереп, араларына калын бер пәрдә корып куя иде.

Мясниковның киңәше буенча, Борһан абзый быел кыш Хәятны 5—6 ай русча да укытты. Зирәк, ләкин бераз ялкаурак Хәят, русчаны бик яхшы сөйләшә белүе аркасында, шушы аз

---

[1] *Хосусан* — аерым алганда.

[2] *Истисна белән* — исәпкә алмаганда.

[3] *Вечер* — кичке мәҗлес.— *Ф. Ә.*

[4] *Игътикат* — ышану.

вакыт эчендә русча укып аңларга, беркадәр язарга өйрәнеп һәм беркадәр хисап башлангычлары белеп өлгерде. Кирәк Борһан абзыйга вә кирәк Хәятның үзенә шулкадәр нәрсә бөтенләй җитә иде...

3. ХӘЯТ, КАЧ, МӨСЕЛМАН КИЛӘ

Лизалар тора торган дачага бару өчен, татарлар күбрәк тора торган берничә урамнарны да кичеп, шәһәр янындагы бер кырга чыгарга кирәк иде. Шәһәр урамнары яңгырдан соң тузансыз, йөрүчеләре дә яңгыр белән үсеп, тазарып, яшәреп киткәннәр шикелле булганлыктан, Мясниковларның матур йөрешле атлары белән бу урамнар буенча бару күңелсез түгел иде. Бары безнең Хәят бу урамнарда иркенләп бара алмады: еш-еш очраган татарлардан ул йөзен качыра барырга тиеш иде. Хәер, бу эш өйрәнгән Хәят өчен әллә никадәр авыр эш түгел, аның кулчыгы, күзләр бер татарны күрү белән, хәзер үзеннән-үзе күтәрелә дә шәлнең бер чите белән йөзенең өч чирек өлешен каплый бара, хәтта күп вакытта Хәят үзе кулының бу эшне эшләп өлгергән икәнен сизми дә кала иде. Шулай да булса җан үзен бертөрле кысынкылык астында күреп тарсына, бары бу кысынкылыкны бетерә алу бәндә кулыннан килә торган эш түгел дип уйлаганлыктан гына сукранмый буйсына иде.

Хәятның болай татар ирләрдән качуына Лиза да күптән өйрәнеп җиткән иде инде. Хәтта бәгъзе вакытларда, Хәят татар килгәнне күрми калса, Лиза аңар акрын гына:

— Хаечка, закройся, вон мусульманин идет[1],— дип, аңдырудан кире тормый вә үзенең бу эшен дустының дин тойгысын хөрмәт итүдән килә дип уйлый иде.

Кырга чыктылар. Монда чыккач, Хәят та иркенләп утыра ала башлады. Чөнки «намәхрәмнәр»[2] күренмиләр иде.

Кыр, яңа баш күтәргән очсыз-кырыйсыз чәчәкләргә батып, ерак түгел генә агып тора торган Идел елгасы күтәргән саф вә бераз юешрәк һавага бер-берсеннән хушрак йөз төрле ис чыгарып тора иде.

Дөньяның җылы тарафларыннан Хәят туган илгә җәй үткәреп кенә китәргә килгән кадерле кунак — вак-вак кошчык-

---

[1] — Хәят, кач, мөселман килә.— *Ф. Ә.*

[2] *Намәхрәм* — никахланырга хәрәм саналмаган. Бу урында «татарлар» мәгънәсендә.

лар, табигатьнең бу күренешенә гашыйк булган шикелле, мәгънәсен үзләре генә белә торган музыкаларын яңгыраталар; вак кына канатлары мең төрле төс белән чуарланган юаш күбәләкләр дә көләч йөзле чәчәкләр белән кызу-кызу үбешеп йөриләр иде.

Дусларның хәзергә кадәр кызып китә алмаган сөйләшүләренә дә җан керде: Лиза күрше дачаларында тора торган Евгений исемле бер яшь офицер белән үзе арасында булып үткән вакыйганы бик озайтып, бик чуарлап сөйләде. Өченче көн Евгений Лизага, үзенең аны сөюен әйтеп, бер хат язган икән; дуслар, Лизаның ридикюленнән[1] алып, аны да укыдылар.

Лизаның кирәк сөйләү рәвешеннән вә кирәк йөзенең яктылыгыннан, Хәят нәрсә аңларга кирәклеген туры чамалады да кучерга ишетелмәслек шыпыртрак тавыш белән:

— Лизочка, дөрес түгелме, Евгений синең үзеңә дә ошаган булырга кирәк? — дип сорады.

Лизаның йөзе бер генә секундка алсуланып китте. Ул, дустының соравына туры җавап бирмичә:

— Күрсәң, син дә ошатырсың әле аны... бик мәхәббәтле егет ул,— диде. (...) Килеп җиттеләр.

4. МӘҖЛЕС КҮҢЕЛЛЕ ИДЕ

Мясниковлар тора торган дача бик бизәлеп, әллә ничә җиренә вак кына, җыйнак кына балконнар чыгарып, түбәсенең дүрт почмагына кечерәк-кечерәк дүрт манара утыртып салынган, әллә кай җирләренә хәтле төрле рәвештәге, төрле пыялалы тәрәзәләр белән бизәлгән җәйлек өй иде. Дүрт ягыннан каплап алган куе ботаклы, зурлыкланып, башларын югары күтәреп тора торган агачлар, бу бинаны үзләренең челтәрле күләгәләре белән кояшның башка каба торган эссесеннән саклап, җиңел вә рәхәт салкынлык һәм ял итү урыны ясыйлар иде.

Кызлар өй эчендә озак юанмадылар: бакчага чыктылар.

Урманның бер кисәген койма эченә алып ясалган бу бакчаның карт-карт агачлар белән бер буйдан тезелгән топольләре аңкытып ис чыгаралар; читләренә чәчәкләр тезелгән юллары йөрүчеләрне үзләренә чакырып торалар, түре Идел елгасының нәкъ кырыена, биек бер ярга чыга иде.

---

[1] *Ридикюль* — хатын-кыз кулында йөртелә торган кечкенә сумка.— *Ф. Ә.*

Дуслар юлларның берсеннән киткәннәр иде, каршыларына Лизаның агасы Михаил очрады һәм, шат елмаеп, Хәятка кулын сузды:

— Кемне күрәм мин! Ничә җәйләр, ничә кышлар![1] Бер кыш эчендә сез, Хаят (Хәят), танымаслык үсеп киткәнсез, тагы да матурлангансыз,— ди-ди кызлар белән бергә китте.

Михаил да, Лиза шикелле үк, Хәятның кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде. Ул, үткән көз Казан университетына кабул ителгәнлектән, бу кышны Казанда уздырып, кичә генә N шәһәренә кайткан иде. (...)

Күптән күрешмәгән дусларга сөйләшер сүзләр күп табылды: Михаил Казан хәлләрен, анда ничек торганлыгын сөйләде. Хәят мондагы кышкы хәлләрне хикәя итте. Лиза сүзгә аз катыша, күбрәк тыңлап утыра иде. Михаил Хәятка туры гына карап утыра, урыны килгәндә комплиментлар[2] әйтеп китәргә дә онытмый һәм бу эше белән Хәятны кайсы вакыт кызартып та җибәрә иде.

Бервакыт Михаил:

— Карагыз әле, Хаят, сез әле мин киткәндә генә бала идегез, җиде-сигез айда инде бөтенләй җиткән кыз булып өлгергәнсез; сез үзегез белми торгансыз, сез хәзер шәһәребезнең беренче гүзәле бит...— дип, тагы комплиментлар әйтә башлаган иде, Хәят кызарынып китте дә күзләрен җиргә төшерде һәм:

— Фу, черкиләрегез нинди усал... Шулкадәр рәхимсез тешлиләр,— дип, одеколонга манчылган яулыгы белән маңгаена хәзер генә килеп кунган черкине куып җибәрде дә бу кечкенә «залимнәрдән» зарланырга тотынды. Аннан соң урманнар, елгалар, сәяхәтләр турысында сүзләр башланып, бер-бер артлы коелдылар. Мәҗлес күңелле иде.

«Кунаклар килә» дип хәбәр бирелгәч, Лиза вә аның белән бергә Хәят та кунакларга каршы киттеләр. Михаил утырган җирендә калды.

* * *

Кызлар киткәч, Михаил урындыкның аркасынарак ята төште дә аякларын киеребрәк алга сузды һәм, ак чесуча[3]

---

[1] Озак күрми торган белешләрен күргәндә, руслар шулай диләр.— *Ф. Ә.*

[2] *Комплимент* — мактау сүзе.— *Ф. Ә.*

[3] *Чесуча* — киндер кебек бер аркылыга, бер буйга тукылган тыгыз ефәк тукыма.

күлмәге өстеннән бәйләнгән зәңгәр ефәк зөннарының[1] зур-зур чуклары белән уйнап:

— Шулай ук бу кызчык минем башны әйләндерермени? Матурлык! Менә матурлык! — дип уйланды.

Быелга кадәр Михаилның Хәятка мөнәсәбәте коры дуслык кына иде. Һәм шулай булмый хәле дә юк. Хәят моңар кадәр бала иде бит әле ул. Шулай да үткән көз, Казанга китәр алдыннан, Хәят белән ахыргы күрешүендә, Михаил үзе аңламый торган бер тойгыдан әсәрләнгән иде. Ләкин барган яңа шәһәре, әүвәл бусагасын атлаган гали мәктәбе һәм яңа белешләр, Михаилның ул белемсез тойгысын тиз оныттырып, Хәятның сурәтен аның фикереннән качырганнар иде.

Мартның соңгы көннәреннән берсендә Михаил Лизадан бер хат вә хат эчендә аның Хәят белән бергә төшкән портретын алды. Хатта Хәятның быел кыш кинәт үсеп киткәнлеге вә тагы да матурланганлыгы язылган иде. Михаил, портретны бик яхшылап карап, бу сүзләрнең дөреслегенә күзләре таныклыгы (шәһадәте) белән ышанды.

Портретта инде Хәят бала түгел, бөтенләй җиткән кыз иде. Бу Хәят инде Михаилның бала чагыннан бирле үк белеп килә торган, дус итеп кенә яратылырга мөмкин кызчык түгел, бәлки кыз итеп сөелергә мөмкин бер матур иде.

Михаил рәсемгә бик озак карап торды да аңар хыялый бер тереклек бирде һәм Хәятның бөтен кыланышларын, күз йөртешләрен, гәүдәсен тотышын, озын кара толымнарын селкетеп чабып китешен, матур кыйгач кашларын җиңелчә генә сикертеп сөйләшен... күз алдына китерергә тотынды. Ул Хәятның бу кыланышларын моңар кадәр дә ярата иде. Ләкин ул ярату сөйкемле бала, сөйкемле дус баланың мәгъсуманә[2] кыланышларын яратудан гына гыйбарәт иде. Хәзер аның күз алдында бу кыланышлар бөтенләй икенче мәгънә аңлата башладылар. Алар бер-берсе янына тезелделәр дә дөньядагы иң матур, иң шагыйранә күренешләрнең берсе булып киттеләр. Алар кинәт үзләренең балалыкларыннан чыктылар да кызлар хәйсиятенең[3] иң матур, иң көчле яклары булып киттеләр. Михаилның йөрәге ешрак-ешрак, каушабрак-каушабрак, әллә нинди газаплы бер ләззәт белән тибә башлады.

---

[1] *Зөннар* — билбау.

[2] *Мәгъсуманә* — гөнаһсыз.

[3] *Хәйсиятенең* — хәленең, сыйфатының.

Шул көннән бу көнгә кадәр Хәят Михаилның фикереннән чыкмады. Ул кадерле рәсем дә Михаил өстәленең иң кадерле урынына барып басты да китап карап арыган күзләренең ял итә торган бердәнбер кәгъбәсе[1] булып торды.

Хәятның бүгенге күренеше Михаилда тагын теге тойгыны уятты, һәм бу юлы инде кискенрәк һәм билгелерәк итеп уятты.

Михаил, борылып, кызлар киткән юлга караганда, алар инде юлның аргы башына барып җиткәннәр иде. Хәятның, кечкенә аякчыкларын җиңелчә генә ике тарафка каратып, нечкәрәк, ләкин бик зифа буен (фигурасын) иркә тотып барышын карап торганда, Михаилның йөзе бертөрле серле җыерылып китте. (...)

6. ХӘЯТ, МИН СЕЗНЕ СӨЯМ!

Мясниковлар дачасы бу урманда ялгыз гына түгел иде. Бу урын шәһәр тирәсендә иң матур урын булганга күрә, күптән үк инде үзенә шәһәрнең бик күп байларын китергән һәм бик күп купшы җәйге йортлар (дача биналары) белән тулган иде. Бу дачаларда торучы яшьләр дә инде, бер-берсе белән тәмам танышып, барысына уртак бер тормыш ясап өлгергәннәр... Вакыт күңелле, рәхәт һәм ахырдан искә төшерер өчен төрле-төрле сагындыргычлар калдырып үтә иде.

Якшәмбе булганлыктан, бүген дачникларның һәммәсенә дә кунаклар килделәр. Мясниковларга да шәһәрдән Лизаның ике иптәш кызы агалары белән килгәннәр иде. Сәгать алтылар булганда, Мясниковлар бакчасында егетләр вә кызлардан 14—15 ләп кеше булды. Болар арасында Евгений да бар иде. Лиза Хәятны мондагы кешеләрнең әүвәлдән таныш булмаганнары белән вә шулар арасында Евгений белән дә таныштырды. Каргылт йөзле, озын буйлы вә калын җилкәле бу таза офицер, Евгений, Хәятта билгеле бер тойгы калдырмады диярга ярый; бары аның калынрак вә бик кызыл иреннәре әллә ничек ятрак нәрсә шикелле күренделәр.

Яшьләр төркем-төркем төрле тарафларга таралдылар. Бер төркемдә Хәят, Лиза һәм Евгений да киттеләр. Евгений, әүвәл бераз Лиза белән сөйләшеп барса да, тиз арада Хәят янына сырышты һәм, аның бүген генә танышкан кыз булуына кара-

---

[1] *Кәгъбә* — биредә: табына торган әйбер.

мыйча, үзе комплимент дип уйлаган сүзләрдән берничәсен әйтеп тә өлгерде:

— Сез русча гаҗәп яхшы сөйлисез икән. Сез бөтенләй рус кызы төсле... Сез бер дә генә дә мусульманкаларга охшамыйсыз... Әгәр бу, чәчләрегезгә кадаган матур нәрсәгез (калфак) булмаса, сезне мөселман кызы дип танып та булмас иде... Мин әүвәл мәртәбә сезнең шикелле мөселман кызын күрәм һәм танышканыма бик шатланам... Ул чәчләрегезгә кадаган нәрсәгез сезнеке шикелле матур чәчләргә бик килешә икән...

Хәят икенче бер егет белән бара торган Лизаның пошынып караввы астында гадәтендәгедән артыграк кызарынып китте дә:

— Лизочка, сиңа бер сүзем бар! — дип, Евгенийдан читкәрәк китте.

Лиза, бергә бара торган егетеннән арттарак калып, колагын Хәятка якын китерде. Һәр икесе туктабрак төркемнән артта калдылар. Хәят шыпырт кына тавыш белән:

— Шушымы инде синең мактаган Евгениең? Гаепләмә, күгәрченем, ул миңа бер дә ошамады; ничектер тупас... — дип, Лизаның күзләренә карады.

Лиза ясанып кына көлде һәм, Хәятның йөзенә карамаскарак тырышып:

— Ул сиңа нинди комплиментлар әйтә, син аны ошатмаган буласың... — ди башлаган иде дә, Евгенийның башкалардан артка калып, үзләрен көтеп торганлыгын күреп, сүзен тәмам итмичә кисте.

Евгений ачык вә булдыклы тавыш белән:

— Әфәнделәр, мине дә серегезгә катыштырсагыз ла... — дип, боларның сүзләренә катышып китмәкче булган иде дә, Хәят, йөзенә чын риза булмаганлык төсе чыгарып, өзек вә батыр гына тавыш белән:

— Үтенәм, безне үз хәлебездә калдырыгыз! — диде.

Евгений, шактый уңайсыз хәлдә калырга тиеш булса да, осталыгы белән яхшы ерылып чыкты:

— Pardon[1], самоедларда[2] бер мәкаль бар: «Ике дус арасына кысылсаң, телеңнең сөякләре сынар», диләр... — ди-ди алдагылар артыннан китте.

---

[1] *Пардон* — гафу итегез *(французча)*.

[2] *Самоед* — кайбер Төньяк халыкларының (мәсәлән, ненецларның) искечә атамасы.

Лиза Хәятта мондый батырчылыкны әүвәл мәртәбә күрә иде; ул, тавышына ясалма риза түгеллек яңгырашы биреп:

— Ник ул кадәр каты? — дип, йөзен Хәятка якын ук китерде, һәм аның җавабын көтмичә:

— Син бәхетле, Хәят! Синнән каты сүзне дә күтәрәләр... Син бик яхшы кыз, яхшы иптәш... — дип, тиз генә Хәятның маңгаеннан үпте дә, йөзен куллары белән каплап, алга йөгерде: ул үзенең бик нык кызарганлыгын сизә иде. Бу эш, бер яктан, Лизаны Хәятка якынайта, икенче яктан, аның йөрәгенең әллә кайсы җирен тырнап, уңайсызлап тора иде: күңелдә Хәятның матурлыгыннан көнләшү туа башлады...

Лиза, Хәят яныннан киткәч, Евгенийны илтифатсыз гына узды да әүвәлге егете янына килде һәм, җанындагы уңайсыз тойгысын яшерү өчен, ясалма искитмәгәнлек күрсәтеп сөйләшергә һәм көлешергә тотынды. Бары тавышының гадәттәгедән катырак һәм әллә ничек кытыршырак чыгуы аның яшерергә теләгән нәрсәсен ачып күрсәтә иде...

Хәят, Лизаның бу серле үбүеннән һәм йөгереп китүеннән аптырашта калып, нәрсә дип уйларга белми барганда, үзе артында Михаилның адымнарын ишетте. Яңадан бер-ике адым — ул килеп тә җитте һәм, Хәятның күренешеннән куркып киткән сыман каранып, йомшак һәм пошынган тавыш белән:

— Дускаем, бу кадәр үз-үзегездән югалып, ни уйлыйсыз? — дип сорады да, җавап көтмичә, кулындагы чәчәкләр бәйләмен Хәятка сонды. Бу бәйләм, хәзерге вакытта үсә торган чәчәкләрнең һәр төрлесеннән оештырылып, килешле тезелгән, матур бәйләнгән иде. Хәят, чәчәкләрне алып, йөзенә якынрак китерде дә күзләре белән Михаилга тәшәккер[1] ишарәсе итте. Чәчәкләр Хәятка карап көләләр һәм әллә кай җирләреннән генә аның борынына берничә исне берьюлы сирпеп торалар иде.

Михаил, сынын ия төшеп, Хәятка култыгын сонды. Алар алдагылар артыннан китмәделәр: читкә аерылып киткән бер юлга чыктылар. Таррак кына, кызыл ком белән түшәлгән бу юлның як-якларында озын һәм эре агачлар тезелеп, батып бара торган кояшның кызгылт нур тамчыларын челтәрләндереп төшерәләр, чит-читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге бөтен һаваны аңкыталар; яфраклар арасына яшеренгән кошчыклар адәмнәр аңламый торган җырларын

[1] *Тәшәккер* — рәхмәт әйтү.

көйлиләр дә бөтен бу юл, бу кызыл тамчылы нур һәм бу резедаларның тормышларына бер серлелек биргәләр иде.

— Хаят, сез бая гына нинди шат идегез, хәзер әллә нинди бик тирән уйга баткансыз, кояшта сулган чәчәк шикелле булгансыз,— дип, Михаил Хәятка табарак бөкрәйде. Аның уйчан тавышы күңеленең тирән җиреннән чыккан шикелле иде.

Хәзергә кадәр җиргә карап килгән Хәят, күтәрелеп, Михаилның йөзенә карады. Бу йөздәге матур коңгырт күзләр уйчан карыйлар, күзләргә караганда каргылтрак киңчә генә кашлар да, бик кирәкле берәр нәрсә уйлагандагы шикелле, эшлекле җыерылып торалар иде. Хәят уйчан гына елмайды һәм, көчләнеп, җиңелчә вә нечкә генә итеп тамак кырды да:

— Юк, бернәрсә дә уйламыйм. Озак кояшта йөрсәм, мин арам бугай, ахры,— диде. Үзе Михаилны әүвәл мәртәбә күргән шикелле: «Кара, мәхәббәтле генә бит бу урыс малае»,— дип уйлады.

Юл өстендәге скамьяларның берсенә килеп утырдылар. Сүз әллә ничек җайланып китми иде. Башка вакытта шулкадәр сүзчән Михаилның хәзер генә шулай сүз таба алмый утыруы Хәятка сизелми калмады.

— Сез мине уйга баткан дисез, әмма үзегез хәзер уйга баткансыз,— дип, Хәят күзләрен Михаилга төшерде. Михаилның күзләре очкыннар чәчеп торалар иде. Ул салмак кына елмайды да, Хәятка туп-туры карап:

— Мин уйга чумган? Аның сәбәбе бар... Сез гаепле аның өчен... — ди башлаган иде, Хәят, аңар сүзен бетерергә ирек бирмичә:

— Михаил Алексеевич, Казанда торганда йортыгызны бик сагынгансыздыр, әйеме? — дип, сүзне икенчегә борды.

Михаил бобрик белән[1] кыскартылган чәчләрен кирегә сыпырып куйды да егет сыман гына тавыш белән:

— Беренче: мин сезгә Михаил Алексеевич түгел, Миша гына, чөнки яшьтән бирле Миша гына идем, шулай гына булып калырга телим дә. Икенче: Казанда торганда йортым исемә дә кереп чыкмады, бары сезне генә сагындым,— дип, сынын Хәятка табарак бөкрәйтә төште. Хәзер аның йөзе Хәятның йөзенә якын ук килгән иде. Хәятның күзләре бу, үзләренә якын ук тора торган сөйкемле йөз һәм очкынлы, уйчанрак карый

[1] *Бобрик белән* — ирләрнең чәчен ал якта гына тырпаеп торырлык итеп алу.

торган коңгырт күзләргә төштеләр. Күңелендә ниндидер бер тойгы кабынды да электрик токлары сыман бөтен барлыкка таралды. Бу тойгыны Хәят үзендә әүвәл мәртәбә сизә иде. Ул, Михаилның йөзенең бу кадәр якын торуыннан курыккан сыманрак итеп, читкәрәк кагылды һәм сул аягын, бераз киерелдерә төшеп, җирдән кузгатты да, күзләрен ботинкасының очлы башына төбәп, сүзсез һәм селкенешсез калды.

Хәят Михаилның үзенә нәрсәдер, бик кирәкле бернәрсә әйтергә теләп тә, әйтеп бетерә алмаганлыгын томанлы гына сизенә, ләкин, никтер, ул кирәкле нәрсәнең әйтеп бетерелми калганлыгын теләгән шикелле була иде. Кулындагы чәчәкләр бәйләмен борыны янынарак китерде дә, шул чәчәкләргә әйткән шикелле итеп, ул:

— Ишетегез әле[1], сез әүвәлләрдә бик матур җырлыйдыр идегез. Җырлагыз әле берәр нәрсә,— диде.

Михаил чәчәкләргә карап әйтелгән бу сүзнең үзенә әйтелә икәнен белә иде, назланып тормады: уң кулын чалбар кесәсенә тыкты, йомшак кына тамак кырды да зәгыйфь, ләкин сөйкемле тенор белән:

> В темной аллее заглохшего сада
> Сидя вдвоем на дерновой скамье[2],—

дип башлады да, үз-үзеннән көлеп җибәреп, җырын кисте һәм:

— Юк, Хаят, мондый тавыш белән җырлаганны тыңлап утырганчы, әнә ул агачта сайрый торган кошчык сайравын тыңлагыз. Ул сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый,— диде.

Чынлап та, ниндидер бер кошчык, башкаларыннан аерым бер осталык вә аерым бер дәрт белән, болар утырган скамья каршысындагы агачның яфраклары арасына яшеренеп сайрана иде. Соңгы сүзләрне әйткәндә, Михаилның тавышы бик чынлыклы вә бераз каушанкырак чыга иде. Хәятның йөрәге тыпырчынган шикелле итеп тибә башлады: Михаилга әйтергә аның теленә җавап килми иде. Бер минутлык тик торыштан соң Михаил, уң кулы белән Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотып, уйчан гына тавыш белән:

---

[1] «Послушайте» сүзенең тәрҗемәсе («Карагыз әле» кирәк иде).

[2] Тын бакчаның караңгы юлында икәү генә утырып... мәфһүмендә (эчтәлегендә).— *Ф. Ә.*

— Ачуланмагыз, Хаят, мин сезне сөям... Минем күңелемдә сез генә...— ди башлаган иде, Хәятның кулының үз кулыннан ычкынган икәнен сизде.

Хәят болай итеп әйтелгән «сөям» дигән сүзне әүвәл мәртәбә ишетә иде. Ул әле күптән түгел генә укып чыккан русча бер романда сөю, сөелү дигән сүзләрне күргән вә хәтта үзен шул романда язылган кызларның берсе итеп уйлап укыган булса да һәм мондый эшләрне үзеннән зуррак иптәш марҗа кызларыннан әллә ничә мәртәбәләр ишеткән булса да, хәзер аптырашта калган: кирәк укыган романындагы кызның вә кирәк үзенең иптәш кызларының үзләрен мондый вакытларда ничек тотканлыкларын хәтереннән чыгарган иде. Михаилның «сөям» дигән сүзен ишеткәч тә, ул ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

— Сез бик мәхәббәтле!..— диде дә, йөзен куллары белән каплап, олы юлга таба йөгерде.

Михаил да аның артыннан китте. Аның колагында Хәятның сүзе шатлыклы яңгырый иде:

— Сез бик мәхәббәтле!

Хәят үзенең кызарынганлыгын белә, колакларының ялкынсыз янганлыгын да сизә; һәм хәзер генә булып узган эш аның алдында томан эченнән карап, шатлыклы елмаеп торган шикелле була да, йөздәге кызыллык, колаклардагы яну тагы да көчәя иде.

Яңадан бер минут — Хәят күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек сизде: кинәт бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп төште. Кай җире җитешми? Кай җире китек? Анысын Хәят әле белеп җиткерми иде. Ләкин сизгер яшь йөрәк бу китеклекне тойды. Бары акыл гына әле аның кай җирдә икәнен анык билгеләп өлгерә алмады.

Хәят, җәһәт кенә адымнар белән, олы юл өстендәге бер озын скамья янында төркемләнеп тора торган кунаклар янына килеп җитте. Аның артыннан ук Михаил да килеп җитте һәм, ләззәтле каушавын көчләнеп басып:

— Әмма каты йөгерәсез икән соң, Хаят, сезнең арттан йөгереп әлсерәдем, шулай да җитә алмадым,— диде.

Скамьяда утырып тора торган бер студент Хәятка урын бирде...

7. ХӘЯТ КЫЗЛЫК ВАКЫТЫН КҮҢЕЛ АЧЛЫГЫ БЕЛӘН ҮТКӘРДЕ

Төнге сәгать өчләрдә Мясниковларның аты Хәят вә аны озатырга килгән Михаил вә Лизаны Борһан абзыйларның капка төбенә китереп җиткерде. Михаил, звонок биреп ишек ачтыргач, Хәятның кулын каты гына кысып күрешеп, шыпырт һәм яшерен генә тавыш белән:

— Мин җавап көтәм,— диде һәм, шуңар ук ялгап, ачык вә шатлыклы тавыш белән: —Хәерле кич, матур төшләр, күңелле уйлар, рәхәт йокылар,— дип, берничә теләкләр теләде. «Мин җавап көтәм» дигән сүзнең бер төрле әйтелеп, бу соңгы теләкләрнең бөтенләй башкача әйтелүләре әүвәлге сүзне тагы да мәгънәлерәк ясый иде.

Озатучылар кайтып киттеләр. Берәр квартал җир киткәч, Лиза, күзләрен күккә күтәреп, йолдызларга сөйләгән сымак кыяфәт белән:

— Хаят хәзер әүвәлге Хаят түгел, егетләр алдында чытлыкланырга бик ярата башлаган,— дип куйды.

Хәзергә кадәр уйга чумып килгән Михаил да, йокыдан уянган шикелле уянып китеп, тупас кына:

— Дөрес түгел! Син Евгений ачуын Хаяттан аласың. Бу — ялган,— диде һәм үзе авызын бик зур итеп ачып иснәде. Лиза, ачуланып, яңадан берничә каты-каты сүзләр әйтсә дә, Михаил җавап бирмәде; шулай итеп, агалы-сеңелле юл буе күңелсез генә тик кайттылар.

Хәят, ишек ачарга төшкән асрау кызга кулындагы чәчәкләр бәйләмен биреп:

— Суга утыртып, минем бүлмәгә кертерсең,— диде дә, үзе аякларының очлары белән генә басып, йөгереп менеп китте һәм, бүлмәсенә кереп, тиз генә өске кат киемнәрен ыргытты да кроватена ташланды. Бөтен тәндә рәхәт арыганлык тоела, бит урталары яналар, әле генә узып киткән күңелле кичнең төрле-төрле тойгылары башта чуалышып бетеп кайнашалар, Михаилның «мин җавап көтәм» дигән сүзе яшерен тавыш белән колакларны жулатып тора иде. Таң һавасы суыгы белән салкынланган матур бармакларының аркаларын бит урталарына куйды да ул, күкрәген бер күтәреп, бер төшереп, еш-еш сулап, күзләрен түшәмгә төбәп, ике-өч минут ятты. Бу вакытта Биби чәчәкләр бәйләмен бер вазага утыртып керткән иде. Хәят:

— Биби, акыллым, минем ботинкаларымны гына чиш әле. Үзем бик иренәм,— дип, сул аягын бераз калкыта төште. Кысынкы ботинкалардан юка, саргылт оек эчендәге кечкенә генә нәфис аяклар килеп чыктылар. Моннан соң асрау Хәятның салган киемнәрен элеп куйды да, бер сүз сөйләмичә, авыр вә ялкау гына атлап чыгып китте.

Хәят, ялкау гына урыныннан торып, бакчага караган тәрәзәне ачып җибәрде. Күрше бакчада бөтен һаваны яңгыратып сандугач сайрый иде. Таңның нурлылыгы, сөеклесе гөл чәчәгенең матурлыгы сандугачны шулкадәр җанландырган иде ки, ул үзе белгән көйләрнең иң матурларын сайрый вә шул кечкенә гәүдәсенең әллә кай җирләреннән меңәр төрле ноталар чыгара һәм вакыт-вакыт үз-үзен һәм гөл чәчәгеннән башка, үзен чолгаган бөтен дөньяны оныткан шикелле, үз тавышында үзе җуяла иде. Хәят бер минутка бөтенләй тик калды, тын да алмады. Аның хәтеренә Михаилның «ул кош сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый» дигән сүзләре килде. Аннан соң кечкенә кулчыклары белән тәрәзә бусагаларына таянып, гәүдәсенең яртысын тышкы якка чыгарды да ләззәтле бер дәрт белән, сандугачны аерым бер бирелү белән тыңларга тотынды.

Сандугач чынлап та Хәят өчен сайрый, аның матурлыгын мактый, ул матурлыкка әллә нинди якты бәхетләр, күңелле киләчәкләр вәгъдә кыла шикелле иде. Бөтен барлык ниндидер бер рәхәт онытылуга чумды; аллы-гөлле нурга чолганган бәхет, яшь канга аралашып, иң вак тамырларына кадәр үтте; бөтен йөрәкне шундый бер ләззәт чолгап алды ки, андый ләззәтне дәртле, моңлы, югарылыклы, ләкин тәҗрибәсез яшьлек кенә татый ала вә аның гына әле бер дә алдану ачысын белмәгән гакылы ышаныч белән каршы ала ала. Хәят, берничә минутлар шул хәлендә калганнан соң, хәтеренә кинәт бернәрсә килеп төшкән кешенең ашыгычлыгы белән тәрәзә яныннан китте дә ридикюленнән зур төргәк хатлар чыгарды. Бу хатлар узган кичтә уйналган «почта» уены вакытында алынган хатлар иде. Боларны Хәят вакытында берәр, хәтта икешәр кат та укып чыккан булса да, һәммәсен бик тикшереп, яңадан берәр кат укып чыгудан үз-үзен тыя алмады. Хатларның берсеннән башка һәммәсе комплиментлар белән генә тулы иделәр. Бер хатта: «Сез матур, сез шәрык хикәяләрендә очрый торган пәри падишаһларының могҗизалы гүзәл кызларыннан да матур; кызганыч ки, миңа сезне күрергә бик сирәк туры килә»,— дип

язылган иде. Хәят вакытында бу хатның кемнән икәнен белмәсә дә, уен беткәч, бакчада үзенә урын биргән студенттан икәнен белгән иде.

Хатларның берсендә: «Сезнең шикелле матур кызның мондый ачучан булганын күргәнем юк иде. Хәер, мин моны болай гына әйтәм: гөл чәчәге бик матур да, сабы бик чәнечкеле бит. Сез миңа бик салкын булсагыз да, мин сезгә бик мәхәббәт итәм»,— дип язылган иде. Хәят бу хатның Евгений хаты икәнен башта ук аңлаган, ләкин ни дип җавап язарга да белмәгәнлектән, җавапсыз калдырган иде. Хатларның берсе һәм иң озыны Михаил хаты иде. Михаил бу хатта үзенең Хәятка мөнәсәбәтен башкару —дуслыктан күчү тарихын озын язганнан соң: «Хаят! Сез мине болай ачыктан-ачыкка үз тойгыларымны язган өчен гаепләмәгез. Сез мине яшьтән беләсез, мин болай үз-үзен дә тота алмый торган кешеләрдән түгел идем. Ләкин сигез ай күрми торып, яңадан сезне күргәч һәм шундый искиткеч сөйкемле һәм матур итеп күргәч мин иске Михаиллыгымны югалттым, яңа Михаил, сөю дигән көчле хан кулында әсир булган Михаил булып калдым. Сез, бәлки, мине рус булганга күрә, үзегезгә муафыйк[1] күрмәссез, ләкин, дускаем, сөю дигән нәрсә милләт аермаларын белми торган көчле нәрсә икән ул. Мин аны татып белдем. Минем бәхетем хәзер сезнең кулда, шуңа күрә мин сездән бер хөкем көтәм. Ул хөкем миңа йә чиксез кайгы, йә чиксез шатлык китерергә тиеш»,— дип язган иде. Хәят, хатны укып чыккач, күз алдына Михаилны китерде. Михаилның коңгырт күзләре һаман очкын чәчеп торалар, ул үзе, «җавап көтәм» дип, озын вә матур сынын нәфис бөкрәйтебрәк тора иде. Хәятның уена бакчадагы теге юл вә анда булып үткән эш килде; үзенең йөгереп качып киткәнлеген уйлады да, йөзенә кан сикереп менгәнен сизеп, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, җәһәт кенә утырган урыныннан торды вә каршында эленеп тора торган стена көзгесеннән үзенең кып-кызыл кызарган йөзен күрде. Үз-үзеннән оялды, йөзен куллары белән каплап, тиз генә яңадан урынына утырды. Фикергә җәһәт-җәһәт алмашына торган сурәтләр килделәр: Михаилның җырлый башлавы, сөям дип, йомшак кына итеп кулыннан тотуы, үзенең аптырап калуы, кызарынып йөгереп китүе... Кызарынып йөгереп китүе... Бу соңгы сурәт уйга кат-кат

[1] *Муафыйк* — кулай, туры килгән, тиң.

килде: соңгы катта әллә ничек килешсез булып килде дә Хәятның эчен пошырды.

«Сөям» дигән сүзгә йөгереп китү белән җавап бирү әллә ничек килешсез чыккан, мантыйксыз[1] чыккан, башкаларныкына охшашлы чыкмаган шикелле иде.

Арадан бер хатны Хәят, яңадан укып та чыкмыйча, ерткалап тәрәзәдән ыргытты. Бу хат ирләр язуына охшатып язылган булса да, кызлар язуы икәнен белгертеп тора иде. Мәгънәсе дә кыска: «Сүз юк, сез матур, ләкин үзегезнең мөселман кызы вә мондагы егетләрнең рус егетләре икәнен онытуыгыз гына килешми»,— диюдән гыйбарәт иде. Вакытында бу хат Хәятның бераз ачуын китергән иде дә тиз онытылган иде. Хәзер шул ачу яңадан кузгалды һәм, әүвәлге эчен пошырган сурәткә кушылып, яңа бер сурәт, белемсез, кәефне җибәргеч сурәткә әйләнде. Ул, хатларны җыеп, комодның бер тартмасына салды да бернәрсә дә уйламаска тырышып кына, ялкау гына чишенергә тотынды һәм, чишенеп, эчке күлмәктән генә калгач, көзге алдына барып, толымнарын сүтте дә куе, озын, тәртипсез, ләкин матур таркалган чәчләрен ал якка, күкрәк өстенә чыгарып куйды һәм, көзгедән карап, үз сурәтеннән үзе кәефләнде; эчке күлмәктән һәм куе кара чәчләр арасыннан күренә торган җиңелчә генә алсурак ак муен, урта гына, ләкин бик беленерлек калкып тора торган күкрәк, кружева арасыннан чыгып тора торган, коеп куелган шикелле матур иңнәр, тулырак кына, ләкин арыклыктан ерак түгел кулчыклар — көзгедән күренгән матур йөзнең гүзәл кушымталары иде. Эч пошыра торган сурәт онытылды. Уйда бары шулкадәр күп бәхет вәгъдә иткән шикелле күренә торган, үз матурлыгын сизү тойгысы вә шуннан килгән шатлык калды.

Берәр минут көзге алдында торгач, ул акрын гына тәрәзә янына килде. Таң атып, агачларны берәм-берәм күрсәтә башлаган; сандугач әле һаман үзенең сөеклесе алдында җырлап арымаган иде. Хәят акрын вә тавышсыз гына тәрәзәне япты. Сандугач: «Чут, чут, чут, черррр...» — дип, бетмәс-төкәнмәс сөюен бөтен дөньяга фаш итә калды. Хәятның колагында яңадан: «Ул кош сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый»,— дигән сүзләр яңгырады.

Аккош мамыгыннан ясалган шикелле җиңел очынып тора торган гәүдә кемнеңдер бик сөекле, бик күңелле чиксез рәхәт

---

[1] *Мантыйксыз* — логикасыз, мәгънәсез.

бирә ала торган кочагына атылган шикелле кроватька атылды да, җиңел одеялга яртылай кереп әгузе бисмилла әйтеп, бераз бөгәрләнебрәк кенә ятты. Өйрәнгән тел үз-үзеннән «амәнте билләһи...», «Аллаһеммә инни әгузе бикә...»ләрне укып китте һәм алар янына «Аятелкөрси», «Сүрәи ихлас»лар, әллә никадәр салаватлар да кушылды... Тән һәм уйдагы рәхәт арыганлык һәм гадәтендәге йоклар вакытның узып киткән булуы Хәятны йокыга якынайтканлыктан, ул, тәртипсез булып бөтен гәүдәсе өстенә таркалган чәчләрен яңадан бер кат иплән кенә көлтәләндереп куеп, менә инде чынлап йоклыйм дигән шикелле иткән генә иде, Михаилның күзгә күренми торган сурәте Хәятның колагының нәкъ янына гына бөкрәйде дә акрын вә уйчан тавыш белән:

— Мин көтәм,— диде. Бер секунд эчендә уй яңадан эшкә керешә: «Чынлап та, Михаилга ни дип җавап бирергә кирәк инде?.. Михаил матур бит, Михаил сөйкемле бит... Ул, ул, ул бик сөйкемле, бик чибәр бит. Аның калынрак кына кашлары, матур гына итеп карый торган коңгырт күзләре... тагы әллә кайсы төшләре бик килешле бит. Ул мине сөя, чынлап та сөя, ул минем кулымны да үпмәкче булды. Сөя инде, сөя... Мин аны сөямме? Мин... Михаилны?.. Михаил урыс малае бит ул!» Менә башка шушы соңгы уйлар килгәндә, Хәят кинәт Михаил белән үз арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын сизде. Ничектер, моны әүвәл бер пәрдә белән каплап торганнар да, кинәт ул пәрдәне тартып алып, аның артында капланып торган салкын һәм куркыныч нәрсәне күрсәтеп калдырганнар шикелле итеп кинәт сизде. Бакчада, Михаилдан йөгереп качканда, күңеленә килгән китеклекне ул хәзер генә аңлап җитте: «Михаил мөселман түгел бит, ул кяфер бит». Хәятның күңелендә әллә нинди бер салкынлык, сызлавыклыга охшашлы салкынлык туды да, ул, йөрәген җылытырга теләгән шикелле итеп, күкрәген кечкенә мендәргә бастырып, йөзтүбән ятты: ул мөселман түгел, ул «кяфер» бит! Йөрәкне хәзер генә җылытып торган сөекле Михаил сурәте әллә кая китте дә, аның урынына «кяфер» Михаил сурәте килеп басты. Бу сурәт салкын һәм куркынычлы иде.

Бу сурәтнең тирәсендә җәһәннәмнәр, гөрзиләрен[1] күтәргән зөбанилар[2] йөри башладылар...

---

[1] *Гөрзи* — чукмар.

[2] *Зөбани* — тәмугтагы җәзалаучы фәрештә.

Йөрәктәге салкынлык һәм сызлану артканнан-арта вә куркынычланганнан-куркынычлана башлады. Хәят, бу куркыныч сурәтне күңеленнән чыгарыр өчен, бакчада урын биргән студентны, калын вә кызыл иренле Евгенийны, ниндидер бер уен уйналганда берәр кызның кулын үбү җәзасы куелгач, Хәятның кулын килеп үпкән бер яшь офицерны, тагы әллә кемнәрне уйлап карады. Ләкин күңелдәге белемсез курку һаман бетмәде генә түгел, бәлки көчәйде генә: студент та «кяфер», калын вә кызыл иренле Евгений да «кяфер», яшь офицер да «кяфер», әллә кемнәр дә «кяферлар» — һәммәсе кяфер, кяфер, кяфер.

Хәят үзен «кяферлар» арасында чолганып калган итеп күрә башлады. Йөзе белән мендәргә капланды, тын да алып булмаслык итеп капланды да:

— Әстәгъфирулла, йа Раббем, әстәгъфирулла,— дип уйлады, бу истигъфар[1] астында «көфер»дән вә «кяфер»не сөюдән Алланың кодрәтенә сыену яшеренә иде... Бу истигъфардан соң «теге кяфер сурәтләр» җуялып торган шикелле булдылар.

Хәят, чалкан әйләнеп, бер беләген маңгае өстенә куеп ятты да: «Үзегезнең мөселман кызы икәнегезне, мондагы егетләрнең рус егетләре икәнен онытуыгыз килешми»,— дип язылган хатны исенә төшерде. Үзенең, ничек бу хатны алгач та, хәзер уйлаган нәрсәләрен уйламаган икәнчелегенә таңга калды (гаҗәпләнде). «Кяфер сурәтләр» тагын башны капладылар. Хәят, одеялы белән качынып:

— Әстәгъфирулла, Илаһи, үзең сакла,— дип, тагы Аллага сыенды. «Кяфер сурәтләр» тагы җуялган шикелле булдылар. Моннан соң Хәят: — Раббем, соң мөселман егетләр беткәнмени? — диде дә одеялын яңадан ачып җибәрде. Уйга мөселман егетләр килә башладылар, ләкин ни өчендер болар һәммәсе малахай (тәвәккәл) бүрек кигәннәр иде. Малахай бүрекләрен салып җибәрәләр дә эченнән чәчсез, җирәнгеч ак баш чыга, малахайдан пар күтәрелеп, бик начар ис чыга иде. Хәят көч-хәл белән күз алдыннан бу начар картинаны куып җибәрде дә үзүзенә:

— Һәммә мөселман малахайлы буламыни? — дип сөаль бирде. Җавап урынына фикергә үзе белә торган 10—15 яшь байлар (байбәтчәләр) килделәр. Болар һәммәсе ак якалы иде, ләкин һәммәсе исерекләр, һәммәсе качырып тота торган содержан-

---

[1] *Истигъфар* — ялвару.

калары яныннан кайтып баралар шикелле иде. (Хәят сүз аңлый башлаган заманнан ук үзләренә гайбәт сатып утырырга керә торган хатыннардан шулай ишетеп килә иде.) Аның өстенә бу егетләр һәммәсе: «Без мөселманнар бит, бездән мөселман кызлары качарга тиешләр бит»,— дип торган шикелле торалар иде... Тагы «кяфер сурәтләр» килә башладылар...

Бервакыт Хәятның башына Михаилның мөселман була алуы уе килеп, күңеленә ләззәтле җылылык чәчә башлаган иде, кинәт җуялды: ул яшь вакытында анасыннан мөселманлыкка чыккан русларның асылып үтереләләр икәнлеген ишеткән иде.

Бу кара фикерләр бик озак вакытлар Хәятка тынычлык бирмәделәр. Бу фикерләр арасында берсе бигрәк куркыныч иде: Хәят яшьрәк заманында бервакыт Газизә абыстайдан әллә кайсы мөфтинең, урыска гашыйк булып, чукынган кызлары турысында ишеткән иде. Гомеренең бер генә вакытында, бер генә мәртәбә ишетеп калганы бу кызлар хәзер сурәтләре белән аның алдына килделәр: алар әүвәлдә бик матур булганнар да, чукынгач, йөзләреннән иман нуры китеп, зәңгәрсу акланып калганнар шикелле; алар әүвәл бик яшь булганнар да, чукынгач, карчыкланып, дуңгыз ите ашап утыра башлаганнар төсле; аларның күңелләрендә әүвәл шатлык кына булган да, чукынгач, ачы кайгы, әүвәлге заманнарны, ата-аналарын сагынып, ачыну гына калган шикелле тоела иде.

Бу нәрсәләр Хәятның башын соң дәрәҗәдә авырттырдылар һәм нервларын тиз төзәлмәслек итеп көйсезләндерделәр. Ул, йоклап киткәч тә, тиз генә тынычлап җитә алмады: йомшак кына йомылган, озын кара керфекле күзләрнең аскы капкачлары әледән-әле нервно калтыранып алалар иде.

Бу вакытта ике фәрештә кояшны алтын зынҗырлар[1] белән Каф тавы артыннан өстерәп чыгардылар: дөнья нурга манчылды; урамнарда тереклек кайный башлады.

Шулкадәр аптыраш, шулкадәр уйлану белән үткәрелгән бу төн Хәятның үзен чолгаган рус җәмгыятенә карашын бөтенләй үзгәртте. Ул бу җәмгыять бирә ала торган рәхәт вә күңеллелеккә кул селки алмый, ләкин аңар әүвәлге шикелле бер ышаныч, мәгъсуманә талымсызлык белән дә карый алмый иде: нәкъ әүвәлге шикелле үк тышкы күренеш астында зур бер ышанычсызлык, ихлассызлык яшеренеп тора башлады.

---

[1] *Зынҗырлар* — чылбырлар.

Ул, яшьлек теләве буенча, бу җәмгыятьнең сөйкемле егетләрен читкә кагып җибәрә алмаса да, алар белән катышуын бик гади бер дәрәҗәдән уздырмаска, артык бер мәгънә күрсәтә торган иттермәскә, бары тышкы яктан (мөхес заһири) гына ясап күңелгә һичбер төрле итеп катыштырмаска тырыша иде.

Үз-үзенә ясап куйган бу рамкасы бәгъзе вакытларда аны бик каты кыса, бик күп уңайсызлыкларга сәбәп була, ләкин ул шулай да бирелми, нинди авырлык белән булса да җиңеп чыга иде.

Бик күп вакытларда аңар яшь йөрәгендә яңа гына туып килә торган бик матур тойгыларны буып ташларга туры килә дә соңыннан күңелне әллә нинди бер бушлык, бер эч пошу каплап ала иде. Ләкин ул һаман үзе билгеләп куйган рамкадан чыга алмый, чөнки ул рамканың як-ягын коточыргыч сакчылар: әллә кайсы мөфтинең чукынган кызларының сурәтләре саклап торалар иде. Ул кызларның әле һаман битләреннән нур суырылып чыгарылып тора; алар әле һаман дуңгыз ите ашап утыралар; алар әле һаман ата-аналарын сагынып елашалар шикелле була да, Хәят йөрәгенең капкачларын бик ныгытып ябып вә бикләп куя иде.

Менә бу ясама[1] бикләнү Хәятның бөтен кызлык вакытын күңел ачлыгында үткәрде.

9. АЛАР БЕЗГӘ, БЕЗ АЛАРГА БУЛАСЫ ТҮГЕЛ

Хәятның туганымы Әминә — N шәһәрендәге иң бай татар Мостафа Рәхимов кызы иде.

Гыймадов һәм Рәхимов гаиләләре быел җәй көне генә йөрешә башлаган иделәр. Мостафа абзый үзе елның күбрәк вакытында шәһәрдән алтмыш чакрым ераклыктагы сукно фабрикасында тора; хатыны Рәхимә абыстай ике кызы вә өч ир баласы белән күбрәк вакытта шәһәрдә торалар иде.

Хәят барып кергәндә, Рәхимовларның ялтыратып яктыртылган йорты һәрвакыттагы шикелле шау-шулы, ыгы-зыгылы иде. Марҗа асрау коридор буенча, чәй дирбиясы (җиһазы) күтәреп, җәһәт кенә столовойга таба бара; коридорның аргы башында 7—8 яшьлек бер ир бала, ду килеп, кулга өйрәнгән куян баласын куып йөри; күп санлы электрик кандилләре

---

[1] *Ясама* — ясалма.

белән яктыртылган залдан кемнәрнеңдер тигез вә ачык тавыш белән русча сөйләшкәннәре ишетелә иде. Туганымын каршыларга чыккан Әминә аны:

— Ник бу кадәр соңга калдың, туганым? — дип каршы алды.

Хәят, көзгегә карап, прическасын төзәтә-төзәтә:

— Әни ястүеңне укып кит диде дә, тәһарәтләр алып, намазлар укып кичектем,— диде һәм, көлемсерәп, Әминәгә кулын сузды.

Әминә:

— Шул әниләр үзләре, безнең шикелле яшь вакытта, бер намазларын юньләп укымаганнардыр әле,— ди-ди, Хәятның кофточкасының арт ягын рәтләде дә: — Мин абыйга әйтим, залдан чыксын,— дип, туганымыннан алдарак китте.

Хәят Әминәнең агасы Сәгыйтьтән гади татар кызлары шикелле үк итеп качмаса да, аның белән бер мәҗлестә утырмый иде.

Хәят залга кергәндә, Сәгыйть аны борылып карый-карый чыгып китте. Залда Әминәнең апасы Рөкыя, боларның мөгаллимәләре Анна Петровна, җәй көне кечкенә ир балаларын укытып торган, хәзер укый торган шәһәреннән бәйрәмнәр уздырып китәргә кайткан студент Николай Иваныч һәм Хәятка таныш түгел, сакал-мыекларын бөтенләй кырган, бик купшы киенгән бер яшь егет утырып торалар иде. Хәят болар белән күреште; теге купшы егет белән дә танышты. Ул егет күптән түгел генә Москвадан кечкенә ир балаларны тәрбияләргә килгән француз икән. Рөкыя студентка нәрсәдер сөйли, студент та ихлас белән тыңлап утыра; Анна Петровна белән купшы егет французча сөйләшеп торалар иде. Хәят кергәч, Рөкыя сүзен кисте дә аннан кичегүенең сәбәбен һәм Газизә абыстайның саулыгын сорашып алды. Студент, уйчан гына елмайган күзләрен Хәятка төбәп:

— Хаят Бургановна, мин сезгә бик үпкәлим. Минем хатыма каршы җавап язмадыгыз, әмма вәгъдәгез язарга иде,— диде.

Хәят матур кашларын җиңел генә күтәренкеләде дә:

— Ах, гафу итегез, Николай Иваныч, әүвәл менә язам, менә язам дип йөрдем дә... аннан соң сезнең адресыгыз алышынган дип ишеттем; яңа адресыгызны Рөкыядән сораган идем, ул шул вакытта эзләп караса да табып бирә алмады,— диде.

Студент Рөкыягә уңайсызланыбрак карады. Рөкыя бик беленерлек булып кызарды һәм:

— Икенче көнне мин ул адресны табып куйган идем дә, аннан соң Хәят үзе сорамады. Мин дә бирергә онытканмын,— дип, күзләрен идәнгә төшереп, кулындагы чылбыр беләзекнең бриллиант кашлы төймәләре белән уйнарга тотынды.

Әминә Хәятны залда озак тотмады, үз бүлмәсенә алып чыкты.

Зур ике тәрәзәле, җыйнак кына бу бүлмә, туганымнар кергәч тә, электрик лампалары белән яктыртылды. Бүлмәнең бөтен креслолары һәм диваны яшькелт хәтфә белән тышланган, тәрәзә вә ишек пәрдәләре дә шул ук төстәге плюштан ясалган иде. Мондагы ике өстәлнең берсе бизәү өстәле, икенчесе язу өстәле — һәр икесе үзләренә кирәкле нәрсәләрнең иң яхшылары белән җыештырылган, язу өстәленә Әминәнең Анна Петровнадан укый торган китаплары (рус нәхүе[1], рус тарихы һәм француз сарыф вә кыйраәт китаплары[2]) һәм бер-ике сурәтле журнал да салынган иде.

Бүлмәнең сул стенасына эленгән кыйммәтле урман рәсеменә каршы, уң стенага бик яхшы рам эченә тыгылган, хатты куфи[3] белән язылган «Аятелкөрси» куелган иде дә, «урман», хатты куфигә карап, көлеп тора, хатты куфи, «урманга» карап, кашларын җыерып, ачуланып тора шикелле иде.

Кызлар, бүлмәгә кергәч тә, теге француз турысында сөйләшеп алдылар. Хәят аны уртача гына егетләрдән берсе саный, бигрәк тә мыегын бөтенләй кырганлыгын ошатмый, авызы әбиләр авызы шикелле булып тора, ди иде. Әмма Әминә, моның киресенчә, французны бик чибәргә куя, бигрәк тә мыегын бөтенләй кырганлыгын бик килешле таба иде. Әминә бу сүзләрне сөйләгәч, Хәят, матур гына көлемсерәп, аңа бармак селкеде дә:

— Степанов мыегын кырып йөри шул,— диде.

Әминәнең бит урталары алсу нур белән яктыртып китте, ул ялкынлы тавыш белән:

— Степанов дигәннән, бүген тагы күрәм бит мин аны. Бүгенге спектакльдә ул да уйный бит,— дип, Хәятның янына ук килде дә, кулларын аның иңбашларына куеп: — Ах, какой он очаровательный, туганым, ах, какой он милый![4]— диде. Әминәнең үткен карый торган соры (серые) күзләре,

---

[1] *Нәхүе* — синтаксисы.

[2] *Сарыф вә кыйраәт китаплары* — морфология һәм уку китаплары.

[3] *Хатты куфи* — куфи язуы (гарәп каллиграфиясенең бер төре).

[4] — Ул нинди җазибәле, нинди сөйкемле! — *Ф. Ә.*

ялкынланып, төшкән җирләрен яндырырлык шикелле күренәләр иде.

Хәят Әминәнең шундый ялкынлануын гашыйк булып ярата; кайсы вакытларда үзе дә туганымы шикелле ялкынланырга тырышып карый да, булдыра алмаганлыгын сизенеп, әллә нинди бик кирәкле бер нәрсәсе җитешмәгән кеше шикелле кәефсезләнә иде. Бу юлы да Хәят туганымының ялкынланганын рәхәтләнеп һәм сөеп карап торды, аннан соң кашларын уйчан гына күтәрде дә:

— Син, туганым, әле һаман белеш түгел бугай аның белән? — дип сорады.

Бу сорау, утлы күмергә сибелгән су шикелле, Әминәне сүндерде. Ул ничек тиз ялкынланган иде, шулай ук тиз сүнде дә: ялкаурак кына чигенеп, креслосына утырды, аскы иренен йомшак кына тешләде дә берәр минут җавап бирми торды; аннан соң тигез генә тавыш белән:

— Юк, белеш түгел, белешләнергә теләмим дә: андый егетләрне читтән торып сөяргә генә ярый... Сөй, сөймә, барыбер, туганым, алар безгә, без аларга буласы түгел бит инде,— диде.

Ахыргы сүзләрнең никадәр дөрес икәнлеген Хәят тойгысы белән аңлый иде. Шуңар күрә туганымыннан дәлил-фәлән сорап тормады, йөзенә яңлыш вә салкын бер ачыклык чыгарып, җиңел генә башын селкеп, туганымы сүзенә ышанганлыгын белдертте.

Дуслар берәр минут тик утырдылар. Аннан соң Әминә шул ук тигез һәм пошынган тавыш белән:

— Мин әле апаның да Николай Иваныч белән бик артык увлекаться итүе[1] өчен пошынып торам... Син беләсең инде, көз көне, Николай Иваныч укырга киткәч, ул нинди уйга батып, үз-үзенә урын таба алмый йөрде,—диде.

Хәят Рөкыядә көз көненнән бирле булган алмашынуны сизенә, бу алмашынуның сәбәпчесе Николай Иваныч икәнен дә белә, ләкин Әминә белән ул турыда сүз башларга уңайсызлана иде. Хәзер Әминә үзе ычкындырып ташлагач, ул да күптән уйлап йөри торган нәрсәсен:

— Рөкыя апаның ул кадәр увлекаться итүе гаҗәбрәк инде. Минемчә, Николай Иванычның артык матур диярлек җире дә юк бит...— дип әйтә башлаган иде дә, бүлмә ишегенең ачылганын күреп, сүзен кисте.

---

[1] Мәҗзүб булуы.— *Ф. Ә.*

Коридордан җәһәт кенә Сәгыйть килеп керде. Хәят салмак кына аңар аркасы белән әйләнде, Әминә дә:

— Бире керергә ярамый, абый! Бире керергә ярамый! — дип кычкырды.

Сәгыйть, Хәятның монда икәнен бик яхшы белеп кергән булса да, яңлыш кергән булып күренер өчен:

— Ах, виноват![1]— дигән булып чыгып китте.

Моннан соң Хәят, ялкау гына өстәл өстендәге сурәтле журналны алып, сурәтләре өстеннән тиз-тиз генә күз йөртеп чыгарга башлаган иде, Әминә аны бер кыз сурәтенә туктатты да:

— Кара әле, туганым, менә хәзер шушындый кофточка[2] модага кергән инде. Мин Мәскәүдә әллә ничә марҗада күрдем шундыйны,— дип, теге кызның кофточкасын күрсәтте. Бу рәсем быел гына юридический факультет (хокук шәгъбәсе) тәмам итеп, хатын-кыз таифәсеннән[3] бөтен Европада әүвәлге дәгъва вәкиле[4] булган кызның рәсеме иде. Хәят мондый кофточканы беренче мәртәбә күрә икән. Дуслар аның турысында шактый гына уй йөрттеләр...

Озакламый кызларны чәй эчәргә дәштеләр. (...)

10. БЕЗ НӘРСӘГӘ ӘНИ СҮЗЕНӘ КАРЫЙБЫЗ

Купецлар клубында бүген «Ревизор»[5] куелачак, уен тәмам булгач, сәгать өчкә кадәр танецлар булачак иде. Сәгать сигез ярымнар булганда, клубның артык зур түгел залы халык белән тула башлады. Икенче рәт (саф) скамьялардан җидесен Рәхимә абыстай кызлары вә кунаклары белән килеп биләде. Алар кереп утырганда әүвәлге звонок кына бирелгән иде, пәрдә ачылганчы, шактый көтәргә туры килде.

Әминә, бераз кызарыныбрак, уен башланганны көтә; Рөкыя сцена пәрдәсендә бер русалка (су фәрештәсе) сурәте табып алган да, күзләрен бер дә алмыйча, шуңар карап утыра; Хәят, йокысы килгән кеше шикелле, бик еш исни; калганнар үзара сөйләшеп утыралар иде. Пәрдә ачылды. Бераз вакыт узгач, Бобчинский

---

[1] Гаепле! — *Ф. Ә.*

[2] Хатыннар күлмәгенең югары кыйсьме (өлеше).— *Ф. Ә.*

[3] *Хатын-кыз таифәсеннән* — хатын-кыз җәмәгатеннән.

[4] *Дәгъва вәкиле* — адвокат.

[5] Зур рус мөхәррирләреннән Гогольнең түрәләр тормышыннан алып язган комедиясе.— *Ф. Ә.*

ролен уйнаучы Степанов сценада күренде. Әминә сискәнеп китте дә скамьясының алдынарак күчеп утырды һәм беләкләре белән алдагы скамьяның артына таянды. Аның йөрәге сикерә һәм бөтен гәүдәсе кытыкланган шикелле була иде. Хәят акрын гына Әминәнең ботына төртте дә, мәгънәле генә көлемсерәп, аның күзләренә карады. Бу вакытта сценада Бобчинский Добчинский белән тартыша-тартыша сөйләргә азаплана иде. Әминә дә җиңелчә генә елмайды һәм, Хәятның колагы янына ук бөкрәеп:

— Беркөнгегә караганда ябыга төшкән, әйеме, туганым? — диде.

Пәрдә төшкәч, Әминә башкалар туктап беткәнче кул чапты һәм иң ахырдан нечкә генә, сценага ишетелмәслек тавыш белән:

— Браво, Степанов![1]— дип кычкырды.

Йөри торган бүлмәгә (фойега) чыктылар. Монда халык, шау килеп, бүлмә буенча йөренә иде.

Рәхимә абыстайлар төркеме дә, халык арасына катышып, ул бара торган якка юнәлде. Рәхимә абыстай Рөкыя белән студентның урталарында бара иде. Мондагы гаиләләрнең баераклары, һәммәсе диярлек, Рәхимә абыстай белән белешләр икән: аннан да, моннан да аңар баш ияләр, кайсылары килеп күрешәләр һәм кайсылары озак-озак сөйләшеп тә китәләр иде.

Әминә белән Хәят тирәсенә дә бер төркем халык җыелды. Болар яшь руслар: берничә студент, яшь офицерлар, яшь чиновниклар иде.

Бераз йөргәч, Рәхимә абыстайлар төркеме бүлмә кырыйларына тезеп куелган скамьяларга утырды. Яннарындагы русларның да кайсылары утырдылар, кайсыберләре аяк өстендә калып сөйләшә тордылар.

Хәятның матур йөзе бөтен узып баручыларның күзләрен үз төркемнәренә тарта иде.

Ул, үз тирәсендәге рус егетләре белән сөйләшеп торганда, бервакыт, үз өстенә кемнеңдер бик төбәп караганлыгын тойды да шул караш килгән якка күзләрен төшерде һәм ерак түгел генә җирдә утырган бер студентның үзенә бик туры, ләкин йогышлы карап торганлыгын күрде. Студент садә генә, ләкин килешле киенгән, ябык кына битле, коңгырт чәчле, яңа гына

[1] — Афәрин, Степанов! — *Ф. Ә.*

мыек чыга башлаган егет иде. Хәятның күзләре студентның күзләре белән очраштылар да бер генә минут бер-берсенә карашып тордылар.

Студентның ачыграк кына зәңгәрсу күзләре Хәятта бик матур тойгы калдырдылар: ул күзләр зәңгәрсу хәтфәдән ясалганнар да Хәятны кадерләп, тирбәтеп торалар шикелле; студентның йөзендә шул зәңгәрсу хәтфә күзләрдән башка бернәрсә дә юк та, шулай да андый хәтфә күзләре булган йөз бик тулы вә бик сөйкемле шикелле иде. Хәят яңадан бер кат күтәрелеп карады. Хәтфә күзләр яңадан аны кадерләделәр, йомшак кына тирбәттеләр...

Ул Әминәнең колагына табарак бөкрәйде дә:

— Кара әле, туганым, әнә нинди сөйкемле күзләр,— диде.

Әминә, күтәрелеп, студентка карады һәм, күзләрен аннан алмыйча гына:

— Бу студентның моңар кадәр һич күренгәне юк иде, чит шәһәрнеке булырга кирәк,— диде.

Яннарында утыра торган егетләрнең берсе, Хәят белән Әминәнең үзара яшерен генә татарча сөйләшкәннәрен сизеп:

— Ах, мин дә мөселман теле аңласам иде, туташларның үземнән ни дип көлгәннәрен белер идем,— диде дә үзе киң генә итеп елмайды.

Хәят та күзләрен елмайтты һәм татарчалатып:

— Һич юк! Без...— дип әллә нәрсә әйтә башлады.

Бу сүздән бөтен төркем шаркылдап көлеп җибәрде. Теге егет тә:

— Хич юк, хич юк, мы бельмясь[1],— дип көлде.

Хәят шуннан соң гына үзенең руслар белән татарча сөйләшә башлаганлыгын аңлап алды да ирексез үзе дә көлеште... Бу эшкә ялгап, егетләр әллә никадәр анекдотлар[2] да сөйләп алдылар. Бераз вакытлардан соң Хәят үз төркемнәреннән кузгалган Николай Иваныч артыннан хәтфә күзле студентның киткәнлеген күрде дә эченнән генә: «Бу студент безнең белән танышырга тырышып йөри инде»,— дип уйлап куйды. Мондый җирләрдә Хәят белән танышырга теләүче рус егетләре күп була; аларның күбесе, тырыша-тырыша, әллә нинди сәбәпләр табып танышалар да иде. Шунлыктан безнең Хәят соңгы

---

[1] — Һич юк, һич юк, без белмәс.— *Ф. Ә.*

[2] Ма ля ягънинең көлдертә ала торганнары.— *Ф. Ә.* (Мәгънәсез нәрсәләрнең көлдертә ала торганнары.— *Төзүче.)*

вакытларда инде үзенең егетләр күзендә бик югары урында торганлыгын ачык белә, тоя иде.

Бу юлы да Хәятның уйлаганы яңлыш чыкмады: хәтфә күзле студент фойега Николай Иванович белән бергә, аның белән нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә кайтты да Хәятлар төркеменнән ерак түгел бер скамья янында гына аннан аерылып калды. Николай Иваныч Рәхимә абыстай янына килде һәм:

— Менә шушы карточка иясе, студент, сезнең белән танышырга тели,— дип, аңар бер визитный карточка[1] тоттырды.

Рәхимә абыстай карточканы акрын гына оештырып укыды. Анда русча: «Гали Мөхәммәт углы Арсланов. Москва университеты студенты» дигән сүзләр язылган иде. Ул күзләрен олуг сымак кына Иванычка төшерде һәм карточкадан гына аңлап бетмәгән шикелле:

— Ул мөселманмыни? — дип сорады.

Николай Иваныч:

— Әйе! — дип җавап биргәч, салкын вә кыска гына тавыш белән:

— Мөмкин түгел дип әйтегез,— диде.

Әминә:

— Мөселман булса, нәрсә булган соң инде, әни? Безне ашамас бит,— дип карышып караган иде дә, Рәхимә абыстай аны бик кыска туктатты:

— Син мине өйрәтергә яшьрәк әле,— диде.

Хәятка студентның татар икәнчелеген белгән минут — тормышындагы бик санаулы гына изге һәм җанга якын минутлардан берсе иде. Бу минутта ул күңеле һәм тойгысы белән гомер итеп калды: кинәт зәңгәрсу хәтфә күзләр аңар гаҗәп якын, гаҗәп үз булып киттеләр дә йөрәгенең иң нечкә тамырларына кадәр үтә торган ләззәтле нур чәчрәтеп тора башладылар. Ләкин бу кадерле минут озакка сузылмады; Рәхимә абыстайның: «Ул мөселманмыни? Мөмкин түгел дип әйтегез»,— дигән сүзләрен ишеткәч тә, Хәят, күңеленә һәм тойгысына бөтен көче белән каршы килеп, эченнән генә: «Чынлап та, мөселман булгач, танышып булмый шул инде»,— дип уйлады. Хәтфә күзләр әллә кая еракка, югарыга киттеләр дә аларга Хәятның буе җитми башлады. Аларның нуры да хәзер инде Хәят өстенә түгел, әллә кая читкә чәчри иде. Изге, җанга якын

---

[1] Исем һәм фамилиясе язылган катыргы кәгазь.— *Ф. Ә.*

минут Хәятның күңеленә тиеп кенә китте дә җуялды. Әминәнең: «Мөселман булса, нәрсә булган соң, әни? Безне ашамас бит!»— дигән сүзе ул кадерле минутны яңадан тергезә башлаган иде, Рәхимә абыстайның: «Син мине өйрәтергә яшьрәк әле»,— дигән сүзе аңар ирек бирмәде. Хәтфә күзләр җуялдылар: алар Хәят өчен түгел иделәр.

Күңел үзенең ирексезлеген һәм әллә нинди бик тупас бау белән буыла икәнен сизенеп пошынды. Хәятның эчендә нәрсәдер, аның үзенә белеш түгел бернәрсә, күңелнең пошынуы белән сугышырга тотынды...

Хәят тирәсендәге кешеләргә беленерлек булып сүнде; бераздан, кечкенә авызын зур ачып, озын гына бер иснәде.

Озакламады, икенче пәрдәнең звоногы да бирелде... Рәхимә абыстай төркеме кереп үз урынына урнашты.

Пәрдә ачылганчы, Әминә, еш-еш борылып, күзләре белән арттагы скамьялардан кемнедер эзли-эзли утырды да, уен башлангач, Хәятка:

— Әйдә, туганым, уборнаяга[1] барып килик,— диде. Туганымнар, халыкны ерып, уңайсыз гына чыгып киттеләр.

Болар чыккан бүлмәнең бер башында буфет ишеге, икенче башында уборная ишеге иде. Әминә Хәятны бүлмәнең уртарак бер җирендә туктатты да, бернәрсә әйтергә теләп тә, кайдан башларга белми торган шикелле итеп, бераз вакыт туганымының күзләренә туп-туры карап торды.

Хәят бу караштан курыккан сымак бер тавыш белән:

— Нишләдең син, туганым? — дип сорагач, Әминә, үткен карый торган, булдыклы соры күзләрен җәһәт кенә уйнатып:

— Без нәрсәгә әни сүзенә карап торабыз соң, туганым? Әйдә, барабыз да теге мөселман студенты белән танышабыз. Аның әни белән танышырга теләве, билгеле инде, безнең белән танышыр өчен генә бит... Мөселман, имеш! Мөселман булса, ни булган соң? Мөселман булса, бигрәк яхшы: шулай бит, туганым? Бигрәк яхшы! — диде. Бу вакытта Әминәнең тулы гына ап-ак чәһрәсе[2] батырлык һәм ирек сөю күрсәтә, ялкынланган үткен күзләре очкыннар чәчәләр иде.

Хәят аптырашта калды: аның да танышасы килә, хәтта бик килә иде. Ләкин ниндидер бер курку күңелен каплый да бөтен

---

[1] Юына торган бүлмә.— *Ф. Ә.*

[2] *Чәһрә* — йөз, бит.

батырчылыгын һәм танышасы килү тойгысын югалттырырга тырыша иде. Аның башына төрле-төрле уйлар килделәр: менә ул хәтфә күзле студент белән танышкан да татарча сөйләшеп йөри; менә аның үзен дә, Әминәне дә Рәхимә абыстай карышып танышкан өчен бик ачулана; менә Газизә абыстай һәм Борһан абзый да вакыйганы белгәннәр, алар бик рәнҗиләр, тиргиләр; менә мөселман студент белән танышканны шәһәрнең бөтен татар хатын вә кызлары да белгәннәр; алар колактан колакка гына: «Хәят яр сөя икән»,— дип сөйли башлаганнар...

Әминә, Хәятның җавап бирә алмый торганын күргәч, эшкә ныграк тотынды: туганымының култыгыннан тотты да буфет ишегенә таба илтте. Хәят та, тартылыбрак кына, аннан калышмый барды.

Әминә Галине, залда күрмәгәч, буфеттадыр дип уйлый иде. Болар үз-үзеннән буфет ишеге алдында өч кенә секундка тукталдылар да, аннан соң ирексез атылып кергән шикелле, буфетка кереп тә киттеләр. Бу вакытта Хәят үз-үзен белмәслек булып каушаган иде: йөрәге күкрәгеннән сикереп чыгарлык булып типте. Хәер, Әминә үзе дә каушамаган түгел иде; ул, бу эшләрен булдыра алган кадәр тизлек белән үткәреп, үз-үзенә дә сизелмәслек кенә эшләп ташларга тели иде.

Керделәр. Гали буфетта юк иде.

Кызларның һәр икесендәге каушау каядыр китте. Йөрәктә әллә ничек, тыныч вә рәхәт булган шикелле булып калды. Бары матур йөзләрдәге артыграк алсулык кына әле генә узып киткән хәлне искә төшереп тора иде.

Кызлар буфеттан икесенә ике зур гына алма алган булдылар да чыгып киттеләр. Әминә шыпыртрак тавыш белән:

— Кайда китте соң ул җәфа? — дип куйды.

Хәят аңар каршы:

— Очрамаганы ук яхшы, туганым. Рәхимә абыстай белә калса, икебезгә дә уңайсыз булыр иде, минем әнигә дә ишетелер иде,— диде.

12. БЕЗ БЕЛЕШМӘСӘК ТӘ, БЕЛЕШҮЧЕ ТАБЫЛГАН

Галине антракт вакытларында күрә алмагач, Хәят белән Әминә аны клубтан киткән булырга кирәк дип уйлаганнар иде. Хәят моңар бер яктан кайгыра вә икенче яктан куана, әмма Әминәнең Рәхимә абыстайга ачуы килә иде.

Уен тәмам булды. Халык, залның тирәсенә түгәрәкләнеп утырып, танецлар башланганны көтеп калды. Хәят, Әминә вә Рәхимә абыстай да беррәттәнрәк тезелеп утырганнар, музыка вә танецлар башланганны көтәләр иде.

Бервакыт Хәят сөйкемле генә бер кыз белән култыклашып залга кереп килә торган Галине күрде. Гали янындагы кызга елмаеп кына нәрсәдер сөйләп килә, һәм аның күптән түгел генә Хәятны кадерләгән вә аны тирбәткән зәңгәрсу хәтфә күзләре хәзер ниндидер Хәятка мәгълүм түгел кызны кадерлиләр вә аны тирбәтәләр иде. Галинең елмаюы да Хәятка яшерен мәгънәле вә серле шикелле күренде. Теге кызга сөйләп бара торган сүзләре дә әллә нинди матур сүзләрдер шикелле тоелды. Җан коры гына сызланды, аның әллә нәрсәсен кисеп алганнар шикелле иде. Хәят, Әминәнең тезенә төртеп, күзләре белән Галине күрсәтте дә:

— Без белешмәсәк тә, белешүче табылган әле,— диде һәм үзе коры гына елмайды.

Әминә Галинең янындагы кызны бик ныклап карады да Хәятка:

— Бу — Виноградовның Москвада укый торган кызы Ольга булырга кирәк. Впрочем (хәер), танып әйтүем түгел, Виноградовның улына охшатып кына әйтәм,— диде. Бу вакытта Әминәнең күңелендә бик куәтле усаллык кузгалган иде: йөзе күгелҗем төскә керде. Ул үзе ачулы күзләре белән Рәхимә абыстайга карады да: «Аны өйрәтергә ярамый, имеш... Бик шәп эш эшләдең инде: кызларыңны ашатмый калдырдың, син тырышмаган булсаң, әлбәттә, ул безне ашаган булыр иде...» — дип уйлады.

Гали Хәят вә Әминә өстенә күз салды да, аларның үзенә караганлыкларын күргәч, күзләрен тиз генә янындагы кызга күчерде. Ул кыз да, башын бераз күтәребрәк, күз очлары белән Галигә карап көлемсерәде. Гали, йөзендәге матур көлемсерәвен хәтфә күзләренә күчереп, сүзендә дәвам итте.

Музыка вальс[1] башлагач, зал биючеләр белән тулды. Болар арасында Степанов та бар иде. Әминә, бераз кызарынып, аның биегәнен карап утырды. Хәят биючеләр арасыннан Гали белән Ольганы эзләп тапты да музыка туктаганчы инде күзләрен алардан аермады. Галинең фигурасы матур йөри; аяк астыннан эләктереп, тарттырылып куелган тар чалбар балаклары серле

[1] Бию көйләреннән берсе.— *Ф. Ә.*

җыерылалар да әле бөтен буйларына елмаялар, әле назлы гына каш җыералар яки бик булдыклы кыяфәт белән киерәләр иде.

Хәятның әче поша башлады...

13. ЯШЕРЕН ЕЛАШ

Төн яктырак кына, шатырдаган суык төн иде. Бит урталары суыктан оялып кызаралар; аяк астындагы кар да, йөрүчеләр баскач, тапталып кимсетелүдән зарланып шыгырдый иде.

Рәхимә абыстайлар йортларына кайтырга чыктылар. Хәят, Әминә һәм Николай Иваныч — өчесе бер атка утырдылар да кучерга акрын гына алып кайтырга куштылар. Николай Иваныч әледән-әле колакларын тоткалап карый иде дә, туташлар аннан: «Шәлләребезне бирмикме, Николай Иваныч?» — дип көләләр иде.

Акрын гына бара торган ат бер чат янына җитте. Монда бер ямщик зур бияләйле кулларын бер-берсенә сuktырта һәм, аяклары белән тыпырчынып, аларны җылытырга тырыша һәм ара-тирә «их!» дип кычкырып куя иде. Кинәт ямщик бу эшләрнең һәммәсеннән берьюлы туктады да булдыклы гына тавыш белән:

Хөснижамал әйтә икән:
«Мин кияүгә барам»,— дип,
Әнкәсе аңар әйтә икән:
«Бармагаең, кадал»,— дип,—

дип җырлап та җибәрде. Хәят белән Әминә, моны ишеткәч, бер-берсенә караштылар да чыркылдашып көлешеп җибәрделәр. Николай Иваныч, көлүнең сәбәбен белмәгәнгә, туташларга аптырап кына карады да:

— Әгәр сәбәбен белсәм, мин дә сезнең белән көлешер идем,— диде.

Кызлар бер-берсенә караштылар.

Хәят:

— Менә Әминә сәбәбен сөйләсен,— дип, үзе яңадан бер кат көлде.

Әминә, әүвәл татарчалатып:

— Әй җәфа, Галигә булса, бер дә сөйләп торырга кирәк булмас иде,— диде дә аннан соң ямщикның җырының тәрҗемәсен русча сөйләргә тотынды.

Хәят бер сүз дә дәшмичә генә уйга чумды. Аның колагында Әминәнең: «Галигә булса, бер дә сөйләп торырга кирәк булмас иде»,— дигән сүзе яңгырый да күңелен әллә кайларга, Галинең зәңгәрсу хәтфә күзләре янына өстери иде. Кинәт аңар Әминәнең бу сүзләре бик зур мәгънә белдертә торган һәм бик артык дөрес, дөреснең аргы ягында дөрес шикелле тоела башладылар. Николай урынында Гали булса, ул үзе дә теге ямщикның көлке җырыннан көлгән булыр иде; бер дә урынсыз булса да, туганымнар ул җырдан һәм Галинең аннан көлүеннән кызарган булырлар иде; ник кызармаска, анда кияүгә бирү дигән сүз бар бит; ике туганым һәр икесе — кызлар, кияүгә барырлык кызлар, Гали — егет, һәм кыз алырлык егет. Шулай булгач, болар кызарган булырлар иде. Ләкин кызарсалар да, уңайсызланмаган, бәлки кәефле кызарган булырлар иде... дигәндә, Николай Иванычның:

—Хаят Бургановнаның бик йокысы килә,— дигән сүз Хәятны уятып җибәрде.

Күп узмады, кайтып та җиттеләр. Рөкыя, шактый алдан кайтып җиткән булса да, капка төбендә калып, боларны көткән икән. Әминә белән Хәят Николай Иваныч белән күрештеләр дә керә башладылар. Рөкыя болардан соңгарак калды һәм Николай Иваныч белән шыпырт кына нәрсәдер сөйләште дә алдагылар артыннан чапты. Аның адымнарында, тын алышында, хәтта бөтен кыяфәтендә бик зур тынычсызлык сизелә иде. Әминә вә Хәят куркышып кына аның йөзенә карадылар. Суыктан кызарган йөздән бернәрсә дә беленмәсә дә, күзләрдәге яшерен төшенкелек Рөкыянең җанында нәрсәдер, бик яшерен бернәрсә барлыгын күрсәтә иде. Әминәнең йөрәге «жу» итеп китте. Ул яшерен генә тавыш белән:

— Ни булды, апа, сиңа? — дип сорады.

Рөкыя бераз төзәнебрәк:

— Бернәрсә дә булмады, бары башым авыртыбрак тора бүген,— диде дә үзе алгарак китте. Аның тавышында җиңелчә генә калтырау һәм ясалма зарлану сизелә иде.

Әминә белән Хәятка йокы урыннары бер бүлмәдә хәзерләнгән иде. Әминә, яртылай чишенгәч, барып, бер йомшак скамьяга ташланды да:

— Кил әле, туганым, алдыма утыр әле,— дип, чишенеп тора торган Хәятны чакырды. Хәят, чишенеп бетергәч, таракларын алып, чәчен тузгытты да, бераз туңган сыман җыерылыбрак, Әминәнең тезләренә килеп утырды. Әминә аны кысып кына

кочаклады һәм, күзләрен ялкынландырып:— Ник Гали безне озатырга килмәде?— дип сорады.

Хәят, уйчан гына көлемсерәп:

— Ул озатырга килгән булса, ямщикның мәхәббәтсез җырыннан көлгән булыр иде бит, туганым? — дип, сорауга сорау белән җавап бирде.

Туташлар ул «мәхәббәтсез» җырдан тагы бер мәртәбә көлеп алдылар да, Әминә:

— Ул да көлгән булыр иде шул, көлгән булыр иде. Хәер, белеп булмый тагын: ирләр кайсы вакытта бик көлке нәрсәдән дә көлмиләр алар...— диде.

Туташлар озакламадылар, яттылар. Галинең зәңгәрсу хәтфә күзләре һәм матур сыны шактый вакытлар Хәятның йомылган күзләре алдыннан китәргә теләмичә тордылар. Бары баса башлаган йокы гына акрын-акрын ул нәрсәләрне томан эченә качыра иде. Хәят укына башлады һәм бераздан йокыга да китте.

Әминәне йокы алмый иде. Ул, «Әлкәүсәр» сүрәсен укып, урынын да өшкереп бакты, ләкин һаман йоклап китә алмады.

Шулай пошынып ятканда, аның колагына күрше бүлмәдә берәүнең мыш-мыш елаган тавышы килә башлаган шикелле булды. Кем елый? Ник елый? Бу вакытта нинди елау?.. Әминә бераз вакыт колакларына ышанмый ятты. Ләкин тавыш һаман басылмады. Тирән төннең тирән тынлыгы эченә яшеренгән бу елау әллә ничек серле һәм җан пошыргыч иде. Әминә җитез генә кроватеннан төште дә, аякларының очлары белән генә басып, тавыш килгән бүлмәгә юнәлде. Һәм яланаяклар аркылы бөтен тәненә җәелгән суыктан вә үзе билгеләп җиткерә алмаган җан тынычсызлыгыннан чытаебрак кына Рөкыя бүлмәсенә барып керде. Елаучы Рөкыя иде... Ул эчке кулмәктән генә, алдындагы өстәлгә кулларын салып вә алар өстенә башын куеп, акрын гына елый иде.

Әминәнең бөтен барлыгы жулап китте: җаны, бик куркыныч бернәрсә сизенгән шикелле, авыртып сызланды. Ул бер кулын йомшак кына Рөкыянең иңбашына куйды да:

— Апа, җаным, ни булды сиңа? — дип сорады.

Рөкыя, сискәнеп, башын күтәрде һәм, Әминәгә килүенең сәбәбен аңламаган шикелле тоныкк кына карап, кулындагы юеш яулыгы белән күзләрен сөртергә тотынды. Әминә яңадан:

— Апа, җаным, әйт зинһар, ни булды сиңа? — дип, Рөкыянең йөзе янына ук бөкрәйде.

Рөкыя шыпырт вә түшенке тавыш белән:

— Эчем поша,— диде дә күзләрен яңадан яулык белән каплады.

Әминә, бераз вакыт нәрсә әйтергә дә белми торганнан соң үзенекенә башка, өзек-өзек бер тавыш белән:

— Башта ук әйттем мин сиңа, осторожно, осторожно, дидем...— дип сөйли башлады да ахырын әйтеп бетермичә кисте.

Рөкыя җавап бирмәде.

Болар бер-берсен бик яхшы аңлашалар иде.

Әминә бары сәгать алты тулганда гына йоклап китә алды.

15. ЭЧ ПОШУ

Март числосының бер пәнҗешәмбе киче иде. Борһан абзый ясту намазыннан соң, һәр пәнҗешәмбедәге гадәтенчә, намазлык өстендә килеш моңлы һәм карт тавыш белән кычкырып, «Ла ястәви» укый башлады.

Аның тавышындагы калтырану һәм каләм белән аңлатып булмый торган бер яңгыраш — бу укуның чын күңел вә ихлас белән уку икәнлеген һәм моның эчендә үлгәннәрне искә төшерү, терекләрне кайгырту, тагы әллә нинди, әллә нинди ят вә авыр тойгылар бар икәнен күрсәтә иде.

Йортта тавыш-тын бетте: Газизә абыстай, намазлык өстеннән тормыйча, картының укуын тыңлый. Хәят бүлмәсендә тын гына утыра. Биби аягын булдыра алган кадәр йомшак басып йөри иде.

Тыштагы буран вә аның тәрәзәгә бәрелүе һәм җилнең выжылдавы йорт эчендәге бу тынлыкны бераз боза вә шуның белән бергә Борһан абзыйның укуына әллә нинди бер серрият[1], тирән бер ясеренлек бирә иде.

Озак бер догадан соң картлар, сәгатьнең тугыз гына булуына карамыйча, йокларга да яттылар. Озакламады, Биби дә ятты.

Хәят, гадәтенчә, комод тартмаларын актарып ташлады да йөз кат күргән нәрсәләрен йөз дә беренче кат күздән үткәреп чыкмакчы булды... Ләкин тыштагы буран, куәтләнгәннән-куәтләнә барып, аның тынычлыгын бозды. (...)

---

[1] *Серрият* — серлелек.

Хәят җәһәт кенә үз бүлмәсеннән чыга башлаган иде дә кире кайтты. Караңгы бүлмәләр аңар куркыныч шикелле һәм аларның берсендә моннан бер генә ай әүвәл үлгән Хәлимә абыстайның өрәге сузылып басып тора шикелле тоелды. Хәят укынып кына лампасы янына килде дә, бер-ике минутлык аптырап торыштан соң, аны алып, бүлмәсеннән чыкты. Һәм артында бик куркыныч нәрсә барлыгын сизгән кеше шикелле атлыгып, Биби йоклый торган бүлмәгә таба китте.

Юлда очраган бүлмәләр, почмакларына качынган караңгы шәүләләре һәм тыштагы коточыргыч давылдан бозылган үлек тынлыклары белән, Хәятка бик эчпошыргыч һәм шыксыз күренәләр иде. Ахыр, Биби янына барып җитте.

Биби, өсте ярым ачык килеш, бер дә кайгысыз, кулларын җәеп, йоклап ята. Аның йөзе, һәрвакыттагыча, майланып ялтырап тора, борын тишекләре кыяфәтсез генә киереләләр һәм янында бертөрле авыр тир исе аңкый иде. Бу күренеш Хәятның тагы да эчен пошырды. Бөтен бу ямьсез бүлмә, бөтен бу Биби, аның мондый ямьсез һәм гамьсез йокысы, баш астындагы бу кечкенә вә иске мендәре һәм тирә-якны тоткан исе — һәммәсе, бергә кушылып, бер тормыш булалар да Хәятның йөрәгенең әллә кайсы җирен кырып торалар иде.

— Биби, Биби, тор әле, тор әле! Кара, Биби, дим, тор, дим! — дип, Хәят аягы белән Бибинең аякларын селкетте.

Асрау, бераз вакыт аңлаша алмый азапланса да, ахырдан торып утырды һәм, әгузе бисмилла әйтеп, күзләрен уарга тотынды.

Хәят Бибине, урыннарын күтәртеп, үз бүлмәсенә алып китте дә шунда ятарга кушты. Йокысыннан айнып җитмәгән Биби идәннең бер почмагына аннан-моннан гына урынын түшәде дә йокыга да китте. Хәят, терсәкләре белән өстәлгә таянып, башын куллары арасына кысып утырып тора башлады. Бүлмәдә, йоклаган булса да, кеше булгач, ул хәзер инде тыштагы тынычсызлыктан курыкмый башлады. Ләкин аның җаны әүвәлгедән дә артыграк сызлана, эче әүвәлгедән дә бигрәк пошына иде. Башта бу пошыну билгесез генә, курку белән катыш башланды да, минутлар узган саен киңәеп, вә шуның белән бергә үк билгелерәк-билгелерәк була барып, саф эч пошуга әйләнде һәм Хәятның бөтен барлыгын каплап алды. Караңгы бүлмәләрдән аңкып тора торган шыксыз үлеклек; аларның эчендәге уннан ятып йоклый торган кешеләрнең бер төрле ага торган тереклекләре; ямьсез йоклый торган ямьсез Биби, аның иске вә

ямьсез мендәре — шул нәрсәләрнең һәммәсенең, үзен (Хәятны) чолгап алып, тереклеге белән үрелеп барулары Хәятка артык күңелсез, әчпошыргыч вә мәгънәсез тоелдылар. Бөтен тереклек аның алдында ямен җуйды, гүя бөтен тормыш шул караңгы бүлмәләр, алар эчендәге «ястүләрен укыгач та» ятып йоклый торган кешеләр, ямьсез йоклый торган Бибиләр һәм караңгы вә коточыргыч давыллы төннәрдән коралып ясалган да, шыксыз вә мәгънәсез булып, скелет (кадид) басып тора иде.

Эч пошты, очсыз-кырыйсыз пошты...

Узган ел гына әле Хәят мондый эч пошуның дөньяда барлыгын да белми, хәтта быел кыш башында да әле ул болай пошынмый иде. Менә бу соңгы өч айда инде анда берничә мәртәбә бу хәл булып узды.

Шушындый эч пошу вакытларының берсендә Хәятның елаганын күргәч, Газизә абыстай да бу хәлгә игътибар иткән иде. Әүвәл ул Хәятны орышып карады. «Тигезлектә үсәсең, зур булмаса да, дәүләт эчендә торасың, Ходайга шөкереннән гаҗиз булырга кирәк; «эчем поша», имеш, ни дигән сүз ул; башыңа нинди кайгы төшкән соң синең?» — дип, вәгазьләп тә карады. Ләкин файда чыкмады. Моннан соң Газизә абыстай: «Бу эш бушка булмас, бозу галәмәте булмасын»,— дип уйлап, Хәятка кырык көн тоташ «Коль-коль җиһан» яздырып эчерде, ләкин «Коль-коль җиһан» да Газизә абыстай теләгән файданы бирә алмады: Хәятның ашказанын боза, эч пошуын төзәтми иде.

16. БАРЫБЕР КАЙЧАН ДА БУЛСА БЕР БАРМЫЙ ХӘЛ ЮК

— Фу, Ходаем, кай җиреннән телгәнмен бит,— дип, Хәят кулындагы кайчысын өстәлгә куйды да хәзер генә икегә кискән батистын карап тора башлады. Батист, чынлап та, кирәкмәгән җиреннән теленгән иде. Хәят батист кисәкләрен берничә төрле итеп әйләндереп карады, бер-берсе янына китереп бакты, ләкин файда чыкмады.

Кирәкмәгән җиреннән теленгән, хәзер инде күлмәкнең иң күренә торган бер җиренә ялгау кирәргә тиеш.

Хәятның кәефе бозылды, ачуы килә башлады да кайчыны бераз арырак төртеп җибәрде, яңлыш киселгән батистларны кровате өстенә атты. Кайчы яңлыш кисүдә, батистлар яңлыш киселүдә гаепле табылганнар иде.

Бүлмәгә, кулына ниндидер бер конверт тотып, Газизә абыстай керде. Хәят йөзен кыйланышланып чытты да зарланган тавыш белән:

— Кара әле, әни, якшәмбе көн эш тотарга бер ярамый миңа, менә ничек телеп ташлаганмын,— дип, теге батистларны алып күрсәтергә тотынды. Газизә абыстай, мондый эш булып киткән чакларда, йөзенә кәефсезлек чыгарып, Хәятны бераз кыздыра:

— Бер эшне күңел биреп эшләмисең син. Үзең монда, күңелең әллә кайда,— ди торган иде. Ләкин бүген, Хәятның гаҗәпләнәсенә каршы, йомшак кына елмайды һәм Хәятка матурлыгына кызыккан сыман бер караш белән карады да: — Йә кызым, юкка борчылма. Монысы бозылса, икенчесе бетмәс әле,— диде. Һәм әллә ничек уңайсызланып кына кулындагы конвертны Хәятка сузды да: — Менә шушы кешене таныйсыңмы дип күрсәтергә кергән идем әле мин сиңа,— диде дә, бик кирәкле бер эше исенә төшкән сыман, җәһәт кенә бүлмәдән чыгып китте.

Конверт эченнән бер егет портреты килеп чыкты. Башының артынарак киелгән кәләпүше егетнең мөселман икәнен күрсәтеп торганга күрә, Хәят анасының бу портретны күрсәтүе тиктомалга түгел икәнен сизенде: «Яучы килмәгәндә, ана кеше нишләп үз кызына егетләр портреты күрсәтеп йөрсен!»

Хәят портретны бик пөхтәләп карарга тотынды. Аның йөрәкчеге уйнаклап тибә башлаган иде.

Егетнең йөз кыяфәте һәм сынын тотышы, портрет күрсәтүенә караганда, бик сөйкемле иделәр: ачык маңгай, кәкрәебрәк килгән шактый киң кашлар, очлары югарыга каратылып куелган куе вә озын мыек һәм күкрәген киерелдеребрәк, егет сымак торыш Хәятка мәхәббәтле күренделәр.

Егетнең кәләпүшеннән башка бөтен киеме иң соң мода белән Европача тегелгән нәрсәләр иде. Портрет иясе бу яктан да Хәятка ошады.

Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты. Шулай карый торгач, бервакыт аңар егетнең кәләпүше артыграк артка киелгән шикелле тоелды да, ул: «Кәләпүшен бераз алгарак киертәсе бар икән»,— дип уйлады.

Аннан соң, Газизә абыстайның аяк тавышы ишетелгән шикелле булгач, Хәят портретны тәрәзә төбенә ташлады да бүленгән эшенә тотынган сыман итте.

Газизә абыстай, кергәч тә, кызының йөзеннән карап берәр нәрсә аңларга тырышса да булдыра алмады: Хәятның йөзе һәрвакыттагы шикелле матур, тыныч һәм ачык иде, яңа бер тойгы аңлатмый иде. Газизә абыстай уңайсызрак елмайды да:

— Таныдыңмы, кызым? — дип сорады.

Хәят йөзен бер дә үзгәртмәскә һәм тавышын илтифатсыз ясарга тырышып кына:

— Ә мин җүнләп карамадым да әле аны,— дип, карточканы яңадан кулына алды һәм өстән генә бер кат күз төшерде дә: — Юк, таный торган кеше түгел,— дип, анасына сузды.

Газизә абыстай бу егетнең Г. шәһәрендәге Салих Фатихов исемле яшь бай, бик тәүфыйклы вә бик образауный кеше икәнчелеген сөйләде һәм, берникадәр сүзләрдән соң, шул егеттән яучы килгәнлеген вә шушы бер-ике көн эчендә аңар бер җавап бирергә кирәк икәнчелеген дә әйтте. Хәят үкчәләре өстендә җәһәт кенә анасына аркан әйләнде. Аның матур йөзе нурлы кызгылтлык белән капланган иде. Газизә абыстай, яңадан бер кат кыска гына, Салих Фатиховның бик бай вә бик тәүфыйклы һәм образауный егет икәнлеген сөйләп, иртәгә ачык бер җавап бирергә кирәк икәнлеген аңлатты да, карточканы Хәятның өстәлендә калдырып, чыгып китте.

Хәят берничә секундлар баскан килеш торды; аннан соң, якындагы скамьяга авыр гына ташланып, бик нык яна торган бит урталарын кулчыклары арасына кыстырды да тик кенә калды. Уй үзенә эшли башларга вакыт икәнен сизенә, ләкин кайдан тотынырга кирәк икәнен белми дә каушап кала иде: бүлмә тарая башлады, тарая, тарая... Менә инде ул Хәятны кысарга ук тотынды... Мондый тар урында ничек итеп фикерне эшләтергә дә, ничек итеп берәр нәрсә уйлап чыгарырга мөмкин булсын!

Хәят иң әүвәл кулына туры килгән бер китапны алды, эченә акрын гына карточканы салды да бакчага чыгып китте.

Бакча киң, җәйге кояш уенчак һәм шат иде.

Хәят, бүлмә эчендә кысылып торып бик арыган шикелле, бакча скамьяларының берсенә килеп утыргач, ял итәсе килү сыман бер тойгыга чумды да, кулындагы китабын ябык килеш тезләре өстенә салып, күзләре белән агачларның яшел яфраклары арасыннан үзенә белемсез бернәрсә эзләргә тотынды. Ләкин ул нәрсә табылмады. Шул нәрсәнең табылмаганлыгыннан булырга кирәк, кояш, яфраклар арасыннан челтәр-

ләнеп, Хәятның күзләренә төште дә бик ачык итеп көләргә тотынды. Кояш көлә, матур кара күзләр оялалар...

Хәят икенче скамьяга күчеп утырды. Хәзер инде, ял итәсе килү сыман тойгы бетеп, аның урынына бик тиз-тиз уйлыйсы, әллә нәрсә, бик кирәкле нәрсә эшлисе килә иде. Хәят китапны ачты да яңадан карточканы карарга тотынды. Карточка әүвәлгедән бераз үзгәргән, кәләпүш хәзер, бераз алгарак килеп, кирәкле урынын тапкан шикелле иде.

Бераздан соң Хәят Салихны сөйләтеп карады. Салих әүвәл бас (калын тавыш) белән сөйләгән иде дә, Хәят аны картсынгач, баритон (ачык вә урта калынлыктагы тавыш) белән сөйли башлады. Салих, моннан да күчеп, нәзек тавыш белән сөйләмәкче булган иде дә, Хәят рөхсәт итмәгәч, аны ташлап, яңадан баритонга күчте.

Хәят күзләргә дә билгеле бер төс бирергә тырышып караса да булдыра алмады: алар коңгыртлык белән чем-каралык арасында, билгесез килеш калдылар.

Моннан соң Хәят Салихның йортын һәм йортындагы тормышын күз алдына китерә башлады: йорт Рәхимовларныкына охшашлырак кына бер йорт; эчендә рояле дә бар; Салих һәрвакыт ак якаларын куеп йөри; кайвакытларда, өстәл янына утырып, счет сала; төнге икеләр-өчләрсез йокларга ятмый; унунберләрсез тормый... Театрлар, концертларга йөри... итеп бер сурәт ясады. Ләкин сурәтләр аермачык чыкмыйлар, әллә ничек томан эченнән генә күренәләр иде.

Хәят үзе утырган скамья янындагы бер агачның яшь ботагын сындырып алды да берәм-берәм яфракларын чәйнәп карады. Яфраклар ачы иделәр. Аннан соң шул ук ботакның кабыгын әрчеп карады. Кабык бармакларны яшькелткә буйый, кабыгы әрчелгән ап-ак чыбык, юешләнеп, «тайгак» булып тора иде...

Хәят карточканы китап эченә салды да үзеннән ерак түгел бер җирдә кояшта кызынып ята торган мәче — «Васька»сын чакырырга тотынды. Ләкин «Васька» ялкау гына күтәрелеп карады да урыныннан кузгалмады. Аның Хәятка бераз үпкәсе бар иде: баягынак ул үзе, аны санга тыкмыйча, алдына менеп утырам дигәндә генә ачуланып төшергән иде. Аннан соң Хәят юлларның берсе белән китте дә, койма янына килгәч, бераз туктап торды.

Күршеләр бакчасыннан сөйләшкән һәм көлешкән тавышлар ишетеләләр иде.

Хәят койма ярыгыннан җиңелчә генә бер күз салды һәм үзүзенә генә:

— Маруся белән жениxы[1] икән әле,— диде дә яңадан агачлар арасында тулганырга тотынды... Башка вакыт булса, ул Мария һәм аның булачак киявенең болай бакчада сөйләшеп, көлешеп йөрүләре хакында, Мариянең чытлыкыгы, булачак киявенең чамадан тыш озынлыгы турысында уйламый гына уздырмас иде. Ләкин бүген аның башына ул уйларның берсе дә килмәде.

Уйланмый иде...

Хәят бер-ике мәртәбә яңадан Салих турысында уйларга тырышып караса да, аны да инде булдыра алмады.

Йомгакның башы җуялган иде...

Кинәт Хәят шәһәр өстенә күтәрелгән колак тондыргыч гөрелтене ишетә башлады. Бу гөрелте, бу шау-шуның шәһәр өстеннән бер генә минутка да җуялып торганы булмаса да, баягынак Хәят аны ишетми иде. Әмма хәзер тупас ямщик арбаларының тупас шатырдаулары, әллә кай җирдәге әллә кемнәрнең әллә нәрсәләр кычкырынулары, зур адымлы зур атларның, купшы чабып, дагалары белән урам ташларын сугулары — һәммәсе, ачык ишетелеп, Хәятның башына каба башлады. Ул шактый вакыт шул шау-шуга чумып утырды. Аның башында хәзер шул гөрелтенең хак вә бар икәнлегеннән башка бернәрсә дә калмаган иде.

Әнә бер ак болыт. Ак ефәк флёр шикелле үтә күрсәтә торган болыт. Ул болыт, артына вак-вак болытчыклар ияртеп, туптуры кояш өстенә бара. Хәят аның, тиз генә барып җитеп, кояшны каплавын тели.

Болыт килеп тә җитте. Аның белән бергә йомшак вә хуш исле җил дә килде һәм Хәятның эсселектән арыган йөзенә, акрын гына исеп, хәл кертте.

Шау-шу басыла төшкән, баш та иркенәеп киткән шикелле булды.

Хәят яңадан портретны карарга тотынмакчы булган иде, ләкин бу вакытта ишегалдында Әминә тавышы ишетелгән шикелле булгач, чабып, аңар каршы китте:

— Бире, туганым!

---

[1] Мария һәм вәгъдәләшкән егет.— *Ф. Ә.*

Әминәнең тулырак кына яңак урталары эсседән матур гына кызарганнар да, бераз тирләгәннәр дә иде. Ул, күзләрен җитез генә уйнатып:

— Әйдә, туганым, киен, мин сине хәзер үзебезгә алып китәм. Кич бергә «Аркадия»гә барырбыз,— диде.

Хәят уйчан гына көлемсерәде дә:

— Мин синең үзеңне җибәрмим бүген, туганым,—диде. Һәм, Әминәнең гаҗәпсенеп каравына каршы, аңар бөтен бүгенге вакыйганы сөйләп, Салихның портретын тоттырды.

Туганымы карточканы караганда, Хәят, бик төбәп, аның үзен карап торды. Әминәнең озак һәм дикъкатьле карашында ошатканлык сизелә иде. Кинәт Әминә күзләрен ялкынландырды вә үзе бөтенләй ялкынга әйләнде дә:

— Барамсың, туганым? — дип сорады.

Хәят күзләрен уйчан гына елмайтты һәм:

— Барыйммы соң? — дип, сорауга сорау белән җавап бирде.

Моннан соң туганымнар карточканы тагы бер кат бик тәфтишләп[1] карадылар һәм карточкадан гына беленеп җитми торган вак-төякне төрлечә чамаладылар да бару һәм бармау ягына булган сәбәпләрне тикшерергә тотындылар.

Хәятның бармау ягына куя торган сәбәпләреннән иң зурысы: N шәһәреннән китәргә вә, шулай итеп, ата-аналары вә дусишләреннән бөтенләй аерылырга туры килү иде. Ләкин Әминә, бу сәбәпкә бер дә исе китмичә, башка төрле сәбәпләр күрә иде: 16—17 ләрдә үк кияүгә чыкканда, кызлык вакыты бик әрәм кала; бик яшьтән балалар белән җәфаланасы була; боларга искитмичә бармакчы булганда да, холкын, табигатен белмәгән, күрмәгән һәм танымаган, ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән кешегә гомерлеккә хатын булу куркыныч дип уйлый иде.

Туганымнарның һәр икесендә бару ягын куәтли торган сәбәп тә юк түгел иде. Егет — матур, бай, тәүфыйклы да, ди. Егет — образауный да: Европа костюмында... Мондый егеткә дә бармаганда, Борһан абзый һәм Газизә абыстайның бик кәефсезләнүләре дә мөмкин.

Кызлар мәсьәләне тагы берничә кат уйлаштылар. Уйлашкан саен, бармау ягын куәтли торган сәбәпләр берәм-берәм җуяла баралар иде.

---

[1] *Тәфтишләп* — тикшереп.

Хәятның N шәһәреннән китәсе килмәүгә, Әминә:

— Карчык булганчы анаң куенында ята алмассың бит, туганым,— дип җавап бирде.

Аның каравы Хәят та туганымы күрсәткән сәбәпләрне ватты:

— Кызлык вакыты әрәм кала, дисең син, туганым. Әрәм кала диярлек нинди хозуры бар соң аның? Болай дип марҗа кызлары әйтсәләр, бер хәер инде: алар, ичмасам, ду килеп, әллә нинди историяләр ясап гомер уздыралар. Әмма безгә нәрсә?.. Холкын, фигылен белмәгән кешегә бару, дисең син. Барыбер, кайчан барсаң да, шулай була бит инде ул...— диде дә Хәят, теләгән нәрсәсен әйтеп бетерә алмаган шикелле итеп, сүзен кисте.

Әминә уйга баткан иде. Бер-ике минут тик тордылар.

Моннан соң Әминә кинәт кенә күзләрен Хәятка төзәде дә батыр вә катгый тавыш белән:

— Бар, туганым, бар! Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк,— диде.

Хәят җавап бирмәде, ләкин күзләренә чыккан салкынча вә корыча ут аның да туганымы сүзләренә ышана икәнен күрсәтә иде.

17. ЙӘ ӘЛЕ, СИН ШӘПМЕ?

Шау-шулы ыгы-зыгысы, тынны кыса торган кызуы, тәртипсез гөрелдәве белән көндез мине чуалта, томаландыра һәм ялкауландыра да Хәятны үзенә кирәкле мәсьәләдән аерып тора иде. Ул бүген көне буе бары шул мәсьәлә турысында, Салихка бару-бармау турысында уйлап йөрсә дә, бер карарга килеп җитә алмады. Әминә белән сөйләшкән сүзләр, хәтта аның шулкадәр ялкынланып әйткән: «Бар, туганым, бар. Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк»,— дигән сүзләре дә Хәятка бер карарга килүгә ярдәм итмәделәр генә түгел, бәлки аны бөтенләй мәсьәләдән ераклаштырдылар гына. Әминәнең һәрвакыттагы сүзләре Хәятка билгеле бер карар бирә алалар иде. Чөнки Әминә үзе, әйткән сүзләренә чиксез-кырыйсыз, бинһая ышанып ялкынлана да Хәятка шик итәргә урын калдырмый иде. Ләкин бүгенге сүзләрен ул алай итеп әйтә алмады. Ул ышанып әйткән шикелле итеп тә әйтте, хәтта ахыргы катгый сүзләрен әйткәндә ялкынланып та әйтте. Ләкин бу ышанып әйтү, бу ялкынлануның үзендә Хәят бер ышанмау, бер ялкынланмау

сизә иде. Шулай итеп, «бару-бармау» мәсьәләсе, Әминә белән сөйләшкәннән соң, бигрәк буталды, бигрәк томанланды:

— Бар, туганым, бар... Бик яшьтән балалар белән җәфаланасы була... Барыбер бармый хәл юк... Ул сине сөяме, син аны сөясеңме икәнен белмәгән кешегә ничек итеп гомерлеккә хатын булырга кирәк?.. Бар, туганым, бар... Портретына карaганда бик матур булырга охшый... Портреттан карап бернәрсә дә әйтеп булмый, туганым. Әнә теге шадра Варяны белә торгансың, портретында бернәрсә беленми, менә дигән матур дип уйларсың... Бар, туганым, бар...

Әминәнең өч-дүрт сәгать эчендә әйтеп өлгергән бу сүзләре бер-берсе янына бик тәртипсез булып тезеләләр дә Хәятның теңкәсенә тияләр иде.

Хәят шадра Варяны белә, хәтта йомшак вә матур холкы, яхшы вә туры җаны өчен ул аны сөя дә, дус та тота иде. Хәят Варяның ертлач-ертлач шадрасының портретта бөтенләй беленми икәнен дә, шул карап торырга бик ямьсез Варяның портретта чип-чибәр чыга икәнен дә һәм үзенең, Салих шулай булып чыга калса, сөю түгел, аның йөзенә туры карый да алмаячак икәнен дә белә һәм шул белүе белән газаплана иде.

Бервакыт Хәятның зиһенендәге Салих чынлап та шадраланып китте. Салихның шадралары нәкъ Варяныкы шикелле икән. Хәят, куркынып, зиһенендәге бу шадра Салихны куарга тотынды һәм, аның китмәгәнен күргәч, үз-үзен мыскыллаган тавыш белән:

— Буламы соң? Килешмәгәнне! «Ул» нишләп шадра булсын? — диде. Болай дигәч, Салих, шадрасы бетеп, портрет күрсәткәнчә матур булып калды. Алай да Хәят, әүвәл бер күрмичә торып, барырга риза булмаска уйлап куйды да иртәгә анасына:

— Үзе белән белешмичә, бер сүз дә әйтә алмыйм,— дип җавап бирмәкче булды. Моннан соң Хәят, өстендәге әллә нинди куркыныч вә авыр фарызны үтәгән шикелле, тынычлап калды. Ләкин, Хәятның тәгаҗҗебенә[1] каршы, бу тынычлык озакка сузылмады, җимерелде. Кинәт аңар яучылагач кына, кияүгә бару өчен генә танышу оят төсле, мәгънәсез шикелле күренә башлады. Кирәк Салихка, кирәк үзенә болай итеп танышу бик уңайсыз, авыр һәм килешсез булыр шикелле тоелды. Белешкәч тә, сөйләшергә сүз дә табылмас, җай да табылмас та, товар

---

[1] *Тәгаҗҗеп* — гаҗәпләнү.

карашкан төсле бер-берсен карашырлар да, әллә нинди авыр тойгы белән бер-берсеннән аерылышып, акрын гына икесе ике якка китәрләр шикелле булды: менә Салих аңар карый... Хәят аның күзләрендә:

— Йә әле, кызый, син шәпме? Миңа хатын булырга ярарлыкмы? — дигән сүзләрне күрә дә Салихтан да, үз-үзеннән дә ояла, әллә нәрсәдән хурлана. Менә Хәят Салихка карый... Салих та, үз чиратында, Хәятның күзләрендә:

— Йә әле, егет, син шәпме? Миңа кияү булырга ярарлыкмы? — дигән сүзләрне күрә дә Хәяттан да, үз-үзеннән дә ояла. Хәят аның оялганлыгыннан бигрәк ояла. Салих та, Хәятның бу оялуын күреп, яңадан, яңадан ояла, кашларын җыера, йөзләрен чыта... Һәр икесе кып-кызыл кызарышалар...

Бу нәрсәләрне уйлаганда Хәят чын-чынлап кызарды да, куллары белән йөзен каплап:

— Юк, юк, булмас, мәңгегә булмас...— диде. Хәзер инде ул Салих белән никахка кадәр танышуны теләү түгел, Салих үзе танышмакчы булса да, риза була алмас иде...

Төн килде. Бөтен табигать, бөтен җир йөзе, бөтен яшь йөрәкләр шикелле, Хәят та язгы төннәрне сөя иде. Язның салкынчарак хуш исле төннәре, бигрәк тә ул төннәрнең шундый хуш исле булучылыгы Хәятның йөрәгендә үзенә белемсез бер тойгы уята иде. Бу тойгыда җиңелчә генә моң, җиңелчә генә шатлык, нәрсәнедер җиңелчә генә сагыну, нәрсәнедер җиңелчә генә көтү, нәрсәгәдер җиңелчә генә куану, тагы әллә нәрсәләр бар иделәр. Хәят язгы төннәрдә бу тойгы белән исерә дә, үз-үзен онытып, томанлы рәхәтлек эченә батып кала иде.

Бүгенге төн Хәяткa, үзенең салкынчарак кына аязлыгы, язлыклы хуш исе эченә төрендереп, катгый бер карар да китерде.

Хәят, һәр көнге гадәтенчә, бакчага ачылган тәрәзәсе төбенә килеп утырды да, бакчадан керә торган салкынча һаваны зурзур йотымнар белән эчеп, әлеге үзенә билгесез тойгының томанлы рәхәтлегенә талды. Һәм, шул томанлы рәхәтлек эченә төренеп, иртәдән бирле башын әйләндергән мәсьәләне салмак вә тыныч кына чишеп ташлады.

Карар булды: Хәят Салихка барырга риза! Салихка баргач, бу соңгы айларда була башлаган эч пошу бәласе дә бөтенләй бетәчәк булды. Чөнки Хәят тормышының тойгы белән генә беленә торган китек ягын Салих бөтенләй тутырачак...

Бу вакытта ай, җир белән күкнең бер-берсенә тоташкан җиреннән аз гына күтәрелеп, Хәятка күренмичә генә, аның арка ягыннан, агач башларына көмеш сыман тоныг нур чәчеп тора иде. Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күләгәләре Хәятның күңелендә хыялый картина тудырдылар: әнә шул күләгәләр арасында плащка (ридага) төренгән, башына зур читле кара эшләпә кигән Салих килә! Хәят кайчандыр театрда, шундый бер бакча буйлап, шундый бер егетнең үзенең сөеклесе янына килгәнен күргән иде. Салихның да кулында, теге егетнеке шикелле, бер думбрасы бар икән. Ул, шул думбрага бик матур чиертеп, кычкырып җырлап, Хәят утырган тәрәзәгә таба килә икән...

Салихның «Сөям сине» дигән сүзсез җырлана торган җыры бөтен бакчаны яңгыратса да, Хәяттан башкаларга: Борһан абзый, Газизә абыстай һәм Бибигә ишетелми икән, ләкин Хәятка аермачык ишетелә икән.

Болай яшерен генә килгәч, Салих, билгеле инде, Хәят янына кермәкче булып килә. Ул тәрәзә аркылы керер... Кергәч, билгеле инде, Хәятның матурлыгын мактап, баритон тавыш белән җырлар; аннан соң, үзенә барырга риза булган өчен, Хәятның маңлай, яңак, күз һәм иреннәреннән үбәр; Салихның куе мыегы Хәятның йөзен дә, борынын да, маңлаен да кытыкландырыр...

Боларны хыялына китергәч, Хәят чынлап та кытыкланып китте, кызарынды һәм, үз-үзеннән оялып, мендәренә барып капланды да:

— Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде! — диенде.

Бу теләк кызлык вакытының иң ахыргы вә шуның белән бергә иң куәтле теләге иде.

1911

Шәриф Камал
(1884—1942)

АКЧАРЛАКЛАР[1]

ДИҢГЕЗ КӨЛӘ

Җәй башы иде. Каспий диңгезе буендагы балык промыслоларында елдагы рәвешчә хәрәкәт башланган; «сельдь» тотарга хәзерләнәләр; аралары өчәр-дүртәр чакрымнан диңгез кырые буйлап тезелеп киткән һәм кыш буе диңгез моңнары, дулкын аккордлары тыңлап кына йоклаган промыслоларның лабазларында инде кешеләр кайнаша башлаган иде...

Мартның калган атнасы — чалт аяз һәм салкынчарак бер көн иде. Кояш иңәр алдыннан гына диңгез читe буйлап ике кеше, сүрән-сүрән адымнар белән, Мительбаум промыслосына якынлаша иделәр. Көнчыгыштан искән йомшак кына җил диңгезнең өс катын азрак җыерчыкландырып бизи, матурландыра һәм диңгезнең чит буйларында, вак-вак дулкыннар ясап, кырый ташлары белән ачусыз гына бәрештерә тора иде.

Мительбаум промыслосында чаннар тазартып маташкан эшчеләр инде эштән туктадылар.

Монда әле неводчылар килеп җитмәгән. Тачкачылар гына эшләп маташа иделәр. Боларның барлыгы биш татар егете, өч рустан гыйбарәт иде. Алар лабазга якын ук, диңгез кырыеннан унбиш-егерме саженьнар гына читтә бер баракта тора иделәр.

[1] Кыскартып алынды.

Барак, калкурак җирдә булып, яртысы комга күмеп ясалган, арт ягында диңгезгә караган бер генә тәрәзәсе бар, ул да җир белән тигез иде.

Эшчеләр баракка җыелгач, десятник Исак үзе белән ике кеше ияртеп керде дә:

— Менә монда сезнең земляклар да бар. Теләсәгез алар белән бергә эшләргә мөмкин булыр,— диде һәм, мондагыларга карап, эш турысында сөйләп китте:

— Егетләр, кызурак кирәк... Баягынак та әйттем, хозяин телеграммасында әйтә: ике йөз кеше яллаган. Әстерхан казаклары, ди. Бик җитез халык, алар инде юлдалардыр. Озакламый җитәрләр чамасы; невод[1] сала башлагач, чаннар белән маташырга ярамас...

Бу шулай сөйләп торган арада, сары мыеклы бер эшче, яңа килгәннәрнең берсенә төбәп, шатланган тавыш белән:

— Әй, синме бу? Кайдан болай? Таныр хәл дә юк,— диде дә, нык кына кул кысышып, алар белән күреште.

Сүзен бетерергә өлгермәгән Исак, кинәт сүзе киселгәнгә оятлы булган төслерәк кәефсезләнсә дә, сиздерергә яхшысынмады, күрәсең, бер яңа килгәннәргә, бер сары мыеклыга күз йөртеп:

— Менә әйттем ич земляклар, танышлар тагын. Мин шулай ук белдем дә...— диде. Һәм шул көйгә сөйләнә-сөйләнә ишектән чыкты. Чыккач, тагын ишектән башын сузып:

— Менә шулай, иртән конторага кереп чыгарсыз,— диде.

Сары мыеклы егет:

— Ярар, ярар, керерләр,— диде һәм, теге ишекне япкач:

— Шылт итмә, егетләр, эшчегә пачут арта башлады, күрдең ничек чакыра, читкә җибәрәсе килми бит, хәзер кечкенә генә назлангаларга да ярый,— диде.

Берәү ялгап:

— Солдатка иртә саен чәй янына кайнар коймак требовать итсәк нишләр? Бирерләр бит? Булмаса, үзең эшлә, дияргә кирәк.

Икенче берсе:

— Варенье, яхшысын гына, каз ите, салкынга куйганны! Миколай белән икесенә, ха, ха, ха! — дип кешнәп җибәрде.

Миколай дигәннәре татарча яхшы белә иде. Ул өстәл өстендә чәчелеп яткан чүп-чар һәм икмәк валчыкларын кулы белән җиргә сыпырып җибәрде дә:

---

[1] *Невод* — җылым, балык тота торган зур ятьмә.

— Өйрәгә май сорарга кирәк, май, киндер мае, тоз да су, су да бәрәңге; ул бит эчәгеләрне генә бөрештерә, ә сез коймаклар да вареньелар белән саташасыз, эх сезне,— диде.

Сары мыеклы егет, аны аркасыннан сугып:

— Менә озакламый балык ашый башларбыз, балык! Бер дә кайгырма, Миколай Петрович, тешең генә түзсен! Балык булыр озакламый,— диде.

Аның исеме Хөснетдин иде, тик аны монда Солдат дип кенә йөртә иделәр.

Чын да, ул ике-өч ел гына элек солдатта булган икән. Әле дә аның кайсыбер кыйланышларында андагы манералар күренгәли иде. Ул, яңа килгән егетләрнең сумкаларын алып, сәкегә үз урыны янына урынлаштыргач, аларны мондагы иптәшләренә дә таныткан булды:

— Болар минем настоящий дус кешеләр. Петровскида без болар белән бервакыт дөнья куптарып тордык! — диде. Һәм кара күзле, матур кыяфәтлесен күрсәтеп:

— Әлеге, таза дип, мактап сөйләгән идем ич сезгә, Гариф исемле егет менә шушы егет инде ул! Сигезәр потлы капчыкларны уйнатып ала торган егет,— диде.

Солдат шулай дигәч, төрле яктан бу егеткә берничә күз төште, гүя сокланып карый иделәр.

Ул карарга да таза күренә, өсте-башы да иптәшенекеннән шомарак иде. Аның шактый эре башында арзанлы, бәйләгән бүрек белән өстендәге иске генә кышлык пальто да никтер килешле күренә иде.

Солдат аларның кайларда йөреп, кайдан монда килеп чыкканнарын сораша башлады. Ул арыган кыяфәттәрәк, бер терсәге белән өстәлгә таянып, янтайган килеш утырган, кыскалык белән өзеп-өзеп баштан үткәннәрен аңлата. Иптәше аның сүзләрен дөресләгән рәвештә баш ишарәсе генә ясаштырып утыра иде.

Алар көзен, Солдат белән аерылышкач, Дербендка килгәннәр. Дербендта бераз вакыт пристаньда эшләп, соңыннан Бакуга килгәннәр. Анда кыш буе нефтьтә эшләп, инде менә «балыкка» чыкканнар икән...

Ул сөйләгәндә башкалар күңел куеп тыңлый, аның авызына карап тора иделәр. Ул үзе дә тәмам үзсенгән рәвештә янындагы кешеләргә һәм баракның буена сузылган сәкегә күз йөртә иде. Үзсенерлек тә бар шул; менә алама-шалама сөйкемле генә

егетләр, һәммәсе дә үз кешеләр, әнә сәкедә түшәгән, җыйнак кына, риясыз гына аларның урыннары...

Җил юк, ышык. Ерак юл йөреп арыган өстеннән шушы иптәшләр арасында рәхәтләнеп йоклап китәргә генә.

Алар сөйләшеп торган арада аш килде. Аш әлеге — күптән түгел генә Николайның зарланганы — өйрә иде.

Буланып торган бәрәңге өйрәсен яңа килгән егетләр дә тәмле генә арыш икмәге белән яратып ашадылар. Тик туя торгач кына, гүя Николайның баягы сүзе исләренә төшеп: «Бу нәрсә эчәкләрне бөрештермиме икән?»— дигән сөаль белән зиһеннәре мәшгуль төсле күренә иде.

Аштан соң, кайсы кайда сузылып, тәмәке төтәтә башладылар. Барак эче махорка төтене белән тулып калды. Урта бер җирдә генә саргылт-кызыл якты биреп тора торган асмалы лампа кисәге болытлы һавада төнлә белән диңгез уртасында уйчан булып күренгән маяк утына охшый иде. Сәкегә сузылган кешеләр дә төтен дулкыннары астында диңгез мәхлуклары төсле күренә иделәр.

Шул арада ишектән дәү генә бер кеше килеп керде. Аның башында йончылган кара эшләпә, өстендә кыска гына иске соры чикмән, чикмәннең алгы чабулары ике якка ачылып киткән; күксел-кара күлмәгенең изүеннән йонлы күкрәге күренеп тора иде. Буе уртачадан озын булмас, тик иңбаш араларының киңлеге, кулбаш әгъзаларының эрелеге аны шактый дәү күрсәтә иделәр. Хосусән түгәрәкләнеп кырыккан чал сакалы, киң һәм кара тутлы йөзе белән ул төтен дулкыннары арасында әллә нинди «дию» кыяфәтендә булып күренә иде.

Кергәч тә карана-карана эчкә таба узды.

Сафа дигән егет өстәл җыештырып маташа иде.

— Менә әйткән идегез килмәс дип, әйдүк, Шәрәфи абзый! — диде. Теге эндәшмәгәч, тагын ялгады:

— Хәзер генә Исак сине эзләп йөридер иде. Җир тишегенәме кергән, һич табар хәл юк, ди, үзен!

Теге, карлыккан тавыш белән ашыкмыйча гына:

— Кашыкларыңны саташтырма, санап кына куй, дип әйтмәдемме? — диде.

— Юк шул, ансын әйтмәгән иде.

— Әнә иң кирәклесен әйтми калдырган!

Ул, яңа килгәннәрне күрмәгәнгә салышып, илтифатсыз гына:

— Солдат, шашкы уйныйбызмы? — диде.

Солдат гафу үтенгән сымак:

— Бик арыган идем шул, Шәрәфи абзый. Менә иптәшләрне дә сагынылган, серләшәбез әле үзләре белән...— диде.

Шәрәфи карт, боларны яңа гына күргән булып:

— Ә, якташлар, кайсы губерна? Ә өяз кайсы? Бәләбәй, диген... Авыл кайсы? Ярый...— диде дә бер аягына тайчанган көе, икенчесен алгарак җибәреп тәмәке урый башлады, тәмәке урагач, иреннәре белән чылатып ябыштырганда:

— Бәләбәйнең минем бер дус кеше бар иде. Хәер, мин үзем мишәр, Красный-Слабудский өяз... Ну шунда да...

Сафа янтыктан моның сүзен бүлде:

— Шәрәфи абзый, сүзеңне оныттырмыйм, Красный-Слабудка өязендә бер генә дә юньле кеше юк, диләр бит, һәммәсе дә ат караклары, ди!

Шәрәфи карт, аңар җавап бирмичә, сүзендә дәвам итеп:

— Хәер, авылныкы булгач, сез аны белмәссез, бик һәйбәт кеше иде,— Сафаны күрсәтеп,— әнә шундый агач авызларга күп лыгырдарга бирмидер иде ул; чалт иттереп авызга куя да җибәрә: чүплә инде аннан соң тешләреңне идән буеннан... Атаң белән тиңдәш кешене мыскылламассың икенчеләп,— диде.

Ул, сүзен әйтеп бетерү белән, Сафага шундый бер җиңгән кыяфәттә карады, гүя теге, чынлап та, идәнгә чәчелгән тешләрен чүпли иде.

Сафа оятлы булган кебегрәк:

— Юк, Шәрәфи абзый, мин бит тегеләй генә, мыскылларга Ходай сакласын... Болай мин кеше сүзен генә әйтәм... Син бәлки гомереңдә дә ат урлаганың юк; ә кеше сөйли ул! — дип, сүзне шаяруга сабыштырды.

Карт инде тынычланган тавыш белән:

— Өяздә чакта, энем, минем үземнең дә менә дигән атым бар иде,— диде.

— Бар өстенә бар — май өстенә бал, диләр; нәрсә генә булмасын, Красный-Слабудскийларны мактамыйлар, Шәрәфи абзый! Аның өчен ачуың килмәсен! — диде дә үзе шаркылдап көлеп җибәрде. Бу юлы башкалар да көлгәнгә күрә, карт үзе дә көлкегә кушылып, аптыраган кыяфәттәрәк бераз көлемсерәп торды.

Шул арада Солдат, Гарифны күрсәтеп:

— Менә бу егет монда калса, мин инде шашканы икегезгә тапшырам. Шәрәфи абзый, бу кеше, баксаң, сиңа да нужник[1] биргәләр,— диде.

Карт Гарифка кырын гына көлемсерәп карады.

— Менә күрерсең,— диде Солдат.

Монда эштән туктаган арада еш кына шашка уйнап маташа иделәр, әмма картка каршы уйнаучы юк иде. Башкаларга караганда Солдат яхшы уйный, ләкин Шәрәфи агай белән уйнаганда ул да һаман җиңелә иде.

Шәрәфи карт калын һәм тупас бармак араларында бик кыска калган тәмәке очын, актык мәртәбә бик тәмләп чытырдатып суыргач, җиргә ыргытты һәм, аны аягы белән басабаса:

— Калырга кирәк, нәрсә, иптәшләр яхшы... күңелле... Башка промыслоларга китеп тә нинди иптәшләргә очрарсың,— диде.

Сафа, Солдатка күз кысып:

— Бабаң яхшы партнерны читкә җибәрәсе килми ул! — диде.

Шәрәфи карт, аның сүзен ишетмәгәнгә салышып:

— Ярый, хушыгыз... Кайтып йоклап карыйк...— диде. Һәм салмак кына хәрәкәт белән ишеккә таба юнәлде. (...)

Ул чыккач, Солдат яңа килгән иптәшләренә аның кемлеге һәм монда нинди хезмәттә торганлыгы турында сөйләде; ул монда солильщик (сельдь тозлаучы) икән. Хәлбуки бу егетләр күргән башка бер промыслодагы шома итекле, байковый тужуркалы, ялтыравык козырекле картуз астыннан чыккан тип-тигез кисүле һәм майлаган чәчле солильщик белән бу «Красный-Слабудский» солильщик арасында тышкы яктан һичбер охшаш күренми иде: солильщик булгач, солильщик төсле булырга тиеш бит. Чөнки аның жалованьесы да гади эшчеләрнеке белән бертигез булмый, урыны да югарырак йөртелә. Әмма бу карт, бер ояга кунаклап, искергән мещаннарның искергән аяк киемнәрен иске күннәр белән ямап-йөрмәштереп утыручы «гакыллы сапожник»ка охшый.

Шулай Гарифның күңеленә килеп китте. Ләкин ник алай да ник болай дип сорашмады.

---

[1] *Нужник* — б и р е д ә: шашка уенында аерым пешкаларны ябып куюны аңлата.

Сүз мондагы эш җаена күчте. Солдат та, башка иптәшләре дә яңа килгән егетләрне мондагы эшкә кызыктыра һәм үзләре белән калырга димли иделәр. (...)

Тышта ай яктысы, көнчыгыш ягыннан йомшак кына салкын җил исә иде. Ерак-еракларга җәелеп киткән газамәтле[1] диңгез ай яктысында аклы-күкле ялтырап, очсыз-кырыйсыз нур һәм серле күләгәләр эчендә гүя күңелсез генә көлемсерәп ята иде... Аның кырыенда гына караңгы баракларда салам өстенә түшәлеп яткан адәм балалары күбрәк балык тотып, аена кырыгар сум акча эшләү өмете белән, һәм дә әллә кайларда, зиннәтле бүлмәләрдә йомшак түшәкләр өстендә сузылып яткан промысло хуҗалары шул ук балык хисабына кырыгар мең сум төшерү хыялы белән ләззәтләнеп төш күрә-күрә йоклаган чагында, табигатьнең матур һәм аңгыра мәхлуклары — балыклар — һичнәрсәдән хәбәрсез бертуктамый айга каршы сикерә, уйный иделәр...

КЫЗЫ ЧИБӘР ГЕНӘ

Алар конторадан чыкканда, томан сыекланган һәм дә диңгез ягыннан аксыл томан аркылы тонык кына нур чәчеп торган кояш шактый югары күтәрелгән иде. Һава кичәгегә караганда шәп иде. Җил юк, йомшак кына саф һәм ләззәтле бер салкынлык сулыш белән эчкә керә дә, бөтен тамырларга җәелеп, җанны рәхәтләндерә иде. Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайлардан ишетелгән шатлык шаркылдауларына охшый иделәр.

Бу өч иптәшнең рухлары шактый күтәренке иде. Солдат, кулы белән селтәп торып:

— Кара мартышкаларны, көлеп эчләре ката бит! Значет, балык аз булмас! — диде.

Гариф, Солдатның иңбашына кулын салып:

— Әй, картка нишлибез, керәбезме? Чәйгә чакырган иде ич,— диде.

Солдатның авызы ерылды, күзләре көлә иде.

— Сезне алып керергәме икән? — диде дә, күзләрен майландырып, Гариф белән Мусага алмаш-тилмәш карады. Тегеләр

---

[1] *Газамәт* — тантана, мәһабәт.

гүя бернәрсә дә аңламый иделәр. Ул Гарифны иңбашыннан этеп җибәрде дә:

— Газизәгә күзең төшмәсен, дим, жулик! — диде.

Гариф хәзер генә исенә төшкән шикелле:

— И, кызы бар дигән идең, чын да, менә юләр; әйтәм нәрсә сөйли бу! — диде.

Солдат, Мусага күз кысып:

— Бу нәгъләткә ышанырга ярамый, иптәш, исеңдәдер теге Марфа Петровна ничек кабартмалар белән сыйлый иде үзен,— диде.

— Ә, Петровскида, теге харчевня[1] тотучы хатын? Әйе шул...

— Без каткан күмәч белән чәй эчәбез, ә ул Марфа Петровна янында кабартмалар сыта!

Солдат бу сүзләрне әйткәндә, күзләрен почмакландырып, күбрәк мәгънә аңлатырга тырыша һәм тегеләргә алмаш-тилмәш карый, көлә иде.

— Үзе чакыргач, ник утырмаска соң, юләр! — диде Гариф.

— Әйтерсең лә мулла остабикәсе белән рәхәтләнә; без, мескеннәр, каткан күмәч ашап җаныбыз чыга, ә алар майлы кабартмалар сыталар! Ха-ха.

Муса да Солдатка кушылып көлеп җибәрде.

Гариф, аз гына көлемсерәп:

— Майлыларны диген, ә, юләр син, Солдат! Дөрес сүз икән ул, солдат кешедә төшкә кадәр бер дә акыл булмый имеш, тышта әле завтрак кына шул,— диде.

Кечкенә казарма алдында Шәрәфи карт үзе юк иде; кискәгә чабып куйган балтасы гына читтән караганда әллә нинди нечкә гәүдәле ерткыч кошка охшап күренә, тирә-ягында ап-ак йомычка кисәкләре чәчелеп ята иде.

Болар казарма ишегалдында тукталдылар.

— Шәрәфи абзый өйдәме? — дип, Солдат кычкырган иде, озакламый ук ишек ачылып, ишек арасында мөлаем генә бер кыз күренде:

— Ул хәзер генә лабазга дип чыккан иде,— диде.

Шулай дигәч, болар бер-берсенә карадылар.

Теге тагын ялгады:

— Әйдә керегез, Хөснетдин абый... Ул, хәзер кайтам, дип әйткән иде... Сезгә керергә кушты.

---

[1] *Харчевня* — ашханә.

Бу сүзләрне әйткәндә, ул инде ишегалдына чыкты. Күзләрен кояштан ышыклар өчен, бер кулын кашлары өстенә куеп, лабаз ягына карана иде. Гариф көнләшеп-көнләшеп: «Шул була инде күрәсең Газизә...» — дип уйлап алды. Үзенчә исе китмәгән гади һәм гөнаһсыз рәвештә тегеңәр күз төшергәли иде. Ул төсбаш күренеше белән шәһәрләрдәге урта катлаудан түбәнрәк татар гаиләләрендәге бер кыз иде; өстендә тубыктан югарырак торган иске генә аксыл ситсы күлмәк, аягында да каюлы һәм искерәк кенә кызыл читек белән ялтыравы беткән сары резинка галошлар иде. Аның аз гына кызгылт ак йөзе, кош борынына охшаулырак килешле борыны, уйчан кара күзләре дә бер караштa гади генә күренәләр. Гариф, аның күзенә туры карарга яхшысынмаганлыктан, авызына күз төшергәләде... Ләтыйф[1] гөл чәчәге кебек иреннәре гадәттән тыш матур иде. Ияк астына китереп бәйләгән простой күк сарфинка яулык та аңа ярыйсы гына килешә иде. «Калфак кисә, тагын да шәп буласы икән...» — дип, Гарифның күңеленә килде.

Алар берничә минут керергәме, кермәскәме дип икеләнеп торгач, картның үзе белән бергә килергә булып, керми киттеләр.

Лабазга җиткәндә, Солдат, Гарифның янтыгына төртеп:

— Ну, ничек? — диде.

— Нәрсә ничек?

— Газизә?

— Ә... Газизә зарарсыз. Чибәр генә.

Болар лабазга кергәндә, анда кычкырыш, шау-шу бара иде. Эре бөдрә чәчле, кызыл чырайлы, йөнтәс һәм таза гәүдәле Николай Шәрәфи картны, чикмән итәкләрен аркасына җыештырып, биленнән тоткан, арлы-бирле чайкап йөртә, башкалар читтән карап көлешә һәм кычкырышалар:

— Бирешмә, Шәрәфи абзый!

— Бәр таза гына! Күрсәт егетлегеңне!

— Җибәрмә, Миколай!

— Тот, Шәрәфи абзый.

Карт, тегене бер дә тотмыйча, кулларын ике якка җәйгән, бернәрсә эшли алмый, аптыранган, күзләрен кысып көлә.

— Җибәр, дим, зинһар, җибәр, Миколай, бәйләнмә, юләр, эшем бар, әнә карчык чакыра... Әнә Солдат килде, аның белән көрәш...— дип, Николайга инәлә.

[1] *Ләтыйф* — күңелгә ятышлы.

Николай аны ычкындыргачтын, ул йөдәп алҗыган хәлдә:

— Уф, тәмам хәлдән тайдырды, хәерсез! Нишләп анда азрак көтмәдегез, Солдат? Хәзер кайта идем бит... Йомыш белән генә килгән идем,— диде.

Шул арада Исак килеп керде.

— Ну, егетләр, кызурак тотыгыз, бүген бетерергә кирәк, иртәгә калмасын, кич белән неводчылар килә, иртәгә невод салырга булыр,— диде.

Шәрәфи карт:

— Ансы бетәр, Исак Моисеевич... Тик әле менә җылылар кирәк иде, кичә бит менә нинди салкын булды, хәерсез! Хәзер әле аларның (балыкларны әйтә) җыеннары унбиш чакрымнан да якын читкә сугылмыйлар... Бер чакрымлык неводны тик тартып азаплан!

Исак мөсәлләм[1] булмады.

— Юк, Шәрәфи Осипич, хәзер инде алар читкә сугыла, чөнки инде вакыт! — диде.

— Аларның календарьлары юк шул, җылы кирәк аларга, Исак Моисеевич.

Шәрәфи карт белән Исак шулай сүз көрәштереп, лабазның икенче башына, тоз өемнәре һәм буш мичкәләр тулган сарайга киттеләр. Шәрәфи агай бүген кичәге гакыллы сапожник кыяфәтендә үк түгел, башында кичәге эшләпә, өстендә печемсез чикмән булса да, күкрәк йоннары күренми; чикмән астыннан кыска камзул кигән, аягында да озын балтырлы шома гына итекләр иде. Гарифның күзенә ул бүген эшлекле генә бер агай булып күренә иде.

Солдат читтә торган бер ушатны[2] алып, нык кына иттереп җиргә куйды да:

— Әй егетләр, кунакларны бүген үк эшләтергә килешми дә инде... Ну тот әйдә, мәгъзум[3], назланып торма! — диде. Һәм ушатның ике як колакларыннан үткәрелгән нечкә арканны Гарифка тоттырып, үзе аягы белән ушатны чан эченә тибеп җибәрде.

Чан дигәннәре шушы бик зур лабаз эчендә уртадан юллар гына калдырып ясалган, төп һәм стеналары цементтан койган дүрт почмаклы зур гына базлардан гыйбарәт иде.

---

[1] *Мөсәлләм* — сүздә җиңелү.

[2] *Ушат* — агач чиләк *(диал.)*.

[3] *Мәгъзум* — мулла малае (мәхдүм).

— Менә мин түбәнтен тутырып бирермен,— диде Солдат,— сез тегендә, канауга чыгарып түгәрсез; анда күрерсез кая түгәләр...

Ул сәләмә пиджак җиңнәрен беләгенә таба җыештырды да чан эченә төшеп китте һәм, электән җайлап куйган такталарга басып, озын саплы лейка белән чалтырата-чалтырата, былтырда калып сасыган селедка суын ушатка тутыра башлады.

Базның эче өстән яхшылап күренми, караңгы иде. Тик Солдатның озын йонлы кавказ бүреге селкенеп торганы күренә дә, чалтыраган тавыш ишетелә. Һәм дә әчкелтем-төчкелтем сасыган балык исләре куерып чыга иде. Башка иптәшләре башка базларда шулай ук чалтырата, шундый ук исләр куерта иделәр.

ЧУАР ОЕКЛАР

Газизә иртән йокысыннан уянганда, һәрвакыт ишетелеп, колаклары күнегеп беткән калын һәм тонык аваз ишегалдында әйләндереп куйган таз өстенә су тамчылары төшкән шикелле гөмбердәп тора иде. Аз гына туктый, тагын гөмбердәп китә... Ул, чаршау аркылы әнкәсенең якында икәнлеген сизеп:

— Әткәй кем белән сөйли? — диде.

— Тор инде, балакаем, торырга вакыт... Кем белән сөйләсен — Мәкәйне (Мәһдине) станциягә җибәрә торгандыр...

Карчык соңгы сүзләрен бертөрле ризасызлык һәм рәнҗелгән тавыш белән әйтте. Газизә дә Мәкәйне станциягә җибәрүнең мәгънәсен аңлый иде. Шунлыктан аның йокыдан уянгандагы күңелле тойгылары шиңә куйды. Урыннан күңелсез генә торып, ләтыйф һәм җылы аякларына оек белән читекләрен тарта башлады. Чаршауның икенче ягында арлы-бирле йөреп торган әнкәсенең күләгәсе үк гәүдәләнгән кәефсезлек булып аның күзенә, бигрәк тә күңеленә чагылып тора иде.

Аналы-кызлы аларның монда беренче мәртәбә килүләре иде. Газизәнең бала чагында ук алар Саричинда торалар. Шәрәфи агай байтак еллардан бирле промыслочы еврейләрдә хезмәт итә. Берничә елдан бирле сельдь вакытында хуҗаларның шушы промыслосында ай ярымнар чамасы балык тозлау эшендә тора иде. Быел инде сельдь вакыты якынлашканда ук боларны да үзе белән алып баруын белдерде. «Үзегезне генә инде кемгә калдырасың... Далада булса да, ичмасам, үз янымда булырсыз...» — дип, аларга шәфкать күрсәтте. Вакыйган, быел

болай да күп хәсрәт тарткан бу кечкенә гаиләнең тагын аерылып таралуы хосусән ана белән кыз өчен түзүе читен һәм эч өзәрлек бер хәл иде.

Шуның өчен бабайның «ичмасам, үз янымда булырсыз» дигән сүзе ана белән кызның кайгылы күңелләренә азрак юаныч бирде. Әмма китәр вакыт җиткәч, далага сәфәр нияте белән төялеп чыкканда һәм үзләренең ярлы гына фатир ишегенә йозак салганда, ниһаять, извозчик: «Ну, әйдә, бисмилла!» — дип, атын кузгатып боларны пристаньга алып киткәндә, карчык эче өзелеп, үксеп-үксеп елады. Аның көз көне генә үлгән егет улы өчен булган хәсрәте яңадан кузгалган иде. Гүя аның бердәнбер сөйгән улы, элек вакытлар бай хезмәтеннән өйгә, әнкәсенең хәлен белергә кайтканы шикелле, хәзердә дә кайдандыр өйгә килә, ләкин ишек бикләгән була. Елап торган буш һәм күңелсез фатирның тәрәзәләреннән карый-карый да кире кайтып китә... Карчык шуларны күңеленә китереп үксеп-үксеп елый. Газизә аңар карап яшен тота алмый елый иде. Шунда да сәфәр дигән нәрсә яхшы: шатлыклының шатлыгына катнаша, хәсрәтлене дә төрлечә мәшгуль итеп хәсрәтен җиңеләйтә. Алар пароходка утыргач, еламый, сыктанмый гына килделәр. Монда килгәч тә картның дала дигәне аларга бик үк начар тәэсир бирмәде. Тирә-як саф комлык, бер якта очсыз-кырыйсыз җәелеп ялтырап яткан диңгез, икенче якта еракта матур газамәтле таулар, караган саен аларны күңеллеләндерә, рәхәт кенә моңландыра иде.

Тора торган урыннары да иркен һәм якты гына булып, шушы тирәдә үк кайнашкан «үз кешеләр» — татар егетләренең булуы да алар өчен күңелсез түгел иде. Шулай да дөньяның тынычсызлыгы дөнья хәтле, берсенең сөекле улы, икенчесенең иң якын күргән туганы өчен булган хәсрәтләренә караганда байтак җиңел, ләкин даими булган бер җан тынычсызлыклары бар; монда ул аларның эчләрендә әллә нинди бер уңайсыз җирне һаман әкренләп тырный, рәхәтсезләндерә иде. Ул исә картның шактый гына исерткечкә мөбтәлә[1] булуы. Аның аяктан егылырлык кадәр эчүе бик сирәк була. Ләкин акчасы була торып, тәмам аек йөрүе дә шулай ук еш булмыйдыр иде. Ул үзе аек чагында хатынына каты мөгамәләле түгел. Газизәгә шәфкатьле. Әмма исерек чагында тагын да йомшап китә,

---

[1] *Мөбтәлә (мөбтәля)* — дучар булучы.

шулай да, бердән, һәрвакыт акчага интегеп торуга карамый, эшләп тапкан юклы-барлы акчасын әрәм итүе, икенчедән, үзләренә бердәнбер арка таянычы булган өлкән кешенең даими төпле һәм ышанычлы хәлдә генә булуын чын күңелләре белән теләп торганда, шул кешенең кирле-мырлы сөйләнеп торучы бер юләр кыяфәтендә күренүе аларның җаннарын авырттыра иде.

Менә хәзер Газизәнең йокыдан уянгандагы матур тойгыларын җимергән Мәкәйне станциягә җибәрү әңгәмәсе дә шушы җан авырттыргыч мәсьәләнең бер кисәге иде. Шөйлә[1] ки, карт аракысы беткәннең иртәгесендә, күп үтсә берәр көннән соң, мотлак каравылчы дагстанлы кумыкны станциягә җибәрү чарасын күрә башлый. Хәзер аның аракысы беткәнгә ике көн бар иде.

Кечкенә һәм иске генә, ләкин үзләренеке булганга һәм дә күптәннән бирле күрә-күрә ияләшкәнгә, үзләренә сөйкемле генә күренә торган самавырны Газизә өстәлгә күтәргәндә, аталары килеп керде. Сәгыйдә апа, аның өстенә карамыйча гына: «Эшен рәтләгәндер, ахрысы, ничек яшь егетләрчә генә ишектән шома керә. Ишекне чалт иттереп кенә ябып куя!» — дип, күңеленнән кечкенә генә бер мыскыллау кичерде. Ләкин тышка чыгарып бер сүз дә әйтмәде. Чөнки барыбер, ни генә әйтсә дә, тегенең мең мәртәбә тәкрар иткән җавабын тагын бер мәртәбә тәкрарлатуга гына сәбәп булачагын белә иде. Ул теләсә яхшылап, теләсә ачуланып әйтсен, Шәрәфи агайның җавабы һаман бер:

— Юк, болай, аз гына... Әллә ник эч авырта төшеп тора, уңайрак булмасмы, дим...

Карчыгы теләсә нихәтле сүз озайтсын, ул артык җавап биреп маташмый инде, йә уйга калып эндәшми тора, яисә башка берәр сүз табып, моны артка калдырырга тырыша.

Кергәч тә ул сөйләнә башлады:

— Әрсез халык та соң! Неводчыларны әйтәм, йөз иллеләп кеше, хатыны-кызы бергә, бер казармада чукырдашалар, умарта кебек кайный, кайда ул чаршаулар да ниләр, кайда оят, кайда изәт[2]... Бер якта хатыны-кызы түшәлә, икенче якта ирләр аунап ята... Кичә кереп чыккан идем — кәмит инде менә!

---

[1] *Шөйлә* — шулай.

[2] *Изәт* — уңайсызлану.

— Хатыннары соң ни эшкә килгән? — диде Газизә.

— Алар, кызым, селедканы сорты белән сайлыйлар, бочонкаларга тезеп тутыралар. Анасы! Теләсә Газизә дә алар белән эшләр... Авыр түгел бит ул. Җыр, көй, уен, көлке арасында харап күңелле була! Тәмам шайтан туе ясыйлар.

Карчык әкрен генә:

— Ни булган эшләмәскә...— диде һәм, Газизә нәрсә әйтер дип көлемсерәп, сөйгән күзе белән аңа карады.

Газизә ачылып ук:

— Кешеләр эшләгәндә, ни эшләп мин тик торыйм! — диде.

Газизәнең күңелләнеп кенә биргән бу җавабыннан атасы белән анасы эчләреннән азрак сөенделәр. Анасының шунда ук: «Үзенә һәйбәт кенә берәр күлмәклек эшләсә, ни яхшы булыр!» — дип, күңеленнән кичте. «Әйе шул, өч күлмәк өстенә тагын бер яшелле-кызыллы матур гына бизәүле күлмәк...» — дип, бераз тәфсыйлга[1] да күңеле китте. Әмма атасының зиһене андый матурлык ягына авышмады, тупас кына: «Ары-бире расходка ярар ичмасам...» — дип, күңеленә килде.

Карт, ул мәсьәләне озайтмыйча, шулай гына калдырырга тиеш күреп, башка сүзгә китте.

— Эх,— диде.— Элекке куршик[2] яхшы кеше иде... Быел килмәгән, авылында калган, инде энесе аның урынында. Начар, әллә нинди төмсә нәрсә. Эх, теге чибәр кеше иде. Урыстан, татардан андыйлар сирәк очрый, анасы, тәмам үз кешең — туганың кебек ягыла иде.

Карчык, Газизәгә дигән кызыллы күлмәген күз алдына китереп уйлап торганда, картның әллә ниткән бер русны мактауларын, сагынып сөйләүләрен бер дә әһәмият биреп тыңламый. Эченнән: «Бергә эчкәнсез, шуңа күрә сүзегез дә килешкән булыр...» — ди иде.

Шәрәфи агай, бер чынаяк чәй эчкәч, тагын шуны ук башлады:

— Юк, ул әйбәт кеше иде... Әнә Газизәнең зәңгәр сарфинка яулыгы бар иде ич, былтыр алып кайткан идем... Аның бүләге ул, Петровскида аерылышкан чакта: мә, имеш, Шәрәфи Осипич, кызыңа миннән падарка булсын... Ни әйтергә кирәк, алмый ярамый бит, якынлык күрсәтә икән... Ярар, дим, Степан Федрич, дай бох сиңа добрый здоровие...

---

[1] *Тәфсыйл* — җентекләү.

[2] *Куршик* — невод (җылым) көймәсен турылаучы.

Газизә, аның сүзен бүлеп:

— Әткәй, син дә аның кызына берәр бүләк бирәсе идең,— диде.

— Аның кызы юк шул, ир балалары гына, шунда да хатынына дип бер пар чуар оеклар алып бирдем. Әлеге анаңныкы шикеллеләр иде. Икесен дә бергә алган идем.

Газизә, әнкәсенең аягына карап:

— Һәйбәт кенә иделәр яңа чакта,— диде.

Сәгыйдә апай да утырган җирендә бер аягын алгарак сузып, чуарлыгы уңып беткән төсмерсез оегына куанмыйчы гына карап:

— Бүләккә каршы бүләк бирмичә яхшы булмый инде... Яңа чакта бик матур иделәр, яратып кигән идем, бизәүле читеккә охшанкырый иделәр...— диде.

Чуар оекларның болай макталуына Шәрәфи агайның азрак кәефе дә килде. Чөнки моның белән үзенең бүләк алыш, бүләк биреш кебек «нечкә» эшләрдән дә хәбәрсез түгеллеге күренү өстенә, хатын-кыз әйбере ала белү турысында уңганлыгы да исбат ителә иде.

Ул, мыек астыннан аз гына көлемсерәп:

— Тагын шундыйларны алырмын, иншалла, аның моңардан чибәрләре бар әле! — диде.

Карчык юаш кына тавыш белән:

— Читекләр дә кирәк иде... Үземнекеләрнең киярлекләре дә калмаган. Газизәнекеләр дә искерә инде,— диде.

Газизә әнкәсенең колагына килеп шыпырт кына:

— Юк, әнкәй, миңа чуар оеклар белән шиблитлар[1],— диде.

Шәрәфи агай, Газизәнең сүзен ишетмичә, хатынына карап, салмак кына:

— Читекләрне инде, Алла боерса, бәйрәмгә таба алырбыз,— диде.

Ул чынаягын каплап чыгып киткәч, Газизә:

— Әнкәй, кайсы бәйрәмгә таба ул?— диде.

Карчык аз гына уйлап торды да, күңелсез генә иттереп:

— Белмим, кызым...— диде.

Бәйрәмнәр ерак иде әле...

---

[1] *Шиблит* — штиблет (аяк киеме).

Карт, кунакларына күзен кысып:

— Егет булмый ни? Син генә юләр бит, мине картсынган буласың! — диде,

Кечкенә генә, иске генә самавыр инде бик гайрәт белән өстәлдә булар пошкырып утыра. Китек-митек чынаяклар да «ләббәйкә»[1] дигән кебек, үзләренә чәй коелуны көтәләр. Карарак кына бодай күмәче телемнәре дә, ягымлы гына рәвештә тәлинкәгә өелеп, өстәлне күркәйтеп тора иделәр.

Карт, үзенең артыграк сүзгә бирелеп киткәнлеген сизеп алгач та:

— Йә, нишлибез, анасы? Үзеңме чәй ясыйсың? Газизә, кил, кызым, утырамсың? — диде.

— Минем әле азрак эшләрем бар иде, үзең генә башкара тор әле,— диде карчык.

Аның артык эше булмаса да, тик кенә эш табып маташа. Чөнки Газизәнең бергә утыруын килештерми, ялгызын гына читтә калдырырга да уңайсызлана иде. Самавыр капкачын өстәл янына алып килде дә, ду күчеп утырган кечкентәй самавырны каплый-каплый, үз-үзенә сөйләнгән кебек әкрен генә:

— Без хәзер генә аналы-кызлы эчкән идек, кунакларны яхшылап эчер... Ашка да җитегез, балакай, тарсынмый гына аша, эчегез,— диде.

Газизә, чаршау корылулы урынның бер кырыена утырып, өстәл янындагыларны читтән карап тора иде. Аның ягыннан өстәл лампасының яктысын самавыр ышыклаганга күрә, өстәл янындагыларга ул бик ачык күренми иде. Анасы килеп аның колагына шыпырт кына:

— Без соңрак эчәрбез, балакай,— диде.

Газизә баш ишарәсе белән генә риза булганлыгын аңлатты. (...)

Кунаклар кайтырга чыкканда, карт ишегалдына чаклы озата чыкты. Тышта караңгы, диңгез яктан салкын җил исә, йолдызлар, суыктан калтыранган балалар төсле, матур гына, күңелсез генә йомгаланып тетрәнеп тора иделәр. Диңгезнең, суык тидергән кәефсез карт кебек, әкрен генә уфылдаган, ыңгырашкан тавышы ишетелә иде.

Егетләр артыннан карт:

— Иртәгә шашка уйнарга килегез,— диде.

— Ярар, ярар,— дип, тегеләр караңгылыкта югалдылар.

---

[1] *Ләббәйкә* — боерыгыз, баш өсте.

Карт өйгә кергәч сөйләнә башлады:

— Әрәм булып йөри, юләр! Рабочий булып аю базында ят менә! Астында салам, өстендә ерык билле урыс пальтосы! Жалкы, мескен! Рәтле генә күренә үзе...

Карчык белән кызы картның кемне сөйләгәнлеген аңлый иделәр.

— Чынлап та, мулла улымыни? Ялганлый торгандыр,— диде карчык.

Карт кызыбрак китте.

— Ялганлый, ди! Солдат авылын атап сөйли бит! Күрше авыллар,— диде.

— Ата-анасы бармы, ди?

— Атасы үлгән шул... Шуны сөйләдек бит. Анасы бар икән.

Карт шулай дигәч хатыны йомшак кына тавыш белән:

— Мескен...— диде.

Газизә анасының кемне, егетнеме яисә анасынмы шулай кызганганлыгын беләсе килсә дә, сорарга базмады... атасыннан тартына иде. Шуның белән калды. Сүзне озайтмадылар. Шәрәфи агай үзе чишенеп тиз үк йокларга ятты. Болар да тавышсыз-тынсыз, күп вакыт үткәрмичә генә, чәй эчкәләп урыннарына үрләштеләр.

Байтак вакытлар Газизә юрган астында әйләнә-тулгана йоклый алмый ятты. Атасының чалган куй шикелле сулыш тартып-тартып хырылдап йоклавы, тыштан ишетелгән авыр-авыр диңгез уфылдаулары, караңгы өй эчендә әллә нинди моңсу бер аһәң белән очсыз-кырыйсыз дәрт һәм хыяллар көйли. Газизәнең зиһененә килеп күз алдында гәүдәләнгән сурәтләрне аллы-гөлле нур дулкыннары арасында тирбәтә иде... Әнә аның мәрхүм абзасы нурдан хөлләләр кигән, гөлләр, чәчәкләр арасында сәленә[1]... Әнә аның дусы Хөсәен аны эзләп килә... «Газизә җаным, мин сине сагындым!» — ди. Ләкин ул күп сөйләми, азрак көлемсерәп карый да югала... Ә менә бу «юләр» егетнең күзләре һаман Газизәдә. Газизә аның белән сөйли: «Исемең ничек соң, юләр егет, якташ та якташ дип йөртәләр сине... Нишләп синең күзләрең бу хәтле матур? Башкаларга син болай сөйгән күз белән карамый торгансыңдыр бит? Күк сарфинка яулык иясенә генә шулай карагансыңдыр? Чынлап та, син яхшы егет булсаң, мин сине яратыр, бәлки сөяр дә идем...» — ди. Менә ул тагын Газизәгә елмаеп карый... Менә

[1] *Сәленә* — таган атына.

Карт, кунакларына күзен кысып:

— Егет булмый ни? Син генә юләр бит, мине картсынган буласың! — диде,

Кечкенә генә, иске генә самавыр инде бик гайрәт белән өстәлдә булар пошкырып утыра. Китек-митек чынаяклар да «ләббәйкә»[1] дигән кебек, үзләренә чәй коелуны көтәләр. Карарак кына бодай күмәче телемнәре дә, ягымлы гына рәвештә тәлинкәгә өелеп, өстәлне күркәйтеп тора иделәр.

Карт, үзенең артыграк сүзгә бирелеп киткәнлеген сизеп алгач та:

— Йә, нишлибез, анасы? Үзеңме чәй ясыйсың? Газизә, кил, кызым, утырамсың? — диде.

— Минем әле азрак эшләрем бар иде, үзең генә башкара тор әле,— диде карчык.

Аның артык эше булмаса да, тик кенә эш табып маташа. Чөнки Газизәнең бергә утыруын килештерми, ялгызын гына читтә калдырырга да уңайсызлана иде. Самавыр капкачын өстәл янына алып килде дә, ду күчеп утырган кечкентәй самавырны каплый-каплый, үз-үзенә сөйләнгән кебек әкрен генә:

— Без хәзер генә аналы-кызлы эчкән идек, кунакларны яхшылап эчер... Ашка да җитегез, балакай, тарсынмый гына аша, эчегез,— диде.

Газизә, чаршау корылулы урынның бер кырыена утырып, өстәл янындагыларны читтән карап тора иде. Аның ягыннан өстәл лампасының яктысын самавыр ышыклаганга күрә, өстәл янындагыларга ул бик ачык күренми иде. Анасы килеп аның колагына шыпырт кына:

— Без соңрак эчәрбез, балакай,— диде.

Газизә баш ишарәсе белән генә риза булганлыгын аңлатты. (...)

Кунаклар кайтырга чыкканда, карт ишегалдына чаклы озата чыкты. Тышта караңгы, диңгез яктан салкын җил исә, йолдызлар, суыктан калтыранган балалар төсле, матур гына, күңелсез генә йомгаланып тетрәнеп тора иделәр. Диңгезнең, суык тидергән кәефсез карт кебек, әкрен генә уфылдаган, ыңгырашкан тавышы ишетелә иде.

Егетләр артыннан карт:

— Иртәгә шашка уйнарга килегез,— диде.

— Ярар, ярар,— дип, тегеләр караңгылыкта югалдылар.

---

[1] *Ләббәйкә* — боерыгыз, баш өсте.

Карт өйгә кергәч сөйләнә башлады:

— Әрәм булып йөри, юләр! Рабочий булып аю базында ят менә! Астында салам, өстендә ерык билле урыс пальтосы! Жалкы, мескен! Рәтле генә күренә үзе...

Карчык белән кызы картның кемне сөйләгәнлеген аңлый иделәр.

— Чынлап та, мулла улымыни? Ялганлый торгандыр,— диде карчык.

Карт кызыбрак китте.

— Ялганлый, ди! Солдат авылын атап сөйли бит! Күрше авыллар,— диде.

— Ата-анасы бармы, ди?

— Атасы үлгән шул... Шуны сөйләдек бит. Анасы бар икән.

Карт шулай дигәч хатыны йомшак кына тавыш белән:

— Мескен...— диде.

Газизә анасының кемне, егетнеме яисә анасынмы шулай кызганганлыгын беләсе килсә дә, сорарга базмады... атасыннан тартына иде. Шуның белән калды. Сүзне озайтмадылар. Шәрәфи агай үзе чишенеп тиз үк йокларга ятты. Болар да тавышсыз-тынсыз, күп вакыт үткәрмичә генә, чәй эчкәләп урыннарына үрләштеләр.

Байтак вакытлар Газизә юрган астында әйләнә-тулгана йоклый алмый ятты. Атасының чалган куй шикелле сулыш тартып-тартып хырылдап йоклавы, тыштан ишетелгән авыр-авыр диңгез уфылдаулары, караңгы өй эчендә әллә нинди моңсу бер аһәң белән очсыз-кырыйсыз дәрт һәм хыяллар көйли. Газизәнең зиһененә килеп күз алдында гәүдәләнгән сурәтләрне аллы-гөлле нур дулкыннары арасында тирбәтә иде... Әнә аның мәрхүм абзасы нурдан хөлләләр кигән, гөлләр, чәчәкләр арасында сәленә[1]... Әнә аның дусы Хөсәен аны эзләп килә... «Газизә җаным, мин сине сагындым!» — ди. Ләкин ул күп сөйләми, азрак көлемсерәп карый да югала... Ә менә бу «юләр» егетнең күзләре һаман Газизәдә. Газизә аның белән сөйли: «Исемең ничек соң, юләр егет, якташ та якташ дип йөртәләр сине... Нишләп синең күзләрең бу хәтле матур? Башкаларга син болай сөйгән күз белән карамый торгансыңдыр бит? Күк сарфинка яулык иясенә генә шулай карагансыңдыр? Чынлап та, син яхшы егет булсаң, мин сине яратыр, бәлки сөяр дә идем...» — ди. Менә ул тагын Газизәгә елмаеп карый... Менә

---

[1] *Сәленә* — таган атына.

Газизә аның кочагында... Алар баралар... Хыялда туган тылсымлы болытлар арасында тирбәлә-тирбәлә, егетнең туган иленә кайталар... Юк, ул егет юләр түгел. Син ялгыш сөйлисең, эткәсе! Әйе, ялгышып әйткәнсеңдер, ул юләр түгел, ул дөнья гизәргә чыккан, ул Газизәне эзләп килгәнгә охшый. Аны Газизә чакырган... Юк, юк, ул чакырмый гына, үзе эзләп килгән!

Төн урталары иде инде, Шәрәфи карт һаман авыр-авыр сулап хырылдый, ара-тирә йомшак кына ыңгыраша да, гүя сөйли: «Әйдә, йоклыйк инде, кызым, мин ялгышканмындыр, йоклыйк, бәбкәм, борчылмыйк, менә мин ничек йоклыйм... Йом, бәбкәм, күзләрең... Мин ялгышканмындыр... Ул юләр түгелдер. Менә шулай... Йом күзләрең... Йокла, җаным, борчылма!»

БУЛЫР ӘЛЕ

Башлап беренче мәртәбә невод салган көн иртәдән үк промыслода гадәттән тыш хәрәкәт, кайнашу башланды. Барактагы егетләрне дә Исак гадәттәгедән иртәрәк кузгатты. (...) Һава шактый салкын һәм болытлы. Кояш әле йә калыккан, йә калыкмаган иде. Лабазның аръягы буеннан ялпакланып[1] киткән комлыкта диңгез читенә якын ук неводчы казаклар җыелган иде. Аларның кайсылары җылыныр өчен шаярып сугыша, кайсы көрәшә, кайсылары йөгерешеп куыша иделәр. Тик кенә торып, невод салырга киткән көймәне карап торучылар да бар иде. Болар да халык янына килеп тукталдылар. Көймә читтән бер чакрым чамасы эчтә булганлыктан, андагы кешеләрнең нишләгәнлекләре аермачык күренми, тик анда биш-алты кешенең кырмыскалар кебек хәрәкәтләнеп, казынып торганлыклары гына күренә иде.

Гарифның промыслода эшләгәне юк иде. Әлегә хәтле колак алкасы кебек кечкенә кармак яки өч-биш саженьлы[2] бредниктан[3] башка кораллар белән балык тотканны күрмәгәнлектән, мондагы эшләр аңа шактый сәер тоела иде. Менә инде лабазда аның гаҗәпләнеп караган һәм кечкенәрәк авылны чорнап алырлык дип уйлаган биш йөз саженьлык неводны көймәдәге кырмыскалар диңгезгә ыргыта киләләр...

---

[1] *Ялпакланып* — кыйшаеп, янтаеп.

[2] *Сажень* — озынлык үлчәве берәмлеге, 2,13 м чамасы.

[3] *Бредник (бредень)* — ятьмә, сөрәкә.

Исак, Шәрәфи агай, бухгалтер һәм тагын әллә нинди кара тутлы бер кеше бергә җыйналып, лабаз ягыннан халык ягына килеп чыктылар. Дүртәү сөйләшеп торган егетләрне күрү белән, Исак, бик эшчән кыяфәттә алар янына килеп, Гарифка:

— Ну, господин артельщик, кайда башка иптәшләрегез? Кайда алар? Лямкаларыгыз да юк, ах сез, болай ярамый бит, болай мөмкин түгел бит! — диде.

— Әнә киләләр! — диде Солдат.

Чын да, тегеләр барактан чыгып ашыкмыйча гына бире таба килә иделәр.

Исак болар яныннан борылгач та, Сафа Гарифка:

— Артельщик булуын булдың, якташ... Инде бу усал җен сиңа гына бәйләнергә тора,— диде.

Солдат, Гарифны аркасыннан кагып:

— Ничава, иптәш, берни эшләтә алмас, каушама гына! — диде. Һәм җитди генә иттереп ялгады:— Шулай да, егетләр, үзебез өчен дә эшне дружнорак тоткан яхшы... Этнең өреп торуы беренә дә салават түгел...

Николай болар янына килеп туктады да, башын кашып торып:

— Солдат ниндидер манифест укыйдыр, ахрысы; равнение-фәлән юкмы? Хәзер Россиягә кайтабыз, андый эш булса, берәм-берәм боярларны тотып кыйна, анасын янтыгы! — диде.

Сафа ярым җитди, ярым шаярып аңар бәйләнде:

— Лыгырдама инде, пожалысты! Ялкау аю кебек ятып торасың-торасың да әллә ниткән манифестлар белән җенләнәсең, башкалар сиңа ияреп чыкмыйлар. Күрмәдең монда артельщикны ничек кыздыралар!

— Ничава! Артельщик булгач, безне дә шулай кыздырырлар. Зато артельщик. Шулай бит, господин артельщик?

Гариф та шаярып:

— Ну, канечно! — диде.

Гариф үзенең артельщик булып китүенә аптырый һәм көләсе килә иде. Эш болай булды: бер-ике көн элек Исак аларга үз араларыннан бер кешене артельщик итеп билгеләргә кушкан иде. Кладовойдан алган заборларын[1] яза барырга һәм үз араларында тәртип карарга бер кеше кирәк, имеш... Солдатның Гарифны укымышлыгы белән мактаулары аркасында,

---

[1] *Забор* — б и р е д ә: бурычка алып тору.

беравыздан аны артельщик итеп сайлаганнар иде. Шушы берике көн арасында аңар кладовой дәфтәреннән элекке заборларны күчереп, яңадан алына барган махорка һәм шырпыларны теркәп кую кебек җиңел эшләр, ягъни артельщикның ак хезмәтләре генә тигән иде. Инде менә бүген иптәшләренә башлык кылуы да таләп ителә башлагач, ул шактый уңайсызлык хис итте.

Мондагы эшнең рәтен белми бит ул, үзеңнән күп белгәннәргә башлык сөр, имеш!

Хәйрулла белән Сафа лабаздан лямкалар алып килгәндә көймәдән арканны кырыйга ыргыткан иделәр инде. Тула штанлы, күн чабаталы казаклар, кырмыскалар кебек, аркан буенча тезелделәр. Безнең егетләр дә арада иделәр. (...)

Кырыйга якынлаша торган невод өстендә, көмешле йомычкалар төсле, ак балыклар бер туктамый ялт та йолт сикереп маташалар, гүя үзләренең тоз эчендә һәлак буласыларын белеп, кырыйга чыгарга теләми, неводтан ычкынырга тырышалар... Очы-кырые күренми җәелеп яткан матур диңгез өстендә әллә нихәтле акчарлаклар, өермәгә эләккән яфраклар төсле, буталып очыналар һәм акылдан шашкан кешечә эчләре катып көлгән яисә үчегеп ярсыган шикелле гыйгылдап йөрәкләрне кытыкландыралар. Әллә алар шушы сәләмә кешеләрнең дә аларның үзләре кебек оча алмауларыннан һәм тамаклары өчен борыннары белән җиргә абынып тырмалуларыннан көләләр, әллә болар балыкны бетерәләр дип көнләшә һәм үчегеп елыйлар...

Берзаман Исак бар көче белән:

— Уң як, акрын! Сул як, кызу тарт! — дип акырды. Ләкин халык, шау-шу белән аның сүзенә илтифат итмичә, «амбарны» кыйшайган көе сөйри бирделәр...

Башлангыч шәп булмады. Шулай да бөтенләй үк буш түгел иде. Биш-алты тачка йомычка балык, сельдь, унбиш-егермеләп биреш, эре генә өч сазан чыкты.

Ике вагонлык чан төбенә егерме-егерме биш пот балыкны сибеп салгач, Шәрәфи агай үзенең кыска саплы матур көрәген ак кар кебек тоз эченә бик оста гына чумырып торып, берничә мәртәбә чәчеп җибәрде.

— Хәере белән булсын! — диде.

Исак, борынын мышкылдатып, күңелсез генә:

— Бер дә рәт күренми әле...— диде.

Шәрәфи карт тыныч кына:

— Әле вакыт бар...— диде.

Җавап бирүче булмагач, тагын өстәде:

— Ни булса да унбишеннән соң була инде... Әмма су артык салкын түгел, булыр әле...

Шәрәфи картның авызына карап, тачкачылардан да кайсыберләре авыз эченнән аның соңгы сүзен тәкрарладылар:

— Булыр әле...

ЕГЕТ ЕЛЫЙ

...Беркөн төш алдында, беренче неводны чыгаргач, нык кына җил кузгалды. Көн иртәдән бирле болытлы булып, инде диңгездә давыл булырга охшый иде, шунлыктан барактагы егетләр, бүген инде икенче мәртәбә невод салынмас дип уйлап, төш ашыннан соң кайсы йокларга ятты, кайсылары шашка уйнарга тотындылар.

Бервакыт Исак барак ишеген ачты да аптыраган тавыш белән киреле-соңлы җикеренергә тотынды:

— Чыгыгыз, әйдә тизрәк! Неводка әйдә! Аркан ычкынган! Неводка тизрәк! Неводка, дим! Уят шуларны!.. Тизрәк әйдә!.. Давыл кузгалды!

Ул ишекне япмыйча ук тавышлый-тавышлый китеп барды. Сафа белән Хәйрулла шашка уйнап утыра иделәр.

— Аптырадыңмыни, шайтан! — диде Сафа.— Давыл кузгалса, невод салдырмыйлар аны! Бәдбәхет!

Гариф өч-дүрт иптәше белән алдан китте. Башкалар да, кискен җилгә ян биребрәк, бөкрәйгән көе, тегеләр артына ялганган иделәр. Лабаз артыннан әйләнеп үткәч, кинәт бик газамәтле күренеш алдына чыктылар. Диңгез кузгалган... Күз күременчә зур су түтәлләре, ак күбекләр пошкырып, бер-берсен куа киләләр. Күктә каралҗым болытлар ага, диңгез артларын соры томан каплаган...

Солдат кычкырып җибәрде:

— Их-хи! Карагыз, көймәне кайда илтеп ташлаган!

Сафа алга карады да, күтәренке тавыш белән:

— Неводны харап итә, егетләр! — диде. Һәм үзе, Николайны иңсәсеннән этеп, сикерә-сикерә йөгереп, неводчылар җыелган җиргә китте. Вал янында һичкем юк, неводчылар гадәттә невод чыга торган урыннан йөз илле саженьнар чамасы ерак киткәннәр иде.

Сафа артыннан башкалар да йөгерешеп киттеләр. Тик Николай белән Хәйрулла гына, кешегә иярмәгән булып, бер үк

көйгә, йөгермичә генә, селкенә-селкенә бардылар. Азрак баргачтын, алар да юыртып киттеләр.

Неводчылар янына иң элек барып җитүчеләр Сафа белән Гариф булды. Исак белән Шәрәфи агай һәм Абрам да анда иделәр. Гадәттән тыш аптырау, кычкырыш бара иде. Читтән биш-алты саженьлап эчтә невод көймәсе әллә ничә уңайга бәргәләнеп, чайкалып тора, көймәдә биш-алты кеше — невод салучылар — йомычка кисәгенә ябышкан булдыксыз һәм кызганыч тараканнар шикелле аумаска, ычкынып китмәскә тырыша иделәр. Ухылдап торып килгән дулкыннар бер бәреп, көймәне югары сикертә, кире кайтып, комга утыртып куя, тагын бәрә дә тагын сикертеп җибәрә... Койрыктагы куршик, бер кулы белән руль тоткасына ябышып, аяктан егылмаска тырыша, икенчесен бутап-бутап бар көче белән кычкыра, кемнедер сүгә. Монда Исак үзалдына акылдан сапкан кешечә җикеренеп йөри, кеше саен бәйләнә.

Гариф, Шәрәфи карт янына барып:

— Нәрсә ул, ни булган? — диде. Теге салкын кан белән генә:

— Арканны ычкындырганнар, куршик тагын дүрт ишкәкче сорый, баручы юк! Эт эткә, эт койрыкка җибәрә...— диде.

Гариф кинәт, кирәкле хәбәр ишеткән төсле, күзләрен уйнатып:

— Мин барам! — диде. Һәм сикереп үк су янына йөгерде. Шәрәфи агай ашыгып ук:

— Тукта әле,— дисә дә, тегеңәр ишеттерә алмый калды. Артыннан барып тотарга кешеләрдән яхшысынмады. Шулай да акрынлап барып, кешегә сиздермичә, тегенең чабуыннан тарту нияте белән урыныннан кузгалып, тегеңәр юнәлгән иде, ни күрсен: дулкын эчкә кайткан арада, Гариф сикереп торып көймәгә ташланды һәм көймәнең читенә барып асылынды... Көймәдәгеләр аны тартып алырга маташканда, тагын килеп дулкын бәрде дә Гарифны муеннан ук эләктерде; шулай да ычкындырмыйча, аны көймәгә тартып алдылар. Аңар иярүчеләр дә тиз табылды, бер-бер артлы өч кеше, шундый ук маневрлар ясап, көймәгә керделәр. Җансыз сөяк кебек чайкалып торган шактый зур көймә кирәкле кешеләрен алгач та җанланды; өч пар ишкәкне алты кеше бер уңайга күтәреп сала башлагач, ул, килешсез кара бер җанвар кебек, дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп китте. Ул, читтән ераклашкан саен,

көчсез һәм кызганычрак күренә, гүя хәзер батарга, югалырга тора иде. Бераздан соң бер батып, бер калкып уйнаган кармак калкавычы рәвешендә генә күренә башлады.

Җил улый, сызгыра, диңгез һаман дулкынлана, дулый бара иде.

Исак белән Абрам халыктан читтәрәк йөреп торалар, неводчылар, бергәрәк җыйналып, шау-шусыз гына карап торалар, диңгез дулкыннары арасында бата-чума күренеп барган иптәшләрен күздән югалтмаска тырышалар. Гарифның иптәшләре дә аптыранып Шәрәфи агай янына җыелышканнар, аның авызына карыйлар, ул акрын гына Исакны сүгә:

— Кабахәт нәрсә, хәерсез! Ничек буласы төш вакытында ук билгеле иде бит. Кирәкми, дим, невод салдырма, давыл күтәрелә... Юк, тыңламый бит, шайтан! Менә хәзер дә аркан ычкынган икән, бер яктан гына тарттырасы, ярты сәгатьтә эше бетә! Исак Моисеевич, дим, шулай гына итик! Юк, имеш, алай невод ишелеп, чуалып бетәр... Невод чуала дип, кешеләрне күрәләтә батарга җибәрә, мәлгунь!

Ул, бераз туктап торгач, көлгәнрәк тавыш белән:

— Ул, йөзе кара, шушы минутта да балык өчен тырмана, невод чуалуы сылтау гына... Бер яктан тартып невод бер дә чуалмый... Аны ул үзе дә белә... Тик әле балык килеп тыгылмасмы дип уйлый! Ну әле аңар иртәрәк шул,— диде.

— Балык булса соң, аңар нәрсә? — диде Солдат.

— Аңармы нәрсә? Пае[1] бар ич, юккамы шулхәтле тырыша дип беләсең? Ул үзе өчен тырмана, господин унтер. Менә элекке куршикны җибәреп карар идең шундый җәһәннәмгә, «пошел ты к чорту» дип кенә җибәрер иде үзен! Монысы бозау шул, хәерсез... Үзенең иптәшләренә бугазын ертканчы акыра да хуҗага яхшы күренә, имеш, дурак касалапый! Гариф тагы нәрсәгәдер юләрләнеп китте. Минем аңар ачуым килә! Тотып та өлгерә алмадым, ичмасам...

Сафаның көләч йөзе үзгәргән, уйчан һәм кайгылы төс алган иде, ул кинәт кенә:

— Батарлар микәнни? — диде.

— Ходай язмасын, батмасыннар иде дә... Әнә карагыз, нишләтә көймәне! Рулевой авызын ачмаса, шулай да котылырлар... Инде авыз беләнрәк караса — бетте диген! Борылганда

---

[1] *Пай* — өлеш.

дулкын буена калып, шомарак әйләнмәделәрме — бәрә дә каплый! Шома маташканда бу давыл гына әле ул хәтле куркынычлы түгел...

Николай, руслар арасыннан аерылып, болар янына килеп туктады һәм Исак белән Абрамга таба карап алды да, нык кычкырмыйча гына:

— Дурак безнең артельщик,— диде.— Ул төшмәсә, тегеләр берсе дә төшәселәр түгел икән...

Ул, тавышын тагын да акрынайтып:

— Беләсез, тегеләр нәрсә ди... Әгәр көймә кайтмаса, әнә теге ике господинны буып суга ташламакчы булалар,— диде.

Шәрәфи агай, әкрен генә борылып, тегеләр ягына карады да, бик читен бер мәсьәлә турысында уйларга керешкән төсле иттереп:

— Эһем...— дип, алдына карады.

Солдат Николайга:

— Һәммәбезгә дә каторга ич ул чагында...— диде.

Николай, җавап бирмичә, иңбашларын гына тартты.

Шәрәфи агай, җилгә каршы торып, яшьләнгән күзләрен кул аркасы белән сөртеп, бераз вакыт алга таба карап торгач:

— Кайтырлар, Алла боерса... Инде борылганнар да бугай... Карагызчы яхшылап,— диде.

Еракта, дулкыннар арасында, бер югалып, бер калкып торган көймә һаман да бер урында төсле күренә, кырыйга елышканлыгы да, эчкә таба китеп барганлыгы да күренми иде. Шәрәфи карт аның кире борылганын болай чамалап кына әйткән иде, күрәсең.

Байтак вакыт шулай тынычсызланып торганнан соң, кешеләргә җан керә башлады: көймә кайтып килә иде. Көймә һәм көймәдәгеләр тере күренәләр, юлны кыеграк тотып, лабазга таба чыгарга азаплана иделәр.

Инде Шәрәфи агайның да чырае ачылды:

— Маладец, Әндрюша! — дип, койрыкчыны мактап куйды.

Көймә һаман якынлый иде; ул тискәре һәм усалланган дулкыннар белән җан-фәрманга көрәшеп килә; бер дулкын сыртыннан алга сикереп киткәндә, икенчесе бәреп аны артка чигерә, ул тагын алга үрмәли, тагын сыртка күтәрелә, тагын сикерә, тагын үрмәли иде...

Шәрәфи карт, баскан җирендә тора алмый кулларын уыштырып:

— Ризамын, егетләр! Шулай кирәк! Юләр бул да егет бул! Батып калсагыз, сугәр идем, инде афәрин, шайтан икәнсез! — дип сөйләнә-сөйләнә йөри иде.

Хәзер инде көймә булдыксыз, кызганыч ябалак кебек түгел, йөрәкле карчыга шикелле матур һәм сөйкемле күренә иде. Көймәдәге егетләр дә көчсез һәм йомшак тараканга түгел, гайрәтле үткен кырмыскаларга охшый иделәр.

Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә, калкынып ук, көтеп торган халык алдына килеп, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады. Арттан килгән дулкыннар да инде аны кузгатып ала алмый иделәр...

Исак, аларның күңелләрен күтәрер өчен:

— Молодцы, ребята! — дип кычкырган булды. Ләкин аңар әһәмият бирүче булмады; тавышын ук яратмый иделәр... Халыкның бер өлеше тиз-тиз генә көймәне корыга сөйри башлады, бер өлеше валга йөгерделәр. Тачкачылар Гарифны урап алганнар иде. Ул утырып итекләренә тулган суларны түккәч, Шәрәфи агай, аны читкәрәк тартып:

— Күлмәк-ыштан бармы? Тиз генә барып алмаштыр... Булмаса, мин бирим... Бездән барып ал...— диде.

Гариф оялган сыман көлемсерәде:

— Бар, Шәрәфи абзый, үземдә бар, борчылмагыз, зинһар...— диде.

— Ну, бар, тиз генә алмаштыр да безгә кил, ишетәмсең, йомыш бар... Йөгер инде, әйдә, тиле.

Николай чын эч фикере белән:

— Аңарга хәзер берәр чарка аракы кирәк иде. Юкса, шиксез, бизгәк эләктерә! Исак ул коры теле белән генә мактаган була, хәерсез! — диде.

Гариф көймәдә бертуктамый көч биреп ишкәнгә күрә кызган иде. Көймәдән төшкәч тә ул кадәр салкынлык хис итмәде. Әмма баракка килеп кергәч, баракның бушлыгы, шакшылыгы, нар буена җәйгән салам урыннар, озын такта өстәл буенда чәчелеп яткан чүп һәм икмәк валчыклары, нәкъ уртада асылынып торган иске лампа, диңгезгә караган бер генә тәрәзә, әлхасыйль[1], баракның барлык эч күренеше гүя аның йөрәгенә боз булып утырдылар. Ул калтырана, туңа башлады. Бигрәк тә

[1] *Әлхасыйль* — кыскасы, җыеп әйткәндә.

тәрәзәнең бозылган бер күзеннән улап кергән җил тавышы белән бергә тонык һәм тирәннән гөжләп килгән дулкын тавышлары, аның эчен чымырдатып, чәчләрен терпәйттерә иделәр. Ул, коры күлмәкләр киеп алгач, Солдатның баш очындагы запас чолгауларын һәм дә үзенең, иске генә булса да, коры һәм йомшак пальтосын бик зур рәхмәт хисе белән, әүвәлгеләрне итек астыннан, соңгыны күлмәк өстеннән эшкә кертте. Һәм дә тиз үк Шәрәфи агайның җылы һәм уңайлы өен күңеленә китерде.

Ул барактан чыккач, үткен җил улавы арасыннан диңгез гөрләүләре белән бергә неводчыларның һай-һу тавышлары ишетелеп, аның күңелен әллә нишләтеп, борчып җибәрделәр; кешеләр ду килеп акыра-бакыра вал әйләнәсендә йөгергәндә, диңгез «чылбырдан котылган аждаһа» кебек котырганнан-котыра барганда, ул ялгыз гына, хәстә кеше кебек, пальтога төренеп йөрсен, имеш...

Бара-бара җилгә янтыгы белән әйләнеп көлемсерәде дә якыннан барган бер иптәшенә сөйләгән кебек: «Бабай һәйбәт кеше безнең... Теләсәң күлмәк-ыштан да киертә! Эх, бабай, бабай, күп яшә!» — диде. Ул бер исәп белән туры неводчылар янына китәргә дип тә уйлаган иде, ләкин картның чакыруын илтифатсыз калдырырга уңайсызланды.

Бу ишектән керүгә, Шәрәфи агай, кадерле бер кунак көткән кебек, каршы ук алды.

— Әйдә, Гариф, әйдүк, туган,— диде.

Газизә бер читтәрәк нәрсәдер тегү, чәнчү белән утыра. Карчык анасы самавыр куеп маташа иде. Шәрәфи агай аларга бүгенге эш буенча да Гарифның юләр егетлеген сөйләгән,— ул ишектән кергәч тә, гүя көтүдән адашкан тәкә кайтып кергән кебек булды. Карчык белән Газизә аңа гаҗәпләнгән сымак көлемсерәп карадылар. Гариф бераз кызарынды. Өстәлдә ярты савыт аракы, бер чәй чынаягы утыра иде. Гариф утырмас борын ук Шәрәфи агай бәрәкәтле генә иттереп чынаякны тутырып куйды да, җитди генә чырай белән:

— Әйдә, эчеп җибәр шуны! — диде.

Гариф, аның күзенә карап, аптыраган сымак:

— Юк, Шәрәфи абзый, мин бит ул нәрсәне эчми идем,— диде.

Ул ялганлады, электән эчкәли иде. Әмма хәзер хатын-кыз алдында уңайсызланды. Аларның яхшы карашларын сындырырга теләми иде.

Карт, эшлекле кыяфәтен бозмыйча гына, чынаякны моның борын төбенә үк сузып:

— Дару өчен, юләр! Юкса хәзер бизгәк эләктерерсең... Эчеп җибәр, җылынып китәрсең,— дип, бик кыска бәйләнде. Шулай да Гариф тагын бераз сатулашмыйча эчәргә яхшысынмады:

— Юк, Шәрәфи абзый, миннән булмый...— диде. Карчыкка карап: — Бер дә эчкәнем юк иде шул, апай! Ничек итеп эчәсең аны!..— диде.

Карчык чын эч фикере белән:

— Шулай шул, балакай, яхшылар эше түгел инде... — диде.

Карчык сүз кушкан арада, чынаяк Шәрәфи агайның үз иреннәре арасында бушатыла иде. Ул, тиз генә тозга басып, икмәк катысы капты да, хатынына әйләнеп:

— Зарурый бит бу, юләр! Бизгәк эләктерсә яхшымы булыр? Шушы салкында муеныннан суга чумды бит ул! Бир әле монда борыч савытын... Бераз борычлап җибәрик!.. — диде.

Газизә, тиз генә торып, борыч савытын табып китерде. Карчык нәрсәгәдер өстәлгә бер чәй кашыгы китереп куйды.

— Кашыкның кирәге дә юк... Без аны болай гына эшлибез...— дип сөйләнә-сөйләнә Шәрәфи агай элек чынаяк төбенә бераз борыч сипте, аннан соң аракы салды.

Гариф, көләсе килеп, эченнән: «Җыйнаулашып дарулагач, инде карышып торырга килешмәс»,— дип уйлады. Алар әле Шәрәфи карт белән икесе дә утырмаганнар; өстәл янында торып аяк өстендә генә сатулаша иделәр. Бу юлы инде Шәрәфи агай, эшне пешкәнгә санап, чынаякны сузды һәм, катгый иттереп:

— Тот әйдә, шифасы белән! — диде. Үзе утырып, бер карт доктор клиентына караган төсле, Гарифка күз текте.

— Менә шулай! Башка вакытта эчмә, кирәге юк! Инде зарурый булгач, Ходай үзе дә кичерсә кирәк, вәссәлам!—диде.

Гариф эчкәчтен чыраен сытып, күзләрен кыскалап, йөзен каплаган булып кыланган арада, карт, кемнең дә кыставын көтмичә, тагын бер чынаяк эчеп алды. Һәм шешә төбендәге барлык аракыны бушатып, тагын Гарифка сузды. Гариф та, сандык өстенә утырып, бу юлы инде борычларга-ниләргә дә эшне терәмәде.

— Менә шулай,— диде карт,— бизгәк ул кабахәт нәрсә, Ходай сакласын, бер эләктереп алдымы, тиз генә җибәреп

булмый аны! Монда бит Раси[1] түгел... Диңгез ул кабахәт! Менә мин үзем дә әллә кайчаннан бирле эч белән азапланам... Нишләмәк кирәк, бер-ике йотым нитәсең дә, аз гына уңайланган шикелле була... Ә син юеш киемнәреңне нишләттең? Баракта? Юк, алай ташларга ярамый, анда кипми ич алар, ичмасам кухняга элеп куярга кирәк, әйбәтләп кипсеннәр...

Гариф урыныннан торды.

— Син чыгасыңмы, Шәрәфи абзый? — диде.

— Чыгып карарга кирәк...

Карчык йомшак кына тавыш белән:

— Чәй эчмисезмени? — диде.

— Юк инде, Гариф барып ятсын,— диде карт.— Минем дә эшем баррак, үзегез генә инде әйбәтләп эчәрсез... Чикмәнне генә бир дә, без чыгыйк.

Ишегалдына чыккач, Шәрәфи агай чикмәнне Гарифка тоттырды.

— Бар, әйбәтләп кенә төренеп ят! Кичрәк Солдат белән икәү чәйгә килерсез,— диде.

— Юк, мин инде җылындым, тегендә бармакчы идем...

— Анда синең кирәгең юк, во-первых, и сиңа хәзер җил дә ярамый... Бар да әйбәтләп кенә төренеп ят! Менә ансы шифага булыр!..

Гариф карышмады, тагын баракка китте.

Барак тагын шулай ук ямьсез, кызганыч, буш көе тора. Ватылган тәрәзә күзеннән һаман да шулай җил ыжгыра. Җил улаган арада әллә кайлардан гөрләп килгән тонык һәм көчле дулкын тавышлары ишетелә иде. Аның зиһене чуалмаса да, буын һәм әгъзаларында ул шактый какшау һәм калтыранганлык сизә иде. Солдатның иске шинелен салам өстенә салып, үзенең пальто кисәге һәм картның чикмәне белән баштан ук ябынып ятты. Яткач та бик арыган кешенең йомшак һәм уңайлы урынга сузылганда хис итә торган бер рәхәтлек тойгысы аның күңелен тутырды. Гүя әллә нинди бик килешсез бер эш, төзәтүе мөмкин булмаган бер хатасы барлык зиһененә килеп, кинәт борчыла башлады. Газизәнең җитди генә чырай белән өстәлгә борыч савыты куйганлыгын, карчыкның чәй кашыгы алып килгәнлеген күз алдына китерде... Алар шул чагында нәрсә уйладылар икән? Гарифның юри генә рияланганын әлбәттә сизгәннәр булыр. Инде карчык каршында аның

[1] *Раси* — Россия.

«балакайлык» мәхәббәте, Газизә каршында «Гариф абзый»лык хөрмәте бөтенләйгә югалгандыр шул...

Көн әле бик кич булмаса да, Гарифка төн кебек тоела иде. Ул чикмәнгә бик нык төренгәнгә күрә, тәрәзәдә улаган җил һәм дулкын гөрләүләре аермачык ишетелми. Тик әллә кайсы почмакта, гүя әллә кем акрын тавыш белән ярсуланып-ярсуланып бертуктамый елый иде... Аһ, мескен, кем соң син?.. Гарифның әнкәсе генә шулай елый иде... Әнә аның әткәсе — кара күзле, таза гәүдәле, исерткечкә мөбтәлә[1] мулла... Ул балаларын, якыннарын бик сөя, ләкин аны сөюче юк... Менә ул базар авылыннан пар ат яллап кычкыра, җикерә, җырлап кайта... Әнкәсе тавыш чыгармый, бер җирдә качып, әкрен генә елый... Менә мәчеттә тавыш чыгып, ул, намаз укытмыйча, күзләрен бөтенләй кан басып, өйгә кайткан... Тагын әнкәсе елый... Менә кешеләр икендегә җыела. Ул керми, ак күлмәкчән ишегалдында тезләрен кочаклап һич хәрәкәтләнми утыра; аның «указы» алынган... Әнә ул хәстә, балаларын чакырып-чакырып берәмләп үбә, салкын куллары белән башларыннан сыйпый... Менә аның урынын тартып алган «сары җиләнле мулла» инде аның җеназасы өстендә иелеп, бөгелеп, әрле-бирле йөгерә... Бу чагында инде әнкәсе тавышсыз түгел, өзелеп-өзелеп тавышлап ярсый...

Гариф шушы күңелсез хатирәләргә бирелеп торган чагында, кинәт ишек ачылып, аны сискәндерде. Чикмәнне азрак ачып карагач, бераз аптырап китте: Газизә кергән иде.

— Гариф абзый, йокламыйсың икән... Юеш әйберләреңне әнкәй сораган иде, кухняга илтеп җәясе үзләрен...— диде.

Гарифның бер читкә ташланган тужуркасы белән күлмәкләрен Газизә җыештырып алып чыкканда, Гариф утырган җиреннән: «Мәшәкать булыр, борчыласыз, Газизә...» — дип сөйләнеп калды.

Газизә чыгып киткәч, ул беркадәр аптыранган рәвештә ишеккә карап торды-торды да тагын бөркәнеп ятты. Кайсыдыр почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде. Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңеленә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык катыш эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде. Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газаплаган шушы билгесез

---

[1] *Мөбтәлә* — дучар булган.

моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...

Киң күкрәкле, юлбарыстай көчле һәм матур егет иске чикмән астында әкрен генә елый иде.

МАТУР БЕР ИРТӘ, МОҢЛЫ БЕР КИЧӘ

...Давыл башланганга ике тәүлек тулып өченчегә киткәч, кич белән җил басылган, диңгез шактый күтәрелеп чайкалса да, күбекләр пошкырмый йомшак кына тирбәнеп тора иде.

«Балык, балык...»

Һәркемнең авызында шул сүз иде. Чөнки сезонның нәкъ чилләсе килеп җиткән. Әмма лабазда бер генә чан төбендә барлыгы бер-ике йөз пот балык ягылып ята иде.

Кич ашыннан соң эшчеләр озак маташмый, тизрәк яту белән булдылар: ярты төннәр тирәсендә невод салыначак иде. Шулай итеп, алар үзләре өчен якында гына кызу һәм күңелле бер хәрәкәттә хәзерлек хисе белән кичнең лэтыйф һәм уңайлы кочагына бирелделәр...

Вакыйган[1], ике көн эшсезлек аркасында, йөрәкләрне әкрен генә кимереп торган эч пошу артыннан, эш көне гадәтчә бер бәйрәм кебек күңелле башланды.

Кояш калыккан чагында неводның арты кырыйга килеп җитәргә күп калмаган иде.

Һаваның лэтафәт[2] һәм сафлыгы, күк йөзенең зәңгәр хәтфә төсле мөлаем матурлыгы, күптән түгел генә котырып чыккан каралҗым диңгезнең күксел сәдәп төсенә кереп күзләрне рәхәтләндерә-рәхәтләндерә йомшак кына тирбәнеп ятуы, шушы чиксез матур һәм мөлаем диңгез артыннан җем-җем иткән кызыл җәүһәр тәгәрмәч рәвешендә тетри-тетри кояш чыгуы җиһан сараена әллә нинди тылсымлы матурлык бирә, бу дөньяның көндәлек хакыйкатенә охшамый, зиһеннәрдәге хыялый оҗмахларны аңдыра[3] иде. Диңгез өстендә яңгыравыклы тавышлар белән гигиләп бертуктамый очынган акчарлаклар да, кызгылт шәүләләр эчендә гүя гади кошлар түгел, «оҗмах» кошлары булып күренә иделәр...

---

[1] *Вакыйган* — чыннан да.

[2] *Лэтафәт* — гүзәллек, матурлык.

[3] *Аңдыра* — төшендерә, күзаллата.

Невод кырыйга якынлашкан саен халыкта рух арта, йөзләр көлә иде; невод чолгап алган урында диңгез өстендә, әллә нихәтле ялтыравык ак йомычкалар чәчрәп торган шикелле, бертуктамый ялт та йолт балыклар сикерешә иделәр.

Өметләр бушка чыкмады.

Сәгать җиделәрдә промыслода кечкенә генә бәйрәм иде. Тачкачылар көлмәкчән генә, хәтта көчсезрәкләре изү бауларын җибәреп балык ташыдылар.

Ике вагонлап балык чыккан иде.

Актык тачкалар бушатылган арада, Исак, шактый әре кыяфәттә бер кулына су чиләге, икенчесенә кечкенә генә рюмка тотып, лабазга керде. Бусы егетләргә тагын да бераз күңелле булды.

Шәрәфи агай, мыек астыннан көлә төшеп:

— Сыйлыйсың да ахры үзләрен...— диде.

— Азрак кирәк бит...— дигән булды тегесе.

Рюмка нечкә билле түгел, кечкенә генә стакан формасында иде. Исак ике бармагы белән генә рюмканы читеннән чеметеп чиләк эченнән чак кына чумырып алгач, бераз көлемсерәп, Шәрәфи агайга суздды.

Ә ул кешеләргә карап кызыклы гына иттереп күз кысты да:

— Картларны сыйламаганда да ярар иде, әнә егетләрне кирәк,— диде. Һәм бердән генә йотып та куйды.

Исак, ачык йөз белән генә һәммәсенә берәр рәт биреп чыккач:

— Артельщик, артельщик кайда? Иң кирәкле кеше юк ич,— диде.

Шәрәфи агай кыска гына:

— Хәзер шунда иде, ну ул эчми,— диде.

— Йә, алай булса,— диде Исак,— кайтып ашагыз да, егетләр, озакламый чыгарсыз; тегеләр невод салырга киттеләр. (...)

Кич гаҗәеп гүзәл иде, каралҗым күк йөзен аксыл җәүһәр кисәкләре төсле балкып торган хисапсыз шаян йолдызлар бизи, җирдә диңгез буйлап куе караңгылыкны ачып җибәргән саргылт кызыл факеллар яна. Ерак-еракларда, чит промыслоларда яндырылган шундый ук факелларның төмсә һәм юаш утлары караңгы диңгез буйлап су өстеннән күңелгә ягымлы йомшак нур сызыклары җибәреп торалар. Алар диңгез өстендә гүя елмаялар, гүя көләләр. Әллә нинди төпсез тирәнлек һәм серләр эчендә уйнап җанга аңлашылмаган бер дәрт, җылылык һәм рәхәтлек бирәләр. Кайсылары ераклардан

чагылып, гүя елый-елый әкренләп сүнәргә торалар, кемнедер бәхилләшергә чакыралар... Диңгез ягыннан искән йомшак кына җил, чак хис итәрлек таза су һәм тоз исләре аңкытып, битләрне сыйпый, миләрне кытыкландырып, күңелләрне рәхәтләндерә иде.

Алар вал янына җиткәндә эндәшми генә бардылар. Ат дагалый торган «станок» шикелле, ләкин шактый киң булган ояга урнаштырылган баганаһың тирә-ягындагы тоткаларына утыз-кырыклап кеше ябышкан, тавышсыз-тынсыз кызу гына тирәли әйләнеп йөри иделәр. Хуҗа да анда иде. Болар халык янына барып туктагач, Исак, күзләрен ялтыратып:

— Менә безнең тачкачылар,— диде.

Хуҗа көлемсерәп кенә эшләпәсен кузгатты да:

— Ә, князьләр икән... Яхшы халык... Яратам мин аларны, эшчән булалар...— диде.

Ул утыз бишләр чамасында, кара тутлы, матур гына чырайлы, мыекларын югары таба бөтереп җибәргән, шома гына кыяфәтле кеше иде.

Аның чем-кара күзләре факел яктысында артыграк ялтырый, көлемсерәп каравы да, «князьләр»гә яхшы тәэсир бирмичә, чәнечкән кебек тоелды.

Алар, аның эшләпә кузгатуына каршы үзләренең искемоскы бүрекләрен гүя башларыннан төшмәгәнме икәнлеген белер өчен генә тотып куйгач, акрын гына икенче якка шуарга, неводчылар арасына кушылырга карадылар...

Невод чыгып беткәнче, хуҗа һаман эшчеләр янында әйләнде, аңар карап эшчеләр нихәтле кызу тотсалар да, эш байтак озакка тартылды. Әмма балык күп түгел иде: утыз-кырык тачкалап балык чанга салынгач, Шәрәфи агай, фонарен тотып тачкачылар белән бергә сөйләнә-сөйләнә, лабаздан чыкты.

Сүз хуҗа турында иде. Ул, лабаз йозагын шыгырдатып торып бикләп алгач:

— Кешесе карарга әйбәт, тик артык комсыз малай,— диде.

Гариф сорады:

— Ничек ул?

— Үткән ел балык аз булгач, буыла башлаган, мәлгунь! Анасы белән сеңлесе генә чак коткарып калганнар. Хәер, байларның һәммәсе дә шундый мәлгуньнәр.

Инде бик соң иде, сүзне артык озайтмадылар. Шәрәфи агай, фонарен чайкый-чайкый, үзенең кечкенә генә гаиләсе янына, тачкачылар баракка юнәлделәр. Ай, яңа гына диңгез артыннан

күтәрелеп, күңелсез генә карап тора, аның бер чите китек, гүя шуның өчен кайгыра, сүнгән факелларның берничәсеннән әле дә төтеннәр чыгып тора иде...

ӘЙТ ШУНЫ

Пасха[1] көне иде. Барактагыларга иртә чәйне гадәттәгечә каткан чәйнекләрдән иске-москы кружкалар белән эчәргә туры килсә дә, бәйрәм әсәре бөтенләй юк түгел иде. Кеше башына берәр булки өләшенүе бу көннең гади эш көне түгеллеген бик яхшы сиздерә иде. (...)

Бүген балык та шактый мул пешкән, башка көнге кебек сыек өйрә генә булмыйча, ике табакта бутка кебек өелгән килеш өстәлнең ике башына куелган. Булар чыгарып, тәмле исе белән кешеләрнең ашыйсыларын китереп тора иде.

Элекке чынаяк тагын карттан башланды. Ул бик яхшы теләкле тон белән:

— Сау буласыз, егетләр! — диде. Һәм чыраен сытмый торып чынаякны ялт иттерде.

Чынаякны кире биргәч, бер күзен кыса төшеп, чыраен сыткан көе авызына балык тутыра-тутыра:

— Һәр көн пасха булса иде! Николай, син ничек уйлыйсың, начар булмас иде бит? — диде.

— Кайда ул һәр көн! Көнаралаш булганда да ярар иде, минемчә...

— Әйе шул... Ике бәйрәм арасында бер көнне ничек тә үткәрер идең инде. (...)

...Токкасыз чынаяк инде берничә рәт әйләнеп чыкты. Кешеләрнең күзләре үзгәргән, сөйләнешләрдә пружиналар ычкынып-ычкынып киткән төсле, китек һәм сөйкемсез тавышлар ишетелә иде.

— Яле, господин фабрикант! Тотчы менә чынаякны...— диде Сафа.— Сиңа яхшырактан, кызылдан-нидән кирәк иде... Ярый инде, ни бары белән сыйлыйк...

Ул шулай дигән генә иде, Федор торды да чалт иттереп аның яңагына кундырды.

— Нишләп миннән көләсең! — дип, җиңел кулдан икенчене дә өлгертте. Үзара шаулашкан исерек халык та акаешып кал-

---

[1] *Пасха* — христианнарның дини бәйрәме.

дылар. Сафа тегенең изүеннән эләктерде, Сафаның дусы Заһид исемле егет тә аңа ябышты.

Шәрәфи карт:

— Туктагыз, тукта, егетләр! — дип кычкыра, ләкин тыңлаучы юк; Федорны өстәл арасыннан чыгарып җиргә екканнар, ике кеше берьюлы кыйныйлар...

Карт, өстәл аркылы сузылып:

— Аерыгыз, аер, егетләр! Ярамый! Аерыгыз! — дип кычкырып тора. Николай аның янында, өстәл арасыннан чыга алмый маташа.

Шул арада булмады, Гариф арага төште. Ул кыйнаучы егетләрне читкә ыргытып җибәрә башлады. Солдат та аңар булыша иде. Николай белән Шәрәфи агай да инде өстәл арасыннан чыгып арага керделәр. Федор араланды. Шәрәфи агай, Николай, Солдат, шактый аек кыяфәттә, өлкәнлек күрсәткән булып, кыйнашучыларны шелтәләргә дә тотындылар. Шушы арада Сафа җирдә аунаган тупас чынаякны алды да, ачу белән читтән ыргытып, Гарифның яңагына кундырды. Гариф корт чәнечкән шикелле булып сугылган җиренә кулын каплады. Бармак араларыннан кан тамчылары бер-бер артлы җиргә төшә иде. Ул, гүя моның ни өчен булганлыгын аңлар өчен, тирә-янындагыларга караганда, Сафа кулларын йомарлап сугышырга да әзер тора иде. Гариф аңа атылып, ике яклап колак янга берәрне бик нык төшереп, җиргә тәгәрәтеп җибәрде, һәм егылган җирендә дә типмәкче иде, ләкин Шәрәфи агай белән Солдат аңар тагылып, ачуын бастырдылар. Сафа, торгач, тагын Гарифка бәйләнмәкче булып маташса да, аны җибәрмәделәр...

Федор шактый нык изелгән, хосусән[1] авызы, борыны, аяк астында тапталып булырга кирәк, ямьсез шешкән, канга буялган иде. Шулай да ул канлы иреннәрен сары тула поддевкасы[2] чабуына сөртә-сөртә эндәшми генә тагын өстәл янына утырды. Сафа һаман төрле усал сүзләр белән Гарифны сүгә һәм дә яный иде.

Шәрәфи карт, Федорга карап, башын чайкый-чайкый:

— Дурак! — диде.— Пешмәгән нәрсә! Бер дә юкка нинди җәнҗаллар кузгатасың.

Федор кычкырып ук елый башлады:

---

[1] *Хосусән* — бигрәк тә, аеруча.

[2] *Поддевка* — кәзәки (ирләр киеме).

— Алар бит мине мыскыл итәләр, Шәрәфи Осипич, как будто мин ялганлыйм, имеш, аларга! Билләһи менә, әгәр мин ялганласам! Шырпы фабрикасы... «Лашкарев» фирмасы... Безнең үз фамилиябез бит шулай... Ә болар мине мыскыллыйлар... Миндә аларның ни эшләре бар соң?

Шәрәфи агай иңбашын тартты да:

— Странно,— диде.— «Лашкарев», бар бугай шул... Солдат, кая әле чынаякны китер... Лашкарев белән Сафаны килештерик... Егетләр, егетләр, акылыгыз булыр да мин булмам, картаям инде әкренләп, әйдә, энем Сафа, кил, утыр! Кыйнашудан файда юк: Алладан тәүфыйк сора, озын гомер... Сүгешмә, кеше рәнҗетмә, шулай бит, Миколай? Дөрес әйтәм бит? Әх, егетләр, егетләр, нәрсә җитмәгән үзегезгә, күз тигән бәбкәләр кебек чукышасыз, алай ярамый бит... яхшы түгел...

Шул арада Солдат аңар аракы сузды.

— Юк инде, господин унтер, миңа бирмә инде... Әнә бу егетләрне килештерик әлек. Сафа, тотчы, энем... Иң элек сиңа әләкте бит... Менә шулай... Аннан соң господин Лашкаревка чират, аңар беррәттән икене бирергә дә ярый... Аның клажасы[1] бераз авыррак иде бугай... Мәгъзумны да онытып куйма, Хөснетдин. Чынаяк тигән җиренә азрак шифасы булыр, бәлки... Шулай үзең белгәнчә рәтлә инде... Тукта әле, кая китәсең. Тукта, эчеп чыгарсың, мәгъзум!..

Гариф аның сүзенә илтифат итмичә чыгып китте. Ул ишектән чыкканда берьюлы:

— Кил әле, тукта әле! — дигән исерек тавышлар шауласа да, артыннан чыгучы булмады. Ул, кулъяулыгын яңагына басып, лабазга таба китте. Кыстатып-кыстатып эчкән ике чынаяк аракы аның башын яхшы ук сөремләндергән иде. Шулай да бaрактан чыккач, кояшлы саф җәй башы һавасы аны рәхәтләндереп, тәмам айныткан шикелле булды. Яңагындагы җәрәхәт күңелен борчымый, бәлки ләззәтле сымак әрнеп кычыта гына иде. Ләкин нидәндер аның күңеле бала чагындагы кебек нечкәргән иде. Әллә кайда еракларда калган туган иленә, әллә кайчан үткән бала чакларына күңеле китте... Җиргә караган килеш көлемсерәп уйлый-уйлый бара иде.

Лабазның диңгез ягында хатын-кыз тавышы ишетелә башлады. Ул, почмакны әйләнеп чыккач:

---

[1] *Клажа* — йөк.

— Иһи! Менә кайда икән рәхәт,— диде.

Берничә рус хатын-кызлары лабаз алдында кояшка каршы тезелешкән, чыр-чу килеп көнбагыш чиертеп утыралар. Кухарка белән Газизә дә шунда иделәр.

Газизә аптыранып һәм кызганган тавыш белән:

— Гариф абзый, нишләдең болай? Битең каный ич! Нишләп ул! Ходаем, ничек кан агып киткән! — диде.

Гариф, тегенең аптыраганына кәефе килеп:

— Әткәң белән кыйнаштык, Газизә! Мин сине үземә кәләшлеккә яучылаган идем, ул, мин сиңа әйтим, кыйнашырга...

— И! Шаярмый гына дөресен әйт әле! Ни булды соң, ә?

Гариф аңар якын гына бер мичкә өстенә килеп утырды да, җитди һәм тынычландыра торган тавыш белән:

— Бернәрсә юк ла! Берсе ялгышлык белән әйбер ыргытканда тидереп аз гына тырнатып алды шунда...— диде.

Рус хатын-кызлары да кызганган чырай белән карашып тора иделәр. Гариф аларга да шулай аңлатты.

— Бир әле яулыгыңны,— диде Газизә,— мин юып килим... Биргәнне дә көтмичә, ул, Гарифның канлы яулыгын кулыннан алып, диңгез кырыена йөгерде.

Ул бүген Гарифка гадәттән тыш сөйкемле күренә иде. Читтән караганда, нурлы кояшка күкрәк ачып күзләрне рәхәтләндерә торган шәүләләр эчендә, елмая-елмая яткан диңгез ягасында чүмәшкән килеш үзенең садә[1] генә ал күлмәге һәм башындагы күк яулыгы белән ул түгәрәк кенә ләтыйф бер гөл чәчәгенә охшый иде.

Гариф, битеннән каннарын юарга уйлап, эре-эре адымнар белән Газизә янына төште. Ул инде яулыкны сыгып маташа иде.

— Мәшәкатьләнәсең бит, Газизә...— диде Гариф һәм, йомшак кына челтерәп комга сугылып торган дулкын кисәкләреннән кулы белән алып, битенә су коя башлады.

Газизә, аның янына ук килеп:

— Тукта әле, яулык белән...— диде.

Газизә, чыланган яулык белән аның яңагын сөртә-сөртә:

— Җылы су булганда әйбәт буласы икән... Безнең өйгә генә керәсе иде... Тырналган җире калып торсын әле... Су тигәч ярамас бит, әрнер...— дип кызганган тавыш белән балаларча сөйләнә иде.

---

[1] *Садә* — гади.

Аның болай чын ихластан кызганган рәвештә шөгыльләнүе, самими һәм садә кыланышы Гарифны эчтән көлдерә дә, елата да, тәмам үзәген өзә иде. Хосусән, ул шулай бик мөһим эш эшләгән төсле дикъкать белән яулыкны чылатып-чылатып Гарифның яңагыннан каткан каннарны сөртеп маташканда, аның алсу йөзе Гариф йөзенә шактый якын торуы Гарифны үтерә иде... Ул Гарифның күзенә карамый, барлык дикъкате белән җәрәхәткә су тигезмәскә тырыша, гөл чәчәгенә охшаулы иреннәре беленер-беленмәс кенә тетри... Шундый бер момент булды: бу иреннәрдән үбеп үләргә генә булса, Гариф өчен чиксез бер бәхет булыр иде... Тик нидер, үлемнән көчле бернәрсә аны тотып калды.

— Җитәр, җаным, калганы өйдә юылыр,— диде.

Чит хатын-кызга әйтергә килешмәгәнен белә торып «җаным»ны Газизәгә беренче тапкыр ихтыярсыз ычкындырды. Газизә ул сүзгә бер дә әһәмият бирмәгәне күренә иде. Лабаз янына кайтканда бер дә тартынмыйча, Гариф белән янәшә үк сөйләнә килде. Гариф инде аларда берничә мәртәбә утырган, картлар алдында да алар Газизә белән сөйләшәләр, сәләмә катыргылы «Сәйфелмөлек» китабын да бергәләшеп укыганнары бар. Ләкин Газизә аңар бүгенге кебек кыюлык һәм үзсенү күрсәткәне юк иде. Гариф хәзер, бердән, бу беркатлы һәм сөйкемле туташтан үзенең исереклегән яшерә алганлыгы белән күңеленнән мактана, икенчедән, аның гадәттән тыш үзенә якынлык күрсәтүенә җаны рәхәтләнә иде. Алар элекке урыннарына утыргач, Гариф хикәя сөйләргә башлаган рәвештә:

— Бер атна-ун көннән соң, Газизә... монда акчарлаклар тавышы гына яңгырар... Бәлки алар да инде кайсы кая китәрләр...— диде.

— Нишләп?

— Эш бетә ич, шуннан таралышабыз...

— Авылыңа кайтасың, әйе?

— Ансы әле билгеле түгел, ничек булыр...

— Юк, авылыңа кайт, Гариф абзый, авылыңа кайт, яме? Туганнарың көтәләр булыр... Бар бит туганнарың? Сагынганнардыр үзеңне? Менә кайтырсың бервакыт...

Гариф көлде:

— Минем белән барсаң, кайтам! — диде.

Газизә кызарынып китте.

— Мин нәрсәгә? Мин эткәйләр белән ич! — диде.

— Ә мин ялгыз гына авылга кайтмыйм...

— И, шаяртмачы! Анда бик һәйбәт мулла кызлары да сине көтәләр булыр...

— Мулла кызлары... Әйе шул. Ну шулай да без Газизә белән икәү кайтабыз!..

Гариф бу сүзләрне әйткәндә Газизәгә туп-туры һәм дә «иблисчә»рәк карый иде. Газизә, кызарып, куллары белән йөзен каплады. Якында утырган рус хатын-кызлары да яшьләр арасындагы сүзнең көндәлек түгеллеген сизенә һәм кызыксынып елмая иделәр...

Гариф, аларга карап:

— Менә якташны үземә кәләшлеккә күндермәкче булам: бергәләшеп авылыма кайтырга димлим... Ә ул риза булмый,— диде.

Тегеләр ачылып китеп:

— Менә нәрсә икән! — диештеләр.

Бере Газизәгә:

— Юләр булсаң гына шушындый егеткә бармассың! — диде.

Кухарка карчык:

— Ышана күрмә, ул шулай сине алдамакчы була! — диде.

Карчыкның шаярган сымак әйтеп салган сүзе Гарифның борынына суккан шикелле булды. Ул кинәт эчтән борчыла башлады: Газизә аңар рәнҗегән шикелле тоела иде. Ул бигрәк шушы минутта үзенең Газизәне алдамакчы булмаганлыгына кешеләрне ышандырырга мөмкинлек юклыкка борчыла иде. Ул җитди һәм акрын тавыш белән Газизәне юаткан рәвештә сөйләргә тотынды:

— Мин сиңа тагын мондый сүзләр сөйләмәм... Мин сине кардәш урынына күрәм. Җаным... Син мине бу юлы кичер... Мин кардәшемне алдамыйм, мин кемне дә алдарга теләмим!.. Мин сине үземнең туган сеңлем кебек яратам. Сине генә түгел Шәрәфи абзый белән Сәгыйдә апайны да яратам... Сез мине үз итәсез, сезнең игелегегезне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән мин оялам. Минем күңелем борчыла, мин сине бит чынлап яратам. Синең матур чәчләрең, ачык, килешле маңгаең минем күзләремә рәхәт, җаныма җылы бирә... Мин сине сөям, күз нурым. Чиксез бәхетле булуыңны, чиксез сәгадәтеңне, чиксез зур булуыңны, күкләрдә очуыңны, кояш булуыңны күңелем тели! Шушы теләкләремне булдыра алмауга җаным газаплана, аягыңа егылып елыйсым килә... Газизә кардәшем! Саташам дип курыкма... Тик кенә сөйләнәм... Мин бит исерек! Мин ялгыш синең янга килдем...

Газизә башта хәзер торып китәргә генә уйлаган төсле аптыранып торса да, сүзнең соңгысы аны бераз ачып җибәрде:

— И Ходаем, әйтәм дә шуңар охшый! Әллә нәрсәләр чуалтасың, бернәрсә аңлар хәл юк! — диде.

Шушы арада лабазның аръягыннан әллә нинди сөйкемсез җикеренүләр, кабердән чыккан тавышлар шикелле авыр ыңгырашулар ишетелә башлады.

Сафа белән Солдат, чак-чак кына аяк өстендә торып кочаклашкан көе, лабаз артыннан килеп чыктылар. Сафа, боларны күргәч, бер кулын бутап торып, бар куәте белән кычкыра-кычкыра ыңгырашып җырлый башлады:

Без эчәбез дә җырлыйбыз,
Акча бетсә урлыйбыз,
Ходаем безгә шушылай язган,
Мулласыннан курыкмыйбыз...

Кешеләр янына җиткәч, алар туктадылар. Ләкин бер урында басып тора алмый, бер-берсен этә-этә бер алга, бер артка авышып, көчле дулкында чайкалган көймәдә басып торган шикелле егылмаска тырыша иделәр. Сафаның күз төпләре шешкән иде. Ул яртылаш йомылган күзләрен киңрәк ачып, авызын кыйшайтып көлеп җибәрде. Һәм дә борыла төшеп күз кысмакчы булды, ләкин шул арада авышып китә башладылар... Ул тагын рәхәтләнеп көлеп җибәрде дә:

— Газизә туташ! Безгә ачуланмыйсыңмы? — диде.— Әй якташ, җаным, якташ... Син бит... якташ буласың безгә... Якташ син, әйе?

Газизә көлеп:

— Әйе,— диде.

— Кил, мине бер үп, җаным.

Солдат аның авызын капларга сузылган иде, эләкмәде — якасыннан тотты:

— Дурак! Авызыңны сугып җимерәм! Шәрәфи абзыйның кызы ич ул... Үзебезнең Шәрәфи абзыйныкы... Беләсеңме шуны, дурак! Газизә, ачуланма, акыллым... Дурак... исерек ул...

Сафа һаман көлеп маташа һәм сөйләнә иде:

— Мин дурак, Газизә туташ, билләһи мин дурак, җаным... Син мине кызган! Син бит якташ буласың! Кызган мине! Мин бит монда адашкан кеше. Без бит һәммәбез дә адашканнар. Әнә акчарлаклар нәрсә ди. Алар дурак диләр миңа. Алар үзләре дә

адашканнар... Алар балык әзли-әзли адашканнар! Гариф менә дуңгыз ул! Аның янында юкка утырасың, җаным... Ул мине кыйнады бүген... Менә күзләрем шешкән ич. Аны Гариф шулай итте... Кабахәт ул! Мин аңардан курыкмыйм... Ул дуңгыз ул... Мин курыкмыйм, утыр, Солдат, әйдә! Мин курыкмыйм... Үтерсеннәр әйдә... Куркыр хәлем юк, җаным... Теләсәң нишлә... Ну Гарифка менә тияр, Алла бирсә...

Алар ерак түгел бер читтәрәк утырдылар.

Гарифның эче тырный башлады. Сафа аңар чынлап кызганыч күренә. Күз тирәләре күгәреп ямьсез шешкән; сөйкемле генә чырае тәмам үзгәргән, бозылган иде. Аның көлүе елаудан да күңелсез һәм кызганыч тоела иде. Ул арка өстенә сузылып ятты да:

— Шулай икән, якташ, үпмисең, ә! — диде.

Газизә шаярган сыман:

— Юк шул инде, якташ, калып торсын,— диде.

Неводчылар казармасы ягыннан хор гөрелтесе белән бергә гармонь тавышлары килеп, су буенда моңлы һәм йомшак кына бер яңгырау тудыра иделәр.

Сафа яткан җиреннән күккә карап сүрән генә җырларга тотынды:

Алмалары, хөрмәләре
Җәй булгач пешәр әле.
Хөрмәләре, алмалары
Кызарып пешәр әле.
Әле исеңә төшмәгәч тә,
Газизәбану, сылуым иркәм,
Исеңә төшәр әле...
Җәйли исеңә төшмәсә дә,
Газизә җаным, сылуым иркәм,
Исеңә төшәр әле...

Соңгы мисрагны[1] алар Солдат белән икәү күтәргән иделәр, Гариф та кычкырып җибәрде:

— Әйт шуны!

Шушы минутта баракта Николай белән Андрей «Последний нынешний денечек»ны сузалар. Хәйрулла, Муса һәм башка иптәшләр «Баламишкин» көенә алмаш-тилмәш такмак әйтәләр, Шәрәфи агай өстәлгә капланган, хырылдап йоклый...

---

[1] *Мисраг* — шигырь юлы.

Неводчылар казармасында бер груһ[1] хор белән «Чудный месяц»ны тарталар, кайсыберләре ду күчереп «Камаринский»га басалар. Контора дигән өйдә ике кеше счет шакылдатып, язып-сызып утыралар. Берсе — хуҗа — тәмәке төтәтеп, фикергә калган сымак, идән буенча йөренеп тора. Сәгыйдә апай казармада ялгызы гына картының иске күлмәген ямап утыра. Карт белән Газизәнең озак кайтмауларына эче пошканнан, ишетелер-ишетелмәс кенә авыз эченнән ниндидер бер көй тартып моңая иде.

МИН СИНЕ КӨТӘРМЕН!

Апрель ахырлары иде инде. Диңгез ягасы комлыкта җылылыктан башка табигать алмашынуы сизелмәсә дә, ераклардан күренгән газамәтле таулар, таулардан түбән тимер юлы буендагы болынлык һәм таллар гүя чем-яшел хәтфәгә бөркәнгән көе ерактан торып көлә һәм матур җәй башлануын сөйлиләр... Әллә кайларга чакыра иделәр...

Безнең тачкачылар, балыкны бик күп тотып та, кырыгар сум акча эшләү хыялларына инде бит сыптырган иделәр. Балыкның барлыгы өч чанда гына булып, алар да тулы түгел иделәр. Ләкин балыкның аз булуы аларны өметсезләндермәде. Җәй башының көләч кояшы, матур яшел хәтфәгә бөркәнгән серле таулар аларга әле бик күп нәрсә ышандыра, мең төрле вәгъдәләр бирә иделәр.

Алар инде гел китү турысында сөйлиләр: кем кайда бара, кем үткән ел җәен кайда эшләгән, кайда эш яхшы, кайда күңелле, кайда акча күп бирәләр... Сүз һаман шул тирәләрдә әйләнә. (...)

Невод салу тукталгач, алар берничә көн лабазда эшләделәр. Тозланган селедканы озын саплы соскычлар белән чаннардан сөзеп алып чыгара баралар, хатын-кызлар,ише-ише белән сайлап, мичкәләргә тутыра иделәр. Газизә дә шунда алар арасында эшли иде. Сәгыйдә карчык, ирендә Газизәне күзәтеп йөрерлек салахыять[2] тапмыйча, егет-җилән арасында алай-болай шаярулар булмасын дип шикләнеп, еш-еш кына берәр сылтау белән үзе лабазга килеп караштыра иде. Ләкин ул караштырмаганда да егет-җилән Газизәгә әдәпсезлек күрсәтми иделәр. Газизәнең сөйкемле һәм җитди чыраенда, садәлек катыш чын кыланы-

[1] *Груһ*—төркем.

[2] *Салахыять (сәляхият)* — сәләт.

шында, кешенең күңелен үзенә тарту белән бергә аны бертөрле хөрмәт иттерә торган бер хасыять бар иде: мондагы татар егетләре үзләре сизмичә аны эчтән хөрмәтле тоталар, аңардан әдәп саклыйлар. Әлхасыйль, иң дөресе — һәммәсе диярлек эчтән аны сөя иделәр. Шунлыктан аны хөрмәтсез итәргә, оялтырга берсенең дә күңеле бармый иде. Бервакытта Гариф белән буташтырып сөйләнгән гайбәтләр дә инде онытылды. Кемнең дә күңеле Газизәне пычранган күрәсе килми һәм аны дөресләми иде.

Шулай да актык чан бушатылган көн Сафа байтак кына аның белән шаярып сөйләнде. Бер арада:

— Якташ,— диде,— киләсе ел монда булырсың бит?

— Бер дә әйтә алмыйм... әткәйләр нишләр...

— Әгәр син булсаң, без дөньяның дүрт почмагыннан монда җыелабыз, өйрәнеп киттек инде... Бер семья кебек бит... Солдат менә үзенең сторожлыгын ташлап килә. Хәйрүк тә нефтен ташлап калдыра. Инде Гариф монда көтеп торырга да риза. Ну, мин инде губернаторлыкка куйсалар да карамыйм, пичәтләремне генә ташлыйм да — кая син промысло! Килерсең, әйе?

Газизә кызарынып көлемсерәде дә:

— Киләсе елга хәтле мин үләрмен шул. Киләсе ел бик ерак әле...— диде.

— Ходай сакласын, җаным, алай әйтә күрмә! Әнә синең өчен ичмасам Солдат үлсен. Нәрсә аңар, барыбер ич! Службасын тутырган, паспорты да элмә-телмә өзгәләнеп беткән. Шулай бит, Солдат?

Солдат көлде дә:

— Почти что шулай!.. Ә үзең, үзең ничек? — диде.

— Кем, минме? Эһм... Үләргә дисең, юк шул, миңа не ахута, чорт вазми! Ну бит минем паспорт та синеке хәтле үк өзгәләнмәгән.

— Ходай сакласын! — диде Газизә.— Берең дә үлмәсен, илдә аналарыгыз зарыгып көтә торганнардыр... Кайтып аларны кинәндерегез ичмасам...

Сафа клоун төслерәк, кулларын авыштырып:

— Ух, якташ! Син нихәтле чибәр... То есть акыллы кыз... Аналарыбыз өчен дә борчыласың! — диде.

Газизә тагын кызарынды: «якташлары» назланган, сөйкемле балага караган кебек, елмаеп аңар карап тора иделәр... Гариф тиз генә эшне искә төшерде:

— Ну, егетләр, кич була бит! — диде.

Дөрес тә, тышта кич була иде инде. (...)

Иртән аяз, ләкин шактый салкын һәм җилле иде.

Тачкачылар иртән үк исәп алып, төш вакытларына станциядә булырга дип кичтән чамалаган булсалар да, эш алар уйлаганча барып чыкмады. Аларга әле көн буе лабаз тирәсендә маташырга туры килде. Исак, алардан биш мичкәләр күчертеп, калдык тозларны бер җирдән икенче җиргә ташытып, байтак кына башларын әйләндерде. Шулай итеп, иртән алырга уйланган исәпне кичкырын гына алдылар. Исәптән вак-төяк әйбер һәм акчалата алганнары чигерелеп һәммәсенә йөз ун сумлап акча бирелде. Баракка җыелып, аны үзара бүлештеләр, һәркемнең аерым-аерым язылган расходына карап, табышны Гариф өләште. Иң күп алучыга унөч сумлап, иң азына җиде сум да ничә тиен тиде. Тәмәке тартучылар азрак, клиндер дә ашаштыручылар тагын да аз алдылар. Иң күпне Гариф белән бергә килгән Муса исемле егет, иң азны Николай белән Хәйрулла алдылар.

Акчаны бүлешкәнче, хәтта бүген иртәдән башлап кешеләр көйсезләнә, нервничать итә иделәр. Моннан элек берничә көннәр китү, таралу мөнәсәбәте белән дусларча гәпләшүләр, бербересен сәфәр иптәшлегенә димләшүләр бүген әллә кайда очкан иде. Һәркем үзе белән генә мәшгуль, кәефсез, ачулы. Акча алганда байтагысы ризаланмый, расходын күпсенә, Гарифка ышанмый, көйсезләнә, икенче, өченче кат саната иделәр. Николай үзенең заборын беррәттән дүрт мәртәбә санаткач кына азрак тынычланды, юкса һич ипкә, көйгә килми.

Ниһаять, акчалар кесәгә салынгач, монда инде бер тиен дә арттырырга юл калмаганлыгы беленгәч, өсләреннән авыр йөк төшкән шикелле булып, кешеләр тынычланды һәм әкренләп сумкаларын кия башладылар. (...)

Гариф белән Солдат иң арттан чыктылар. Гариф кинәт туктады да:

— Карт белән исәнләшәсе иде бит,— диде.

— Әйдә инде, булмады... Мин кергән идем...

— Ничек булмады?

— Исерек... Әбисен белми ята!

— Ул хәтле үк булмас ла!

— Бар алайса тиз генә... Нәни кош белән саубуллашасың бардыр, нәгъләт!..

Гариф, төенен барак алдына куеп, тиз генә йөгерде. Солдат аның артыннан:

— Әй! Мин китә торам, кара, озаклама, шайтан,— дип, шаярган тавыш белән кычкырып калды.

Гариф барганда Газизә күлмәкчән генә, кара шәл бөркәнеп ишегалды баскычында утырып тора иде. Ерактан ук Гарифның күзенә күңелсезләнеп, кайгырып утырган төсле күренде, һәм шул минутта Гариф әллә нинди чуалчык хисләргә бирелде... Кинәт үзенең әлеге, ни исерек, ни аек түгел чагында җиңел баштан, Газизәне авылга алып кайту турысында яшелле-кызыллы сүзләр сөйләп ташлавы исенә килеп күңеле һәм оят, һәм ачы тойгылар белән тулды... Яулыкка төреп кесәсенә салган сигез сум җитмеш алты тиен акчасын әллә кайда ыргытып торып, үзеннән-үзе аунап көләсе, үзен-үзе мыскыллап үч аласы килеп китте...

Газизә чын да күңелсез иде. Гариф, аның янына җиткәч тә:

— Безнең китеш! Газизә...— диде.

— Хәерле юл инде... Авылга, әйе?

— Юк әле... Азрак акча эшлисе бар, туганкай. Монда юллык та булмады ич.

Газизә күңелсез генә елмайды, һәм Гариф артыннан ишегалдына хәтле керде. Ишегалды яртылаш караңгы иде. Гариф ишек ачарга торганда Газизә ашыкканрак тавыш белән:

— Өйдә кем дә юк бит... Әткәй йоклый...— диде.

— Әнкәң?

— Кухняга чыккан иде.

Гариф ишек тоткасыннан кулын алып әйләнгәндә, Газизә аңар якын ук тора иде. Берничә секунд эндәшми тордылар. Бер айдан бирле Гарифның күңеленә җылы яктылык биреп торган бу сөйкемле туташ белән аерылышу минутында гына болай икәүдән-икәү очрашу, бигрәк тә аерылышуның билгесез вакытка, бәлки дә бөтенләй күрешмәскә булуы әллә нинди, очына чыгалмаслык бер табышмак төсле аны аптыратты. «Гыйшык җыры» җырларга инде урын юк һәм соң да, сау бул, исән бул дип кенә шоп-шома китәргә дә мөмкин түгел! Ара бик якын... Бу аптыраш биш-ун секунд кына сузылды. Гариф, ике яклы мәгънәгә туры китереп:

— Соң нишлибез, алай булса? — диде.

Газизә, аның соравына җавап бирмичә, шаярган булып кына, ләкин каушаган тавыш белән:

— Менә Гариф абзыйга ышанып тор! Мине дә авылга алып кайтырга әйткән идең ич...— диде.

Гариф, акрын гына кулын Газизәнең башына куеп:

— Мин озакламый Саричинга кайтырмын... Аннан менә авылга барырбыз... Туй да ясарбыз, ярыймы, җаным?— диде дә, Газизәнең ачык һәм килешле маңгаена иреннәрен куеп, әч өзгеч бер мәхәббәт белән үпте. Шуның рухани ләззәте белән башы әйләнгән арада кинәт Газизәнең чәчәк кебек лятыйф һәм хәрарәтле[1] иреннәре дә аның иреннәренә кушылды. Коеп ясаган рәвешле матур күкрәкләре дә киң һәм көчле күкрәккә кысылган иде. Шул арада бер-берсенә ишетелерлек өзек-өзек шыпырт кына тавыш белән алар вәгъдәләшә иделәр:

— Мин озакламый... Саричинга кайтырмын, җанашым...

— Мин сине көтәрмен...

Гариф ишегалдыннан чыгып киткәндә, Газизә тагын аның артыннан кычкырды:

— Кара, мин сине көтәрмен...

Гариф, янә әйләнеп:

— Беләм, беләм, җаным... Хуш хәзергә!! — диде.

Гарифның иптәшләре инде байтак еракта, бер төркем булып, диңгез кырыйлап туктаусыз бара иделәр; Солдат алардан артка калган, Гарифны көтеп туктый-туктый бара иде.

Гариф канатланып очкан шикелле аны җитәргә дип йөгерә иде. «Мин сине көтәрмен» дигән җөмлә аның колак янында әллә нинди югары һәм әч өзгеч ноталардан җырланып бара, аның җанын ләззәт белән катыш ачыта, сызлата иде.

Газизә байтак вакыт, ишек яңагына сөялгән көе, китеп баручылар артыннан карап торды. Кояш та иңгән йә иңмәгән! Ул якны инде болыт каплаган иде... Диңгез өстендә сирәк-саяк акчарлаклар күренгәли; алар ак канатларын селтәп-селтәп бер югары, бер түбән очып, тонык һәм әчпошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйгылдап кычкырыналар... Газизә хәзер аларны карамый, ул диңгез кырые буйлап очмыйча гына китеп барган канатсыз акчарлакларны гына карый иде... Тик боларның тавышлары гына, үкереп елаган шикелле булып, аның колагында чыңлый иде. Ул, бераз торганнан соң, өйгә керде һәм мендәренә капланып әкрен генә үксеп-үксеп елый башлады... Бик тирән әч пошу аның йөрәген өзә иде.

Өй эче ярыйсы ук караңгы, исерек көе изелеп яткан Шәрәфи карт, хәрабә хәленә килгән иске тегермән шикелле, кызганыч-ыңгырашулар, сөйкемсез хырылдаулар арасында, әллә нинди чуалчык, караңгы төшләр күреп саташа иде...

1914

[1] *Хәрарәтле* — кайнар.

Габдулла Тукай
(1886—1913)

ТӘӘССЕР[1]

Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән,—
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән[2] бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый
башлыйм,
Яңакларны мөкатдәс күз яшемлә[3] энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем, укыйм иман, булам мөәмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам[4] авыр йөкдин.

Ходайа! Син тыйган эшләр тәмам әкътаг вә әбтәр[5], дим,
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһехак![6] Аллаһеәкбәр![7]»— дим.

1908

---

[1] *Тәәссер* — тәэсирләнү.
[2] *Дилдән* — күңелдән.
[3] *Яшемлә* — яшем белән.
[4] *Хәлас булам* — азат булам.
[5] *Әкътаг вә әбтәр* — кирәксез һәм яраксыз.
[6] *Аллаһехак* — Алла дөрес.
[7] *Аллаһеәкбәр* — Алла бөек.

АНА ДОГАСЫ

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр вә сахралар тора балкып.

Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый — каты, тәмле вә рәхәт уйкуга[1] талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә[2] ул шунда үз угълын:
«Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!»

Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

1909

ТАЯН АЛЛАГА

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага.

Йә Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул — рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең
пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезләң дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә[3]!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

1909

---

[1] *Уйку* — йокы.
[2] *Яд итү* — исенә төшерү.
[3] *Гаршенә* — югарыга, күккә.

МИЛЛИ МОҢНАР[1]

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып, җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»

1909

ДУСТЛАРГА БЕР СҮЗ

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Йосыф-Йагъкуб китабы»ның көен көйлим[2];
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим,—
Җебем — кара, инәм каләм булсын имди.

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк,—
Егъла-тора алга таба атлыйк имди.

---

[1] «Зиләйлүк» көенә. *(Г. Тукай искәрмәсе.)*

[2] XIII йөз болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы үлчәвенә ияреп язганга күрә, Тукай шулай ди.

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк,—
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлумнәргә[1] якты, нурлы көннәр килде,—
Азатлыкның кояшы тугъды имди.

Һәр милләтләр максудларын хасил итә[2],
Депутатлар ясап, Петербурга китә;
Инде нәүбәт без бичараларга җитә,—
Җыйлып-җыйлып депутатлар сайлыйк имди.

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә[3] дөнья тардыр;
Бу хөррият — Манифесте государьдыр,—
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди.

Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,
Дин эшендә башчы иттек без аларны;
Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный[4] егетләргә тәмам имди.

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәккыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!

1905

И КАЛӘМ!

И каләм! Китсен әләм, сән әйлә безне шадыман;
Без дә саяндә улалым тугъры юла кадыман.

Без өсәраи, кәсаляи дә сәүкъ ит һиммәтә;
Кыйл тәрәххем милләтә —калдырма, зинһар, зилләтә.

---

[1] *Мәзлум* — җәберләнгән (кеше).
[2] *Максудларын хасил итә* — теләкләрен тормышка ашыра.
[3] *Гафил* — ваемсыз (кеше).
[4] *Абразауный* — укымышлы.

Рәфгъ идеб Аурупаи сән гарше эгъляя кадәр,
Нә ичүн безне дөшердең фәрше әднәя кадәр?

Милләтең бу хале мәктүбме китабы хикмәтә?
Монхәсыйрмы ане гомре хале мәхзүниятә?

Яз тәгаллемләргә тәргыйб, әйлә тәкъдир къәдрене;
Ит наданлыкларны тәгъриф, зәһрене яз, гъәдрене.

Караны яз кара диб һәм игътираф ит аны ак,
Җөпне җөп дип язмали сән һәм ушандак такны так.

Бакма һич кәс хатеринә, милләтең дәрденә бак!
Бәддога — явыз догая һәр заман асма колак.

И каләм, сәндин кәлүр һәм бәхтемез, икъбалемез;
Бәкләнүр дүрт күз илә лотфында истикъбалемез.

Кичмәсен караңгылыкта маһемез һәм салемез;
Гафилез без, җаһилез — вай халемез, вай халемез!

Һәр тараф мөслимләри бер-бер иләрләр аһ вә ваһ!
Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сияһ?

Әйлә ярдәм безгә һәрдәм, и каләм, кыйл мәрхәмәт;
Дәфгулынсын җөмлә хәсрәт, фәкър вә хәкър, мәскәнәт.

1906

Хәзерге телгә тәрҗемәсе:

И КАЛӘМ!

И каләм! Китсен газап, ит син безне шат;
Без дә синең аркаңда туры юлга басыйк аяк.

Без әсирләрне, ялкауларны да зур эшкә этәр;
Милләткә мәрхәмәт ит,— зинһар, хурлыкка калдырма.

Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр,
Ник төшердең безне — җиде кат җир астына кадәр?

Милләтнең бу хәле хикмәт китабына теркәлгәнме?
Гомернең һәрбер сулышы хурлык белән чикләнгәнме?

Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит;
Наданлыкның начарлыгын, аңлат агу икәнен.

Яз караны кара дип һәм акны ак,
Җөпне җөп дип һәм шулай ук такны так.

Һәр кеше күңелен күрмә, милләт авыруына бак!
Бәддога — явыз догага һичвакыт салма колак.

И каләм, бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер;
Якты киләчәгебез дүрт күз белән рәхмәтеңнән көтелә.

Үтмәсен караңгылыкта айларыбыз, көннәребез
Гамьсез дә без, надан да без — вай хәлебез, вай хәлебез!

Һәрьяктан мөселманнар бер төслүк аһ-ваһ итә!
Безгә мондый кара бәхет нидән килде? — дип әйтә.

И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит;
Хәсрәт, хурлык, мескенлекләр — мәңгегә кит!

ШАГЫЙРЬ

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да,—
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым сүнмы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз — һаман да яз,
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!»— дип җырлармын,
Җәсәдемне[1] туфрак берлә күмгәндә дә.

1908

---

[1] *Җәсәд* — тән, гәүдә.

БЕР ТАТАР ШАГЫЙРЕНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп[1] каршы торам, миңа милләт[2]
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз[3] алга барам,
Юлда манигъ[4] күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү хәрам.

Шикләнмибез дошманнарның көчендин без,
Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без;
Шагыйрь гомре хәсрәт, кайгы күрсә күрер,—
Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез.

Яхшылыкка эреп китәм — балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне — бал авыз мин;
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм! —
Ул тугърыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!

Яманлыклар тәмам мине котыртала,
Таяк берлә гүя корсакка төртәләр, —
«Нигә болай?» «Ярамый»,— дип сөйләндереп,
«Тфү, чортлар! ахмаклар!»— дип төкертәләр.

Әгәр атса нахак җиргә бер-бер рами[5]
Мине, димим: «Дуст, бу рамьиң[6] һич ярамый».
«Яңлыш аттың, иптәш, кире ал, дип, угың»,—
Дустлык итәм, кадалганына карамый.

Ачы булгач күңлем, шигърем ачы чыга,
Бәгъзан[7] пешкән дип уйласам да — чи чыга;
Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,
Әллә ничек! — мыр-мыр итеп мәче чыга.

---

[1] *Күкрәк биреп* — күкрәкне киереп, курыкмыйча.

[2] *Миңа милләт* — сүз өстен катлаулар, шагыйрьнең тәнкыйтенә юлыккан кешеләр турында бара.

[3] *Һәнүз* — һаман.

[4] *Манигъ* — каршылык, киртә.

[5] *Рами* — укчы.

[6] *Рамьиң* — угың.

[7] *Бәгъзан* — кайбер чакта.

Мактаулыдыр аллы-гөлле нәрсә төсе,—
Тәмле нәрсә була күбрәк ачы-төче,—
Шулай итеп, ачы-төче язсам да мин,
Чыкса кирәк яхшы ниятемнең очы.

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам;
Тау башына менеп кычкырмакчы булсам,
Биек җир бит, егълырмын дип шүрләп калам.

Максуд җитәр: бара торгач — юл кыскарыр;
Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр;
Бөкре түгел, төзәлергә кабер кәтмим,
Тәңрем фәйзы[1] минем күңлемгә әз салыр.

1907

СӘРЛӘҮХӘСЕЗ[2]

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы.
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы.

Мискин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә,
Ямьсез якны уйлап куя эчтән генә.
Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,
Һич кайгысыз кеше булса — адәм түгел!

Бераз вакыт шатлык таба исрек кенә,
Үз-үзенә ачы агу эчреп кенә:
«Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,
Бу дөньяда кемнәр бар, дип, миннән дә зур!»

1909

---

[1] *Фәйзы* — рәхмәте.

[2] *Сәрләүхәсез* —исемсез (шигырь).

СОРЫКОРТЛАРГА

Аристократ — сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!

Халык батсын да бетсен, тик боларның эчләре күпсен;
Авызлары ачык бик киң, ниең бар: «Дай сюда, дай-дай!»

Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак;
Әйа корсак, вәйа корсак, җиһанны капладың, вай-вай!

Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак;
Тотып ярсак боларны без заман үткәрми, картаймай.

Ярыйк, дуслар, ярыйк, дим, чөнки безнең бәхетебез шунда;
Шулай йоткан безем икъбалемезне[1] бер дә кызганмай.

Җитәр инде, җитәр инде, давайте сызганыйк җиңне;
Салып ташлыйк киемне: һич өмид юк җиңне сызганмай.

Һөҗүм кирәк ишаннарга — сорыкорт, гөмбә башларга;
Бетер! сындыр, кырып ташла, мәгальурра вә билбанзай[2]!

Пәйгамбәрдән калан[3] дин урнына килгән чегәннәрдән
Үзенә башка бер дин, кайдадыр исламыбыз, һай-һай!

Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр;
Моны сизгән мөселманга чыдау мөмкинме җан җанмай[4]?

Ашап яткан сорыкортка кадалдым мисле хәнҗәр[5] мин;
Боларның мәсләге[6] — безне талау бит, бер дә коткармай.

Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вастрог[7] бар бит;
Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмай;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

---

[1] *Икъбаль* — якты киләчәк.

[2] *Мәгальурра вә билбанзай* — «ура», «банзай» дип кычкырып. («Банзай» сүзе японнарда бездәге «ура» диясе урында әйтелә.)

[3] *Калан* — калган.

[4] *Җан җанмай* — җан янмый.

[5] *Мисле хәнҗәр* — хәнҗәр кебек.

[6] *Мәсләге* — тоткан юлы.

[7] *Вастрог (острог)* — төрмә.

Чебен җанымны чын юлда бирәм бең кәррә[1], кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем[2]-юлым бөтенләй социаллардай.

Бу юл — алтын юл; котылуны теләсәң, шул юл белән бар;
Моның саликләре[3], үлгәнче, ялганнарга алданмай.

1906

ГОСУДАРСТВЕННАЯ ДУМАГА

Ник бик тиз беттең син, Дума,
Ник җир-ирек алмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума[4]?

Ник бик яшьләй картайдың соң,
Ник мәңгегә калмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник безне кызганмадың соң,
Коллыктан коткармадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Залим башлыкларны тотып,
Ник йөрәген ярмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник куылдың син үзең соң,
Ник кумадың үзләрен? —
Аң син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник баш бөктең залимнәргә,
Ник тыңладың сүзләрен? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

---

[1] *Бең кәррә* — мең тапкыр.

[2] *Чөн мәсләгем* — чөнки тоткан юлым.

[3] *Салик* — бурыч.

[4] *Бума* — бумы («Дума» сүзе белән рифмалаштыру өчен шулай бирелгән).

Ач-ялангач мужикларга
Кайда ирек, кайда җир? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Бирәм, дидең, вәгъдә бирдең.
Күрсәт җирең? Кайда? Бир! —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Депутатлар куылдылар,
Черки төсле, көш тә көш! —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Иткән гайрәтең бума?

Самый важный генерал да
Түлке күрсәтте күкеш,—
Ах җанашым, Дума, Дума,
Кыйлган гайрәтең бума?

Әйдә, дустлар, бер тибрәник,
Акны Тәңре яклар бит.—
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Барлык гайрәтең бума?

Караны бер көн каралтып,
Акны бер көн аклар бит.—
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

1906

«АЛТЫНГА КАРШЫ»

И Тәгалә! җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,
Яндыручы бу мөкаддәс җирне — бу ялкынны ал!

Куш мәләкләргә[1]: җиһанны тазартсыннар иде,
Барча алтынны, җыеп, дүзәхкә[2] атсыннар иде.

Сап-сары шайтаннар анлар шунда янсыннар иде,
Җөмлә гасыйлар[3] үчен шунлардан алсыннар иде.

---

[1] *Мәләкләр* — фәрештәләр.
[2] *Дүзәхкә* — тәмугка.
[3] *Җөмлә гасыйлар* — барлык гөнаһлы кешеләр.

Бу җиһан Иблис[1] вә шайтаннар белән калыр тыныч,
Бетсен иде шул сары йөз,— шундадыр зур куркыныч.

Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра;
Ялтырап, күзләрне чагып, тугъры юлдан яздыра.

Мин тәмам гиздем җиһанны,—кайда, кайда йөрмәдем,
Тик шул алтыннан — бәла, шайтан-фәлән һич күрмәдем.

Һәр тараф, һәр җирдә халкың — шул металлның бәндәсе;
Күрмиләр хакны, чөн[2] алтын һәр хакыйкать пәрдәсе.

Бу халыкча: зөһде[3], тәкъва[4], тугърылык та, дин дә шул!
Хәзрәти Коръән, Зәбур, Тәурат та шул, Инҗил[5] дә шул!

1907

МИЛЛӘТӘ

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;
Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем.

Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем.

Бәхтиярым — бәндәңи гәр итсәләр нисбәт сәңа;
Гаҗизанә шагыйрең улмакга вардыр ниятем.

Ләфзы «милли» и сәвәр кальбем бәнем, билмәм, нәдән?
Әйлә «милли», милләтем, бәхшәйлә мәмнүниятем.

Һәр хыялдан татлыдар милләт хыялы, ля мәхаль;
Бу хыялятдән кәлүр, гәр кәлсә мәҗнүниятем.

Әйлә шагыйрьлекдә сабит та әбәд, Тәңрем, бәни;
Бу сәбатә мөхәсыйр мәфтүн вә мөҗлүбиятем.

И фәләк! ал җаными, тик алма, зинһар, шаными;
Бәнчә, үлмәкдин әшәд мәнсә вә мәтрүкиятем.

---

[1] *Иблис* — Алла каһәрләгән фәрештә.
[2] *Чөн* — чөнки.
[3] *Зөһде* — суфилык.
[4] *Тәкъва* — яхшылык.
[5] *Коръән, Зәбур, Тәурат, Инҗил* — дин китаплары.

Үлмәсен, үлсәм дә, наме гаҗизем, фәүтитмәсен;
Көтмәсен буша бәнем җәһдем вә мәшгулиятем.

Берзаман ял әйләсә бильилтифат милләт бәни,—
Иштә будыр максадым, мәәмүл вә мәсгудиятем.

Әйләдем гарзы мәхәббәт бән сәңа, и милләтем;
Дуст күрерсең сән бәни дә — вар буңа әмниятем.

1906

Хәзерге телгә тәрҗемәсе:

МИЛЛӘТКӘ

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле;
Дөнья бирсәләр дә, сатмам, милләт, миллиятемне[1].

Синеке дип исәпләсәләр — бәхетле мин;
Игелекле шагыйрең булырга ниятлимен.

Күңелем «милли» дигән сүзне сөя — белмим, нидән?
Милләтем, мине «милли» ит — миңа шатлык бүләк ит.

Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы;
Шаша калсам, тик шул хыялдан гына булыр.

Мине шагыйрьлектә мәңге тугъры ит, Тәңрем;
Шунда гына — күңелемнең бөтен теләк-омтылышы.

И күк! ал җанымны, тик, зинһар, алма шөһрәтемне;
Минемчә, онытылу, тибәрелү — үлемнән яманрак.

Үзем үлсәм дә, гаҗиз исемем үлмәсен, югалмасын;
Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.

Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса,—
Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем.

Мин сине яратуымны сөйләдем, и милләтем;
Мин ышанам ки: син дә мине дус күрерсең.

---

[1] *Миллиятемне* — милләтемне сөюемне.

ҮЗ-ҮЗЕМӘ

Телим булырга мин инсане гали[1],
Тели күңлем тәгали биттәвали[2].

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы[3], Валлаһе әгъләм[4]?

1906

КИЧКЕ АЗАН

1

Кичке азан!
Кичке азан!
Моңнар, уйлар
Килә аннан;
Төшә искә
Иске заман,
Хөлусән мөс-
тәмигъ[5] азан.
Фи бәдьиһи
Вә бәгъдә[6] азан.
Күңелне тет-
рәтә, кәән-
нәһү тәсби-
хе рәгъд[7] — азан.
Китте Касыйм,
Китте Казан,
Бетте татар,
Кырылды хан,
Бохар, Хоканд
Һәм Әстерхан!

2

Ханнарга
иреште хизан[8],
Җылый-җылый
Бирделәр җан:
Сөембикә
дә Чыңгыз хан;
Нә дәүләт кал-
ды да, нә шан[9]!

---

[1] *Инсане гали* — бөек кеше.

[2] *Тәгали биттәвали* — туктаусыз күтәрелүне.

[3] *Кырылмасмы вавы* — сүз уйнату: «вәгъдәм» дигән сүзнең «в» хәрефе кырылса, төшеп калса, «әгъдәм» сүзе укыла, ягъни «юк» дигән сүз килеп чыга. Шагыйрь: «Вәгъдәләрем юкка булмасмы?» — дип борчыла.

[4] *Валлаһе әгъләм* — Алла белә, Алла күбрәкне белә.

[5] *Хөлусән мөстәмигъ* — ихлас белән тыңланган.

[6] *Фи бәдьиһи вә бәгъдә* — башлангычында һәм дәвамында.

[7] *Кәәннәһү тәсбихе рәгъд (рәгыд)* — бер-бер артлы күк күкрәгәндәй.

[8] *Хизан* — кайгы.

[9] *Нә шан* — ни дәрәҗә, ни мәртәбә; ни игътибар, ни әһәмият.

Һич калмады
Шаннан нишан[1],
Калды дингә
Дошман ишан!

3

Аһ, ник соң без
Булдык вәйран[2]?
Бөтен дөнья
Калды хәйран,
Гаҗиб[3], нидән
Бу ханәман[4]
Кисәктән әй-
ләде тайран[5]?!

4

Юк шул безләр-
дә берләшмәк;
Юк бергә-бер-
гә гөрләшмәк,
Бер җан, бер тән
Булып, һәр неч-
кә серне бер-
гә серләшмәк.
Үтте бездән
Инде дөнья,
Җан бирәбез
Галәлгомья[6].
Дөнья! актык
Сүзне тыңла:
Бәхил бул без-
дән, и дөнья!

5

Сау бул, дөнья!
Инде беттек;
Бетәргә сүз-
не беркеттек;
Вактында җир-
не селкеттек,
Инде беттек,
Инде беттек!

1906

КИТМИБЕЗ!

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр[7]:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә[8] кит! — диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!

---

[1] *Нишан* — эз, билге, тамга.
[2] *Вәйран* — ватык, җимерек, хәрабә хәленә килгән.
[3] *Гаҗиб* — искитәрлек.
[4] *Ханәман* — өй җәмәгате, мал-мөлкәт.
[5] *Әйләде тайран* — тузан кебек күккә очты.
[6] *Галәлгомья* — күз йомып, сукырлык белән.
[7] *Тәклиф иттеләр* — көчләделәр, мәҗбүр иттеләр.
[8] *Солтан җире* — Төркия.

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә[1] ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз[2],
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз[3].

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйзе вә җәл)[4].

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе ру сияһ!*

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
— Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!**

1907

МӨХӘРРИРГӘ***

(Кыйтга)

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибрия[5]!
И мосаувир[6]! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибрия!

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия[7]!

Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях[8],
Сәүдәгәрлектер зыялылык[9] вә сәүдәдер зыя[10].

---

* *Ру сияһ* — кара йөз димәктер (фарсына). *(Г. Тукай искәрмәсе.)*
** Сезгә яхшырак булса, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр.
*** 1913 елда Гаяз Исхакыйга багышлап язылган.
[1] *Сәкарь* — тәмуг.
[2] *Әмсар* — шәһәрләр.
[3] *Әгъсар* — гасырлар буенча үткән еллар.
[4] *Гыйззе вә җәл* — кодрәтле һәм шанлы.
[5] *Кибрия* — зур дәрәҗәлелек, горурлык, дан.
[6] *Мосаувир* — сүз остасы, рәссам.
[7] *Рия* — икейөзлелек.
[8] *Лөгать, истилях* — сүзләр, атамалар.
[9] *Зыялылык* — интеллигентлык.
[10] *Зыя* — яктылык, аң-белем.

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия*.

Алты ел торды чупансыз[1], айрылышты яшь көтү;
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән[2] курка шайтаннар» дигән төсле рәсүл[3],
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

1913

КЫЗЫК ГЫЙШЫК

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк.
Өст-башын салган; вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.

Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;
Нишләсен мискин — суык су куркыта.
Күп азаптан соңра гайрәткә килеп[4],
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да,— син нечкәләп бер баксана —
«Әл дә тәнгә тимәде»,— дип шатлана!

* * *

Мин моны яздым, бу — гыйшкым миследер[5];
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам —
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.

Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш!

---

*1905—1907 еллардагы инкыйлаб вакытында алдынгы фикерләр, омтылышлар белән рухланып йөргән кайбер кешеләрнең аннан соң үзара тарткалашулары, максатларыннан читләшүләре турында сүз бара.

[1] *Чупансыз* — көтүчесез; җитәкчесез мәгънәсендә.

[2] *Гомәр* — Мөхәммәт пәйгамбәрнең якыны, хәлифә.

[3] *Рәсүл* — Мөхәммәт пәйгамбәр.

[4] *Гайрәткә килеп* — кыюланып.

[5] *Миследер* — охшаштыр, төследер.

Бер шигырь язсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен дип куркудан.

Тугъры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.
Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай;
Шәһренә күптән барып җиткән бугай.

Кайда, ул миннән җибәрмәк хат-сәлам?! —
«Белми китте, күп шөкер»,— дип шатланам.

Белми дим дә, бәлки, «белгәндер» әле!
Әллә инде белгәнен белдермәде?
Аңламыйм, төшмим дә аңлау касдына[1],
Шигъреми җәйдем аягы астына;

Өенә җиткәнче басып кайтса аңар,
Шагыйре зур илтифатыннан санар.

1908

БӘЙРӘМ ВӘ САБЫЙЛЫК ВАКЫТЫ

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбъян[2] берлән бергә.

Төшә искә гарәфә кич[3] яткан чагым,
Уйлап: «Кайчан таң?» — дип, ул атмаган таңым;
Тәти читек, тәти күлмәк-ыштаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым;

Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,
Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
«Гает җитте, тор, аппагым! тор, аппагым!»

---

[1] *Касдына* — теләгенә, ниятенә.

[2] *Сыйбъян* — балалар.

[3] *Гарәфә кич* — Гает алды киче. Согуд Гарәбстанындагы Мәккә шәһәреннән 30 чакрым чамасы көнчыгыштарак урнашкан Гарәфәт тавы исеменнән алынган.

Таң аткачдин урам буе чапкан чагым,
Мәгъсуманә[1] ләззәт, хозур тапкан чагым;
Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,
Гает укып, көлә-көлә кайткан чагым.—

Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь;
Хозур ла соң! инсан[2] өчен бу хәл, бу яшь!
Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар ага,
Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!

Тәңре! чигерче яшемне, синнән сорыйм;
Теләгемне синнән сормый, кемнән сорыйм;
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикреп, көлеп, уйнап йөрим!

1908

КЫЙТГА[3]

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

1913

---

[1] *Мәгъсуманә* — гөнаһсыз, пакь килеш.
[2] *Инсан* — кеше.
[3] *Кыйтга* — өзек, кисәк, өлеш.

Дәрдемәнд
(Закир Рәмиев)
(1859—1921)

КАЛӘМГӘ ХИТАБ[1]

Каләм! Кальбеңдә[2] ни сер бар — гаян ит[3],
Килеп-кичмешләр әхвәлен бәян ит[4].
Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!

Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе[5] бар...
Кара тупрак тулы мәзлум[6] нидасы[7],
Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы[8]?..

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп-кичмешләр әхвәлен бәян ит.

Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!..

1906

---

[1] *Хитаб* — эндәшү, мөрәҗәгать.
[2] *Калеб* — күңел, йөрәк.
[3] *Гаян итү* — ачып салу, аныклау.
[4] *Бәян итү* — сөйләп бирү.
[5] *Армандә* — теләк, өмет.
[6] *Мәзлум* — җәберләнгән, рәнҗетелгән.
[7] *Нида* — зар-ыңгырашу.
[8] *Фида* — корбан.

ЯЗ ЧӘЧӘГЕ

(Мәдрәсәи Мөхәммәдиягә тартыладыр)

Килер-килмәс борын гөрләп матур яз,
Ничөн бөктең, умырзая, билеңне?
Исәр-исмәс икән таңда җиләс җил,
Ничөн кызганмадың, туктең гөлеңне?

1906

ШАГЫЙРЬГӘ

Ничөн бу хиддәт[1], и шагыйрь,
Нәдер бу ярганың ярма?
Эчеңдә бармы йә бер чир,
Вә йә синдә күңел тарма?

Әдиплек шәэнеңи[2] саклап,
Әдәпле сирәт[3] эзләп тап;
Бигүк түрләргә уздырма,
Катаңны да хата мактап.

Бирелмә ул кадәр зарга,
Сиңа көндәш түгел карга;
Вәли[4] бик калкынып очма —
Сакын[5], тап булма шоңкарга!

Яңылма, и яңа былбыл,
Тикәннән[6] гөлне айрып бел;
Телеңдә хар вә хөсса[7] булса,
Вафаи васләт[8] итмәс гөл.

Ала кошларга бакмакча,
Газизем, булма такмакчы;
Матур гөлләргә бул былбыл,
Нәзакәт багына сакчы!

1907

БЕЗ

Гасырлар кичте китте... кичте еллар!
Нәбиләр[9], падишаһлар, сөрде дәвран[10]...
Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,
Килеп кичте җиһандан канча[11] илләр!..

---

[1] *Хиддәт* — ачу, кабарыну.
[2] *Шәэн* — дәрәҗә.
[3] *Сирәт (сиярәт)* — гадәт, холык.
[4] *Вәли* — ләкин, «вәләкин»нең кыска формасы.
[5] *Сакын* — саклан.
[6] *Тикән* — үсемлекләрдә була торган чәнечке, тигәнәк.
[7] *Хар вә хөсса* — чәнчү һәм дошманлык хисе.
[8] *Вафаи васләт* — турылыклы аралашу.
[9] *Нәби* — пәйгамбәр.
[10] *Дәвран (дәверан)* — гомер, чор.
[11] *Канча* — күпме, ничә.

Сүнеп, вәйран булып[1] мәгъмур тиякләр[2],
Җир астында төзелде ку[3] сөякләр!..
Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз...
Дәрийгъ[4], мәхзүн[5] күңел, без дә бетәбез!

Мосафир, кем, җиһанга басты ботны,
Биетте ажгырып аны замана...
Өеп чергән өмидне... төртте утны —
Йотып утларны китте... яна-яна...

1908

НИ ГАЗИЗРӘК?[6]

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр —
Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
    Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем[7] газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
    Сөт калыр, ватан китәр!
    Сөт калыр, ватан китәр!

БҮЗЛӘРЕМ МАНА АЛМАДЫМ

Гәрчә мин дә бар саналдым,
Ил катар[8] сан алмадым;
Илдә йөрдем, хазлар[9] алдым,
Уйласам — сан алмадым.

---

[1] *Вәйран булу* — җимерелү, хәрабә хәленә килү.
[2] *Мәгъмур тиякләр* — төзек корылма, тораклар.
[3] *Ку* — кипкән, коры, буш.
[4] *Дәрийгъ (дәригъ)* — үкенеч.
[5] *Мәхзүн* — аянычлы, кайгылы.
[6] Шигырьгә исем төзүче тарафыннан бирелде. *(Төзүче Ф. Г.)*
[7] *Туган каүмем* — нәсел-нәсәбем.
[8] *Ил катар* — ил рәтендә, кеше рәтендә.
[9] *Хаз* — өлеш

Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,—
Бер янып ат алдылар.
Мин, гариб, мең кат янып та,
Яндыга саналмадым.
Уйлагыз: мәгъшука меңләр!..
Мин гашыйк саналмадым!
Кемгә васләт[1],кемгә өмид
Нигъмәтен бирде фәләк[2],
Мин өмиднең сул кулындан
Бер сынык нан[3] алмадым.
Кемгә васләт, кемгә өмид!..
Мин сынык нан алмадым!
Әйттеләр, кем, бер бәхетсез
Илгә гашыйксың, фәкыйрь.
Бер кызардым, бер бузардым[4]...
Ни таныйм — таналмадым.
Ни таныйм?.. Таналмадым!
Сезне, милләт кызлары, аh!
И өмид йолдызлары!
Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп,
Бер күреп каналмадым[5].
И өмид йолдызлары!..
Бер күреп каналмадым!
Исте җилләр ил эченнән,
Иртә-кич салдым колак.
Җил-җиләсләрнең моңыннан
Зәүкы әлхан[6] алмадым.
Кайда бер тау, кайда мәэмүл
Чишмәи абелхәят![7]
Тез йөгендем, яшь тамыздым,—
Дәрткә дәрман алмадым.
...Дәрткә дәрман алмадым!

---

[1] *Васләт* — кавышу.
[2] *Фәләк* — язмыш.
[3] *Нан* — икмәк.
[4] *Бузару* — агару.
[5] *Каналу* — юану.
[6] *Зәүкы әлхан* — көй ләззәте.
[7] *Мәэмүл чишмәи абелхәят* — булыр дип фараз ителгән мәңгелек чишмә.

Биэре миллэт[1], маэи зэмзэм[2]
Күзләдем еллар буе.
Җитте дәфнем[3] вакыты,
Кәфнем бүзләрен маналмадым!..
Вәйля[4]!..
Дәр-и-й-гъ[5]
Бүзләрем мана алмадым!..

1908

НӘСЫЙХӘТ

Гәрчә күрсәң ата-анаңдин җәфалар күп заман,
Син җәфа итмә аларга, бәлки — хөрмәт, и угълан!
Син нидер иттең исә атаң өчен, анаң өчен,
Син дә угълыңнан алырсың аны, әлбәт, и угълан!

1909

ИСЕМСЕЗ КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР[6]

* * *

Атам-анам йорты өчен
Булса мең җаным фида[7],
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

* * *

Урысча күп сүзең, азы татарча,
Белалмыйм, кем син — урысмы, татармы?
Ничектер белмәдек исме шәрифең:
Хәсәнме, юкса Иванмы, Макармы?

---

[1] *Биэре миллэт* — милләт коесы.

[2] *Маэи зэмзэм* — зәмзәм суы.

[3] *Дәфен* — күмү, җирләү.

[4] *Вәйля* — ни үкенеч.

[5] *Дәрийгъ* — ни кызганыч.

[6] Язылу вакытлары билгесез, беренче мәртәбә «Дәрдемәнд әсәрләре»ндә (1929) басылганнар.

[7] *Фида* — корбан.

* * *

Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер.
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

* * *

Татарлыктан татар һич гарь итәрме,
Кеше үз исмене инкяр итәрме.
Татарлыкта татар угълы татармын,
Татар түгел димә — башың ватармын!

* * *

Фәхер Разыйдан

Калмады галәмдә мәгълүм булмаган,
Аз булыр әсраре мәфһүм булмаган[1].
Уйлагач җитмеш ике ел төн вә көн,
Аңладым: һичнәрсә мәгълүм булмаган.

* * *

Булырмы яз, исеп җилләр,
Килерме җәй, ачып гөлләр;
Җитәрме кыш, кичеп еллар,—
Диярмен — сез, газиз илләр.

* * *

Булат[2] такмый кәмәрләгән[3] конан бил[4],
Тази[5] атлар җалын какмый биә[6] җил.
Өшәнләнде даланың толпар аты,
Урал шоңкарының[7] сынды канаты.

* * *

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен — дошман түгел!

---

[1] *Әсраре мәфһүм булмаган* — серләре аңланмаган.

[2] *Булат* — кылыч, хәнҗәр.

[3] *Кәмәрләгән* — б у о ч р а к т а: затлы итеп бизәлгән.

[4] *Конан бил* — тайлык чорыннан чыгып җитмәгән яшь атның сыгылмалы биле.

[5] *Тази* — йөгерек.

[6] *Биә* — бии.

[7] *Шоңкар* — бөркет.

* * *

Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар,
Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.

* * *

Синең ялгышыңа тимим, күрәсең;
«Чәбә!» дип әйткәнем юк, ник өрәсең!..

* * *

Агышың, и агымсу, туп-тулы зар,
Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар?

* * *

Тегәп моңлы күзем күкнең йөзенә,
Хикәя сөйләдем айның үзенә.

* * *

Әгәр барсаң, саба җил[1], безнең илгә,
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!
Төшендә юл өчен чәчкәен тарасын[2],
Гарибнең[3] кайтырындан фал карасын[4],
Ходаендан кавышмаклык сорасын.
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!
Дәрийгъ[5], бер гомер икән сөргән элек без,
Йөрер бергә, көлер-уйнар идек без.
Бу көндә Сак белән Соклар кебек без...
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә!

* * *

Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озайтма,
Катып кунган күңелләргә боз атма!
Дилең[6] өчен телең булсын тозаклы,
Йөз аклыгың өчен — аузың йозаклы!

---

[1] *Саба җиле* — таң җиле.

[2] *Төшендә чәчкәен тарасын* — төштә чәч тарауны күрсәң, өндә юлга чыккан кешене күрерсең яки үзең юлга чыгарсың дигән ышануга ишарә.

[3] *Гариб* — туган-үскән иленнән аерылып, читтә яшәүче.

[4] *Фал карасын* — киләчәкне әйтеп бирүче китапны карасын.

[5] *Дәрийгъ* — кызганыч, үкенеч.

[6] *Дилең* — күңелең.

Сәгыйть Рәмиев
(1880—1926)

ТАҢ ВАКЫТЫ

(Мөсәҗҗәгъ[1] нәсер)

Таң вакыты... Татар йоклый...
Мин, йокысыз, уянам,
Уянам да, тиле кебек,
Тик бер үзем уйланам.
Уйланам, уема батамын,
Тормыймын үзем, ятам...
Ятмас идем дә, җибәрми
Атадан калган хатам.
Хатам тирән, тамры ерак...
Ботагы дөнья каплаган,
Каплаган да тора-тора һаман,
Яфрагын да какмаган.
Какмаган бер яфрагын да
Һич татар курку белән,
Теге, ләгънәт, үсә, зурая, әле һаман да.
Колактан колакка туку белән.
Тукыйлар колакка, укыйлар тарихын,
Тикшерергә төбен кушмыйлар;
Аталар сөйли бабадан ишетеп,
Балалар шуны хушлыйлар.

---

[1] *Мөсәҗҗәгъ* — рифмалы, рифмалаштырылган.

Хушлыйлар чын күңел белән,
Ышанмыйлар һич: «юк, түгел» белән.
Башларын ваткан татарларның
Тик шул бер алла!
Бетәрләр микән татарлар, алла, ди-ди?
Әллә белерләр микән хаталарын бер алда?
Һай, юк, хата бик зур,
Бөтен дөньяны бар иткән,
Бардыр, үзе бердер,
Әмма көнһенә[1] ирешмәктән
Гакылларны тар иткән.
Әй син, Габдулла[2]!
Мөселман булсаң, уйлама юкны!
Ят, йокла!
Йокла рәхәт, йокла тыныч, саклан,
Саклан, утка таба йөз тотма!

Юк, юк!.. Мин шашам!
Яталмыйм урнымда, күккә ашам!
Менә таң атты!.. Әнә кояш чыкты!..
Әнә әллә кем миңа кычкыра:
— Әй, син, кайгырма, шат бул:
Аягың бәйдән ычкына!
Менә сиңа юл, бу анага угыл бул,—
Ди, миңа яшь бер кыз күргәзә.—
Туг яңадан мәгърифәтле анадан!
Югыйсә син, әй татар,
Бел, бетәсең! — ди,— надан.
Бетмә надан, туг яңадан
Мәгърифәтле анадан!
Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,
Хата ул өмид алладан![3]

1908

---

[1] *Көнһенә* — хакыйкатенә, асылына.

[2] *Габдулла* — Алла колы.

[3] Алла, Хак Тәгалә, Раббым, Тәңрем, Аллаһы Тәгалә сүзләре һәм башка исемнәр баш хәрефтән язылырга тиеш булсалар да, «Таң вакыты» шигырендәге «Алла» сүзе башка мәгънәгә, ягъни Рәсәй империясенә ишарәләгәнгә күрә, ул юл хәрефе белән язылды. *(Төзүче Ф. Г.)*

АЛЛА

Кем Ул — белмим, вә нәрсәдер,
Белим дип юл да эзләнмим,
Мәгәр Аннан бүтән затка
Җегенмим мин вә тезләнмим.

Олуг дим мин Аны һәм Ул
Мине аңлар вә ишетер дим,
Ни сөйлим йә на уйлыйм. Ул
Йолыр, онтыр вә кичерер дим.

Була үпкәм Аңа бәгъзан[1],
Дүнәм хәтта, җитәм чиккә,
Тәмам иркә, очынган бер
Бала төсле китәм читкә.

Ләкин күңлем Аны һәрдәм
Үз иткән. Ул даим бергә,
Газап чикмәс җаным бер дә,
Мәгәр чиксә чигәр бергә.

Мөкатдәсмен, әминмен[2] бар
Көфердән, бар гөнаһлардан,
Аяк баскан җирем барсы
Гөлстан бер, җинанлардан[3].

Кем ул андый, сәгыйд[4] иткән
Мине һәм урнымы, белмим,
Беләм тик: бу җаным Аннан
Яратылган, мин — Ул, Ул — мин.

1909

«МИН»

«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,
Миңа бер зур көч кирә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

---

[1] *Бәгъзан* — кайвакыт.

[2] *Әмин* — ышанычлы.

[3] *Җинан* — җәннәтләр, җәннәт шикелле пакь урыннар.

[4] *Сәгыйд* — бәхетле.

Бер үзем хөр каламын киң
Җир йөзе һәм күктә дә;
Әй рәхәт тә соң шул вакыт!
Шуны телимен күпкә дә.

Кайвакыт мин уләмен,
Сөймим үзем дә үземе,
Күрми торсам ул «мин»емне
Йә ишетми сүзене.

Үләмен, һич эшли алмыйм,
Таба алмыйм барны да,
Бар халык шат үзләренчә,
Мин бер үзем кайгыда.

Әмма соң кайчан күземә
Ул «мин»ем бер күренә:
Менәмен күкнең югары,
Иң югары түренә...

Дөньяда бар су — минеке,
Бар кара җир — минеке,
Бар тау, урман, бар матур кош —
Барысы да минеке!

Күрмимен мин ул вакытта
Һич бәхетсез бер кеше,
Барсы да үзен караган,
Миндә юк һичбер эше.

Мин дә «мин»емнең юлында
Бик тирән уйга талып,
Табынам — укыйм бер догамны
Ятлаган көйгә салып.

Нигә бу мин — «мин» дигәндә
Очам икән күккә дә?
Миңа гына микән алай?
Юк, шулайдыр күпкә дә.

«Мин!» димен мин, яшәсен «мин!»
«Мин!» минемчөн Алла ул,
Рухым үлгәндә күренсә,
Рухыма җан салган ул.

1908

«СИН»

Мине утка аткан ул — син,
Мине суга салган да — син,
Утка янсам, суга батсам,
Тартып алган Аллам да — син!

1908

«УЛ»

Кашлары — ай аның, яңа туган,
Йөзе — айның тулган көннәре,
Керпекләре — нурлар, кич чәчелгән,
Ике күзе — шул кичнең күлләре.

Үзе аның — диңгез, гыйшык диңгезе,
Бар мәхәббәт аңа җыелган,
Аңа күк тә ае, йолдызлары
Белән төшеп сәҗдәгә егылган.

Бите — кояш, кызарып чыгып килгән,
Көлгән чагы — гүя бер сахра,
Тавышлары — чын-чын былбыл тавышы...
Аһ, үләмен, үләм шул чакта!

1908

ТАЛДЫМ

Нигә уйлыйм тәгали[1] мин.
Дәнилек[2] җир тутырганда?
Сәгадәт таңрена каршы
Ачудан ил котырганда?

Галилек бар идеме ул,
Асылдук[3] юк иде мәллә?
Алайса ник гали җанлы
Яраттың соң мине, Мәүла[4]?

---

[1] *Тәгали* — бөек.
[2] *Дәнилек* — түбәнлек, әшәкелек.
[3] *Асылдук* — чынында.
[4] *Мәүла* — Алла.

Илаһым, ал мине! Талдым,
Юлыңда бер үзем калдым,
Куям кылчым[1] кире кынга...
Газаплый тик сиңа антым...

1918

ХАТЫННАР ГАЛӘМЕ[2]

Әй хатыннар галәме! Сез
Ник наданлык дәрьясы?
Дәрьяңызда баткан, үлгән
Бар татар зат баласы.

Белмиләр сезсез татарлар
Үз кирәк, файдаларын,
Күрмиләр рәхәт, сәгадәт
Нәрсәдә, кайда барын.

Сез һаман тик торасыз, ник
Яктылыкка бармыйсыз?
Ник татарларны да юлга,
Якты юлга салмыйсыз?..

1907

* * *

Кайвакыт уйлыймын мин
Уйны — тәмлесен генә,
Тәмле уйларым эчендә
Тәмлерәге — «син» генә!

«Син» генә бар хәсрәтемне
Тараталасың, тарат!
«Син» генә рәхәт кояшын
Караталасың, карат!

«Син» генә — бар күккә патша,
Аш! — диген, күккә ашыйм!
«Син» генә — рух биргән Аллам,
«Син» яшә! Һәм «мин» яшим!

1908

[1] *Кылчым* — кылычым.
[2] *Галәме* — дөньясы.

ДӨНЬЯГА

Аһ, әгәр бу күңелем үткен
Сөңге йә ук булсае;
Яисә ул бер уй белән су
Яндырыр ут булсае.

Әмма соң бер эт итеп бу
Дөньяны атар идем,
Җир-суын яндырыр һәм
Күкләрен ватар идем!..

Юк шул ул көч бу күңелдә,
Ул зәгыйфь, ул кечкенә,
Уйласам уй, сызлый күңлем,
Сызлый җан да эч кенә.

Бигрәк артык изде дөнья...
Калмады сабрым, бетәм,
Тик азаккы тамчы яшьнең
Җиргә тамганын көтәм.

Ул тамар бер, мин бетәрмен,
Тик шуны белсен үзе,
Бу азакккы яшь булыр бу,
Идеалымның йолдызы!..

Бу яшем, юк, җиргә сеңмәс;
Бу калыр, бу ялтырар!
Һәм, караңгы көн бетеп бер,
Мәңге якты ай туар!

Тугмый калмас, бер туар ул,
Идеалым күренер әле,
Шунда эчкән яшенә дөнья
Тончыгыр, күбенер әле!

Ник исәпсез калдырыр җан
Елгалап аккан канын?
Юк, алыр һәр тамчы канга
Дөньяның мең кат җанын!

1909

МИНЕМ ТӨН

Караңгы һәм дә таңы ерак,
Уты сүнгән җәһәннәм минем төн,
Олы кайгы, олы хәсрәт
Һәм эч пошу тулы гел минем төн.
Минем төн озын, минем төн кара,
Күрмим хәят, тирәм дөм караңгы,
Караңгы хәтта янган шәмем,
Караңгыдан рухым да каралды.
Караңгы һәм тар бар күк асты,
Тапмый күңлем бер карар һичкайда,
Карыйм да күккә, очарга уйлыйм,
Уйлыйм, әмма күрмим нур һәм ай да.
Нурсыз ул, нурсыз йолдызлар да,
Хәят беткән, җаны юк таңның да,
Торам да карыйм, юк, таң атмый...
Янам, көям, сызланып, кайгымда.

Егылам да егълыйм, саташам шуннан,
Кешеләр чорный тирәмне өемдә,
Рухлары фахиш, кара эч бар да,
Күрми идем эчләрен өнемдә.
Кәриһ[1] дә ямьсез тавышлары,
Йөрәк яргыч сөйләшкән сүзләре,
Нәфасәт[2] хисен хурлап тора
Килеш-килбәт, буй-сын һәм үзләре.
Көләләр шулар, сөйләшәләр,
Гакыл, мәгънә юк сүз һәм эшендә,
Бозыклык, ялган, ачу күрәм
Хакыйкать, гыйффәт[3], мәхәббәт эчендә.

1909

---

[1] *Кәриһ* — җирәнгеч, чирканыч.
[2] *Нәфасәт* — нәфислек, гүзәллек.
[3] *Гыйффәт* — сафлык, намуслылык.

«МИН ҮЛӘМ»

Һәрвакыт, чыксам агачлар,
Бакчалар эчләренә,
Шаккатам, тел бәйләнә бу
Дөньяның эшләренә:

Нинди япь-яшь гөл-чәчәкләр,
Нинди урман һәм сулар —
Һәммәсе — тик моң да кайгы,
Кайгылы һәм шау-шулар.

Ул илаһи бер матурлык —
Фәхри[1] урман аллары,
Ул илаһи төз зифа буй
Сахиранә[2] таллары.

Ул яшел хәтфә келәмнән
Җир йөзен япкан үлән —
Һәммәсе бер кайгылы көй
Көйлиләр: ул — «мин үләм».

1908

МИНУТЛАР

Кайвакытлар тормышымда
Бер минутлар табыла:
Зәррә[3] хәтле бер рәхәт бик
Зур биек бер тау була.

Тау булып, сыймый күңелгә
Бәгърем өзгән кайгылар
Һәм дә рухымның чәчәген
Каплап үскән кайрылар.

Шул минутта юк булып, бер
Күңлем иркен киңәя
Һәм татарлык җаныма бер
Фахиранә[4] көйләнә.

---

[1] *Фәхри* — макталырга лаеклы.
[2] *Сахиранә* — сихерле матурлык белән бизәлгән.
[3] *Зәррә* — тузан бөртеге, атом.
[4] *Фахиранә* — горур булып.

Бар татарлык каннарым саф
Алсу сөткә әйләнә,
Таш күңелләрем эреп бер
Чын мәхәббәткә әйләнә.

Шунда яшрен бер фәрештә —
Ак бәхет булмак булам,
Яшренеп һәм шул татарлык
Башына кунмак булам...

Шунда тәмле-тәмле уйлар
Һәм фаразларны корам,
Шунда тик бер чын бәхетле
Һәм рәхәттә утырам.

1908

АВЫЛ

Әй авыл, син мең шәһәрдән
Мең кабат ямьле вә хуш:
Бер кеше юк бер урамда...
Нинди тын һәм нинди буш.

Нинди иркен, нинди рәхәт,
Нинди бар җир гөл генә;
Синдә төн дә юк, төнең дә
Бер болытлы көн генә.

Ул кара бер күгеңә бу
Фирүзә[1] бит, бик зуры,
Күр аеңны, кайда бар бу?
Бер гаҗәеп бит нуры!

Нинди нурлар сачрәтеп ул
Уйный, нәкъ нурда йөзә,
Нәкъ көлә, нәкъ елмая, нәкъ
Юри бәгъреңне өзә.

[1] *Фирүзә* — яшел төстәге кыйммәтле асылташ.

Нинди тамчы-тамчы нурлар
Сачрәгән күк йөзенә,
Чеп-чуар чын бриллиант
Сипкәнмени, күр, үзенә.

Һәм гаҗиб[1] бер яктылыкта
Җир көмеш төсле тора:
Анда —урман да таулар,
Монда кырлар яктыра.

Синдә бар да чын матур һәм
Чын матур синдә генә,
Тагы да артыр бер матурлык
Китдисәм мин дә менә.

1908

КӨЛСЕННӘР!

Үтәр бер ел, тагын бер ел... шулайтеп
Үтәр еллар, үтәрләр юл шомайтеп[2]...
Үтәр еллар эзеннән һәм гомер дә,
Калыр тик күз яшем түглеп гомергә.

Белерләрме ачылыгын яшемнең —
Бәһале һәм кадерле иптәшемнең?
Белерләрме, йә әллә тик көлерләр?
Малайлар су итеп уйнап йөрерләр?

Йөресеннәр дә көлсеннәр! Син ак тик,
Агып бар җир йөзен капла да ят тик!
Булыр бер көн, ачык антым, торырмын,
Бөтен дөньясына ләгънәт орырмын!

1908

[1] *Гаҗиб* — шаккатырлык, искитәрлек.
[2] *Шомайтеп* — шома итеп.



Нәҗип Думави
(1883—1933)

ЯЗ

Күзне ачып карыйк әле: яз китәдер,
Фәкыйрьләрне җәфалаган кар китәдер.
Кыш буенча үлеп яткан умарта да,
Белмим нигә, терелгән күк шау итәдер.
Авылларда урам тулы хайван йөри,
Шәһәрләрдә арестаннар сазлар көри;
— Полный вода быел булыр, беләңез! — дип,
Ак сакаллы, дөнья күргән картлар йөри.
Нә гаҗәеп татлы исле урман буе!
Чәчелгән болыннарга куйлар[1] туе.
Ничә еллар[2] туңып яткан елгаларда
Аваз илә сулар ага — ярлар тулы!
Тау буйлары сызык-сызык каралганнар,
Юл буена козгыннар да таралганнар,
Ничә айлар тигез яткан иделләр[3] дә,
Дугаланып, таулар кеби кабарганнар.
Гагылдашып казлар килә кызу яктан,
Урамдагы балаларга кызык арткан:
Бу мәгъсумнәр[4] оныткан дөньяларын,—
Сизенмиләр — аяклары туңып каткан.

---

[1] *Куйлар* — сарыклар.
[2] *Ничә еллар* — ничә айлар булырга тиеш. *(Төзүче Ф. Г.)*
[3] *Иделләр* — биредә: «елга» мәгънәсендә.
[4] *Мәгъсумнәр* — балалар, сабыйлар, гөнаһсызлар.

Тайлар кебек кырын-мырын борылалар,
Кайсылары таеп китеп егылалар;
Нә гаҗәп хәл! Егълашмыйлар авыртса да,
Торалар да тагын каты йөгерәләр.
Таянганнар аксакаллар таякларын,
Шатлык кергән — кыргалыйлар тамакларын;
Айгырларын җигеп чыгып, егетләр дә
Чабып-чабып җыялар юл маякларын!

1906

ЗОЛЫМ

Дөньяны капламыштыр фетнә, фәсад[1],
Кылмага булып китте аны асат.
Котылмак мөмкин түгел, теләсәң син
Киемне тимерләрдән бөгеп ясат.
Инсанны хокукыннан аермышлар,
Гүяки ясамышлар суккан башак.
Галәмгә гыйбрәт илә күзне салмай
Гомерне уздырганнар йоклап, ашап.
Гыйлемгә акайтканнар күзләренә,
Мактату Мәкъсуд булган үзләрене.
Җәһелгә[2] пумаланы манып алып,
Халыкның буяганнар йөзләрене.
Һәркайсы язылмыштыр тарихларда,
Күрерләр гакыл түгел, кабихлар[3] да.
Гыйлемне агу диеп сөйләшкәннәр
Рухани исмен алып сабиклар[4] да.
Нәтиҗә: рәваҗ улмыш[5] җәһаләткә[6],
Әзалил[7] менеп кунмыш сиядәткә[8].
Золымнар томан кебек бу дөньяны
Каплагач, юл булмамыш гадәләткә[9].

---

[1] *Фәсад* — бозыклык.
[2] *Җәһел* — наданлык, белемсезлек.
[3] *Кабих* — әшәке, начар.
[4] *Сабик* — әүвәлге.
[5] *Рәваҗ улмыш* — таралды.
[6] *Җәһаләт* — наданлык.
[7] *Әзалил* — азгыннар.
[8] *Сиядәт* — өстенлек.
[9] *Гадәләт* — гаделлек, гадел булу.

Тынычсыз булып китмеш бәни адәм[1],
Ахырда башын салмыш хәмакатькә[2].
Асылда берлекләрен онытмышлар,
Сокланып таралмышлар инанәткә[3].
Көчлеләр таптаучылар, көчсезләрне,
Мөкатдәс корал диеп буш сүзләрне,
Ишектән тагын түбән йөреткәннәр
Күкрәге колач булган акбүзләрне.
Бу сәкыйм тарикъ[4] илә дәвам итеп,
Кәефләр теләгәнен тәмам итеп,
Оялмый суырмышлар адәм канын,
Мәйданда әһалигә гаян итеп[5].

1906

ҮТТЕ, ҮТӘ...

Аh-ваh итеп, кайгы илә сүзгә башлап,
Эчемнән хәсәдләрнең[6] барын ташлап,
Язарга каләм алсам хакыйкатьне,—
Ничек тә лязем[7] була гаеп ачмак.
Гаепне ачар булсаң, хәзер бездә
Тиештер ватаныңнан ерак качмак;
Юк исә башың бетте, үзеңне тиз
Ясарлар төбе төшкән агач башмак!
Гомерләр коштай очып узып бара,
Артыннан кара туфан чыгып кала;
Беләмсез: ахырлары ни булачак,—
Хәзергә төзәлмаслык йөрәк яна!..
Хәзергә төзәлмаслык йөрәк яна,
Ышанмасаң, сереңне сөйләп кара:
Алырсың хәрфе саен бер камчыны,—
Аннары, үзең уйла, урның кая?

---

[1] *Бәни адәм* — адәм балалары.
[2] *Хәмакать* — акылсызлык.
[3] *Инанәт* — мин-минлек, тәкәбберлек.
[4] *Сәкыйм тарикъ* — начар юл.
[5] *Әһалигә гаян итеп* — кешеләргә күрсәтеп.
[6] *Хәсәд* — көнчелек.
[7] *Лязем* — тиеш.

Һай, шатлык кебек иде үктәбердә*,
Узсалар дия идек: «Тукта, бергә!..»
Җил кебек узып китте хәзер бары,
Ышаныч юк икән шул һич ...га!**
Җибәрде ничә меңнәрне каторга!

. . . .***

Түгел бер башы кырган без такырга!..[1]

1906

МӘХБҮС[2] ДУСТЫМА

Әй бөрадәр[3]! Нәрсә күрде күзләрең тышта синең?
Һәр даим бакмакта никтер күзләрең тышка синең.

Әллә ялгызлык сине туйдырмый, бу төрмәдә
Нәрсә эзли күзләрең, нәрсә телисең күрмәгә?

Юк, туган, иләк кебек тимер рәшәткә аркылы
Бик ерак китмәс күзең, күрсәң күрерсең сакчыны;

. . . .

Чөнки ялгызлыкка калса, каплый уй һәр кемсәне.

Уйласаң уйла, ләкин итмә хата, булма габид[4];
Дуст вә ишләреңне хәтерләп кыла күрмә өмид!

---

* Сүз инкыйлабның күтәрелеш чоры булган 1905 елның октябрь көннәре турында бара. Патша 17 октябрьдә хәтта кайбер ирекләр бирү турында манифест игълан итәргә мәҗбүр була. Дөрес, алар соңыннан бетерелделәр. Кулында хакимиятне саклап калу өчен төрле боргалануларга барган җитәкчелеккә ышанырга ярамаганлыгына ишарә ителә.

** ...га — патшага.

*** Нокталардан торган юлдагы сүзләр «Казан мөхбире» газетасының 1906 ел 4 август санында төшереп калдырылган. Аларны бары тик фараз итәргә генә мөмкин. Анда «Ирек кирәк барлык милләтләргә» дип язылмаган идеме икән? *(Төзүче Ф. Г.)*

[1] *Без такырга* — такыр башлыларга; татарларны, көлеп, «такыр башлар», «гололобый» дип йөрткәннәр. Шуңа ишарә.

[2] *Мәхбүс* — тоткын.

[3] *Бөрадәр* — туган.

[4] *Габид* — надан.

Ул иректәге дуст-ишләрме? Алар бит хөр алар,
Дөньяда тормакка эстәр[1] чын кеше бит тик алар.

Башкасын куеп хәзергә, иң якын дустың сүзен
Тәмсил[2] өчен монда язам, калганын уйла үзең.

Син, теләсәң, чер, корып бет, ал сулыш көчкә генә;
Бар гаеп аның үзендә дип куяр кыска гына.

1912

СУГЫШ

Ни хәл бу? Капланган көррәи арыз[3]
Кан белән, буялган төтенгә.
Бу нинди? Нинди бу? Ничек барыш?
Ни төсле өмид яктумгә[4]?

Шартлады пулемет, авыр туплар,
Кан ага монда һәм тегендә;
— Илаһи ярдәм! — дип улый поплар
Корышкан куллагач[5] төбендә.

— Безнеке җиңсен!—дип, муллалар да
Кул җәеп фатиха бирәләр...
Кызганыч, егетләр шыр далада
Тилмереп, иңерәп үләләр...

Очлы штык без кебек кереп китә
Адәмнең йомшак тәненә,
Генерал йөрәге пыт-пыт итә
Булачак медальнең тәменә.

Кылычлар чыкырдап барып тия,
Ит ярып эчтәге сөяккә.
Каты пуль выжгыйлап барып керә
Маңгайга яисә иякккә.

---

[1] *Эстәр* — тели торган.
[2] *Тәмсил* — мисал.
[3] *Көррәи арыз* — җир шары.
[4] *Ни төсле өмид яктумгә* — нинди өмет бар билгесезлеккә.
[5] *Куллагач* — куллы агач; тәре дигәнне аңлата.

Тегендә егыла, монда ава,
Канына күмелеп солдатлар.
Туктаусыз яңгыр күк пуля ява,
Чыдамый чинаша һәм атлар.

Анда ут, монда ут — тәмуг кебек
Ялтырый, гөрелди, шалтырый;
Җир өстен каплаган канлы күбек,
Басарга аяклар калтырый.

Монда баш, анда кул җәйрәп ята,
Тегендә кабырга, тез башы;
Солдатым белмидер кайда ата,
Күргәзми — качынган йөз-башы.

Сөйләргә бик җиңел, әмма барып
Күрсәңез, еламый түзмәссез!
— Сугышлар бетсен! — дип, Гаагая
Йөрүче[1] кешеләрдән бизмәссез.

— Бетмәсен, югыйсә адәм үрчи,
Диюче — ялганчы сатлыклар!
Әйтеңез, булмаса, нәрсә борчый?
Булганда — сезгә ни шатлык бар?

1908

СИН — КЕШЕ!

Бирмә серне, бул гали — типсен йөрәк зурлык белән!
Булма мәхзүн[2] — сынма төшенкелек белән, хурлык белән!

Бирмә тезгенне кара көчләргә — булма кол кеше!
Бул — батыр! Бул — нык кеше! Бул — ир кеше! Бул — хөр кеше!

Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын?
Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!

Син — бөек! Салган Ходай күктән сиңа үз орлыгын.
Бул — гали! Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык» зурлыгын!..

1916

---

[1] *Гаагая йөрүче* — 1899 һәм 1907 елларда, Гаага шәһәрендә тынычлыкны яклап, конференцияләрдә катнашучылар күздә тотыла.

[2] *Мәхзүн* — кайгылы, моңлы.

СУГЫШ ТӘЭССОРАТЫ[1]

1

Кычкырмачы, карга, баш янымда,
Китче, зинһар, миннән арырак!
Күрмисеңме канны як-ягымда,
Куллар мәҗрух[2], тездән юк аяк?
Тынды туплар, тынды пулеметлар,
Мылтык таушы ауды сул якка;
Сугыш күчте моннан, сүнде утлар,
Югал, карга, син дә шул якка.
Карап торма миңа күзең терәп,
Сулыш алыйм — нинди тын кичә!
Куркам, вәхши карга, явыз йөрәк,
Китмәссең дип каным эчмичә.
Җәрәхәтем авыр, рухым төшкән,
Тынлык тели җаным кич белән.
Күрәм: канлы күзең канга төшкән,
Кызганмасаң аша, эч, бирән!

2

Еглама, балам, ник егълыйсың,
Күз яшеннән безгә ни файда?
Гомер буе егълап ник тормыйсың —
Кызганмаслар, булма дивана!
Заман халкын кара — нинди эштә,
Шунда хәят сиңа, шунда көн.
Алар нишли — син дә шуны эшлә,
Залим булсаң бул, тик булма кол!
Хаклык, вөҗдан диеп торма, балам,
Җир йөзендә көн юк аларга;
Юл киссәләр, юл кис, урла, балам,
Җыенсалар — җыен таларга.
Елга-елга булып ага каннар,
Ычкындырма кулдан мылтыкны;
Шунда сиңа «егет» диерләр,
Кызганмыйча када штыкны!

1916

---

[1] *Сугыш тәэссораты* — сугыш тудырган хисләр, тәэсирләр.
[2] *Мәҗрух* — яралы.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ ХӘЗРӘТЛӘРЕНЕҢ КАБЕРЕ ЯНЫНДА

Нинди тәэсирле күңелгә мондагы кабер яны,
Чөнки мәдфүн[1] монда милләтнең бөек каһарманы.

Без онытмыйбыз сине, әй мөхтәрәм карт пәдәремез[2]!
Рәхәт булсын җаныңыз һәм нурлы булсын кабереңез!

Сез вафат җисмән[3], мәгәр мәгънән[4] әбәд[5] вафат түгел;
Сезне мактый, сезне тәкъдир әйли[6] һәрбер пакь күңел.

Күп терекләрдән мөкатдәм[7], әле дә сез остаз әле,
Күп терекләрдән гыйлем бабында[8] сез мөмтаз[9] әле.

Һич югалмас дөньядан, юлбашчы ул асареңез[10];
Булмаган үз гасрыңызда мислеңез[11], әмсалеңез[12].

Түктеңез күп бабта[13] көч һәм кылдыңыз күп иҗтиһад,
Сез бит ул чакларда ялгыз ачтыңыз гыйльме җиһад[14].

Инде уйганды бу милләт тә, хәзер аңлый ала,
Яхшыны тәкъдир итә һәм данлыны данлый ала.

Һич онытмас сезне милләт, истә һәрбер хөснәңез[15],
Бәс, югалмас дөньядан ул шанлы, данлы исмеңез!

Без онытмабыз сине, әй мөхтәрәм карт пәдәремез!
Рәхәт булсын җаныңыз һәм нурлы булсын кабереңез!

1912

---

[1] *Мәдфүн* — күмелгән.
[2] *Пәдәр* — ата.
[3] *Җисмән* — физик яктан.
[4] *Мәгънән* — мәгънә ягыннан.
[5] *Әбәд* — мәңге.
[6] *Тәкъдир әйли* — таный.
[7] *Мөкатдәм* — алда.
[8] *Бабында* — ягыннан.
[9] *Мөмтаз* — өстен.
[10] *Асареңез* — әсәрләрегез.
[11] *Мислеңез* — охшашыгыз.
[12] *Әмсалеңез* — тиңдәшләрегез.
[13] *Бабта* — эштә, өлкәдә.
[14] *Гыйльме җиһад* — сугыш фәне.
[15] *Хөснәңез* — күркәмлегегез.

ТАТАР[1]

Караңгылык тора каплап татарны,
Качан[2] да булса бер таңы атармы?
Атар да бер таңы, нурын чәчәрме?
Татар да бервакыт күзен әчәрме[3]?
Татар да кузгалыр, алга йөрерме?
Бу күзләр шундый көнне бер күрерме?

Дөрест, бик зур өмид бар алгы көндә —
Алгы көннән алгы көннең алгысында.
Ләкин булмый белеп: ул көн җитәрме?
Татар алга китәр әллә бетәрме?

Шаярма, тукта, углан, куй татарны!
Татар димсең, татармы ул, татармы?
Беләмсең, нинди зур, нинди бер ат ул?
Шаярма син татар берлән, ерак бул!

Татарда юк дисеңме шәп адәмнәр?
Җитәрлек мәдрәсәдә пишкадәмнәр[4].
Татарда юк дисеңме шәп ишаннар,
Тавык тозлап тутырган мичкә, шаңнар?
Татарда һәм җитәрлек имамнар —
Бөтен гомрен бәлеш берлән тәмамлар.

Татарда бар хәзер һәм шундый яшьләр —
Аларда мәгърифәтнең яшене яшьнәр.
Шуның өчен күп хәзер шундый егетләр —
Күзен йомган көе алга мәтәкләр.
Шулар торса булып безнең татарда,
Кирәкмәс инде юкка баш ватарга!

1914

---

[1] Шигырьгә исем төзүче тарафыннан бирелде. *(Төзүче Ф. Г.)*
[2] *Качан* — кайчан.
[3] *Әчәрме* — ачармы.
[4] *Пишкадәмнәр* — зур яшькә кадәр укыган шәкертләр.

ҮТӘ ЯШЬЛЕК

Үтә айлар, үтә еллар, үтә хөрмәтле яшь гомрем;
Ниләрне тик өмид кылмый хыялланмакта яшь күңлем.

Үтә көннәр илә төннәр дә искән җил мисалында[1],
Ләкин сизми күңел: һич туктамастан үз хыялында.

Күрер төсле күңел истикъбалендә[2] күп сәгадәтләр[3],
Ләкин очмакта бер-бер артлы бушка җанлы сәгатьләр.

Үтәләр бушка иң якты, мөкатдәс, көчле минутлар,
Сүнәләр төптә юкка яшь йөрәктән чаткылар, утлар.

Сизәм мин: йомшый дәрт, бетмәктә гайрәт һәм дә япьтәшле;
Сизәм: аһ, мәңгегә миннән китә, саубуллаша яшьлек.

Беләм: салмак күңел талпынмый ямьнәргә дә тәмнәргә.
Беләм: ямьнәр дә тәмнәр күчтеләр инде бүтәннәргә.

1913

---

[1] *Җил мисалында* — җил кебек.

[2] *Истикъбалендә* — киләчәктә.

[3] *Сәгадәтләр* — бәхетләр.

Галиәсгар Камал
(1879—1933)

БАНКРОТ[1]

ПЬЕСА

3 пәрдәдә

ӘШХАС[2]:

Сиражетдин Туктагаев — заһирдә бик суфи[3] күренә торган сәүдәгәр.

Гөлҗиһан — Сиражетдинның хатыны.

Җамалетдин Туктагаев, Камалетдин Туктагаев — Сиражетдинның бертуган карендәшләре.

Нәгыймә — им-том итеп йөри торган карчык.

«Туганым» — Гөлҗиһанның карендәш тиешле кешесе.

Гарифә, Мәликә — кунаклар.

Мөхәммәтҗан 1 нче, Закир — кибетчеләр.

Мөхәммәтҗан 2 нче — кибетче малай.

Гарәфи — Сиражетдинның юлдашы.

Хәмди — асрау.

Доктор һәм Москва доверенныйлары.

---

[1] Кыскартып алынды.

[2] *Әшхас* — катнашучылар.

[3] *Заһирдә бик суфи* — тыштан бик изге.

Вакыйга Казанда.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сираҗетдин Туктагаевның йорты. Яхшы итеп җыештырылган, байсымак бер өй. Сул якта кантор өстәле, аның янында бер шкаф, уң тарафта диван, өстәл, креслолар. Стена буенда урындыклар, көзгеләр, ике тарафта һәм түрдә ишекләр, ике як-янда тәрәзәләр. Пәрдә ачылганда сәхнәдә бер кеше дә юк.

Сираҗетдин *(ишектән бик кызуланып кереп, як-ягына каранып).* Бик яхшы булды әле, бер кеше дә юк икән. *(Өстеннән намаз тунын салып ташлап.)* Бер дә шаулама, эшләрнең һәммәсе дә минем файдага баралар әле. *(Кесәсеннән бер гәзитә чыгарып.)* Менә бүген дә бик шәп хәбәрләр язганнар әле. *(Укый.)* «Астраханнан менеп килә торган «Кавказ-Меркурий» пароходының беренче классында килә торган юлчы — Тарабаров исемле бер бай — өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән. Аның белән берничә мәртәбәләр чәйләр эчеп һәм бергә ашап килгәннәр. Кич белән чәй эчкән вакытта теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган дару салып эчерткән. Тарабаровның һушы китеп егылгач, янында алып бара торган унбиш мең сум акчасын алып, өстеннән каютын бикләп, үзе бер пристаньда төшеп калган». Шәп иткән бит, ә, Тарабаров йоклаган диген, ә? Йоклаган шул, йоклаган. Бигрәк аңгыра нәрсә икән. Хәзерге заманда шулкадәр күп акчаны үзең белән бергә юлга алып чыгарга ярыймы соң? Җүләр нәрсә, аны алдан сандыкка салып, кладавайга бикләп китәргә ярамаган икән. Кладавайга бикләп киткән булса, бер дә югалмас иде. Җүләр икән шул, җүләр. Җүләрне чәчеп үстермиләр аны, ул үзе үсә. Ну, ярый, бик шәп булды әле, бу да бик шәп. Ярый, үземезчә гәзитәләр чыгуның файдасын быел ук күрдем. Үземезчә гәзитәләр чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгара алыр идем? *(Гәзитәне шкаф астына куя да, аннан бер кочак гәзитә чыгарып.)* Менә алар монда никадәр! Боларның һәммәсендә дә шундый хәбәрләр тулып ята. Мин аларның монда талаучылары бер дә тотылмаганнарын гына сайлап җыеп куйдым. Миңа аның талаучылары тотылганнарының кирәге дә юк. Мине талыйсылары да юк, һәм минем үз янымда акча йөртәсем дә юк. Янымда акча йөртергә мин җүләр түгел. *(Гәзитәләрне тыгып куеп.)* Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз әле. Сез минем өчен бик кадерле нәрсәләр. Сез миңа

никадәр зур гакыл бирдегез. Сез биргән гакылны шайтан үзе дә эзләп таба алмас. Коры көе генә, турыдан-туры гына, зарар иттем, кеше өстендә алачакларым бик күп китте-фәлән дип кенә шартлап[1] булмый. Алай итеп кенә мәскәүләргә сумына ун-унбиш тиен генә биреп булмый. Аның мудасы да беткән, ышанмыйлар да. Ә болай булганда үзләренең дә күзләре алакаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар. Ну, болай монда вакыт уздырып, озаклап торырга ярамый, тизрәк банкыга барырга кирәк. *(Шкаф астыннан бер кечкенә саквояжны чыгарып һәм аңа берничә төргәк кәгазьләрне салып.)* Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз. Сезнең һәрберегез бишәр йөз сумнан — барысы 49 мең тәңкә акча, ди. Ну, инде вакыт җитә. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Сәгать унбер булган, озакламый поезга төшәргә вакыт җитә. Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм! Кая, син, бире кил әле!

Гөлҗиһан *(ишектән кереп)*. Ай Алла, син кайткансың да икән. Мин белми дә торам. Теге якта, сиңа юлга булыр дип, кәтлит пешереп ятадыр идем.

Сиражетдин. Мин хәзер банкыга барам, аннан акча алып кайтам, поезга төшәргә вакыт җитә, син нәрсәләрне тизрәк хәзерләп куй. (...) Мин хәзер кайтам, мин кайтуга һәммә нәрсә дә хәзер булып торсын... *(Чыгып китә.)*

Гөлҗиһан. Әй, харап булдым, сорарга да оныттым. *(Ишеккә тиз генә барып, ишекне ачып.)* Кара әле, сиңа әйтәм, нинди көрпәне куйыйм, зурнымы, кечкенәнеме? Юрган куйыйммы, адиялмы? *(Ишекне ябып.)* Йә, ярар инде, ишетмәде. Әле онытмаска кирәк, Мәскәү өстендә[2] бер-ике табын хатыннар уздырып алырга кирәк. Инде мәҗлес уздырмаганга әллә никадәр булды. Мәкәрҗә өстеннән бирле бер табын да мәҗлес уздырганым юк. (...)

Асрау *(ишектән кереп)*. Абыстай, Нәгыймә әби килгән, монда гына чыгып керсен әле, ди.

Гөлҗиһан. Ярар, хәзер чыга, диген. *(Асрау чыгып китә.)* Мәскәү өстендә тамыр кайнаттырып эчә торган идем. Шуны кайнатып бирергә дип килгәндер әле. *(Чыгып китә.)*

Сиражетдин *(ишектән кызуланып кайтып кереп, өстен чишенеп ташлап)*. Һәммәсе дә мин теләгәнчә булды. Барысына да бишәр йөз сумлык акчалар алдым. «Андый акчалар ни эшкә

---

[1] *Шартлау* — бөлү, банкротка чыгу.

[2] *Мәскәү өсте* — «ире Мәскәүгә киткән вакытта» мәгънәсендә.

кирәк соң алар?»— диләр. «Акчаны үзем белән алып барам, шуның өчен кирәк»,— дигән булам. Фидыр Иваныч әйтә: «Айһай, Сиражетдин Гыйлаҗетдинович, хата кыласың икән. Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү апасны бит, пиравaт белән генә җибәрергә кирәк иде»,— ди. *(Өстәл тартмасыннан әллә нәрсә эзли.)* «Ничава,— дим,— Алла кушмаган эш булмас,— дим.— Мин бит мөселман кеше,—дим.— Мөселман кеше ул андый юк-бар эштән курыкмый»,— дим. Миңа нигә куркырга? Аны кладавайдагы тимер сандыктан кем килеп урлый ала? *(Өстәл тартмасыннан ачкыч алып, саквояжны шкафка куеп, кесәләрендәге акчаларны бераз чыгарып, яңадан тыгып куеп.)* Әйдәгез әле сез, акчалар, мин кайтканчы кладавайда бик һәйбәтләп, тынычлап кына ятып торыгыз әле. Эшне төзәтергә бәлки сез артыгы белән җитеп торырсыз. *(Чыгып китә. Гөлҗиһан белән Нәгыймә керәләр.)*

Нәгыймә. Мин Сиражетдинны киткәндер дип белгән идем, ялгыш иртәрәк килгәнмен икән.

Гөлҗиһан. Килсәң ни булган, син аннан кача торган кеше түгел бит.

Нәгыймә. Әйе шул, кызым, ә Сиражетдин бит ул минем балам шикелле кеше. Рәхмәт инде аңа, мине һичбер вакытта да хәтереннән чыгармый. Зәкятыннан[1] да, нәзер-ниязларыннан[2] да һичбер вакыт коры калдырмый. Әле узган Мәскәүгә баруында да: «Мә, әби, Хуҗа Баһаветдин[3] рухына багышлап дога кылырсың»,— дип, илле тиен садака биреп киткән иде. Җылый-җылый хәер-догалар кылдым, рәхмәт яусын инде аңа. Дәүләтенең дөнья вә ахирәт игелеген күрсен. Мин һәрвакыт догада гына торам. Безнең шикелле ятим карчыкларны зурлаган өчен инде аны Алла үзе зурласын.

Гөлҗиһан. Амин!

Нәгыймә. Кызым, инде «садака бирде» дигәч тә, мин аны болай гына әйтәм. Син тагы «бүген дә шулай садака өмет итеп килгән икән» дип уйлый күрмә. Аннан-моннан әйтүем түгел. Инде моңа кадәр биргәннәрен дә Алла үзе кабул итсен. *(Асрау керә.)*

---

[1] *Зәкят* — дини налог; сәүдәгәрләр килеренең 40 тан бер өлеше, башкаларныкыннан 100 дән бер өлеше алына торган салым.

[2] *Нәзер-нияз* — дини йола; бирәр теләккә ирешү өчен дога кылдыру.

[3] *Хуҗа Баһаветдин* — XIV гасырда яшәгән суфи, изге кеше.

Асрау. Абыстай, син ул чебешләрне кайсы кәрзинкәгә салырга дип әйткән идең?

Гөлҗиһан. Кайсы кәрзинкәгә булсын, капкачлы түгәрәк кәрзинкәгә. Кеше әйткәнне яхшылап колагыгыз белән тыңламыйсыз да, аннан ары тик миегез череп йөри. Күлмәкләрне хәзерләдеңме?

Асрау. Юк әле.

Гөлҗиһан. Һи, аңгыра нәрсәләр! Хәзер бит абзаң кайтыр вакыт җиткән. Бакзалга төшәргә кызуланып йөри. Үзең карамасаң, бер эшне дә җүнләп эшләүче кеше юк. Нәгыймә абыстай, син бераз утырып тор әле, мин чыгып шул нәрсәләрне генә рәтләп керим әле.

Нәгыймә. Ярар, кызым, бар, бар. Минем өчен эшеңнән кала күрмә. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)*

Нәгыймә. Биргән кешегә Алла бәхетне учлап биргән. Бирмәгәнгә бер тиен дә юк. Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде. Аз арада гына нинди баеды да китте. Әүвәлге йорты да нинди яхшы һәйбәт йорт иде. Базарга йөрергә ерак дип, ансын сатты. Хәзер инде Сираҗи зур пулатлы бай булды. Хәзер инде Сираҗиның ялтыраган көмеш көпчәкле ризиновыйларда киерелеп утырып йөргәнен күрсәң, танымассың да. Ризиновыйларның көпчәкләре җылык-җылык итеп тора. Карарга күз чагыла. Ризиновыйның шиннәре бүрәнә җуанлыгы бар. Мескен Сәлимә генә бу рәхәтләрне күп күрә алмады. Үлеп китте. Берәү үлә, икенчеләре көн күрә. Ни эшләмәк кирәк соң, әҗәлдән котылып калыр хәл юк шул. Берәүнең бәхетенә икенче кеше керә алмый. Яшь хатын бәхете инде. Бичара Сәлимә бик яхшы хатын иде. Килгән саен учлап-учлап чәй-шикәрләр биреп җибәрәдер иде. Куркулыкларны[1] да бик еш койдырадыр иде. Хәер, әле Гөлҗиһан да минем өчен файдасыз түгел. Әледән-әле тамырлар кайнаттырып ала. Тукта әле, мин тагы бу якта утырып, авызымны ачып юл садакасыннан колак кагып калмыйм. Сираҗи китеп-нитеп бармасын. Чыгыйм әле. *(Чыгып китә.)*

Сираҗетдин *(ишектән кереп, язу өстәле янына барып, кечкенә дәфтәрне өстәл тартмасына салып).* Инде эш тәмам булды. *(Ишек янына барып.)* Кара әле, сиңа әйтәм. Бире кара

---

[1] *Куркулык* — кеше авырганда, берәр нәрсәдән курыккан дип, шул авыру янында кургашын эретеп салу.

әле. *(Гөлҗиһан керә.)* Нихәл, нәрсәләрне хәзерләп бетердеңме? Миңа китәргә вакыт.

Гөлҗиһан. Хәзерләдем.

Сиражетдин. Бик яхшы алай булса. Кая, миңа бик яхшы таза аякчулар китер әле.

Гөлҗиһан. Ни эшлисең ул аякчулар белән? Мин кичә генә ак аякчулар биргән идем бит.

Сиражетдин. Бар әле син, тизрәк китер. Пуезга соңга калам. Ни эшкә икәнен соңыннан күрерсең. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)* Эшне шулай итеп бик ныгытып пешереп эшләргә кирәк. Бер дә кеше шикләнерлек булмасын. *(Шкафтан саквояжны алып.)* Менә болар инде акчалар, ди. Аларны югалмасын өчен бик яхшылап балтырларга чорнарга кирәк. *(Аякларын чишенә башлый.)* Бераз йөрәк сикерә сикерүен дә, шулай да булса серне бирергә ярамый. Нык торырга кирәк. *(Каты гына итеп тамагын кырып, киемнәрен төзәтеп, үзенә канәгатьле бер кеше кыяфәте биреп куя.)* Менә шулай. Бер дә серне бирмә, нык тор. *(Гөлҗиһан керә.)*

Гөлҗиһан. Менә аякчулар китердем. Бу аякчуларың да ак иде әле.

Сиражетдин. Мин сиңа әйттем бит, соңыннан аңларсың дип. Менә бу кәгазьләр акча булыр. Боларда кырык тугыз мең тәңкә, аңладыңмы? Кырык тугыз мең, кырык тугыз мең тәңкә акча бар.

Гөлҗиһан. И Ходаем! Кая әле? *(Бер төргәкне алып, ачып карамакчы була.)*

Сиражетдин. Чү-чү-чү! Тия күрмә! Мин аларны бик ыспайлап юка итеп төреп куйдым. Чуалтма. *(Төргәкле кәгазьләрне ала. Халыкка карап.)* Бөтенләй эшне боза язды. *(Гөлҗиһанга.)* Менә аларны шушылай итеп, бик һәйбәтләп читек балтырына батырабыз. *(Төргәкләрне икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый.)* Бар, син, кара әле, ишекләр яхшы ябылганмы? Анда ишек ярыгыннан карап торучылар булмасын!

Гөлҗиһан *(ишекләрне барып карап)*. Юк, бернәрсә дә юк, һәммәсе дә бик яхшы ябылган. Кара әле, сиңа әйтәм, соң ул акчаларыңны читек балтырыннан төшереп югалтып, харап булмассыңмы? Әллә ни эшләп күңелем шикләнә. Шул саквояжга гына салсаң, тагы да яхшырак булмасмы? Бу саквояжның биге дә бар.

С и р а җ е т д и н. Һи, хатын, хатын, синең бер дә башың йөрми икән. Соң шул саквояжны урласалар? Ул вакытта ни эшләрсең? Ул бит кечкенә нәрсә, күтәрерләр дә алып чыгып китәрләр. Ә син акчадан колак кагып калырсың.

Г ө л җ и һ а н. Хәер, инде ансын үзең беләсең. Шулай да ул кадәр күп акчаны читек балтырына гына кую, әллә ничек, бик куркынычлы шикелле тоела.

С и р а җ е т д и н. Тәкъдирдә язылмаган булса, бернәрсә дә булмас. Бая банкыда Фидыр Иванич та шулай дип әйткән иде. Мин әйттем: «Мин мөселман кеше, тәкъдиргә ышанам»,— дидем. «Ето, дидем, судба, дидем. Судбада язылмаса, бернәрсә дә булмас»,— дидем. Фидыр Иванич башын селкеп, бик гаҗәпләнеп калды. *(Киеп бетерә.)* Нихәл, бик җуан булмадымы? Тыштан бик беленеп тормыймы?

Г ө л җ и һ а н. Юк, алай зарарлы түгел, бик беленми.

С и р а җ е т д и н. Кая инде алайса, әйберләрне чыгарсыннар. Поезга төшәргә вакыт, Закирны дәшсеннәр, әйберләрне күтәреп чыгарыр. Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә. Бу чагында бер дә кешегә ышаныр хәл юк.

Г ө л җ и һ а н. Алла үзе сакласын. Кешегә сөйләргә мин җүләр түгел.

С и р а җ е т д и н. Бар әйт, тизрәк нәрсәләрне чыгарсыннар!

Г ө л җ и һ а н *(ишекне ачып)*. Кая, абзагызның багажларын чыгарыгыз! *(Ишектән асрау белән Закир багажларны күтәреп керәләр.)*

З а к и р. Абзый, менә шулай итеп бәйләгән идем, ярармы? (...)

С и р а җ е т д и н. Ярый, бик яхшы. Закир, бар син тизрәк әйберләрне атка чыгарып сал. *(Закир күтәреп чыгып китә.)* Йә, әйдә, Аллага тапшырдым инде, дога кылыйк. (...)

Г ө л җ и һ а н. Йә, ярый. *(Дога кылырга утыралар.)*

Н ә г ы й м ә *(акрынлап ишектән кереп)*. Ярабби Ходаем, тәүфикълы, талигале[1] гомерләр насыйп ит. Байлык, шатлык белән көн күрергә, шатлык, рәхәтлек белән йөреп кайтырга насыйп булсын. *(Урындыкка утыра. Дога кылалар.)*

С и р а җ е т д и н. Исәнме, Нәгыймә абыстай? Син монда идеңмени?

---

[1] *Талигъ* — бәхет, яхшы киләчәк.

Н ә г ы й м ә. Әйе, улым, монда. Син Мәскәүгә китә дигәч, күрешеп калыйм, дидем.

С и р а җ е т д и н *(кесәсеннән бер көмеш акча чыгарып биреп).* Яхшы, Нәгыймә абыстай. Хәер-фатихада булыгыз инде.

Н ә г ы й м ә. Рәхмәт, улым, рәхмәт. Сәламәтлек, шатлык, куанычлык белән күрешергә насыйп булсын. Бай бул, улым! Баеп кайт. Минем шикелле ятим карчыкларны куандырган өчен, сине Алла үзе куандырсын.

С и р а җ е т д и н. Хуш инде, әби, хуш, Гөлҗиһан. *(Гөлҗиһан белән күрешә.)*

Н ә г ы й м ә. Хуш, улым, хуш. Исән-сау йөреп кайт. *(Сираҗетдин чыгып китә, Гөлҗиһан озата чыга. Кесәсеннән акчасын алып карап.)* Ярый, ярый, хәерле сәфәр булсын. Бөтенне яудырган икән. Ахры, бу араларда файданы яхшы итә башлагандыр. Гөлҗиһан керсен дә инде, аннан ары акрынлап кайтырмын. Бәлки тамыр кайнатырга акча да бирер әле. *(Гөлҗиһан кереп, тәрәзә саен карый.)* Нихәл, кызым, озаттыңмы? Ярый инде, сәламәтлектә, шатлыкта йөреп кайтсын.

Г ө л җ и һ а н *(тәрәзәдән башын алып).* Киттеләр. Мәскәү өстендә дүрт-биш табын хатыннар уздырып алырмын дигән идем. Үзеннән сорап калырга аз гына хәтеремнән чыкмаган, озата чыккач, өйалдында гына исемә төште. (...) Әйдә, Нәгыймә абыстай, теге якка, чәй эчәрбез. Аннан, сиңа тамыр кайнатырга акча да биреп җибәрермен. Берсекөнгә ашка син дә килерсең. Онытма, йәме?

Н ә г ы й м ә. Ярар, кызым, ярар. *(Тора башлый.)* Алла! Ай! Билләрем авырта. Картлык. *(Чыга башлыйлар.)*

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге зал. Ак эскәтерләр ябылган өстәлләр хәзерләнгән. Түрдәге сәгать икенче ярты булган.

Н ә г ы й м ә *(ишектән чирекле шешә белән саргылт төстә сыек бернәрсә күтәреп кереп).* Уф Алла, арып беттем. *(Шешәне урындыкка куеп, башыннан шәлен сала.)* Бүгенге мәҗлескә килгәнче тизрәк өлгерсен дип алып килдем. *(Шешәне селкетеп.)* Йөзе кара, бер дә күбекләнми. Тизрәк әчесен, тизрәк төнәсен дип, трахтир сырасын ике шешә итеп салган идем, алай

да әле әчеп җитмәгән. Монысы кыйммәткә төште: егерме тиенгә тамыр алдым, ике шешә трахтир сырасы, ярты кадак шикәр салдым. Мин кайнаткан тамырны бай хатыннары бик яраталар: «Синең кулың бик шифалы, эчеп җибәргәч тә, бөтен тамырларга китә, тәмам изелдереп йоклата»,— диләр. Трахтир сырасын күбрәк салсаң, аның өстенә актан да бераз тамызсаң, йоклату гына түгел, җырлатыр да ул. *(Шешәне алып.)* Тукта әле, моны кая булса да бер җиргә яшереп куярга кирәк. Йә кунаклары-ниләре килеп күрерләр. Бай хатыннары алар бер дә серләрен кешегә сиздерәселәре килми. *(Шешәне диван астына яшереп.)* Аларның баш ярылса — бүрек эчендә, кул сынса — җиң эчендә була. *(Икенче ишектән чыгып китә.)*

Г ө л җ и һ а н *(«Туганым» белән ишектән кереп).* Туганым, зинһар инде син булыша күр. Бер дә күз-колак булырлык, булышырлык кешем юк. Син, зинһар инде, шунда рәтләп, кунакларны карап утырта күр. Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше. Түбәнгә калдырсаң, күзенә күренгән бер кешене дә калдырмас, һәммәсенә сөйләп йөрер. Аны менә бу табынга, түргә утыртырсың.

«Т у г а н ы м». Ярар, ярар.

Г ө л җ и һ а н. Аннан ары, аның менә бу ягына Гариф хаҗи хатыны Мәликәне утыртырсың. Аларның икесенең бер-берсе белән серләре бик килешә. (...)

«Т у г а н ы м». Ярар, ярар.

Г ө л җ и һ а н. Әнимай Ибрае, Самавыр Кәрим, Кылтын Гарәфи, Чатан Хафиз хатыны шикелле бертөрлерәк кешеләрне теге якка табынга утыртырсың; аларга өстәл булмаса да ярар. Үзләре дә әллә кем түгел әле. Әнимай Ибраеның хатынын бөтенләй чакырмыйм да дигән идем әле, үзенә кардәш тигәнгә күрә, чакырмый калырга яхшысынмадым. Беркөннәрдә кызлар җыены җыйган, шунда, күршедә тора торып, мине утыртып калдырган. Бөтенләй минә җен ачуларым чыкты.

«Т у г а н ы м». Тумачи җиңгине кайда утыртыйм?

Г ө л җ и һ а н. Тумачи җиңгиләр, Апак абыстайлар — алар үз кеше. Алар, урын булса, теге якка утырырлар, урын булмаса, тагы калып та торырлар. Соңыннан утырырлар. Камилә туганым да теге якка табынга утырыр. И валлаһи, бу асрауларга ышансаң, һичбер эшне юньләп эшләмиләр. Кара инде бу урындыкларны, чат тузан. Өй җыештыруларының һичбер эләтагы юк. *(Ишекне ачып.)* Хәмди, кая, миңа бер кара сөлгеме, чүпрәкме бир!

«Т у г а н ы м». Фатыйма тудык кайда утырыр?

Г ө л җ и һ а н. Фатыйма тудык? Һә! Борын астыннан китеп торыр әле. Мин аны чакырмадым.

«Т у г а н ы м». Ни эшләп?

Г ө л җ и һ а н. Теле бик озын, шуның өчен. *(Асрау сөлге кертеп бирә. Асрауга.)* Сезнең, ахры, инде бөтенләй күзегез үк чыккандыр. Күзегез чыккан булмаса, менә бу тузаннарны күрер идегез. Бар, эшеңдә бул! Шәрифә остабикәгә ат җибәрсеннәр.

Х ә м д и. Ярый. *(Чыгып китә.)*

Г ө л җ и һ а н *(тузаннарны сөрткәләп, сүзендә дәвам итә).* Беркөнне Нәгыймә абыстайга дөньяга килмәгән сүзләр сөйләп җибәргән. Мине бөтенләй эреткән дә череткән: бичара Сираҗи бик бәхетсез икән, бәхетле булса, ул бер дә Гөлҗиһанны ала торган егет түгел иде, ди икән. Мине, Сәлимә үлгәч, үзе өфү-төфүләр китереп, яучы җибәреп, Сираҗига ялынып барды, ди икән. Гөлҗиһан ул Сәлимә туганымның кисеп ташлаган тырнагына да торырлык түгел, өфү-төфүләр итеп-итеп, ярап тора инде шунда, дип әйтә, ди. Аллам сакласын, ашым-суымны аңар әрәм итәргә. Гомерем буена, Алла боерса, мин аны бусагамнан да атлатмам!

«Т у г а н ы м». Аның инде бер дә теле-теше тимәгән кешесе юк. Кемне күрсә, шуңа бәйләнә. Шуңа күрә үзе дә кибеп, корып беткән инде. Им-том белән генә тора. (...)

Х ә м д и *(ишектән кереп).* Абыстай, Гаян остабикәнең асравы кергән, аларның ашлары бүген микән, иртәгә микән, дип әйтә, ди.

Г ө л җ и һ а н. Син нәрсә дидең?

Х ә м д и. Бүген, дидем. Миңа биргән запискәләрендә иртәгә дип язылган, Гыймади муллаларга биргән запискәләрендә бүген дип язылган, дип әйтә, ди.

Г ө л җ и һ а н. Ул ни дигән эш икән, туганым, әгәр дөрес булса, харап булдык! Әгәр бүтән кешеләргә дә шулай дип язылган булса, хур булдык! Ул нинди эш икән! Мөхәммәтҗан мондамы?

Х ә м д и. Монда. Әле генә өндәүдән йөреп кайтты.

Г ө л җ и һ а н. Бар, әйт, монда керсен. *(Асрау чыгып китә.)* Үзең карамасаң, һичбер эшнең рәте юк. Кара инде монда, табынга тоз савыты да куймаганнар. Туганым, бар, син генә чыгып, тоз савыты гына алып керсәнә. Алакайган күзләр, шуны да күрмиләр.

«Т у г а н ы м». Ярый. Тоз савытларыгыз кай төштә?

Г ө л җ и һ а н. Шунда асраулардан сорарсың, биререлләр. (...)

М ө х ә м м ә т җ а н[1] *(ишектән кереп)*. Нихәл, абыстай, ни йомыш?

Г ө л җ и һ а н. Бирермен, өшегән авыз, сиңа йомышыңны! Күзең чыккан нәрсә! Ни эшләп Гаян остабикәнең запискәсенә «дүшәмбе көн» дип яздың?

М ө х ә м м ә т җ а н. Юк, абыстай, алай дип язмадым, «якшәмбе» дип яздым. Гаян остабикә ул үзе язу танымый.

Г ө л җ и һ а н. Ялганлама миңа, остабикә кеше ни эшләп язу танымасын.

М ө х ә м м ә т җ а н. Абыстай, валлаһи, танымый менә, билләһи, танымый. Кичә мин запискәне биргәч тә: «Син теге, лимунчы Гыйлаҗиләрдән килдеңмени?» — ди. «Абыстаң исәнме? Кечкенәләре исәнме?» — ди. Мин әйтәм: «Юк, абыстай, безнең бай хатынының баласы юк, аның баласы булмый»,— дидем. «Мин лимунчы Гыйлаҗи малае түгел»,— дидем.

Г ө л җ и һ а н *(ачуланып)*. Нәрсә? Кит моннан, йөзең кара, бар, тиз чык! Мин сине, абзаңа әйтеп, типкәләтеп чыгарырмын. *(Мөхәммәтҗан чыгып китә.)* Кара син аны! Көчегенә кадәр: «Абыстайның баласы булмый аның»,— дип, очраган бер кеше саен сөйләп йөри бит! Мин телләрегезне бик тиз кыскартырмын. Ул аны зурлары авызыннан ишетеп сөйли торгандыр әле. Мин аларны коры тотармын. Абзаларына әйтеп, һәммәсен дә кибеттән кудырып чыгарттырырмын.

«Т у г а н ы м» *(ишектән кереп)*. Туганым!! Монда гына чыгып кер әле, харап булдык! Оятлы булдык! Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең аш артыннан утыртырга бламажи[2] да хәзерләнмәгән.

Г ө л җ и һ а н. Ә, ни дисең? Ай Алла, туганым! Ул нинди сүз? Харап булдык! *(Чыгып китәләр. Зал бераз буш тора.)*

Х ә м д и *(кулына эскәтер белән тоз савыты күтәреп, көлә-көлә)*. И билләһи, кызык соң тегендә. Абыстай тетә тегендә безне тиргәп. Мине тирги, Мәрфуганы тирги, аш пешерүчене тирги. Аш артыннан утыртырга бламажи пешерелмәгән, ди. Аның өчен без гаеплемени? Йөрмәссең түшеңне киереп, калфакларыңны кәкрәйтеп! Үзенең кулыннан бер эш килми,

---

[1] Мөхәммәтҗан 2 нче.

[2] *Бланманже* — сөт, какао яки җиләк-җимеш суларына шикәр, желатин кушылып әзерләнгән һәм аш артыннан бирелә торган ашамлык.

кешене тиргәгән була. Бая тагы: «Безнең абыстайның баласы булмый»,— дигән өчен кибетче малайны куып, тиргәп чыгарган. Аның баласы булмаганга безнең нинди гаебебез бар? «Баласы булмый» дип әйтүче кеше без түгел. Абзый үзе берсәннәрдә кибеттә, кантур бүлмәсендә, Сафа абзыйга сөйләп утырган: «Минем хатынның баласы булмый, шуның өчен бер дә мәхәббәтем юк, әгәр эшләрем яхшы барса, Мәскәүдән кайткач монысын аерып, аның урынына икенче бер, бала китерә торган кыз алам, өйләнәм»,— дигән. Закир аны ишек артыннан тыңлап торган да Мөхәммәтҗанга әйткән. Мөхәммәтҗан миңа әйтте: «Безнең абыстай бала китерми икән, абзый аны яратмый икән, аны аерып икенче бер яшь хатын алмакчы була икән»,— диде. Ә абыстай монда беркөннәрне, Мәкәрҗә өстендә, абзый өйдә юк вакытта, Нәгыймә әби чүлмәк салырга килгән чакта, абзыйны гаепләп утырды: «Аның баласы булмый»,— диде. Аларның берсенә дә ышаныр хәл юк. *(Чыгып китә.)*

Гарифә *(Мәликә белән ишектән кереп, түргә утырып).* Син ишеттеңме? Алар анда нәрсә пыш-пыш сөйләшәләр?

Мәликә. Юк, мин ишетмәдем. Мин кергәч, шып тукталылар.

Гарифә. Мин кергәч тә, шулай иттеләр. Әллә нәрсә «бламажи» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Йә бламажилары оемагандыр әле. Йә җилемен аз салганнардыр.

Мәликә. Бламажилары оемаган дигәннән исемә төште, беркөнне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, авызга алгысыз чи иде, бөтенләй лычкылдап тора.

Гарифә. Андый була ул, әнә беркөнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем. Кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган. Бөтенләй менә үзе такта шикелле, үзе ике куллап сындырып булмаслык каты булган иде.

Мәликә. Читекче Таҗи дигәннән исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде. Ончы Шакир улына кияүгә биргәннәр иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалар микән?

Гарифә. Белмим, чибәрдер, сорашканым юк, каенанасының сүзен бер дә тыңламый диләр иде.

Мәликә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый дигәннән исемә төште әле, син ишетмәдеңме, тегүче Әхмәдулла хатынын аерган дигәннәр иде, чын сүз микән?

Г а р и ф ә. Чын булырга кирәк, беркөнне югары урамга кибеткә чыкканда күргән идем, кулына кәрзинкә күтәреп, бәрәңге алып йөридер иде.

М ә л и к ә. Бәрәңге димәктән, безнең дә кәбестә тозлыйсы бар иде әле, алдырырга һич җитешә алганым юк. Сез тозладыгызмы әле?

Г а р и ф ә. Тозладык, алма белән карбыз да тозладык. Кәбестәләр бик һәйбәт туры килде.

М ә л и к ә. Кавын тозламадыгызмыни?

Г а р и ф ә. Пудвалчы Әхмәтләр кавынны үзебез җибәрттерербез дигәннәр иде дә, ужулары[1] җитмәде. Карбызлар көпшәкләнеп бетәр дип, көтмәдек.

М ә л и к ә. Ул пудвалчы Әхмәтнең улы аталарын ташлап чыгып киткән дигәннәр иде, дөрес булды микән?

Г а р и ф ә. Дөрес. Аларның астында фатирда торган ямшекнең бер кызы бар икән. «Шул кызны алам»,— дип әйткән, ди. Аталары алырга риза булмагач, ташлап чыгып киткән, ди.

М ә л и к ә. Ул башы белән чыгып кая бара инде ул? Алар инде бөтен нәселләре белән шулай булып чыктылар. Әхмәтнең энесе дә аның җүнле җирдән өйләнмәде. Нигъмәтҗан күчернең кызынябыштырып чыгарды.

Г а р и ф ә. Хәзер инде кыз ябыштырып чыгару бер җола булып китте. Әле менә шул көннәрдә генә итче Вәлинең кызы тулчукчы Сабир улына ябышып чыккан, ди.

М ә л и к ә. Ай Алла, ул шулаймыни? Миңа тагы аны беркөнне Хәмидә үзләре алдылар дип сөйләгән булды.

Г а р и ф ә. Алдылар, алмый ни! Кызлары ябышып чыкмаса, Вәлиләр кызларын үзләре риза булып тулчукчыга бирерләр идеме соң? Вәлиләр алар бай кешеләр бит.

М ә л и к ә. И, бай булсалар да инде, бер дә затлы кешеләр түгел. Хатыны бөтенләй чирмеш әкәе төсле нәрсә.

Г а р и ф ә. Чирмеш әкәе дигәннән, шуны әйтим әле, теге бүрекче Гобәйдулладан калган Мәфтуха үзләрендә торган Хәйретдингә кече хатынлыкка бара, ди.

М ә л и к ә. Чынлапмы? И адәм көлкесе, адәм көлкесе! Мөгаен, аларның араларында элек тә берәр эш булгандыр. Юк исә аның хатынын, балаларын кан-яшь җылатып барып йөрмәс иде.

---

[1] *Ужу* — вакыт.

Г а р и ф ә. Йөрмәс дип, Әхмәтҗан бай хатыны карт башы белән үзләрендә торган япь-яшь егеткә бармадымыни?

М ә л и к ә. Барса да инде, аның эше икенче, аның акчасы да күп, аннан соң ул Әхмәтҗан байны яратып та тормады.

Г а р и ф ә. Ә соң Фазлый хатыны? (...)

М ә л и к ә. Ә, ул чибәр, бик матур бит! Аның әле бер дә яшь кызлардан аермасы юк. Аннан соң бит ул хатын өстеннән дә бармады.

Г а р и ф ә. Бармаса да инде, мыек чыкмаган япь-яшь егеткә баруы оят.

М ә л и к ә. Оят димәктән, кара әле, син ишеттеңме, теге Галләм, кызын марҗага җибәреп, кул эше өйрәттергән була, ди. Ничек кешедән оялмый икән?

Г а р и ф ә. Алар марҗадан гына өйрәттерәләр әле, ул хатын кеше. Әле менә Миңнебай Фатихы өйләренә бер шәкерт китертә, ди. Кызын шул шәкерт көн саен килеп укытып йөри, ди. Фатих үзе, сакалын салпайтып, шуның укытканын карап утыра, ди. «Остабикәләр бик надан, бер дә укыта белмиләр»,— дип әйтә, ди. Алладан курыкмасалар да, бераз бәндәдән оялырга кирәк иде.

М ө х ә м м ә т җ а н *(ишектән сулуы кабып йөгереп кереп).* Абыстай! Абыстай! Әй, монда юк икән. Җамали абзый кереп килә: «Бик кирәкле йомышым бар, хатын-кызлар бер читкә китеп торсыннар»,— ди.

Г а р и ф ә. Һи, мәхәббәтсез, тапкан икән йомыш йомышларга вакыт! *(Чыгып китәләр.)*

Җ а м а л и *(ишектән кереп, әрле-бирле йөгергәләп, ишекләр саен барып).* Килен! Килен!

Г ө л җ и һ а н *(ишектән кереп).* Нәрсә, абзый, ни бар?

Җ а м а л и *(сулу кабып).* Килен!.. Мин... Мин... Сезгә... Уф...

Г ө л җ и һ а н *(каушап).* Нәрсә бар? Нәрсә?

Җ а м а л и. Сираҗетдин... Сираҗетдинны... Талаганнар!

Г ө л җ и һ а н *(урындыкка егылып).* Аһ! Харап булдык! Читек балтыры!

Җ а м а л и. Әйе, әйе, читек балтыры... Менә тилиграм... Сираҗетдинның читек балтырыннан акчасын алганнар!

Г ө л җ и һ а н. Аһ!... Кырык тугыз мең!

Җ а м а л и. Ни дисең? Кырык тугыз мең? Кырык тугыз мең дисеңме?

Гөлҗиһан *(авыр сулап)*. Әйе, кырык... тугыз... мең!

Җамали. Читек балтырында кырык тугыз меңме?

Гөлҗиһан. Әйе!

Җамали. Булмас!

Гөлҗиһан. Үзем, үзем күрдем.

Җамали. Алай булса, харап булдык! Малайның башы бетте! Читек балтырында кырык тугыз мең диген, ә! Әйтеп адәм ышанмаслык сүз! Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең! *(Урындыкка утыра, бераз аптырап тора.)*

Гөлҗиһан. Үзем күрдем, бишәр йөзлек иде.

Җамали. Ах, җүләр, җүләр, соң читек балтырында кырык тугыз мең тәңкә акча йөртергә ярыймы?! Ах, җүләр, җүләр, шыр тиле икән!

Камали *(ишектән кереп)*. Абый, абый!

Җамали. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең!

Камали. Нәрсә дисең?

Җамали. Кырык тугыз мең!

Гөлҗиһан. Ах! Читек балтыры!

Камали. Нинди читек балтыры? Нинди кырык тугыз мең?

Җамали. Сираҗиның читек балтыры!.. Сираҗиның кырык тугыз мең сумы!..

Камали. Читек балтыры ни эшләгән?

Җамали. Талаганнар.

Камали. Читек балтырынмы?

Җамали. Кырык тугыз мең сумын!

Камали. Ни дисең?

Җамали. Менә тилиграм...

Камали. Мин укый белмим.

Җамали. Мин дә белмим, Вәли укыды.

Камали. Нәрсә ди, ни эшләгән ди?

Җамали. Ни эшләсен, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын талап алганнар, ди.

Камали. Кайда?

Җамали. Пуезда.

Камали. Ә үзе?

Җамали. Үзе... үзе... килен, акылдан шашкан, ди!

Гөлҗиһан. Аһ! (...)

Камали. Соң, соң, ни эшлимез?

Гөлҗиһан. Аһ!

Җ а м а л и. Белмим.

К а м а л и. Үзе кайда, ди?

Җ а м а л и. Бүлнистә, ди.

К а м а л и. Алай булгач, аны аннан алып кайтырга кирәк.

Җ а м а л и. Ие шул.

К а м а л и. Бүген үк китәргә кирәк.

Җ а м а л и. Бүген үк.

К а м а л и. Ие, бүген үк. Бүген, пуез белән. Әйдә, тизрәк китик. Тилиграмны Вәлигә укытыйк та, бүген үк китик.

Җ а м а л и. Шулай дисеңме, бүген үк дисеңме? Башым әйләнә, бернәрсә дә белмим. Ах, җүләр, җүләр! Читек балтырында кырык тугыз мең сум! Әйтергә генә ансат, кырык тугыз мең сум!

К а м а л и. Әйдә, абый, әйдә, кичекмик, китик. *(Җамалины җитәкли.)*

Җ а м а л и. Шулай дисеңме? Минем башым бер дә йөрми.

К а м а л и. Шулай дим. Әйдә, китик. Килен, хуш, сау бул. Без Сиражины алып кайтабыз. *(Чыгалар.)*

Г ө л җ и һ а н. Аһ, харап булдык! Читек балтыры! Кырык тугыз мең сум! Туганым! Туганым! Ни эшлик? Кырык тугыз мең сум! Бөлдек, беттек! Инде ни эшлим? Мәҗлес! Бламажи! Кунаклар! Хәмди! Мәрфуга! Гайниҗамал! Мөхәммәтҗан! Барыгыз, бар! *(«Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә керәләр.)*

Һ ә м м ә с е б е р д ә н. Нихәл, ни булды? Нәрсә бар?

Г ө л җ и һ а н. Барыгыз, бар! Йөгерегез! Кунакларга әйтегез! Килмәсеннәр. Мәҗлес бетте! Бөлдек, харап булдык! Һай, читек балтыры! Һай, кырык тугыз мең сум! Барыгыз, бар! Бламажи да кирәк түгел, бернәрсә дә кирәк түгел, мәҗлес тә юк! Ах, харап булдык, Сиражиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын урлаганнар. Ух! Үләм! Бетәм! *(Егыла, Нәгыймәдән башкасы Гөлҗиһан янына җыелалар.)*

Н ә г ы й м ә *(бер читкә тайпылып)*. Ай Алла, харап булдым! Бәхетсезлек! Дүрт-биш тәңкә чиертә дип торганда гына, харап булдым! Ичмаса ясаган тамыр әрәмгә китмәсен, кемгә булса да икенче бер кешегә бирермен. *(Диван артыннан чирекле шешәне алып, шәле астына кыстырып, аяк очлары белән генә басып, артына борылып карый-карый чыгып китә.)*

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Залда күп үзгәреш юк. Өстәлләр җыелган. Җамали белән Камали Сираҗетдинны җитәкләп килеп керәләр.

Җамали. Килен, килен!.. Әйдә, Камали, булыш әле, менә шунда гына утыртыйк! *(Сираҗетдинны бер эскәмиягә утырталар. Сираҗетдин, дивана кеше төсле, тирә-ягына ялт-йолт карап утыра. Ишектән Гөлҗиһан килеп керә.)* Килен, мин сезгә ничә мәртәбә әйттем, Сираҗетдинны яхшы саклагыз, өйдән чыгып китмәсен дип. Ул бит үзен бер дә белешми. Әле менә хәзер, трамвай дип белеп, утын төягән вагуннар өстенә менеп утырган да киткән. Хәмидуллалар җитәкләп китерделәр. Ул бит бернәрсә дә белми.

Гөлҗиһан. Абзый, мин ни эшләтим соң инде аны, аны бит бер дә җиңеп булмый. Бәреп җибәрә дә, чыга да китә.

Сираҗетдин *(урыныннан сикереп тора да почмакта, өстәл өстендә тора торган граммофон янына барып бора башлый. Бер колагына кулын куеп)*. Палисә, палисиски! Палисиски!

Җамали белән Камали *(урыннарыннан сикереп торып, Сираҗетдинның ике кулыннан тотып)*. Чү, чү, ни эшлисең?

Сираҗетдин. Палисиски! Каравыл! Талыйлар!

Җамали. Һай, бичара!

Камали. Чү, энем, чү, монда бер кеше дә юк, бер кеше дә!

Сираҗетдин *(итек балтырларын тотып карап)*. Таладылар! Таладылар! *(Ике кулы белән чигәләрен тотып, икенче якка таба китә. Аннан тагы җәһәтләп китеп, ишектән чыга башлый.)*

Җамали белән Камали *(Сираҗетдинны барып тотып)*. Чү, Сираҗетдин, чү, бернәрсә дә юк, бернәрсә дә! Кил, урыныңа утыр! *(Урындыкка утырталар.)*

Җамали. Менә, агай, эш! Моны ни эшләтергә инде?

Камали. Сумашушныйга менгерсәк ничек булыр икән? Ул монда киленнәрне дә борчып бетерер. Төнлә белән ялангач көенчә чыгып китеп, белешмичә, әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал.

Сираҗетдин *(халыкка таба карап, үзалдына)*. Төшәр, төшәр, суга төшәргә мин җүләрмени? Болар инде мине чынчыннан җүләр дип беләләр.

Гөлҗиһан. Абзый, шул, мин дә шунсыннан куркам. Бөтенләй төн йокыларым качып бетте инде. Аз гына бернәрсә

кыштырдый башлады исә, ул чыгып китә торгандыр дип, котым оча.

Җамали. Менә инде Мәскәү давиринныйлары гына килеп, килешеп китсеннәр, аннан соң сумашушныйга менгерсәк менгербез.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Тотарсыз капчыгыгызны! Алар килеп киткәч, ничек йөрергә икәнлеген мин үзем дә бик яхшы белермен.

Камали. Алар соң әле ни диләр?

Җамали. Бернәрсә дә әйтмиләр, кибеттәге кенәгәләрне карадылар. «Сезнең бу кенәгәләрегезне чурт үзе килсә дә аңлый алмас»,— диләр.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Аны шул алар төшенсен дип язмыйлар.

Камали. Соң син нәрсә дидең?

Җамали. Нәрсә дип әйтим, мин дә шул бернәрсә дә аңлый алмыйм, үзе булса, бик яхшы аңлар иде дә бит, хәзер исән түгел, гакылдан шашкан, дидем.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Шашкан гакылдан, шашмый ни! Мин сезнең үзегезне гакылдан шаштырырмын әле.

Камали. Соң тагы нәрсә диделәр?

Җамали. Бүген без аны барып карыйк әле, үзебез белән бер доктор да алып барырбыз, ул аның гакылдан шашканмы, юкмы икәнлеген карар, диделәр.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Ә менә монысы гына бераз күңелгә ятып бетмәде. Әгәр ул минем җүләр түгел икәнлекне белсә, эш харап. Тукта әле. Алар килгәнче, җүләрлекне ныклап күрсәтергә өйрәнә торырга кирәк. *(Аякларын бөкләп, өстәл өстенә менеп утыра.)*

Камали. Чү, чү, Сираҗетдин, ни эшлисең?

Җамали. Тимә, тимә, утырсын. Тик утырсын.

Камали. Ярый, алайса. Хуш, тагы нәрсәләр дип әйтәләр дидең, докторга күрсәтербез дип әйтәләр дисеңме?

Җамали. Әйе, докторга күрсәтербез, ди. Әгәр дә доктор авыру дип әйтсә, бераз скитке ясап булса да килешербез, диләр. Кибеттәге малларны да бер кат карап чыктылар. Малы бик аз калган икән, диләр.

Камали. Соң син нәрсә дидең?

Җамали. Нәрсә дип әйтим, бары шунда инде, дидем. Менә бит сезгә бирергә дип малны акчага алмаштырып бетергән иде дә, хәзер инде акчасыз да, малсыз да калган, дидем.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Бер дә хафаланмагыз, акча ерак түгел, кладавайда гына. Ачкычы менә монда, кесәдә генә.

Гөлҗиһан. Соң инде, абзый, без шулай бер тиенсез бөлеп калырбыз микәнни? И Ходаем! Бар икән күрәселәребез! *(Елый.)*

Камали. Хафаланма, килен, хафаланма. Алла язмаган эш булмас. Сираҗетдинның болай булуы безнең өчен дә бер дә күңелле түгел.

Гөлҗиһан. И Ходаем, күңелле генә итеп аш уздырам дип йөргәндә генә бөтен эшләр чуалды да китте.

Камали. Килен, анысы бик зур эш түгел. Сираҗетдин терелсә, бар да булыр әле.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Эшне бетергәч, ничек фарсит итәргә кирәклеген Сираҗетдинның үзе дә бик яхшы белер әле. *(Өстәл өстеннән сикереп төшеп, кулына лампа алып, ишеккә таба бара башлап.)* Ахмак нәрсәләр, йөзе каралар, кладавай ишеген ачык калдырганнар.

Камали. Чү, зинһар, чү, һәммәсен бикләгәннәр! *(Сираҗетдин һаман чыгарга маташа.)*

Җамали. И бичара, бөтенләй коты очып, куркып беткән. *(Камали белән Җамали. Сираҗетдинның кулыннан тотып чыгармаска тырышалар.)*

Сираҗетдин. Талыйлар, талыйлар! Тотыгыз!

Җамали *(һаман да кулыннан җибәрмичә).* Юк, Сираҗетдин, юк! Бернәрсә дә юк!

Сираҗетдин. Талыйлар! Әнә йозагын ваталар! *(Ишектән чыгып китә. Аның белән бергә Җамали белән Камали да чыгып китәләр.)*

Гөлҗиһан. И Раббым, и Раббым, тәмам харап булдык! Эштән чыктык! Фатыйма тудык инде миннән авызын җырып көләр. Нинди генә матур иттереп аш уздырам дип торганда гына харап булдык. Әле менә кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. Урам кибетеннән акча сорыйлар. Акча чыгармасагыз, бер тиенлек тә әйбер бирмибез дип әйтәләр, ди. Итче дә бүген ит бирмичә керткән. Аласыз да аласыз, акча бирүне белмисез, сез җүләрне туйдырырга мин ялланып керешмәгән дип әйтә, ди. Асрауларның да берсенә дә бер сүз әйтер хәл юк, хәтта үзеңнән битәр, биш өлеш артык итеп кычкырырга торалар. Кичәгенәк Гайниҗамал: «Торасың да кычкырасың, торасың да кычкырасың, мин җүләр кешенең хатыны түгел, мин кычкырмасаң да аңлыйм. Кычкырырга беләсез, ә өскә-башка ясарга белмисез,

менә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы бер алъяпкычлык алып бир»,— ди. Хәзер инде кучерләренә кадәр мыскыл итә башладылар. Кичә тудыкларга барырга ат җигәргә кушкан идем: «Әллә, абыстай, син дә инде акылга җиңеләя башладыңмы? Чыгасыз да утырасыз да, бер эшсезгә чабасыз, ул атларның аяклары тимер түгел бит көне буена чабып йөрергә»,— ди. Белмим инде мин, ни эшләргә дә аптырадым. Сираҗины җүләр дип әйтер идем, кеше юк чагында үзалдына әллә нәрсәләр хисаплый, әллә нәрсәләрне шутка сала. Мин килә башладым исә, «таларга киләсең» дип кычкырынырга тотына. И Аллам, харап булдык шул, харап булдык. Бламажи пешерелми онытылып калган дигәч тә әллә нәрсәгә эчләрем «жу» итеп киткән иде. Күрәчәгебезгә каршы булган икән шул. *(Ишектән Нәгыймә карчык килеп керә.)* Әйдә, хуш киләсең, Нәгыймә абыстай, килүең-китүең юк.

Нәгыймә. Исәнме, кызым Гөлҗиһан, исәнме? Кешенең борчулы вакытында һаман-һаман килеп кешене борчып йөреп булмый шул. Нихәл әле, кызым, ниләр эшләп торасыз? Исәнсау гына торасыңмы? Хафалана торгансыңдыр, ахры, ябыгып киткәнсең.

Гөлҗиһан. И Нәгыймә абыстай! Ничек итеп хафаланмаска кирәк? Инде Мәскәү бүләкләре кайта дип көтеп торганда гына, ирең шулай җүләрләнеп кайткач, ничек итеп хафаланмассың! Ичмасам, акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын да бер хәл иде. Әле ярый, көн күреп торырга сумабыз бар дип торыр идең. Әле әнә мәскәүләр килеп кибетне дә пичәтләгәннәр, ди. «Сираҗины докторга күрсәтәбез. Әгәр чын-чыннан җүләр булса, аз белән дә килешермез»,— дип әйтәләр, ди. Ул инде соң, җүләр булмаса, урамда утын төягән вагуннарга утырып йөрер идеме?

Нәгыймә. Әйе шул, әйе шул, кызым, бер дә акыллы кешенең эше түгел инде. Әле менә беркөн, теге, беләсең ич Хәмди Мәфтухасын, шуның Әсма атлы бер кызы бар. Шул кыз урамнан узып бара икән. Сираҗетдин шуның каршысына барган да: «Син кем кызы, бик матур кыз икәнсең, мин сине үземә кече хатынлыкка алам»,— дип, юлыннан туктаткан. Ул аны анасына кайтып сөйләгән. Анасы тагын, җүләр нәрсә, шул сүзгә ышана калган: «Бай кеше бит, сораса, ни эшләп бирмәскә, бирәм, һәйбәт, яхшы атларга утырып рәхәтләнеп йөрер»,— ди. Мин әйтәм: «И җүләр, җүләр, шул сүзгә ышандыңмы? Ул бит хәзер акылдан шашкан, белешеп әйтми ул, аның хатыны

Гөлҗиһан синең Әсмаңнан меӊ өлеш артык, синең йөз Әсмаңны бәреп егар»,— дим.

Г ө л җ и һ а н. Кайсы Хәмди Мәфтухасы инде ул?

Н ә г ы й м ә. Ай Алла, син Хәмди Мәфтухасын белмәскә, менә тагы, алар бит синең әтиләрең күршесендә, Чүпрә Йосыф йортында, түбән өйдә фатир торганнар иде.

Г ө л җ и һ а н. Ай, әҗәткана, шулмыни? Сираҗины башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам миңа ир бетмәгән! Ачуымны китерсәләр, иртәгә үк аерылып китәрмен. Тәмам туеп беттем инде. Беркөнне карап утырды, утырды да: «Әйдә, гармун алып уйнап җибәр әле»,— ди. Мин тагы, җүләр, аның сүзенә ышанып, чынлап әйтә дип белеп, уйнарга гына тотынган идем: «Әйдәле җырлап та җибәр»,— ди. Мин җырламагач, тотынды биергә, тотынды биергә, мин, куркып, гармунны ташладым, ул һаман бии дә бии. Тәмам арып, башлары-күзләре әйләнеп бетте. Чәнчелеп китсен Сираҗилары, башларына чәйнәп яксыннар! Шул җүләргә бирмәсәләр, кызларына урын таба алмаганнар икән.

Н ә г ы й м ә. Мин шуны әйтәм: «Юкка җүләрләнеп, үзегездән кеше көлдереп, алай итеп йөри күрмәгез»,— дим.

Г ө л җ и һ а н. Бирсеннәр, минем бер сүзем дә юк. Гомеремдә мин аннан нинди рәхәт күрдем?

Н ә г ы й м ә. Анысы шулайдыр да инде, шулай да булса, иргә бер баргач, шунда торган яхшы. Әле соң ни эшләп торасыз? Бераз өшкертеп-төкертеп караганыгыз юкмы? Бәлки, Алла кушса, сәламәтләнеп тә китәр иде. Әле менә сезгә шуны әйтим дип килгән идем. Нурый хаҗиларга читтән бер ишан килгән, ди. Сулышы бик шифалы, өшкерткән кеше бер дә сәламәтләнми калмый, ди. Әле менә әллә кемнең хатыны шуңа өшкерткән генә икән, бик зур файда күргән, ди.

Г ө л җ и һ а н. Мин бер дә хәзер ни эшләргә дә белмим инде. Әле менә бүген мәскәүләр белән килешмәкче булып йөриләр. Шулар белән килешеп, эшләр уңайга китсә, тагы ни булса да ул булыр иде. *(Ишектән Җамали, Камали, Сираҗетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан килеп керәләр, Сираҗетдинны урындыкка утырталар.)*

Җ а м а л и. Закир, Мөхәммәтҗан, сез шунда Сираҗетдинны яхшы гына каравыллап утырыгыз, бер җиргә дә чыгып китмәсен. Килен, сез дә бераз күз-колак булыгыз. Әйдә, Камали, без кибеткә төшик. Анда теге давиринныйлар безне көтеп тора

торганнардыр. Аларны монда алып килербез. Гарәфигә дә әйтерергә кирәк, ул да килсен, ул аның юлда ничек таланганын күргән кеше, бәлки файдасы тияр. *(Чыгып китәләр.)*

Г ө л җ и һ а н *(урындыкта башын артка таба салып, йоклаган төсле утырган Сираҗетдинны күрсәтеп).* Әнә инде, Нәгыймә абыстай, аның хәле шул инде. Йә ул шулай башын артка сала да изелеп йоклый, йә тора да пыр тузып, өй эчендә йөгергәләп йөри, йә булмаса өстәл өстенә менеп утыра да әллә ниләр мыгырдап укырга тотына. Менә инде көне буе шуны саклап утыр, әгәр гомер буена шул җүләрлегендә булса, аның белән ничек торырсың?

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Тормассың, тормассың бер дә. Тизрәк эшем генә бетсен, мин аннан ары сине типкәләп ишегемнән чыгарып җибәрермен.

Н ә г ы й м ә. Шулайдыр шул, Гөлҗиһан, шулайдыр. Бу килешкә булганда, хәлең бик яхшы түгел; ичмасам, байлыгы бар вакытта шулай булган булса бер хәл иде. Байлыгы бар дип чыдап торыр идең; син яшь кеше, балаң-чагаң юк, бер дә хафаланмас идең. Әле менә теге җүләр Йосыф хатыны акча белән калды да, нинди чибәр яшь кешегә барды.

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Күрәсезме, карчык нинди яхшы киңәшләр бирә! Калдырдылар ди сезгә акча, капчыгыгызны тотмыйсызмы?!

З а к и р *(үзалдына).* Итәрсең аны җүләр, үз файдасына килгәндә ул бер дә җүләр түгел! Беркөнне миңа алмаштырырга дип егерме биш тәңкәлек акча биргән иде, шул вакытта мин, бераз батырып калыйм әле дип, бер өчлекне кесәгә яшергән идем, хәзер сизде. «Кая акча?Талыйлар!» — дип, каравыл кычкыра башлады.

М ө х ә м м ә т җ а н *(үзалдына).* Акчасы булгач, баргандыр шул, акчасы булса, абыстайны алудан мин дә качмас идем. Мин дә бит бик чибәр егет. *(Мыекларын боргалап-төзәтенеп куя.)* Абыстай карт кеше түгел, акчасы булгач, аның белән торырга мөмкин. Матур булмаса да, акчасы булгач, ярап торыр иде.

Г ө л җ и һ а н. Нәгыймә абыстай, зинһар, акрынрак сөйли күр. Йә үзе ишетер, тегендә тегеләр дә тыңлап торалар, үзе ул дивана булса да, сөйләгән сүзне бик тиз ишетә. Әйдә, без теге якка чыгып, бераз сөйләшеп утырыйк. *(Закир белән Мөхәммәтҗанга карап.)* Сез монда абзагызны саклап утырыгыз. *(Чыгып китәләр.)*

З а к и р *(Мөхәммәтҗан янына барып утырып).* Нихәл, Мөхәммәтҗан? Кичә бит минем ай тулды. Беләсеңме, миңа акча кирәк. Жалунияне аласы иде. Бу җүләрне көтеп торсаң, монда жалуния алганчы сакалың агарыр.

М ө х ә м м ә т җ а н. Минем үземнең дә жалуния алганым юк. Кичә Җамали абзыйдан сораган идем, сезнең ябык кибетегез өчен мин нишләп сезгә жалуния түләп торыйм, абзагыздан сорагыз, ди.

З а к и р. Ә соң мин кайдан алыйм?

М ө х ә м м ә т җ а н. Белмим.

З а к и р. Җамали абзыйдан сорыйм да, әгәр ул бирмәсә, ташлыйм да чыгып китәм.

М ө х ә м м ә т җ а н. Теләсәң ни эшлә, мин сине тотып тора алмыйм. *(Тик утыралар.)*

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Тимә әле, минем бу җүләр булып кыллануның бик күп файдасы булды, мине җүләр дип фараз кылып, һәммәсе дә үзләренең серләрен яшермичә сөйлиләр. Хатынның да, кибетчеләрнең дә, кучерләрнең дә — һәммәсенең серләре мәгълүм булды. Тизрәк эшләрем генә бетсен, аннан ары мин сезнең барыгызны да ничек итеп өреп чыгарырга белермен. Инде теге мәскәүләр тиз килеп җитәрләр. Алар күзенә җүләррәк булып күренү өчен алданрак юллар эзләп куярга кирәк. Әгәр доктор чын-чыннан да җүләр дип шаһитлык бирсә, эшне озакка сузмаслар, тиз килешерләр. Аны ничек тә булса кулга алырга кирәк, докторлары нинди кеше икән? Аңа бер биш йөзлекне сузмый туры килмәс. Эшнең башы шунда. Аннан гына эшне бозарга ярамый. Әгәр биш йөздән дә ким бирсәң, бәлки ул риза булмас. Абыйлар бик йомшак маташмасалар ярар иде. Сумына ун тиеннән артык бер дә бирергә ярамый. Кибеттә малы бик аз икән дип әйтәләр, ди. Аз булмый, анда икенче кеше исемендәге вывиска астындагы кибеткә мал төямичә, пила чүбе тутырмаган. Алар барысы да мал. *(Ишектән Мәскәү доверенныйлары керә башлыйлар.)* Уф! Килеп тә җиттеләр. Ничек тә булса серне сиздермәскә кирәк.

Җ а м а л и. Әйдә, Василий Димитрич, әйдә, пожалысты, пожалысты. *(Доверенныйлардан дүрт кеше, доктор, Җамали, Камали һәм Гарәфи килеп керәләр.)* Пажалти, пажалти, менә монда утырыгыз. *(Урын күрсәтә.)*

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Тукта әле, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, әүвәле Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович белән

күрешергә кирәк. *(Сиражетдин янына килә.)* Здравствуйте, Сиражетдин Гыйлажетдинович!

Сиражетдин *(алдына гына карап утырган урыныннан сискәнеп, сикереп торып).* Каравыл! Талыйлар! *(Ишеккә таба бара башлый.)*

Закир һәм Мөхәммәтҗан. Тукта, абзый, тукта! *(Урынына китереп утырталар.)*

Василий Дмитриевич *(куркып, артка чигенеп утырып).* Кызганыч бичара, куркыныч.

Икенче доверенный. Бөтенләй төсләре дә үзгәргән.

Сиражетдин *(үзалдына).* Үзгәрерсең, уен түгел ул, кырык тугыз мең тәңкә диләр аны!

Җамали. Бар, Мөхәммәтҗан, әйт әле, чәй китерсеннәр.

Бер доверенный. Юк, юк, кирәк түгел. Без эшебезне генә эшлик тә, китәрбез.

Сиражетдин *(үзалдына).* Шаулама, бу беренчесе яхшы чыкты әле, малайларның куркудан котлары чыкты. *(Сикереп өстәл өстенә менеп утыра.)*

Бер доверенный. Карагыз әле, тагы әллә ни эшли.

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Доверенный. Ах, бичара.

Сиражетдин *(үзалдына).* Күрсәтермен әле мин сезгә бичараларыгызны!

Василий Дмитриевич. Ну, менә без хәзер барыбыз да җыелган чак. Сез тагын бер сөйләгез әле, вакыйга ничек-ничек булган?

Сиражетдин *(үзалдына).* Беләләр алар вакыйганы! Аны сез миннән сорасагыз, мин әйтер идем ничек булганын. *(Урыныннан сикереп торып, ишеккә таба бара башлый. Утырган кешеләргә күзләрен зурайтып ачып карый. Закир белән Мөхәммәтҗан барып тотып, яңадан урынына китереп утырталар.)*

Бер доверенный. Нишләп ул һаман тынычсызлана?

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Василий Дмитриевич. Ну, ярый, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сөйләгез әле, эш ничек булган?

Сиражетдин *(үзалдына).* Берничек тә булмаган.

Җамали. Менә ничек булган. Ул безгә сөйләнеп йөргән иде: «Мин фәләнчә көн Мәскәүгә барам»,— дип. Мин аңа әйттем: «Тукта, бераз сабыр ит, бергә барырбыз»,— дип. Ул әйтте: «Юк, мин хәзер барам, кибеттә мал бик аз калды. Күп нәрсәләрнең төрләре беткән»,— дип. Шуннан соң мин дә бер сүз

әйтмәдем, ул да китеп барды. Ул акчасын үз янында алып киткән икән, минем аннан да хәбәрем булмады.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Китәр, китәр, үз янында алып китәр! Үз янымда алып китәргә мин дурак түгел!

Җамали. Хәтта мин аның күпме акча алып киткәнен дә белмәдем. Соңыннан, Сираҗетдин таланды, дип менә Гарәфидән тилиграм килгәч, киленнән ишеттем, кырык тугыз мең, диде.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Бик дөрес, шулай, кырык тугыз мең.

Василий Дмитриевич. Киленегез аны кайдан белгән? Үзе әйткәнме?

Җамали. Юк, үзе әйтмәгән. Ул, чыгар алдыннан аягын чишенеп, кәгазь акчаларны балтырына чорнап, аягын киенгән.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Анысы дөрес, кәгазьләрне балтырына чорнап киенгән.

Василий Дмитриевич. Киленегез мондамы? Аннан да сорап карасак, ничек булыр?

Камали. Юк, ярамый, хатын кешегә ирләргә күренергә шәригать ни вилит!

Җамали. Сорасыннар, сорасыннар, безгә кеше хакы бер тиен дә кирәкми, сорасыннар.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Дөрес, дөрес, бер тиеннәре дә кирәкми!

Җамали. Бар әле, Мөхәммәтҗан, абыстаңны монда чакыр, хәзер генә чыгып керсен әле. *(Гөлҗиһан керә.)* Менә, килен, болар Мәскәүдән килгән давиринныйлар, синнән сорамакчы булалар.

Гөлҗиһан. Нәрсәне?

Җамали. Сираҗетдинның акчасын.

Гөлҗиһан. Нинди акчасын?

Җамали. Югалткан акчасын.

Гөлҗиһан. Аны ничек миннән сорыйлар, мин аны кайдан алып бирим?

Василий Дмитриевич. Туктагыз әле сез, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сез сорый белмисез. Менә нәрсә, абыстай: сез Сираҗетдин Гыйлаҗетдиновичның үзе белән акча алып киткәнен белдегезме?

Гөлҗиһан. Белдем.

Василий Дмитриевич. Ул аны кайсы кесәсенә салып алып китте?

Гөлҗиһан. Бер кесәсенә дә салмады. Иң әүвәл менә шушы төшкә утырды да аякларын чишенде. Аннан соң кырык тугыз мең тәңкә акчасын дүрткә бүлде дә аякларының як-якларына, балтырларына куйды да киенде.

Василий Дмитриевич. Сез ул акчаларның нинди икәнлекләрен күрдегезме?

Гөлҗиһан. Күрдем.

Василий Дмитриевич. Нинди акчалар иде?

Гөлҗиһан. Бишәр йөзлек.

Сиражетдин *(үзалдына)*. Күрдең пычак, ул вакытта инде ул акчалар күптән кладавайда яталар иде.

Василий Дмитриевич. Ул акчаларны ул кайдан алып чолгады?

Гөлҗиһан. Сумкадан алып чорнады. Банкыдан алып кайтты да аягын чишенеп чорнады.

Василий Дмитриевич. Аягын киенгәч, өйдә озак тордымы?

Гөлҗиһан. Юк, озак тормады. Аягын киенде дә, атка утырып, вакзалга төшеп китте.

Василий Дмитриевич *(башка доверенныйларга карап)*. Әфәнделәр, сез дә берәр нәрсә сорап карамыйсызмы?

Доверенныйлар. Юк.

Василий Дмитриевич. Ярый, абыстай, рәхмәт. Башка сорый торган сүз юк. *(Гөлҗиһан чыгып китә. Башка доверенныйларны бер читкә тартып.)* Ну, әфәнделәр, сез ни дисез? Минемчә, боларның әйткән сүзләре дөрес шикелле күренә. Банкның кассиры да һәммәсе бишәр йөз тәңкәлек акчалар бирдем дигән иде.

Бер доверенный. Минемчә дә дөрес.

Икенче доверенный. Мин дә бер дә шикләнергә урын күрмим. *(Һәммәсе дә килеп утыралар.)*

Василий Дмитриевич. Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, сүзегезне сөйләп бетерегез, аннан соң ни булган?

Җамали. Аннан соң ни булганын мин бик яхшы белмим. Менә бу Гарәфи аның белән бер поезда барган кеше, эшне ул бик яхшы белә. Безгә тилиграмны да ул бирде.

Василий Дмитриевич. Алай икән, бик яхшы. Алай булса, сез, Гарәфи әфәнде, эшнең ничек булганын безгә сөйләп бирегез әле...

Гарәфи. Без аның белән вакзалдан кузгалып киттек. Юлда бик яхшы бардык.

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Бик дөрес, хәтта пирасатка төшкәндә бергә пирәшләдек[1] тә.

Г а р ә ф и. Соңыннан Мәскәүгә барып җитәргә берничә станса калгач...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Әйе, берничә станса калгач.

Г а р ә ф и. Сираҗетдин: «Мин тышка чыгып керим әле»,— дип, тышка чыгып китте. Төн караңгы иде...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Дөрес, караңгы иде.

Г а р ә ф и. Пуез да бик шәп барадыр иде. Ул чыгып бераз торгач, пуез бер стансага туктады, аннан да кузгалып китте...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Анысы да дөрес.

Г а р ә ф и. Шуннан соң мин, тынычсызланып, Сираҗетдинны эзләргә чыктым. Бәдрәфне барып төртеп карадым, бәдрәф бикле иде...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Монысы да дөрес.

Г а р ә ф и. Бәдрәф янында бер-ике кеше көтеп торалар, бәдрәфтәге кешене озак торды дип сүгәләр иде...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Анысы да дөрес. Хәтта ишекне дөбердәтеп аптыратып бетерделәр.

Г а р ә ф и. Шул вакытта бер кандуктыр узып барадыр иде, аңа жалуба бирделәр...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Анысын да ишеттем.

Г а р ә ф и. Кандуктыр: «Стансада торганда икенче кандуктыр бикләп куйгандыр аны»,— дип ачып керде...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Уф! Иң читен җиренә килеп җиттеләр.

Г а р ә ф и. Бервакытны ачып керсәк... ни күзебез белән күрик, Сираҗетдинның башыннан бүрекләре, кәләпүшләре төшкән...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Дөрес.

Г а р ә ф и. Аякларын салдырганнар...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Анысын үзем салдым.

Г а р ә ф и. Казакиларын, камзулларын чишкәннәр...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Аларын да үзем чиштем.

Г а р ә ф и. Бернәрсә белмичә, һушы китеп ята...

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Әйе, белмәмешкә салынып яттым.

Г а р ә ф и. Моны күргәч тә минем йөрәкләрем «гөп!» итеп китте, кандуктыр да: «Кенәзне талаганнар!..» — диде.

---

[1] *Пирәшләү* — исерткеч эчеп кәеф-сафа кору.

Сираҗетдин *(сикереп торып)*. Каравыл! Тотыгыз! Тот! *(Ишеккә таба йөгерә, һәммәсе дә урыныннан сикереп торалар. Сираҗетдинны барып тоталар.)* Каравыл! Талыйлар!

Җамали, Камали, Гарәфи һәм башкалар *(беравыздан)*. Җибәрмәгез, җибәрмә! Сираҗи, Сираҗи, бернәрсә юк, утыр! Утыртыгыз! *(Урындыкка китереп утырталар.)*

Сираҗетдин. Каравыл! Талыйлар! *(Урындыкка егылып, изелеп төшә.)*

Доверенныйлар. Доктор, доктор әфәнде, ярдәм итегез, карагыз. *(Доктор килә.)*

Доктор. Рәхим итеп, бер чүпрәкне салкын суга манып китерегез әле. Бераз хәл алдырырга кирәк булыр. Аннан соң тамырларын карарбыз. *(Сулы чүпрәкне китерәләр. Доктор сулы чүпрәкне маңгаена куеп.)* Шул килешкә бераз гына торып хәл алсын әле, сез, зинһар, бераз читкәрәк китеп торыгыз, яңадан күзен ачып җибәреп, сездән курыкмасын. *(Читкә китәләр. Доктор бераз торып.)* Менә инде хәзер тамырларын карап карыйк. *(Сираҗетдинның асылынып торган кулын кулына ала. Шул арада Сираҗетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра. Доктор, биш йөзлеккә күзен төшереп, үзалдына.)* Һа, алай икән, эш сизелде, бик шәп акылдан шашкан икән. Ярый, миңа барыбер. *(Кесәсеннән сәгать алган булып, биш йөзлекне кесәсенә тыга. Тамырыны тотып бераз караганнан соң.)* Эш бу яктан бик өмитле түгел, тамыр бик еш тибә. *(Күкрәкләрен тыңлый.)* Монда да хәл бик яхшы түгел. Йә әле, башкача тәҗрибә кыйлып карыйк. *(Кесәсеннән бер нәрсә алып, кулларына, битләренә төртеп карап.)* Дөрес. *(Доверенныйларга әйләнеп карап.)* Әфәнделәр, эш бик өмитле түгел, гакылына бик зур хәләл[1] килгән. Әгәр дә бик зур, хәтта харикыльгадә[2] бер вакыйга булып, шул вакыйганы күргәндә кинәттән гакылына килмәсә, дәва белән генә терелтергә зур өмит күренми. Менә бу чүпрәкне алып куегыз әле. Хәзер күзен бераз ача башлады. Инде миңа тагын бер стакан салкын су китереп бирегез, шуны эчерткәч, бераз хәл алыр. Аннан соң мин сезгә бер дару язып бирермен. Шул даруны эчерткәч, ул тынычсызлануыннан бераз тукталыр. Шулай да булса, әфәнделәр, бөтенләй терелүенә өмит бик аз.

---

[1] *Хәләл* — зарар.

[2] *Харикыльгадә* — гадәттән тыш.

Гөлҗиһан *(ишектән елап кереп).* Доктор әфәнде, мин нихәл итәрмен, кая барырмын?

Доктор. Тс, тс! Тавышыгызны чыгармагыз! Авыру янында җылаган тавыш чыгарырга ярамый, ул аның кәефен генә боза. *(Гөлҗиһан күзен яулык берлә каплап, акрын гына елый.)* Белмәссең, бәлки, Ходадан вәгъдә җитсә, терелеп тә китәр. Дөньяда төрле вакыйгалар була. Менә бервакыт шундый бер кеше акылыннан шашкан, ничә еллар үзен-үзе белмичә йөргән. Бервакыт шуларның йортлары яна башлаган. Ул кешенең 6—7 яшендә кечкенә кыз баласына ут кабынырга якынлашкач, бала бик каты, ачы аваз белән кычкырып җибәргән дә, шул тавышка теге кеше йокысыннан уянып китеп, коточкыч пожарны күреп, кыз баланы кочагына алган да, ут эченнән йөгереп чыгып, баланы янудан коткарган һәм үзе дә яңадан акылына килгән.

Җамали. Хода безгә дә шулай ярдәм бирсә иде.

Камали. Илаһым, үзең ярдәм бир!

Гөлҗиһан. И Раббым, Ходаем! *(Тынычлык.)*

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде, алайса сез Сираҗетдин әфәнденең акылына зарар килү хак дисез?

Доктор. Анда һичбер шик-шөбһә юк.

Василий Дмитриевич *(доверенныйларга карап).* Алай булгач, әфәнделәр, безгә эшкә керешергә вакыт. Сез ни дисез?

Сираҗетдин *(күзләрен бераз ачып, үзалдына).* Йа Алла, эшләр бераз җиңеләя, иң авырлары узды. Акча төрткәч, докторың эреде. Шайтан да эзләп таба алмаслык ялганнарны ялганлый!

Доверенныйлар. Без дә шуны уйлап торадыр идек, без дә шул фаразда. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)*

Василий Дмитриевич. Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, соң сез нинди фаразда?

Җамали. Без нинди фаразда булыйк?

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде әйтә, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович акылга килерлек түгел, ди. Шулай булгач, инде ул моннан соң сату итә алмас. Кибеттәге бар малын, йортларын сатарга кирәк тә, шуның белән бурычларын түләргә кирәк.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Ай-яй, начар сүз әйтте.

Җамали *(аптырап китеп).* Ул ни дигән сүз? Ничә еллардан бирле бер тиен калдырмый түләп килгән фирманы шулай итеп тар-мар итмәкче буласызмы?

Василий Дмитриевич. Ә соң сез ни эшләмәкче буласыз?

Җамали. Минә сезнең белән килешсәк, агай-эне икебездән беребезне апикун итеп куярбыз да әүвәлгечә сату итә бирербез.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Менә монысы яхшы сүз.

Василий Дмитриевич. Соң сез ничек итеп килешмәкче буласыз?

Җамали. Белмим, ничек килешергә?

Василий Дмитриевич. Соң сез күпме бирмәкче буласыз?

Җамали. Белмим.

Василий Дмитриевич. Илле процент бирәсезме?

Җамали. Ул ни дигән сүз? Аның йорты залук[1], кибетендә малы юк, акчасы урланган.

Василий Дмитриевич. Анысын һәммәсен дә беләбез.

Җамали. Шулай булгач, ни өчен илле прасинт сорыйсыз? Аның кибетендәге бар малын сатып бетерсәгез дә ун прасинттан артык җыя алмассыз.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Монысы өчен абыйга рәхмәт.

Василий Дмитриевич. Соң күпме бирмәкче буласыз?

Җамали. Күпме дип, ун прасинт бирербез. Аны да инде тик, барган көенә фирманың эше туктамасын дип кенә бирәбез.

Василий Дмитриевич. Алай бик аз. *(Доверенныйларга карап.)* Әйдәгез әле, монда килегез. *(Бер читкә китәләр.)* Ну, сез ни дисез? *(Үзара шыпыртлап бераз киңәшәләр. Янәдән килеп утырып.)* Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, менә нәрсә, унбиш процент бирерсез. Аннан да ким булганда, иптәшләр риза булмыйлар.

Җамали. Ихтыярыгыз, без артык бирә алмыйбыз. Ничә еллардан бирле килгән фирманы бетерәсез икән, хәерле булсын.

Василий Дмитриевич. Алай булса, менә нәрсә: ун процентның һәммәсен дә иртәгә биреп бетерергә кулыгыздан подписка бирәсезме?

Җамали *(Камалига карап)*. Камали, синдә иртәгә алты мең тәңкәләп акча булырмы? Калган яртысын мин табам.

Камали. Яхшы, ярар, булыр.

Василий Дмитриевич. Димәк, алай булгач, риза буласыз?

---

[1] *Залук (залог)* — бурычка салу.

Җ а м а л и. Риза.

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Эш пешә.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Ну, доверенныйлар, сез дә ризамы?

Д о в е р е н н ы й л а р. Риза, риза.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Алай булса, мин актны язам. *(Яза).* Менә сезгә үзебезнең йөз егерме мең сум алачагыбыз бәрабәренә унике мең сум алырга риза булганлыгыбызга распискалар. Рәхим итеп, һәммәгез дә шуңа кул куегыз! *(Куялар.)* Яхшы, инде алай булса, менә, менә монысы сезгә. Ә менә монысы безгә. *(Кесәсенә тыга.)* Яхшы, хәерле сәгатьтә булсын. *(Кул бирешәләр.)* Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, инде эш бетергәнлекнең сые сездән.

Җ а м а л и. Әйдәгез, рәхим итегез, барабыз.

Б е р д о в е р е н н ы й. Ә Сираҗетдин Гыйлаҗетдиновичны тәбрик итәргә кирәк.

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Юк, ярамый.

Җ а м а л и. Әйдәгез. *(Чыга башлыйлар.)*

С и р а җ е т д и н *(үзалдына).* Ух, эш пеште! Бер көн эчендә йөз дә сигез мең тәңкә файда!

Д о к т о р. Әфәнделәр, сезгә бер сүзем бар. Әгәр дә минем сүземне тотсагыз, хәзерге көндә ике кешегә сез бик зур файда китерә аласыз. Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.

Д о в е р е н н ы й л а р. Ничек итеп?

Д о к т о р. Менә ничек итеп: бая мин сезгә сөйләгән идем бит, харикыльгадә бер эш булса, диваналарның терелүе ихтимал дип.

Д о в е р е н н ы й л а р. Ие.

Д о к т о р. Менә хәзер минем башыма бер фикер килде. Сезнең кайсыгызда булса да дүрт данә бишәр йөз сумлык акчалар бардыр бит?

Д о в е р е н н ы й л а р. Бар, миндә дә бар.

Җ а м а л и белән К а м а л и. Миндә дә бар.

С и р а җ е т д и н *(үзалдына, шатланып).* Аңладым, аңладым, бу доктор түгел икән, шайтан икән! Яңадан бер биш йөзлекне тамызмый туры килмәс. Дәртен белгән —дәрманын белер диләр, бик дөрес сүз.

Д о к т о р. Булса, китерегез монда акчаларыгызны. *(Бирәләр.)* Хәзер миңа калын-калын итеп дүрткә бүлеп төргән чуар кәгазьләр бирегез.

Җамали. Хәзер китерәм. *(Чыгып китә. Камали да өстәл асларыннан кәгазьләр эзли башлый.)*

Василий Дмитриевич. Сез ни эшләмәкче буласыз? Мин аңламыйм.

Доктор. Бераз гына сабыр итегез, хәзер күрерсез. *(Кәгазьләрне китереп бирәләр.)* Менә аларны шушылай итеп төрик. *(Төрәләр.)* Хуш, сез, әфәнделәр, менә бу почмакка килеп, бер дә дәшми-тынмый гына тик торыгыз. *(Тегеләр почмакка китәләр. Доктор, тышкы ягыннан бишәр йөзлек акча белән төргән кәгазьләрне икешәр-икешәр ике кулына тотып, аларны югары күтәреп, акрынлап, аяк очлары белән генә басып, Сираҗетдинның артына килә. Соңра кинәттән, аяк тибеп, бик каты аваз белән: «Сираҗетдин!» — дип кычкыра. Сираҗетдин, сискәнеп, аяк өстенә баса. Акчаларны карап тора. Соңра көлеп җибәреп: «Акчам! Акчам!» — дип, кулларын суза.)*

Доктор *(акчаны биреп)*. Мә, ал акчаларыңны! Монда кырык тугыз мең тәңкә! Акчаң табылды! *(Сираҗетдин, акчаларны алып, кантор өстәленә йөгерә. Өстәл эченә салып бикләп, ачкычны ала.)*

Доктор *(халыкка карап)*. Ну, каналия, нинди оста эшли, артист кына буласы бар! *(Сираҗетдин янына бара. Бер кулы белән Җамалига ишарә кыла. Җамали килә.)* Сираҗетдин әфәнде, бу кем? Бу абзаң, күрешегез.

Сираҗетдин *(Җамалига карап)*. Абый!

Җамали. Исәнме, энем! Исән кайттыңмы?

Камали. Исәнме, энем?

Сираҗетдин. Исәнме?

Доктор. Хатынын чакырыгыз!

Җамали. Исән-сау кайттыңмы, энем?

Сираҗетдин. Ә?

Җамали. Исәнме дим?

Доктор. Менә болар — агаларың, таныйсыңмы?

Сираҗетдин. Таныйм.

Доктор. Танысаң, күреш. *(Сираҗетдин күрешә. Гөлҗиһан керә.)* Менә монысы кем?

Сираҗетдин. Гөлҗиһан?

Доктор. Күрешегез. *(Күрешәләр.)* Йә, инде утырыгыз. *(Дүртесе дә утыралар.)* Йә, менә инде тыңлап торыгыз, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович! Әнә сезнең кырык тугыз мең тәңкә акчагыз, сез ул акчаны Мәскәү юлында югалттыгыз.

Сираҗетдин *(сикереп торып)*. Ә?

Доктор. Утыр, утыр, менә инде хәзер ул акчалар табылды.

Сираҗетдин. Сез кем?

Доктор. Мин — доктор.

Сираҗетдин. Хуш?

Доктор. Хәзер инде син терелдең.

Сираҗетдин. Мин авырмадым!

Доктор. Ярый, авырмасаң. *(Халыкка карап.)* Авырмаганлыгың бик мәгълүм. *(Сираҗетдинга.)* Ярый, хуш инде! Мин китәм.

Сираҗетдин *(урыныннан торып)*. Ярый, хуш! Ә болар кемнәр? Ә, Василий Дмитриевич, уһуу, исәнме? Миңа ник әйтмисез, исәнме? Һа, сез дә исәнме? Акчага дип килдегезме? Менә хәзер сезгә акча бирәм. *(Өстәл астын барып ача башлый. Доверенныйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.)*

Василий Дмитриевич. Юк, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович, кирәк түгел. Бирерсез әле. Әйдә, без сине сыйланырга алып барабыз. Шунда сөйләшербез.

Сираҗетдин. Ярар, барам, бар, чыга торыгыз. Кая, Гөлҗиһан, бүрек белән яңа киемнәрне китер. *(Һәммәсе дә чыгып китәләр. Доктор кала. Докторга.)* Аңладым, аңладым. Сезгә тагын биш йөз. Мин хәзер чыгам. *(Доктор чыга.)* Ә менә монда икән җилән. *(Киенә.)* Эш пеште! Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында! *(Чыгып китә.)*

Гөлҗиһан *(ишектән сөйләнеп керә)*. Бүрекләрең бу яктадыр, ахры. Ай Алла, чыгып та киткән, күрми дә калдым. Үзе дә терелде! Байлыгыбыз да үзебезгә калды. Кунакка барам, кунакка чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!

Пәрдә.

1911



Гафур Коләхмәтов
(1881—1918)

ЯШЬ ГОМЕР[1]

Драма биш пәрдәдә

Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкълидән[2] язылмыштыр

УЙНАУЧЫЛАР

ИРЛӘРДӘН

Мостафа — 23 яшендә. Бай угылы. Интеллигент. Урта буйлы. Юанрак кына гәүдәле. Түгәрәк йөзле, бераз шадра. Кырган мыеклы. Фырт киемле. Бүреген уң тарафкарак салып кия.

Гали — 25 яшендә. Интеллигент. Озын буйлы. Уртача таза гәүдәле. Озын кара чәчле, кара мыеклы, брюнет. Башында татар бүреге. Ашыкмаенча, вәкарь белән генә сөйләшә.

Вәли — 35 яшендә. Галинең фикердәше. Эшче. Таза. Бите шадра. Озын мыеклы, уртача куе сакаллы, брюнет. Европача киенә. Билендә каеш. Башында татар бүреге. Тавышы юан. Сөйләшүе салмак.

Йосыф — 30 яшендә, эшче. Вәлинең иптәше. Урта буйлы. Юанрак бәдәнле. Уртача мыеклы һәм кечерәк кенә сары сакаллы. Татарча киемдә.

---

[1] Кыскартып алынды.

[2] *Тәкълид* — ияру.

Татар егете
Татар егете } — Мостафаның иптәшләре. Киемнәре урта.

Сөйләшүләре җитез. Кәсепләре — бай егетләрне имеп йөрү. Әлхасыйль[1], ялган интеллигентлыкка яңа гына чыга торган вакытлары.

Татар кунак
Татар кунак } — берсе 30—35 яшьләрендә, икенчесе 40—45 яшьләрендә булган чын Казан татарлары.

Хезмәтче малай — Мостафаның (хезмәтче) малае. 28—30 яшьләрендә. Тәбәнәк буйлы. Кысыграк күзле, сакал-мыегы да бар. Бер кызык кына кеше.

Полицейский.

Каравылчы.

ХАТЫННАРДАН

Зөләйха — 19 яшендә. Урта буйлы. Таза гына бәдәнле, түгәрәк битле, ак йөзле бер матур кыз. Сөйләшүе кызу. Мостафаның хатыны.

Фатыйма абыстай — 50 яшендә. Галинең анасы. Урта буйлы. Юан. Башында яулык, өстендә татарча тегелгән ситсы күлмәк. Тавышы ачык. Сөйләшүе салмаграк. Аяклары сәламәтсез булганга күрә, аяк басулары авыр һәм йөргән вакытта уңнан сулга (чайкалып) атлап йөри.

Шәмсениса абыстай — 35 яшендә. Галиләргә күрше хатын. Озын буйлы. Чандыр. Ситсы күлмәк кия. Башында простой шәл. Аягында читек-кәвеш. Кычкырып һәм тиз-тиз сөйләшә.

Камилә абыстай — 40 яшендә. Егетләр берлә кызларны сөйдерүче һәм кавыштыручы хатын. Өстендә сары ситсы күлмәк. Аягында читек һәм резинка галош. Чапаннан. Тавышы нечкә. Сөйләшүе җитез.

Татар кызы — озын буйлы. Чапан бөркәнгән. Матур татар кызы.

Асрау карчык — 55 яшендә. Тәбәнәк буйлы, чандыр. Бите җыерчыкланып беткән. Күзләре кечкенә, кысынкы. Шуның өстенә сул күзе зәгыйфькә күрә, уң күзеннән кечкенәрәк. Сүзне сузыбрак сөйләшә. Сөйләшкән вакытта кулы илә һәрдаим селкеп тора. Башында яулык. Өстендә каралып беткән ситсы күлмәк. Япкан алъяпкычы ертык. Аягында читек.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Гуляние бакчасы. Җәй көне. Сценаның каршысында урталыкта бер озын тераксез агач скамья. Скамьяның артында якын-тирәдә төрле агачлар. Уң һәм сул тарафта арты терәкле агач кәнәфиләр. Бакчада, праздник көне булганга күрә, рус һәм татар кешеләре арлы-бирле йөриләр. Ерактан аз гына музыка тавышы да ишетелә. Пәрдә күтәрелеп бераз торгач, чапанлы ике хатын — берсе чибәр генә кыз, икенчесе урта гына хатын — сцена уртасына чыгып сөйләшә башлыйлар.

---

[1] *Әлхасыйль* — җыеп кына әйткәндә.

Камилә абыстай һәм кыз.

Кыз. Син мине алдап кына йөртәсең бугай.

Камилә. Юк. Нишләп алдалыйм! Аллага шөкер, мин гомеремдә һич тә алдаганым юк әле. Борчылма, бәбкәм, борчылма. Ул алдаламас. Ул үз сүзендә тора торган егет.

Кыз. Ышанып бетә алмыйм, Камилә абыстай.

Камилә. Йа Алла!.. Син мине әллә кем дип белдеңме?

Кыз. Әллә кем дип әйтмим ич... Менә кояш та баерга тора инде. Мостафа абый юк әле.

Камилә. Борчылма, дим, бәбкәм, борчылма! Бер-бер эше булгандыр. Шуңар күрә бераз соңга да калгандыр. Борчылма.

Кыз. Камилә абыстай! Ул мине харап итеп алдалар гына бит. Алмас.

Камилә. Менә... нишләп алдаласын! Ул сине бик ярата... Менә күрешерсез, танышырсыз. Соңыннан, Алла боерса, никах та укытып алырсыз. *(Үз-үзенә.)* Алмаса алмас, анда минем эшем юк. Миңа акчасы гына булсын.

Кыз. Алырмын дип әйткәне бармы соң?

Камилә. Нишләп алмасын! Ул сине алыр өчен генә йөри ич. *(Үз-үзенә.)* Дөньяны татыгач, акча да күп булгач, һич тә кияү кирәк булмас әле.

Кыз. Куркам, Камилә абыстай, куркам... Әйдә, җаным, өйгә кайтыйк. Аласы килсә, яучы җибәрсен.

Камилә. Андый чибәр егетләр бер дә күрмәгән, белмәгән кызны алмыйлар шул.

Кыз. Куркам, җаным, валлаһи, куркам!

Камилә. Курыкма... Курку башта гына була ул. Соңыннан үзең үк миңа рәхмәт укырсың әле. *(Үз-үзенә.)* Менә бәла!

Кыз *(йөрүче кешеләргә карап)*. Камилә абыстай, кара әле. Әнә ике иптәше белән Мостафа килә бугай!

Камилә. Ул, ул, бәбкәм, ул!.. Әйткән идем ич, борчылма, килер дип... Әйдә, сине бер аулак җиргә илтеп куйыйм да, аннан соң Мостафаны синең катыңа җибәрермен, бәбкәм.

Кыз. Камилә абыстай, җаным!.. Икмәктер, куркам!.. Менә йөрәгем дә сикерә башлады инде.

Камилә. Әйдә, дим!.. *(Үз-үзенә.)* Нишлим икән?

Кыз. Җаным, Камилә абыстай... бәгырем... Харап кына итмәс микән?

Камилә. Кояштыр, алам, ди! Әйдә, дим. Монда торырга ярамый ич. Аулак урында күрешергә кирәк. Кеше күзе

алдында ярамый, яхшы түгел. *(Кулыннан тотып.)* Әйдә, бәбкәм, әйдә... *(Өстерәп алып китә. Бераздан өч егет килеп керәләр. Өчесе дә бераз исерек.)*

Мостафа ике иптәше берлә.

Беренче иптәше *(Мостафага)*. Камилә абыстай эшне булдырса, безне ни белән сыйларсың?

Мостафа. Чава жалаеш!

Икенче иптәше. Кара, әйткән сүзеңнән кайтма.

Мостафа. Мостафа әйткән сүзеннән кайта торган егет түгел. *(Кәгазь акча чыгарып.)* Даржи задатык!

Беренчесе. Безнең Мостафа маладис, брат. *(Җилкәсеннән кага.)*

Мостафа. Әллә маладис түгелме?.. Маладис шул!

Беренчесе. Мостафа, кара әле монда.

Мостафа. Ни бар?

Икенчесе. Сине Камилә абыстай дәшә.

Мостафа. Кайда?

Икенчесе *(бармагы белән күрсәтеп)*. Әнә ич!

Мостафа *(Камиләгә карап)*. Мин сиңа лаки түгел бит, үзең монда кил!

Беренчесе. Чү... акрын... Нигә болай кычкырасың?

Мостафа. Хачу, кычкырам! *(Янә кычкырып.)* Монда кил, дим!

Икенчесе. Кычкырса соң. Тик кычкырсын. Кычкырудан ни була дип беләсең?

Беренчесе. Булуын берни дә булмас... Яхшы түгел.

Мостафа. Безгә бар да яхшы.

Шулар ук һәм Камилә абыстай.

Камилә. Нишләп торасың инде? Әйдә, эш булды. Кара, мине дә онытып бетермә. Яме?

Мостафа. Ярый, ярый, онытмам. Иртәгә кибеткә кил, бар да булыр.

Камилә. Рәхмәт яусын, бәбкәм, рәхмәт яусын... Кибеттә эткәң булса, мин нишләрмен?

Мостафа. Өйлә вакытында килсәң, эти булмас.

Камилә. Ярар, бәбкәм, ярар... Әйдә, сине кыз көтә-көтә алҗып бетте инде.

Беренчесе. Йә, бар инде! Нишләп торасың?

М о с т а ф а *(көйләп).* Әйдә, җаным Камилә, кыз катына бараек. Кыз катына бараек та эшебезне кыйлаек. *(Камилә берлә бергә чыгып китәләр.)* (...)

Г а л и белән В ә л и.

В ә л и *(Галигә).* Зөләйхага гыйшык тотасыңмы әллә?

Г а л и. Юк. Гыйшык тотмыйм.

В ә л и. Гаҗәп...

Г а л и. Монда һич тә гаҗәпкә кала торган урын юк, иптәш.

В ә л и. Ник булмасын?

Г а л и. Янә юк дим.

В ә л и. Бу сүзләреңә минем фикерем һич тә җитә алмый, иптәш.

Г а л и. Гыйшык тотмыйм, әмма сөям... Шул гына...

В ә л и *(гаҗәпкә калып).* Гыйшык тотмый, әмма сөя!..

Г а л и. Сөям дә!.. Кызганам.

В ә л и. Теләсәң ни әйт. Әмма бу арада мин сине һич тә аңлый алмыйм.

Г а л и. Уйлап кара әле. Камил булмаса да, шундаен фикерле кызны бер кабахәт кешегә тотып бирсеннәр дә, кызганма, имеш. *(Кәнәфигә утыралар.)*

В ә л и *(уйлап).* Хәзер төшенә башладым бугай.

Г а л и. Йә, ни дип әйтерсең?

В ә л и. Бөтен Русиядә кызганыч кыз бер Зөләйха гына микән?

Г а л и. Бер Зөләйха гына түгел. Алар бик күптер.

В ә л и. Күп булгач, ни кылырга кирәк соң?

Г а л и. Беләм, иптәш, беләм. Барысын да кызганырга кирәк. Һәм...

В ә л и. Һәм барысын да хатынлыкка алырга кирәкмени?

Г а л и *(гаҗәпкә калып).* Алай түгел!.. Мин ничек барысын да үземә хатын итеп алыйм?

В ә л и. Соң нишләргә уйлыйсың?

Г а л и. Бу күп кызганыч кызлар арасыннан ичмаса Зөләйханы гына коткарасым килә. *(Моңлана.)*

В ә л и. Бер Зөләйханы гына коткарып, зур хезмәт иттем дип уйларсыңмыни?

Г а л и. Син мине аңламыйсың, иптәш, аңламыйсың!.. Нишләп зур хезмәт иттем дип уйлыйм?! Бу арада минем башым төрле-төрле фикерләр белән тулган, шул кадәр тулган, сиңа

барысын да һич тә сөйли алмыйм!.. *(Тора.)* Әчем поша, иптәш, әчем поша!..

Вәли *(торып)*. Иптәш, хәтерең калмасын: син Зөләйхага гыйшык тотасың бит.

Гали. Ни уйларга да белмим инде... Әмма гыйшык тотам дип тә үз-үземә ышана алмыйм.

Вәли *(Гали сәгатенә карап)*. Зөләйха килергә ярты сәгать вакыт бар әле. Бакчаны бер тапкыр әйләнеп килмибезме?

Гали. Әйдә... *(Югалалар. Бераздан, бөтен битен шәл белән каплап, Зөләйха керә.)*

Зөләйха ялгызы.

Зөләйха. Әллә соңга калдым микән? *(Сәгатькә карап.)* Юк, иртәрәк килгәнмен икән. Ун минут вакыт бар әле. *(Кәнәфигә утыра.)* Галине күреп, ни әйтермен икән?.. И Алла, ник син Галине бай итмәдең! Ул бай булса иде, әткәем дә разый булыр иде. *(Як-ягына каранып.)* Бер-бер белгән кеше күрмәсен, харап булырмын... Мостафа белән мин ничек торырмын икән?.. Үзе ямьсез һәм халык аны эчә, азып-тузып та йөри, диләр. *(Тора.)* Гали белән качып китсәм, әткәйләр рәнҗерләр бит. И бу рәнҗүләр булмаса иде!.. Әткәйләр һәм мулла бер төрле сөйлиләр, Гали икенче төрле сөйли. Әткәйләрнең сүзен аңлыйм, әмма Галинең сүзләрен ни сәбәптәндер аңлап бетерә алмыйм. *(Шул вакытта бер егет, йөрүче кешеләрдән аерылып калып, Зөләйхага карый.)* Аңлап бетерә алмасам да, рәхәтләнеп китәм. Чөнки ул шулкадәр матур һәм ләззәтле итеп сөйли, шулкадәр башымдагы фикеремне ача, аннан аерылсам, дөньяның бөтен кабахәтен күрә башлыйм. И Алла, кайсы мине хак юлга өнди: әткәйләрме, Галиме икән?.. *(Утыра. Карап торган егет, Мостафаның икенче иптәше, Зөләйха янына килә.)*

Зөләйха белән егет.

Егет. Исәнме, чибәр абыстай?

Зөләйха *(качып)*. Кит, син миңа кирәк түгел!

Егет. Ник болай әйтәсең? Ихтимал, кирәк булырмын.

Зөләйха *(куркып)*. Белмәгән кешегә ник килеп бәйләнәсең?

Егет. Тора-бара белермен әле.

Зөләйха. Син миңа кирәк түгел. Кит, дим!

Егет. Мин кирәкмәсәм, син миңа кирәк шул.

Зөләйха *(каушап)*. Нигә кирәк?!

Е г е т *(якынлашып)*. Кил, утырып сөйләшик әле.

З ө л ә й х а *(икенче кәнәфигә күчеп)*. Кит! Алла хакы өчен кит.

Е г е т *(көлеп)*. Син яныма килмәсәң, мин барыйм. *(Бара. Шул вакытта Гали берлә Вәли, гаҗәпкә калып, читтән карап торалар. Зөләйха сцена уртасына йөгерә.)*

З ө л ә й х а *(үз-үзенә)*. Йа Алла, нишлим?!

Е г е т *(Зөләйха артыннан)*. Чибәр абыстай, курыкма, мин бүре түгел, тешләмәм.

З ө л ә й х а *(елаган тавыш белән)*. Алла хакы өчен кит, дим!..

Е г е т. Алла хакы өчен гыйбадәт кыл. *(Якынлаша.)*

З ө л ә й х а *(янә кәнәфи катына килеп)*. Мин сиңа нишләдем? Ник килеп бәйләнәсең?!

Е г е т *(якынлаша-якынлаша)*. Мин әйткән җиргә барсаң... *(Бу вакытта Гали чыдый алмыйча кереп кычкыра.)*

Ш у л а р у к һәм Г а л и белән В ә л и.

Г а л и. Полицейский! *(Гали белән Вәли кереп Зөләйха һәм егет арасына килеп туктыйлар. Егет каушый. Зөләйха куркуыннан елый башлый.)* Башыңны ватармын, сукин сын! *(Гали, кулын күтәреп, егеткә сугыйм дигәндә, Вәли тотып кала.)*

Е г е т *(чигенеп)*. Сугып кара!

В ә л и. Йә, күп сөйләнеп торма!

Е г е т. Сөйләшеп тормаска... Мин нишләдем?

Г а л и. Нишләгәнеңне карап тордык ич! *(Зөләйха янына барып, аны кәнәфигә утырта. Полицейский килеп керә.)*

Ш у л а р у к һәм п о л и ц е й с к и й.

П о л и ц е й с к и й. Ни булды?!

Г а л и. Менә бу егет шушы абыстайны шулкадәр мыскыл итте, хәтта мескен елый башлады. Мыскыл итүенә икебез дә шаһит. Карап тордык.

Е г е т. Бер сүз дә әйтмәдем ич!

Г а л и. Егетне алып барып, протокол куегыз әле.

П о л и ц е й с к и й. Әйдә! *(Егетне Вәли белән җилтерәтеп алып китәләр. Гали Зөләйха янына бара.)*

Г а л и белән З ө л ә й х а.

Г а л и. Җаным, сабыр ит!

З ө л ә й х а. Син булмасаң, мин бичара нишләр идем? Рәхмәт сиңа.

Г а л и. Син курыктыңмы, җаным?

З ө л ә й х а. Шулкадәр курыктым, шулкадәр оялдым, кайда торганымны да белмәдем. Усал эт кебек ябышты. Мин качам, ул артымнан йөгерә.

Г а л и. Менә, җаным, безнең татарлар нинди хәлдә булып гомерләрен үткәрәләр!

З ө л ә й х а. Әйтмә дә инде.

Г а л и. Менә шундый кабахәтлекләр кылуны безнең татарлар егетлек дип беләләр. Әмма бер-бер файдалы сүз сөйли башласаң: «Я сам больше знаю!» — дип, туп-туры бозык урыннарга барып керәләр. Дуңгыз кеби ашап, ишәк кеби эчеп, акчаларын туздырып бетерәләр. Өйгә кайтып айныгач, баш авырту, акча бетү үчен кызганыч хатыннарыннан алалар. Сүгәләр, кыйныйлар, җәберлиләр!

З ө л ә й х а. Без бичара хатыннарны һич яклаучы юк шул инде.

Г а л и *(Зөләйханың сүзләрен ишетмичә)*. Бу җәберләр өстенә безнең татар хатыннары, саф һава күрмичә, казаматтагы кеби, өйдә генә ябылып ятып, ябыгып, авыруга сабышалар. Соңыннан ирләре аларны яратмый башлап, бер фәрештә кеби яшь кыз алып, мескинәне утка салалар. Олуг хатыннарын асрау урынында тоталар... Аh, бичара татар хатыннары нинди кызганыч хәлдә торалар!.. Сез кайчан бу бәлаләрдән котылырсыз?! Тизме иркенлектә рәхәтләнеп гомер итәрсез?! *(Йөри башлый.)*

З ө л ә й х а. Шушы җәберләрне мин дә күрермен микән?..

Г а л и *(Зөләйха каршысына туктап)*. Шиксез күрәчәксең.

З ө л ә й х а. Нишлим соң?

Г а л и. Янә бер әйтим: качыйк, җаным.

З ө л ә й х а *(моңаеп)*. Мостафа да шундый ук булыр микән?

Г а л и. Әйтә алмыйм.

З ө л ә й х а. Бер дә яшермичә генә фикереңне әйт, җаным!

Г а л и. Җаным, хурласам, ихтимал, мин сине үземә алыр өчен генә Мостафаны хурлый дип уйларсың. Әмма аны мактарга вөҗданым кушмый...

З ө л ә й х а. Йа Алла! Нишлим?!

Г а л и. Зөләйха, җаным... Син мине бу сүзләрең белән гаҗәпкә калдырасың. Чөнки кичә бер төрле сөйләгәнеңне бүген икенче төрле сөйлисең. Яз көне мин сине үземә хатынлыкка сораган идем. Син: «Хәзер авырыйм, лечиться итәсем бар,

сабыр ит. Кымызга барып кайтыйм әле»,— дип әйттең. Әмма кымызга бармадың. Дөрес бит?

Зөләйха. Дөрес. Авыруым да ялган түгел ич.

Гали. Беләм, җаным, беләм... Ялган дип әйтмим. Яз көне әйткән сүзләреңә мин бөтен җаным-тәнем белән ышанып тордым. Бу ышануыма каршы хәзер синнән ни ишетәм... Үзеңне миңа бирергә атаң-анаң разый булмаган вакытта да син минем белән качарга разый идең. Бу сүзләрем ялган түгел бит?

Зөләйха. Ялган түгел... Мин хәзер дә синең белән качарга разый... әмма...

Гали. Әмма!.. Әмма ни дигән сүз соң ул?.. Янә әүвәлге сүземә кайтыйм. Синең белән танышып җиткәч, ягъни берберебезне сөйгәч, ни сәбәптәндер һәр икебез дә кавышырга ашыкмадык. Ашыкмасак та: әгәр сине миннән начар кешегә хатынлыкка сорый башласалар, бернигә дә карамыйча, мин сине алачак һәм син миңа барачак дип, бер-беребезгә вәгъдә итешкән идек. Бу да дөрес бит?

Зөләйха. Гали, мин синең бөтен сүзләреңә ышанам һәм ялган сөйләмәсеңне дә бик яхшы беләм. Әмма...

Гали. Тагы әмма!.. Җаным, мин беләм, син атаңның рәнҗүеннән куркасың.

Зөләйха. Куркам шул...

Гали. Бу эшкә атаң түгел, бөтен дөнья халкы бәддога кылса да, кабул булачак түгел. Чөнки мин сине яратам һәм, яшермә, җаным, син дә мине яратасың бит. Мин сине аласым килә һәм синең дә миңа барасың килә. Шулай булгач, бу эшкә дин ягыннан да, вөҗдан ягыннан да катышырга һичкемнең хакы юк.

Зөләйха. Гали, җаным. Мин ике куәт арасында торып, фикерем шулкадәр чуалды, шулкадәр чуалды, хәзергә һичбер сүз әйтә алмыйм. Чөнки әти фикере белән мулла фикере бер яктан, синең фикерең икенче яктан пычакка пычак килеп торалар. Кайсыгыз җиңәр икән? Бу сөальгә мин һич тә җавап бирә алмыйм. *(Гали моңлана. Зөләйха, торып, сәгатькә карый.)* Ни булса да булыр, иртәгә сиңа актык җавабымны язармын.

Гали. Актык сүзем шул: үкенечкә калма, үз фикерең белән йөр һәм үз фикереңә карап эш кыл.

Зөләйха. Рәхмәт... җаным, мин китәм инде. Вакыт.

Гали. Әйдә... *(Югалалар. Вәли килеп керә.)*

Вәли ялгызы.

Вәли. Бай егет тугыры килде. Акча биреп котылыр йөзе кара, котылыр... *(Кәнәфигә утыра.)* Гали эчемне пошыра башлады... И интеллигентлар, интеллигентлар!.. Шушы интеллигентларга карап гаҗәпкә калам. Гаҗәпкә калмый хәлең дә юк шул. Менә, еракка бармый, Галигә генә карыйк. Ул, йөз утыз миллион Россия кешеләре, шакшы җан ияләре кеби, пычракка коенып торган вакытта, халыкка хезмәт итәм дип, Зөләйханы коткара, имеш!.. *(Тора.)* Бу Зөләйха артыннан йөри-йөри никадәр вакыты әрәм үтте. Никадәр эше калды. Кирәкле кәгазьләр вакытында язылмаган. Кирәкле урыннарга вакытында барылмаган. Сәбәбе ни? Зөләйха! Шушы интеллигентларны к... тибеп партиядән куалап чыгарасы иде,— ярамый! Аларның фикерләре эшче фикереннән җиңел булса да, эшчеләргә юл күрсәтеп торулары һәм эшчеләрнең фикерләрен ачулары кирәк шул. Менә бу көннәрдә митинг буласы. Гали булмаса, ул митингта кем торып сөйләсен? Галидән башка сөйләүче кеше юк шул. Гали — бик яхшы кеше. Әмма Зөләйха белән чуалуын гына яратмыйм. Зөләйханы коткарып, бер-бер файда булса ярар иде дә, файдасы юк бит. *(Бераз уйлап.)* Кая югалдылар?.. Көтим микән? Әллә кайтыйммы?.. Бераз утырып ял итим әле. *(Утыра. Гали керә.)*

Гали белән Вәли.

Гали. Син мондамыни?

Вәли. Монда.

Гали *(Вәли янына барып утыра)*. Әллә нигә эчем поша...

Вәли. Кайда югалдың?

Гали. Бераз Зөләйханы озаттым.

Вәли. Йә, ни ди?

Гали. Куркам, ди.

Вәли. Курка?.. Нидән курка?

Гали. Әйтергә дә көлке. Атасының рәнҗүеннән.

Вәли. Иптәш, куй бу эшеңне, куй. Барыбер булдыра алмассың. Күпме йөрсәң дә, булмаган эш булмый. Аның артыннан йөри-йөри вакыт кына әрәм үтә бит.

Гали. Кызганам, иптәш, кызганам!

Вәли. Нихәтле кызгансаң да, барыбер Зөләйха Мостафа хатыны булачак.

Гали. Ник алай?.. Ничек ул Мостафа хатыны булачак?

Вәли. Син хәерче бит. Мостафа — миллионер. Шуның өчен.

Г а л и. Зөләйха малга кызыга торган кыз түгел!

В ә л и. Зөләйха малга кызыкмаса кызыкмас, сүз юк. Әмма атасы кызыга шул.

Г а л и. Соң Зөләйханы ничек коткарыйм? Алла хакы өчен әйт әле! Син бит минем туганым кеби якыным, бер-бер юл күрсәт әле.

В ә л и. Ташла, дим, бу эшеңне! Үзең беләсең бит, Зөләйханыкыннан да зуррак эшләребез күп әле.

Г а л и. Нинди зур эшләр?

В ә л и. Бу арада митинг буласы бит.

Г а л и. Булса соң?

В ә л и. Хәзерләнергә кирәк ич!

Г а л и *(бераз уйлап)*. Кайда буласы?

В ә л и. Билгеле түгел әле.

Г а л и. Сөйләргә ни хәзерлим икән?

В ә л и. Әлбәттә, Думаны тарату һәм яңа сайлаулар тугрысында. *(Тора.)* Әйдә, кайтабызмы?

Г а л и. Ибраһимнар нишләп яталар? Эшләре бармы?

В ә л и. Басып бетерәбез, диләр. Әйдә, кайтасыңмы?

Г а л и. Бар кайт. Мин утырам әле.

В ә л и. Ярый. *(Кул биреп.)* Хуш. Иртәгә сиңа килермен.

Г а л и. Кил. Көтәрмен.

В ә л и. Йосыфны күргәнең юкмы? Югалды бит.

Г а л и. Юк, күрмәдем.

В ә л и *(китеп)*. Эчә торгандыр, йөзе кара. *(Югала.)*

Г а л и ялгызы.

Г а л и *(бераз моңаеп тора, сцена караңгылана башлый)*. Ардым... бу арада фикерем дә чуалды. Нишлим?.. Кая барыйм?! Ялгыз булсам да эчем поша, кеше арасына керсәм, ялгыз буласым килә... Китәр идем бер дә җан иясе булмаган бер урынга, күрмәс идем кабахәтлек үз юлымда!.. Әллә гыйшык тотам микән? Бардыр. Гыйшык тотмасам, бу кадәр җаным сызламас иде... И бичара! Әрәм буласың бит. Надан атаң һәм җаһил мулла аркасында үзеңне терелэй утка саласың бит... Майлы бәлеш төпләре ашап, кыйммәтле атларда йөреп, гомереңне бушка үткәрерсең. Әмма никадәр золым да күрәчәксең!.. *(Торып.)* Җитәр!.. Булса булыр, булмаса булмас. Аның әрәм булуына мин сәбәпче түгел; үзе гаепле ич. *(Йөри.)* Эчем поша... *(Йөрүчеләргә күрсәтеп.)* Менә бу кешеләр монда нишләп йөриләр икән?.. Әгәр куәтем җитсә иде, бөтен дөньяны

астын өскә әйләндерер идем!.. Аh!.. Бүгенге кеби hич тә эчем пошканы юк иде. Җитмәсә тагы Вәли бәйләнеп тора: «Бу арада мин сине hич тә аңлый алмыйм»,— ди. Ул түгел, үзем дә аңлап бетерә алмыйм әле. Икенче яктан бичара Зөләйха: «Качар идем дә, куркам», имеш. Кемнән hәм нидән курка?! Гаҗәп! Монда торып файда булмас. Кая булса да моннан китим әле. *(Китә башлаганда Йосыф керә.)*

Гали hәм Йосыф.

Йосыф *(Галине күрмичә).* Эчәм шул, кемнең ни эше бар! Үз кул көчем белән тапкан акчамны эчәм бит. *(Кәнәфигә утырып.)* Менә бу кәнәфидә дә минем хакым бар. Ничек бар? Бар булгач бар, дим! Юк, әйт әле, ничек бар? Ничек бар? Бу кәнәфине кем эшләгән? Эшчеләр. Йосыф кем соң? Эшче. Менә аңладыңмы инде? *(Галигә, танымыйча.)* Әй син, шулай бит?!.

Гали. Шулай, шулай. *(Үз-үзенә.)* Китим. Бәйләнсә котылып та булмас. *(Югала.)*

Йосыф ялгызы.

Йосыф. Молодец!.. Менә иртәгә эчмәм. Ничек эчмәссең? Акчам бетте. *(Янчык белән тәмәке чыгарып.)* Менә бу — тәмәке. Йосыф әфәнде тарта торган тәмәке. Махорканың первый сорты. *(Тәмәке төреп.)* Менә бу агачларда да минем хакым бар. *(Аягын тибеп.)* Бу җирдә дә минем хакым бар. *(Кулларын җәеп.)* Бөтен дөнья малында да минем хакым бар!.. Хакым күп җирдә бар. Әмма акчам юк. Бу ник болай икән? Ә?.. Уйла, башыңны ват, аннан соң белерсең. Башыңны кызганып уйламасаң, кеше дә булмассың. *(Тәмәке кабызып.)* Менә, кабызгач яна бит. Кабызмасаң янмас иде. Һәрбер эш шулай: тырышып эшләсәң — була. Тырышып эшләмәсәң — булмый. Җырласам — була, җырламасам — булмый. Әллә бер җырлыймммы?.. Җырла, Йосыф, кемнән дә курыкма! *(Җырлый.)*

Гомер үтте, хәлем бетте,
Ашарыма булмады;
Күп тырышып, нык эшләдем;
Рәхәт миңа килмәде.

Теләгәнемне булдырам бит! *(Шул вакытта полицейский килеп керә.)*

Йосыф hәм полицейский.

Полицейский. Әй син! Монда кыланып утырма. Бар, кит моннан!

Йосыф. Син кем?

Полицейский. Күп сөйләнеп торма, дим!

Йосыф. Юк, әйт әле, син кем?

Полицейский. Лыгырдап торма, дим!

Йосыф. Әйтәсең килмимени?

Полицейский. Килми.

Йосыф *(торып)*. Әй туган! Нишләп болай һаваланасың? Ә?..

Полицейский. Монда җырлап утырма, дим. Яхшылыкта бар кайт, дим.

Йосыф. Кайтмасам, ни эшләрсең?

Полицейский. Участкага алып барырмын.

Йосыф. Җиңә алмасаң?

Полицейский. Күп сөйләнеп торма. Кит, дим!

Йосыф *(утырып)*. Ардым. Ял итим әле.

Полицейский. Әле дә мыскыл итеп тора, бәдбәхет! *(Йосыфны тотып.)* Әйдә тор! Сиңа әйтәм бит!

Йосыф. Ардым, дим. Бераз ял итим.

Полицейский. Алаймыни? *(Йосыфны кулыннан тотып, сызгырта.)*

Йосыф. Әкрен! Халыкны куркытырсың!

Полицейский. Участкага барып ял итәрсең. Ярыймы?

Йосыф. Анда кибәк күптер.

Полицейский. Баргач күрерсең.

Йосыф. Әллә бет тә бармы?

Полицейский *(җавап кайтармый. Каравылчы керә)*. Әйдә тот! *(Йосыфны торгызып, алып бара башлыйлар.)* Менә күп сөйләнеп торсаң!

Йосыф *(карышмыйча)*. Эчәбез дә эчәбез. Ял итәргә таш пулатка барабыз. *(Югалалар.)*

Пәрдә төшә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Галинең бүлмәсе. Каршыда бер ишек. Уң тарафта урамга караган бер тәрәзә. Тәрәзә кырыенда кушетка. Сул тарафта бер өстәл һәм берничә скамья. Өстәл читендә бер шүрлек. Шүрлектә һәм өстәл өстендә төрле кәгазьләр һәм китаплар. Стенаның бәгъзе җирләрендә портретлар.

Фатыйма абыстай ялгызы.

Фатыйма *(пәрдә күтәрелгәндә тәрәзә янында утырып тора).* Күрше хатыннары балалары белән шаулап торалар. Гали дә өйләнсә ярар иде. Ичмаса, тик ятканчы, балаларын карап, гомеремне үткәрер идем. Нишләтим? Өйләнми бит. Иртә белән тора да, рәтләп ашамый-эчми, әллә кая чыгып йөри. Нихәтле белергә тырышып йөрсәм дә, һич тә белә алмыйм. Сорарга куркам. Чөнки бу арада ябыга да төште. Бер-бер усаллык артыннан йөрмәсә ярый ла... И Алла! Үзеңә тапшырдым инде. Ни уйларга да белмим. Дөнья усаллык белән тулып бетте. Монда талыйлар, анда үтерәләр... Гаҗәп! Күршеләр үзләренчә лыгырдыйлар, Гали үзенчә сөйли. Беркөнне Йосыф килде дә: «Кайгырма, курыкма. Мужиклар да җиргә туяр, безнең дә тормыш җиңеләер»,— ди. Бик вакыт, бик вакыт! Чөнки халык шулкадәр фәкыйрьлектә газапланып тора, карадың исә, еласың килә башлый! Без яшь вакытта байлык күп булмаса да, хәзерге кеби фәкыйрьлек һич тә юк иде. Хәзерге вакыт борынгы вакыт кеби түгел бит!.. Зур урамнарга чыгып карасаң исең китәр! Өчәр-дүртәр катлы зур-зур таш пулатлар. Нинди зур магазиннар. Уңга карасаң, кибет тулы алтын; сулга карасаң, кибет тулы энҗе-мәрҗән; кибет тулы төрле-төрле нигъмәтләр, якут ташлар кеби тезелеп торалар. Әмма шулай булса да ачялангач торучылар да бик күп, гаҗәп! Хәзерге байлыклар кайда китеп бетә икән соң? Бу мал белән кемнәр генә файдалана икән?..

Бер хатын тавышы *(урамнан).* Исәнме, Фатыйма абыстай!

Фатыйма. Аллага шөкер. Кая барасың?

Тавыш. Сезгә киләдер идем.

Фатыйма. Бик яхшы, рәхим ит.

Тавыш. Угылың өйдәме?

Фатыйма. Юк. Өебез аулак. Шәмсениса, кер, сөйләшеп утырырбыз.

Тавыш. Ярый, керим алайса.

Фатыйма. Әйдә, кер. *(Ишек янына бара. Шәмсениса керә.)*

Фатыйма һәм Шәмсениса абыстай.

Фатыйма *(Шәмсенисаны каршылап).* Әйдә, утыр. Эчем дә пошып торадыр иде. Ичмаса, синең белән бераз сөйләшеп утырыйк.

Шәмсениса. Пошар шул, җаным, пошар! Һәрдаим ялгыз торасың бит.

Фатыйма. Нишлим соң?

Ш ә м с е н и с а. Өйләндер. Ичмаса, килен белән икәү булырсыз.

Ф а т ы й м а. Өйләнми бит.

Ш ә м с е н и с а. Ник өйләнми соң?

Ф а т ы й м а. Белмим. Әйтеп-әйтеп карыйм да... тыңламый.

Ш ә м с е н и с а. Ни дип әйтә?

Ф а т ы й м а. Вакыт бар әле, өйләнермен, ди.

Ш ә м с е н и с а. Бик яшь тә түгел бит инде.

Ф а т ы й м а. Бик вакыт, җаным, бик вакыт! Егерме бишләрдән үтеп бара инде.

Ш ә м с е н и с а. Әллә бик сайлыймы?

Ф а т ы й м а. Юк! Хатын-кыз дигән сүзен авызыннан ишеткәнем дә юк. Ни уйларга да белмим, ахры, килен күрмичә үләрмен инде.

Ш ә м с е н и с а. И Алла! Ник алай дип әйтәсең? Алай әйтмә, җаным! Алла күрергә насыйп итсен диген.

Ф а т ы й м а. Амин!.. Рәхмәт әйткән сүзеңә.

Ш ә м с е н и с а. Менә Галигә Хәким кызы Зөләйханы тырышып алырга кирәк. Әрәм була бит мескен.

Ф а т ы й м а. Ярәшәләрме әллә?

Ш ә м с е н и с а. Менә!.. Әле генә белдеңмени?

Ф а т ы й м а. Кемгә бирәләр?

Ш ә м с е н и с а. Сөйләмә дә инде, җаным... Шундый укыган, гакыллы, фәһемле кызны, акчага кызыгып, Мостафага биреп харап итәләр бит!

Ф а т ы й м а. Гани бай угылынамы?

Ш ә м с е н и с а. Әйе... Гани бай угылына.

Ф а т ы й м а. И мескен! Юкка югала икән.

Ш ә м с е н и с а. Югала, җаным, югала. Байлыгы корсын! Акча рәхәт бирми бит. Бер бозык, пиянич егеткә шундый кызны биреп, утка салчы, аһ!.. Бераз Алладан куркырга кирәк иде.

Ф а т ы й м а. И Шәмсениса, Шәмсениса!.. Хәзерге халык Алланы онытты инде, хәзер кеше акчаны сүксә дә, яратмаса да, шул акчага кол булып, кушкан эшне эшли бирә, хәтта акчага табына, акча күрдеме, берни дә күзенә күренми, малы гына булсын.

Ш ә м с е н и с а. Шулай шул, шулай... Гали кайда китте соң? Тиз кайтырмы?

Ф а т ы й м а. Галигә йомышың бармы әллә?

Ш ә м с е н и с а. Йомышым юк. Мәскәүгә, угылыма әдрис кенә яздырасы бар иде.

Фатыйма. Бераз көтеп тор. Бәлки кайтып та кермәс микән.

Шәмсениса. Башка кешедән яздырып җибәрсәң тапшырылып җитми. Әллә җиткезеп яза белмиләр шунда. (...) *(Гали кайтып керә.)*

Шулар ук һәм Гали.

Фатыйма *(каршылап)*. Кайттыңмы? Самавыр куйдыйыммы? Чәй эчәсең килә торгандыр?

Гали. Куйдыр, эчәрбез. *(Шәмсенисаны күреп.)* Кунак та бар икән. Исәнме, Шәмсениса абыстай?

Шәмсениса. Аллага шөкер. Үзең исән генә йөрисеңме? *(Фатыймага.)* Син, Фатыйма абыстай, минем өчен борчылма. Рәхмәт! Эчәсем килми. *(Галигә.)* Гали, миңа бер әдрис кенә язып бирсәнә.

Гали *(өстәл янына утырып)*. Кемгә языйм?

Шәмсениса *(конверт белән кәгазь биреп)*. Менә монда татарча язылган.

Гали *(алып)*. Мәскәүгә?

Шәмсениса. Әйе, Мәскәүгә. Угылыма. Байлары аркылы язарга кушкан бугай.

Гали. Ярар, ярар, язармын. *(Язып бирә.)*

Шәмсениса. Рәхмәт, Гали, рәхмәт. Алла теләгәнеңне бирсен.

Фатыйма. Угылым, Шәмсениса абыстай бер бик зур кызганыч хәбәр китерде.

Гали. Бер-бер кеше хатынын аергандыр инде.

Фатыйма. Юк. Аннан да кызганычрак.

Шәмсениса. Бик кызганыч!

Гали. Ни соң?

Шәмсениса. Гани бай угылы Мостафа өйләнә, харап итә инде.

Гали *(торып)*. Кемне ала?..

Шәмсениса. Әрәм итә инде. Зөләйханы.

Гали *(каушап)*. Дөресме?

Шәмсениса. Дөрес. Бик дөрес! Эшне бик кызу тотарга уйлыйлар. Чөнки никахны иртәгә үк укытырга торалар.

Гали *(каушаганын белгертмичә)*. Нишләмәк кирәк соң!.. Тере килеш утка салалар шул. *(Янә утыра.)*

Шәмсениса. Мин китим инде. Өйдә бераз эшем дә бар. Хушыгыз, гаеп итеп калмагыз. Гали, рәхмәт сиңа.

Фатыйма. Әйдә, сине озатыйм. *(Икесе дә чыгалар.)*

Гали ялгызы.

Гали. Йа Алла!.. Ни кылыйм?.. Бу бичара кызны ничек итеп коткарыйм?.. *(Йөри.)* Бу сүзләрне ишеткәч, җаным утта янган шикелле булды... Вәлинең сүзе дөрес. Мин гыйшык тотам икән... Елдан артык үз-үземне алдалап, аны кызганам гына дип йөрдем. Әмма хәзер ышандым... Иртәгә никах булачак, ди. Булмас! Ышанмыйм... Мостафага бармый, минем белән качмас микәнни?.. Йа Алла! Нишлим?! Ярдәмеңне сорыймын! Ни булса да булыр, актык хатымны языйм әле. *(Утырып яза башлый.)* «Җаным! Яз көне сине Габделкадыйр сорый һәм сине аңар бирәләр имеш дигән сүзләрне ишеткәч, минем вөҗданым бер дә тынычлык тапмаган иде. Сине сөйгәнлегемне язмыйм. Чөнки аны үзең бик яхшы беләсең. Үзеңнән барып сорадым. Хәзергә торып торам, дәваланам, дидең. Шуннан соң мин сине, көз көне хатыным булырсың дип өмет итеп, бу көнгә кадәр көтеп тордым. Хәзер генә синең кинәт, минем хатыным булмыйча, икенче кешегә барасыңны ишеттем һәм белдем... Ни уйлыйм?! Бер дә белә алмыйм, җаным! Минем бәхетем син булмыйсың икән... Нишлим?! Булмасаң булмассың. Мин... мин разый. Разый булсам да, актык мәртәбә җавабыңны сорыйм: бу барасы кешеңне күргәнең бармы? Аны беләсеңме? Һәм яратып барасыңмы? Әгәр минем шушы өч сөалемә: әйе, дип җавап бирсәң, җаным тыныч булыр. Әмма юк дисәң... ни эшлим?! Хуш, җаным, хуш! Әле вакыт үтмәгән. Үлсәм дә, булдырырга тырышырмын! Кайвакытта да һәм кай урынга булса да, үзеңне алмага барырга кушсаң, барырмын, җаным, барырмын!» *(Язган хатны конвертка салып, урыныннан тора, киенә һәм хатны кулына тотып чыга башлый.)* Мин кая барам? Үзем ничек тапшырырмын икән? Йа Алла! Кемнән сорыйм? Бу хатны кем белән җибәрим? *(Тыңлый.)* Кеше килә бугай. *(Ишеккә карый. Йосыф килеп керә.)*

Гали белән Йосыф.

Гали *(хатны биреп)*. Йосыф, мә, бар! Хәзер бар!

Йосыф. Тукта, ашыкма. Ичмаса, утырып, бер тәмәке тартыйм.

Гали. Юлда тартырсың. Бик кирәк.

Йосыф *(Галигә карап)*. Иптәш, сиңа ни булды?

Гали. Берни дә булмады. Мә хатны, бар!..

Йосыф *(алып)*. Кая барыйм соң?

Г а л и. Ары бар... Беләсең ич!..

Й о с ы ф. Тукта, каушама. Рәтләп кенә әйт әле, ни булды? Әллә бер-бер зур хәбәр ишеттеңме?

Г а л и *(үз-үзенә)*. Уф Алла!.. *(Кычкырып.)* Утыр.

Й о с ы ф *(утырып)*. Йә, ни бар?

Г а л и. Син Зөләйханың йортын беләсеңме?

Й о с ы ф. Беләм.

Г а л и. Синең аларга барганың бар бит?..

Й о с ы ф. Бар.

Г а л и. Бүген анда бара аласыңмы?

Й о с ы ф. Ун тапкыр бара алам.

Г а л и. Зөләйханы күрә аласыңмы?

Й о с ы ф. Йөз тапкыр күрә алам.

Г а л и. Менә шушы хатны Зөләйхага илтеп бир, мөмкин булса, җавап та алып кайт. Төшендеңме?

Й о с ы ф. Фу, беткере!.. Куркытып бетердең. Баштук шулай дип әйтергә кирәк иде. Мин әллә ни булган дип уйладым.

Г а л и. Яхшы кара, һичкем белмәсен, берәү дә күрмәсен.

Й о с ы ф. Беләм инде, беләм. Йосыф барысын да белә... Әүвәл белгертмичә йөргән булдың. И иптәш! Йосыфтан яшергән буласың бит!

Г а л и. Гаеп миндә.

Й о с ы ф. Йосыфтан якын кешең бармы соң?

Г а л и. Гаеп миндә, дим ич!

Й о с ы ф. Бетте. Соңыннан сөйләшербез. *(Тора.)* Барып, әүвәл эшне булдырыйм.

Г а л и. Алла хакы өчен шыпырт йөр. Ярыймы?

Й о с ы ф. Чебен булып керермен, бака булып чыгармын! Йосыфны өйрәтмә, йәме? Йосыф дөньяны синнән күбрәк күргән.

Г а л и. Өйрәтмим, әйтәм генә.

Й о с ы ф. Әйтмә дә! Нинди эштә ничек йөрергә кирәкне Йосыф үзе дә бик яхшы белә. *(Чыга.)*

Г а л и ялгызы.

Г а л и. Китте... Нинди җавап алып кайтыр икән?.. Эчем поша... *(Чишенә.)* Кызганам, кызганам диеп кенә йөреп ниндәен хәлгә килеп җиттем... Нишлим соң? Сөям бит. Үземә Зөләйхадан да артык иптәш һич тә таба алмам дип беләм. Чөнки гомеремдә күп кыз күргәнем булса да, аның кеби кызны күргәнем юк иде... Юк, түгел, күргәнем бардыр. Әмма сөйгәнгә күрә ул миңа бик якын күренә торгандыр. *(Тәрәзә янына*

барып, урамга карый.) Менә аның тора торган йорты. Җаным, нишләп торасың? Мостафага барып, рәхәт гомереңне кайгыда үткәрерсең. Мал эчендә торып, күз яшеңне һәрдаим түгәрсең. Берни дә күрмәссең, белмәссең, барасы килгән җиреңә бара алмассың, теләгән эшеңне эшли алмассың! Фәкать Мостафага кол булып кына гомереңне әрәм үткәрерсең. *(Сцена уртасына туктап.)* Эчем поша. *(Өстәл янына барып утырып, китап караган була. Соңра кычкырып укый.)* «Җәй көне. Кояш бу көн, бер-бер нәрсәгә ачуланган кеби, үзенең кызуы илән җан иярен һич кызганмый җәберлидер иде. Чөнки июль числосының эсселегеннән, урам тузаны гына житми, чокырларда булган сулар кибеп, чокыр бөтенләй тузанга әйләнеп, һаваны тузан илә тутырадыр иде. Шундый көннәрдә агачларда кунган кара каргаларның тавышлары адәмнәрнең колагына «Яңгыр, яу! яу! яу!» дигән кеби ишетеләдер иде. Агачларның моңаеп торуларыннан су сораганнары сизеләдер иде. Арыш башаклары, җил аз булганга күрә, бер-берсенә акрын гына бәрелеп: «Түз, иптәш, түз!.. Алла яңгыр бирер әле, бирер!» — дип, бер-берсе белән сөйләшкән кеби кешеләрнең күзенә күренәдер иде». *(Китапны куеп.)* Юк, түзәр хәлем калмады! *(Уйланып торган вакытта Вәли килеп керә, аның кергәнен Гали сизми.)*

Гали белән Вәли.

Вәли *(Галигә карап үз-үзенә)*. Ни бар икән? *(Бер мәртәбә йөткерә.)*

Гали *(әйләнеп)*. Килдең? Мин сине көтәдер идем.

Вәли. Килдем, кичә әйткән идем ич: төшәрмен дип. Әллә оныттыңмы?

Гали. Юк. Онытмадым.

Вәли *(үз-үзенә)*. Монда әллә ни бар. Зөләйхадыр инде. *(Кычкырып.)* Теге кәгазьне тәрҗемә итеп бетердеңме?

Гали. Бетердем.

Вәли. Кайда, карыйм әле.

Гали. Юк, бетермәдем әле. *(Тәрәзә янына бара.)*

Вәли *(үз-үзенә)*. Монда Зөләйха гына булмаска кирәк. Чөнки бер дә төсе калмаган. *(Утыра.)*

Гали *(тәрәзәдән карап)*. Әнә күрше түбәсендә ике күгәрчен утыра. Гаҗәп... күзгә күз генә карашып торалар. Бер-берсен бик сөя торганнардыр, ахры... Вәли, бу ике мәхәббәтле күгәрченне көчләп аерырга кемнең хакы бар?

Вәли. Менә ни нәрсә уйлап чыгардың!

Гали. Юк. Алай да. Минем беләсем килә.

Вәли. Анарны аерып торырга берәүгә дә хаҗәт түгел.

Гали. Мин хаҗәт дип сорамыйм. Аерырга хаклары бармы диеп кенә сорыйм.

Вәли. Нишләп булсын! Юк.

Гали *(онытылып)*. Алла безне дә ник күгәрчен итеп яратмаган икән? Безне дә беркем аера алмас иде. *(Моңлана.)*

Вәли *(үз-үзенә)*. Хәзер беләм инде. Зөләйханы Мостафага бирә торганнардыр, ахры. *(Кычкырып.)* Гали, Йосыф килгәне юкмы?

Гали. Хәзер генә монда иде.

Вәли. Кая китте?

Гали. Мин аны бер йомыш белән җибәрдем. *(Вәли янына килеп.)* Вәли... кичә әйткән сүзләрең дөрес булып чыкты бит... Үзем дә бүген генә белдем.

Вәли. Нинди әйткән сүзләрем?

Гали. Кичә бакчада әйткән сүзләрең.

Вәли. Аңламыйм. Мин, монда кереп, сине күргәч үк бер-бер хәл бар дип белдем; сорарга кыймадым. Яшермә, иптәш. Дөресен әйт. Ни булды?

Гали. Ни булсын?.. Зөләйханы Мостафага бирәләр.

Вәли. Гаҗәп түгел. Бирерләр шул.

Гали. Гаҗәп түгел? Күгәрченнәрне аерырга беркемнең дә хакы булмагач, безне аерырга кемнең хакы бар соң?!

Вәли. Бар шул.

Гали. Ул кем? Әйт!

Вәли. Зөләйханың атасы, Хәким.

Гали *(кызуланып)*. Аның правосы бармыни?!

Вәли. Төптән караганда булмаса да, бар. И Гали! Моны да белмисеңмени? Син үзеңне, егерменче гасырда торганыңны онытып, егерме беренче, егерме икенче гасырда торамын дип уйладыңмыни?.. Як-ягыңа әйләнеп кара әле: анда гаделсезлек, монда җәбер!.. Беләм, иптәш, беләм! Үзем гыйшык тотканым булмаса да, авыр хәлеңне күрәм... Әмма вакыт үтте инде.

Гали. Бер-бер гакыл бир әле.

Вәли. Ни әйтим?.. Баштук мине тыңлаган булсаң, кызганам, кызганам дип, вакытны бушка үткәреп йөргәнче, хезмәтеңдә булсаң, бу хәлгә төшмәгән булыр идең. Үзең уйлап кара: хәзерге вакытта синең фикереңне аңлый торган кызлар бармы? Юклыгын үзең дә беләсең бит.

Г а л и. Укыган кызларыбыз юкмыни?

В ә л и. Укыган кызларыбыз бар. Ник булмасын. Әмма фикерле кызларыбыз юк. Мин укыган кызларыбызга карыйкарый гаҗәпкә калам. Аларның күбесенә, шомлыкка каршы, Алла матурлык биргән. Алар шул матурлыклары аркасында, башларын күккә күтәреп, муеннарын боргалап йөри-йөри, башларын фикер белән түгел, җил белән тутыралар. Җилнең дә файдалысы булса ярар иде. Файдасыз җил белән тутыралар; һәм көн буе портнихаларга йөреп, матур киемнәр белән берберсен уздырырга тырышып, гомерләрен әрәм итәләр. Менә сиңа Габдулла кызы Мәрьям: матур, солтанәт, укыган һәм байлыгы да юк түгел. Ник аңа гыйшык тотмыйсың? Менә сиңа Хәсән кызы Рабига: буе зифа, биле нечкә. Ник аны сөймисең?

Г а л и. Зөләйха болар кеби түгел ич.

В ә л и. Шул Зөләйхага елдан артык фикереңне чәчеп йөрдең. Әмма бер генә тиенлек файда күрдеңме? Юк. Ни өчен юк икән?

Г а л и. Аңламагандыр.

В ә л и. Аңламагандыр... Кара, надан эшче белән ике тапкыр утырып сөйләшсәң аңлый. Әмма безнең укыган кызларыбызга бер ел фикер чәчсәң дә аңламыйлар. Гаҗәп!.. Иптәш! Өйләнәсең килсә, тот та бер эшче кызы ал. Ичмаса, чәчкән фикерең әрәм булмас. Җаның да тыныч булыр. Чөнки эшче кызларның фикере безнең укыган кызларның фикере кеби чуалчык түгел. Алар укыган кызлар кеби төрле якка чапмый, чын хатын булып гомер итәчәкләр һәм балаларына да чын ана булачаклар!

Г а л и. Кара, бу фикерең хата фикер түгелме? *(Башын түбән салып моңлана.)*

В ә л и. Һич хата түгел!.. *(Галигә карап.)* Гали! Минем бу сүзләремне тыңлап тору сиңа җиңел түгел. Беләм. Әйт, иптәш. Кулымнан килгән кадәр сиңа хезмәт итәрмен.

Г а л и. Рәхмәт... Йосыф кайтсын әле... Соңыннан уйлап карарбыз.

В ә л и. Йосыфны кая җибәрдең соң?

Г а л и. Зөләйхага.

В ә л и. Зөләйхага?! Ни өчен?

Г а л и. Миннән хат алып китте.

В ә л и *(башын селкеп)*. Җавап китерәчәкме?

Г а л и. Җибәрсә китерәчәк. *(Бераз сөйләшми торалар.)*

Шулар ук һәм Йосыф.

Йосыф. Кайттым. Гали, мә тот. *(Хатны бирә. Гали торып хатны ала һәм үз-үзенә укый. Йосыф, Вәли — икесе Галигә карап торалар.)*

Гали *(хатны укып бетереп).* И мал! Бу дөньяның иманы син! Бу дөньяда синнән куәтле бер-бер нәрсә бар микән?! Йа Алла! Кайчан син бу җансыз малның куәтен бетереп, бөтен дөньяга гаделлек чәчәрсең икән?!! *(Кулындагы хатны ыргытып).* Мә, укыгыз! *(Утыра.)*

Йосыф *(хатны алып).* Кайгырма, иптәш, кайгырма! Барысы да булыр. Тырышырга гына кирәк. Әгәр бергәләшеп тырышсак, гаделлекне Алла чәчәчәктер. *(Вәлигә.)* Мә, укы, иптәш. Без дә белик, бер-бер эш чыгарып булмас микән?

Вәли *(укый).* «Әфәндем! Мин Мостафага бармыйча, синең белән качарга разый. Боңар анам да разый. Чөнки ул сине бик ярата. Әмма... рәнҗи күрмә, әфәндем!.. Мостафага теләми баруымны һәм синең белән булган дуслыкларымны атам белгән. Ул, анамны чакыртып, аңар шул сүзләрне әйткән: «Әгәр Зөләйха мин теләп бирә торган бай егеткә бармыйча, Гали белән качса, ул вакытта син гаепле булырсың. Шуның өчен сине һәммә балаларың белән өемнән куып талак итәрмен»,— дигән. Әфәндем! Үзем рәхәттә торырмын дип, анамны актык көннәрендә утка салыйммы? Юк, салмыйм! Ни булса да булыр, анамны бәладән коткарып, үземне утка салам. Хуш». *(Хатны өстәл өстенә куя.)*

Йосыф. Әгәр куәтем җитәрлек булса иде, Хәким бай һәм Гани бай кеби кешеләрне һәммәсен бер өемгә өеп, салам белән каплар идем, аннан соң керосин сибеп, ут белән газап кылыр идем!.. *(Вәли читкә китеп тора, Йосыф сцена уртасына стулга утыра. Һәммәсе дә моңланып торган вакытта, урамнан «Караул!» дип кычкырган бер тавыш ишетелә. Вәли белән Гали башларын күтәреп тәрәзәгә карыйлар. Йосыф, урыннан торып тәрәзәгә йөгерим дигәндә, стулы белән авып егыла. Урамнан шул ук «Караул!» дип кычкырган тавыш тәкрар ишетелә. Гали белән Вәли торалар. Йосыф та, торып, тәрәзәгә йөгерә һәм башын сузып кычкыра.)* Сал берне!

Вәли. Чү!.. Нишлисең?

Гали. Ни бар?

Тавыш. Караул!

Йосыф. Сал берне, сал!

Гали }
Вәли } *(йөгереп, бергә)*. Ни булды?.. Ни бар?

Йосыф. Камчы белән кыйный!

Тавыш. Караул!

Йосыф. Сал! Сал берне!

Вәли *(тәрәзәдән карап)*. Ха! ха! ха!.. Чү, бәлагә керерсең.

Гали. Кычкырма, иптәш, кычкырма!

Тавыш. Караул!

Йосыф. Сал берне!.. Шулай!

Тавыш. Караул!

Йосыф. Ә, ә, ә... Халыкны кыйнаганда яхшы идеме? Сал берне!

Вәли. Чү, дим, бәдбәхет!

Гали. Зинһар, кычкырма!

Йосыф. Туганнар! Бу шатлыктан бөтен әгъзаларым уйнап тора. Кара. *(Бии.)*

Тавыш. Караул! Караул!.. *(Тавыш ераклаша бара.)*

Йосыф. Сал берне!.. Кара... аты сыер төсле. Һич тә әйләнә алмый.

Вәли. Менә кызык.

Гали. Кешене каны чәчрәп чыкканчы кыйнасыннар да, кызык булсын, имеш. *(Өстәл янына бара.)*

Тавыш *(ерактан)*. Ка-ра-у-л!

Йосыф. Юк, туганнар! Мин чыдый алмыйм. *(Тәрәзәдән урамга сикереп төшә. Үзе күренмичә.)* Сал берне! Сал!.. Менә, менә... шулай!

Вәли. И бичаралар! Гакыллы җанияләре! Ерткыч хайваннар кеби бер-берегезне ашар вакыт килеп җиттемени?..

Пәрдә төшә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Урам. Каршыда уң яктарак капка һәм калитка. Сул якта витрина (витрина куярга мөмкин булмаса, кое яки бер агач. Әлхасыйль, ике кеше ышыкланырлык бер урын). Пәрдә ачылган вакытта, берничә вакыт сцена буш һәм моң булып тора. Бераздан Йосыф керә.

Йосыф ялгызы.

Йосыф. Менә бу йорт. Әмма һич тә йорт кыяфәте юк... Бу йорт җәһәннәм капчыгы төсле. Алай булса да, бу йортта никах булачак. Нинди никах? Кемне бирәләр?.. Бер фәрештә кеби

кызны ерткыч бүрегә охшаган Мостафага бирәләр бит!.. Шул сүзләрне уйласаң, бөтен дөньяны һәлак итәсең килә! И мескен!.. Кичә Гали хатын укыганда елады. Чыдап булмады, мин дә еладым. Кызганыч бит. Никадәр яшь түгеп, никадәр хәсрәт күрә торгандыр... Гали дә бик кайгыра. Авырмаса ярар иде. Аны да бик кызганам. Ирлек гайрәте күп булганга гына кичә еламады бит. Мин дә елаган булыр идем, урамдагы вакыйга булып кына еламый калдым. И бичаралар!.. Бу ике яшь гомерне ничек итеп бергә кушасы? Гали әрәм булмый. Менә Зөләйха әрәм була. Галигә Зөләйхадан да матуррак кыз табарга тырышырбыз әле, Алла боерса! Зөләйха югала. Менә аны ничек итеп коткарасы? *(Бераз уйлап.)* Уйлаган эшемне эшләми ярамый. Зөләйханы ничек булса да урлыйм. Соңыннан икесен бергә кавыштырып шатландырыйм әле... Разый булмас. Куркак бит. Булмаса булмас, тотармын да көчләп алып китәрмен! *(Вәли керә.)*

Й о с ы ф һәм В ә л и.

В ә л и. Йосыф, син монда нишләп йөрисең?

Й о с ы ф. Тик. Эчем пошканга.

В ә л и. Галине күрмәдеңме?

Й о с ы ф. Ул бүген өенә дә кайтмаган. Абыстайның бик эче поша.

В ә л и. Пошмый ни. *(Йосыфка карап.)* Күзләрең бик ялтырый, иптәш. Әйт. Миннән яшермә. Монда нишләп йөрисең?

Й о с ы ф. Эшне бозып йөргән буласың тагы.

В ә л и. Әйтмисеңмени?

Й о с ы ф. Синнән котылып булмас инде. Бел алайса: Зөләйханы урламакчы булам. Белдеңме?

В ә л и. Урламакчы? Кемгә? Ни өчен?

Й о с ы ф. Кемгә дип сораган буласың тагы! *(Башын кашып.)* Бик кызганыч бит. Икесен дә кавыштырырга уйлыйм.

В ә л и. Кемнәрне?

Й о с ы ф. Кемнәрне... Гали белән Зөләйханы.

В ә л и. Әллә шаштыңмы?

Й о с ы ф. Юк, шашмадым. Нишләп шашыйм... Уйлап кара әле, иптәш, бу эштә ике кешенең гомере юкка югала бит.

В ә л и. Кичә Зөләйха хатын укыганда бар идеңме?

Й о с ы ф. Булса?

В ә л и. Аңладыңмы?

Й о с ы ф. Син әллә ни сөйлисең!.. Зөләйха әрәм булса ярый. Әмма анасы әрәм булса ярамый, имеш. Соң Зөләйха дөньяга үз рәхәтен күрми, кеше рәхәте өчен генә килгәнмени?!

В ә л и. Бик дөрес!.. Ләкин мин Галинең гыйшык тотуына ышанып бетә алмыйм.

Й о с ы ф. Ник ышанып бетмисең?

В ә л и. Ул сөйми, кызгана гына. Кара да тор, бер айдан Зөләйханы онытыр. Шиксез онытыр!

Й о с ы ф. Булмас. Онытмас, иптәш.

В ә л и. Онытмас? Гали онытмасмы? Гали кем соң? Интеллигент бит! Интеллигентларның гыйшык тотулары һич тә бер айдан артыкка бармый! Белдеңме?

Й о с ы ф. Гали андый түгел шул. Мин Галигә ышанам.

В ә л и. Вот ни. Монда вакытыңны бушка уткәреп йөргәнче, Галине кара.

Й о с ы ф. Нишләп карыйм? Ул имчәк баласы түгел бит.

В ә л и. Аны әләктерергә йөриләр.

Й о с ы ф. Кемнәр?

В ә л и. Кемнәр. Үзең беләсең.

Й о с ы ф. Булмас. Ышанмыйм.

В ә л и. Ышанмасаң, Зөләйха капкасын саклап йөр.

Й о с ы ф. Нишлим соң?

В ә л и. Сак булырга кирәк. Нинди вакыт икәнен беләсең бит.

Й о с ы ф. Кая югалды икән? Иптәш, әйдә эзләп табыйк әле.

В ә л и. Бар син эзләп тап. Мин, менеп, өендәге кәгазьләрен карап чыгыйм әле. Ярыймы?

Й о с ы ф. Ярый. *(Ашыгып китә.)*

В ә л и *(Йосыф артыннан)*. Шәһәрнең бер җирен дә калдырмый эзлә!.. Әгәр Галине дә тотып япсалар, бер кешебез дә калмый. Калмаса калмас, әрәм итәргә кирәк түгел. Аны иртәгә үк икенче бер шәһәргә озатып, яшерми ярамый. *(Каранып.)* Менә кунаклар да җыела башлады. Өенә менеп тикшереп карыйм әле. *(Китә. Шул вакытта ике кунак килеп керәләр.)*

И к е к у н а к.

Б е р е н ч е с е. Бу кем? Безне күреп качты.

И к е н ч е с е. Белмисеңмени?

Б е р е н ч е с е. Белсәм сорамас идем.

И к е н ч е с е. Бу Вәли дигән бер кеше.

Б е р е н ч е с е. Кайсы Вәли?

Икенчесе. Гали иптәше. Белмисеңмени?

Беренчесе. Социализм Галинеңме?

Икенчесе. Әйе.

Беренчесе. Әйтәм, мәхәббәтсез. Үзе татар бүрке кигән булган. Мыскыллап йөрмәсә ярамаганмыни!

Икенчесе. Ис тә китәрлек! Шулкадәр дин хурлап йөриләр бит. Аларны ничек җир йотмый? Гаҗәп.

Беренчесе. Алла түзә. Җәһәннәмдә урын хәзерләп куйгандыр инде.

Икенчесе. Куймый ни. *(Шул вакытта Гали витрина артына поса.)* Без социализм, имеш! Безнең партиядән гадел партия юк! Без фәкыйрьләр өчен тырышып йөрибез дип, авызларын ачып, оялмаенча сөйләп йөриләр җитмәсә.

Беренчесе. Падишаһ юаш. Мин падишаһ булса идем, барысын да җыеп, астырып бетертер идем.

Икенчесе. Бетерми ни... Аларның партияләре гадел партия булса иде, бөтен муллалар социализм булырлар иде.

Беренчесе. Куй. Сөйләмик. Аларны сөйләп, гөнаһка гына батып бетәрбез. Алла сакласын!

Икенчесе. Дөрес шул. Әйдә, керик.

Беренчесе. Кунаклар күренми әле, бераз сөйләшеп торыйк. *(Шул вакытта Вәли дә Галинең артына акыртын гына килеп поса, Гали сизми.)*

Икенчесе. Уйлап торам-торам да, социализмнарга карап исем китә.

Беренчесе. Бер дә ис китәрлек түгел. Дөньяда алардан бозык кеше һич тә юк. Син аларны әллә кем дип белдеңмени?

Икенчесе. Нишләп әллә кем дип белим? Алла сакласын!.. Алар бигрәк тә кызык кешеләр бит. Мөселман хатын-кызлары, марҗалар кеби, качмыйча йөрсеннәр, имеш. Ха! ха! ха!..

Беренчесе. Теләгән кеше, теләсә кем хатыны белән торсын, диләр. Ха! ха! ха!.. Менә бусы кызык ичмаса. Ягъни... Аларча, шулай була: бөтен дөнья зина кылсын, имеш инде. *(Шул вакытта Гали, чыдый алмыйча, поскан урыныннан чыгып күренә.)*

Шулар ук һәм Гали.

Гали. Туганнар! Сөйләшкән сүзләрегезне ишетәсем килмәсә дә, бераз тыңлап тордым. Бу сөйләшкән сүзләрегез һәммәсе ялгыш. Чөнки сез, безнең мәсләгебезне бер дә белмичә, фәкать җаһил кешеләргә ияреп кенә хата әйтәсез.

Икенчесе. Без монда синең сүзеңне тыңлар өчен килмәдек. *(Иптәшенә.)* Керик.

Гали. Кардәшләрем! Мин сезне монда озак тотмам.

Беренчесе. Әйдә, керик.

Гали. Бу качуыгыз белән үзегезнең бернәрсә дә белмәвегезне күрсәтәсез бит.

Икенчесе. Теләсәң ни әйт. *(Керең китәләр.)*

Гали. Киттеләр... *(Сцена уртасына туктый. Вәли керә.)*

Гали һәм Вәли.

Вәли *(Галинең җилкәсенә кулын куя, Гали сискәнеп, башын борып карый).* Иптәш! Бу юк эшләреңне кайчан ташларсың икән?

Гали. Син икәнсең. Мин кайттылармы дип торам.

Вәли. Бу татарларга сөйләп, бер-бер файда булыр дип беләсеңме? Һич юк!

Гали. Белмичә сөйлисең бит.

Вәли. Беләм, барысын да беләм! Сине күрдем дә, килеп, артыңда посып тыңлап тордым.

Гали. Мин бераз файдалы булмас микән дип сөйли башлаган идем. Тыңламадылар.

Вәли. Аларга пәйгамбәр килеп сөйләсә дә тыңлаячаклар түгел.

Гали. Ышанмыйм.

Вәли. Ышанмыйсың? Тыңладыларммы соң?.. Эшләр бозылып торган вакытта, юк артыннан йөргән буласың.

Гали. Әллә бер-бер нәрсә булдымы?

Вәли. Булды шул.

Гали. Ни булды?

Вәли. Николайны тотып япканнар.

Гали. Китсәнә? Булмас, иптәш.

Вәли. Мин юкны сөйли торган кеше түгел ич. Үзең беләсең.

Гали. Беләм, иптәш, беләм.

Вәли. Әйдә. Моннан китик.

Гали. Моннанмы?

Вәли. Әйе, моннан.

Гали. Зөләйхага хәзер никах укытырга торалар бит.

Вәли. Никах укыталар дип, аның өен сакламакчы буласыңмы? Өен саклап, төрмәгә керәсең киләмени?

Гали. Нишләп төрмәгә керим?

Вәли. Сине дә тотарга йөриләр. Әйдә, качыйк.

Гали. Минеме?

Вәли. Сине шул. Эзләп йөриләр инде.

Гали. Өемдә дә булдылармыни?

Вәли. Белмим. Булганнардыр. Булмасалар да, өйгә кайтырга ярамый. Саклый торганнардыр.

Гали. Йа Алла! Кая качырмакчы буласың?

Вәли. Почтовый атлар алып, бер-бер станциягә кадәр китми ярамый. *(Шул вакытта сцена артында елаган тавышлар ишетелә.)*

Гали. Чү... ни бар икән? Елыйлар бугай?!

Вәли. Белмим. Әйдә ышыкланыйк! *(Посалар, Зөләйха бер карчык белән елап чыга.)*

Шулар ук һәм Зөләйха.

Зөләйха. Әрәм булам, җаным, әрәм булам!.. Никахымны да тыңларга рөхсәт бирмәделәр!.. Яратмаган кеше белән ничек торырмын икән?.. Ничек гомеремне үткәрермен икән?.. *(Югалалар.)*

Гали белән Вәли.

Гали. Җаным...

Вәли *(Галинең авызын кулы белән каплап)*. Чү... Нишләмәкче буласың?!

Гали. Җибәр!..

Вәли. Чү, дим! Кая бармакчы буласың?

Гали. Бармыйм. Җибәр! *(Вәли җибәрә.)* И бичара, бичара!.. Бу мөбарәк яшьләреңне мал аркасында түгәсең бит!.. Һәм никадәр түгәчәксең!

Вәли. Иптәш, җитәр! Монда торып эләгәбез бит. Әйдә, китик.

Гали. Хәзер миңа бар да бер инде.

Вәли. Әйдә, дим.

Гали. Бармыйм.

Вәли. Шулаймыни?

Гали. Шулай.

Вәли. Хуш алайса! *(Китә башлый. Гали Зөләйха киткән тарафка карый. Гали белән Вәлинең арасы ераклашкач, бер кеше керә.)*

Шулар ук һәм бер кеше.

Кеше. Гаеп итмәгез. Гали әфәнде сез буласызмы?

Гали. Сезгә миннән ни кирәк? *(Шул вакытта Вәли витрина артына поса.)*

В ә л и *(үз-үзенә)*. Эләкте...

К е ш е. Сез Гали әфәнде буласыз бит?

Г а л и. Мин.

К е ш е. Сез булсагыз, минем артымнан рәхим итәсез.

Г а л и. Нишләп мин сезнең артыгыздан барыйм?

К е ш е. Эшне зурайтмагыз. Барыбер барачаксыз.

Г а л и. Мине кая алып бармакчы буласыз?

К е ш е. Монда сөйләшеп торырга мөмкин түгел. Барып җиткәч сөйләшербез.

Г а л и *(үз-үзенә)*. Эләктерделәр... *(Кешегә)*. Әйдәгез. *(Китәләр.)*

В ә л и ялгызы.

В ә л и *(таягын ике кулына тотып)*. Харап булды! И бу Гали кебек кешеләрне!.. *(Таягын шартлатып сындыргалап.)* Барыйм әле. Кая илтеп кертер икән? *(Югала.)*

Пәрдә төшә.

БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Гани бай йорты. Каршыда, уң һәм сул тарафта ике ишек. Ике ишек арасында мич. Уң тарафта стена буенда палас. Палас өстендә йомшак кәнәфи, ике кресло һәм өстенә кыйммәтле, бәйләгән эскәтер япкан түгәрәк өстәл. Өстәл өстендә яхшы лампа. Кәнәфи өстендә стенада көзге. Пәрдә кырыенда түгәрәк өстәл белән гөл. Сул якта агач кәнәфи, аш өстәле һәм венский стуллар. Кәнәфидән бире зур көзге һәм түгәрәк өстәл белән гөл. (Мөмкин булса, бүлмәне арка белән дә бүлеп куярга ярый.) Сул тараф стенада пәрдәләр белән томалап куйган ике тәрәзә. Коридорга чыга торган ян ишекләр ачылып торалар. Пәрдә күтәрелгәндә, З ө л ә й х а сөлге чигеп тора.

З ө л ә й х а ялгызы.

З ө л ә й х а. Бүген дә кайтмый торгандыр. Марҗасы белән эчә торгандыр инде. Кайтып кыйнамаса гына ярар иде. И Алла, бөтенләй кайтмаса да разый. Сигез ай Мостафаның хатыны булып торам. Бер рәхәт тә күргәнем юк әле. Галинең әйткән сүзләре барысы да дөрес булып чыкты. Мал эчендә торып, күз яшьләреңне түгәрсең дип әйткән иде... *(Елый.)* Түгәм, Гали, түгәм!.. Мин генә гомеремне елап үткәрсәм ярар иде. Минем бу хәлемне күреп, анам да елый-елый авыруга сабышты. Үлмәсә генә ярар иде. И әткәм! Гомерең эчендә бер хата эш эшләми, бу эшеңдә генә алдандың. Малга кызыгып, үз-үзеңне харап иттең.

(Елый.) Синең алдануың аркасында, минем яшь башым, яшь гомерем әрәм булды... Йа Алла! Ни өчен мине бу кадәр җәбер эчендә дөньяда тотасың?! Бу кадәр җәбер күргәнче, үләргә разыймын. *(Күзләрен сөртеп.)* Күп еладым инде. Җитәр. *(Сөлге чигә. Асрау карчык керә.)*

З ө л ә й х а һәм а с р а у.

А с р а у. Тагы еладың бугай? И бичара!

З ө л ә й х а. Еладым, җиңги. Чыдый алмадым. Елагач җиңелрәк булган кеби күренә.

А с р а у. Менә мин сездә дүртенче көнемне генә торсам да, күрмәгәнемне күрдем инде, бәбкәм, күрдем. Эш күп, әмма ашарга бернәрсә дә юк. Байлыклары корсын!

З ө л ә й х а. Монда торырга теләмисеңме әллә?

А с р а у. Монда торып, нишләп үз-үземне җәберләтим?

З ө л ә й х а. Шулай шул. Син, фәкыйрь булсаң да, миннән күп мәртәбә яхшы гомер итәсең. Монда торырга теләмәсәң, тотасың да чыгып китәсең.

А с р а у. Җаным тыныч булсын. Үзем сәламәт булсам, Алла теләсә, тамагым туяр!

З ө л ә й х а. Моннан китеп нишләрсең? Кая барырсың?

А с р а у. Алла мәдәд[1] бирер әле. Менә сиңа гына карап эчем поша. Барысын да белдем инде. Өченче көн сине никадәр кыйнады... Мин үләрсең дип торган идем. Сине кыйнаганда, шулкадәр курыктым, бәбкәм, шулкадәр курыктым! Гомеремдә һич тә болай курыкканым юк иде.

З ө л ә й х а. Син аз беләсең. Сезгә барысы да ишетелми.

А с р а у. Аз!.. Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!..

З ө л ә й х а. Әгәр барысын да белсәң исең китәр иде.

А с р а у. Зөләйха, син теләгәнеңә барсаң, рәхәтләнеп торыр идең.

З ө л ә й х а. Мин Мостафага теләп бардым бит.

А с р а у. Алдама. Теләп бармадың!

З ө л ә й х а. Юкны сөйләмә, җиңги!

А с р а у. Алдама, бәбкәм, алдама! Син Мостафага теләп бармадың. Сине атаң көчләп бирде. Шулай бит? Яшермә, бәбкәм, сөйгән егетеңне дә беләм.

З ө л ә й х а *(куркып)*. Юкларны сөйләмә, дим, җиңги!

---

[1] *Мәдәд* — ярдәм, булышлык.

А с р а у. Син миннән курыкма. Минем синең белән бик сөйләшәсем килеп торадыр иде. Әмма мөмкин түгел иде. Менә хәзер каенанаң белән каенатаң иминиягә киттеләр. Өй аулак калды. Мин синең янына сөйләшергә мендем. Син миннән бер дә курыкма, бәбкәм!

З ө л ә й х а. Нишләп куркыйм. Нинди сүзең бар соң?

А с р а у. Никах булган көнне капкагыз явына килеп, сине коткарырга йөреп, казаматка керде мескен.

З ө л ә й х а. Кемне сөйлисең?

А с р а у. Кемне... Галине.

З ө л ә й х а. Нинди Галине?

А с р а у. Яшермә, дим. Әйтмәсәң дә беләм бит. Барысын да беләм.

З ө л ә й х а *(ачуланып)*. Җитәр! Әллә ниләр сөйләшә башладың.

А с р а у. Бер дә әллә ниләр түгел! Барысы да булган эш.

З ө л ә й х а. Нәрсә булган эш?

А с р а у. Нәрсә? Менә нәрсә... син Галинең иптәше Йосыфны беләсең бит?

З ө л ә й х а. Йә?

А с р а у. Син Мостафага барган вакытларда, мин Йосыфларда фатирда торадыр идем.

З ө л ә й х а. Соң?

А с р а у. Шуңар күрә Гали белән ике арагыздагы булган эшләрне һәммәсен беләм. Син миннән курыкма. Мин моны һичкемгә дә әйтмәм.

З ө л ә й х а. Җиңги, җаным! Берәүгә дә сөйләмә. Ярыймы?!

А с р а у. Нишләп сөйлим! Әгәр бер-бер кешегә сөйләгәнемне ишетсә үтерер. Җанымны алыр!

З ө л ә й х а. Кем?

А с р а у. Кем булсын! Йосыф. Ул минем монда кергәнемне белеп килде дә: кара, әгәр бер-бер сүз ычкындырсаң, валлаһи, кыйнап үтерермен, диде. Вәли дә бармагын селкеп янады, булган эш беткән, яңадан кузгатма, дип әйтте. Мин шашмаган бит. Нишләп сөйлим соң. Ансыз да әле көн саен кыйный дип әйтергә ярый. Әгәр дә сөйләсәң суяр. Бер дә кызганмас. Бик усал бит. Мондый усал кешене гомеремдә күргәнем юк иде.

З ө л ә й х а. Вәли дә исәнмени?

А с р а у. Исән. Аллага шөкер. Абыстай гына үлде. Кайгысына чыдый алмады.

Зөләйха. Кайсы абыстайны сөйлисең?

Асрау. Гали анасын. Белә торгансың бит?

Зөләйха. Үлдемени?

Асрау. Үлде.

Зөләйха. Мескен... Бик яхшы карчык иде.

Асрау. Аның кеби кешеләр дөньяда бик аз шул.

Зөләйха. Син, кайгырып үлде, дидең. Нинди кайгыдан үлде соң?

Асрау. Менә ул ничек булды: синең никахың көнне Йосыф өйгә кайтты да ашады, эчте. Соңыннан уйлап торды да: «Нишлим? Әллә урлыйммы»,— диде. Мин: «Нәрсә урлыйсың?» — дидем. «Зөләйханы урларга йөрим»,— диде. «Аны ни өчен урлыйсың?» — дидем. «Гали белән икесен кавыштырам»,— диде. «Кара, эләкмә»,— дидем. «Эләксәм эләгермен»,— диде дә чыгып китте. Чыгып китеп, сезнең өегез янына, сине урларга дип барган.

Зөләйха. Йә?

Асрау. Аннан соң... Тукта, бер-бер җире онтылып калмый микән? *(Уйланып.)* Юк, калмый. Йосыф сезнең өегез тирәсендә шулай урлыйм дип хәзерләнеп торганда, Вәли, Галине тотарга йөриләр дип ишетеп, Галине шәһәр тирәсендә эзләргә керешә. Эзләп йөргән вакытта Вәли дә сезнең капкагыз янына килеп төшә. Килеп төшә дә, Йосыфны күрә, аңа бөтен эшне сөйли. Аннан соң Галине эзләргә Йосыф китә. Вәли Галинең өенә китә. Нәкъ сиңа никах укыган вакытта гына өегез янына Гали килеп төшә. Вәли аны шунда килеп таба һәм өенә алып кайтыйм дигәндә генә, бер кеше килеп чыга да Галине казаматка тотып алып китә.

Зөләйха. Галинеме? И бичара! Ул хәзер дә казаматта ятамыни?

Асрау. Юк. Хәзер ятмый. Чыкканына бер айлап бар инде.

Зөләйха. Йә... тагын ни бар, сөйлә.

Асрау. Бервакытны, өйдә шулай утырганда, Вәли килеп керде. Бер дә төсе калмаган. Йосыф өйдәме, диде. Юк. Кайтканы юк, дидек. «Кайткач ук, Гали эләкте, дип әйтегез. Үзе дә сак булып торсын. Ярыймы?» — диде дә чыгып китте. Кайткач Йосыфка сөйләдек. Ул бик кайгырды. Бераз елады да. Икенче көнне торып... *(Шулвакыт бер кеше: «Җиңги!» — дип кычкыра. Зөләйха урыныннан сикереп тора.)* Фу беткере! Куркытты. Киявең бүген дә кайтмады. Малайны ашатыйм.

Ашыйсы килә торгандыр. Мин хәзер менеп сөйләп бетерермен. Ярыймы?

Зөләйха. Бар. Ашат. Соңыннан менәрсең. Кайда калганын да сорап бел.

Асрау. Ярар. Сорармын. *(Чыга. Зөләйха урынына утыра.)*

Зөләйха ялгызы.

Зөләйха. Бөтен йөрәгем жу итте. Шыпырт кына кайтып тыңлап тормаса ярар иде дип, котым да калмады. Алла сакласын! Әгәр Гали белән булган эшләремне белә калса харап итәр. Кыйнап җанымны алыр. Һич кызганмас. *(Чигүен чигә.)* И эткәм! Кызыңны, Мостафага биреп, харап иттең бит. Минем аркада Гали никадәр кайгы-хәсрәт күргән. Төрмәгә кергән. Карчык анасы үлгән. И бичара Гали!.. Чиккән хәсрәтләрем күп иде. Бүген тагын да артты. *(Сискәнеп, як-ягына карана.)* Звонок шалтыраган кеби булды бугай! И Алла! Җенләнмәсәм генә ярар иде. Чөнки бу арада шылт иткән тавыш та колагыма звонок төсле ишетелә башлады. Ни өчен болай булдым икән? Бер дә белә алмыйм. Әллә куркуымнан микән?.. Шулайдыр. Йокламаганнан да булыр шул. Утырып көтәсең-көтәсең, кайтмый. Ятып йоклар идең, ярамый. Җәберли. Бу арада бигрәк тә усалланды. Марҗасы котырта торгандыр, ахры. *(Янә сискәнеп карана. Бераздан асрау керә.)*

Зөләйха һәм асрау.

Зөләйха. Кайда калган? Сорадыңмы?

Асрау. Соравын сорадым да, әйтми.

Зөләйха. Ни өчен әйтми?

Асрау. Әйтергә кушмады, ди.

Зөләйха. Малай да исерекме әллә?

Асрау. Исерек шул.

Зөләйха. Бар чакыр, менсен әле. Зөләйха дәшә, диген.

Асрау. Дәшим әле. Ул сиңа әйтер. *(Чыга.)*

Зөләйха ялгызы.

Зөләйха. Трактирларда эчеп исергәндер дә марҗасына киткәндер. Бу вакыт җиткәч, кая барсын икән? *(Тора.)* Бу эчүен кайчан ташлар икән? Үзен кыйныйлар да. Ристанскига кереп никадәр утырды. Бу җәбергә эт тә чыдамас. Беркөнне шулкадәр каты кыйнаганнар: бөтен башы, бите, күкрәге һәм аркасы күгәреп беткән иде. Мин үләр дип торган идем. Үлмәде бит. Терелде. *(Асрау һәм малай керәләр.)*

Зөләйха һәм асрау белән малай.

Зөләйха. Абзыеңны кайда ташлап калдырдың?

Малай *(башын кашып).* Әйтергә кушмаган иде.

Зөләйха. Шулай итеп, миңа да әйтмисеңмени?

Малай. Сиңа кушмаса да әйтәм.

Зөләйха. Йә, әйт. Кайда ташлап калдырдың?

Малай. Марҗасында калды.

Зөләйха. Шуннан башка бара торган җире дә юк шул.

Малай. Ул кунаклар! Ул кунаклар!

Зөләйха. Кайда кунаклар?

Малай. Кайда? Марҗада. Ул сый... Ул сыйларны күрсәң, исең дә китәр иде. Ул егетләр, барысы да яшьләр! Татар егетләре дә бик күп.

Зөләйха. Татар кызлары да бармы әллә?

Малай. Юк. Татар кызлары юк. Барысы да марҗа! Уенчылары да бар. Уйнап торып җибәрәләр!.. Исең дә китәр! Валлаһи, ялганламыйм! Марҗасы юмарт икән. Мине дә сыйлады.

Асрау. Юмарт булмый ни!.. Мостафа акчасы бит.

Малай. Мине сыйладылар да: ну типир, князь, пләши! диделәр. Тоттым да бии башладым. Палтиннек акча биреп җибәрделәр.

Зөләйха. Мостафа исерекме?

Малай. Алай ук исерек түгел. Мин биегән вакытта килде дә: йә, җитәр, бар кайт, дип куып чыгарды.

Зөләйха. Бар, ашыңны аша да ятып йокла.

Малай. Мин сөйләде дип әйтмә, апа, ярыймы?

Зөләйха. Әйтмәм, әйтмәм! Бар, ят. *(Малай чыга.)*

Зөләйха һәм асрау.

Асрау. Син, җаным, бер дә пошынма. Әчсен. Кылансын. Башы бетсен! Бер дә кайгырма.

Зөләйха. Җитәр. Бик күп кайгырдым инде! И җиңги! Ул миңа шулкадәр җәфа күрсәтте, шулкадәр күрсәтте. Алла иң усал бәндәсен дә мондый җәфалардан ерак кыйлсын!

Асрау. Беләм, җаным, беләм. Аз торсам да, күп күрдем инде.

Зөләйха. Мондый кеше дөнья йөзендә тагы бар микән? Булмас. Беркөнне исереп кайтты да, чишен, ди, бөтенләй чишен, ялан өс кал, ди.

Асрау. И Алла! Бу ни кыланыш тагын!

З ө л ә й х а. Башта үзем дә белмәдем. Әллә шашканмы дип тордым. Бәйләнә бит. Бөтенләй чишен, ди. Җаным, ни өчен, дим. Мин әллә кыйныймы дип торам.

А с р а у. Бу ни гаҗәп!.. Ни өчен соң?

З ө л ә й х а. Ялан килеш партритка төшерәм, ди.

А с р а у. Йа Алла! Әстәгъфирулла! Бу ни дигән сүз?!

З ө л ә й х а. Шулай ди!

А с р а у. Әллә төшердеме?

З ө л ә й х а. Юк. Бирелмәдем. Бераз кыйнады да шуның белән бетте.

А с р а у. Менә рәхмәт, бәбкәм. Мондый эшләргә бер дә бирелмә. Үлсәң дә бирелмә. Мондый эштә үлсәң, шәһит булып үтәрсең. Алла үзеңне оҗмахка кертер.

З ө л ә й х а. Үлсәм бик ярар иде дә, үлмим бит.

А с р а у. Алай дип әйтмә, бәбкәм! Алай әйтергә ярамый. *(Сөйләшми бераз торалар. Шул вакытта сцена артында сәгать берне суга.)* И Алла! Сәгать берне сукты бугай.

З ө л ә й х а. Сукса ни. Миңа бар да бер йокламаска.

А с р а у. Ят. Йокла. Ул бүген кайтмас.

З ө л ә й х а. Кайтса? Кыйнар бит.

А с р а у. Кыйнар, бәгырем, кыйнар. Нишлибез соң?

З ө л ә й х а. Син китеп ят. Мин утырам әле.

А с р а у. Мин бүген көндез дә бераз йоклап алдым. Түзәрмен. Син бар да кәнәфигә ят. Мин саклап торырмын. Әгәр кайтса, сине тиз генә уятырмын.

З ө л ә й х а. Куркам.

А с р а у. Курыкма. Кайтса да сизмәс. Исереп кайтыр бит.

З ө л ә й х а. Сизсә?

А с р а у. Сизмәс, дим! Бар, җаным, ят!

З ө л ә й х а. Ярый алайса. Ятам. Кара, звонокка килеп кагылды исә, уята күр, җиңги.

А с р а у. Беләм инде, беләм! Бар, ят, дим. *(Зөләйханы кәнәфигә яткыра. Зөләйха яткач ук йокыга китә. Асрау Зөләйха янына креслога утыра. Сцена бераз тын була.)* Йоклады мескен. Китәрмен дип торадыр идем... Китеп булмас, ахрысы. Бу бичараны ничек ташлап китим? Кызганыч бит. Ичмаса, минем белән сөйләшеп, эчен бушата. Мин булмасам, аның белән сөйләшүче кеше дә юк ич. *(Төзәтенеп, моңлана. Сцена тыныч була. Соңыннан кинәт звонок шалтырый башлый. Зөләйха сикереп тора. Як-ягына карана.)*

Зөләйха. Җиңги, җаным, бар, кач! Синең монда икәнеңне күрмәсен. *(Ишек ачарга чаба. Асрау чыгып китә. Сцена артында Мостафа белән Зөләйха сөйләшәләр.)*

Зөләйха һәм Мостафа.

Мостафа. Ник озак ачмый тордың?!

Зөләйха. Кәнәфидә утырадыр идем.

Мостафа. Кәнәфидә!.. Ярамаган тагын ишек катында торырга! *(Керә. Артыннан Зөләйха керә. Мостафа пальтосын сала.)* Ни авызыңны ачып торасың! Ал! *(Зөләйха пальтоны алып чыга. Янә керә. Мостафа галошларын салып.)* Боларны да алып куй! *(Зөләйха алып чыга. Янә кереп, Мостафага карап тора. Мостафа бүреген салып утыра.)* Ни карап торасың! Әллә танымадыңмы?

Зөләйха. Нишлим соң?

Мостафа. Ни эшлим!.. Самавырың кайнаганмы?

Зөләйха. Куймаган.

Мостафа. Бар, куйдыр!

Зөләйха. Зурысынмы, кечерәгенме?

Мостафа. Зурысын куйдыр! *(Зөләйха чыга. Мостафа торып, тәмәке кабызып, мышнап тарта.)*

Мостафа ялгызы.

Мостафа. Сүзне ничек итеп башлыйм икән? Гарьләнер бит, бармас... Бармаса бармас. Күбрәк эчеп кайтырмын да бераз сабак биреп өйрәтермен. Соңыннан ни булыр, карарбыз. Алып бармасам ярамый бит. Иптәшләрнең хатыннары бара, минем хатыным бармый, имеш. Оят бит. Марҗам да көләр... Югалды. *(Аягы белән идәнгә кага.)* Өйрәтермен мин сине! *(Янә кага.)* Өйрәтермен... Барырсың! Бармый хәлең булмас! *(Зөләйха керә.)*

Мостафа һәм Зөләйха.

Мостафа. Йә! Куйдырдыңмы?

Зөләйха. Куйдырдым.

Мостафа. Хәзерлә! *(Йөри. Зөләйха өстәлгә чәй хәзерли.)* И син! Китеп, яхшы гына киен әле. *(Зөләйха аңламыйча карап тора.)* Сиңа әйтәм бит!

Зөләйха. Ни өчен киеним?

Мостафа. Кирәк булганга күрә. Кунакка барырбыз.

З ө л ә й х а. Нинди кунак? Бу вакытта бөтен шәһәр йоклый инде.

М о с т а ф а. Әллә йокламакчы буласыңмы?

З ө л ә й х а. Минем йоклаганым юк ич әле.

М о с т а ф а. Мин дә йокламаган бит!

З ө л ә й х а. Хәзер чәй була.

М о с т а ф а. Чәй эчмәбез.

З ө л ә й х а. Үзең, эчәм дип, самавыр куйдырдың ич.

М о с т а ф а. Куйдырдым шул. Әмма эчмим. Әллә көчләп эчермәкче буласыңмы?

З ө л ә й х а. Нишләп көчләп эчерим?

М о с т а ф а. Эчермәгәч, лыгырдап торма! *(Өстәл янына килә. Зөләйха өстәл өстенә салфеткалар китереп куя.)* Чәй эчмибез, дим. Ташла! Бар, киен!

З ө л ә й х а. Ни киим соң?

М о с т а ф а. Иң яхшы киемнәреңне ки... *(Йомшарып.)* Әгәр бүген мин дәшкән урынга барсаң, үзеңне бервакытта да җәберләмәм.

З ө л ә й х а. Җаным, ятыйк. Вакыт бит.

М о с т а ф а. Әллә бармаска уйладыңмы?!

З ө л ә й х а. Кая алып барасың соң?

М о с т а ф а. Барсаң әйтәм.

З ө л ә й х а. Кая барасын белмичә, ничек барам дип әйтим. *(Мостафа янә йөри. Зөләйха куркып Мостафага карый.)*

М о с т а ф а. Мин сиңа ир бит. Андый-мондый урыннарга алып бармам. Курыкма. *(Янә йөри.)* Марусяга барасыңмы? *(Зөләйха дәшми. Мостафа өстәл янына килеп туктый.)* Әллә ишетмәдеңме?

З ө л ә й х а *(акрын тавыш белән)*. Мин анда бармыйм.

М о с т а ф а *(салфетка белән Зөләйханың битенә бәреп)*. И бәдбәхет!..

З ө л ә й х а *(елап)*. Кыйна... үтер... җанымны... ал... Әмма әйткән җиреңә бармыйм.

М о с т а ф а. Бармыйсыңмы?

З ө л ә й х а. Бармыйм.

М о с т а ф а *(якынлашып)*. Бармыйсыңмы? *(Зөләйха елый.)* Бармыйсыңмы, дим?!

З ө л ә й х а *(чигенеп.)* Әйттем ич инде.

М о с т а ф а *(йодрыкларын кысып)*. Өйрәтермен мин сине!.. Җаныңны алырмын!.. Янә әйтәм: бармыйсыңмы?

З ө л ә й х а *(елап)*. Бармыйм.

М о с т а ф а. Китер пальтомны! *(Зөләйха, чыгып, пальто кертә. Мостафа пальтосын киеп.)* Китер галошларны! *(Зөләйха галошларны кертә. Мостафа киенеп бетә. Соңыннан бармагын селкеп янап.)* Кара. Мин бүген кайтырмын. Йоклама! *(Чыгып китә. Зөләйха да чыгып, озатып, елап керә. Бүлмә уртасына туктый.)*

З ө л ә й х а ялгызы.

З ө л ә й х а. Уф Алла! Бу ир белән гомеремне ничек үткәрермен?! *(Кәнәфигә барып утыра. Яулык белән күзләрен сөртә. Өстәлгә кулларын куеп, башын түбән ия. Сцена тын булып кала.)*

Пәрдә төшә.

1908



Галимҗан Ибраһимов

(1887—1938)

КАЗАКЪ КЫЗЫ[1]

Роман

Киң дала, күрәсең гуй, ана җаткан,
Җебәктәй җәсел чүптә битен җапкан.
Аскар тау, балдай татлы сулары бар,
Ана шул анам иде мине тапкан...

I

Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругсы бар иде. Берсен кара-айгыр дип, икенчесен сарман дип атыйлар иде. Болар, меңләгән җылкылары, яхшы нәсел төяләре, исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында, ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәт-рәхәт күчеп йөриләр иде. Бәхетләре ким түгел иде. Мәгәр «канымыз Чингиздән килә» дип мактанучы кайбер кабиләләр соңгы заманнарда, җир-суга тарлык кылып, үзләренең җәберләрен арттыра башладылар. Тик менә шул аларның күңелләрен борчый иде. Болай барса, ике арада яман гауга чыгу куркынычын алга китерә иде.

Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда, бата кыйлырга[2] дип, илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз

---

[1] Кыскартып алынды.

[2] *Бата кыйлу* — искә алу, еллыгын укыту.

мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң, заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып, әңгәмә ачылды. Сүз сүзне тартты, картларның берсе камчысын уйната биреп әйтә салды:

— Ике йортның өлкәннәре кода булды дип ишеттек, мәгәр күз белән күрмәдек. Әгәр бу дөрес булса, җир берлегән кан белән беркетсәк, кайсы яман бу ике илгә җау чыгарыр? — диде.

Бу сүз, күңелдәге теләкне хәбәр рәвешендә сөйләп, димчелек кылу иде. Чалның[1] тапкырлы кинаясе мәҗлеснең хушына китте. Ил агасы өлкән аксакал Биремҗан әкә моны куәтләп алды:

— Найманнар белән дүрткаралар һәр ике йортның мазасын китәрәләр[2], кызларын урлыйлар, җәйләүләрен басып алалар, аяклы малларын куып китәләр; сарманнар белән кара-айгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр, кодалык котлы булсын! — диде.

Башка сүзгә урын калмаган иде инде.

Хәбәр бөтен җәйләүгә таралды, куанычлар, казакъ әйтмешли, куенга сыймады. Шул көн сүз куештылар. Бер атна үтүгә, югары-түбән ат җибәреп, илне җыйдылар. Кымызның мул чагы, туктыларның[3] симез заманы, йөгерекләрнең дә, дер кайнап, йөрәк суккан вакытлары иде. Яше, карты, бүз баласы, сылу кызлары җыелып, үләң[4], җыр әйтеп, думбра чиертеп, ат уйнатып, утыз көн уен, кырык көн туен кылып, ике ыруг кодалыкка кул бирештеләр.

Калым өчен күп сатулашу булып үтте. Озак талаштан соң, йөз баш кара[5], дүрт йөз алтын, ике сандык асыл зат өстендә килештеләр.

Шул көннән Сарсымбайның яшь ярымлык кызы Карлыгач кара-айгырларның ай ярымлык ир баласы Калтайга әйттерелгән булды. Берсе кияү, берсе калымлык саналып китте.

Айлар, еллар үтә. Яңадан-яңа җәйләүләргә күчәләр. Ике коданың катнашы күп, сыйлары уртак, уен-көлкеләре бергә бара. Тик әйттерелгән балалар гына үзләренең каената-каена-

---

[1] *Чал* — карт.

[2] *Мазасын китәрү* — рәтен җибәрү.

[3] *Тукты* — тууына алты айдан артыграк вакыт узган куй бәрәне.

[4] *Үләң* — шигырь.

[5] *Кара* — терлек.

наларына күренмәскә, очраса — качарга, яшеренергә тиеш булалар.

Шул далада, шул шатлыклы күченүләр, шау-шулы маллар эчендә кайнап, ашлык сугып, сахрада ат уйнатып, туйларда бүз балалар, сылу кызлар, төрле җегет, төрле матурлар арасында үләң, җыр әйтешкәндә катнашып, Калтай белән Карлыгач үсеп буйга җиттеләр. Мәгәр бер-беренә күңел якынлыгы юк иде әле. Кыз үзенең җегетен, очраганда, һичнәрсә аңламастан, хәйран булып карый иде. Яшүсмер Калтай, бу сүзгә үткен, гәүдәгә үзеннән зур, чибәр кыз алдында ни әйтергә белмичә, бераз югалып, каушап кала иде.

Карлыгач сахраның матуры булып пешеп өлгерде. Тавышы өчен аны былбыл диләр. Җырлаганда казакъның акыннары аның зифа буен төз камышка охшаталар — билең нечкә, күзләрең тирән, керфекләрең уктай, үзең айдай дип мактыйлар иде. Ил эчендә дә коры исеме белән генә әйтмичә, Карлыгач-Сылу дип атыйлар иде.

Кыз гомеренең унсигезенче язына аяк басканда, һәр ике йорт, зур туй кылып, аны каенаталар йортына озату чараларын күрү уена төштеләр. Тиешле калым түләнеп беткән иде. Казакъның гадәте буенча, хәзер инде җегет, ата-аналарыннан, өлкәннәрдән яшеренрәк, киленчәкләр аркылы, кызның куенында булырга хак алган; һәм караңгы төннәрдә, җәйләүләр тынгач, аның күңеле сабырсызланып Карлыгач-Сылуның тирмәсенә тарта торган булды.

II

Җәйнең аяз, матур айлы кичләреннән берсе иде.

Җегет асыл киемнәрен киде, сөекле тулпары Байчобарны иярләде, камчыны билгә такты да, ил-күз тынгач, ат җилдереп, Алтын-Күлгә, Сарсымбай җәйләвенә килде.

Зур күлнең кыйбла як башында уникe ак тирмә якты ай астында, яшел сахрада тезелеп утыралар. Боларның уртадагы өчесе — байныкы. Кызның торганы шул өчнең сул ягындагы ак өй икәнен ул белә иде. Мәгәр туры анда барырга, гадәт буенча, иртәрәк әле. Ике арада илчелекне үтәүче килен авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәдә иде. Атны бәйләп, шунда керде. Өйдә башка адәм юк, тар билле, күкрәге тәңкәле бишмәт кигән, башына ак урамал сарган киленчәк Айбала җегетне елмаеп каршы алды. Җегет, аманлык сорагач, туры үзенең серен ачты:

— Карагым[1], җиңгәм, күңелемне беләсең, Сылуыма хәбәр ит: мин сагынып килдем,— диде.

Әзерләп килгән бүләген бирде. Болар һәммәсе һәркемгә билгеле гадәтләр иде. Айбала аз гына да тартынмады, кыенсынмады, сөйкемле күзләре белән көлеп:

— Ир-җегет үзенең ярын сагынмасмы?! — дип җавап кайтарып, тиз-тиз чыгып китте.

Тышта бәйләүле ат, бу хатынны күреп, бераз куркынып, бер якка тартылды. Кутандагы[2] куйлар, өркеп, урыннарыннан кузгалдылар.

Киленчәк, вак, ашыгыч атлап, туры Карлыгач-Сылу тора торган ак өйгә юнәлде. Уң яктагы кечкенә тирмәдә якты юк. Уртадагы олкән өйдә ирләр, ашарга көтеп, әңгәмә сугып утыралар булса кирәк. Аннан көлгән тавышлар килә. Шуның алдында гына тукалның[3] ак урамал сарган башы, казан астындагы утның ялкыны күренә. Кызның өендә ут бар, мәгәр тавыш-тын юк.

Киленчәк ашыгып керә куйды.

Түгәрәк тирмәнең эче кечкенә лампа белән яктыртылган иде. Карлыгач-Сылу өйнең түрендә, ике як кабыргасына кат-кат тезелгән күп сандыклар, палас, юрганнарның арасыннан нидер эзли иде. Аның башында каракүлле озынча нечкә бүрек, өстендә нечкә билле, күкрәге, якасы укалы бишмәт иде. Аяк тавышына борылды, кара-туткыл йөзендә, матур кара күзләрендә җиңелчә елмаю уйнады.

Айбала аның янына ук барды, бераз серле тавыш белән:

— Иркәм җан, сиңа хәбәр белән килдем,— диде.

Кыз артык сүзсез үк аңлады, елмаюы югалды, керфекләре йөзенә таба сузылды.

— Карагым, җиңгәм! Дустым булсаң, миңа андый сүзләр белән килмәс идең! — диде.

Киленчәк хәйран күзләре белән Сылуга карады:

— Колынчагым, бу ни сүз булды бу?

Кыз күтәрелеп карамады, акрын эчке аваз белән җавап кайтарды:

— Әйткәнем шул: минем аңа кабулым юк! Күңелем башкададыр! Мине җәфаламасаң иде!

---

[1] *Карагым* — сөеклем.

[2] *Кутан* — тирмәләрдән торган авыл уртасындагы уртак мәйдан.

[3] *Тукал* — яшь хатын; ирнең икенче яисә өченче-дүртенче хатыны.

Айбала һушыннан китә язды, телен югалтты, сердәшенең беләгенә тотынды:

— Акылың бармы?! Ике йорт уналты ел кода булып яшәде. Калымлык алынды. Уенчак яшь күңел кая сикермәс. Илнең арасына зур гауга ташлыйм дип торганыңмы бу синең, сәүләм[1]?! — диде.

Карлыгач-Сылуның күзләренә хафа чыкты. Ләкин әйткәне һаман шул мәгънәдә иде:

— Боларны күп ишеткәнмен, ни кылыйм? Үзең беләсең гуй: үткәндә берничә мәртәбә килде. Йортның җоласы, тәкъдирнең язганы шул икән дип, куеныма алдым... Мәгәр ни күрдем: буе тәбәнәк, йөзе яман шадра, борыны томшык, күзе кыйшык, тәненнән яман ис килеп тора! Ул бәндә белән, карагым җиңгәм, ничек гомер итәрмен?! Кайбер адәм бар: йөзе булмаса, сүзе, акылы белән күңелеңне ала, гайрәте, ирлеге белән йөрәгеңне тарта! Ул Калтай дигәннең яман куллары белән күкрәгемә маймыл кебек сузылудан башка эше дә юк, сүзе дә юк! Инде миңа ни кыл дисең?!

Киленчәк тагы — уналты ел кодалык дип, калым дип, ир-җегет үз ярын сагынып килмәсме дип сөйли башлаган иде, кыз аны:

— Җегетлеге корсын, сагынуы корсын,— дип бүлде.

Ул арада тыштан аяк тавышы ишетелде, буяулы нечкә ишек ике якка ачылды. Зур буйлы, солтанат кыяфәтле, агара башлаган чәчле байбичә килеп керде. Карлыгач өстен чишенә башлады, киленчәк уңайсызланып чыгып китте.

Ул, аптырап, кая барырга белмичә катып калды. Тулган айны күрмәде, ялтыраган күл аңа сихерле диңгез кебек тоелды, үткен күзенә авыл читендәге тирмә янына бәйләнгән иярле ат чалынды.

Кунак җегетнең Байчобары аның куркуын тагын көчәйтте; буш кул белән, кабулым юк дигән җавап белән, ул иярле ат бәйләнгән йортка кайтырга аның йөрәге җитмәде.

Ләкин ни эшләргә, кемгә киңәш итәргә?! Киленчәк шулай аптырап торганда, уртадагы өлкән тирмәнең ишеге ачылды, бер адәм чыкты. Якты ай аның йөзен ачык күрсәтте. Үтә куе, елтыр җитү кара чәчле бу казакъ җегете — хатынның ире иде. Айбала, сабыр атлап, шунда юнәлде:

---

[1] *Сәүләм* — яратып мөрәҗәгать итү: нурлы йөзем, күз нурым мәгънәсендәрәк.

— Картым, туктасаңчы! — дип дәште.

Ир җилкәсенә көпесен салган килеш көтте. Барып җитүгә, шаяра биреп, биленнән алды, көлеп әйтте:

— Ясаган иям үземә катынның тәүверен[1] бирде гуй: син минем артымнан килдеңме? Ит ашыйм да кайтам! — диде.

Киленчәк аны янынан этәрде, әрнүле тавыш белән:

— Куя бир мине, уйнар вакыт түгел, бер эштән башым әйләнде,— диде дә фаҗигане сөйләп бирде.— Карлыгач-Сылу үзенең киявен кабул кылмый торыр, җегетнең миңа бер күлмәклек белән бер тукты вәгъдәсе бар иде, инде ни кылыйм, миңа бер акыл әйт!

Ир, кулын селтәп:

— Үзе дә, вәгъдәсе дә корсын: дуңгыз кебек аска карап йөргән ул Калтаегызны яратмыйм мин! Карлыгач-Сылуны күп кызганам,— диде дә китә башлады.

Айбала бөтенләй куркынган төс белән аның кулларыннан тотты:

— Анаңа нәләт булгыры, синең сөйләгәнең нәрсә? Ике йорт уналты ел кода булганы юкмы? Сарсымбай, калымны алып, ике айдан кызын озатырга әзерләнеп ятмыймы?

Казан янында азапланучы тукал, табак тутырып, итне өлкән өйгә алып керде. Җегет, моны күргәч, вакыт әрәм итәсе килмәде:

— Куя бир мине, әнә ит керде,— диде дә, үзенең йомышын онытып, өлкән өйгә китте.

Учакта ут сүнде. Өлкән өйдә табак күренү белән булса кирәк, тавышлар, көлкеләр берьюлы басылды.

Айбала үзенең уйларга өйрәнмәгән башы белән бу эшнең очына чыга алмады, иярле Байчобар бәйләвендә тибенеп торган читке ак тирмәгә кайтып китте.

Кунак җегет тирмәнең түрендә, киез өстендәге мендәргә кырын яткан, шунда өйнең уртасына ягылган утны камчы белән уйнатып, сабырсызланып, бераз сызгырынгалап көтә иде.

Киленчәк сабырын туплады, көчләнеп елмайды: иркә, ягымлы тавыш белән, ләкин, ялганлап, фаҗигане аңлатты:

— Җиңгәңне,— диде,— ничек шелтә кылсаң да ярый торган булды; мәгәр, колынчагым, гаеп миндә генә имәс;

---

[1] *Тәүвер* — чибәр.

Карлыгач-Сылу бу кич кабул кыла алмый: карагым үпкәләмәсен, бик каты наукасланып[1] калдым, ди...

Җегет кинәт урыныннан торды. Күз алды томаланып китте. Йөзенә усал, астыртын ерткыч төсе чыкты. Ни дияргә белмичә, ачуына, хурлыгына җиңелеп катты.

Ул гайбәтче кимперләрдән[2] кайбер нәрсә ишеткән иде. Яман телләр аның калымлыгы Карлыгач-Сылу белән танабугаларның Арысланбай дигән бер егете арасында тамырлык[3] барын сөйлиләр иде. Мәгәр бу адәмне ике ел элек, ак патшага каршы тел әйтте дип, җир аудардылар[4]. Ул сөрелгәч, Калтайның күңеле тынычланган иде. Шул тамырның ике көн элек кайтуын ишетмәгән иде. Киленчәкнең сүзе җегетнең күз алдына тагын шул Арысланбайның куркыныч сурәтен китереп бастырды. Кызның наукасланып калдым дигән сүзенә, әлбәттә, ышанмады. Ләкин чит йортта моңа каршы берни кылырга да амал юк иде. Кәмәрен тартып бәйләде, очлы бүреген киде, камчысын кулына алды да чыга башлады. Айбалага егерме тиенлек көмеш бирде.

Күктә болытлар йөриләр, ай, бер капланып, бер күренеп, уенчак, сылу кыздай елмаеп үтеп бара иде. Байчобар хуҗасын акрын гына кешнәп каршы алды, тезгенендә тартылып, җегеткә таба борылды. Ләкин Калтай ачулы иде, гадәтенчә тулпарын иркәләмәде, каты кул белән баганадан чиште, тезгенен муенга кайтарды, аелны тартты да аягын өзәңгегә салды. Киленчәк үзенең кунагын озата чыккан иде. Ләкин, ни әйтергә белмичә, аптырабрак тора иде. Җегет атка сикереп менде дә хатынга әллә кайдан, астан чыккан карлыккан тавыш белән:

— Аман булыгыз! Сүземне әйтегез: яхшы атадан туган ул яман Сылу белән безнең кара-айгыр йорты ничек исәпләшергә белер! — диде. Ат, баскан җирендә түзә алмыйча, аякларын тупырдата башлады.

Айбала үзенең даими ягымлы иркә сүзләрен әйтте:

— Асылкан җегетем, бу ни сүзегез! Сылуның наукаслыгы бетми тормас гуй!

Байчобар түзмәде, тартыла биреп, Алтын-Күл буеннан киң далага җегетне алып очты.

---

[1] *Наукаслану* — авыру.

[2] *Кимпер* — карчык.

[3] *Тамырлык* — дуслык.

[4] *Җир аудару* — илдән сөрү.

Ай болыт эчендә иде. Караңгылыкта кунакның шәүләсе тиз югалды. Мәгәр тулпарның каты тоякларының тавышы, дөп-дөп итеп, беразгача ишетелеп барды, соңра ул да тынды.

Айбала чыннан куркынды. Бу караңгы серне эченә сыйдырып калырга көче җитмәде, күңеле байбичәгә тартыла иде. Мәгәр аңа ни дип әйтергә? Әле бит җегетнең яшеренеп йөргән заманы гына. Гадәт буенча, бу йөрү кызның ата-аналарына белдерелмәскә тиешле. Сизелсә дә, болар белмәмешкә, күрмәмешкә салыналар. Хәл шулай булганда, бу хәбәрне Алтынчәч бикәгә әйтсәң, ул шелтәләп чыгарыр.

— Казакъ йортында буй үстердең, ике бала анасы булдың, миңа мондый сүзләр белән килергә ничек йөзең оялмый? — дияр.

Мәгәр башка чара юк иде. Җегетнең киткәндә әйткәне — ике ыруг арасында канлы талаш булачагы белән куркыту иде. Хатын чыдамады: «Сөйләми амалым юк; ничек шелтәләсә дә түзәрмен, бәлки ачуланмас, туй алдыннан мондый гаугалы хәлнең чыгарга торуын аңлатканга, бәлки, рәхмәт әйтер»,— дип уйланды. Ире кайтканны көтмичә үк, байбичәгә серен ачарга дип, куйлар, кутаннар арасыннан Сарсымбайның ак тирмәсенә китте.

III

Ил агасы Байтүрә морза үлем түшәгенә ятты. Мәгәр кабилә, партия талашлары эчендә кайнаган карт йөрәге, үткен мие сәламәт иде әле. Үзеннән соң найман, дүрткара балаларының язмышы ничек булуы турында күп уйланды. Дошманнарның баш күтәрүе аңа ачык иде. Үзенең бай тирмәсенең түрендә ятып, бу хакта күп баш ватканнан соң, чараларның берсе буларак, Биремҗан аксакалны чакыртып, аңардан бәхиллек алу фикеренә килде:

— Бу ялганда[1],— диде,— яхшылыгым күп булды, мәгәр яманлыгым да аз имәс. Дөньяныкы дөньяда бетсен: Азым әкәне җибәреп, үтенечемне әйтим, килсә, ту бия[2] суйдырып, кымызны мул куеп, асыл елкыдан үзенә берничә кара бүләк биреп, ризалыгын сорыйм. Сүземне алса кирәк: үзе белән бергә үстек, бергә сабакка йөрдек, бергә ат уйнаттык. Ул тамырым-

[1] *Бу ялганда* — бу вакытлы дөньяда.

[2] *Ту бия* — кысыр бия.

ның күңелен тапмый китсәм, җаным тыныч булмас. Найман балаларының миннән соңгы эшләрендә дә күп кыенлык чыгар,— диде.

Карт бу сүзләрне әйткәндә, тукал өйдә иде. Зиннәтле, зур, бай тирмәнең ишеге төбендәге сабадагы кымызны пешкәк белән шапырып тора иде. Хатын иренә аптырап карады: «Апырмай, бу ни булды? Югыйсә баем саташамы»,— дип гаҗәпләнеп калды, ләкин каршы тел әйтергә йөрәге җитмәде.

Башына ак ефәк урамал сарган, кара күзле, ап-ак чәчле байбичә бу вакыт авыруның янында утыра иде. Байтүрәнең сүзләрен башына сыйдыра алмады, сабыр, мәгәр ачулы тавыш белән аны бүлде:

— Син,— диде,— акыл белән, баһадир ирлек белән гомер иттең. Инде ахыр көнеңдә бер тинтәклек кылыйм дип ятканыңмы бу?!

Авыру җавап бирергә өлгермәде, ишек ачылды. Аннан урта буйлы, калын муенлы, симез гәүдәле, агара башлаган сирәк сакаллы Якуп килеп кереп, агасының кәефен сорады. Рөкыя бикә моңа гаҗәпсенгән тавыш, аптыраган йөз белән фаҗигане аңлатты:

— Ханнарның, солтаннарның баласы, аксөяк найманнарның агасы, кырык ел ил тоткан абзаң бүген, мәлҗерәп беткән Биремҗан карт белән килешсәм, аны чакырып адәм җибәрсәм иде, дип ята, шуңа башым әйләнеп калды! Моннан егерме ел элек ул яман чалның Яңгырбайлар туенда миңа әйткән бер сүзе йортның хәтереннән чыкмаган булса кирәк... Ул адәмне мин ничек кабул кылырмын, ничек кунак итәрмен. Син бер нәрсә әйт, бәлки, телеңне алыр,— диде.

Якуп кирәгәгә асылынган иярләр арасыннан нидер эзли иде. Каеш аел белән көмешләнгән саплы камчыны тартып чыгарды да, һичкемгә күтәрелеп карамастан, әйтә куйды:

— Агам,— диде,— миңа моны кичә әйтеп иде. Ни дисәм дә, сүзем үтми калды... Биремҗан дигән ул исәр чал[1]— йортның барына да билгеле адәм гуй!

Ләкин үз гомерендә әйткәнен эшләми калырга өйрәнмәгән карт арыслан, авыру булса да, боларга колак салмады, өстендәге атлас юрганнарны бер яккарак ташлый биреп, ачуыннан башын күтәреп:

---

[1] *Исәр чал* — җиңел акыллы карт.

— Сәүләм Рөкыя! — диде.— Аяллыгыңа[1] барма, күп гомер эчендә яманын да, яхшысын да күрми амал юк! Син егерме ел элек аңардан бер каты сүз ишеткән булсаң, мин аның белән кырык ел талаш кылганмын; мәгәр акылыңны киң йөртергә кирәк: Сарсымбай дигән яман эт баласы безгә каршы гаута чыгарам дип ятыр; ил эчендә күп әңгәмә таралып китте. Уйлаганым — үзем өчен имәс, тәкъдир җитеп, ясаган иям җанымны үзенә кайтара торган булса, найманның, дүрткараның чамасын төзәтим дип яткан эшем гуй! — диде.

Сөйләүдән арып китте, хәлсезләнеп кире ятты, ахыр фәрманын кыенлык белән әйтә алды:

— Мин ике сөйләргә гадәтләнмәгәнмен: Азымбай белән нугай молданы чакырыгыз. Кашка белән Дөлделне иярләгез, бу ике байгыш Коргак-Күл җәйләвенә барып кайтырлар!.. (...)

Тукал байның хәбәрен ирештергән булса кирәк, тыштан ук шаулап, тавышланып Азымбай килеп керде.

IV

...Авыру яткан җирендә кунакка таба әйләнде, хәлсез, зәгыйфь рәвештә ни өчен чакыртуын сөйләде:

— Дөнья дигәннәре шул икән, Азым әкә! Хан бул, түрә бул, бай бул — һәммәңнең барып туктала торган җире бер икән!.. Үзең беләсең, Биремҗан аксакал белән күп талашымыз булды... Куәт миндә иде, илнең тоткасы миндә иде... Картны рәнҗеткән, күңелен сындырган чагым аз имәс. Үзем бүген-иртәгә дөньяны куйсам кирәк дип ятам... Телем, акылым сау көндә ул кордашымның ризалыгын алып, найман балалары белән килештереп китсәм икән, дим... Синең белән бу ялганның яхшылыгын да, яманлыгын да бергә үткәрдек... Актык йомышымны да син үтә: күк Дөлделемне атлан, камчымны биләңә сал да Коргак-Күл җәйләвенә бар. Бирем әкәгә сәламемне тапшыр, арызымны[2] әйт, найман, дүрткара илләренең кунагы булуыңны көтәбез, диген!..

Азымбай чал, кымызны эчеп, савытны бикәгә бирде, бераз аптырап, уйланып, сирәк сакалын сыйпады:

— Кушсаң,— диде,— бармый амалым юк. Мәгәр Биремҗан аксакалны яхшы танучы идем. Ул адәм найман дигәннең

---

[1] *Аял* — хатын-кыз.

[2] *Арыз* — үтенеч.

исемен ишетсә дә яман бер сүзгә килә: «Казакъ йортын ак патшага сатып, Сары-Арканы урыс түрәгә таптаткан ул этләрне минем алдымда телгә алмагыз»,— дип әйтә торган каты бавырлы, аз акыллы бер исәр чал гуй. Карт күңел бер сынгач, яңадан төзәлерме? Аргамакны тирләтеп, ул җәйләүгә бару бушка булмасмы?..

Бу сүзләр авыруның йөрәгенә агу булып төштеләр. Аның йөзенә, күзенә ачу катнаш кайгы чыкты. Калын, салынкы кабаклары дерелдәде, ләкин кызмады, кабаланмады, тирән борчулы, ачулы тавыш белән Азымбайның сүзен бүлде:

— Картлыгым җитеп, акылым китеп калдымы?! Булмаса, казакъ йортының адәме бозылдымы?! Наукасланып ятканымнан бирле телемне алмас булдылар. Бүз балаларны, акылсыз аялларны бер якка куя биреп, үзеңне чакыртсам, синең дә әйткәнең шул! — диде.

Байбичә картка күз белән ишарә ясады, бу бераз каушап калды:

— Сиңа коллыктан баш тартканым юк! Каршы әйтүем түгел иде... — диде.

Байтүрә яңадан аның сүзен кисте:

— Мин,— диде,— молдакә белән икәү барырсыз дигән идем. Инде ул уйдан кайттым. Үзенең чакча баш[1] нугайлыгы белән бер-бер сүзне исәпсез әйтеп, эшне бозар дип куркам. Ул балаларны укыта бирсен. Ялгызың бар,— диде.

Карт хуш әйтеп чыгып китте. Байбичә: «Яхшы юл булсын»,— дип калды.

V

Азым әкә үз гомерендә кабилә, партия талашларының борылмаларын күп кичерде. Ләкин бүгенге йомышы аның өчен тагы зуррак булып күренде: арадагы сүзләр ничек кенә әйтелгән булмасын, әмма аңа тапшырылган эш мәңге гаугалашып килгән ыругларның килешүе өчен бер чама тартып карау иде. Әгәр юл уңса, Байтүрәнең иң яман дошманнарыннан булган Биремҗан аксакал бу йортка килеп кымыз татыса, иттән авыз итсә, ул вакыт ике кабиләнең талаштан туктавында сукмак салынган булачак иде. Йөкләтелгән бурыч шундый зур булганга, карт үзен Якты-Күлдән кызылкортларга җибәрелгән илче итеп уйлады. Өс-башының да шуңа охшашлы бер рәвештә

---

[1] *Чакча баш* — артка калкып чыгып торган баш.

булуын кирәк тапты, авыру янында чыккач та, туры үзенең өенә таба бар кадәренчә киенеп килү өчен кайтып китте.

Бу җәйләүдә барлыгы унбиш тирмә бар. Боларның тугызы авылның ярлы казакъларыныкы, уртадагы алтысы Байтүрәнеке иде. Картның өе бер читтәрәк иде.

Байдан чыгып үз тирмәсенә атлау белән, аның җаны әрнеп китте: ул алтмыш ел дөнья куды. Ходайга: «Мал да бирче, бак[1] та бирче!» — дип моңлык кылды. Шул Байтүрәләргә коллыктан котылуын, ил өстендә баш булуны өмет итте. Ләкин бәхет килмәде. Инде баеп җитәм дигәндә, каты буранлы, яман бозлы бер көздә, аның күп хайванын җот[2] һәлак кылды. Карт тагы зәһәрләнеп, дөньяга, Аллага, байга үч итеп, сүгенеп йөри торган булды. Авыру арысланның фәрманын алып чыкканда, аның каршына ачылган күренешләр бу ачуын, бу әрнүен тагы арттырдылар. Тирмәдән далага күз ташлауга, аның алдына кайнап торган җәйләү килде: әйтерсең штаб тирәсен сырып алган миллионлы гаскәр! Шундый кара болыт булып бөтен тирәякны, даланы, кутанны, җәйләүне Байтүрәнең маллары каплап алып, шулай кайнашып торалар.

Әнә күлдән далага таба төяләр китеп баралар.

Гәүдәләре эре, өркәчләре ияр кебек ике аерылы, башлары кечкенә, муеннары түбәгә асылган; әйтерсең сафлап тезелгән кәрван: шулай акрын, салмак, сабыр гына тирбәлә-тирбәлә атлыйлар.

Нәзек буйлы, биек, нечкә аяклы, гаҗәп матур күзле буталар[3] алар янында уйнаклап йөриләр.Ерактарак иярләп ат менгән ике көтүче бара. Кулларында чыбыркы, яннарында озын колга сөйрәлгән.

Бу төяләр кәрванынннан бирерәк, күл белән тирмәләр арасында, ничә йөзләп колыннар бәйләүдә тора. Ак башлы, кара бишмәтле хатыннар шуннан ерак түгел йөргән бияләрне корыклап китерәләр дә савып йөриләр. Болардан ераграк, төшкә кайткан көтүче исәбе-саны булмаган, сахраны каплаган куйларны акрын гына киң дала буенча куып алып китеп бара.

Дәрья булып, болыт булып кайнашкан бу исәпсез мал картның күңелен кыздырды:

---

[1] *Бак* — бәхет, уңыш.

[2] *Җот* — азык җитешмәгәнлектән терлекләрнең кырылуы.

[3] *Бута* — дөя баласы.

— Ай Кодаем, ау, шуның йөздән берсен миңа бирсәң, синең кай җирең җимерeләчәк иде?! Телемне алмадың, ау, Тәңрем! — дип әрнеп, боларның эченнән ялгыз фәкыйрь тирмәсенә барып җитәм дигәндә, арттан бер хатын тавышы ишетелде:

— Азым әкә! Сары биянең җаен тапмый торабыз. Бире килсәңче!

Кычкыручы байның яшь хатыны — тукал иде. Чара булмады, борылып, бәйләүдәге колыннар янына китте.

Азымбай карт, үзе ярлы булса да, гомер буенча мал арасында үскән, хайваннар белән гаҗиб[1] үзләшкән бер адәм иде. Ул ат-җылкы тануда тирә-якның беренчесе санала. Аның кулы малга шифа дип карала. Бер байның кадерле юртагы авырса, аны чакырталар. Зур базарларда, ярминкәләрдә мал җыйган чакта, татарның Әхмәт, Гани, Яуыш дигән кебек байлары мал сайлау өчен аны күп акча белән алдыралар. Хатыннар арасында: «Азым әкә хайванның телен белә»,— дип йөриләр. Кырыс, усал яшь бияләр саудырмаса, баласын имезмәсә, аңа киләләр. Әле дә байның тукалы көлә биреп каршы алды.

— Ялчы хатын сары бия саудырмый дигәч, үзем барып идем. Азым әкәне тыңлаган җылкы миңа ничек карышсын дип, эчемнән киберләнеп... Мәгәр эшем чыкмады, син безгә булышлык кыла күр,— диде.

Карт җавап бирмәде. Баягы әрнүле уйлардан соң аның күңеле төзәлмәгән иде әле. Хатын янында маташкан зур гәүдәле ялчының кулыннан корыкны алды да, бер-ике атлап, сиздермәстән, сары биянең муенына ташлады. Ат, куркынып, китим дисә, арканга тартылып калды. Азымбай, адәмчә сөйләнеп, корык буйлап барып, биянең муенына кул салды. Бу сабырсыз хайван иде, пошкырып, дулап китәргә теләде. Ләкин карт аңа карамады, акрын, йомшак тавыш белән һаман иркәли биреп, аркадан, кабыргадан сыйпады, җиленгә килеп җитте дә, ике көн буенча савылмаганга, тулып таш кебек каткан имчәкләргә бармакларын тидерде. Сары бия, көйсез хатыннар кебек чыелдап, тибенеп дулый башлады. Тукал бераз мыскыл белән көлде:

— Дөньяда Азым әкәнең телен алмаган маллар да бар икән! — диде.

---

[1] *Гаҗиб* — бик нык, искиткеч.

Карт ашыкмады, бияне тынычлатып, ялыннан, сыртыннан сыйпап, тагы җиленгә кул суздЫ. Җылкы тагын тибенде, тагы дулады.

Хатынның көлүе бөтенләй мәсхәрәгә әйләнде:

— Ай, баба! Бу сары бия синең илле еллык абруеңны югалтагуй! — диде.

Азымбай гаҗиб бер сабырлык белән өченче мәртәбә тотынды һәм җиңде: бия, бер-ике тарткач та, рәхәтләнеп, аякларын ике якка аерды, имчәкләрдән сөт агып китте.

Карт мыскыл күзе белән тукалга карап әйтте:

— Инде хәзер зәгыйфь яратылган аяллар да сава алыр!

Хатын камил җиңелде:

— Азым әкә, үзең яхшысың, мәгәр кайбер вакыт яман телең адәмне чагып куя,— диде.

Баба монда эшен бетерде дә, колыннар, бозаулар арасыннан боларның нәселләрен, шәплекләрен карый-карый өенә кайтып, бик тиз арада киенеп чыкты.

Аягында Казанның әйбәт читек-кәвеше, башында яңа колакчын, якасы бишмәттән кайтарылып төшкән ак күлмәк, эчетышы сырулы эре чуар бизәкле яңа көпе, билдә кәмәр — хәзер Азымбай чыннан да теләгән илгә би булып сайлана алырлык хөрмәтле бер аксакал иде. Байның үзе менә торган күк Дөлдөлен иярләп куйган ялчы аны бераз көлеп каршы алды:

— Асыл киендең, җылкының тулпарына мендең... Юлың ак булсын, Азым әкә,— диде.

Ләкин картның йөрәге тыныч түгел иде, атка менә биреп, әрле тавыш белән әйтә куйды:

— Ясаган Тәңрем мондый җылкыларны Байтүрәләргә биреп бетереп, безне мәхрүм калдырды. Монда хикмәте нидер, күп уйласам да, акылым җитә алмады...— диде.

Бу атның бай үзе авырганнан бирле йөргәне юк иде, сабырсызланып кузгалды. Найманның илчесен Коргак-Күл җәйләвенә карап алып китә бирде.

VI

Якты-Күл җәйләвеннән чыгып, сәгать ярымнар баргач, ат өстендә чабып килгән бүз балалар очрады, карт балалардан Әхмәт авылының хәзер кайда күчкәнен сорады. Бик аз гына сузып: «Ә-нә... тора!» — диделәр. Ләкин казакъның «ә-нә... тора» дигәне алтмыш чакрым булып чыкты.

Азым әкә, күк Дөлделне тирләтеп Коргак-Күл туфрагына аяк басканда, төш ауган, һава бераз талгынланган, маллар чел-ләнең көндезге кызулыгыннан соң рәхәтләнеп ашый башла-ганнар иде. Бу җәйләү картның күңеленә ошамады: туфрагы начар, саргылт; үләне сирәк, сыек; күле чыннан да корып бетеп бара, аның тирә-ягы әллә каян-кая кызыл вак үлән белән кап-ланган. Сахрада көтү-көтү йөргән малларның да чырае юк: җәй уртасы җитсә дә, Якты-Күлдәге кебек симереп җитмә-гәннәр, кайбер тайлар әле һаман да ябагаларын коеп, матур-ланып китә алмаганнар. Ара-тирә корчаңгы атлар да күренә. Боларга карап:

— Дөнья тигез түгел, ау, Тәңрем! — диде дә Азымбай карт, бер баланың күрсәтүе буенча, авылның бае Әхмәтнең тирмә-ләреннән соңдагы бер киез өйнең артына барып туктады. Кыч-кырып бирелгән сәламгә каршы, башына ак урамал сарган, фәкыйрьчә, ләкин бары белән пакь киенгән бер киленчәк чык-ты. Сабыр, басынкы тавыш белән:

— Иркәкләремез өйдә юк, атам сукыр булганга, каршы чыга алмый, хуш киләсез! — диде.

Кунак, аттан төшеп, аргамагын бәйләп, камчысын кулына тотып, киленчәк артыннан өйгә керде.

Зур, биек, ләкин бик күп ямаулы тирмә.

Җир идәннең күп җире ачык, тик түргә генә бераз киез түшәлгән, кирәгә буенда буяулары югала башлаган берничә сандык, алар өстендә берничә юрган, келәм, сул якта бер камыт, кибеп ауган буш саба, күптән кымызга тимәгән пешкәк, кер-ле самавыр, берничә табак — менә өйнең бөтен җиһазы шул иде.

Өйнең иң түрендә, озын кызгылт җонлы куй тиресе өс-тендә, сандыкка аркасын терәп, тезләрен бөкләп, бер карт утыр-ган. Аягына иске читек-кәвеш, өстенә изүе бау белән бәйләнгән, якасы кире кайтарылган озын ак күлмәк, аның өстеннән төя җонынкан сугып, кыл катнаштырып эшләнгән зур көпе кигән, зур буйлы, бөркет танаулы, озын ак сакаллы, ләкин ябык, кип-кән тәнле бу баба — кунакның эзләп килгән мәшһүр Биремҗан аксакалы иде.

Азымбай керүгә ул урыныннан кузгалмады, баш күтәрмәде, йөзе-күзе үз алдындагы бер ноктага текәлгән көенчә калды, ләкин бөтен торышында колаклары белән бик аз, бик әкрен тавыш тулкыннарын да аерып танып торган бер дикъкать сизелә иде.

Кунакның сәламен алмады, күзләрен шул элекке ноктага терәгән хәлдә:

— Юл булсын, кордаш! Тавышың, аяк атлавың найман иленең Азымбай әкәнекенә охшап калды... Сезнең ыруг бу Коргак-Күл җәйләүләренә килә торган юлларны онытып бетмәгән икән әле! — диде. Үз яныннан урын күрсәтеп, утырырга кушты, мал-җанның аманлыгын, ил-көннең саулыгын сораша башлады.

Кунак, аманлык-саулык турыннан үткәч, беренче сүз буларак, аксакалның зирәклегенә хәйран калганлыгын әйтте:

— Сары-Арканың өлкән ил агасы Чингиз байның җиназасы куй елында булып иде, инде икенче әйләнеп, җылкы елы килде. Ялгышмасам, ундүрт ел үткән була... Ул чакта сез даланың асыл җире, Яшел-Сырт дигән җәйләүләрдә күчеп йөри идегез. Шул җиназадан соң Биремҗан ағамны күрү насыйп булмады... Шунча гомер үтеп тә, сез мине тавышымнан таныдыгыз. Моңа адәм акылы ирешә алмый! Ясаган иямнең биргән зирәклегенә чик булмаса кирәк! — диде.

Хуҗа аксакал авыр бер сулады, һаман күзләрен бер ноктага терәгән көенчә, әчке, авыр хәсрәтле тавыш белән, ләкин бөтенләй икенче яктан җавап кайтарды:

— Колагымның зирәклеге белән ни кылыйм, чырагым! Күп ел инде ясаган иямә моңлык кылып утырамын, мәгәр сәгате җитмәсә кирәк, телемне алмый: аңа әйттем, Сары-Арканың бу авыр тәкъдирен күрсәтеп йөрәгемне яндырма, минем җанымны ал, дидем. Булмаса, күземне сукыр кыл, илнең бу җәфаларын, бу газапларын күреп утырудан мин котылыйм, дидем. Колагымны саңгырау кыл, йортның күз яше катнаш ыңгырашуларын ишетмәс идем, дидем. Телемне алмады, яшем сиксәннең эченә керде, туксанга табан карап бара ятыр, ризыгымны кис диеп, күп зарилык иттем... Тыңламады. Тик бер сүзем кабул булды — күзләремне күрмәс кылды. Мәгәр колагымның ишетүе элеккедәй көчле булып калды: унбиш ел элек бер мәртәбә очраган адәмне тавышыннан тану гына түгел, бөтен илнең, Олуг йөз, Кече йөз, Урта йөзнең һәрберендә, казакъ ярыктыгының авыр тәкъдирдән моңланып, анасы югалып кыйналган бутадай хәсрәтләнеп җылаганын шушы иске тирмәм эченнән ишетеп утырам... Җанымны алмаган өчен аңа үпкәм зур,— диде.

Ишектән самавырын күтәреп киленчәк керде. Тирмәнең сул ягында торган тәбәнәк шкафтан керле ашъяулык, сабы

сынган чәйнек, ямаулы чынаяклар, берничә бавырсак салган бер тәрилкә алып, боларны кунак алдына китереп куйды, куе каймак салып, чәй ясый башлады.

Акылы, чәчәнлеге белән Сары-Аркада дан тоткан Биремҗан аксакал заманында уртача дәүләтле адәмнәрдән иде. Байтүрәләр эш башына менеп, бу аларга каршы гауга башлаганның икенче елында, караңгы төннәрнең берендә, бер көтү җылкысын куып алып киттеләр. Атбасар, Күкчәтау, Кызылъяр арасында йөргән зур кәрванын бастылар. Шул ике бәла аның билен сындырды, бәхетен кире җибәрде. Борынгы мактаулы Яшел-Сырт дигән җәйләүләр найман ыругларының интригасы белән урыс хәзинәсенең ат заводларына, хохолларга алып бирелеп, менә шул Коргак-Күл җәйләүләрендә күчеп йөри башлагач, малларга бу җирнең тозлы икълиме[1] ошамады, аксакал акрын-акрын бөлде. Үзе сукыраеп, бердәнбер угылы Җанбирде дә авырып киткәч, карт инде менә шул хәзерге хәленә төште.

Казакъның борынгы гадәте буенча, ул кунакка хөрмәт кылу тик кымыз һәм ит белән генә була дип карый, самавыр, чәй, бавырсак кебек начар бидгатьләрне[2] эшкә санамый иде. Килене чәй әзерләгәч, карт казакъ кунагыннан гафу үтенергә кирәк тапты:

— Ерак илнең мөсафире безне гаеп кылмасын: байлыгымыз бетте... Өемез кымызсыз утыра! Үткән-барган кунакларны ит белән, кымыз белән сыйлап җибәрергә куәтемез җитмәүдән күңелем бозылып кала,— диде.

Дөньяны күп күргән, атаклы чәчәннәр белән сүз көрәштергән Азымбай бу аксакал алдында үзен югалтты. Картның һәрбер сүзе гүя аның йөрәгенә ук булып кадала; гүя уйлап килгән йомышы алдан ук җимерелә бара кебек иде. Шулай да сүзне ул якка таба борырга батырлык кылды, озын әңгәмәләрдән соң, иплэп китереп, Байтүрәнең арзуын[3] әйтә салды:

— Бу ялганда адәмнең яманлыгы да, яхшылыгы да булучан. Яшьлек тамырыбыз Байтүрә каты наукасланып, тәкъдирем җитте дип, әҗәл көтеп ятыр... Мәгәр кордашым Биремҗанның күңелен алмый китсәм, кабердә җаным тыныч тапмас дип, мине сезгә җибәрде,— диярәк сүз башлады да, соң-

---

[1] *Икълим* — климат.

[2] *Бидгать* — яңа кертелгән әйбер.

[3] *Арзу* — теләк.

гы утыз ел буенча найман белән сарман кабиләләре арасындагы талашны, моңа нигезләнгән партия, булыслык[1], билек сайлавы өчен булган талашларның тудырган фаҗигаләрен озак-озак итеп, бер-бер санап чыкты. Ахырында:

— Найман йорты ыруглары Урта йөзнең өлкән аксакалы Биремҗан әкәне үз илемездә кунакта күрсәк иде дигән өмет белән калдылар... Әгәр инде бу сүзләрдә хатам булса, олуг аганың ак күңеле мине кичерер, илченең аяк тайган җирләрен күрсәтер, төз юлга барырга акыл бирер, безнең теләгебез шул,— дип тәмамлады.

Казакъ сүзгә никадәр оста булса, башкалар сөйләгәнне дә шулкадәрле үк тыңлый белә. Кунакның ит пешәрлек вакыт сузылган сүзләрен Бирем әкә бик аз бүлдерүләр белән, тирән дикъкать эчендә акылына салып утырды, аннан соң ашыкмый үзе сүз башлады:

— Безнең,— диде,— найман ыругсына ачуыбыз юк. Мәгәр ул партиянең башлыклары булган Байтүрәләр, Якуплар йортына барып кунак булуны, аларның кымызыннан, итеннән авыз итүне дуңгыз белән бер табактан тамак җию дип күрәбез! — диде.

Сүз акты. Байтүрәләрнең утыз ел буенча, урыс түрә белән берләшеп, Сары-Арканы нинди хурлыкка, коллыкка төшерүләре, үзләре дәүләт-мал арттырып, илне җирсез-сусыз калдырып, бөлгенлеккә салулары, алар сүзе белән җир аударылган, Өмбенең, Симинең, Яман Каланың, Тургайның, Кызылъярның зинданнарында, даласын, итен, кымызын, анасын сагынып, тимер рәшәткә эчендә елап утырган казакъ балаларының газапланулары акрын, сабыр тел белән кунакның күз алдыннан үтте. Ахыр килеп:

— Илчегә үлем юк, мин сиңа шелтә кылмыйм, мәгәр,— диде,— син Байтүрәгә әйт: адәм баласы кулы белән эшләгәнне муены белән күтәрергә тиешле! Илгә таш чәчте, кан агызды, әгәр болар бугазына утырса, үз чәчкәннәрем үсте дип белсен!!! Тәкъдире җитеп дөньядан кайтса, яшьлек тамырым булганлык өчен җиназасына барачакмын, мәгәр дәверенә, тәһлиленә кермәм, бүләген алмам, итеннән, кымызыннан авыз итмәм... Найман ыругларының яхшыларына миннән сәлам әйт!

Сүзнең болай бетүен кунак үзенә фатиха дип аңлады, әдәп

[1] *Булыс* — волость.

йөзеннән тагы берничә моң-зарын әйтте, дөньядан шикаять кылды:

— Өметем зур иде, бу талашларның чиге күренми, күңелем бозылып калды, Бирем әкә,— дип, кулына камчысын алды.

IX

Бу тирмәләр белән Кызыл уйсу арасындагы кутанда, бәйләүле колыннар янында, ак башлы хатыннар, чиләк, корык тотып, бия савып йөриләр иде. Карт, атны уңга тартып, өйләрнең арт ягына чыкты. Ике тирмә арасында җылгыр күзле, кайбер калку күкрәкле киленчәкләр белән, җефәктәй кара чәчләрен җилкәләрендә тулкынландырып, башларына кечкенә кызыл кәләпүшләр кигән сылу кызлар ачык һавада җырлый-җырлый киез басалар, бер кимпер аларга юлбашчылык кыла; бүз балалар, шулар тирәсендә бушны-бушка бушатып, киленчәкләр белән, сылулар белән сүз көрәштереп, бүген кич янынңа барсам, кабул кылырсыңмы дигән мәгънәне читләп аңлатып, шаярып йөриләр.

Йортның бер ягында ике төрәнле тимер сабан, уру һәм чабу машиналарының бу дала тормышының уртасында күренүе карт өчен, мәчет эчендә зур чәчле, тәреле урыс күренгән кебек, ят булып тоелды.

Карт боларның яныннан үтте, туры уртадагы өлкән ак тирмә артына барды. Анда бер ат янында берничә казакъ җегете тора, боларның берсе, яшьрәге, бөтенләй юлча әзерләнеп киенгәнгә охшый иде.

Азым әкә якынлашуга, бу җегет аңа каршы барды:

— Хуш киләсез! Яман-Чүл сезне күрмәгәнгә ун еллар үтеп инде,— дип сәлам бирде.

Бу җегет картның эзләп килгән Арысланбае иде.

Кул бирештеләр. Мал-җанның аманлыгын, ил-көннең саулыгын сораша-сораша, өйгә керделәр.

Күп еллар элек Азымбай карт бу йортның кодасы иде. Дәүләте үсеп барган чакта җегетнең атасы Магҗан хаҗи белән якыннар иде. Ике яшьлек кызы Чулпанны дүрт яшендәге Арысланбайга әйттереп, бераз калым да алган иде. Кыз чәчәк авыруы белән дөньядан үтте.

Партия талашлары бик кызып киткән заманда Азым әкә Байтүрә ягында булды. Магҗаннар Сарсымбайга кушылды. Шулай итеп, ике арада йөрешү-кунаклашу да тукталды.

Үткәндәге ул якынлыклар өстенә, җегет өчен бу кунакта аерым бернәрсә бар иде.

Арыслан шул көннәрдә генә сөргеннән кайтты, карт исә Сары-Арканың аяклы хәбәрчесе, партия, кабилә талашларының, барлык интригаларының үзәгендә кайнаучы иде. Соңгы ун елдагы ара суыклыгын бөтенләй онытты, Арысланбай моның килүенә чын ихластан шатланды.

Ул бүген иртә белән генә үзенең тамыры Карлыгач-Сылудан хәбәр алган иде. Кыз кичә кич үзенең кияве Калтайны кабул кылмый кайтаруын белдергән:

— Кайтканыңа ике көн булды дип ишеттек... Тамырыңның хәлен белмичә, атаң урынына калган агаң Сарсымбайның йортына сәлам бирмичә торуың бер яман эш гуй,— дип әйттергән иде; Арыслан хәзер шунда барырга әзерләнеп ат иярләткән иде.

Ләкин, карт килеп төшкәч, кичегергә уйлады: Байтүрә дигәннәре үлем түшәгендә ята; партиянең, ыругның эшләре бик гаугалы заман; сайлаулар да җитеп бара... Мондый вакытта найманнарның өлкәннәреннән булган Азым әкәнең килеп төшүе бушка булмаячагы мәгълүм иде. Шуның өчен дә Арысланбай Азым әкәгә ачык йөз күрсәтте, байларча җыештырылган матур, зур ак тирмәнең түренә, кадерле урынга утыртты, шунда йөргән киленчәккә, ярым шаярып:

— Борынгы кодагыз гаепләп китмәсен: туктының симезен суегыз, кымызны мул китерегез,— диде. Ләкин кунагының кәефе мондый уенчак булмавы хуҗаны бераз гаҗәпкә калдырды. Карт, гәрчә аз-маз уен-көлке сөйләсә дә, аның йөрәгендә нindидер бер яра бар кебек сизелә иде. Җегет берничә мәртәбә сорарга дип авыз ачса да, өлкән адәм үзе әйтмәгәч, батырчылык кыла алмады. Мәгәр карт озак көттермәде, кымызның куәте тамырларга таралып, канны бераз кайната башлавы белән, Азымбай үзе серне ачты:

— Атаң мәрхүм белән якын дус идек... Кызым Чулпан исән торса, киявем булачак идең; шулай булса да, мин бу җәйләүгә кунак булып килмәдем,— диде. Коргак-Күлдә булуын, Биремҗан аксакалга ни өчен килүен сөйләде, ахыр килеп, теге дивана карчыкның — Миндинең таягына тукталды:

— Яшем,— диде,— алтмышны үтеп бара ятыр!.. Буз җегет заманында тукалның җылкысын урлап бер тотылдым. Аркамны ярганчы кыйнадылар. Шуннан бирле һичбер адәм кул тидергәне юк иде... Бүген яман бер кимпер ил алдында түбәләп

ташлады... Каршы әйтергә йөрәгем җитмәде... Гомеремдә бер мәртәбә авызым ябылды. Син, диде, җоны коелган ямаң этсең, Байтүрәнең ташланган сөякләре өчен аның хәрәм малын багучы, аның ил талап җыйган дәүләтен саклаучы яман этсең, атаңа нәләт... сакал... дип, үземне хур кылды! — диде.

Арысланбай өчен бу гаҗәп бер хәбәр иде. Ихлас күңелдән картны кызганды, ләкин Азымбайның фаҗигасе тагын да тирәнрәк иде:

— Шул акылдан шашкан кимпер мине акылга утыртты! Каршы ни әйтим! Эт булуым рас гуй. Мәгәр миңа һичбер сөяк тигәне юк. Би кылып сайламадылар, авылнай ясамадылар, булыс булуны төшемдә генә күрәм! Ара-тирә байның кымызын эчәм, итен ашыйм икән — казакъ йорты үзенең бу нигъмәтләрен далада каңгырып йөргән бичара нугай хәерчегә дә бирә түгелме?! Карт күңелем бозылып калды... Коргак-Күлдән найманга кайтмыйча, күк Дөлдөлне Яман-Чүлгә тартуым — менә шуның өчен иде! — диде.

Карт бу төнне Арысланбайда кунды. Җегет, үзенең тамыры Карлыгач-Сылуның шелтә кылачагын белсә дә, сәбәбен аңлагач кичерер, дип уйлады. Кунак белән озак әңгәмә кылды. Үзенең йөргәннәрен, күргәннәрен сөйләде, соңгы ике елның талашларын сөйләтте.

Азымбай әкә икенче көнне, итне ашап, кымыз белән әбдән мас булып алганнан соң[1], үзенең актык сүзен әйтте:

— Балам,— диде,— Алтын-Күл җәйләвенә бар. Сарманнарга миннән сәлам әйт. Ул йортның өлкәннәренә минем шушы сүземне ирештер: тауның ташы, ничаклы каты булса да, бер барып җимерелә икән! Диңгез булып җәйрап яткан күлләр дә бер корый икән! Байтүрә нәселе хәзер шуңа охшап калды!.. Әгәр сезнең танабугалар, кара-айгырлар, кызылкортлар, сарманнар яңа йорт салырга ният кылсалар, илнең ак күңел адәмнәре ярдәмгә әзер булырлар... Сарсымбай минем сүзләремә колак бирсен!

Илче кунакның бу кинаяләре җегеткә ачык аңлашылды. Аның күңелен шатлык белән тутырды. Үз ягыннан җавап итеп:

— Инде, Азым әкә, безнең җәйләүнең юлын күрдегез! Танабуга йорты һәрвакыт сезне үзенең кунагы кылмакка тели! — диде. Шул сүз белән далага чыктылар.

---

[1] *Әбдән мас булып алганнан соң* — бөтенләй исергәннән соң.

Атлар иярләнеп әзерләнгән иде. Карт, аягын өзәңгегә куя биреп, үзенең эчке зарын әйтте:

— Ясаган иям тел бирде, акыл бирде, мәгәр малың булмагач, бу дөньяда кадерең юк икән! Байтүрәнең эте булып, яман кимперләрдән кыйналуым күп ел гомеремне кыскартты. Инде калганын адәм сынлы үткәрсәм иде!

Озата чыккан җегетләр, моны аңламыйча, аптырашып, берберенә карандылар. Илче Азым әкә белән Арысланбай атларына менделәр. Берсе Якты-Күлгә, берсе үзенең тамыры Карлыгач-Сылуның сагынып көтеп яткан җәйләвенә карап юлга төштеләр.

XI

Карлыгач-Сылу, күптән уянган булса да, кичәге күңелсезлектән соң, анасына күренергә кыенсынып, күп уйларга гадәтләнмәгән башы белән үзенең авыр язмышы турында хафаланып, караңгы кайгы эчендә ята иде. Ялчы төнлекне ачты, югарыдан бөркелеп сахраның саф һавасы тулды. Уң якның киезен күтәрделәр, якты кояш нурлары, кирәгенең челтәрләре арасыннан кереп, өйнең идәнендә, киез өстендә түшәлгән паласларда шакмак-шакмак булып уйный башладылар, сул якның ачыклыгыннан тыштагы яшел үләннәрдә кибеп барган чык тамчылары ялтырап күренде. Ләкин иркә Сылу һаман кузгалмады, түгәрәк тирмәнең уң як түренә, кирәгә буена куелган караватында чәчләрен туздырып, кечкенә, нәфис, алсуак аякларын кичке күлмәк эченә, үзеннән үзе тулкынланып торган матур тәнен йомшак юрганнар астына яшерә-яшерә, һаман бер яктан икенче якка ауный бирде. Зиһенен нәрсәгә генә юнәлдерергә тырышса да, анасының кичәге сүзе аның колагыннан китми иде:

— Телемне алмасаң, сиңа биргән ак сөтемне бәхилләмәм!

Өченче көн кич җегете Калтай килде. Туй булмаганга, гадәт буенча, ата-анадан яшеренеп, киленчәк Айбала аркылы хәбәр итте, Карлыгач-Сылу кискен сүз белән:

—Минем аңа кабулым юк,— дип җавап бирде.

Җегет хурланган, киленчәкнең калымлык исеменнән, ялганлап: каты наукасланып калдым, карагым үпкәләмәсен, дигән сүзенә ышанмаган.

— Яхшы анадан туган ул яман кыз белән безнең кара-айгыр йорты ни кылырга белер! — дип, каты ачу белән үзенең Байчобарын суга биреп, караңгы төндә кире кайтып киткән. Арадагы

илче Айбала боларның барын да кызга шул көндә үк әйткән иде.

Ләкин байбичәгә бу хәбәрне ишеттергәнме, яки ана йөрәге, үзе сизенеп, кодалык йорты белән ике арада зур талаш чыгачагын уйлаганмы — иркә Сылу моны белмәде. Мәгәр анасы Алтынчәч бикә кичә кызын чакырды да башта сөеп, иркәләп, ай ярымнан туй булачагы турында ишарә кылды; кыз баланы күз агыңдай кылып үстерәсең дә чит йортка җибәрәсең, ана күңеле өчен күп хәсрәтле бер эш бу дигәндәй кинаяләр сөйләде.

Карлыгач-Сылу башта сүз кайтармады, ахырдан түзмичә, анасының күкрәгенә капланып:

— Чичәм[1], ике күзем, ул адәмгә бармыйм мин! — дип, туптуры әйтте дә елап җибәрде.

Ана гадәттән тыш хафалы тавыш белән кызын юатты:

— Өлкән нәселнең, яхшы атаның баласы булган бер җегет... Тәкъдирең шул... Яшь ярымнан әйтелгән, калым алынган!..— дип озак сөйләде.

Карлыгач, боларга карамастан, сүзендә нык торды, елавыннан туктап, ишек яңагына барып сөялде дә актык сүзен әйтте:

— Теләгәнеңне кыла бир, Калтайны яратмыйм, күңелем башкада... Әгәр көчләсәгез, гәүдәмне Алтын-Күлдән эзләп алырсыз!

Байбичәнең күңеле катты, шелтәле һәм үпкәле тавыш белән:

— Телемне алмасаң, без биргән җегетне ташлап, кодалар белән талаш чыгара торган булсаң, сиңа имезгән ак сөтемне бәхилләмәм! — диде. Шуның белән сүз киселде.

Кызның бөтен дала кояш нуры эчендә йөзеп, тыштта малтуар уйнап, җәйләү кызу кайнаган заманда тирмәдә ялгызы ятып, очына чыга алмас уе менә шул күңелсезлекләргә бәйләнгән иде. Сарсымбайның казан янында эремчек кайнатып маташкан Айбалага йомшак тавыш белән: «Киленчәгем! Карлыгач-Сылуың тормаган булса кирәк, барып уятсаңчы!» — дигән сүзен ишеткәч, кызның йөрәге дерелдәп китте: атасы һәрвакыт ялгызым дип, иркәм дип кадерле, ул бәлки көчләмәс, сөйләп, итәгендә еласам, бәлки, күңеле кызганыр дип уйлады. Ләкин бу да шөбһәле иде. Чөнки Сарсымбай соңгы көндә никтер бераз хафалы күренә, үзенең сылу кызына

---

[1] *Чичә* — әни.

йөрәгендә бер үпкәме, ачумы асрагандай бер хәлдә карый, үзен салкын тота иде. Кыз: «Ни кылыйм, башым җитми, ау!..» — дип, тагын аптырауга чумды.

Тыштан аяк тавышы ишетелде, кулларын сызганган килеш, казакъның тирән музыкалы көе белән акрын сузып:

Асылдың кыягындамы,
Тулпарның тоягындамы,
Артык туган идең, ау!..—

дип җырлап, Айбала килеп керде.

Кыз яткан җиреннән кычкырып көлә бирде, киленчәкнең җырының ахырын шаян тавыш белән үзе көйләп каршы алды:

Соңкардай чөелгән,
Лачын костай[1] төелгән,
Җиңсез фиран киенгән,
Шаһзатдың[2] токымы идең, ау!..

Айбала фәкыйрь, ямьсез, ләкин ваемсыз, һәрвакыт шат күңелле, дәртле йөрәк бер хатын иде. Ишектән керүгә, әле һаман юрганнар эчендә иренеп яткан дусын шаяртып шелтәләде:

— Тирмәнең төнлегеннән якты кояш үзеңне карап тора! Тургайлар өй турында: «Карлыгач-Сылу, торсаңчы!» — дип сайрап, һавага менәләр... Иркә таем, син ни кылып һаман ята бирәсең? Кузгалсаңчы! — диде дә, караватка килеп, кызның юрганнарын тартып уйната, кытыклап үбә, шаярта башлады.

Болар бик күптәнге дуслар, сердәшләр иде. Иркә кыз ачуланмады, тартып алган юрганнарын кире ябынып:

— Тәнемне ачасың, сәүләм, мин киенмәгәнмен гуй!..—дип, рәхәтләнеп уйнап, яңадан юрганнарына төренде. Баягы кара уйлар бөтенләй югалдылар.

Шулай шаярышкан вакытта киленчәк кызның күз төпләрен, бераз тартылган яңакларын, әйтерсең, яңа күргәндәй гаҗәпләнеп карады да кинәт уйнаудан тукталды:

— Карагым, сиңа ни булды? Сулган гөлгә охшап калгансың гуй!..— дип, иркәле кызгану белән йөзеннән үпте, икесенең дә зиһеннәре икенче якка китте.

Шаяру бетте. Карлыгач-Сылу бераз хафалы тавыш белән:

— Йокым начар булды, яман төшләр тынычлыгымны алдылар,— диде.

---

[1] *Костай* — коштай.
[2] *Шаһзат (шаһзадә)* — шаһ улы, патша улы.

Киленчәк ихлас күңелдән борчылды, кызның мендәрен каплап, тулкынланып яткан кара җефәк чәчләрен уйнатып, ярым кочаклады:

— Иркә таем,— диде,— кичә Калтай белән булган эш өчен акылсыз сердәшеңне кичергән булсаң, төшеңне сөйлә, йөрәгеңне ач! — диде.

Карлыгач авыр сулады:

— Сәүләм, синнән яшергән ни нәрсәм бар? Сөйләсәң — сүз җитмәс, көйләсәң — көй җитмәс, бу киң даланың шундый бәхетсез бер баласымын гуй! — диде дә уйга калды. Бераз кысык кара күзләренә нечкә хәсрәт төсе чыкты. Кара туткыллы, үткен сылу йөзен нииндидер эчке бер борчу каплады.

Ләкин Айбала киленчәк кайгы-хәсрәткә җиңелеп озак тора алмый торган адәм иде. Аның бетмәс уен дәрте дә яңадан күтәрелде, кызны тагын шаярта биреп:

— Колынчагым, куйсаңчы юкны, мал, бәхет эчендә үсәсең, ил эчендә якты йолдыздай сылулыгың бар, тагы җитмәгәнең нәрсә? — дип, дусын күңелләтергә теләде. Бик сак, бик киная белән генә, икенче бер җегет күңеленә хафа салып йөрсә кирәк, дигән мәгънәдә ишарә ясады.

Кызның йөзе ачылды. Күзләрендә мәхәббәт нуры ялтырады, тулы карасу-кызгылт иреннәрендә елмаю уйнады... Гүя үз эчендә уйнаган шатлыкка, зиһенендәге матур хыялга карап, акрын гына:

— Сизгерлегең бар, ау, җиңгәм!.. — дип, акрын гына көлде. Саф энҗедәй тезелгән вак тешләре ялтырап калды.

Киленчәк кызның романын күптән сизә иде. Арысланбай белән ике арадагы тамырлыкның тирәнәюен дә чамалый иде. Ләкин бу дәрәҗәгә җитәр дип уйламый, яшь күңел бер тулкынлана да туктала, бу да шулай булыр дип карый иде. Мәгәр кичәге Калтай вакыйгасыннан соң аның алдында зуррак яра ачылды. Карлыгачның хәзерге сүзе аңа куәт бирде:

— Чырагым, күңелеңне аңлыйм, мәгәр кара-айгырлар йорты бер яманлык кылмасыннар! Йөрәгем шуннан куркып калды,— диде.

Бу куркыныч кызның үз башын да күптән хафалый иде. Ләкин күңелен тыя алмый иде. Моны дусыннан яшермәде.

— Язганын күрербез, мәгәр мин Арысланнан бүтәнгә бармам дип ант эчтем... Анама да әйттем, Калтайга көчләсәгез, Карлыгачның гәүдәсен Алтын-Күлдән эзләрсез, дидем...

Айбаланың куркуы җиңелде, хатынлык дәрте кузгалды. Кызны уенлы үпкә белән шелтәләде:

— Арыслан ир-җегетләрнең асылыдыр. Аңа сүзем юк. Мәгәр дусыңнан моңарчы яшереп килүеңә күңелем рәнҗидер... Инде хәзер дә сөйләмәсәң, Айбаланың үпкәсе каты булыр, иркәм! — диде.

Кыз урыныннан торды. Акрын, иренеп төзәтенә башлады. Ярым ачы, ярым уен-көлке эчендә:

— Үпкәләвеңне күрәм... Инде алайса тыңла,— диде дә, үзенең дүрт еллык серен ачып, сөйләп бирде.

XII

Казакъ илендәге зур туйларның берендә бүз балалар белән яшь сылулар кара-каршы утырганнар. Думбрасы, зөрнәсе белән шау килеп, уен-көлке кылалар, үләң-җыр әйтешәләр. Карлыгач ундүрт яшендә генә, мәгәр буйга җитү, йөрәгендә дәрт уянган бер кыз иде. Аның каршысында асыл киенгән, укалы бүреге, алтынлы кәмәре белән ялтырап, кызылкортның бер җегете утыра. Мәгәр кызның күңеле моңа бармый. Җегетнең мактавына каршы каты чәнчеп, үләң белән җавап кайтара... Шул вакыт ишек ачыла, ялгыз бер җегет килеп керә. Бүз балалар, сылулар арасында кайнашып йөргән бер акын, тора биреп, кунак җегетне мактый башлый. Кыз аңа күз ташлый: озынча төз буй, яңа сызылып килгән куе кара мыек, маңгайга таба бераз киңәеп килгән акыллы йөз, билдә кәмәр, кулда камчы!

Яшь йөрәккә ут төшә, кан кайный, мәгәр танымады, кем дип сорарга кыймады, сүз әйтергә теле бармады...

Ахырдан түзмәде: «Кем ул иде?» — диде. Танабугаларның өлкәне Магҗан хаҗи дигәннең ялгыз баласы, диделәр. Мәгәр, диделәр, күңелеңне сузма. Найман иленең Азымбай дигән берәүнең, айдай йөзле, камыштай буйлы бер сылу кызы — ул җегетнең калымлыгыдыр, диделәр. Хәер, диде, киң далада кызның да, җегетнең дә сылулары аз имәс гуй, диде.

Мәгәр яшь күңел бу сүз белән тынычланырмы?! Адәмнең һичберенә әйтмәстән, аны эзли башлый.

Айлар үтә. Сарсымбай авылы Җылкы-Батканнан менә шул Алтын-Күл җәйләвенә зур кәрван булып күчеп барган заманда яңадан очрашалар. Картлар, өлкәннәр, хатыннар — һәммәсе арбаларга утырганнар, кайберләре төягә менгәннәр. Карлыгач-Сылу, яулык ябынып, шул кимперләр белән утырып йөрсенме?!

Ул кызлар, җегетләр белән ат өстендә уйнаклатып бара... Шулвакыт каршыдан асыл айгырларны иярләп менгән ике кыз, өч җегет килеп чыга. Арада теге Магҗанның баласы да бар.

— Юл булсын!

— Юл булсын!

— Сарсымбай әкәнең авылы Алтын-Күлгә күчеп бара ятыр.

— Танабугадан Яшел-Сыртка кунакка китеп барабыз. Шул гади сүзләрдән соң, арадан бер шаяны әйтә сала:

— Кызларның сылулары, җегетләрнең асыллары каракаршы килгән икән, бер уенсыз үтеп китәргә ярамас... Алышмы, бирешме? — ди.

Карлыгач, үз атын тарта биреп, алга килә:

— Безнең йорт алышка да, бирешкә дә әзер, үз чамагызны карагыз,— ди.

Тезгеннәр тартыла, камчылар уйный, өзәңгеләр селкенә башлый. Якты кояш астында ачык далада, чаң[1] кузгатып, айгырларны тирләтеп, ат өстеннән бер-берен тартып алу белән уйнап китәләр.

Сылу кызның бер яман уе бар иде, теге сызылган кара мыеклы җегетне, юртагыннан тартып төшереп, бер көлке кылсам дип ниятли иде.

Астындагы елдам атны суга биреп, җегетнең каршысына килә дә лачын коштай тизлек белән аның тезгенен тартып җибәрә, айгыры борылыйм дигәндә, култыгыннан тартып, бер якка өстери, җегетнең астындагы ак юртак бераз кайшала биреп куя, мәгәр егылмый; җегет тиз генә әйләнә дә кызның атына яман камчы бирә. Карлыгач тотып өлгерә алмый; җегет, аны куып җитеп, сүз әйтеп авыз йомылганчы, бөркет коштай кагына биреп, Сылуның биленнән ала да үзенә тарта; ат туктый, кызның аяклары өзәңгедән, үзе иярдән чыгам дигәндә асылып кала, егылырга рәт җитә...

Бүз балалар яңгырашып көләләр, җегет кычкыра:

— Җиңүчегә ни бирәсез? — ди.

Карлыгач үзе дә көлеп җибәрә:

— Җегетлегең зур, теләгеңне ал! — ди.

Һәр икесе ат өстендә булган килеш, җегет, кызның гәүдәсен үзенәрәк тарта биреп, битеннән, тулы кызгылт иреннәреннән үбә дә кире ияргә утырта.

---

[1] *Чаң* — тузан.

Алар — кыйблага, Карлыгачлар төньякка карап китә бирәләр.

Менә бу җегет кызның хәзерге тамыры Арысланбай иде. Шул көн аларның беренче якынаюлары булды.

Айбала бу хикәяне гаҗиб бер дәрт эчендә кайнап тыңлады. Бетермичә туктыйсы килмәде. Анда казандагы эремчекләр өчен байбичәнең шелтәсе көтсә дә, сүздән аерыла алмады, Карлыгач үзе дә бөтенләй ачылган, күңелләләнгән иде инде. Шаяртыбрак дәвам итте:

— Ике көннән соң үз йомышы белән безнең йортка бер киленчәк килде: кабулы булса, тамырлык арзуым бар, дип әйтә, диде. Эзләгән ир-җегетем шул булса, кабул кылмаска амалым бармы? Йортның бер асыл җегете икән, телен алмаска кыюлыгым җитмәс, дип җавап кайтардым... Шул көзне сабый Миңсылу белән ике яшәрлек Куйбагарны әйттерделәр. Ул җегетнең нәселе белән безнең йорт ераграк булса да, кода шикелле булды... Кымыз катнашы китте... Асыл җегеткә безнең өйнең кунагы булырга җай ачылды. Шуннан бирле ул җегетне йөрәгемдә асрыйм... Иренендәге бал тәмен суырганым, эссе кочагымда аны йоклатканым бар... Мәгәр ике ел кичкәч, яман Байтүрә аны: ак патшага тел әйтте дип, ялган ант ясатып, җир аударды... Ерак илләргә китте...

— Кайларда булды икән бичара җегет!

— Моны белмим. Мәгәр миңа бер хат килде... Моның белән ни кылмага аптырадым. Укытырга ышанычлы бер адәм тапмыйча, ай буена, өстендә вак-вак итеп кара белән язылган шул ак кәгазьне күкрәгемдә сакладым. Башка юлы булмады, бер мумын[1] нугай молдасы килеп чыкты. Бер сум бирдем: фатиха кыл, никтер йөрәгем авырта, дидем... Бичара адәм иде, ышанды, бөти язып тагарга бирде. Ахырдан аңа кәгазьне укыттым, гаҗәпләнеп күземә карады да: «Ай, чырагым, бөтием синең бу авыруыңа дәва булмас»,— дип, көлеп китә бирде.

Киленчәк үз алдында ачылган бу фаҗигаләрдән тәмам югалып калды. Кызны күкрәгенә алып:

— Мине кичер, җаным, моннан соң Калтай дип авызга алмам! Синең колың булырмын, мәгәр миңа бер сүз әйт: йортның хәле ничек булыр? — диде.

Кыз уйлап тормады:

---

[1] *Мумын* — тыйнак, сабыр.

— Җегетем кайтты, киләм дигән хәбәре бар, аны бүген һәр сәгать көтәм, ни теләсә шул булыр, мин һәммә нәрсәгә әзер,— диде.

Килен, куркып, кызга карады, ләкин башка сүз белән борчымады:

— Сәүләм җан, мине кичер, мин колың булыйм,— дип, ашыга-ашыга үзенең эремчекләренә йөгерде.

Карлыгач-Сылу үзенең кайгысын гомерендә беренче ачуы иде. Җаны җиңеләйде, йөрәгендә кискен карар туды, шул карар белән урыныннан торды. Кечкенә аякларына Казан эше булган кызгылт төсле тар, нечкә матур итек, өстенә зәңгәрсу кара күлмәк киде, кара чәчне, үрмичә, бәйләмичә, озаклап тарап, тулкынландырып, аркасына таратып җибәрде. Яшьрәк вакыттагы кечкенә кара кәләпүшне башының бер ягынарак салды да көннең эсселеге белән, хатын-кызның, малның шау-шуы белән кайнап торган далага чыкты.

XIV

...Кулларына камчылар тоткан, көннең кызулыгына карамастан, зур итек, көпе, колакчын кигән дүрт казакъ килеп керде.

Сәлам бирделәр.

Бай:

— Юл булсын! — диде.

Кунаклар, үз дәрәҗәләренә карап, кайсы түргә, кайсы түбәнрәк, аяк бөкләп утырдылар. Арадагы юан, симез, Этбай исемле бер казакъ:

— Кашкарбай хаҗиның елы тулган көн икән. Шуңа бата кылырга китеп бара идек... Мал-җанның аманлыгын белик, өлкән йорт кымызыннан дәм татыйк, яхшыларга сәлам бирик дип уйладык,— диде.

Бай хуш килдегезне әйтте; тукал кереп, ишек төбендәге зур сабаны пешкәк белән берничә кат шапырды да өлкән табак белән Сарсымбайның алдына кымыз һәм берничә савыт китереп куйды.

Дөньяның, йорт-илнең саулыгыннан, кучәргә җәйләүләр бетеп баруыннан, зур күлләр, асыл сахралар урыс түрәләргә китеп, казакъ өчен мал йөртергә генә түгел, балаларын күмәргә каберлек тә калмавыннан күп сүз булды.

Бай, шапыра биреп, шапыра биреп, кымызны сала торды.

Җәйләүдән Байтүрәнең үләм дип авырып ятуына, ул дөньядан кайтса, яңадан партия талашы башлануына күчтеләр.

Ул арада ак урамалны сарган, сабыр, мәһабәт Алтынчәч килеп керде. Кунаклар, урыннарыннан кузгалмыйча гына:

— Аманмысыз, байбичә? — диделәр.

Хатын, күтәрелеп карамыйча, ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Шөкер! — дип җавап кайтарды да, түрдәге сандыклардан берсен ачып, нидер ала башлады.

Сүз яңа вакыйгага күчте.

Байтүрә партиясенең, найман ыругсының юлбашчыларыннан Яңгырбай дигән зур байның кызы җиде яшьтә икенче бер байның улына әйттерелгән икән. Калымлык башка берәүне сөйгән. Шул кызны бүген төндә дүрт җегет, ат менеп килеп, урлап алып качканнар. Бүген ике йорт арасында, алач әйтеп, гауга чыгарга торадыр, ди.

Аңарчы үз эшендә булган Алтынчәч, сүз моңа күчкәч, сандыгын ябып, мәҗлескә таба әйләнде. Берничә сөаль бирде; чөнки бу кодалык бөтенләй Байтүрәнең өлкән хатыны Рөкыя байбичәнең осталыгы белән эшләнгән иде. Бу ике байбичә исә яшь вакытларында матурлык белән, аннан соң байлык белән илдә өстенлек өчен ярышучылар иде. Хатын сабырлыгын җуйды, йөзенә җылан зәһәре чыкты. Кунакларга әйләнеп, начар яшерелгән шатлык катнаш агулы тавыш белән сүзгә кушылды:

— Рөкыя байбичә Тургайбай хаҗиның туенда, күп җәмәгать алдында, миңа иблистәй мактанып әйткән иде: «Кирәксә — мал бирәбез, кирәксә — кыз бирәбез, кирәксә — җир аударабыз, мәгәр үз теләгәнебезне кылабыз»,— дигән иде! Инде күреп карыйк. Найманнар белән җегетнең кардәш-ыругысы, алач кычкырып, бер-берен канга батырса, малын-җылкысын куып китсә, Байтүрәнең данабикәсе[1] ни нәрсә кыла белер икән! — диде.

Мөсафирләр бу ике бичә арасындагы талашны яхшы беләләр, Байтүрә белән Сарсымбай арасындагы илгә баш булучылык көрәшенә караганда да, бу ике матур, акыллы байбичә арасында хатыннарча зәһәрлерәк, ялкынлырак дошманлык барын күптән күрәләр иде.

Хуҗаның күңеле өчен бер сүз әйтүне кирәк таптылар, түрдәге калын казакъ, бикәгә карап:

---

[1] *Данабикә* — зирәк акыллы бикә.

— Борынгыларның бер сүзе бар: «Корымаган кое булмас, ярылмаган таш булмас»,— дигәннәр. Рөкыянең хәле дә шуңарга охшап калса кирәк,— диде.

Кунаклар, савытларын бушатып, чыгарга уйладылар, ләкин Алтынчәч:

— Юлыгыз ерак, көн бик кызу, сау малдан да берәр аяк татыгыз,— дип, кечерәк бер сабадан тагы кымыз китереп утыртты.

Кунаклар, эчеп, бит сыйпадылар.

Авыл тиздән күчәчәк булганга, алдан барачак Кызыл-Ком җәйләвен барып карап кайтам дип, Сарсымбай да чыгып китте.

Байбичә табакны, аякларны алып куйды да, яңадан сандыгын ачып, ниндидер кәгазьләр актара башлады: ай ярымнан Карлыгач-Сылуның туе булырга тора, партия, сайлау талашлары да ерак түгел, боларның һәр икесенә күп чыгым кирәк булачак, малның хакы да күтәрелгән, диләр. Шуңа күрә бай якын арада җылкыдан, куйдан, үгездән барлыгы бер илле баш караны шәһәргә сатарга кудырмак була. Кайберләренең язулары югалган, байбичә хәзер шуны эзли иде.

XVI

Карлыгач, бу кызуда янып, бүз балалар, киленчәкләр белән шаярып арыгач, тирләп-пешеп ак өйгә керде.

Төнлекне япты, кояш карамаган якларның киезләрен бөтенләй күтәреп, өч яктан кирәгәләргә челтәрләрне сөяде. Тирмәдә беркадәр талгын һава булды. Шуларны бетереп, үзенең кул эшен алырга гына торганда, шатлыгыннан кая басарга белмичә, Айбала килеп керде дә кызны кочаклап үбә башлады:

— Карагым, сөенечеңне әйт: тамырың килде! — диде.

Карлыгач:

— Сәүләм, җаным, җиңгәм! Зур бүләгем юк, яңа теккән ак күлмәгем синеке булсын! — дип, киленчәкнең биленнән алган хәлендә, ашыгып тышка ташланды.

Хәбәр дөрес: өлкән өйнең артында көмешләнгән иярле сылу айгыр, көннең кызулыгыннан, йөрүдән тирләп, башын чайкап тора; аның янында тукал, дивана кимпер, тагы берничә хатын күренә; болар уртасында башына укалы бүрек кигән, чуар кием өстеннән кара алтынлы кәмәр буган, урта буйлы, текә киң маңгайлы, карасу йөзле, тараеп килгән иякле, сызылып

чыккан кара мыеклы, ялтыр кара чәчле, тулы канлы, камыш буйлы бер җегет, кулындагы камчысын уйната биреп, көлә-көлә нидер сөйли. Кызның йөрәгенә тулкын йөгерде, каны башына китте. Айбала курка калды, Карлыгач-Сылу бу яман телле, гайбәтчел кимперләр алдында яшьлек кылмагае иде дип уйлады. Ләкин кыз үзен бер минутта кулга алды, атлавын акрынайтты, ачык, шат елмайды, әчке мәхәббәтле, ягымлы тавыш белән:

— Ак патшага кара тел әйтеп, даладан сөрелгән минем тамырым өчен юллар ак булсын! Казакъ йорты еллар буенча сине күз яше белән көтте,— дип күреште.

Кунак җегете, Сылуның нәфис, кечкенә, йомшак кулларын җибәрмичә, бераз кысып, ләкин нурлы кара күзләрен аңардан алмыйча, тамырының сәламенә каршы:

— Казакъ йорты үзенең җир аударылган баласын искә алгандырмы, юктырмы, мәгәр Арысланбай, бу җәйләүләрнең алтын көннәрен сагынып, ерак илләрдә күп моңлык кылды,— дип, кызга киная ташлады.

Бу сүзләрдән Карлыгач-Сылуның кара туткыллы сылу йөзенә, нечкә хәсрәт пәрдәсе белән өртелгән матур кара күзләренә нур чәчелде. Бераз гына да уйлап тормыйча, тамырына елмайды, аңа каршы шундый ук киная ыргытты:

— Кунагым,— диде,— хафа булмасын, мал-җан аман, йорт-ил исән. Алтын-Күлнең ак кошлары турында югары һавада кара соңкарлар күп әйләнде, мәгәр тәкъдир саклады! — диде.

Киналәрне җегет белән кыз үзләре генә түгел, башкалар да аңладылар. Шаян, үткен, ләкин сак киленчәк Айбала, яратып көлә төшеп, сүзне икенчегә борды:

— Чит илләрнең җир-суы килешкән булса кирәк, безнең Арысланыбыз киткәндә бала сыман иде, ике елда әбдән мыктый, тәвер җегет[1] булып кайткан,— диде.

Тукал да, йортның бу арада иң өлкәне булганга, кунакны сагынулары, аның язмышы өчен хафаланулары турында берничә сүз әйтте. Аңарчы ахмакча елмаеп торган дивана карчык та телгә килде:

— Ай Кодаем, ау! Ашыйсы ризыгы бетмәс, башы исән булса, адәм баласы бер кайта икән... Минем Шакирым үлеп калган булса кирәк! — дип, үкереп елап җибәрде.— Атаңа нәләт...

---

[1] *Әбдән мыктый, тәвер җегет* — бөтенләй таза, чибәр егет.

Байтүрә... җиде бабаңның каберен ачып...— дигән кебек мәгълүм тиргәүләрен тезә башлады.

Айбала уңайсызланды, кимперне:

— Кунак алдында оят булды гуй, чичәм,— диярәк, бер якка тартты.

Тукал, кымыз салып китерү өчен, уртадагы өлкән тирмәгә китте. Карлыгач-Сылу белән кунак җегет Арысланбай, йортның әдәпләре буенча, акрын, сабыр рәвештә сөйләшә-сөйләшә, ак өйгә юнәлделәр. Ләкин үзләре ут эчендәләр иде.

Түгәрәк киез өйнең эченә кереп, артта ишек ябылуга, илнең гадәте, йоласы, тышкы вәкаре бер секундта каядыр очтылар. Кызның сабыры бетте. Акылдан шашып, йөзе агарынган хәлдә, үзен-үзе белмичә: «Карагым, иркәм, үләм, ау!..» — дип, җегетнең көчле кочагында югалды. Дөньяны, адәм кайнап торган даланы оныттылар... Җир, күк әйләнде, аяк астындагы туфрак каядыр китеп, караңгылык алды. Айлар буенча озак сагыну утында газапланган йөрәкләр, эчке сөю ялкынында эреп, бергә яндылар. Кайнаган каннар, томаланган күзләр, янып көйгән иреннәр озак, каты үбү эчендә хәлдән тайдылар...

. . . .

Тыштан ниндидер каты тавыш ишетелгән кебек булды. Кыз һушына килде, керәләр бугай дип, тузган чәчләрен рәтлирәтли, ишеккә таба ташланды, ләкин берәү дә юк иде. Җегет, яңадан кочагына алып, Сылуның тулы канлы, карасу-кызгылт иреннәреннән үпте...

Карлыгач:

— Харап булырбыз, өстебезгә килерләр,— дип, көченнән язган гәүдәсен, гүя җәберләп, читкә таба тартты да өстендәге күлмәген рәтләде, йөзен, башын каплаган чәчләрен тиз генә тарап, кулбашларына төшерде.

XVII

Ишек ачылды, зур чаган табак белән кымыз күтәреп, тукал керде. Аның артыннан байның кечкенә кызы Гөлчәчәк, йөгереп килеп, кунакка сыенды. Арыслан, аның башыннан сыйпап, йөзеннән сөйде дә, кулындагы ашыкларын карап, кайдан алуын сорашып, ике конфет бирде. Бала (...) йомыркалар белән булган иртәнге талашын сөйли башлады. Яшь хатын фаҗигане сизә иде. Ләкин катнашырга йөрәге җитми иде, хәзерге ире белән

үзе дә бәхетсез булганга, кайсы хәерле булачагын уйлап очына да чыга алмый иде. Карлыгач-Сылуның яңаклары кызарып януыннан, күзләрендәге ялкыннан, киемнәренең бөтәрләнүеннән эшнең җаен сизенсә дә, аз гына булсын шөбһә күрсәтмәде, гөнаһсыз елмаю, ышанулы тавыш белән кунакка:

— Арыслан иркәм, сезне без генә түгел, бала да сагынганын күрәсезме? — диде. Утырырга өндәп, кымыз сала башлады.

Җегет җавап биреп өлгермәде, сабыр белән, вәкарь белән атлап, салкын караш белән байбичә килеп керде. Ләкин кунакны күрүгә, аның йөзе ачылды, күзләрендә, иреннәрендә елмаю уйнады.

Җегетнең анасы мәрхүм Гөлсем бикә белән Алтынчәч якын дуслар иде. Әгәр партия, ыруг талашының интригалары кара-айгырлар белән кода булуны лазем итмәгән[1] булсалар, бәлки, ул Арысланны кияү итәргә дә каршы тормаган булыр иде. Тәкъдир башкача чыкты, ләкин һаман да, аналарына хөрмәт йөзеннән, бу җегетне дә чын күңеленнән якын күрә иде. Бусагадан атлар-атламас ук:

— Хуш килдең, балам! — дип сәламләде.

Арыслан, торып, кул биреп күреште, аманлык сорады.

Бикә, кымыз мәҗлесенә таба утыра биреп:

— Күршенең бер кимпер үләм дип ятыр икән, шуның хәлен белим дип барып, озаклап калганмын... Гөлсем иркәмнең баласын каршы ала алмадым, оят булды,— диде.

Кунак, кымыздан авыз итә биреп, ерак җирләрдә бу йортны сагынып, күп кайгырганын сөйләде.

Байбичә:

— Чичәң Гөлсем бикә белән ахирәтлек булып гомер кылдык. Сине үз балам кебек күрүче идем, киткән вакытыңда күрми калгач, йөрәгем парчаланды... Инде тыныч аяк белән кайткан булсаң иде. Бала дип, җан дип, күңел шатлыгы белән үстерәбез дә көннең берендә аерылып калабыз! — дип, урамал очы белән күзендәге яшен сөртте.

Тыштан ат аягы тавышы ишетелде. Сарсымбайның калын, акрын тавышы килде. Гөлчәчәк:

— Әкәм кайтты, әкәм кайтты,— дип, тышка атылды. Башкалар да, кузгалып, каршы чыктылар.

Байның, күчәчәк җәйләүне карап, иртән китүдән яңа кайтуы иде. Арыган, янган иде. Хатыннар белән бергә

---

[1] *Лазем итмәү* — тиеш күрмәү.

Арысланбайны күргәч, кинәт җиңеләеп китте. Салынкы кабаклары күтәрелде, симез йөзенә шатлык чыкты. Дуслык шелтәсе белән:

— Атасы урынына калган агасы идем... Кайтканына ике көн булды, безгә һаман сәламе юк, дип үпкәләп торадыр идем,— дип күреште, аманлык сорады.

Бары бергә яңадан, баягы ак өйгә түгел, уртадагы өлкән тирмәгә керделәр. Тукал үзенең хезмәтләренә китте. Төнлеге ябылган, киезләре күтәрелеп, челтәр куелган бу тирмәдә һава бераз талгын иде. Бай, кунак белән сөйләнә-сөйләнә, башындагы очлы бүреген, өстендәге көпесен салды, кып-кызыл, симез җилкәсен, муеннарын сөлге белән сөртте дә кунакның уң ягыннан түргә аяк бөкләп утырды. Карлыгач, теге өйдән аякларны алырга дип чыгып, тукалны күрде.

— Апам,— диде,— кунакның кадерлесе килде... Туктының симезен суйдырып, казылыкның, ялның майлысын салсаң кирәк,— диде.

Тукал: «Ай балам, йөрәгеңә бетмәс ут төшкән икән»,— дип кызганып калды.

Кыз савытларны кунакларга куйды, яңадан өстәп, кымызны уртага китереп утыртты, шапырып сала башлады.

Сарсымбай, ил-көннең гади хәлләрен сорашканнан соң, кунакка:

— Җә, карагым, инде синең ерак илләрдә күргәннәреңне тыңлыйк,— диде.

Табак өстәлә барды, савытлар бер-бер артлы йөреп бушала, яңадан тула торды. Карлыгач үзенең кул эше белән мәҗлестән бераз читтәрәк утыра иде, күп эчмәде. Башкаларның чикәләре кызарды, йөзләренә тир чыкты, исереклек, кан тамырлары буена тарала биреп, тарала биреп, кәефле, бераз кызмача хәлгә керде. Казакъның ансыз да сүз сөйләр теле хәзер бер ләззәт белән әңгәмәне акрын-акрын суза торган булды.

Җегет кайбере караңгы, кайгылы, кайбере көлке күренешләрдә үзенең күргәннәрен сөйләп утыра бирде. Атбасар, Кызылъяр, Күкчәтау, Кустанай, Сими, Өмбеләрдән алып, Сары-Арканың башка илләре: Урта, Кече, Олы йөзләре, Тургай, Мафышлак, Пешпәк чүлләре, Балкаш, Арал диңгезләре, Зарафшан буйларын кичеп, Ташкентлар, Актүбәләр аша Яман-Калага җитте. Аннан соң үзенең ничек кайтуына тукталды:

— Әкәмнең якын дусларыннан адвокат Тынычбаевның бу турыда зур ярдәме булды,— диде.— Ул адәм губернаторда

булган, Петербурга барып, вәзирен-мәзирен күргән, бу кешенең димләве буенча: «Арысланбайның сөргенгә дучар булуын хаксыз күрәбез, без аны яхшы беләбез: ул ак патшага яман тел әйтә торган адәм имәс. Тик җәйләүдә үзе кебек бүз балалар белән, ил кыдырып, кымыз эчеп, кызык эзләп, кыз күзләп йөрүдән башканы белмәгән бер җай казакъ гуй»,— дип, йортының яхшылары, кул куеп, кәгазь биргәннәр. Менә шуның буенча аңа калага: «Танабуга ыругсы, Магҗан баласы Арысланбай дигән җегет казакъның гөнаһсыз бер баласы икән, аңа үз иленә кайтырга рөхсәт бирелә» дип язылган әмер килә,— диде.

Яхшы ук кызып алган Сарсымбай утырган җиреннән ишеккә таба каты итеп какырып җибәрде дә:

— Атаңа нәләт, шул найманнардан Сары-Арканың котылыр көне булырмы, юкмы?.. Сине сөрүчеләр шулар булды гуй,— дип, тәмләп, каһәрләп сүгенә башлады.

Сүз дивана кимпернең таягына күчте.

Бай, кызына карап, көлеп куйды:

— Азымбайны акылга утырткан ул кәкре агач кыйммәткә төште: Карлыгачым аның хәбәрен китергән өчен миннән сөенечкә күк тулпарның баласы — ала айгырны алды,— диде.

Моңарчы тик утырган Сылу, шатланып, сүзгә кушылды:

— Әкәмнән,— ди,— ел буенча шул асыл юрганы сорап йөридер идем, Байтүрәнең илчесе, үзе белмәстән, миңа алып бирде,— диде.

Кунак җегет:

— Минем атланганым да шуның ераграк бер нәселеннән килә. Сылу белән ярышып карасак, ничек булыр икән! — дип шаяртты.

Кыз атасына карады:

— Әкәм миңа вәгъдә бирде, бүген җылкыга барып алып кайтсак, сезнең йөгерекнең чамасын күрербез!

Карт кәефләнеп көлде:

— Иркә таем! Атаң иртәдән бирле ат өстеннән төшкәне юк, ерак җәйләү карап кайттым, син аны тагын җылкыга алып китәргә кызганмыйсыңмы? — диде.

Байбичә эченнән ризасызлык белән дәшми утырды. Ләкин кыз үзенекен кылды, атасын, бүген көтүгә барып, айгырны алып кайтырга күндерде.

Кунак, Карлыгач, Сарсымбай өчәүләп, көн бераз сүрелгәч барырга булдылар. Сүз яңадан «таяк»ка күчте.

XVIII

Моның төбе Арысланбайда иде:

— Кичә,— ди,— сезгә килергә ат иярләтеп идем... Шул вакыт йортның борынгы кодасы Азым әкә килеп төшмәсенме? Астында Байтурәнең күк аргамагы! Мәгәр үзе арыган, чарчаган[1], күңеле бозылган иде, туктының симезен чалып, кымызны мул куеп, кунак кылдым. Миндә кунып, бүген иртә бергә юлга чыктык... Ул найман иленә атын тартты, мин сезгә киттем... Ул адәмнең күп сүзе бар, карт көнендә акылы төзәлгәнгә охшый.

Сарсымбай ул картны яхшы белә иде. Заманында сәүдә белән алыш-биреше дә булган иде. Илчелектә осталыгы белән дә таныш иде. Биремҗан аксакалга барып, дивана кимпернең таягын алганнан соң, бөтенләй кире юл белән Яман-Чүлгә борылуы ни дә булса тирән бер әйбер булганын аңа ачык күрсәтә иде.

Кымызны яңадан сала биреп:

— И... ни булган икән ул байгышка? — диде.

Кунак савытын бушатып куйды да:

— Азымҗан картның миңа әйткәне шул: балам, диде, Алтын-Күл җәйләвенә бар, сарманнарга миннән сәлам әйт. Ул йортның өлкәннәренә минем сүземне ирештер: тауның ташы, никадәрле каты булса да, бер җимерелә икән. Диңгез булып җәйрап яткан күлләр дә бер корый икән... Байтүрә нәселе хәзер шуңа охшап калды. Әгәр сезнекеләр яңа йорт салырга ният кылсалар, илнең ак күңел адәмнәре ярдәмгә әзер булырлар,— диде.

Һичбер сүзне качырмастан йотып утырган хуҗа урыныннан кузгала бирде. Бу аның өчен көтелмәгән бер эш иде. Бер минутта алдагы көрәшнең бөтен күренешләре күз алдына килде. Бер якта Байтүрә, Якуп, Янгырбай; аңа каршы Сарсымбай, Арыслан, кияве Калтай ыругсы, тагы әллә ничаклы ярдәмчеләр! Дошманда мал күп, акча күп, урыс түрә дә астыртын аларны яклый; мәгәр сарман ыругсы, кирәксә, акча да бераз түгәр, халыкның Байтүрәгә ачуыннан да файдаланыр...

Боларны уйлап, Сарсымбай кунакны да, мәҗлесне дә онытып җибәрде. Башын югары күтәреп, тышка кычкырды:

— Җолкынбайга әйтегез, бире килсен,— диде.

---

[1] *Чарчау* — хәлсезләнү, ару.

Тиз арада зур буйлы, киң кара, шадра йөзле, ертык киемле ялчы килеп керде дә, ишек төбенә тукталып, ач күзләре белән табактагы кымызга текәлде. Бай утырган җиреннән аңа санап әмер бирде:

— Калага баруны иртәгәчә кичектерербез. Хәзер тарантаска бүген яланнан кайтарылган Кола юрга белән Бүртә айгырны җик, арбага киез, юрган, мендәр сал, яныңа Кәрим картны утыртып, Коргак-Күл җәйләвенә бар! Туры Биремҗан аксакалга туктал, Сарсымбай сине кунакка чакырды, йортымызның туктысыннан, кымызыннан тәм татысын дип үтенде, диген! Танабуга иленнән Магҗан хаҗиның баласы Арысланбай да бездә кунак булып калды, диген. Төшендеңме?

Ялчы Җолкынбай кымыздан күзен алды, чөнки өметләнү файдасыз иде:

— Төшендем,— диде дә борылып юлына китте. Ләкин чыгып өлгермәде, бай аңа:

— Тукта,— диде. Җегет кире керде.— Син үзең,—диде,— кал, атларны җигеп бир дә Кәрим картның үзен генә җибәр, тиз йөрсен,— диде.

Ялчы, ярый, дип, далага чыкты. Мәҗлестәгеләр аптырап калды. Кунак сорарга кыймады, ләкин байбичә аңламый калырга теләми иде:

— Яше туксанга карап барган ул аксакалны болай мәшәкатьләргә теләвеңнең сәбәбен белә алмадым,— диде.

Сарсымбай ике сүз белән аңлата куйды:

— Таяк үзе бар, мәгәр кыйналган Азымбайның Биремҗан аксакал белән ниләр сөйләшкәне, ни өчен килгәне безгә аз мәгълүм. Чакыртуым — шуның өчен!

Кымыз бөтен тамырларга таралып өлгергән, артык сыйдырырга урын калмаган иде, ничектер сүзнең дә җае өзелгән иде, бу һәммәсенә сизелде. Кунак:

— Далага йөреп керсәк! — диде.

Бары да кузгалып сахрага чыктылар.

XIX

Төш ауган, һава бераз талгынланган, көндезге кызу да кайткан, маллар һәммәсе далага, яшел үләнгә таралганнар, тик бүген бәрәнләп тә бүлтерекләре әле еракка китәрлек ныгып җитмәгән дүрт куй гына өй тирәсендә күренәләр. Бәйләүдәге

колыннар, киң сахрада чабарга сабырсызланып, арканнарында тартылып, кич җиткәнне түземсезлек белән көтәләр. Тукал, урта өй каршысында зур казан тутырып ит пешерә.

Сарсымбай күрше фәкыйрь тирмәдән бер җегетне кычкырып чакырды:

— Балам, син безгә атлар иярләп бир, менә Карлыгач-Сылу арыган атасын ерак җылкыга алып барырга көчләп тора,— дип, кызы белән Арысланга карап аз гына елмайды. Үзе җиз комган тотып сахрага юнәлде.

Бай әйләнеп кайтып, атлар иярләнеп өлгергәнче, җегет белән кыз өчен берничә минут аулак вакыт булды.

Карлыгач-Сылу хәлне сөйләп алды:

— Ачык әйтеп бетермиләр, шулай да ике айдан туемны ясап, мине Калтай йортына озатырга әзерләнүләре сизелә... Җегет өч көн элгәре килгән иде... Айбала җиңгәм артыннан хәбәр иттергән. Мәгәр мин, кабулым юк дип, кире кайтардым. Ул, киткәндә, яхшы атадан туган яман Сылу белән безнең ил ни кылырга үзе белер. Карлыгач өчен сарманнарга кара айгыр ыругсы белән исәпләшергә туры килмәсен, дип әйткән... Анам да сизенә булса кирәк: чакырып үгет кылды, мин җыладым, көчләсәгез, гәүдәмне Алтын-Күлдән эзләрсез, дидем... Ул күз яше белән рәнҗеде; телемне алмасаң, ике йорт арасында талаш чыгара торган булсаң, сиңа имезгән ана сөтемне бәхилләмәм, дип каргады... Инде ни кылабыз?

Җегет моны көтмәгән иде. Ул, калымлыгын түләгән тәкъдирдә, ата-ана риза булыр, кара-айгырлар да талаш кузгатмаслар, дип өмет итә иде. Ләкин тукталырга исәпләмәде:

— Карагым, син хафа булма,— диде,— Биремҗан аксакалны алырга атлар китте. Ул килер, мин аның белән киңәш кылып багыйм. Сарсымбай белән байбичәне ризалатырга, бәлки, өстенә алыр, булмаса, үз җаебызны карарбыз,— диде.

Кызның йөзе катты. Күзләренә ниндидер авыр уй чыкты:

— Бозылырга теләмәсәләр, ни кылырбыз?

Җегет бер сүздә кисте:

— Мин ярты юлда тукталырга өйрәнмәгәнмен, синең йөрәгең батырлыгына да ышанам; ат өстендә уйнап оча торган казакъ җегетләре далада бетте дисеңме? Караңгы төндә асыл аргамаклар белән Алтын-Күлдән Яман-Чүлгә китсәк, бу йортның кайсы адәме безне куып тотар да, кайсы җегетләре, танабуганың Магҗан баласы Арысланбай җәйләвеннән Карлыгач-Сылуны тартып алып кайтам дип, сугышка чыгар микән?!

Кыз мәхәббәт һәм кискенлек тулган матур кара күзләре белән җегеткә карады:

— Кара-айгырлар белән кан түгеш чыга калса?..

Атларны иярләтеп китерделәр. Бай да кайтып килә иде. Арысланбай, ачу катнаш усаллык белән:

— Хафа булма, колынчагым, бер җай табарбыз! — дип сүзен бетерде.

Атландылар да өчәүләп җылкыга киттеләр.

XXIII

Болар кайтканда көн кичеккән, батып барган кояшның кызгылт-сары нуры белән иге-чиге күренмәгән хәтфәдәй яшел сахрадагы күлләр, алтындай ялтырап, күңелгә рәхәт, тыныч матурлык биреп торалар иде.

Кечкенә, зәгыйфь буйлы аксак көтүче Күчәрбайның куйлары кайтып кутанга урнашканнар, Җолкынбай белән ялчы хатын Каләмпер бәйләүдәге колыннарны ычкындырып йөриләр. Айбала белән тукал, тагын бер күршенең фәкыйрь киленчәге һәм көндез йомырка өчен Гөлчәчәк белән талаш чыгарган малайның анасы, сыерлар савып, бозауларны аналарына җибәрәләр, дивана кимпер, көндез баскан киезләрне төреп, кара киез өйгә ташып йөри иде.

Сахра кичне каршы ала. Бияләр, сыерлар көн буенча аерылган балаларына кавышып шатланалар, ялап, шаяртып иркәлиләр. Колыннар, нечкә, көмеш тавышлары белән аналары тирәсендә чабып уйный-уйный, далага таба китәләр. Бөтен җәйләү төнге рәхәткә әзерләнә.

Тукалның күптән салган симез куй ите, майлы казылыклары, яллары озак кайнап, гаҗиб тәмле, көчле булып өлгерделәр.

Өй тирәсендә һәммә кеше, итнең тәмен бөтен тамыр сизүләре белән сизеп, казаннан табакка бушата башлауны сабырсызлык белән көтәләр, тик кайбер гамьсез балалар гына, яңа җылкыдан алып кайткан матур, янар күзле, ак күбеккә батып тирләгән ала айгырны карап, үзләренчә шәпме, начармы, Арысланбайның юртагын узармы дип, сүз көрәштереп маташалар иде.

Җегет белән кыз кайткач та аерылдылар. Сөйләшергә җай булмады. Тик Арысланбай:

— Карлыгачым, сиңа сүзләрем күп, кич янына барсам иде,— дип әйтә алды.

Сылу, мәхәббәтле елмаю белән:

— Көтеп алган җегетне кире кайтарырга кайсы кызның куәте җитәр,— дип җавап кайтарды да ак тирмәгә, анасы янына кереп китте.

Зур табак күтәреп, тукал казанга чыкты, күршедән берничә казакъ, көпеләрен җилкәләренә салып, акрын, сабыр атлап, казаннан табакка сосылган итнең чамасына күз төшереп, уртадагы олкән өйгә керделәр. Йортның ялчылары, хатыннары, ач күз бала-чага берәм-берәм шул ит керәсе зур тирмәгә таба юл тоттылар. Җылкычы ата үзенең кардәше аксак Күчәрбай белән сөйләшеп тора иде. Казан тирәсендәге кузгалу көчәйгәнен күргәч:

— Әйдә, итне состылар бугай,— диде.

Болар кергәндә өлкән өйнең эче халык белән ярым тулы иде инде. Һәркем, үзенең дәрәҗәсенә карап, кайсылары ишек төбендә баскан, кайсы чүгәләгән, өлкәнрәкләре киез өстендә урнашканнар.

Иң түрдә, хәтфә палас өстендә, аякларын бөкләп, зур симез гәүдәсе белән Сарсымбай утыра. Аның бер ягында — ука бүрекле кунак җегет Арысланбай, аннан түбән — Җылкычы ата, аның янәшәсендә — авылның фәкыйрь карты Ирҗан баба, байның икенче ягында — хуҗаның сәүдә эшләре белән йөри торган Куйбагар атлы җегет, аңардан түбәнрәк шул җәйләүнең ир уртасы фәкыйрьрәк казакълар тезелеп, бөтен мәҗлесне түгәрәк бер табын ясыйлар. Башкалар бу мәҗлескә кермиләр, читтә көтеп торалар.

Җолкынбай, кулына кечкенәрәк кенә җиз ләгән, комган алып, түгәрәк табындагыларның шул утырган хәлләрендә, мәҗлес уртасында йөртеп, кулларына су сала башлады. Иң элек байга әйткән иде. Ул:

— Мин юганмын,— диде, башкалар һәммәсе юдылар. Керле сөлге бирелде. Кулларын сөрттеләр.

Кемдер:

— Ит килә,— диде.

Ишек ачылды, аннан тукал белән ялчы хатын табаклар күтәреп килеп керделәр. Ишек тирәсендәге халык ач күзләрен парланып торган майлы итләргә текәделәр, түрдәге табынга туралмаган симез тукты, казылык белән түбәләмә тулы табакны китереп утырттылар. Иң өстә көйдерелеп пешерелгән куй

башы, азрак җаймә бар иде. Бай, гадәт буенча, Тәңренең биргәненә шөкер дигән мәгънә белән ит өстенә карап бит сыйпады да табакны Җылкычы атага табарак этәрде.

Хезмәтчеләрнең һәммәсе,— олысы-кечесе,— ит, кымыз мәҗлесләрендә читтә, ишек төбендә күз атып карап торганнары хәлдә, Юныс карт һәркайчан табынның уртасында була иде. Чөнки казакъның көн итешендә җылкы асраучылык иң беренче урын тотканга, җылкы көтүләренең башлыкларының дәрәҗәсе дә башка ялчылардан югары тотыла; Җолкынбайлар, аксак Күчәрбайлар һәм башка бик күпләрдән аерылып, Җылкычы атаның уртада булуы шул гадәт буенча иде.

Юныс карт, алдына табак килүгә, кесәсеннән бер каеш тартма чыгарды, аннан агач саплы кечкенә пычак алып, тимер табакның читенә берничә ышкыды да, биргәнеңә шөкер дип, иткә тотынды. Иң элек башны йортның хуҗасы Сарсымбайга бирде. Бу берничә җирдән өзеп капты да кадерле кунак җегет Арысланбайга тоттырды. Тирмәнең уң ягында утырган тукал, Юныска карап:

— Мин ак өйгә ит бирмәдем, шуннан өлеш чыгарасыз,— диде.

Кечкенә ак тимер табак китерделәр. Җылкычы ата аңа берничә кисәк казылык, дүрт кабырга, бер майлы бөер, бераз җаймә салды да: «Алыгыз!» — диде. Киленчәк Айбала моны алып чыгып китте.

Бусы — теге өйдәге байбичә белән Карлыгач-Сылуга иде.

Калган ит шундагы җәмәгатьнеке иде инде.

Бу читке өлешләрне бетергәч, Юныс карт пычагы белән турый башлады. Байның икенче ягындагы чәчле сәүдәгәр җегет тә кесәсеннән пәке чыгарып турарга тотынды, башкалар тураганны ашарга керештеләр. Ләкин тураучылар үзләре дә ким куймыйлар, авызлары даим селкенә, күп вакыт иң симез локмаларны[1], елт иттереп, үзләре йоталар иде.

Бик сирәк сүзләр белән, берничә минут буенча яңаклар, куллар, тешләр туктаусыз эшләделәр. Өелеп килгән ит табакның төбендә генә калгач, эшнең чамасын сизүче Җылкычы ата иң элек үзе инсафка килде. «Булдым, биргәнеңә шөкер»,— дип, майлы кулларын итек кунычларына сөртә башлады. Башкалар да, туйганмы, юкмы, бу ишарәне аңладылар. Азакқы локманы зур, симез итеп йота-йота туктадылар.

---

[1] *Локма* — кисәк.

Бай, табакны алдынарак тартып, кунак җегеткә сонды; Арысланбай, булдым, дигәч, хуҗа теге ишек төбендәгеләргә берәм-берәм согындыра башлады. Бу өләшүдә алдан яки ахырдан, зур яки кечкенә бирү согынучының дәрәҗәсенә карап иде.

Сарсымбай, акрын, сабыр сайлап, кулына биш турам майлы ит алды да:

— Куйчым, кил бире,— диде.

Көтүче карт Күчәрбай, аксап килеп, уң кулын сузды. Бай бирмәде:

— Авызыңны ач,— диде.

Көтүче, барын кабып, чәйни-чәйни урынына барды. Аның бүгенге ит насыйбы шуның белән тәмам иде.

Хуҗа, тагы өч-дүрт кисәк ит алып:

— Ялчым, кил бире,— диде.

Зур, озын гәүдәсе белән күтәрелеп, җыртык киемле Җолкынбай килде дә үз өлешен йотып китте.

Күршедән берничә җегет бар иде. Икешәр-өчәр локма алар да согынды; көндез Гөлчәчәк белән талаш куптарган пычрак, бөтенләй ялангач кара малай ит кергәннән бирле кечкенә, елтыр кара күзләрен табактан алмый карап торды. Симез локмаларны бармак арасына кыстырып авызга сузуларын, чәйнәүләрен бөтен тәме белән үзе кичерә барды. Бирмиләр, бетә дип коты очкан иде. Ләкин бай аны да хәтерләде:

— Әбаш, кил бире,— диде.

Хуҗа юри кулын тутырып җәймә, ит, май йомарлаган иде, баланың авызына сыю шөбһәле иде. Малай атылып килде, авызын ачты; бай, бөтен җәмәгать көлешкән хәлдә, тыгызлап-тыгызлап тутырды, баланың тын алырга хәле калмады, авызының ике ягыннан май ага башлады, күзе әйләнде, тончыга язды, шулай да бирешмәде: тулы авызы белән сүзсез урынына барып, бөтен мәҗлеснең көлүенә карамастан, ләкин күп мәшәкать белән чәйнәп йотып җибәрде.

Табакта бер кисәк җәймә белән берничә локма ит калган иде, бай моны күтәреп, тукалга сузды:

— Миңди кимпергә бирегез,— диде.

Бу әле бүген иртә генә килеп төшкән теге дивана карчык иде, ул көн буе эшләп арудан калгып утыра иде. Хуҗаның сүзенә кисәктән уянды, бер-ике мәртәбә тәнен кашып алды да табактагы итне каплап куйды.

Моннан соң, ике-өч стакан сыешлы агач савыт белән, кайнап суынган шулпа бирә башладылар. Күп һәм симез ит белән озак

кайнаган бу шулпа бик көчле, бик тәмле, бик туклыклы иде... Бай өч кенә мәртәбә йотты да Арысланбайга бирде, ул бик аз гына татып карады. Табындагыларның һәммәсенең карыннары тулган, йотарлык рәтләре калмаган иде. Ләкин ишек төбендәгеләр кулларына тигән савытта күпме шулпа бар, һәммәсен эчеп бетерергә тырыштылар.

Бөтен өйдәгеләр шулпадан татып чыккач, һәммәсе рәтләнеп утырып дога кылдылар.

Яшь киленчәкләр, бала-чагалар, хезмәтчеләр, күрше җегетләр чыгып киттеләр, өйдә калганнар, тук ашаудан соң берәр аяк кымыз эчеп, һәркем дәрәҗәсенә карап урын тапты, мендәр, палас, киез яки ут башы урынындагы җиргә сузылып ятып, ара-тирә кикереп, «әлхәмдулла», «биргәнеңә шөкер» әйтеп, какырып, тагы кикереп, насбайны[1] салып, кайбере тәмәке яндырып, озын-озак уен-көлкеле әңгәмәгә керештеләр.

Арысланбайның сөргендәге хәлләреннән, Сарсымбайның Байтүрә партиясе белән талашларыннан соң, сүзнең иң кызыклылары Җылкычы ата Юныс картта булды. Ул үз гомерендә чит дошман илләрдән, бигрәк тә казакъ җәйләвенә утырган кукаллардан[2], көтү-көтү малларны ничек урлап, куып алып киткәнен, югалган асыл малларны каракларда ничек табып алганын көлке һәм куркыныч итеп сөйләде. Сүз арасында йөзенә чыккан усал төс, кысык, кечкенә кара күзләрендә ялтыраган ялкын аның хикәяләрен җанлы итеп күз алдына китерәләр иде.

XXIV

Тышта кемнәрдер сөйләшә башладылар. Арада, көмеш кыллардан уйналган музыка кебек саф яңгырап, Карлыгач-Сылуның көлгәне ишетелде. Өйдәгеләрдән һичкем моңа колак салмаса да, кунак җегете моның үзен чакыру икәнен аңлады. Шулай да яшь башы белән өлкәннәрнең сүзен, мәҗлесен ташлап китү ярамаганга, форсат көтеп утыра иде.

Даладагы көлү-сөйләшү тукталды, каты, ашыгыч баскан атның, дөп-дөп итеп килеп, якында туктавы ишетелде, кемнеңдер ат өстендә хәлендә каушаулы рәвештә:

— Вафат... җиназа...— дигән сүзләре ишетелеп калды.

---

[1] *Насбай* — тел астына сала торган тәмәке.

[2] *Кукал* — казакъ далаларына күчеп утыртылган башка милләт кешеләре.

Тирмә эчендәгеләр, кузгала биреп, тышка колак салдылар. Анда адәм тавышы бетте, яңадан ат аяклары дөп-дөп итеп җиргә бәрелгәне, моның ераклаша барганы ишетелде.

Әңгәмә киселде, һәммәсендә ниндидер бер куркулы сизенү уянды. Сарсымбай, һичкемне атамастан:

— Ни бар? Берегез чыгып белсәгезче! — диде.

Арада яшьрәкләре чәчле җегет иде, ул чыгарга кузгалды. Ләкин ишеккә дә җитә алмады, тар билле, күкрәкләре укалы, бәрхет бишмәт, башына түбәсе укалы, чите каракүлле озынча бүрек кигән Карлыгач-Сылу кызулап килеп керде дә тирән, җитди тавыш белән вакыйганы аңлатты:

— Без,— ди,— Айбала җиңгәм белән икәү бәйләүдәге ала айгыр янында тора идек, Озын-Күл ягыннан бер атчабар килде. Әйткән сүзе шул: «Бүген кояш баткан вакытта найман ыруг-сының өлкәне Байтүрә морза дөньядан кайтты... Кайгылы энесе Якуп белән тол калган байбичә Рөкыя сарман иленә мине хәбәр белән җибәрделәр, иртәгә төш вакытында җиназасы булачак...» — диде дә башка илләргә үзенең хәбәрен ирештерергә яңадан чабып китә бирде,— диде.

Кызның хәбәре яшен тәэсирен бирде, берничә минут һичкем һичбер сүз әйтми катып калды, гүя дошман Байтүрәне алган үлем үзенең кара канаты белән бу түгәрәк тирмә эченә кереп капланды... Шундый авыр, басынкы хәл килде.

Иң элек җитү чәчле җегет телгә килде:

— Атаңа нәләт булсын! Илне кортуың җиткән иде. Урының тәмуг!.. — дип сүгенеп куйды.

Ләкин акыллы, тактикалы Сарсымбай аны тыйды:

— Кулы белән кылганын муены белән күтәрер, адәмне үлгәч сүкмиләр,— диде.

Хәбәр тиз таралган булырга кирәк, ак өйдән байбичә килеп керде. Аның тышкы кайгы пәрдәсе астында йөзендә һәм күзендә зәһәрле шатлык күренә иде:

— Тол калган Рөкыя байбичәдән Байтүрәнең җиназасына чакырып атчабар чыккан, диделәр, бу хәбәрнең аслы бармы? — диде.

Кыз, балаларча чынлык белән, бөтен вакыйганы яңадан, каушап, кызуланып сөйләп бирде.

Тагы сүз киселде. Сарсымбай үлгән дошманының калдыклары белән көрәшү планнарына китте. Алтынчәч кара-айгырлар белән кодалыкны җимерүнең хәзер ничаклы зарарлы

булачагын уйлады. Арысланбай исә Карлыгачның язмышы тагы чуалачагын хәтеренә китерде.

Башкалар өлкәннәрдән үтеп сүз ачарга кыймый утыралар иде. Ахыр Җылкычы ата түзмәде:

— Адәм,— диде,— кулы белән кылганының барын муены белән күтәрәчәк булса, Байтүрәнең кылганнарын күтәрергә Сары-Аркада муен җитәрме икән?

Аңарчы дәшми утырган кунак җегет Арысланбай да сүзгә кушылды:

— Байгышның туфрагы авыр булыр, үз йөрәгенә күп адәмнең күз яшен йоткан иде! — диде.

Бай белән бикә начар сүз әйтүне уңайсыз таптылар. Хуҗа сүзне икенчегә борды. Якын арада яңа җәйләүгә күчү турында сөйләде. Алтын-Күл буенда бу авыл айга якын утырган, үлән начарланган, маллар, сабырсызланып, башка яланнарны сорый башлаганнар иде инде. Шуңа күрә печән, иген эше башланганчы, яңа урынга күчәргә тиешләр иде. Сарсымбайның бу хактагы сүзен һәммәсе, бигрәк тә Карлыгач, бәйрәм шатлыгы белән каршы алдылар. Чөнки кәрван кебек төялеп күчүләр, мәшәкатьле булса да, казакъ өчен бу бер бәйрәм, уен-көлке кебек бер ихтыяҗ иде. Бай:

— Җиназадан соң кайтсак, безне көтмичә, кайбер нәрсәләрне җыя, төйи башларсыз! — диде дә кузгалды.

Аның белән башкалар да чыктылар.

Төн караңгы, күк йөзе болытлы, аз гына җил дә чыгып тора, күлнең тулкыныннан йөрәккә бер шомлы тавыш килә иде. Тулы ай болыт арасыннан бер генә күренде дә бөтенләй югалды. Даланы куе караңгылык басты. Ала айгырны бүген таң ашырырга булдылар. Юныс карт Карлыгач атланып кайткан юртакны менде:

— Җылкыны авылга кайтармам, туры Кызыл-Комга китәрбез,— дип кычкырды да көтүгә китте.

Башкалар ак өйгә керделәр. Җәйләү тынды.

XXVII

Бөтен дала тирән йокыда, тик Якты-Күл буендагы найманнарның уртадагы зур ике тирмәсендә генә ут яна. Байтүрәнең вафаты, иртәгә булачак җиназа һәм үлем хәсрәте бу йортның тынычлыгын алган, болар авыр кайгы эчендә иртәнге дәфенкүмү мәшәкатьләре белән караңгы төнне уяу үткәрәләр. Якуб,

Рөкыя, Яңгырбай, Азым әкәләр туктаусыз сөйләшәләр, нидер эшлиләр, нәрсәгәдер әзерләнәләр.

Якты-Күл җәйләве таң иртәдән шәрекънең базары, гаребнең карнавалы, гарәпнең мәхшәр дигәне кебек кайный башлады.

Көн яңгырлы, күктә кара-соры болытлар туктаусыз йөриләр, Якты-Күл ачулы тулкыннар белән өзлексез шаулый, юеш томанны бер яктан икенче якка куып, киң дала буенча каты җил сызгырып уйный иде.

Шуңа карамастан төш алдыннан Байтүрә авылының бөтен тирә-ягы җиназага җыелган халык белән тулган иде инде. Нечкә билле, ука күкрәкле бишмәтләр кигән, ак урамалар ябынган ак чәчле, җыерчык битле, кайгылы күзле кимперләр, елап күзе кызарган киленчәкләр һәм шау-шулы җирне ярата торган сылу кызлар, ак тирмәләрнең берсеннән чыгып, берсенә кереп, нигәдер йөреп торалар. Симез җилкәле, калын гәүдәле, һәрвакыт ат өстендә йөрүдән бераз кәкрерәк аяклы, киң маңгайлы, тар иякле, карасу йөзле, сирәк сакаллы, ике якка бәреп чыккан яңаклы казакълар, яңгырдан, җилдән колакчынны басып киеп, көпе өстеннән билгә кәмәр бәйләп, унары-егермешәре, өем-өем булып, килгән-киткәнгә, кергән-чыкканга аратирә күз салып, төрле җирдә нәрсә хакындадыр акрын, сабыр тавыш белән сөйләшәләр. Болар арасында чалма, җилән кигән татар муллалары, каракүл бүрекле, казаки, читек-кәвешле төрле татар сәүдәгәрләре, студент, семинарист киемендәге казакъ җегетләре, кысыкча кара күзләре, карасу киң йөзләре белән кай халыкның баласы икәнен күрсәтеп торган берничә офицер, бөтенләй европача киенгән, өлкән ак сакаллы карт казакъ адвокаты, күкрәккә медаль таккан калын биләр, бәдәл[1] эзләп йөргән, тар, нечкә чалмалы, сырган кызыл җөббәле хәерче гарәп хаҗилары, нәселе, киеме мәгълүм булмаган тагы әллә кемнәр — һәммәсе, һәммәсе шул мәхшәр кебек җәмагать эчендә бер яктан икенче якка тулганалар.

Бераз читтәрәк, бөтен басуны каплап, күбесенә пар ат җигелгән тарантас, арбалар, иярле атлар, алар тирәсендә чобалган ярлы казакъ ирләре күренә. Кутандагы киртәләрдә иллегә якын мал бәйләнеп тора. Арада берничә колынлы бия, ике симез айгыр, дүрт төя, биш корчаңгы тай, бер арты пычрак сыер, байтак куйлар күренәләр. Арбаларның, иярле атларның,

---

[1] *Бәдәл* — үзе урынына кеше яллап хаҗга җибәрүче.

өйләр арасындагы халыкның саны арткан саен, бу бәйләүле малларга да мәрхүмнең фидиясе өчен дуслары, кардәшләре тарафыннан китерелгән буталар, кысыр бияләр, яшь тайлар, чирле башмаклар, рәнҗү куйлар һаман кушыла бара, кушыла бара...

Бу хайваннар үзара тыныша алмыйча тешләшәләр, бияләр чыелдап тибенәләр.

Өйләрнең берсендә елау күтәрелә, ат кешнәве, төя акыруы, арба тавышы, адәм сөйләше белән гөж килгән мәйдан бик күп хатыннарның, берсен-берсе бүлә-бүлә, ачы, моңлы зар белән:

— Ай, түрәм, ау! Безне кемгә калдырдың, ау!..— дип елап әйткән көчле, кызганычлы авазы белән дерелдәп китә, йөрәкләргә ниндидер авыр бер шом катнаш хәсрәт агуы төшә, кан тамырлары бу елаудан әрнеп өзеләләр.

Хатыннар тиз тукталмыйлар, мәрхүм Байтүрәнең яхшылыкларын сөйләп, аны сагынып, күз яшьле тавыш белән әйтәләр-әйтәләр дә тагы йөрәк өзгеч бер ачы зар белән:

— Ай, җан түрәм, ау! Безне кемгә калдырдың, ау!..— дип, бөтен җәйләүдә, һәммә йөрәкләрдә шомлы бер кайгы уятып, күзгә яшь китерәләр.

Бу ачы, зарлы елауларның бераз тынып торган заманында, биленә думбра таккан бер адәм ат белән килеп төште дә мәет яткан тирмәгә таба китте. Казакъча киемле, ябык йөзле, дивана йөрешле, хыялый күзле бу кеше тирә-якның мәшһүр акыннарыннан Тылсымҗан иде.

Мәйданда төрле яктан:

— Акын килде, акын килде! — дигән тавыш ишетелде.

Кичәдән бирле туктаусыз ат өстендә чабып, җәяү йөгереп, байбичә Рөкыя һәм мәрхүмнең энесе Якуп белән бергә дәфенҗиназа артыннан йөргән Азымбай карт бу шагыйрьне күрүгә кулыннан алды:

— Күзеңдә яшь, йөзеңдә кайгы күренә. Сүзең беттеме? Ник бер нәрсә әйтмисең дә? — диде.

Акын хыялый күзләре белән Азым әкәгә карады да шунда ук казакъ арасында мәгълүм, авыр, акрын бер көйгә салып җавап кайтарды:

— Акылым китсә дә, сүзем бетсә дә гаҗәп имәс. Сары-Арканың өлкән ил агасын югалттык түгелме?! — диде.

Акынның тирәсенә бер-берсен таптап халык өелде. Ул үзенә әйткән һәрбер сүзгә, аз гына да туктамыйча, көйләп җаваплар бирүдә дәвам итте.

Шагыйрь тирәсендә тупланган халык эчендә Карлыгач-Сылуның кияве Калтай да бар иде. Акылы, фикере ким булса да, башкалардан калышырга теләми торган бу җегет ямьсез борын тавышы белән Тылсымҗанга бәйләнде:

— Күзеңнән су ага, йөзең кара көйгән, юеш кабердән чыгып килдеңме юкса? — диде.

Акын, һич уйламастан, көйгә салып шул мәгънәне әйтте:

— Кайгы белмәс, дөнья җимерелгәндә дә хәсрәт чикмәс үлек йөрәкләр барлыгын ишетәбез. Мәгәр бүген казакъ баласының күзендәге яшькә, йөзендәге ваем һәм хафасына һичберәүнең исе китмәсен! Адәм түгел, җир-күкнең үзе бүген авыр уйга калды, якты кояшны каплаган куе кара болытлар, өстебезгә явып торган яңгырлар — Байтүрә морзаның вафаты сәбәбеннән күк йөзенең кара кайгы пәрдәсе һәм хәсрәтле күңеленең күз яше имәсме? — диде.

Калтай тынды, башкалары, акынны мактап:

— Ай, ярыктык, ясаган ияң үзеңә чәчәнлекне кызганмый биргән гуй! — диештеләр.

Акын туктамады, һаман төрле көйгә салып җырлый бирде:

— Бүгенге хәсрәтне әйтү өчен чәчәнлек кирәк имәс. Күңелең ак булса, йөрәгеңдә илгә мәхәббәт кипмәсә, син телсез булсаң да, бүген кайгы җырын көйләрсең!.. Ай, Байтүрәм, син бер идең! Каның Чингиздән килә! Ата-бабаларың ханнар, солтаннар иде! Яшьлегеңдә азамат[1] булдың! Ир чагыңда ил өчен кан койдың. Картлыгың килгәч, көн димәдең, төн димәдең, йортның, аләүмәтнең[2] кайгысы синең кайгың булды! Ясаган Тәңрем сиңа меңләгән җылкы, төя, исәпсез куй бирде, болардан йортның бары туйды! Син киттең, исемең далада мәңге яшәр, мәгәр безне кемгә калдырдың, ау! — дигән мәгънәдә, байның зур нәселен, исәпсез байлыгын, илдә өстенлеген җырлады.

Мәрхүмнең дуслары моны әләктереп алдылар, акынның әзе буенча үзләре арттырып, бөтен җыелган халыкка сүз күбәйттеләр.

Татар муллаларыннан берсе ниндидер зур нугай ишанның сүзен очырды: гүя ул әйткән була:

— Әгәр Байтүрә булмаса иде, далада диннең, исламның хәле мөшкел булачак иде,— дип.

---

[1] *Азамат* — булдыклы, батыр егет.

[2] *Аләүмәт* — җәмәгать, халык.

Бу җиназага җыелган халык эчендә үзенең күп алыш-биреш эшләрен үтәү исәбе белән килгән, заманында казакъ даласында җон-ябаганы чирек хакка алып, әйберне биш мәртәбә кыйммәт сатып, үлчәүдә һәр ике тәкъдирдә алдашып баеп киткән якын шәһәрнең татар сәүдәгәре моңа каршы тагын арттырды:

— Өяз начальнигын, губернаторны гына әйтмим, ярыктык Байтүрә ак патшаның үзенә дә мәгълүм адәм иде гуй. Бу хәзерге Николай Второй дигән патша тәхеткә утырганда, областан карнаваниягә барган ике ил агасының берсе — Байтүрә имәсме? — диде.

Байтүрә партиясенең олыларыннан Яңгырбай дигән бай, үткен казакъ, боларга хатимә бирде[1]:

— Байтүрәбез бар иде. Чингизләрдән килгән бер аксөяк ил агасы иде. Аның урынын кем ала белер — Кодай үзе юл күрсәтсен! — диде.

Дуслар, шулай аклап, күккә күтәрделәр, дошманнар, гәрчә җиназага килсәләр дә:

— Казакъ йортының өстендәге бер яман адәм чәнчелде, инде ил үз хәлен үзе белер, казакъ йорты найман балаларына яңадан кол булмас,— дип, үлгән Байтүрә урынына энесе Якупның утыру ихтималына каршы, үз кешеләре арасында җыелып-җыелып, утлы сүз йөртүдә дәвам кылдылар.

XXVIII

Җәмәгать шулай үзара шау килеп торганда, теге акын тирәсендә үләң тыңлаучыларның берсе, бу җәйләүгә таба килгән арбаны күрсәтеп:

— Атлары Сарсымбайныкына охшый... Түрдә утырганы Биремҗан аксакал имәсме? — дип сүз ташлады.

Моны ишетеп, Азымбай чыннан шатланды:

— Үзе исән вакытында кымызыннан, итеннән тәм татымам, мәгәр, тәкъдир килеп, әҗәле җитә калса, җиназасына барырмын дигән иде, адәмнең асылы гуй, ак күңел картым килә ятыр,— дип, янындагы Сарсымбайга чаптырып килгән тарантасны күрсәтте:

— Атлар синекенә охшый!

---

[1] *Хатимә бирү* — нәтиҗә ясау.

Сарсымбай аксакал артыннан кичә үк ат җибәрсә дә, аның авылы икенче җәйләүгә күчү сәбәбеннән, элекке урыннарыннан эзләп, урап барганга, кучер соң җитешкән, шуңа күрә Алтын-Күлгә тимичә, җиназага өлгерер өчен, шул ук атлар белән Биремҗан аксакал Якты-Күлгә үз авылыннан туры килгән иде.

Боларны күрүгә, Арысланбай белән Сарсымбай картка каршы бардылар, башкалар да, тулкын кебек, аксакал ягына таба агылдылар. Моның сәбәбе юк түгел иде: Биремҗан карт моннан өч ел элек үлгән Магҗан хаҗиның (Арысланбайның атасы) җиназасыннан бирле һичкемнең каберенә килгәне юк иде. Телдән әйтмәсәләр дә, аксакалның Байтүрәгә дошманлыгын белгәнгә, бу җиназага килерме, юкмы дип шөбһәләнәләр иде. Аның күренүе зур вакыйга булды. Һәркемнән элек Азымбай барып җитте:

— Олуг атамыз, син килмәсәң, күңелемез китек була иде,— диде.

Карт, ике адәмнең ярдәме белән арбадан төшә-төшә, моның сүзен кисте:

— Исәр булма, мин сиңа әйттем: итен, кымызын татымам, мәгәр җиназасына барырмын, дидем, моны онытып калдыңмы?

Башкалар яшерен мәгънә белән бер-берсенә карашып алдылар.

Арысланбай, бу карт белән сөйләшеп, Карлыгач-Сылуны кара-айгыр ыругсы Калтайдан алып, үзенә бирү турына киңәш итешмәкче иде; ләкин беренче адымнан ук күрде ки, җиназада бу мөмкин булмаячак. Аксакал ялгыз кала алмый, аның тирәсендә һәрвакыт адәм кайнаячак. Сүзне Алтын-Күлгә кайткангача кичектерергә булып, карт белән барып исәнләште. Бирем әкә аны тавышыннан ук таныды:

— Казакъ йортының гадәте буенча, яшьләр бер җирдән кайтса, аксакалларга сәлам бирүче иде! Үзеңне Яман-Чүлдә дип ишетәбез: мәгәр атаңның карт дусына барып әйләнергә чамаң килмәде, ай балалар! — дип шелтә кылды.

Җегет ни өчен бара алмавының сәбәбен сөйләп, кичерүне үтенә башлады, ләкин картны чорнап алдылар. Сарсымбай килеп:

— Сезне кичә үк көткән идек, Алтын-Күл җәйләве үзегезне сагынып иде,— диде.

Карт ике сүздә аңлатты:

— Җәйләвебез күчеп калды, адәмегез соң килде,— диде.

Башкалар берәм-берәм аның белән исәнләшә, сөйләшә башладылар. Халыкны ерып, европача киенгән, аз сакаллы казакъ адвокаты килеп сәлам бирде. Биремҗан аны тиз таныды:

— Хезмәтеңне ишеттем, Арысланбайны кайтару юлында тырышканлыгың өчен аның атасы Магҗан хаҗиның җаны сиңа күп рәхмәт әйтсә кирәк. Илнең яхшылары синең ярдәмеңне онытмаслар,— диде.

Карт казакъ адвокат:

— Сезнең бу сүзләрегез минем өчен иң зур рәхмәт булды, артык һичнәрсә кирәкми! — диде.

Ул арада мәрхүм Байтүрә партиясенең зурларыннан Яңгырбай килеп аманлашты, аксакалның хәлен сорашып:

— Сезнең былтыргы җәйләүләрегезне кукал басып киткән икән, бу ел мал йөртергә урын аз калган дип ишеттек. Теләсәгез, өяз начальнигы аркылы ул җирләрне сезгә кайтарыйк,— диде.

Аксакалны җитәкләп алып килеп, зур ак өйнең каршысына, үләнгә киез палас җәеп утырттылар. Аның тирәсенә илнең өлкәннәре җыелды.

Яңгырбайның кузгатуы буенча, сүз кукалга, урыс түрәгә, ак патшага күчте. Бирем бераз тыңлады да бу сүзләрне кырт кисте, Яңгырбайга карап шелтә ясады:

— Син үзең, мәрхүм агаң Байтүрә һәм сезнең бабаларыгыз белән бер нәселдән килгән, бергә эшләгән Кече йөзнең Әбелхәер ханнары, бөтен Өч йөзгә хан булыр өчен урыс патшага Сары-Арканы саттыгыз! Бабаларыгыз ханлык өчен, аталарыгыз солтанлык өчен, сез үзегез түрәлек, билектә булыслык өчен яхшы җәйләүләрне кулыгызда калдырып, мал, дәүләт саклау өчен Сары-Арканы урыс патшага кол кылдыгыз! Инде хәзер килеп, кара чикмән, кукал баскан даланың бер почмагын миңа кире алып бирмәк буласызмы?! Мин карт инде, ясаган иямнән әҗәл көтәм, миңа ике адымнан артык тупрак кирәкмәс,— диде.

Бу сүзләр бер-берен таптап тыңлаган җәмәгатькә яшен кебек тәэсир итте. Мәрхүмнең һәм барлык найманнарның дошманнары: «Ай, ярыктык аксакал, һәр сүзе мең алтын гуй»,— дип, эчләреннән бәйрәм иттеләр. Дуслары: «Бу акылдан язган чал исәрне китерү кирәкмәс иде!» — дип кара көйделәр. Адвокат, берничә семинарист, студент казакълар, хәйран булып, якында стражник юкмы дигәндәй як-якка карандылар. Арадан бер карт казакъ, торып, рәнҗүле, шелтәле тавыш белән карт кунакка сүз ачты:

— Аксакал, сиңа хөрмәтебез зур, мәгәр күңелебездә шөбһә бар: син Әбелхәерне, нугайның Тәфкилев генералын гомер буена сүгәсең, нәселләре Чингизгә барган аксөяк найман балаларын мал, дәүләт, түрәлек өчен Сары-Арканы кол итәләр дип хурлыйсың, мәгәр Яшел-Сыртны кукал килеп басканда, без бөтен йорт, алач кычкырып, казакъның өлкәнен-яшен сугышка чакырдык. Шулвакыт каршы әйтүче безнең өлкән атабыз Биремҗан әкә түгел идеме?

Карт шул секундта ук җавап бирде:

— Әйе, мин идем! Кукалның малын каулап, йортын яндыруга мин каршы булдым. Сәбәбен беләсең килсә, сукыр чалның сүзен тыңла. Үзең белмәсәң, башкалардан сора, Биремҗан бөтен гомере буенча малыннан, йортыннан язып, казагым, карагым дип, талаш кылып йөргән адәм имәсме?

Җыелган җәмәгать:

— Өлкән атаның сүзе рас гуй...— дип, төрле яктан кычкырдылар.

Аксакал дәвам итте:

— Бу сүз рас булса, мин сезгә тагын бер рас сүз сөйләп бирим: бер заман хан куеп, аннан соң боларны бетереп, урыннарына солтаннар сайлатып, күп азапланганнан соң, урыс патша Сары-Арканың йөрәгенә керергә уйлады. Барлык казакъ җире — урыс йортының уртак малы, дип әйтә салды. Үзенә хезмәт кылган адәмнәрдән мал белән, ялган ант белән алдап биләр, булыслар сайлата башлады. Аңарчы без белмәгән, ишетмәгән адәмнәр — кукаллар, урыс түрәләр безнең җәйләүләрне, зур күлләрне, елгаларны алып, кара чикмәнгә бирә, безне яман корыган чүлләргә куа торган булды. Ул заманнарда Сары-Арканың күп җирендә булдым, мәгәр һәркайда ак сакалым буенча күз яше түктем. Ясаган иямә шулвакыт ант бирдем: кайда мөмкин — шунда кукалны, кара чикмәнне үтерү, канын кою, малын урлап китү миңа бурыч булсын, дидем... Кулымнан күп җан кичердем: урысның күп малын далага качырдым; көннәрнең көнендә атлары югалган өчен бер казакъ йортына килеп, талаш кылып яткан биш кукалны күрдем. Янымда гайрәтле җегетләр бар иде, сәбәбен сорамадым: җавабын үзем бирермен, түбәләгез, каннарын түгегез дошманнарның, дидем!.. Арада сугыш китте, сүз әйтеп авыз йомганчы, кара чикмәннәр быт-чыт булып җиргә сузылып ятты. Арадан берсе, качып, өйдә яшеренгән икән. Җегетләрем аны тоттылар да, кыйнап, анасын югалткан бута кебек акыртып, каршыма

китерделәр. Бу бичара начар киемле, чабаталы, ак сакаллы бер кукал иде. Куругә аягыма егылды, аз-маз казакъча бытылдый икән: «Өемдә биш балам... авырып яткан кимперем бар. Мине кызган!» — диде. «Әй, атаңа нәләт булгыры! Казакъны талыйсың, җәйләвен аласың, инде үз башыңа төшкәч, кызгану кирәк булдымы?» — дидем. Кукал карт сабый балаларча җылады: «Утагасы,— диде,— сүземне тыңла, миңа тидертмә»,— диде. «Әйтәчәгең ни? Сөйлә!» — дидем. Бичараның ак сакалы буенча мөлдер-мөлдер күз яше акты: «Без ни кылыйк,— диде,— туган илебездә кояш җылы, туфрак яхшы, анда алма, йөзем үсә; мәгәр, диде, көн итәргә җиремез булмаганнан, тынычсызлык чыгаргач, безне бу якка куалар. Сезгә килсәк, җәйләвемезне аласыз дип, сез безне каһәрлисез, инде без кая барыйк?» — диде. Яман каты акырып җылый бирде. Күземә яшь килде, янымдагы бүз балаларга: «Картны куя бирегез, китсен, күңелем бозылды»,— дидем. Берәүсе телемне алмады, яңадан түбәли башлады. Карт аягыма егылды, шундый бер яман җылады, йөрәгем парчаланды. Җегеткә: «Тукта!» — дидем. Ачуланып миңа карады, кукалның йөзенә каты бер камчы сызды да, атын тартып, янымнан кача бирде. Шул көннән антымны боздым, кукалның, кара чикмәннең канын коюдан, малын куудан күңелем суынды. Яшел-Сырт өчен алач кычкырып, сугыш ачуга каршы әйтүем менә шуннан соң иде... Акылың булса, башыңа сал: берәү сине кыйнаса, аның камчысы гаепләме, кулымы?

Аксакалның сүзе шау-шу тудырды. Аңлаучы аз булды, арадан берәү чыгып, каты әйтә башлады. Кайберәүләр: «Моның картлыгы җиткән, акылы китеп калган»,— диделәр. Башкалар: «Илнең өлкән агасына мондый сүзне әйтә алган телең корысын!» — диделәр.

XXXII

Моңарчы кабилә, партия талашын онытып, бары бергә кайнашкан казакълар, атка менеп далага чыгу белән, яңадан һәммәсе үз хәлләренә кайттылар. Сүз берләштергән кебек, ничектер һәр ыруг, һәрбер груһ[1] үзләренә аерым укмаштылар. Зиярат ун чакрымнар бар иде. Бөтен юл буе — ат өстендә корылган бик күп аерым киңәш, яшерен план мәҗлесләренә әйләнде.

[1] *Груһ* — төркем.

Сарсымбай белән Арысланбай ат менеп килгәннәр иде; бай һәрвакыт үзелергә торган төсле күренгән кодасы Сарыбайны үзенә ияртте. Болар киң далада юлсыз-нисез барган атлылар, арбалылар арасыннан Биремҗан аксакалны таптылар. Ул ике айгыр җигүле тарантаста бара, янына теге акын Тылсымҗан утырган иде. Җитеп, хәл сорашуга, акын шагыйрь үзенең җәберләнүен сөйләде:

— Өлкән атабыз Бирем әкә миңа шелтә кылды...— диде.

Карт аның сүзен бүлде:

— Мин ни сөйләгәнемне беләм. Сакалыңа чал кереп бара ятыр. Акылга утырырга вакыт; аксөякне мактап, гидайны[1] хурлап гомер итәсең! Сары-Арканың өлкән акыны Абай белән Тургайбай акыннан гыйбрәт алсаң булмасмы дип әйтәм! — диде.

Акын булгач, партия турында сүз ача алмадылар. Чөнки ул найманнар көен җырлаучы адәм иде. Картны калдырып, өчәве алга чаптылар.

Болардан бер якта дүрт-биш казакъ тагы шулай ат өстендә киңәш кылып, дала буйлап чабалар иде. Урталарында Якуп күренде. Яңгырбай белән Азымбай карт та шулар янында иде.

Сарсымбай, атын каулый биреп, шул груһка ишарә кылды:

— Арысланбай, күрдеңме Азым әкәңне? — диде.

Җегет кулын селекте:

— Йомшак адәм гуй! Тун белән чапан аның күңелен ризалаткандыр!

Аңарчы тик барган Сарыбай телгә килде:

— Ул исәр картка мин тун белән чапан гына түгел, иярле ат белән буталы төя биргән булыр идем!

Сарсымбай тирән бер мәгънә белән моңа каршы әйтте:

— Иярле атлар белән буталы төяләр бирә торган адәмнәребез Азымбайдан башка да күп булса кирәк,— диде.

Сахра тутырып кабергә чапкан җәмәгать эчендә төрле ыруглар булса да, шул юлдагы сөйләшү, бергә баруда да төп ике агым сизелә иде. Танабуга, кызылкорт, кара-айгырлар бергәрәк кайнаша, болар ничектер сарманнарга тартылалар иде; дүрткара, алтын ыруглары симез найманнар тирәсендәрәк чуалалар иде.

Күрер күзгә беренче груһның адәме күбрәк күренә иде.

---

[1] *Гидай* — ярлы, хәерче.

Сарсымбай эченнән уйлап барды да юлдашларына ишеттереп әйтә куйды:

— Алар аксөякләре белән мактанса, без күплегебез белән җиңәрбез, күрәсезме алачны? — диде.

Алда, яшел сахра уртасында, зур күл буенча тәбәнәк, киң ак өйләр күренде.

Бу борын Бирем әкәнең җәйләве булып, ун ел элгәре генә килеп, хохоллар утырганнар, хәзер зур авыл булганнар иде инде... Һаулап этләр өреп чыкты, калын аяклы, ялангач башлы марҗалар, өйләреннән чыгып, кызык итеп, бу нинди җау дигәндәй карап калдылар. Казакълар ат-арбада чаптырып үтеп киттеләр.

Шул авылдан ярым чакрым ары каберлек иде.

Чите җимерек, эреле-ваклы, төрле язулы, иске, яңа кабер ташлары ерактан ук, безне читләр арасында ташладыгыз дигән кебек, хәсрәтле хәрабә хәлендә күренделәр.

Каберстанның бер ягында өелгән халык, тукталган арбалар, бәйләүле иярле атлар торалар; анда Байтүрәне ләхеткә төшереп күмәләр.

Зиратның өсте колакчыннар, бүрекләр белән чуп-чуар төстә: һәркем мулласын ияртеп дә үзенең якын үлекләренең каберләрендә, береннән икенчесенә күчеп, Коръән укытып йөри.

Кемдер:

— Тәмам! — дип кычкырды.

Төрле җиргә чәчелгән җәмәгать ашыгып-ашыгып җыелдылар.

Уртада Байтүрәнең әле яңа гына өелгән кечкенә тау кебек биек кабер туфрагы, аның дүрт почмагында дүрт мулла, кабыргаларында, баш, аяк очларында тагы икешәр-өчәр динче утыра.

Халык һәммәсе җыелып бетүгә, казакъ бае Ис Әхмәт калын, киберле тавыш белән:

— Молдакәм, укы тәбарәк,— дип кычкырды.

Зәки Гайфи, тамак кырып, укырга авызын гына ачкан иде, Бүребай мулласы Сәйфулла, беренчелекне бирмәс өчен, көчле, матур тавыш белән:

— Әгузе билләһи минәшшәйтанирраҗим. Бисмилләһиррәхманиррәхим,— дип сузып та җибәрде. Зәки Гайфине туктарга мәҗбүр кыйлып, аз вакыт эчендә тәбарәкне ярып укып та

чыкты. Бу — бик тиз, кызу, ләкин музыкалы яңгыратып, Шәйморза мәкаме[1] белән укучы иде.

Казакълар, мактап:

— Ай, ярыктык, молдакәм! Кандай тиз агыза гуй,—диештеләр.

Дүрт почмактагы, яндагы муллалар да кыска-кыска мәкъризләр[2] укыдылар. Тагы бер мулла, баеның әйтүе белән, «Ясин»ны башлаган иде, «минәлмөкәррәмин»гә җиткәч яңлышты да: «сөбханә раббикә раббил гыйззәти гамма ясыйфун»ны әйтеп тәмам итте.

Моның белән мулла үз бае алдында гына түгел, башкалар алдында да үзенең базарын бетерде, начарга мисал булып йөрергә калды. Күп вакытлар көлеп сөйләргә телләргә керде.

Динчеләргә унар тиен садака бирделәр. Дога кылынды.

Җиназа, дәфен[3], садака шуның белән бетте. Җәмәгать яңадан атларга менде. Тагы камчылар уйнады. Тагы ыруглар, кабиләләр, партияләр, груһ-груһ киңәшеп, дала буенча киттеләр. Хохолларның балчыктан ясалган акбурлы өйләрен үтеп, тагын этләрен өрдереп, инде ит, кымыз уе белән, яңадан мәрхүмнең җәйләвенә — Якты-Күлгә шаулашып кайттылар.

XXXIII

Болытлар таралды, күк йөзе ачылды. Аяз, матур көн, күңелләрне иркәләп, яктылык белән елмайды. Яңгырдан соң бөтенләй кибеп җитмәгән хәтфәдәй яшел, киң, тигез сахра, ерактан асыл зөбәрҗәт диңгезе кебек җемелдәп, кояш нурында уйный башлады. Киезгә, тунга уралып, тирмә эчендә бөрешеп утырган балалар шатлана-шатлана далага чәчелделәр. Буз җегетләр, сылу кызлар, ат иярләп, юк йомышны бар итеп, җәйләүдән җәйләүгә чаптылар. Озак яңгыр, юеш салкын җил астында төсләре качкан матур колыннар, ду килеп, тавыш белән кешнәшеп уйнарга тотындылар. Якты-Күл әйтерсең көмеш

---

[1] *...Шәйморза мәкаме белән...* — Татарстандагы элекке атаклы Шәйморза (хәзерге Буа районында) мәдрәсәсе дамеллалары Коръәнне үзләренчәрәк көйгә салып (үзгә мәкам белән) укыганнар. Бу мәдрәсәдән чыккан шәкертләрнең Коръән укуы традицион укудан аерылып торган.

[2] *Мәкърәә* — Коръәннән өзек.

[3] *Дәфен* — җирләү.

диңгезенә әверелде, шулай матур, тыныч, саф нур белән ялтырап китте.

Зияраттан кайткан халыкның да күңеле берьюлы күтәрелде, иртәнге, көндезге авыр һава, кара болыт, моңа кушылган мәет-җиназа, кабер басынкылыклары таралды.

Бу җәйләүдәге унбиш тирмәнең унысы төрле фәкыйрь казакъларныкы булып, уртадагы зур, яңа ак киез өйләр Байтүрә белән Якупныкы иде. Халык, һәркем үз дәрәҗәсенә карап, шул биш тирмәгә тулдылар. Боларга сыймаганнар өчен далада җиргә киезләр, паласлар җәелде, ачык көн, якты кояш астында утызар-кырыгар кешелек табыннар ясалды.

Гадәт буенча, башта Коръән укылды, динчеләргә садака бирелде. Аннан соң инде әйтерсең Байтүрә, җиназа, кабер бөтенләй хәтерләреннән чыкты, мәҗлесләр, нindидер уенкөлке җыелышлары, үткен сүзләр, тапкыр җаваплар көрәшенә әйләнде. Байның үз кымызы да хисапсыз иде. Мәрхүмнең якыннары, кардәш-ыруглары да һәммәсе турсыклар, сабалар белән килгәннәр иде. Эчүнең исәбе-саны булмады, кымыз күбрәк китерелгән саен, башлар җиңеләя, күзләрдә ут уйный, телләр чәчәнләшә бара иде.

Байның үзе торган өлкән өйгә илнең зурлары: кабилә башлыклары, аксакаллары, биләре, байлары утырдылар. Иң түрдә Биремҗан аксакал, аның бер ягында Якуп, Яңгырбай, икенче ягында Сарсымбай, аның кодасы Сарыбай, аларга тоташып, Карлыгачның тамыры Арысланбай белән кияве Калтай, аннан түбәнгә таба шулай һәркем дәрәҗәсе буенча урнашканнар иде. Азым әкә, мәрхүмнең чапанын киеп, көлкерәк кыяфәттә, бу мәҗлескә хезмәт кылучы булып, бераз кызарып, уен әйтеп йөрүче иде.

Бирем әкә үткән заманнарның хәлләрен сөйләде. Әбелхәер ханны каһәрләде. Яман тылмачлык, илчелек кылды дип, татар Тәфкилевне шелтәләде. Ерак киная белән китереп, бу җирдә дә үзенең Хәерләре, Тәфкилләре булмады түгел дип, найманнарның хан, солтан булып яшәгән, йортны ак патшага кол итүдә булышлык иткән бабаларына да күләгә ташлады. Боларга каршы баш күтәргән казакъ баһадирларына, ерак илдәге Көтибар исемле каһарманга озак тукталды. Аның бу сүзләре Байтүрә-Якуп яклылар өчен агу, Сарсымбайлар өчен бер бәйрәм иде.

Яңгырбай белән Арысланбай ярым көлкеле, ләкин агулы сүз белән чәнчешеп тә алдылар.

Ләкин кымыз эчеп кәеф күтәрелгәнгә, сүз болардан уенкөлкегә тартылса, һәммәсе дә шат булачаклар иде. Азымбай моңа бер чара таба алудан гаҗиз иде.

Мәрхүмнең каберендә озаклап утырып, елап калган акынның кайтып ишектән керүе бар кеше өчен дә бер җиңеллек тудырган кебек булды. Азым әкә аны култыклап алды, бераз кузгалыштылар, шагыйрьгә уртада урын бирелде. Түрдә кирәгәдә бер укалы бүрек белән бер яшел чапан асылып тора иде. Якуп, урыныннан кузгалмыйча ук:

— Азым әкә, шуларны акынга кидерсәңче, агамның әйткән сүзе шулай иде! — диде.

Мәҗлестә бер яңалык булып алды. Азымбай карт йөгереп барды, уйнап-көлеп бүләкләрне алды да киендерде — мәҗлестә гүя күзне уйнатырлык күренеш Азым әкә белән Тылсымҗан иде.

Акын:

— Биргәнеңә шөкер,— дип, ярым-йорты бит сыйпады, билендәге думбрасына кул сузды:— Байтүрәбез бер иде... Аны югалтудан күңелем яраланып калды... Думбрам да бүген, ак таң беленеп кайгылы кара үлем хәбәре йөрәгемне яралаганнан бирле, телдән тукталды, өлкәннәрнең рөхсәте булса, аның бер моңлык әйтүгә исәбе юк түгел иде,— диде дә, җавап көтмичә үк, үзенең гомерлек юлдашын моңлатып, халык җырларыннан берен көйләп җибәрде:

Ат җаксысын сорасаң,
Ир җаксысын күрерсең,
Тун җаксысын киерсең,
Андиҗан менән Куканда;
Кырыйм менән Казанда,
Хива менән Бохарда.

— Борынгылар шулай дигәннәр, мәгәр, безнең бу заманда ирнең яхшылары Сары-Арканың үз эчендә дә юк имәс,— дип, мәҗлеснең, илнең зурларын берәм-берәм ярым көй, ярым кара сүз белән мактап китте:

— Арабызда бер чал бар, яше өлкән, акылы югары: маңлай күзе күрмәгән белән, ак күңеле казакъ йортының каты кайгысы өчен ялкынланып янып тора,— дип, башта Биремҗан аксакалны олуглады.

Аннан соң:

— Нәселе Чингизгә җитә, каны ханнардан, солтаннардан килә, яхшы атаның бу баласы— хәзерге көн ил агасы,— дип, Якупка тукталды.

Әйтәчәк фикерләрен, сүзләрен бераз эзләгән кебек, көйне озын-озын сузып, бераз уйланды да, Арысланбайга карап:

— Атаңның өлкәнлеге даланы каплады, үзеңнең яшең аз булса да, маңлаеңда акыл нуры балкый, йөрәгеңдә азаматлар куәте бар,— дип, озак җырлады.

Думбраны, җырны ишетеп, башка тирмәләрдән халык монда агылды, сыярга һич җай юк иде; тирмәнең киезләрен күтәрделәр, өйнең бөтен тирә-ягы урамаллы хатыннар, колакчынлы казакълар белән капланды.

Акын, гүя боларның һәммәсеннән хәбәрсез кебек, кулларын уйнатып, башын диваналарча чайкап дәвам итте:

— Сабырың күп, дәүләтең мул, сөягең ак булмаган белән, ил өчен гайрәтең зур: лачыннар арасында бөркет бул,— дип, Сарсымбайны мактады.

— Дошман күрсәң, соңкардай ашкынасың, алач дигән тавыш булса, ук-җәядәй атыласың,— дип, Яңгырбайга берничә сүз әйтеп, ахырдан, көен дә, тавышын да ярым көлкегә әйләндереп, Азымбайга карады:

— Дәүләтем юк, бәхетем ким дип зарлык кылма, кыямәтнең оҗмахында тәхетең бар,— диде.

Бу соңгысы халыкның кәефенә бигрәк ошап калды. Өйдәге һәм тыштагы җәмәгать, көлеп:

— Ай ярыктык, Тылсымҗан! Ясаган ияң чәчәнлекне кызганмаган үзеңнән! — дип шаулаштылар.

Азым карт, бераз рәнҗегән тавыш белән:

— Акыным, ялкыным, ау! Иртә-кич Тәңрегә: «Мал да бирче, бак та бирче!» — дип моңлык кылдым, сүземне алмады, биргән малын кышның яман җоты белән һәлак кылды,— диде.

Азымбай яше зур, сакалы ак булса да, байлыгы юк, кабилә эчендә дәрәҗәсе кечкенә, шуңа күрә аның белән бераз җүләрләрчә шаяралар иде.

Сарыбай бераз кинаяле мәгънә белән әйтә куйды:

— Бай үлде, сиңа тун белән чапан калды, күңелең һаман канәгать түгелме? — диде.

Бу бик тупас тоелды. Яңгырбай, үткен усал йөзенә тәхкыйрь[1] төсен чыгарып, Сарыбайның уңайсыз сүзенә:

---

[1] *Тәхкыйрь* — мыскыл итү, хурлау.

— Мондый чәчәнлекне начар биядән туган кара-айгырлар гына әйтә белсә кирәк,— диде. Бу кара-айгыр кабиләсенең түбән дәрәҗәсенә ишарә иде.

Сүзләр кабынды. Кымызның кәефе мигә йөгерде, кара-айгырларның берсе, арттан торып:

— Башкалар ай сөйләсә да үпкәм юк, мәгәр Яңгырбай үзенең төрекмәннән урланган дүрткарасы белән мактана башласа, казакъ йорты көлми ничек чыдый?! — дип чәнечте.

Бу инде бөтенләй каты әйтү иде. Чөнки хәзерге көндә аксөяк саналган дүрткара кабиләсе хакында чыннан да шундый бер әкият бар иде. Яңгырбай өчен бу һәрвакыт җан әрнеткеч бер кара тап иде. Ул сабырын югалтты, аягүрә басып, камчысын биленнән ала куйды.

Сүз талаш-кычкырыш чигеннән ашты. Башта кара-айгырлар белән дүрткара кабиләләре кыздылар, боларга сарманнар, кызылкортлар катнашты.

Азымбай, кызып, каны кайнап, үзенчә зур сүз әйтергә теләде:

— Башка кабиләләр үзара талаш кылганда да, һәммәдән өстен булган симез найман ыругсы барлыгын оныттыгызмы? — диде.

Бу зур хата булып чыкты. Аңарчы тик утырган танабугалар кузгалды. Чөнки найманга мәңгелек дошманнар иде. Азым әкәнең сүзен бетертмәстән, берәү кычкырды:

— Найманнарның исеме симез булса да, тоткан юллары тигез имәс! — диде.

Якуп та катнашты; ул, өлкән адәм сыйфаты белән:

— Яманлык юк димәм, мәгәр найманның кылган яхшылыкларына кем күз йомар?! — диде.

Бу тагы утка май салу булды. Еллар буенча кабилә, ыруг пәрдәсе эченә өртелеп, җир-су өчен, җәйләү өчен, ил өстендә баш булу өчен дәвам итеп тә, җиназа сәбәбеннән тышкы ягы капланган дошманлыклар һәммәсе бәреп өскә чыкты. Каннар кызды, күзләрдә ут уйный башлады. Камчылар кулга киелде. Берәүнең найманнар турында:

— Илгә яхшылыктан башка эшләре булмады,—дигәненә каршы, аңарчы сабыр торган Арысланбай да чыдамады, камчысын кизәнә биреп:

— Атаңа нәләт булгыры!.. Казакъны җәйләвеннән куган, безне җир аударган кем иде? Сез найманнар түгелме?! — дип кычкырды.

Моңа каршы, күзен кан басып, Яңгырбай килде. Алач кычкырып, сугыш китүе бик якын иде, мәгәр сукыр аксакал Биремҗан тыеп калды: ул урыныннан кузгалды, кәвешен киде дә аягүрә басты.

— Талаш өчен башка урын табарбыз, балалар,— дип, тирмәдән далага чыкты.

Моны һәммәсе, аксакал кайтырга, таралырга куша, дип төшенделәр.

Җәйләү шау килде, арбалар кузгалды, атларның иярләре тартылды, казакълар:

— Атаңа нәләт!.. Җиде бабаңның каберен... фәлән кылыйм! — дип сүгенеп, кычкырышып, атларын менделәр дә найман белән дүрткарадан башкалары һәммәсе, зур сугышка ташланган кебек, Якты-Күл җәйләвеннән киң даланың төрле ягына чәчелделәр.

Якуп хәлне аңлады. Бу — илдә өстенлекнең кемнәр кулында булуы өчен ачык сугышның башлануы иде. Ул агасы, Байтүрәнең җиназасын башка төрле файдаланмакчы иде, ләкин киресе килеп чыкты.

Якты-Күл җәйләвеннән таралып, сахра тутырып, иярле ат өстендә төрле якка чыккан казакълар аңа теге дүрт кабиләнең: «Инде моннан соң сезнең ыругны эш башыннан куабыз, булыслыкны, билекне сездән алабыз. Найманның елгасы кипте, тавы җимерелде, хәзер яңа җәйләү эзлибез!» — дигән кинаяле сүзе булып тоелды.

Һәм ул яңлышмады. Төзәтү-килештерү өмете беткән, инде мал түгеп, ат арытып, көн-төн көрәшүдән башка чара калмады. Якты-Күлдән каһәрләп, сүгенеп, шаулашып, ат өстендә таралучылар да моны шулай аңладылар: шул ачу белән тешләрен кысып, камчыларын селтәп чаптылар. Моңарчы аста, каядыр яшеренебрәк янган көрәш уты өскә бәреп чыкты, һәр ике як, бил баглап, кан кыздырып, шуңа ташландылар,

XXXIV

Җиназадан талашып таралган җәмәгать, дала буенча ат өстендә җилдереп барган хәлдә, элек һәр ыруг үзара, аннан соң ыруг башлыклары бергә җыелышып киңәштеләр.

Сарсымбай иртә таңнан яңа җәйләүгә — Кызыл-Комга күчәчәк булганга, үзара аңлашу мәҗлесен җомга көнгә кичектерделәр.

Бергә укмашып бераз барганнан соң, шул уй белән исәнләшеп, һәр груһ үз юлына таба китте.

Сарсымбай, Арысланбай, Биремҗан аксакал, чәчле җегет, Кәрим карт бергәләшеп Алтын-Күлгә кайтып җиткәндә, кояш батып бара, колыннар бәйләүдән ычкындырылганнар, куй, сыер шау килеп җәйләүдә кайнаша, ләкин иртә белән тезелеп утырып калган тирмәләрнең берсе дә юк — һәммәсе, сүтелеп, арбаларга төялгәннәр, тик байның ак өе ялгызы калган иде. Кызлар, киленчәкләр, бүз балалар уен-көлке, шау-шу белән шул арбалар тирәсендә нидер бәйләп, төргәк-төргәк киезләрне, җон тутырылган капчыкларны рәтләп азапланалар иде. Элекке урынында казан тулы ит пешә, самавыр быжылдап утыра иде.

Ялчы, каршы килеп, атларны алды. Ак өйдән Карлыгач белән байбичә чыкты. Арысланбайның, авыл күчүне белә торып яңадан килүе Алтынчәчне бераз гаҗәпсендерде, кызы белән булачак фаҗигане хәтеренә китереп, күңелен бозды, ләкин тышка чыгармады:

— Сарсымбай җәйләве өлкән атаны күптән көтә иде,— дип, Биремҗан аксакалны каршылады да, кунак җегеткә карап:

— Кабернең ташын нык бастырган булсагыз ярый, казакъның бер сүзе бар: яман адәм яңадан терелә икән,—диде.

Арысланбай, Карлыгачка мәгънәле елмаеп, байбичәгә җиназаны сөйләп китте:

— Ләхетне сары балчык белән капладык. Найман ыругсының башына җил-давыл күтәрдек,— диде.

Һәрбер шау-шулы хәлләрне ярата торган Карлыгач-Сылу үзе шунда булмавына эченнән үкенде, җилкәсенә төшеп, тулкынланып торган зур кара чәчләрен рәтли биреп, җегеттән вакыйганы хикәя кылдырды. Ләкин бу, ничектер сүз уңае белән, үз хәлләренә күчте. Бер минут аулак вакытны табып, җегет әйтә салды:

— Аксакал белән азрак киңәштем... Ул риза булырга охшамый, бүген бер форсат табып тагын әйтәчәкмен,— диде.

Кызның матур, кара туткыллы йөзенә тынычсызлык чыкты, күзләре берничә минут, бөтенләй эчке уйга туктаган кебек, бер җиргә каттылар. Озын керфекләре салындылар.

— Ай-бай, Кодаем, ау!..— дип, бер көрсенде дә җегетнең колагына якын ук килеп: — Караңгы төн белән иярле аттан башка безгә һичбер кем ярдәм кылмаса кирәк,— диде.

Җегетнең күз алды караңгыланып китте: бер яктан найманнар белән талашу бара; икенче яктан бу көрәштә иң нык

таяныч, юлбашчы булган Сарсымбай һәм Калтай атасы Сарыбайлар белән ара бозылачак. Бу ике ут эчендә ул нинди юл тотарга тиеш?

Ләкин бу — минутлык шөбһә иде. Кызның хәсрәт катнаш мәхәббәт белән ялкынланган бер карашы аны юк итте. Кискен тавыш белән:

— Син йөрәгеңне нык тот, кара-айгырлар кылычы алдында безнең башлар иелмәс! — диде.

Тукал ак өйгә өлкән табак тутырып итне алып керде. Җәйләүдәге һәммә халык шунда йөгерде.

Итне ашап, кымызны эчеп чыкканда, төн килгән, киң дала тыныч, йомшак, рәхәт караңгылык эченә баткан, маллар ятканнар, тик сөякләрне көтеп, этләр генә койрык селкеп, һәр очраганга иркәләнеп йөриләр иде.

Байбичә, аксакал, Сарсымбай, Гөлчәчәк ак өйгә яттылар. Карлыгач-Сылу:

— Чичәм, мин Айбала белән далада йокларга телим,— диде.

Байбичә моңа шөбһә белән карады. Ләкин каршы әйтмәде.

Бу төн җегет белән кыз өчен гомерләрендә беренче килгән иркен, бәхет сәгатьләре булды.

XXXV

Ерактан ак таң беленгәндә җәйләү аяк өстендә иде инде. Хатыннар ашыгып савыт-сабаны җыя, тутыра башладылар. Өлкәннәр торып чыгуга, бик тиз арада ак өйне сүтеп, киезләрен, кирәгәләрен, чаңракларын — һәммәсен аерым бер фурман арбага төяделәр. Чәчле җегет, Кәрим карт үзләренең бөтен әйберләрен кичтән үк җыеп беткәннәр иде. Йокылы күзләрен юмыйча ук байның йортына булышырга килделәр. Ялчы Җолкынбай белән бергә атларны камытлап җиктеләр. Төрле арбаларга тутырылган йөкләрне зур кыл арканнар белән бәйләделәр. Хатыннарга утырырга урыннар ясадылар.

Хуҗа үзе, кунаклары, гаиләсе белән берәр генә чынаяк чәй эчте дә, һәммә эш үз тәртибендә эшләнгәнме икән дип карап чыкты. Кайберен төзәтте, нәзек күчәрле фурманнан өч кисәк әйберне алдырып, боларны ике тәгәрмәчлегә салдырды, эшнең тәмамлыгын күреп:

— Төяләрне китерегез,— диде.

Ак өйнең эчендәге киезләрнең, палас, юрган кебек нәрсәләрнең зур бер өлеше бәйләнгән хәлендә җирдә ята иде. Боларны

арбаларга салмаячаклар иде. Җолкынбай айры өркәчле зур дүрт төяне китерде. Бу хайваннар борын сеңерләрен тишеп бәйләнгән нечкә генә җеп белән һич тә карышмыйча килделәр.

Кәрим карт берсен тартты да:

—Чүк! Чүк! — диде.

Зур төя, бер дә ашыкмый, элек ал аяклары белән тезләнде, аннан соң бөтен гәүдәсе белән чүкте. Байның карамагы астында аның аркасына егерме потка якын йөк салып бәйләделәр.

Карт:

— Һачт! Һачт! — диюгә, акрын, уңай күтәрелеп, сахра корабы аякка басты.

Алтынчәч бабичәнең гомерлек гадәте бар: ул бер җәйләүдән икенче җәйләүгә күчкәндә һәрвакыт төя өстендә барырга ярата иде. Аңардан көлеп тә карадылар, юл ерак, көн эссе булыр, арырсың да, диләр иде, ләкин ул арбага утырмый, төягә атланып, акрын-акрын тирбәлеп баруны сөя иде.

Сарсымбай, өч төяне чүктереп, бәйләп беткәч, хатынына көлеп дәште:

— Минем Алтынчәч сабыем бүген дә төя өстендә тирбәлеп баруны телиме икән?

Хатын, башкаларның елмайганын сизгәнгә, бераз әрненә төште:

— Ак дөлбәрем миннән башка ничек барсын,— диде.

Әлбәттә каршы әйтмәделәр. Кечкенә башлы, матур моңсу күзле, түбәнгә иелгән муенлы, өлкән, юаш ак төяне чүктерделәр; утырырга, ярым ятарга яраклык булган, киң ятак кебек агачлы, палас түшәлгән әйберне өркәчкә ипләп бәйләделәр. Бикә өчен кечкенә күн турсык белән кымыз астылар.

Яшьләргә дигән атлар иярләнеп куелган иде инде.

Инде эш бетте дигәндә, Гөлчәчәк:

— Миңа ат юк, менеп барасым килә минем,— дип көйсезләнә башлады. Башкача ризалата алмадылар, ул байбичә янына төягә атланырга, арыса, тукал янына — тарантаска күчәргә булды.

Аксакал өчен байның үзе йөри торган арба иде.

Сахра артыннан кызарып кояш күренде, дала иртәнге алсукызыл нурга чумды. Күңелләрне якты уенчак шатлык алды.

Һәммә нәрсә әзер иде. Сарсымбай, үзенең сөекле юргасына атланып:

— Кәрим әкә, юл башла! — диде.

Карт:

— Ясаган иям, үзеңә тапшырылдык! — дип, атын кузгатты.

Алдан зур фурманнар, ике тәгәрмәчле арбалар, аннан соң аркаларына йөк бәйләнгән төяләр, тарантаслар, байбичә атланган ак дөлбәр, зур кәрван кебек бер-бер артлы тезелеп, тар юл белән төн ягына таба юнәлделәр. (...)

XXXVIII

Хатын-кыз өйне корып йөргәндә, Сарсымбай үзе әле яңа килеп җиткән маллар — бияләр, куйлар, сыерлар арасында иде. Көтүчеләрдән хайваннарның хәлен сораштьт, авыруларын карап, Кәрим картка күрсәтергә, дәвалатырга кушты.

Башкалар уен-көлке белән, ашыгычлык белән өйләр ясаганда, Арысланбай һәм аксакал бер читтәрәк, яшел чирәмгә киез түшәп, мендәр салып, кырын ята биреп, әңгәмә кылдылар. Җегет, үткән көн башлап та өзә алмаган эше турында карт белән озак сөйләште. Ләкин Бирем әкә якын да килмәде.

— Акылың бар, уйларга чамаң бар, ничек итеп, шундый бер ярамаган эшне башыңа керттең син, балам? — дип, каты сүзләр белән озак шелтәләде.

Ак өйне курчак кебек җыештырып, ятакларга җефәк юрганнарны җәеп, чигүле мендәрләрне кабартып тезеп, киемнәрен кирәгәгә элеп, Карлыгач-Сылу шат ачык йөз белән тирмәгә керергә чакыру өчен килгәндә, шелтәнең иң каты минутлары иде.

Кыз җегет белән картның йөзләрен күргәч курка калды.

Бабаның кашлары салынган, ябык, җыерчыклы бите ачудан каралып көйгән, Арысланбай исә, ниндидер бер кискен уй белән тешләрен кысып, зәһәрләнеп торган кебек хәлдә иде. Сылу каушаудан сүзләрен оныта язды:

— Бирем әкә, өй корылды, чичәм сезне ак тирмәгә чакыра,— дип, нидер бытылдады да кырдан, мал яныннан кайтып килгән атасына — Сарсымбайга каршы йөгерде.

Ләкин барып җитә алмады — күрше җәйләүдән ике ир белән бер кимпернең җәяүләп килүе аны туктатты.

Гадәт буенча, яңа күчеп килгәннәргә күрше авыл ит белән, кымыз белән сәлам җибәрә. Бу адәмнәр күлнең икенче башында утырган авылныкылар, кулларында зур табак тулы пешкән ит иде. Яңа җәйләүне котладылар, мал-җанга аманлык, илкөнгә саулык теләделәр.

Ул арада Сарсымбай да кайтып җитте. Һәммәсе бергә, уртадагы өлкән өйгә кереп, иткә, кымызга утырдылар.

Бу вакыт кояш баеп килә иде инде.

Яңа җәйләүдә элекке гади көндәлек тормыш башланды. Бирем әкәне күчү мәшәкате белән яхшы кунак итә алмадык дип үтенеп, кунарга калдырдылар. Җегеткә вакыт иде инде, рәхмәт әйтте, мал-җанга аманлык теләде дә, атына менеп, Яман-Чүл җәйләвенә кайтып китте.

Күрешер алдыннан аксакал аның үзенә генә:

— Акылга утырыр чагың җиткән, балалык кылма! — дип, каты кисеп әйтте.

Карлыгач-Сылу, бик зур кыюлык аркасында, бер-ике минут аулак заман таба алды, җегет аның йөзенә күтәрелеп карамады, кискен, каһәрле тавыш белән актык сүзен сөйләде:

— Кара-айгырлар белән бозылышудан, ике арада талаш чыгудан куркалар. Аксакал безгә каршы: балалык кылма, дип, миңа яман шелтә ясады! Йөрәгең нык булсын, безгә караңгы төн белән канатлы тулпарлардан башка дус та, ярдәмче дә юк! Бер-ике көннән хәбәрем булыр! Әзер тор! — диде.

Кыз авыр, ләкин шөбһәсез бер уйда калды: Калтайга бармаячак, караңгы кичәдә иярле атлар белән тамыр җегетенең килгәнен көтәчәк!

XXXIX

Канлы, кызгылт ут эчендә туган иртәнге кояш даланың туфрагын партия талашлары эчендә каршы алды.

Якуп белән Яңгырбай җиназага җыелган җәмәгатьнең, юк өчен сүз чыгарып, кычкырышып таралуларын яхшы аңладылар. Үзләре белән барачак ыругның, партиянең юлбашчыларын шул көндә үк җыйдылар, киңәш кылып, эшкә тотындылар. Кемгә мал бирергә, билек, авылнайлык вәгъдә кылырга, дошман арасына ничек коткы салырга — һәммәсен уйлаштылар.

Азымбай карт теге вакыттагы гөнаһлы уеннан кайтты, аттан төшмичә, кирәк адәмнәрне күреп, көн-төн чапты. Бер тәүлек эчендә йөз чакрымны урап кайтып, асыл аргамакларны яндырган вакытлары да булды. Сайлау көнендә артык шар алу өчен түгеләчәк алтынның, өләшенәчәк аяклы малның, биреләчәк чапанның, тунның хисабына чик куелмады. Берничә йөз кара, егерме-утызар мең алтын чыга икән, моның алдында, әлбәттә, тукталмаячаклар.

Рөкыя байбичә бу талашның үзәгендә иде. Ул кайчандыр Сарсымбай бикәсе Алтынчәчкә әйткән сүзен яңадан хәтерләде:

«Кирәксә — мал бирәбез, кирәксә — кыз бирәбез, кирәксә — җир аударабыз, мәгәр үз дигәнебезне кылабыз!»

Арада бик куркыныч бер хәл бар иде. Яңгырбайның кызы Гөлфаныс, җиде яшендә чагында ук әйттерелгән адәмен яратмыйча, башка берәү белән тамырлык кылып йөри иде. Бу соңгы бүз бала үзенең сөйгәнен, караңгы төндә дүрт җегет белән килеп, ат өстендә урлап качкан иде. Бу сәбәптән Яңгырбай ыругсы белән кияү йорты арасында зур талаш чыгарга тора, әгәр бу вакыйга була калса, найманнар белән кара-айгырлар партиясеннән җәберләнгән кодалар ыругсы болардан китеп барып, Сарсымбайга кушылачак, йә үзләре бер партия булачак, яисә читтә катнашмый калачак — һәр тәкъдирдә зур зыян киләчәк иде. Бу кодалык Рөкыянең үз диме, үз осталыгы белән ясалганга, ул, ант итеп, көрәшкә катнашты. Азым әкә аркылы кырык җегетне җыйдырды, итнең симезен астырды, кымызны мул куйды, һәммәсенә бүләкләр вәгъдә кылды. Бүз балаларның берничәсе сыйланып өйләренә китсәләр дә, башкалары, байның йөгерекләрен менеп, урлаган җегетнең авылына бардылар, яман сүгенеп, илне мыскыл кылып, кызны кире алып кайттылар. Гөлфанысны урлаган ил байлыкта урта булганга, Рөкыянең артында урыс түрә торганын яхшы белгәнгә, яңадан сугыш башларга батырлык кылмадылар.

Бу вакыйга тирә-якка зур хәйранлык бирде, ярылып китәргә әзер торган кияү кабиләсен тагы ныграк боларга баглады: найманнар белән шаярырга ярамавын күрсәтте.

Сарсымбайлар өчен бу зур бер күңелсезлек булды. Ләкин моңа карамастан алар талашны көчәйтә бирделәр.

Болар Яңгырбай, Якуп кебек аксөяк түгелләр, алар чаклы алтын, мал да тарата алмаслар, кирәк вакытта ярдәм итәргә артта урыс түрә дә юк, шулай булса да Биремҗан аксакал җиңүгә нык ышана иде. Найманнарны халык ак патшаның йомышын үтәүче дип карый, тыштан хөрмәт күрсәтсә дә, эчтән дошманлык саклый, яхшы җәйләүләрнең китүенә, казакъ йорты, тар кабер кебек, һаман кысыла баруына баш сәбәп — шул Байтүрә нәселе дип уйлый, гөнаһсыз җир аударылган, богаулапып, каланың абактыларында яткан казакъларның язмышы өчен шул Байтүрәләрне шелтәли иде. Илнең, йортның күпчелеге шулай карагач, инде акыллы усал Байтүрә морзаның калдыкларына казакъ баласы тавыш бирмәс дип иман китерә иде.

Сарсымбайда үткәргән төндә сүзнең күбе шул турыда булды.

Туктаусыз симез найманнарның яман кара тарихларын, үзе алар белән ничек көрәшкәнен озак-озак хикәя кылды.

Карт, чыннан да, бу фаҗигаләрнең җанлы тарихы иде.

Аның бабалары Кече йөздә Әбелхәер кул астында яшәделәр. Үзенең дәрәҗәсенә канәгатьләнмичә, өч йортның уртак өлкән ханы булу исәбендә йөргән Әбелхәер, калмыклар белән сугышны бәһанә[1] итеп, ак патшага койрык болгый башлагач, Бирем әкәнең ерак бабасы Торсынбай өлкән ханга әйтте: «Лачыннан котылдырам дип, бөркет авызына ташларга телисең, исемең Әбелхәер булса да, эшләгәнең хәер имәс»,— диде. Кабиләсе көчле булганга, хан аңа ашыгып җәза бирә алмады. Ләкин үз юлыннан тукталмады. Тәфкилев килеп, Петербург ягын каера башлагач, Торсын тагын түзмәде. Әбелхәернең кардәше Бүребай белән татар генералының йөзенә бер камчы орды да тулпары белән далага качты, шуннан Кече йөзне бөтенләй ташлап, Урта йөзгә күчте. Кәрван башы Мостафа дигәнгә ялланып, Кызылъяр, Күкчәтау, Сими, Ташкент, Троицк араларында кәрван йөртте. Картая башлагач, шул якларда мал асрап, бер илгә кушылып, җәйләү тотып яшәп калды. Торсынның балалары зур бай да булмадылар, тынычлык та тапмадылар.

Биремҗан балалык, яшьлек чакларын шул әкиятләр эчендә үткәрде.

Җегет булгач, азаматлык белән дан чыгарды. Ир уртасы чагында ул үз ыругсы кызылкортлар арасында гына түгел, башка кабиләләр эчендә дә аләүмәт эшендә ил агасы булып торган иде инде. Сары-Арканың ханнары бетерелде. Алар артыннан диванлык[2] төзелеп, ага солтаннар мәйданга чыгарылды. Бара торгач, болар да югалды: дала авылнайлар, биләр, булыслар кулына калды.

Болар, элекке вакыттагы кебек, аләүмәт эшендә зур хезмәтләр кылганлыгы, җәмәгать файдасына яшәгәнлеге өчен ыругның, кабиләнең ышануы буенча дәрәҗәгә менгән аксакаллар түгел, мәгълүм туфракта утырган халыкның сайлавы буенча гына куелалар иде.

Бу сайлауларда илгә хезмәт иткәнлек түгел, байлык, мал түгүлек беренче рольдә булып китте.

Элеккечә, кан-ыруглык нигезе җимерелеп, мәгълүм туфракның сайлавы мәйдан алгач, бу урыннарга урыс түрәнең ярат-

---

[1] *Бәһанә* — сәбәп, сылтау.

[2] *Диван* — дәүләтнең югары киңәшү оешмасы.

каннары, аның теләгәннәре үтә башлады. Биремҗан аксакалны берничә мәртәбә булыслык, билек урыннарына сайларга теләделәр, ләкин ул якын бармады, казакъ түрәләренең күкрәгендәге дәрәҗә медальләреннән җирәнеп сөйләнде: «Боларны эт муенына таксыннар, үз муенымны алар белән пычратмам»,— дип, мыскыл итеп көлде.

Бирем әкә шулай йөргәндә, борынгы ханнарның, ага солтаннарның балалары заманның барышын сизделәр, көчнең кайдалыгын күреп, бөтенләй икенче юл тоттылар.

Найманнарның берәве бу туфракта, үзе тырышып, мал түгеп, булыс булды. Якыннарын авылнай, би кылды, илнеңйортның эше боларга күчте. Ак патшаның адәмнәре боларны үз итеп кабул итте.

Биремҗан аксакал тагы яңа дошман алдында калды.

Моңарчы тик каһәрләп йөрсә дә, Байтүрә үлгәч, ул инде, үзенең картлыгына, сукырлыгына карамастан, ак сакалын күтәреп, талаш мәйданына чыкты.

Үзе дәрәҗә эзләми, аләүмәтнең файдасын күзәтер дип, Сарсымбайны Байтүрә урынына булыс ясап үткәрергә тели; бусы барып чыкса, яман авылнайларны, ришвәт буенча эш йөрткән биләрне аннан соң берәм-берәм төшерергә, урыннарына юньле, ак күңел адәмнәр куярга уйлый иде. Арысланбайның Карлыгачка кул сузуы кара-айгырлар белән дошманлык тудырачагын яхшы белгәнгә, җегетне шелтәләве шул яктан иде. Сарсымбай өчен бу бик зур терәк иде.

Арысланбайдан соң төн буена сөйләшеп кундылар. Карт теләсә дә, иртә белән Сарсымбай аны тагы җибәрмәде:

— Кодаларым да килә, сезнең белән бергә киңәш итмәсәк, хәлебез яман,— диде.

Ләкин кунаклар да кунаклык өчен килмиләр иде. Алар янына танабугадан илнең бае Ирҗан, кызылкорттан Әхмәт чакырылды.

Болар — найманнан җәберләнгән, яхшы җәйләүләре алынган, юк-бар сәбәп белән зарар күргән, моның өстенә кодалык, һич булмаса, билкодалык кебек җепләр белән сарманнарга бәйланган кабиләләрнең башлыклары — байлары иде.

Сарсымбай булыс булса, башкалары би булып, авылнай булып үтәргә тиешле иде.

Туктының симезләре суелды, кымыз мул куелды, байбичә, кунакларның кадерен белеп, бик сирәк ашлардан булган куырдак, көйгән бөйрәк кебек сыйлар хәзерләтте.

Яңа җәйләүнең саф һавасында майлы ит белән карынны тутырып, кымызны әбдән мас булганчы эчеп, илнең өлкәннәре көн буенча киңәштә үткәрделәр.

XLIII

Кызыл-Комнан Биремҗан аксакалның шелтәсен күтәреп, кичкә каршы Яман-Чүл җәйләвенә кайткач, Арысланбай күп уйланды. Ни эшләргә кирәк? Ул бер җегет кенә түгел, ун гаиләдән җыелган авылның бае — өлкәне дә булып тора. Бу җәйләүдә ыругның яше өлкән, сакалы ак адәмнәре булса да, алар фәкыйрь булганга, бөтен эштә өстенлек тә, җавап та яхшы атаның баласы Арысланга төшә. Бирем әкә каты шелтәләде. Ул турыда киңәш кылырлык башка адәм юк. Бу эш сәбәбеннән бер-бер кыенлык чыгып, бөтен танабугаларның өстенә җәфа килмәсме? Бу уйлар ике көн аның башын ваттылар. Өченче көн кичкә каршы куй көтүеннән симез тукты кайтартты. Моның өстенә ялның, казылыкның майлысын салырга кушты. Кымызны мул әзерләтте дә ак тирмәгә үзе ышанган өч казакъ җегетен чакыртты.

— Сез, бүз балалар, әйтегез,— диде,— бер җегет белән бер сылу күп еллар тамыр булып, бер-беренә күңел куеп йөрсәләр, кызның әкә-чичәсе, моңа карамастан, аны яшь ярымлык сабый чагында әйттергән яман бер адәмгә бирергә теләсәләр, яхшы сүз, акыллы киңәш үтмәсә,— шулвакыт сез ни кылыр идегез? — диде.

Арада үткен, зирәк, шаян Тургайбай бар иде. Колакчынын арткарак каерды, билендәге камчысын иплəп куйды да, Арысланга карап, көлә биреп:

— Киная сүзне аңламый торган булдым, син ачык әйт: бүген безне чакыруың Кызыл-Ком җәйләвеннән Сарсымбай кызы Карлыгач-Сылуны урлап алып килү өченме? Үзең әйтмәсәң дә, чамаңны дүрт ел буенча белеп киләбез гуй! — диде.

Хуҗа һаман шаяртты:

— Әгәр шулай булса, сезне шуның өчен чакыртсам, әйтәчәгегез нидер?

Кунакларның яшьрәге шат, уен тавышы белән җавап кайтарды:

— Әйтәчәгебез ни булсын? Ат уйнатып Кызыл-Комга барып кайтудан курка торган җегетләр дип беләсеңме безне?

Кунак җегетләр, бик аз гына да каршы әйтмәстән, һәммәсе риза булдылар. Караңгы төшүгә Арысланбайның иң яхшы атларыннан биш айгыр иярләнеп куелган иде инде.

Итне ашап, кымызны эчеп, папиросны тартып, бераз әңгәмә кылдылар да Сарсымбай җәйләвенә карап дүрт җегет, ат әйдәп, бер буш аргамакны ияртеп, якты ай астында киң дала буенча киттеләр.

XLIV

Кызга алдан хәбәр җибәрелгән иде. Айбала киленчәк күлнең төньягына карый торырга, әгәр камышка атлар тукталса, барып белешергә дә Карлыгач-Сылуга әйтергә тиешле иде. Ләкин бүген кичкә каршы бер-бер артлы мәшәкатьләр чыга торды. (...)

Хатын чарасыз иде. Алтынчәчкә булышып, әйбер хәзерләп йөрде. Тик тукал казаннан ит бушатып, йортның өлкәннәре кул юып табынга утыргач кына, Айбала киленчәк башка мәшәкатьләрдән котыла алды. Авылның иң читендәге фәкыйрь тирмәсенә кайтып, аз гына утырган иде, аның үткен колагы төн ягыннан берничә атның дөп-дөп басып килгәнен ишетте. Җиргә ята биреп тыңлады, тавыш тукталды.

Хатын серне аңлады, күл буенча камышка таба тизләп йөгерде: анда бераз яшеренә төшеп, колакларын кайчы кебек торгызган иярле атлар янында, берничә колакчын торганы күренә иде.

Арысланбай, кулындагы камчысын уйнатып, каршы килде:

— Алтынчәч байбичә белән Бирем әкәнең яман шелтәсен ишеттек, мәгәр башкача амалымыз юк, без көтәбез,— диде.

Киленчәк, кутан ашасыннан ашыгып килеп, ак өйгә керде.

Ни күрсен, ана белән кыз, акрын гына сөйләшеп, сай табактан майлы итне, казылыкны ашап утыралар. Тыш яктан иң тыныч бер мәҗлес. Сүз белән әйтә алмады, мәгәр кызга бер караш ташлады, шуның белән бөтен эшне аңлатты.

Байбичә, гадәт буенча, киленчәкне ашарга утырырга чакырды. Ләкин Айбаланың йөзендә, каушаган тавышында ни дә булса барлыгы мәгълүм иде. Карлыгач-Сылу, сизенеп, яшерергә теләде, киленчәккә:

— Карагым, әнә торган сөлгене алып бирсәңче! — диде.

Хатын бераз тынычланды, кызга сөлге биреп, үзе табак янына утырды. Кыз яңадан бер-ике капты да, кулын сөртеп, гадәтне бозу булса да, башкаларның беткәнен көтмичә, ком-

ганын алды, башына, өстенә киде дә, ак тирмәгә бәхилләшкәндәй бер күз йөртеп, далага чыкты.

Аның шул чыгуы унсигез ел яшәгән гаиләсеннән бөтенләйгә китүе, күңеле сөймәгән Калтайдан да, ул адәмгә бирү өчен тиздән туй ясап озатырга хәзерләнгән кадерле әкә-чичәсеннән дә качуы — котылуы иде.

XLV

. . . .

Яман-Чүл җәйләве бүген яңа хәбәр белән уянды:

— Арысланбай җегет Сарсымбайның кызы Карлыгач-Сылуны бу төндә урлап алып кайткан!

Моны башта ялчы хатын белде. Ул куркып, хәйран калып, куйчыга сөйләде, аңардан көтүчегә, ялчыга, аннан берничә минут эчендә бөтен авылга таралды. Карлыгач-Сылу, иң гади киленнәр кебек, башына урамал бәйләп, кулына чиләк тотып, Арысланбайның апасы белән кутанга бия саварга чыккач, бу инде бөтенләй бер бәйрәм төсен алды. Кимперләр, өлкән хатыннар, килеп, аркасыннан сөйделәр.

— Яхшы аягың, ак бәхетең белән кил! — дип сәламләделәр.

Җегетләр, читләр, күз салдылар:

— Арысланбай кызның асылын таба белгән,— дип мактадылар.

Куйлар, сыерлар куылып, колыннар бәйләнгәч, җәйләүнең төрле ягыннан картлар килделәр. Боларның телендә сәлам, котлау булса да, йөзләрендә, күзләрендә курку күренә иде. Кыз урлауны күп күргән, күп ишеткән бу өлкән адәмнәр шулай ук моның ахырын да беләләр иде. Яңгырбай кызын урлаучы җегетнең ыругсына, йортына килгән кебек хәлләр боларны бераз хафалый иде.

Ләкин күп белдермәделәр, киленне яраттылар, инде ни күрсәк тә, Сарсымбай ничаклы адәм җибәрсә дә, каршы торып, якларга тиешлеген эчләреннән беркетеп таралдылар.

Бүген бия суелды, кымыз күп эчелде. Карлыгач-Сылуның килен булып төшүен уен-көлке белән, ат чаптыру белән шау-шу кылып үткәрделәр.

Ләкин чын туй алда иде әле.

Яңа кушылган ике яшь, алдагы куркыныч катнаш бәхетле минутлар эчендә, сарманнар белән кара-айгырлардан нинди хәбәр килүен көтеп яши башладылар. Карлыгач үзен богаудан

котылган адәм кебек сизенде, нинди генә талашлар, сугышлар, рәнҗешләр булса да, яңадан Калтайга бармаска ант итә-итә, бу яңа җәйләүдә яшь киленчәк булып калды.

XLVI

Кызның урлану хәбәре, ил кыдырып, кымыз эчеп, кызык эзләп, кыз күзләп кергән бүз балалар, сайлау алды талашы белән җәйләүдән җәйләүгә туктамый чапкан агалар аркылы бөтен далага шул көн эчендә таралып өлгерде.

Дошманнар шатландылар. Яңгырбай белән Якуп, моны ишетү белән, кара-айгырларга адәм җибәрделәр. Кияү җегетенең мондый хурлыкка төшүен күтәреп калу ярамый гуй, дип коткы салдылар. Сарсымбай белән танабуга һәм сарман йортларын талаштырырга ут кузгаттылар. Һәм моңа нык ышаналар иде.

Дуслар тирән хафага төштеләр. Сарсымбай белән байбичә, башларын уып, ачудан кара көйделәр.

Алтынчәч:

— Өлкән атаның баласы дип кунак кылдым, килсә, түремә утырттым, ашымны ашап, йортыма ... китте,— дип, яман тиргәнде.

Калымлыгы урланган Калтай:

— Мин ул атаңа нәләт балага күрсәтим, кара-айгырлар белән алай шаяру буш үтмәс! — дип сүгенеп, кызны Яман-Чүл җәйләвеннән сугыш белән кире алу өчен үз тирәсендәге җегетләрне оештырырга, кымыз белән, ит белән сыйларга, кан кыздырырга, кабилә намусын уятырга тотынды.

Арада иң каты хафаланган адәм Биремҗан әкә булды.

Хәбәр килгәндә ул үз авылының бае Әхмәтнең өлкән тирмәсендә кунаклар белән кымыз эчеп, борынгы әңгәмәләрне сөйләп утыра иде. Ишетүгә, кинәт аягүрә басты. Таягын алды, сабырын югалтты:

— Яхшы атадан туган ул яманга мин әйттем гуй: бала булма, акылыңа утырыр чагың җиткән, дидем... Сүземне алмаган икән, атаңа нәләт! — дип, шундый әрләде, күп еллардан бирле карттан мондый сүзләр чыкканы юк иде.

Аксакалны куркыткан нәрсә ике кабилә арасында талаш башлануы иде. Чөнки моңардан дошманнар файдаланачак, симез найманнар тагы җиңәчәк иде.

Әхмәткә әйтте:

— Атларыңны җиктер, мин хәзер кара-айгырларга китәм,— диде.

Яше сиксәнгә җитеп, күзе сукырайган карттан мондый кискенлекне күреп һәм гаҗәпсенделәр, һәм сокландылар.

Бер сәгать вакыт үтмәде, тарантаска җиккән ак ат караайгырлар ыругсының башлыгы Сарыбайның җәйләвенә, өлкән ак тирмәнең артына килеп тукталды.

Монда таяк тыгылган кырмыска түндәге кебек кайнашалар, талашалар иде. Һәммә сүз кара-айгырларның уналты ел буенча калым түләп килгән кызларын урлаган танабугалардан һәм урлаткан сарманнардан ничек намус кайтару турында иде.

Сарыбай хафалы йөз белән каршы алды. Аптыраган, каушаган рәвештә кунакны сәламләде, өйгә кертеп утыртты да:

— Өлкән ата, безгә ни кылырга киңәш бирәсең? Кара-айгырларның намусларын таптадылар гуй! — диде.

Аксакал юл буенча, бөтен әйтәчәген уйлап, тәсбих кебек тезеп, санап килгән иде.

— Балалар,— диде,— ашыкмагыз, минем килүем дә шуның өчен: кара-айгыр йорты гомер буенча симез найманнар белән талаш кылды, дошманнарыгыз күп, инде тагы яңа бер дошман арттырудан сак булыгыз,— диде.

Халык тирмәгә тулган, ире-хатыны, яше-карты бары да мондалар иде. Арадан бер карт, торып:

— Кыз җегетнеке имәс, бөтен илнеке... Борынгылар, ирдән китсә дә, илдән китмәс, дигәннәр. Безнең кара-айгыр йорты, алач кычкырып, сугыш кылып, үз киленебезне үз йортыбызга кайтарырга әзерләндек,— диде.

Башка картлар да моңа шаулап кушылдылар. Җәберләнгән кияү кечкенә буе, ямьсез карлыккан тавышы белән ниндидер тәртипсез сүзләр сөйләп китте:

— Малым бетсен, йортым таралсын, мәгәр мин ул Карлыгачны кара-айгырга кайтармый туктамам,— диде.

Ләкин бу сүзләр тиешле нәтиҗәне бирмәделәр. Калтайны начар менәзе[1] өчен дә, казакъ йортында булмый торган ят бозыклыклары өчен дә үз иле яратмый иде. Аның атасы Ирҗан түрәлек хыялы белән җенләнүчеләрнең берсе булганга, улын түрәлеккә хәзерләү өчен дип, аз-маз хәзерләтеп, семинариягә биргән иде. Бер елдан соң аннан ниндидер усаллык

[1] *Менәз* — характер.

өчен кудылар. Бер кимпер аны: «Урыс булмады, казакълыгын да югалтты!» — ди, халык та шулайрак карый иде. Кызның урлануына каршы баш күтәрү җегет өчен түгел, ыругның намусы өчен иде.

Аксакал сүзләрен тыңлады да, кабиләнең үз эчендә дә ике төрле уй барлыгын күргәч, ачык кискен сүзләрдә озак вәгазьләде:

— Ул яман җегет үз кылганының обалын[1] табар, мәгәр илнең өлкәннәре акылга салсыннар, озын чәчле бер аял өчен талаш кузгап кан түксәк, дусларыбыз җылар, мәңгелек дошманнарыбыз — ак, симез найманнар бәйрәм итәрләр, безгә рәхмәт әйтерләр, ашыкмагыз, уйлап эшләгез,— диде.

Әгәр Калтай урынында илнең үз итеп йөрәгендә асраган сөекле җегете булса иде, аксакал, бәлки, күп эш чыгара алмаган булыр иде. Әгәр явыз дошман найманнар күз алдында көлеп, теш ыржайтып, талашыгыз, берәм-берәм барыгызны йотарбыз, дип тормасалар, җегет нинди генә кадерсез адәм булмасын, аксакалның сүзе үтмәс, кара-айгырлар, бер мәртәбә кузгалып, киленне бу йортка кайтару өчен бер күтәрелеп караган булырлар иде. Ләкин шул югарыгы сәбәпләр үзләрен күрсәттеләр. Бирем әкә сүзеннән соң кара-айгырның өлкәннәре уйга калдылар.

Күп талаштан соң, җегетнең даулавына карамастан, Биремҗан аксакал илнең канын басты, талашны туктата алды:

— Сарман белән танабугаларның өлкәннәре килеп, кара-айгырга арыз күрсәтәләр, бирелгән калымны барлык туган балалары белән кире кайтаралар, шуңа риза булмасалар, бу йорт үз намусын ат өстендә алач кычкырып, яу кылып алачак!

Шуңа килештеләр. Аксакал Кызыл-Комга китте. Үзе белән кара-айгыр кабиләсенең өлкәннәреннән дүрт казакъны ияртте. Болар ике йортның арасында булган талашны төзәтер өчен илчеләр иде. Барлыгы бергә Сарсымбайга килделәр. Анда бөтен авыл курку эчендә, хафа, кайгы эчендә иде.

XLVII

Ләкин кызылкорт белән кара-айгыр өлкәннәренең бергә килүен күргәч, Сарсымбай эшнең кая барганын тиз аңлады. Байбичә, йөрәге белән әрнесә дә, фаҗиганең кансыз, талашсыз

---

[1] *Обал* — гөнаһ.

бетәчәген сизенде. Бу җәйләүнең өлкән өендә тагын ыругның, илнең өлкәннәре җыелды. Күп каты сүзләр, үпкәләр әйтештеләр. Менә хәзер талашачаклар да сикереп атка менәчәкләр, һәр ике як үз юлына гауга өчен китәчәк дигән куркыныч минутлар булды.

Ләкин Сарсымбайның сабырлыгы җиңде. Күп талашлардан соң кара-айгырлар җәйләвендә, Сарыбайның өлкән өендә булган килешүне монда да кабул кылдылар. Тик Сарсымбайның каты торуы буенча андагыга кечкенә бер кушымта арттырдылар:

— Сарсымбай үзенең кызы Карлыгач-Сылу өчен алган калымнарын бөтен көенчә кире кайтарачак. Мәгәр бу малның, акчаның яртысын Арысланбай кызның атасына түләргә тиеш.

Бу соңгысы бераз гаҗәбрәк булып чыкты. Кайбер картлар моңардан мыскыл итеп көлделәр:

— Юк белән әвәрә кыласыз, безнең атларны җилгә бәйлисез. Кызыңны урлап киткәннән калым сорамак — казакъ йортында булмый торган бер эш... Әгәр танабугалар моңа риза булмасалар, кыйлачагыңыз ни нәрсә? — дип көлделәр.

Тагы талаш, каты ачы сүзләр белән үпкәләш китте. Бирем әкә, җыелганнарның һәммәсенә яман ачуланып, тавышны туктатты:

— Башларына тай типмәгән булса,— диде,—танабугалар моңа күнәрләр! Яхшы сүз колакларына үтмәсә, үзләре белән бергә дүрт ыругның каты камчысына ничек түзәрләр?!

Бу каты сүз иде. Моның астында «әгәр ике йортның киңәшенә буйсынмасалар, аларга каршы дүрт кабиләнең сөңгесе тора» дигән мәгънә бар иде.

Кымыз күп эчелде. Туктының яхшысы асылган, куырдак ясалган иде. Илне канга батырачак бер эштән болай котылуларына шатланып, әңгәмәне суктылар да, дәүләтең мул булсынны әйтеп, илче кунаклар Сарыбай җәйләвенә килешү булганлыкны хәбәр итәргә юнәлделәр. Биремҗан аксакал үз иленә кайтып китте.

Ләкин аның эше бетмәгән иде әле. Авылның бае Әхмәтне, өлкән яшьләрне җыеп сөйләде дә Яман-Чүлдән Арысланбайны чакырырга кушты.

Бүген бу җәйләү куркыныч астында иде. Ике якның берсе, яу булып килеп, авылны басар, кызны яңадан алып китәргә гауга чыгарыр дип көтәләр иде. Һәр хәлгә каршы, ирләр беркая

китмичә, бай йортында ит ашап, кымыз эчеп гомер уздыралар, байтак атларны иярдә тоталар иде. Коргак-Күлдән атчабар күренгәч, бераз тынычландылар. Бай җегет белән берничә картның чакырылуы хәбәре бу тынычлыкны тагы арттырды. Эшнең килешү белән бетәчәгенә өметне зурайтты. Кичә кыз урлап кайткан атларны яңадан иярләттеләр дә ыругның ике өлкәне белән Арысланбай җегет Бирем әкәнең җәйләвенә юл тоттылар.

Аксакал кунакларны яман шелтә белән каршы алды:

— Байлыгыңыз зур түгел, ыругыңыз кечкенә... Үз чамагызны онытып, ахмак арысландай айга сикерәсез... Караайгырларга, сарманнарга каршы гауга чыгарып, бу далада кем белән яшәргә уйладыгыз? — дип озак тиргәде.

Җегетнең кире чигенергә исәбе күренми, мәгәр сүзендә, йөзендә, гадәт буенча, бераз үзен гаепле күргәнлек төсе бар иде:

— Безне чакыртуыгыз ни өчен иде, өлкән ата? — диде.

Карт бераз кыза төште:

— Сине камчылар өчен, картларны киңәш кылу өчен чакырдым! — диде.

Танабуганың арада өлкәне бер сүз әйтте:

— Казакъның менәзен, йоласын Бирем әкә бездән яхшы белә дип ышанабыз, җегет үзенә тиң кызны урласа, ул кире кайтарылмый торган иде!

Кызган каннарга бу бераз ут өстәде, аксакал тагы яман сүкте.

Ләкин кунаклар телләрен тешләделәр, алар, үзләренең шәрәфен саклау белән бергә, гауга чыгармыйча бетерү ягындалар иде.

Карт сөйләп бирде. Килешүнең юлларын аңлатты. Урланган кызга калым сорауны казакъ йортында беренче ишетәбез дип, болар да бераз гаҗәпләнделәр. Биремҗан чал тагы баягы сүзен әйтте:

— Калым түләмәсәгез, кара-айгыр белән сарманның камчысын ашарсыз!

Тагын бераз кызыш-талаш китүе мөмкин иде. Арысланбай эшне җиңел өзде.

— Безгә карындаш булган ике ыругның өлкәннәре биргән киңәшне бозарга амалыбыз юк, мин Сарсымбай йортыннан кара-айгырга кире кайтачак барлык калымның яртысын кызның атасына түләргә ризамын,— диде.

Шуның белән килешү булды. Танабуганың өлкәннәре:

— Безне зур талаштан коткардыгыз,— дип, аксакалга рәхмәт әйттеләр.

Китәр алдыннан җегет Бирем әкә ыругсының һәммәсен үз җәйләвенә кунакка — туйга чакырды.

— Бу өлкән шатлыкны бәйрәм кылып, туй ясап үткәрергә телибез, берсекөнгә безгә рәхим итәсезләр,— диде.

Шул ук көндә танабугаларның өлкәннәреннән ике адәм, яхшы атларны иярләп, яңа көпеләр, яңа колакчыннар киеп, бай белән байбичәгә, тукалга, илнең өлкәннәренә асыл бүләкләр, алтын акчалар алып, Кызыл-Ком җәйләвенә кодалык белән киттеләр.

Шуның белән Карлыгач-Сылу өчен күтәрелгән гауга бер дәрәҗәдә басылырга исәпләде. Тик кияү җегет Калтай гына моңа буйсынмады, агасы Сарыбайга каты бәйләнде:

— Кызны, сугышып, яңадан үз йортыма китерәм. Булмаса, үз намусын үзе саклый белмәгән бу илне ташлап китәм! — дип, тавыш кузгаудан, нәрсәгәдер әзерләнүдән туктамады.

Моның белән ул үз ыругсы каршында кадерен тагын бетерде, аксакалларның, өлкәннәрнең киңәшен тотмаганга, аны үз адәмнәре дә шелтәли башладылар. Моңа каршы ул симез найманнар белән дүрткаралар арасында үзен яклаучылар тапты. Яңгырбай астан ут йөртте: «Уналты еллык калымлыгын тартып алганда да үз баласын яклый белмәгән ыругның намусы кайда икән?» — дип, коткыны туктатмады. Азымбай карт бу эш өчен, җәйләүдән җәйләүгә чабып, күп ат тирләтте. Мәгәр йөри торгач, ул үзе дә, кара-айгырларның осталыгы аркасында, Сарсымбай партиясенең тозагына килеп эләкте.

XLIX

Кояш күренмәде. Иртәдән үк авыр, карасу болытлар даланың өстен каплап алдылар. Җил кузгалды, өзек-өзек каты яңгыр үтте. Дөнья ямьсез, һава юеш, салкын, сахра күңелсез иде.

Бүген сайлау була.

Һаваның начарлыгына карамастан, елгасыз, күлсез тигез яланның уртасында утырган ак кирпеч өйнең бөтен тирә-ягы мәхшәр кебек халык белән тулган иде.

Илнең өлкәннәре, авылнайлары, байлары, биләр, аксакаллары әнә шул тәбәнәк, киң, акбурлы, өч кенә тәрәзәле өйнең

эченә тыгызланып керөп утырганнар, тышта һәр ике якның адәмнәре шулчаклы кан кайнаткан бу талашның ахырын күрергә җыелганнар. Иярле атларның исәбе юк. Ике ат җигүле тарантаслар, дугасыз дышлолар, ике тәгәрмәчле арбалар, бәйләүле төяләр, болар тирәсендә шаулап йөргән көпеле, колакчынлы казакълар, яшьләр, картлар, урамаллы хатыннар нидер көтеп, сабырсызлык белән шаулашалар иде. Бер читтә, үзенең ак дөлбәр төясенә менгән хәлдә, Сарсымбайның бичәсе Алтынчәч күренә. Икенче якта кыйммәтле экипажга кырый ята төшеп утырган данабикә Рөкыя кем беләндер сөйләшеп тора... Яшел тасмалы, сары төймәле кара шинелен киеп, яшел читле фуражкасын бер якка салып, кылычтан, револьвердан, зур мыеклы, кырган сакаллы стражник хохол Крапченко бик зур вәкарь белән тәртип саклап йөри...

Җәмәгатьнең шау-шуы арасында кем җиңәр, кайсы як күп алыр дигән сүз еш ишетелә, ара-тирә талашып та алалар. Ләкин эшнең чамасы Якты-Күл җәйләве файдасына бармаса кирәк. Найманнар белән дүрткаралларның йөзләрендә, сүзләрендә ниндидер бер шөбһә сизелгән кебек. Әмма кызылкорт, кара-айгыр, сарман, танабугалар исә, күкрәкләрен киереп, тавышны күтәреп сөйлиләр. Арада Җылкычы ата Юныс карт та күренә. Ул туктаусыз сөйли, өем-өем торган җәмәгатьнең әле берсенә, әле икенчесенә бара. Бер җирдә Сарсымбайны мактап, Якупны чәнчә, дошманнарны уен сүз белән шаярта:

— Күрмәгәнегезне күрерсез, симез найманнар,— ди.— Ханнар, агай солтаннар баласының яхшы нәсел тулпарын казакъның җай юртагы Байчобар бүген узып киләчәк,— ди.

Аның бу сүзе тиз тарала, кара болыттай капланып, тулкын кебек шаулап торган киң мәйданда авыздан авызга йөри башлый. Каршы як тавышлана, каннар кыза...

Шул вакыт кирпеч өйнең ишеге ачыла, аннан өстенә көпе кигән, башы ялангач, җитү чәчле казакъ җегете йөгереп чыга да, шунда торган атка сикереп менеп, ияргә аягүрә баса, кулын авызына куеп, бөтен мәйданга каты, ачык санаулы тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Казакъ йорты өчен зур сөенеч булды! Илнең теләгәне табылды: Сарсымбай ундүрт шар артык алды!.. Якуп җиңелде!!!

Мәйдан гөж килә. Коточкыч шау-шу күтәрелә. Җәяүлеләр, атлылар, бер-берен таптап, управлениенең тәрәзәсенә, ишегенә тыгызланып капланалар, стражник Крапченко: «Бунт чыгарасыз, безобразие!» — дип, халыкны куарга, тәртип урнашты-

рырга азаплана; арттан килгән тулкын белән аны егып, аяк астына изеп үтәләр. Арбалар, төяләр, тарантаслар урыннарыннан кузгалалар, элэгешэлэр, кучерлар үзара кычкырышып, камчылашып алалар.

Берничә минут үтә, эчтән чал сакаллы, ялтыр погонлы, кылычлы, рәсми киемдә начальник килеп чыга. Аның йөзендә ачу төсе бар, иреннәре дерелдиләр. Яңгырбай белән Якуп аңа нидер әйтәләр, болар да кара көйгәннәр.

Ул арада калын, симез гәүдәле, тоташ муенлы, тар иякле, киң маңгайлы шат, көләч йөзе белән Сарсымбай ишектә күренә. Җылкычы ата белән чәчле җегет шауларга тотыналар, җәмәгатьтән күбе моңа кушыла: кычкырып, көлеп, тавышланып, аның тирәсенә җыелалар. Бөтен мәйдан кузгала, тулкыннар бер-берен аударалар.

Шул шау-шу эчендә иярле атлар, тарантаслар, төяләр далага чәчеләләр, җәйләүләргә тараладар.

L

Кыш уртасы җитте. Киң дала тирән кар астында калды. Симез җылкылар уйнаклап йөргән җәйләүләрдә хәзер инде күз ачкысыз ачы буран белән яман җил ажгыра; ач бүреләр, көннең зәһәр суыгына түзә алмыйча, кич малга баруны исәпләп, шул карлы давыл эчендә караңгы төннәрне көтеп, тешләрен шакырдатып йөриләр.

Казакълар күптән инде, ак тирмәләрне төяп, яшел сахра белән исәнләштеләр, яртылай җир астына кергән җимерек балчык кышлауларына кайттылар. Хәзер алар, тар, пычрак, юеш кабер-зинданнардан якты дөньяга чыгуны хыял кылып яткан адәм кебек, яңадан яз килеп, күл буйлары яшәрүен, тагы бия бәйләп, ат уйнатып, киң далада киез өйләр коруны өмет итеп, тыгыз җир өйләрдә көн кичерәләр. Җитәрлек ризык булмаганга, малның күп гомере яланда, кар астыннан үлән тибеп үтә. Бик артык каты буран көннәрдә генә болар тибенүдән кышлауның тар, тыгыз ышыкларына кайтып сыгыналар.

Кар төшеп, бераз вакыт үткәч, кинәт көннәр җылынды да, бер кичтә яңгыр явып китте. Иртән яңадан каты, аяз суыклар башланды. Бөтен дала өсте, су сибеп катырган кебек, бозланып ялтырады, җир өстендәге үлән юеш кар белән сыланып туңды. Моның белән илгә җот килде, тибеп ашарга мөмкин булмаганга, малның бик күбе һәлак булды... Аңардан котылып бераз

үтүгә, тоташтан берничә көн кар яуды. Яман салкын бураннар уйнарга тотынды, дөньяны күп күргән картлар:

— Бу ел җылкы елы, кышның яман килүе шуннан гуй,— дип, куйның, яшь малның исән чыгуы турында зур өметсезлек эчендә калдылар.

Кышкы челләнең шундый каты буранлы, салкын җилле караңгы төннәренең бере иде.

Даланың кар баскан юлларыннан җәяүләп, зур буйлы, начар киемле бер казакъ җегете Сарсымбай кышлавындагы бер йортның капкасына тукталды, җавап булмады. Тәрәзә шыкылдатты, һаман тавыш чыкмады. Юлчы: «Адәме йоклаган булса, этләре өрергә кирәк иде»,— дип, балчык койма ашасыннан ишегалдына сикерде.

Монда адәм аягы басмаган, сукмак салынмаган тирән кардан башка нәрсә юк иде. Төньягында киң, тәбәнәк түбә, кыексыз балчык азбарлар кар эченнән ауган капкалары белән чак кына күренеп утыралар.

Җегет бераз аптырап калды.

Ул байның җир аударылганын белә, аның җәй көне үк киткәнен дә ишеткән иде. Ләкин бит байбичә Алтынчәч белән тукалны сөрмәделәр, малны алмадылар. Болар кайда булыр?

Юлчы яңадан тыш якка төште дә, кышлау буйлап, як-ягына карана-карана китте. Арада зур тәрәзәле, түбәсе кыеклы, үзе агачтан салынган өй — тик шул Сарсымбайныкы иде. Монда башка өйләрнең барысы да балчыктан эшләнгән яки бөтенләй җирне казып ясалган, бик кечкенә бер-ике карындык тәрәзәле, түбәләре тигез, үзләре кардан чак кына башлары күренеп торган кызганыч землянкалар, җимерек алачыклар иде.

Малга иркенлек өчен, җәй көне бүленеп, сигезәр, унар гаилә бер авыл булып йөрсәләр дә, җәй көне аерым йөргән йортларның байтагының кышлаулары бергә иде. Монда барлыгы утызлап өй бар иде.

Юлчы авыл өстеннән бер мәртәбә күз йөртте дә тәрәзәсеннән кечкенә генә ут яктысы күренгән бер йортка барды. Зур, усал эт аны һаулап каршы алды. Берсе балчык өйгә терәп, берсе аерым салынган тәбәнәк, киң балчык азбарларда атларның ашавы, сыерларның акрын гына күшәве ишетелде. Болар җегеткә җан бирделәр, малның беразы йортта асралганын күрсәттеләр. Аңа, һәрнәрсәдән бигрәк, атларның өйдәлеге кирәк иде. Тыштан кар баса башлаган кечкенә ишекне шакылдатты.

Эчтән тавыш килде.

Керергә куштылармы, юкмы,— аермады, сүз тыңламас кире ишекне мәшәкать белән ачты да, караңгы чоланнан абына-сөртенә, бөгелә-сыгыла, өйгә керде. Анда ярым караңгы, тик учакта пыскып янган тизәк кенә бераз яктырта иде.

Өй икегә бүленгән, ишектән аяк атлауга беренче бүлмәгә керәсең. Аның җир иданендә ашалган пычрак салам, тапталган печән түшәүле. Болар өстендә яңа туган берничә бозау, унлап бәрән ята; болар авыр, төче ис таратканнар. Бу бүлектән үтеп, эчке якка атлыйм дигәндә, бик зур, тәбәнәк мич. Аннан үткәч, түр бүлмәгә чыгасың. Аның бөтен җире диярлек агач сәке белән капланган. Сәкенең өстенә киез җәелгән, стена буена сандыклар, юрганнар, мендәрләр тезелгән. Өйнең стеналары кара-кызгылт балчык белән сыланса да, ахрысы күптәнге эштер, инде буй-буй булып ярылганнар. Стенаның сул ягына берничә агач кадалган, боларда камытлар, йөгәннәр, иярләр элүле тора.

Җегет тышкы ишекне ачып, алдагы бүлмәгә керү белән сәлам бирде.

Түрдә, сәке өстендә, инде ятарга әзерләнгән, сирәк сакаллы, чуар көпеле, аягында читекле, өлкән карт утыра иде. Сәламен алды, кунакка шат булганлык тавышы белән:

— Юл булсын, балам, түрдән уз! — диде.

Мөсафир барып күреште, ни кылып йөргәнен әйтте.

Мич янында, салкын өйне йокы алдыннан азрак җылытыйм дип, ягып, өреп азапланган киленчәк бар иде, җегет аңа:

— Аманмысыз? — диде.

Килен башын күтәрмәде, акрын тавыш белән җавап кайтарды:

— Шөкер!

Бу йорт аксакалныкы, түрдә утырган карт Биремҗан әкә иде.

Җегет, биш айдан бирле качып йөреп, менеп китәргә ат сорау өчен килгән иде. Ләкин моны, әлбәттә, керә-керүгә үк әйтә салырга теләмәде.

Каты суыкта туңып килгән мосафирны шул көенчә йоклатырга мөмкинме? Вакыт соң булса да, килен, коедан су китереп, самавыр куйды, шүрлектән каймак, бавырсак алды, чынаяклар чыгарды.

Тышта, ахрысы, җил-буран көчәядер, бер генә катлы тәрәзәдән, морҗадан аның адаштырган җен баласы кебек елап-елап ыжылдавы өйгә дә ишетелә иде... Шуңа колак салып,

чәйне акрынлап эчеп, кунак белән хуҗа озын-озак әңгәмәгә киттеләр.

Җегетнең беренче сүзе Сарсымбай турында иде.

Карт тирән бер сулады:

— Партия талашы дигән ул пычракка аягымны гомеремдә бер баскан идем, җиңеп тә чыккан идем, мәгәр ахыры яман булып калды,— диде.

Биш ай буенча адәмнән, полициядән яшеренеп, дөньяның хәлен белми йөргән мөсафир җегеткә вакыйгаларны бер-бер санап бирде. Җегет болардан шаша калды.

Хәлләр чыннан да көтелмәгәнчәрәк иде.

Кара-айгырлар, сарман, танабуга, кызылкортлар берләшеп, сайлауда дошманны җиңделәр. Мәгәр моның белән эш бетмәгән иде. Булыслык бие булып сайланган Сарсымбайны урыс түрә начальникның билгеләве кирәк иде. Ак патшага каршы адәмнәр белән күп катнашы бар, шундый сүзләре ишетелә дип, монда тоткарлык чыкты. Ул арада Карлыгач-Сылуның элекке кияве Калтай үзенең иле белән, агасы белән зур талаш куптарды, ахырдан:

— Үз баласының намусын яклый белмәгән кара-айгыр йортында мин гомер итә алмыйм! — дип, малны хөкем белән бүлдереп, үз башына аерылды да авылны ташлады. Яңгырбай моңа килеп катнашты, җегеткә үз нәселеннән бер кыз тапты, туй ясап:

— Кара-айгырлар кадерен белмәгән асыл җегетләр дүрткарада хөрмәт табалар! — дип, дөнья шаулатып, Калтайны үз авылына алды.

Менә шул җегет Сарсымбай белән Арысланбай өстенә зур фетнә кузгатты. Яңгырбай аркылы яхшы бер адвокатны табып, кәгазь бирдерде. Башлыча гаеп шул иде: «Сарсымбай бездә кода заманында зур мәҗлестә әйтте: мин булыслык бие булыр өчен, түрә булыр өчен кызыкканым юк, мәгәр ак патша казакъ даласын талый, җәйләүне кукалга бирә, безне кипкән комга куып, ач үтермәк була, мин менә шуңа каршы тормак өчен сайланам диде»,— дип, әләк сөйләде, түрәгә шымчылык кылды. Моңа: «Без Сарсымбайның ул сүзен ишеттек!» — дип, кырык казакъ ант итте.

Боларга каршы: «Бу антлар барысы да ялган... Ул антчылар Сарсымбай белән фәлән мәҗлестә юклар иде, фәләне базарда, фәләне авыру, фәләне туйда иде»,— дип, бик күп казакълар Сарсымбай ягыннан ант бирделәр.

Бу соңгы антчыларның антлары ялган, алар сарманнан мал алды дип, өченче, дүртенче антлар кушылып, шундый зур шаушу, гауга кузгалды ки, элекке талашлар бары да кечкенә булып калды.

Мәгәр ахырында Калтай аркылы Якуп-Яңгырбай партиясе җиңде. Сарсымбайны булыслык бие кылып начальник беркетмәде, ак патшага каршы далада тынычсызлык тудыралар дип, илнең өлкәннәреннән дүрт адәмне җир аудардылар. Болар эченә Сарсымбай белән Арысланбай да керде. Бердәнбер кандидат Якуп иде, ул мәрхүм абзасы Байтүрә урынына ил агасы — булыслык бие булып эшне кулга алды да дошманнарын изә башлады.

Карлыгач-Сылу әле иренә яңа кушылган иде. Арысланбай сөргенгә җибәрелгәч, яшь киленнең ялгызы бу илдә торырга йөрәге җитмәде, мин синнән калмыйм, диде. Хәлләрне ерактан аңлый торган Алтынчәч байбичә дә, монда ирсез калганда, симез найманнар көн бирмәячәген күрде. Җылкычы ата белән үзе, базар йөреп, малның һәммәсен сатты да, тукалны, Гөлчәчәкне алып, Карлыгач-Сылу белән бергә, ире, кияве артыннан китте.

Бу ике фамилия электән үк далада зур сәүдә йөрткәләгән адәмнәр иде.

— Борынгылар: «Кеше илендә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул»,— дисәләр дә, ни эшлик, анамыз Сары-Арканың киң даласы безге үги кылды! — дип, бөтенләй калага күчтеләр һәм шунда яшәп калдылар.

Сарсымбайның сөрелүеннән берничә көн үткәч, Яңгырбайның яңа дусы Калтайны үтереп, гәүдәсен күлгә ташладылар. Танабуганың бер җегете белән Җолкынбай бу эштә шөбһәгә алындылар. Дүрт казакъ Коръән тотып ант итте:

— Җолкынбай безне бу эшкә катнашырга чакырган иде, риза булмадык,— диделәр.

Танабуга җегете шул көндә кулга алынды, богауланып, калага зинданга озатылды. Җолкынбай исә алты стражник белән приставның үзен тотар өчен килүен сизенде дә берәүнең атын менеп далага чапты, үзен танымаган чит бер җиргә китеп, кукалга яки заводка ялланмакчы иде.

Башкаларның да язмышлары буталып беткән. Азымбай картның сере ачылган. Дошманга сатылуы беленгән. Моңа ачудан Якуп, аны кыйнатып, малларын читкә кудырган. Хәзер ул акылдан шашкан, ди. Кулына думбра тотып, өйдән өйгә

көйләп йөри икән, җырлаганы һаман: «Мал бир дидем, бак бир дидем... бер бирдең — җот алды, тагы бирдең — Якуп алды... Инде мине кая куясың, ясаган иям!» — дигән кебек, мал-бәхет турында гына була, ди.

Симез найманнарга каршы якта хәзер кара-айгырларның башлыгы Сарыбай бик каты талаш алып бара. Якуп-Яңгырбайның барлык дошманнары шуның янына оешалар икән.

Бу вакыйгаларны сөйләп беткәч, карт бөтен сахрада ялгыз калган адәм тавышы белән кайгырып куйды:

— Дөньясыннан күңелем суынды... Тыштан бер аяк тавышы ишетелсә, әҗәлем киләдер, ярыктык, дигән өмет белән көтәм... Мәгәр аннан синең кебек кайгылы бер адәм килеп керә! — диде.

Бердәнбер улының күптән түгел вафаты картны тагы ныграк ватканга охшый:

— Күкнең эшендә ялгышлыклар булса кирәк, минем кебекләрне калдырып, тулы канлы яшь җаннарны алалар,— ди.

Тышта җил туктады, тәрәзәдән күкнең кечкенә бер кисәге күренде — анда болытлар таралган, йолдызлар ялтырыйлар иде. Тимер Казыкның урыны таңның якынаюын күрсәтә иде.

Мөсафирда ашыгырга теләгәнлек сизелде, аңа, кышлаулар уянып, юлда халык йөри башлагангача бераз җир китеп калу тиешле иде. Картка моны әйтеп, үзенең йомышын аңлатты:

— Киң далада үзенә бер урын тапмый каңгырып йөргән бәхетсез бер ятакчы адәм булып калдым... Мәгәр бу дөньяның бер җае әйләнмәсме, миңа да кояш карамасмы дигән өметем юк имәс... Гомер булса, бер яхшылык белән кайтарырмын, син, Бирем әкә, чамаңнан килсә, миңа менеп качарга бер ат бирсәң иде! Башка берәүгә күренергә күңелем ятмый тора,— диде.

Карт хәлне тиз аңлап алды, берсүзсез бирергә булды. Җегеткә җавап кайтару урынына, шунда бер якка сөяләә биреп, ярым йоклап утырган киленчәккә эндәште:

— Колынчагым, сары күнле ияр белән кыска камчыны, бер каеш йөгәнне алып бирсәңче! — диде.

Үзе урыныннан кузгалды, капшанып, киемнәрен тапты, өстенә тире эчле көпесен, ике якка салынган колакчынын киде, аягына киез эчле, озын кунычлы зур итекне тартты да:

— Йөр, балам, юлчының юлда булуы яхшы! — дип, җегеткә җитәкләнә биреп, йортка чыкты.

Буран бөтенләй тукталган, ерак күк йөзендә йолдызлар яналар. Киң даланың ялтыр ак кар диңгезенә каршы салкын

белән елмаялар. Аяз һава үтә суык, аяк астында кар шыгырдап тора.

Хуҗа кулындагы йөгәнне кунакка бирде, якындагы азбарга күрсәтте:

— Шунда дүрт ат булыр, кара яллы колынны тотып ал,— диде.

Кунак күрсәтелгән җиргә кереп китте.

Азбардан җылкыларның куркып бер якка таба кузгалу тавышы ишетелде. Берсе каты пошкырды, ниндидер баганага бәрелде, бераздан җегет белән бер ат килеп чыкты.

Бу — кышкы тибендә бераз ябыгып, җоннары салына төшкән, озынча йомры буйлы, калын ботлы, нечкә гәүдәле, зур кара яллы, кара сыртлы, яра кашкалы, кола төсле бер айгыр иде.

Чит адәмнең җиде төн уртасында кереп тотуы аны бераз борчыган, карак түгелме икән дип шөбһәгә калдырган иде, ләкин хуҗасын күргәч тынычланды. Аркасына ияр салып, аел тартуга да гаҗәпсенмәде: «Тибендә кунган җылкы көтүендә берәр хәл бардыр, яисә кышлауга бүре килгәндер дә шуны куарга чыгалардыр»,— дип уйлады.

Ят кешенең ашыгыч, мәгәр булдыклы кылануы аның бу уйларын тагы көчәйтте.

Күк йөзе болытлардан бөтенләй сафланган иде инде, еракта таң сызыла башлады, ул аксыл нур булып тирә-якка җәелде, аның артыннан кызгылт ут төсенә кереп бара иде.

Җегет үзенең уңган, бу эшкә өйрәнгән куллары белән тиз әзерләнеп бетте. Хуҗа картка ихлас күңелдән рәхмәт әйтте, ике куллап күреште дә атка сикереп менде.

Бирем әкә мөсафирга ак юл теләп калды.

Кола айгыр, төнге кунакны алып, кызыл уттай яна башлаган ерак таңга таба кар ярып юнәлде.

Бу юлчы җегет Сарманнарның ил агасы Сарсымбайда ялчы булып торган Җолкынбай иде.

1923

Һади Такташ
(1901—1931)

ГАЗРАИЛЛӘР

(1914 елгы Европа сугышына каршы)

Тау өстендә утырган ул, уйга баткан;
Канатлары талган килеш җиргә яткан;
Маңгаенда — нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күренеп тора ерак илләр;
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
— Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт,
Монда үлем, монда патша — газраилләр!

Ул фәрештә моннан бик күп еллар элек
Бу йолдызга күктән очып килгән иде.
Төзер өчен мәңге рәхәт — бәхет багын,
Кызыл гөлләр чәчеп, сулар сипкән иде.
Сипкән иде...
Җырлый-җырлый мәхәббәт һәм күк көйләрен,
Җир йолдызын төзеп, җәннәт иткән иде;
Бизәр өчен җәннәтен ул, гөлләр өчен,
Тагын очып кире күккә киткән иде.
Киткән иде...
Күчеп тиз-тиз бер йолдыздан бер йолдызга,
Бик күп еллар матур гөлләр җыеп йөрде...
Кайтса кире җир өстенә: нинди дәһшәт!
Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде.

Котырган ил... Болгый-болгый кулларында
Ялтырата сөңгеләрен, юлларында
Үлгән ирләр өелеп кала, аунап шунда;
Җәһәннәмдәй утлар уйный уңда-сулда.
Хәят иле, матур йолдыз, янып сүнгән;
Тапталып гөл баглары көлгә дүнгән;
Матур кырлар, бәхет-җәннәт урманнары
«Гакылсызлар» йорты булып әверелгән.
— «Кемнәр алар, җәннәтемә кемнәр килгән?
Нинди явыз ерткыч җаннар?
Кайсы илдән?»
Җавап бирми берәү дә... Тик үкереп-үкереп
Туплар оча фәрештәнең баш өстеннән.

Тау өстендә утырган да уйга баткан;
Канатлары талган килеш, җиргә яткан;
Маңгаенда — нурлы йолдыз; күзләренең
Шәүләсеннән офыкларда таңнар аткан.
Таңнар аткан, күренеп тора ерак илләр,
Яшрен генә аңа килеп сөйли җилләр:
— Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт!
Монда үлем! Монда патша — газраилләр...

1916

КҮКТӘН СӨРЕЛГӘННӘР

Таш-тауларны эретердәй шәфкать нуры
Балкый төпсез күзләренең карашында,
Фәрештә ул; сөйгән өчен адәм халкын
Ята шунда дүрт диварның арасында.
Кара болыт чәчкәйләре тәнен япкан;
Озаеп, дулкынланып җиргә яткан;
Ак тәннәре зифа аның: зур күзләре
Тегәлеп бер ноктага уйга баткан.
Тулган айның ак нурлары бары бергә
Җыелып төшкән шәүләсе ак йөзләренә.
Тәрәзәсе ачык аның; күк дөньясы
Онытылып карый серле күзләренә.

Ул да шулай кайчандыр бер күк кызы иде,
Янып торган күкнең шәфкать йолдызы иде,

Түзә алмагач, җир өстендә аккан канга,
Килеп күкнең патшасына башын иде;
Иде дә ул сорады күк алласыннан:
«Бетсен,— диеп,— җирдә коллык, күз-яшь һәм кан!»
Нәрсә диде аңар каршы күк алласы?
— «Хаинә — син! Синең урының — суык зиндан!»
Әйе, ул бер сөрелгән; шунда күптән инде
Онытылган. Сөрелеп ул күктән инде
Газапланыр өчен җиргә, тар зинданга.
Үтә еллар... Хәятыннан бизгән инде...

Чү! Газраил канатларын селкеп алды,
Таратты бар болытларны офыкларга;
Киң күк йөзе шыр ялангач булып калды;
Мәһабәт ул килеп басты биек «дар»га,
Канатының очларыннан каннар тама;
Канга баткан зур күзләре уттай яна.
«Әҗәл җитте бу кызга!» дип, Тәңре хөкмен
Укыды ул галибанә бар дөньяга.
Барып зиндан ишекләрен ачып керде,
Нәрсә күрде?! — Зәһре[1] бетте йөзләрендә,
Иң беренче канатлары хәлсез калып,
Рәхим, шәфкать ишетелде сүзләрендә.
Иң беренче таш йөрәге каннар сыгып,
Күз яшьләрдән битләрендә күренде юл;
Онытты да Тәңре хөкмен, белештерми,
Күк кызының аягына ташланды ул.
Ташланды, ах! Мискинәнең ак йөзләре
Агарды; куркудан йомылды күзләре.
Күп тә үтми газраилнең колагына
Ишетелде күк кызының шул сүзләре:
«Килмә якын зәһәрләнеп өсләремә!
Ерткычлык чыккан синең йөзләреңә!
Канатларың канлы синең, килмә! Куркам;
Кан йөгергән агу, зәһәр күзләреңә.
Кай җирләрдән кан агызып килдең, әйтче,
Нинди шомлы сер сөйләргә минем янга?
Кем син үзең?
Юл кисүче?

---

[1] *Зәһре* — зәһәре.

Иблисме әллә?
Буялган, әйт, канатларың нинди канга?»
«Адәм каны тама канат очларымнан;
Җан алучы фәрештә мин!»

Кинәт нәрсә?
Шәфкать кызы, бер селкенеп, шул минутта ук
Керфекләрен йомды, мәңге күтәрмәскә...
Ак тәннәре кара ташка әверелделәр
Газраилнең каты тимер кулларында.
«Ант бозучы бөек хаин — Газраил!» дип
Уттан сүзләр язылды күк юлларында.

Чү, Газраил ачу белән сикереп торып,
Зур кылычын кара җиргә ташлады ул;
Ташлады да, канлы кулын күккә сузып,
Дәһшәт, ачу белән сөйли башлады ул:
«Оҗмахларың минем өчен булсын харәм;
Кайтмыйм, явыз, хаин Алла, күкләреңә!
Үкенәмен моңа кадәр алданып, күп
Хаксызга адәм каны түккәнемә!
Кимсенәмен, басмыйм аяк моннан ары
Мәлганәтләр[1] тулган фахирле[2] гаршеңә[3]!
Куйма юкка хур кызларың, җәннәтләрең,
Зур сәнгатең белән нәкышләп, каршыма!
Мин беләмен, бар күкләрең, гаршең синең
Энҗеләнгән җирдәге күз-яшь, кан белән!
Хәзер белдем, бар фәрманың, хөкмең синең
Тулган алдау, канлы үлем, ялган белән!
Моңа кадәр алданып күп каннар түктем;
Шуның өчен, белдем, урным күкләр иттең.
Бер минутлык шәфкатемә түзә алмадың;
Бар биргәнең тартып алдың да кимсеттең.
Китәм хәзер канлы үлем кырларына!
Сөйлим хаклык мазлум адәм улларына!
Биреп канлы кызыл байрак кулларына,
Ачам сугыш, салам киртә юлларыңа!

1918

---

[1] *Мәлганәт* — бозыклык.

[2] *Фахирле* — мактаулы.

[3] *Гареш* — дини мифологиядә күкнең иң югары, Алла тәхете урнашкан тугызынчы каты.

АНТЫМ

Кычкырам:
Килегез, әй, адашкан,
Канга баткан мазлум ил халкым!
Түзә алмый канга, вәхшәткә,
Мәхәббәт байрагын алдым.—
(Алып каннан, сәгадәткә
Чыгарырмын эшчеләр халкын!)
Язып куегыз, кирамән
Кятибиннәр[1], бер бөек антым:
— Хакыйкать мин басам; баскан
Эземдә тетриләр таулар!..

Өзелә бер генә кул селтәвемнән
Мәңгелек баулар...
Еланнар! Сезгә юк тормыш,
Куып юлдан, буып сезне,
Ачам юллар сәгадәткә!
Җуям җирдән фәхиш эзне...
Күрәмсез бу байракны: бар мәзлумнең
Яшен җыйган...
Ул байрак күз-яшь белән
Каннан койган...

1920

ЮАНУ

Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны
Еглатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны.
Көн килер, күз яшьләрем тормыш күгендә ялтырар...
Дәртле җырларым моңыннан ил елар...
Әйе, минем көчле рухымнан җир вә күкләр калтырар.

1921

---

[1] *Кирамән кятибин* — дини мифологиядә кешенең барлык яхшы, яман эшләрен язып торучы фәрештәләр.

УРМАН КЫЗЫ

Кем ул анда, кара шәлен ябынган да,
Гөлдән үреп муенсалар тагынган да,
Күбәләктәй, гөлдән гөлгә күчеп йөри
Шаулап торган кырыйсыз киң карурманда?
— Әминәм! — Ул туктый, тагын атлый,
Бөгелеп-бөгелеп гөлләр өзә ул,
Тирә-ягы гаднән[1] — гөл диңгезе.—
Шул диңгездә уйный, йөзә ул.
Кемгә өздең, сеңлем, ул гөлләрне?

I

Син уйныйсың, ә мин шундый ардым;
Өзелеп-өзелеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син бер хәят үзең
Уйнап йөргән илдә, яланда.
Толымнарың белән җилләр уйный,
Уңга-сулга ташлый туздырып,
Алар бәхетлеләр...
Соң мин, соң мин нигә,
Төннәр буе шунда утырып,
Кул сузарга куркам?!

II

Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне!
Алар тузылып төшсен алдыңа,—
Шулай килешә сиңа. Су кызыдай
Кил дә хәзер минем алдыма,
Төпсез күзләреңне айга тегәп
Утыр; күлдә — шәүләң уйнасын,
Узган-барган кешеләр туктап карап,
«Су кызы» дип сине уйласын!
Аһ, Әминәм! Булмадың ник бер су кызы,
Иркенлектә уйнап йөрүче?
Ник булмадым мин бер урман углы,
Синең дустың — яшь бер көтүче?
Кыймас иде безгә мәкер күзләр
Болай шөбһә белән карарга.

---

[1] *Гаднән* — җәннәт.

III

Һейне җан сөйгәне Матильданың[1]
Һаман шулай чәчен тараткан;
Син белмисең, аһ, ул Матильданы
Ничек өзелеп сөйгән, яраткан!
Үлгән чакта Һейне, Матильдасы
Төпсез күзе белән һаман да
Карап торган, үлгәч яшрен генә
Чыгып киткән шунда яланга.
Бик күп еллар үткән, шул яланда
Ялгыз гына гомер уздырган,
Өзелеп сагынганда Һенрихен ул,
Толымнарын һаман туздырган...

IV

Син уйныйсың?! Ә мин шундый ардым;
Өзелеп-өзелеп тыным алам да
Карыйм сиңа: син бер хәят үзең
Уйнап йөргән илдә, яланда...
«Яшь шагыйрьне сөйгән Матильдадай,
Мин дә чәчләремне таратам;
Кил, син ардың, дустым! Мин бит сине
Өзелеп-өзелеп сөям, яратам!»
— Ник димисең шулай?
Сорасам да:
«Син бит абыем минем!» диярсең,
Ике кулың белән йөзең каплап,
Башың түбән табан иярсең.
Толымнарың белән җилләр уйный,
Уңга-сулга ташлый туздырып;
Алар бәхетлеләр...

V

Нигә?.. Нигә синең шаян күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр
Керфек очларыңнан агалар?!

---

[1] *Матильда* — Һейненең сөйгән кызы. *(Һ. Такташ искәрмәсе.)*

Кайчак күзләреңнән көчләр алып,
Бөеклеккә табан ашам мин,
Ә кайчакта башым түбән иям,
Әй, Әминәм, синнән качам мин.
Син кем, белмим, синең шаян күзләр
Нигә, белмим, болай багалар;
Нинди көчләр, сөйлә, әй, аппагым,
Керфек очларыңнан агалар?!
Син ал инде, ал ул күзләреңне,
Алар шундый, шундый караңгы...
Үле тынлык анда, саф мәхәббәт
Исереп йоклый әле...

VI

Таң алды...
Син кер инде! Тиздән кояш чыгар,
Кер, Әминәм, йокың калмасын!
Мин дә шунда, дустым, ялгыз калып,
Мактый-мактый ак таң Алласын,
Соң мәртәбә алып сорнаемның[1]
Өзгәләнгән сихри кылларын,
Таңның салкын, йомшак җилләренә
Күзләреңне мактап җырларым.
Алар акрын гына тәкърар итәр,
Илдән илгә күчеп җырларлар.
Таңда су алганда яшь киленнәр,
Туктап, таң җилләрен тыңларлар.
Син кер инде, тиздән кояш чыгар;
Әнә томан басты болынны;
Уйганырлар инде кош-кортлар да;
Бир, акыллым, сеңлем, кулыңны!

VII

Күл янында утырып җырлар язам,
Әй, таң җиле, тукта, исмәче!
Йоклап яткан таллар, тирәкләрнең
Яфракларын уйнап ишмәче!

---

[1] *Сорнай* — тынлы музыка уен коралы.

Ниндидер ят өннәр күкрәгемдә
Ишетелә дә тагын тын кала,
Эзлим ул өннәрне, тапмыйм... Кинәт
Тагын бәгърем таша, ут ала...
Туктагыз! Мин җырлыйм:
— Шул урманда
Үскән фәрештәдәй кыз бала,
Җирдә түгел, күктә, гарештә дә
Булмаган бер генә тиң аңа.
Урман биргән аңа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр,
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр;
Таң җилләре аның, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган;
Төн ае, төннәрдә йокламыйча,
Ана булып күктән караган.
Карурманның барлык матурлыгы,
Бар серләре анда җыелган,
Зифа буе булган ак мәрмәрдән,
Күзе сихри нурдан коелган.
Көннәр үткән шулай,
Ул зур үскән;
Менә бер көн матур ак таңда,
Кара шәлен ябынып, чыгып киткән —
Йөрер өчен кара урманда.
Очраткан ул шунда, күл янында,
Абынып-йоклап яткан берәүне;
Уяткан ул аны —
Ул бер юлчы булган.

VIII

Әй, таң кызы! Сиңа талган юлчың
Таңда искән йомшак җил белән
Сәламнәр җибәрә. Иртә белән
Син килерсең шунда, бик беләм,
Тик мин булмам,
Сеңлем, әй, Әминәм!

. . . .

Соңгы ядкарь итеп күл янына
Гөлләр өзеп куям бер күләм.
— Аны сөйгән гөл-чәчәкләр! Ул килгәндә,
Тәгъзим итеп[1] башыгыз иярсез!
«Сине өзелеп сөйгән юлчы абыең
Еракларга китте»,— диярсез.

IX

Тирән сахра минем барыр юллар,
Күчә алмаслык ерак, караңгы...
Беләм, анда мине кара көннәр,
Ул килер дип, анда караулый;
Беләм, мине көткән кайгы-хәсрәт
Тау-тау булып анда өелгән;
Беләм, шул тауларның асларында
Мин эзләгән җәүһәр күмелгән.

1922

ЭШЛИЛӘР

I

Алар эшли, күптән эшли инде
Тимер куллы даһи эшчеләр.
Айлар, еллар үтә,— һаман шунда:
«Даң! Доң! — Даң! Доң!..»
Нидер эшлиләр.

II

— Табигать! Кит минем юлларымнан!
Ташла сангать[2] коралларың кулларыңнан!
Менә сәнигъ[3] синңа! Юл бир миңа!
Төзим җәннәт ташландык ил, кырларыңнан! —
Шулай ди ул, мәгърур бер яшь эшче,
Киң сахрада җәннәт төзә ул;
Тирә-ягы гаднән — гөл диңгезе.—
Шул диңгездә эшли-йөзә ул.

---

[1] *Тәгъзим иту* — хөрмәт иту.
[2] *Сангать* — эш, һөнәр.
[3] *Сәнигъ* — иҗат итуче.

III

Төн уртасы... Эшче уйлап ята
Җир өстендә җәннәт төзергә,
Көчле кулы белән табигатьнең
Барлык богауларын өзәргә...
Табигать тә, аңа баш игәндәй,
Төн карасын вата, тарата.
Нурлар түгеп шунда көлә-көлә,
Күк читендә ашыгып таң ата.

IV

Алар эшли; күптән эшли инде
Тимер куллы даһи эшчеләр.
Айлар, еллар үтә,— һаман шунда:
«Даң! Доң! — Даң! Доң!» — Нидер эшлиләр...
Менә рәссам ашыгып дивар бизи,
Шагыйрь җырлый, тәмам тилергән;
Әнә эшче, батыр үгез кебек,
Нидер бөгеп ята тимердән!

V

«Яңа җәннәт җирдә төзелде!» — дип,
Җибрил[1] күккә хәбәр китерде.
Мәгърур патша — көчле күк Алласы,
Әүвәл көлде,
Соңыннан —
Тилерде...

1922

МӘҢГЕЛЕК ӘКИЯТ

Әкият сөйлим сезгә, таң җилләре!
Туктагыз да менә тыңлагыз!
Шул урманда булган бер әкиятне
Илдән илгә күчеп җырлагыз!

---

[1] *Җибрил (Җәбраил)* — пәйгамбәрләргә Алланың вәхиләрен — хәбәрләрен җиткерүче фәрештә.

Менә урман, чиксез кара урман,
Мәңге шомлы, мәңге караңгы;
Җилләр белән ишелеп һаман, һаман
Улап торган үткән заманны.
Шул урманда яшрен бер урында
Ялгыз кабер тора.
Кем анда?
Нигә ялгыз анда адашкан да,
Нигә яшрен җирдә урманда?
Ул бер егет кабере,
Ул егетнең
Кайгы белән үткән көннәре,
Озын булган мәңге газап белән
Йоклый алмый үткән төннәре.
Ул күп, бик күп уйлап йөргән:
«Адәм кайдан килгән? — Тагын да
Кайда китәр?» Ләкин моңа җавап
Табалмаган үзенең аңында.
Табалмагач, килеп тезләнгән дә
Мәңгелектән җавап сораган.
Озак көткән —
Җавап ала алмагач,
Болай диеп егет җырлаган:
«Нәләт төшсен сезгә, нәләт төшсен!
Әй, урманнар, кырлар, далалар!
Мәңге телсез каты ташка әйләнгән
Җирләр, күкләр, фәннәр, Аллалар!
Җавап көттем сездән, бирмәдегез;
Инде эзләп китәм — табармын;
Көчле кулым белән мәңгелекнең
Тимер ишекләрен ватармын.
Ватармын да илгә яшрен булган
Барлык серне чишәр, ачармын».
Шуннан соң ул яшрен урын сайлап,
Кабер казып җиргә күмелгән;
Мескен егет, кайтам диеп киткән,
Кайтмас җирдән — упкын төбеннән...
Мин әле дә аның кабрен эзлим,
Урманнардан, яшрен җирләрдән,
Мин тавышын ишетәм, һәр көн ишетәм
Таң алдында искән җилләрдән.

Ул киләчәк...
Мин дә, кабрен табып,
Гөлне үпкән кебек үбәрмен,
Зәңгәр күзләремнән, аямыйча,
Кайнар яшьләремне түгәрмен.

Зәңгәр күзле егет кабрен үбәр,
Яшьләр түгәр кабрең өстенә!
Гөлләр сибәр һәр көн таң алдында,
Җырлар җырлар синең исмеңә.
Син эзләгән яшрен, зур серләрне
Мин дә эзлим, егет,—
Тыныч бул!
Син күзләгән төпсез упкыннарны
Мин дә күзлим, егет,—
Тыныч бул!

1923

САГЫНУ

(«Зәңгәр күзләр» шигыреннән бер ләүхә)

Мин сагынам өзелеп яшь чагымны...
Тик ул чаклар минем хәтердә
Бик томанлы, бик томанлы булып калган.
Менә хәзер дә
Бик еракта, гүя бик еракта
Серле җәннәт булып күренә:
Серле җәннәт... Зәңгәр утлар янган.
Бишек элгән җәннәт түренә,
Мин тирбәләм шунда:
«Тирбәт, әнкәй, минем бишегемне!
Очындыр бер тагын һавага!..»
Шундый рәхәт миңа, шундый рәхәт,
Уйный-уйный иркен һавада,
Мин тирбәләм.
«Тирбәт, апай, минем бишегемне!
Уйнат мине, назла, иркәлә;
Йокла, диген, шаян уйнар өчен
Уйганырсың тагын иртәгә!»
Бирегез миңа, бирегез зәңгәр күзле яшь чагымны.

. . . .

Ах, ул чаклар шундый ерак калып,
Күм-күк томаннарга төренгән,
Төштә күргән пәри сараедай,
Күренеп тора күм-күк сөремнән.
Менә мин бер зәңгәр күзле япь-яшь бала,
Тәпи йөреп чыгам урамга,
Кулымдагы нечкә чыбык белән
Казлар куган булам урамда.
Бәбкәләрен саклап, ак ана каз
Миңа таба килә, җилкенә;
Күп тә үтми, аунап җир өстенә,
Калам усал казның иркенә...
Бирегез миңа, бирегез зәңгәр күзле яшь чагымны!
Ах! Сез бирмисез?!
Сез явызлар!.. Сез... Сез... Сез явызлар!
Минем хәсрәтемне күрмисез!..

1923

ТАКТАШ ҮЛДЕ

Көчле кояш күптән баткан инде;
Караңгылык баскан җир өстен,
Ә ул һаман утын якмый, тик утыра.
Бәлки... кем белсен,
Аның көчле кулы бик күп еллар
Шулай эшли-эшли талгач та,
Күкрәгендә хәят нурларыннан
Соңгы нуры сүнеп калгач та,
Аның ирекле күңле тынар өчен
Караңгылык тели торгандыр?
Бәлки шулайдыр да,
Бәлки...

Өстәлендә аның бер хат тора —
Карт анасы язган;
Хатында
Шундый юллар:
...Хәләл сөтен имезеп, төннәр буе
Йокламыйча сине саклаган,

Авырганда, үлем кочагына
Үзен атып, сине яклаган,
Ул кем иде?
Соңгы сынык нанын сиңа биреп
Ач калса да, «балам» диюче,
Бөтен дөнья синнән качканда да,
Бер ялгызы калып сөюче,
Ул кем иде?..
Син ач килеш йөргән чакта,
Синең өчен
Елый-елый күзсез калучы,
Синең бәхтең өчен җир өстендә
Тәмуг газаплары алучы,
Ул кем иде?..
— Мескен әнкәң!
Ул әле дә өзелеп сагына сине,
Ә син?..

Әткәң,
Ул әле дә шулай сөренә-сөренә,
Таяк тоткан килеш, урамда
Туктап ютәлли дә:
«Мин әле дә сезнең өчен
Салкын буранда
Һаман йөрим», ди ул.
Аның күләгәсе һаман йөри,
Һаман, һаман да.
Бер ул гына түгел,
Бире бик күп алар;
Ач, ялангач килеш яланда
Тик йөриләр...
Тик йөриләр...
«Син кайт, балам!
Син кайт безнең янга,
Әүвәлгедәй сине сөярбез,
Балам, иркәм, бәгърем, диярбез!
Син кайт, балам!»
Төн үтә дә,
Иртәнге җил аңа җавап яза:
— Улың үлде.

Сагынып хатлар язма, бәхетсез карт,
Зәңгәр күзле улың исеменә;
Ул юк инде...
Сагынып хатлар көтмә, «изге» карчык!
Көзге төндә,
Тәрәзә төбендә,
Тәрәзәңне кагып:
— Аңардан! — дип,
Хат китермәс хәзер беркем дә...
Төштә күреп аны уянгач та,
Рәсемен кулыңа алып син аның,
Таң җилләре аша
Елый-елый,
Көтмә инде аның сәламен!
Ул юк инде,
Ата!
Синең өчен,
Ул юк инде,
Ана!
Синең өчен,
Сезнең өчен үлде мәңгегә...

Иске тормыш!
Синең кырларыңда
Зәңгәр күзле уйчан яшь егет —
Ул юк инде...
Иске тормыш!
Синең «гөлбакча»ңда,
Сөренә-сөренә ачтан интегеп,
Хәят эзләп йөргән уйчан егет —
Ул юк инде...
Гаиләң тар синең аның өчен,
Йортың — төрмә,
Ишекләре корыч, тимердән.
Балаларың — исрек,
Исреп-исреп,
Нәселең чергән!
Барсы тилергән!..
Нәфрәт итеп «синең гаиләңә»,
Барлык матурлык дип белгән нәрсәңә,

Нәфрәт итеп сиңа!
Ул ант итә Казан урамында,
Ул ант итә мещан базында,
Ул ант итә сезнең арагызда,
Әй, сез, калдык нэпман уллары!
Базар корольләре!
Шарлатаннар!
Череп беткән сыра кортлары!
Сез табынган алтын-көмешләрне
Тәңре итеп үзенә алалмый;
Сез аунаган пычрак баткаклыкта
Үзе өчен урын табалмый;
Ишетәсезме!
Сезгә, кабак дусты,
Җырчы малай булып кала алмый!

Көрәшчеләр!
Сезнең арагызда яшь бер егет килә,
Аның да
Һичбер нәрсәсе юк:
Малы да,
Атасы да,
Анасы да,
Сөйгән яры да...

1923

УРМАН

(Рабфакны бетереп вузда укучы бер студентның истәлегеннән)

...Мин, партизан, анда кайтырмын.
Урман.
Анда давыл симфониясе,
Анда үзенә башка тавышлар,
Анда кыргый кошлар,
Ач бүреләр җырлый,
Анда шаулый күлләр, камышлар...

Урман.
Бер агачтан күчеп бер агачка,
Азык эзләп очкан сандугач
Адашкандыр, бәлки,

Ул урманда,
Мескен,
Кайда кунар инде төн булгач...

Урман.
Яфраклы төн.
Урман —
Зәңгәр төтен.
Яздыр әле анда
Һаман да...
Бүген, бәлкем, энем Әхмүш шуннан
Волсоветка табан үткәндер;
Арык бүре камышлардан чыгып,
Туктап торгандыр да
Киткәндер...
Әхмүш агай, бәлки, төн йокламый
Качып кына юкә кискәндер...

Урман.
Читләрендә аның әнкәй арыш урган,
Ләкин башкаларга...
Мескен...
Үзе ачтан үлгән соңыннан.
Миннән хәзер ерак булган,
Минем көтү көтеп йөргән урман!
Сәлам сина сөйгән улыңнан!
Синең бөтен җиреӊ минем хәтердә;
Сагынсам да сине,
Яратсам да сине,
Кайта алмыйм әле хәзергә.

Көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе
Алдан чабып йөри торгандыр;
Мин партизан булып киткәч, яланыңда
Кемнәр көтү көтеп йөргәндер...

Мин, юкәләр юнып, җырлый-җырлый,
Чабаталар үргән урында,
Кем ул — җырлый-җырлый көннәр буе,
Ак юкәләр сырып кулында,
Утыра торгандыр ул шунда.

Урман!
Сагынсам да, синдә тиз булмам.
Юлларымның башы синдә, урман!
Яшьлек көнем синдә узган!
Синең яланыңда
Әткәй китте аклар кулыннан.

Урман!
Мин, партизан, сиңа кайтырмын!
Кайтырмын бер килер көннәргә;
Тик көтүче булып түгел,
Ә инженер булып эшләргә!

1924

КАРТ АРТИСТ

(1924 елның 31 мартында ясалачак Кари кичәсенә багышлап)

Минә карагыз минем йөзләремә,—
Анда нинди юллар сызылган,
Зур күзләрем эчкә кереп баткан,
Ак чәчләрем ничек тузылган...
Мин — карт артист,
Татар сәхнәсендә
Ач-ялангач килеш күп еллар
Хезмәт итәм. Минә шушы юллар —
Минем хезмәтемнең шаһиты.

Салкын сәхнә минем йортым иде,
Ертык пальто, тузган киемдә
Бөтен гомрем буе хезмәт итәм.
— Кемгә?
Анысын белмим үзем дә...
Караучылар: байлар, байбәтчәләр,
Пудраларга чумган курчаклар
Көлә иделәр миннән;
Бармак төртеп көлә иделәр алар ул чаклар.
Әрәм хезмәт,
Ачлык, ялангачлык
Тормыш төбенә мине ташлады,
Зур теләкләр тулган күкрәгемне
Үлем микроблары каплады...

Менә карагызчы минем йөзләремә,—
Анда нинди юллар сызылган.
Зур күзләрем эчкә кереп баткан,
Ак чәчләрем ничек тузылган...

Бәхетле сез, иркен яшь артистлар;
Иркен сәхнә сезнең йортыгыз,
Шул сәхнәдә ярлы эшчеләргә
Хезмәт итү сезнең бурычыгыз!

. . . .

Бирегез миңа шушы «эшче картны»[1],
Мин ул картны шулай уйнармын,—
Чәчләрегез сезнең үрә торыр,
Яшьләрегез агар,
Мин дә ул карт булып зур сәхнәдә
Тыела алмый үкреп елармын...
Чөнки мин дә шушы эшче карттай
Бөтен авырлыкны күрдем мин;
Аның кебек байга хезмәт иттем,
Аның кебек сөрелеп йөрдем мин...
Бирегез миңа шушы эшче картны,
Шулай матур итеп уйнармын.
А, юк!..
Карагызчы минем йөзләремә,
Анда нинди юллар сызылган,
Күзләремнән үлем карый хәзер,
Ак чәчләрем ничек тузылган...

1924

ДАВЫЛДАН СОҢ

I

Минем геройларым:
СССРның
Бөтен җирләрендә яшиләр;
Эшсез урам даһилары минем геройларым,
Минем геройларым
Көлә, елыйлар;

[1] Шул кичәдә уйналачак «Чабатаңны кемгә тукыйсың?» картын. *(Һ. Такташ искәрмәсе.)*

Минем геройларым
Кабакларда
Чәнчелгәнче сыра эчәләр...
Материалым:
Буран,
    давыл,
        таңнар,
            кичәләр.
Материалым:
    Син дә,
        мин дә,
            ул да,
                бу да,
                    алар да.

Бу темага керә давылдан соң бөтен типлар:
Эшле,
Эшсез —
бары да,
Монда концерт бирә: кулаклар да,
Мин дә.
Бүлмә,
Бүлмәдә кошмар.
Ертык чалбар.
Китап, шкафлар.
Ә урамда:
Кояш чәчәк аткан;
Нурдан туфан
Мәйданнарга ташланган,
Җир уянган.
Урам дулкынланган.
Тормыш симфониясе башланган...

Тормыш симфониясе.
Оркестр:
Йөрәк кылларыннан,
Аһ-зарлардан,
Көлү өненнән,
Тимер тавышлары,
Гудоклардан,
Миллион тавышлардан төзелгән...

Ул оркестр шушы урамнарда
Күптән уйнап килгән,
Аның йөрәк өзгеч кылларында:
Үлем тавышлары,
Коллык аһәңнәре,
Корал тавышлары иштелгән...
Мин дә бүлмә,
Бүлмәдә кошмар,
Ертык чалбар,
Китап, шкафлар...
Бүлмә ишеген бикләп чыгып китәм
Кырга, урамга;
Ачлар арасына,
Туклар дөньясына,
Тормыш симфониясен тыңларга.
Менә урам.
Урам симфониясен
Аяк тавышлары башлыйлар;
Иртә сәгать биштән
Төнге өчкә кадәр
— Шап-шоп, шап-шоп:
Директорлар,
Завлар,
Зур корсаклы кешеләр
. . . . атлыйлар...

II

Байрак илтүче.
Сүзне башлап китәм шул урамда
Моннан бер ел әүвәл күргән баладан,
Исмен хәтерләмим.
Гомремдә бер кат яңадан
Күрерменме?
Белмим.

— Бәйрәм.
Зур мәйдан.
Комсомоллар Ирек мәйданына
Колонналар булып агалар,
Ә ул иң алдан
Байрак тотып килә,

Бөдрә чәче
Җилләр ирке белән таралган.
Байрак илтүче,
Көләч йөзле кем иде ул?
Белмим.
Бөдрә чәчле,
Зәңгәр күзле,
Күк блуза кигән комсомол
Кем иде ул? —
Белмим.
Байрагында:
«Киләчәк көн якты,
Тарих канаты
Безне алып бара.
Без туачак тормыш сызыгында
Бәлки үләрбез...
Ләкин бөтен дөнья азатлыгы
Ишеген ачып,
Хезмәт явын азат итәрбез,
Җиңәрбез!»
Дигән сүзләр.

Исмең белмим.
Ләкин син Казанда
Мине, бәлки, бик күп күргәнсең,
Кыш буенча бу ел укыгансың,
Клубларга йөргәнсең.
Ә мин? —
Очратмадым сине...
Ләкин
Очратырмын, бәлки,
Собраниедә,
Клубта,
Ә бәлки бергә булып та
Танышмыйча үләрбез без
Бер үк полкта,
Бер үк фронтта...

Урам.
Урамда
«Барабыз»лар йөри буранда.

Әй, кем анда?
Милиционер.
Рабфак,
Рабфакта —
Кичә.
Кичекмәбез хәзер барсак та;
— Зур зал,
Залда «Интернационал».
Комсомоллар җырлый:
— «Кузгал»...

Бу гимнга мең клублар кушыла,
Подваллардан,
Завод диварлары арасыннан
Меңнәр тавышы бергә бәйләнә.
Җирдә гыйсъян җыры,
Җирдә тормыш симфониясе,
Җир әйләнә.

Корсак:
Үсәр әле аз-маз сыптырсак!
Кояш иңгән.
Күк йолдызлар белән күмелгән.
Кабакларда кыллы оркестрлар
Мазуркалар белән яңгырый.
Исрек җырлар,
Шешә музыкасы,
Эчке бокаллары шалтырый...
Кошмар:
Бер якта зур зал.
Залда «Интернационал».
Икенчедән:
Нэплар, бокаллар...

Ул авылда туды,
Шунда үсте,
Аны зифа авыл таллары
Кояш эссесеннән саклады.
Салам япкан җимрек каралтылар
Салкын җилдән, кыштан каплады.

Ул авылда туды,
Батрак улы,
Бик күп авырлыклар күрде ул,
Көтүче дә булды,
Фронтларда
Партизан да булып йөрде ул.
Ә бүген
Рабфак кичәсендә,
Зал эчендә ул да бар,
Әүвәл авыл улы иде,
Хәзер — комиссар.

Ул шәһәрдә туды,
Шунда үсте,
Пар атларда чапты,
Типтерде,
Гимназиягә керде.
Себерләрдә йөрде,
Бывший офицер,
Хәзер
Кабак исрекләре арасында
Ул да бар...
Кошмар:
Комиссар да зал.
Залда
«Интернационал...»
Офицер да кабак,
Кабакта шешәләр...
Көчле яшен зәңгәр күк йөзендә
Уттан кылыч булып яна да
Кинәт сүнә.
Көчле күк күкрәве юлбарыстай
Киң сахрага тавыш сала да
Кинәт тына.
Тагын яшен яшьни,
Тагын күкри,
Тагын шулай җилләр исәләр,
Тагын яңгыр ява,
Тагын, тагын, тагын...
Айлар, еллар шулай үтәләр...

Табигатьнең иркен күкрәгендә
Мәңге көрәш,
Мәңге хәрәкәт,
Мәңге туу,
Мәңге артып тору
Белән бергә
Үлем-һәлакәт...
Картлар үлә,
Яшьләр туа бара.
Тормыш яңара...

Базар...
Базарда
Магазиннар.
Сәүдәгәрләр план корып ята таларга,—
Күршедәге эшче кибетләре
Үлем маршы җырлый аларга...

Авыл...
Авылда
Этләр улый җилле давылда.
Кырлар...
Кырларга
Тракторлар килә җырларга.

Октябрина.
Пионерлар исем сайлый:
Кайсы алай,
Кайсы болай, ди,
Шаулашалар.
Соңыннан
«Вил» дип аңар исем кушалар.
— Минем нәни дустым!
Бәйрәмеңдә синең була алмыйм,
Ләкин туган көнең белән тәбрик итми,
Катнашмыйча читтә кала алмыйм.
Ни булса да,
Гомреңне кайда гына уздырсаң да,
Тормыш җепләреңне
Ничек кенә туздырсаң да
Барыбер миңа.

Лəкин —
Көрəшче бул!

Ул үзенең улын исемлəргə
Мəҗлес корып мулла чакырды;
Гайнүк кулак килде,
Ибруш керде,
Шулай итеп мəҗлес ачылды.
Бəлешлəрне бөгеп,
Балны сөзеп,
Əнвəр диеп исем бирделəр.
Битлəр сыпырдылар.
Мулла болай диде:
— Егет, изге юл!
Озак яшə,
Əнвəр паша[1] кебек
Динле бул!
Шулай итеп кошмар...

Пəрдə əкрен генə күтəрелə.
Зур пəрдəнең ике ягында
Ике тормыш күренə,
Тагын да
Пəрдə төшə.
Бер ягында аның иске тормыш:
Зур чиркəүлəр, мəчет, кабаклар,
Таш урамнар —
Шунда бик күп халык,
Акылсызлар, мулла, монахлар...
Бер ягында аның яңа тормыш:
Совнаркомнар,
ЦИКлар,
Губкомнар,
Комсомоллар,
Эшче, коммунистлар,
Комиссарлар, тагы наркомнар.

Иске тормыш үлə,
Коммунизм гиганты күтəрелə.

---

[1] *Əнвəр паша* (1881—1922) — шагыйрь, Төркиянең сəяси эшлеклесе.

Көннәр туа,
Еллар әкрен генә
Аренага безне үстерә.
Кояш һәр көн чыгып көлә-көлә
Безне карап китә.
Без үсәбез! —
Үткән күперләрне ягып
Якты киләчәккә күчәбез.

Киләчәк көн якты,
Тарих канаты
Безне алып бара.
Без туачак тормыш сызыгында
Бәлки үләрбез...
Ләкин,
Бөтен дөнья азатлыгы ишеген ачып,
Җир йолдызын азат итәрбез!!!

1924

СИН ДӘ ҮЛ ИНДЕ

Бүген — соңгы җиңү белән беткән зур көрәшнең
Сигез елы...
Мин — ерактан килгән авыл улы,
Кемне миңа тәбрик итәргә?
«Берәү» килә,
Аны туктатам да сөйлим:
— Бәйрәм безнеке, дим,
Сезнең тараф
Мәңгелеккә инде җиңелде,
Шуның өчен син дә үл инде!

Без кояшлы язның чәчәкләрен
Үзебезчә җырлый белербез,
Безгә кирәк булган матурлыкны
Үз кулыбыз белән төзербез.
Шайтангамы сезнең кырпа бүрек,
Кыска чалбар, читек-кәвешләр,
«Йомшак мендәр», «рәхәт, тыныч төннәр»,
«Яхшы заманнар»ны көтүләр...

Сезнең көткән заманалар
Күптән инде җиргә күмелде,
Сезнең кояш сүнде,
Шуның өчен син дә үл инде!

Бүген бәйрәм көне...
Һәм мин — шашкан уйлар,
Тилергән хисләрнең даһие,
Бүген урам буйлап килгән көе
Үткәнемне уйлыйм:
Менә авыл өе...
Мин авылның «Бурлак Һадие».

Юллар мине шушы урамнарга
Бәйрәм итәр өчен китерде,
Еллар мине — авыл урамыннан алып,
Җырчы малай итеп үстерде...
Бүген — соңгы җиңү белән беткән зур көрәшнең
Сигез елы,
Мин — ерактан килгән авыл улы,
Кемне миңа тәбрик итәргә?..

Яз үзенең соңгы җырын җырлый.
Урам бәйрәм көнен уздыра,
Нэпман гына шунда, урамдагы
Асравына
Ачуланып, нидер кычкыра.
Мин аңарга барып сөйлим:
— Кычкырма! —
Дим,—
Сезнең тараф мәңгелеккә инде җиңелде.
Шуның өчен:
— Лучше үл инде!

Бәйрәм иткәндә
Урамнардан бергә җырлый-җырлый
Колонналар булып үткәндә,
Кемне тагын тәбрик итәргә?..
Бер авыл бар,
Анда безнең күрше
(Әнкәй белән кайчак дау булса)
Мине сүгә.

Ләкин хыянәтсез ана мәхәббәте
Мин киенгән төпсез чабаталарны
Саклый һаман,
— Кайтыр балам, ди ул, сау булса!
Сез аңардан барып күпме генә
Шушы тузган чабаталарны
Сорасагыз да, ул бирмәс сезгә,
— Баламныкы! —
Дияр,
Каберенә илтер аларны!
Ә сез аңа барып сөйләгез,
— Балаң исән!—
Диегез,—
Ләкин сиңа булган мәхәббәте
Көрәш көче тарафыннан җиңелде,
Шуның өчен:
Көтмә, кайтмас!
Син дә үл инде...
Һәм ул тиздән үләр...
Еллар үтү белән минем иптәш
Үзе шулай малай тудырыр.
(Ләкин минем балам художникмы,
«Разбойник»мы, белмим, кем булыр?)
Ул да миңа бәлки әйтер:
— Яңа җырлар белән аренага
Яңа кешеләр килде,
Шуның өчен
Син дә үл инде...
Мин дә үләрмен...

Ләкин бүген әле аренадан
Давыллы хисләрнең ташуын,
Гыйсъян иткән утлы йөрәкләрнең
Җиңелмәслек тиле ачуын
Җырлыймын мин:
— Бүген әле бик тар бер күләмдә
Итсәк тә без җиңү бәйрәмен,
Килер бер көн — бөтен җир шарына
Кадарбыз без Ленин байрагын!
Шунда Англиянең бер солдаты,
Чемберленга нота урнына,

Сөялләнеп беткән кулы белән
Әкрен генә чиертеп борнына,
Әйтер:
— Сезнең тараф
Мәңгелеккә инде җиңелде!
Шуның өчен менә хәнҗәр сиңа,
Син дә хәзер, егет,
Үл инде!..

1925

ӘЙДӘ, ЭНЕМ!

Үләрмен дә, онтырлар, дип,
Юкка гына, йөрәк, янасың.
Тамбов урманнары сагыныр әле
Үзе үстергән бунтарь баласын!

Әйдә, энем, ташла фуражкаңны,
Төкер пиджагыңның өстенә.
Галстугы белән билең бу да
Бишмәтеңне киен өстеңә,—
Киттек!

Бүген бүлмәм өчен акча сорап,
Коммунхоздан килеп керделәр,
Акча таба алмагач, усал кешеләр
Квартирдан тотып сөрделәр...

Шулай, энем!
Монда акча кирәк,
Юкка гына йорттан кузгалдык,
Юкка гына шәһәр урамына
Чабатадан кереп югалдык.
Әйдә,
Егет, чишен аягыңны,
Төкер сандалына! —
Яланаяк кына кайтырбыз,
Авылыбызга кайткач:
— Шәһәрләрен яратмадык! —
Диеп әйтербез...

Их!
Шәһәр гудоклары безне чакрып,
Көрәш таушы белән үкерсә,
Очкын атлар безгә ВКПның
Чакру әмрен тагын китерсә,
Без шәһәргә кире кайтырбыз!
Еллар!..
Авыр еллар,
Сезнең кулыгызда
Күрәчәкне бик күп күрдек без;
Буржуй халкы белән сугышып алдык,
Ертык чалбар киеп йөрдек без!
Әй, сез,
Килер кешеләр! —
Әле безнең хатыннарның
Каннарында аккан «түрәләр»,
Менә
Сезгә бабай булыр кешеләр
Шулай итеп газап күрәләр!
Белегез!
Сыйнфый көрәш тарихында беренче кат
Җиңүчеләр булып чыктык без,
Үзебез өчен дүрт кат чүкеч суксак,
Сезнең өчен биш кат суктык без!
Еллар үтәр,
Безнең аркабызда
Иркен, рәхәт көннәр күрерсез,
Бәлки, көнгә дүрт-биш сәгать эшләп,
Сигаралар тартып йөрерсез.
Ә без,
Һаман ертык чалбар киеп,
«Трезвон»[1] тартып, постта калабыз!

Онытмагыз безне, карагыз!
Сезгә бәхет белән тәүфыйк теләп,
Сәлам яза Такташ бабагыз!..
Их!
Илебезнең чиге тар әле,
Анда соңгы көрәш бар әле!

---

[1] *«Трезвон»* — шул елларда кулланылышта йөргән папирос төре.

Әйдә, энем,
Ташла фуражкаңны,
Төкер сандалыңның өстенә,
Галстугы белән билең бу да
Бишмәтеңне киен өстеңә,—
Киттек!
Җәен үсәр зәңгәр чәчәкләрнең
Җырын ишетәм инде —
Яз килер,
Карлар эрер,
Бозлар китәрләр,
Тау битләре ачылыр,
Безнең кырда
Зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр.

1926

ҖЫРЛАНАЧАК ҖЫРЛАР ТУРЫНДА

Авыл... җырчың синнән
Бөтенләйгә китәм, ди...
...Кырларыңда, авыл, большевикча
Хисләр үссә дә,
Кем урыр соң, бар да шулай
Ташлап китсәләр?
....
...Арт урамда берәү
Авыр башын салган цементка,
Ул эчмәгән үзе, ләкин аны
Җырланмаган хисләр исерткән...

Х. Туфан. «Җырланмаган җырлар турында»

Туфан!
Таш урамда башын салган егет
Синең тиргәвеңне ишетте.
Әйе,
Аны әле җырланмаган,
Җырланачак хисләр исертте!..
Бөек җиңү алып килгән хисләр
Сыеша алмый таша күңелдә;

Әйтче:
Кайсын шунда җырлап бетереп була
Безгә тигән кыска гомердә?
Һәрбер фронт безгә зур көрәштә
Тиңсез җиңү алып китерсә,
Һәрбер җиңү алып килгән хисләр
Үзе белән безне исертә...
Ә җырлаучы кайда шул хисләрне?
«Җырчы» урыны көтә иясен.
Бөек еллар җырда үз Ленинын
Тудыралмый калды, күрәсең...
Маңгай бөдрәләрем туздырып, мин
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм, Туфан,
Әле җырланмаган,
Җырланачак
Хисләр турында...
Ташлап киттем Тамбов урманнарын,
Нишлим?
Шау-шуларга йөрәк чыныккан,
Давылларда туып канатланган
Бунтарь йөрәк качты тынлыктан.
Хәзер инде Тамбов урманнары
Төшкә генә минем керерләр,
Ләкин
Дус агайлар минем җырларымда
Мәңге шәүлә булып йөрерләр...
«Әүхәди»не минем җырларымда
Әле, Туфан, бик күп күрерсез,
Минем белән әле киң кырларда
Бик күп атлар көтеп йөрерсез...
Ләкин бүген менә «арт урамнан»
«Мазут» суы аккан урында
Уйлыйм
Җырланмаган,—
Киләчәктә
Бер җырланыр җырлар турында.

1926

БҮГЕНГЕ МАТУРЛЫК

Дөнья матур,
Шуның өчен дә шул
Сүгенә-сүгенә кайтам салкыннан;
Ә җил, сыбызгыны, ни өчендер
Ияргән дә килә артымнан...
Тфү!
Кышкы җилләр тиде теңкәгә!..
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Җил иркендә калды урамнар;
Ә җил, морҗа сандугачы,
Эче пошкан саен,
Алып килер салкын бураннар...
Буран алып килер,
Карлар ташыр,
Аннан тотыныр карлар өяргә.
Да,
Бу дөньяның салкын кышында да
Кызык табыла «безнең юләргә»...

*

«Барабыз»га утырып, теләгән җиргә
Кошлар кебек очып барабыз,
Кояш — безгә иптәш,
Җил — дус кеше,
Ә җир инде — безнең анабыз...

*

Рәхмәт, әнкәй, сиңа:
Ярый әле мине тапкансың,
Җырлар җырлый-җырлый—
«Иркәм!» диеп,
Төннәр йокламыйча баккансың...
Синең авыр кара тормышыңда
Ярдәмчең булмадым булуын,
Ләкин
Авыр көрәш, бөек еллар өчен
Кирәк булган минем тууым! —

Кан исләре исеп килгән саен,
Мәгъруp бер уй уйный йөрәктә.
Солдат булырмын, дим, бәлки, тиздән
Ил чигендә булып көрәштә...

*

Дөнья матур,
Шушы дөньяның мин —
Ирке чикләнмәгән юлчысы,
Давыллы елларның, зур көрәшнең
Матурлыгын җырлар җырчысы...
Кичәге матурлык бүген үлсә,
Иртән туа аның яңасы;
Безнең тупас куллар — киләчәктә
Туар матурлыкның анасы...
Бүгенге матурлык тупас, ертык
Көрәш киеме белән ябынган;
Бүгенгенең данлы матурлыгын
Безнең йөрәк эзли давылдан...
Кан исләре исеп килгән саен,
Мәгъруp бер уй уйный йөрәктә:
Солдат булырбыз без, бәлки, тиздән
Ил чигендә булып көрәштә!

1927

ҖЫРЫМ СИҢА БУЛСЫН

(Нәни шаярулар)

Анаң мескен сине тудырганда,
Яхшы ният белән тудырган,
Ләкин
Үкенгәндер үзе соңыннан...
Әйтче, кызый!
Болай киенергә
Нинди шайтан сине өйрәтте?
Инде
Тездән узган күлмәк итәкләрен
Ертык ясау нигә кирәкте?

Сез, хатыннар, үзегез «иптәш» дисез,
Үзегез
Иптәшлектән качасыз;
Кызлыгыгыз күренеп торсын өчен
Күлмәгегезне
Тезегездән ашып ачасыз.
Алай булгач, инде бер башлагач,
Ярты юлда туктап калмагыз,
Кызык булыр безгә карар өчен
Күлмәк дигәнен дә салсагыз!
Их сез,
«Иптәш» кешеләр!
Ә соң ничек булыр
Теге — сезнең
«Ирләр көчле» дигән сүзегез?
Көлеп әйтмим,
Болай киенеп,
Сез көчлисез безне үзегез!
— Җырым сиңа булсын,
Яшьлегемне
Үзем теләп бирәм кулыңа;
Ләкин тыңла мине:
Иптәш тә бул миңа,
Ана да бул минем улыма!
Ак каеннар,
Матур булыр өчен,
Яз килүгә яфрак яралар;
Ә хатыннар, белмим, ни өчендер
Каеннарга каршы баралар...
Яз җиттеме —
бетте,
Теләсәң нишлә,
Алар үзләренчә башлыйлар:
Кояш көләргә дә өлгерә алмый —
Баштанаяк чишенеп ташлыйлар.
Бүгеннән соң «кыска күлмәк» дигән сүзне
Авызыңнан җилләр урласын...
Җырым сиңа булсын,
Яшьлек хисләремне сиңа бирәм,
Якты уйлар булсын юлдашың...

1927

БОЛАЙ... ГАДИ ҖЫР ГЫНА

Гомер әрәм китте,
Юк эш эшләп чәчләр агарды;
Үлем микроблары хәзер
күкрәгемдә,—
Алдап булмас, ахры, аларны.

(Авырулар җыры)

Үпкә дә юк,
Артык ачу да юк,
Болай гына борын салынган,
«Барабыз»да кайтып киләм әле
Асылып үлгән берәү яныннан...
Ах, «барабыз»,
Кай җирдән син?
Атың начар, малай, синең дә,
Син дә ахры асылып үләрсең;
«Гомре утта янсын...» диярсең.

Карлар яусын йөргән юлларыңа,
Авыр юлда атың армасын,
Кичер минем усал сүзем өчен,
Ходай өчен хәтерең калмасын.
Кешеләр менә:
Матур киенәләр,
Өйләнәләр,
Кызлар сөяләр,
Чәй эчәләр...
Ә бер көнне безгә ачу итеп
Тоталар да асылып үләләр...
Ачу килә.
Мин этләрне беләм,
Алар менә
Собраниегә,
Театрга барып йөрмиләр,
Сөяк кимереп гомер уздыралар,
Ә шулай да асылып үлмиләр...
Ах, «барабыз»,
Мин үлмәскә булып йөрим әле,
Кызыктыра бабай булуы,

Кызык булыр әле малайларның
Эшләүләрен карап торуы.
Ашкынып җырланган теләкләрнең
Чәчәкләрен килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...
Ах,
Үләсе килмәс, үләсе...

Бәхетлемен, ахры,
Җир үзенең
Сөйдерә алды бөтен ваклыгын.
Һәр почмагы миңа урын җәйде,
Күргәзмичә үзенең ятлыгын.
Кармак салсам суга, балыклары
Ятсынмыйча килеп каптылар,
Марҗалары, бер дә авырсынмый,
Чалбар-фәлән алсам, саттылар...
Урамнарда йөрсәм, милицияләр
Ачуланып тотып япмыйлар,
Данлы дуслар, кызыл каракошлар
Чемберленнан мине саклыйлар.
Их!
Кан эчендә туган зур илемнең
Киләчәген килә күрәсе,
Канатымны еллар каерса да,
Каерса да...
Ах, үләсе килмәс, үләсе...
Әле карлар ява,
Әле
Карлы кышның
Ак канаты җирне каплаган,
Әле
Килер язның, матур язның
Шомыртлары чәчәк атмаган...
Күкрәгемне киереп, кышкы көннең
Туялмыйча сулыйм һавасын...
Их, «барабыз»,
Әйдә, ку атыңны,
Әллә нигә авыр барасың.
....

Синең атың кебек җирән атта
«Аны» озатып бардым киткәндә,
Аерыласы килми сарылды ул,
Соңгы кабат мине үпкәндә...
Хатын-кызлар безне үпкән чакта,
Сагынсын дип, ахры, үбәләр,
Еллар...
Бөек еллар шаулый-шаулый
Сагындырыр өчен үтәләр...

Ах, син, илем,
Ничек үләргә соң,
Сагыныр кешеләр синдә булганда;
Ничек үлим,
Берләр меңнәр өчен,
Меңнәр берләр өчен торганда!..

1928

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Кем кабренә чәчәк ыргытсам да,
Әрәм китмәс төсле чәчәгем;
Мин җирдәге һәрбер сукбай белән
Дус абыйдай тату яшәдем.

Поезд ыргый таныш урманнардан,
Тәгәрмәчләр шаулап баралар,
Уйлар һәр очраган ак каенның
Ботагына асылып калалар...
Юл буенда яшь бер каен кызы
Тынып йоклый баскан көенә,
Исрек усак җәеп канатларын
Аны үбәр өчен иелә...
Тик урманның төнге тынычлыгын
Җимереп килгән поезд таушына
Ул сискәнеп, берни булмагандай,
Үз урнына табан аушына...
Юл буенда йомылып йоклап яткан
Урман чәчәкләре сискәнеп
Уяналар...

Поезд килгән якка
Керфекләрен ачып карыйлар,
Ул үтүгә тагын тыналар,
Урман тынлыгына чумалар...

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен,
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...
Поезд ыргый, ә мин тәрәзәдән
Күрмәмме дип, бер-бер танышны,
Һәрбер станциядән күзем алмый,
Карап барам үтеп барышлый...
Кем соң кирәк миңа?
Станциядә
Арлы-бирле йөргән халыклар,
Ертык бүрке, тузган чабатасы белән,
Миңа якын, миңа танышлар...
Мин гомрем буе шул кешеләрнең
Йөрәк тавышларын тыңладым,
Каныма манчып язган һәр җырымны
Алар теле белән җырладым.
Алар арасында матурланып,
Бөдрәләнде яшьлек чәчәгем,
Давыллы елларда, киң кырларда
Алар белән бергә яшәдем...

Алар башка хәзер;
Алар, тар сукмактан чыгып,
Зур юлларга табан баралар,
Алар көче белән җирдән күтәрелә
Яңа авыл, яңа калалар...

Поезд ыргый,
Ә мин тәрәзәдән
Озатып калам һәрбер танышны,
Һәрберсенә җылы хисләр белән
Елмаямын үтеп барышлый...

1928

Төзүчедән:

Һ. Такташ әсәрнең беренче басмасында «Алар башка хәзер» дигән сүзләрдән алып «Поезд ыргый» юлына кадәр менә болай дип язган булган:

Авыр миңа хәзер,
Элек миннән курыкмый
Сәвит сүгеп йөргән абыйлар,
Хәзер инде миңа болай... әллә ничек,
Читли төшебрәк карыйлар...
Алар нәрсә уйлый хәзер? —
Кайсы аның
Алдашмыйча җавап бирәлә? —
Аю кебек алар... авыр... түземлеләр.
....
Сүгенеп-нитеп булса да әле,
Үз эшләрен алып баралар,
Алар көче белән җирдән күтәрелә,
Яңа авыл, яңа калалар...

* * *

Айга күптән инде мең яшь тулган,
Ә ай аны үзе оныткан;
Кичә саташкан ай кыш дип белеп —
Төн уздырган күктә толыптан...

Ай кебек без озак яшәмәбез,
Көчләр сүнәр,
Куллар талырлар,
Картаербыз,
Соңгы көрәшләргә
Яшьләр генә ахры барырлар.
Яшьләр белән мин дә барырмын дип
Алдыйм болай үзем алдавын,
Ләкин
Бик авырткан чакка туры килер,
Ихтимал, шул бара алмавым...
Их, яшьлекнең үтәр алсу таңы,
Мин туктатмыйм синең агымны;
Үтәр өчен килгәч, карышып тормыйм,
Җырлап озатам яшьлек чагымны...

Әле картлыкның да үз вактында
Матурлыгын таба белербез;
Октябрятлар безне эштән куса,
«Тавык комиссиясе» төзеп,
Тавыкларның
Тормышларын рәтләп йөрербез.
Тавыклар да ун ел безнең белән
Бер аякка басып бардылар:
Салам ояларга
«Совет өчен»
Ап-ак йомыркалар салдылар...
Ах җир, ах җир!
Синең матурлыгың
Шундый тигез итеп таралган:
Һәр дуңгызың, һәрбер песи кызың
Чәчәк кебек матур яралган...
Һәр әтәчкә бүркем салып үтәм,
Совет саулык бирсен аңарга;
Һәрбер эткә, үзе тели икән,
Рөхсәт итәм борным яларга...
Һәрбер сыер мине бозавы итеп,
Ап-ак сөте белән имезгән;
Һәрбер сарык тунын салып биреп,
Кышкы суыкларда кигезгән...
Ә ай ялгыз,
Айда бернәрсә юк,
Әтәч тә юк анда, песи дә;
Катык та юк анда, ипи дә юк
Безнең ише ярлы кешегә...

1928

МӘХӘББӘТ ТӘҮБӘСЕ

Яшьлек,
Гомрең кыска синең,
Шундый кыска булып тоела,
Кичен чәчәк аткан була,
Ә таңында инде коела...
Мәхәббәт,
Ул үзе иске нәрсә,

Лəкин
Һəрбер йөрəк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гомрен бирə
Аның хисе белəн янарга...
Янган яшьлек,
Үткəн мəхəббəтлəр,
Алар мəңге миндə терелмəс,
Күзлəрем дə хəзер беркемгə дə
Гыйшык уты эзлəп текəлмəс.
Инде...
Тəүбə иттем ул эшлəрдəн,
Азгын күңел күпкə басылды,
Ирке чиклəнмəгəн йөрəгемə
Башлык итеп куйдым гакылны.
Гакыл башлык булган көннəн алып,
Көн-төн елый мескен йөрəгем,
Һəр көн ызгыш, һəр көн йөрəгемə
Гакыл-башлык бирə кирəген...
Их, син, яшьлек,
Их, син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чəчəк аткан булдың,
Ə таңында...
Ə таңында инде коелдың...
Язгы сандугачлы яшьлек таңым
Үтте инде...
Онтылдылар бик күп исемнəр,
Инде яшьлəр хəзер яратсыннар,
Инде яшьлəр хəзер сөйсеннəр...
Ə мин...
Ə мин үзем бөтенлəйгə
Тəүбə иттем андый эшлəрдəн,
Читтəн генə хəзер көлеп йөрим,
— Гыйшык! —
Диеп йөргəн кешелəрдəн...
Шулай да əле, кызлар,
Алла хакы өчен,
Миннəн бераз читтə йөрегез,
Я тəүбəне шунда боздырырсыз,
«Гыйшык» итеп куеп берегез!..

Юк шул,
Гыйшкым хәзер иясенә
Кире алынмаска бирелгән,
«Аның» рәсмен беркем, бервакытта
Ала алмас минем күңелдән...
Шуның өчен тыныч күңел белән
Туктап менә шушы урында,
Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка
Булган көчле гыйшкы турында...

I. Зөбәйдәнең рәсме

Кайчак шулай бер-бер иптәшеңдә
Утырып, сөйләшер сүз тапмыйсың,
Өстәленнән альбом кебеген алып,
Рәсемнәрен мактый башлыйсың...
Шулай ялкау гына сөйләнгәндә,
Күзләр бер рәсемгә туктала,
Кара болыт кебек тузган чәчләр
Хыялыңа кереп чормала...
— Бу кем? — дисең,
Ә ул, көлеп кенә:
— Бу, ди, хәзер бала анасы,
Матур иде, яшьли иргә чыкты,
Хәзер инде алты баласы...
Ди ул,
Ә син алданганың
Белдермәскә теләп тынасың.
Ә бераздан:
— Алай икән...
Дигән булып,
Альбом битен ябып куясың.
Матурлык ул шулай:
Кызда булса,
Җыерчыклы йөзгә әйләнә,
Ирдә булса,
Аның матурлыгы
Сакал, мыек белән бәйләнә...
Мәхәббәт тә —
Нәфис матур чәчәк,

Лэкин
Үзе гаҗәп гомерсез,
Кайчак загс белән соңы бетә,
Ә кайчакта...
Яхшук күңелсез...
Зөбәйдәнең рәсеме —
Альбомымның
Күзгә бәрелеп торган урнында,
Альбомымны карап чыккан кешеләр
Һаман сорый аның турында:
— Бу кем, диләр,
Ә мин җавап бирәм:
— Матур кыз, дим,
Булган комсомолка,
Бөтен кешене үзенә карата,
Ә син, егет,
Бераз кичектең шул —
Ул бер наборщикны ярата...

II. Зөбәйдәнең гыйшкы

Сандугачлы таңнар,
Зур урманнар
Аның гыйшкын бизи алмады,
Язгы зәңгәр күкнең йолдызлары,
Матурланып күктә янмады...
Аның гыйшкы көзен чәчәк атты
Эштә,
Собраниедә,
Урамда,
Күңел язы шаулап үтте аның
Тәңкә карлар яуган буранда...

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны,
Шундый якын бу җыр күңелгә,
Җырланган җыр кебек яшьлек таңым
Шаулап үтте...
Шаулап үтте инде гомергә...

Их!
— Зөбәйдә, бар бүген собраниегә,
Анда аның бүген доклады;

Ул елмаер сиңа тагын да,
Затып[1] килер кайткан чагында...
— Зөбәйдә, бар бүген театрга,
Бәлки анда аны күрерсең,
Аның белән залда йөрерсең...
— Зөбәйдә, син барма театрга,
Йөрмә, бәгърем, аның артыннан...
Саклана күр егет халкыннан...

Ашкынулы көннәр шулай үткән,
Минутлардан эзләр калмаган,
Яшьлек үзенең җылы кочагында
Зөбәйдәне һаман алдаган...
Ә бер көнне...
Аны наборщигы
Кунак итеп үзенә китергән,
Алар бергә утырганнар...
Соңыннан
Бүлмә уты сүнгән,
Алар икәү
Төнге караңгыда калганнар...
Төн караңгы булган...
Төн буенча
Ап-ак карлар җиргә яуганнар...
....
Ул төнне ай күктә, эш тапмыйча,
Эче пошып сүгенеп йөрегән,
Ул төнне Әүхәди юлга чыгып,
Кире кайткан куркып бүредән...
Шушы төнне Гыймади, эт өрсә дә,
Тәмле йокысыннан тормаган,
Шәкүр карак аның абзарыннан
Күк айгырын кереп урлаган...
Ләкин
Шушы төнне Зөбәйдәнең
Кайдалыгын беркем белмәгән,
Карт анасы ярты төнгә кадәр
Ни өчендер аны эзләгән...

[1] *Затып* — озатып.

Тик
Мәхмүт торган йортта
Бер студент
Ябылмыйча калган ишектән
Зөбәйдәнең:
— Мәхмүт, бәгърем, җибәр! — дигән
Ярты елау тавышын ишеткән...

Айлар үткән...
Тәңкә карлар ява,
Ап-ак карлар,
Ә Зөбәйдә эшкә бармады,
Керфекләре җиргә карый аның,
Наборщигы аны алдады...

III. Зөбәйдәнең хаты

«...Алдарсың дип сине белмәдем;
Вәгъдә бирдең,
Өзелеп көттем сине...
Ә син?..
Нигә инде шулай килмәдең?
Тагын язам,
Сиңа бер сүзем бар,
Бик кирәкле... кичкә кил әйдә.
Килерсеңме?
Көтәм.
Ком. сәламе белән: Зөбәйдә...»

Ләкин ул килмәде.
Аңа нәрсә,
Эшлисе эш күптән эшләнгән,
Алма кебек матур Зөбәйдәбез
Үзе сөйгән, үзе...
Көчләнгән...

IV. Хатынсыз ай

Ә ай күктә һаман сүгенеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк,
Ай ялгыз ул,
Төн үткәрсен соң ул кем белән...

Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төндә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли...
Ә ай көлә,
Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә,
Өйләнәлми калган,
Шуның өчен
Кайгы нуры күренә йөзендә...
Зөбәйдәнең әние күлмәк тегә,
Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен;
Зөбәйдәнең сеңле уйнап йөри,
Абау матур!
Күзем тимәсен...

V. Зөбәйдә һәм ай

Ай да ялгыз,
Безнең Зөбәйдә дә...
Ул тын гына
Айга карап килеп утырды,
Һаман көлеп йөргән зур күзләрен
Канлы яшьләр белән тутырды...
— Их, син, яшьлек,
Их, син, тиле яшьлек!
Шундый кыска булып тоелдың,
Кичен чәчәк аткан булдың,
Ә таңында...
Ә таңында инде коелдың...
Зөбәйдә...
Ул тиздән ана булыр,
Доктор шулай диган аңарга...
— Йөрәк,
Ян син, ян син, йөрәк,—
Кан бирелгән сиңа янарга!..
Ә син кайда, ата булыр кеше?
Шулмы булды синең сөюең,
Шулмы инде синең:
Ирекле сөю,
Яңа тормыш диеп йөрүең?..

Кичтә янган утлар таңда сүнсә,
Кичен тагын алар кабына,
Зөбәйдәбез бүген бала көтә,
Үзе наборщигын сагына...
Менә баласына күлмәк тегә,
Чәнчеп-чәнчеп ала инәсен...
Зөбәйдә!
Әйт, кемне болай,
Кемне болай сагынып көтәсең?

VI. Ачулы җил

Урам буйлап җил бер исрек белән
Гулять итеп кайтып килә иде...
Ә Ибәй карт,
Юньсез,
Көрәк тотып,
Йорт алдында карлар өя иде.
— Бу ни хәл бу? — диде җил күрде дә,—
Нәрсә дисең инде кешеләргә,
Ачу килә
Шундый эшне күреп,
Кулым күтәрелми эшләргә! —
Мин тау өеп китәм,
Ә кешеләр
Чыгалар да шуны көриләр,
Мин матурлыйм,
Алар чыгып таптап йөриләр...
Тфү! —
Диде,
Үзе зур урамнан
Эре-эре кырга атлады,
Ачу итеп кырдан карлар ташып,
Бөтен урамнарны каплады...
Таң булуга урам көрәүчеләр
Җилнең бабаларын сүктеләр,
Ә шул төнне безнең Зөбәйдәне
Больницага алып киттеләр...

....

Кайда син, әй, ата булыр кеше,
Шулмы инде синең сөюең,
Шулмы инде синең Зөбәйдәгә:
— Комсомолкам, бәгърем! — диюең?

VII. Мәхәббәтнең соңы

Кан эчендә яткан Зөбәйдәне
Ак мендәргә китереп салганнар,
Күз төпләре күм-күк,
Иреннәре —
Кара күмер булып янганнар...
Ул селкенми ята,
Аны әллә нәрсә
Басып торган кебек сизелә...
— Тукта, елау таушы килә,
Бала елый...
Кемнең баласы?
Ник ул елый?.. Ә ник мендәреннән
Башын күтәрә алмый анасы?..
Тукта...
Нигә авыр болай?
Әллә нәрсә...
Күз аллары шундый караңгы...
Ул кузгалды,
Кинәт авыр гына:
— Күрсәтегез,— диде,— баламны!
....
Ана —
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга;
Хатыннарның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке ана булуда!..

Бала елый,
Матур йорт эчендә
Яшь бер бала елый,—
Кемнең баласы?
Ник ул елый?
Ә ник күрер өчен
Килми аның сөйгән атасы?..

Тышта соңгы карлар ява,
Алар инде
Кышкы карлар кебек туңмыйлар.
Тышта язгы җилләр исә,
Алар инде салкын булмыйлар...
Карлар эрер,
Җылы тиргә батып,
Кар астыннан чыгар май ае;
Ә урамда, язның килерен белми,
Елап утыра песи малае...
— Елама юкка,
Дөнья матур нәрсә,
Әйдә, миндә кунак булырсың,
Дуслыгымны аңлап алдашмасаң,
Урлашмасаң миндә торырсың...
Анаң, тәүфыйксызны, ташлап киткән,
Атаң, явыз, сине белми дә.
Кардәшләрең дә юк,
Шәһәр шул бу,
Белмисеңдер монда кемне дә?
Шулай, дустым!
Сезнең песи халкы
Балаларын ташлап китәләр;
Песи халкы гына түгел,
Этләр, аюлар да,
Кешеләр дә шулай итәләр...
Ярый әле сезнең песи малайлары
Ни булса да тере туалар,
Ә кешеләрнең күбесе,
Бала табудан куркып,
Корсакта чакта ук буалар.
Әйдә киттек!
Минем яшь чагымда
Песиләрдән дуслар күп иде,
Син дә шулай кунак булырсың,
Язга кадәр миндә торырсың.

....

Бала елый,
Матур йорт эчендә
Яшь бер бала елый...

Кемнең баласы?
Ник ул елый?
Ә ник күрер өчен
Килми аның сөйгән атасы?..
— Атасы аның, бәлки, мәңге килмәс,
Улын, бәлки, мәңге күрә алмас...
Улы үсәр, җитез, матур булыр,
А, юк!
Ата күңле күрми түзә алмас!
Тукта!
Ишек ачылып бераү әкрен генә
Зөбәйдәгә таба атлады;
Күз яшьләре җиңде аны,
Кинәт борылды да
Йөзен кулы белән каплады:
— Зөбәйдә, син кичер мине! — диде,
Үзе Зөбәйдәнең
Күкрәгенә килеп ташланды...

Алар килештеләр...
Ә биш көннән
Загс белән тормыш башланды...

Ә ай күктә һаман сүгенеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк, улы да юк,
Төн үткәрсен соң ул кем белән?..
Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төнлә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли.
Ә ай көлә,
Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә;
Өйләнәлми калган, шуның өчен
Кайгы нуры күренә йөзендә...

1927

Кәрим Тинчурин
(1887—1938)

АМЕРИКАН[1]

КОМЕДИЯ

Дүрт пәрдәдә

УЙНАУЧЫЛАР:

Апуш, Касыйм, Искәндәр, Самат, Зәйнәп, Нурия — студентлар.

Муса — электәге җәмәгать хадиме[2], татар киеменнән, жилет кигән.

Шәехмирза — элекке адвокат.

Габдуллаҗан — спекулянт.

Сәлим — тарихчы.

Насих Николаевич — мирза.

Сәлимгәрәй — электәге полиция чиновнигы.

Дилбәр — Мусаның кызы.

Мәйсәрә — Габдуллаҗанның кызы.

Разия — Габдуллаҗанның хатыны.

Нигъмәт — карт интеллигент.

---

[1] Беренче пәрдәнең эчтәлеге генә бирелде, калган пәрдәләр тулысынча алынды.

[2] *Хадим* — хезмәтче.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Югары уку йортының бер төркем студенты тулай торакта яши. Көндәлек мәшәкатьләр арасында алар алдына бер сөаль килеп баса: тарих буенча студентларның фәнни түгәрәген ничек яшәтергә, ничек кызыклы итеп алып барырга? Алар сәүдәгәр Габдуллаҗан кулында халыкның борынгы тарихына бәйле бик кыйммәтле материаллар саклануын беләләр. Ләкин аларны ничек кулга төшерергә? Уйлана торгач, Искәндәр исемле студент хәйләсен таба...

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртача җыйналган кабинетка охшашлы бүлмә.

I. Муса ялгызы.

Муса *(ишектән карап)*. Анасы, анасы, пәрәмәчне карап пешерегез. Итен, маен кызганмагыз. Кунак ни җитте кеше түгел, Америка профессоры. Ишетегез, пөхтә булсын. Хуш. Бу профессор Американдан нинди максат белән килде икән? Хөкүмәт эшләре беләнме икән әллә? Юк, юк, тәгаен өйләнергә килгәндер. Америка никадәр шәп булса да, тәрбияле милли кызлар юк шул анда. Бу инде үзе татар булгач, татар кызына, ягъни милли туташка өйләнүне тиеш тапкандыр, күрәсең. Туп-туры миңа килүе мәсьәләне тагын да мөһимләштерә. Шулай ук минем шөһрәтем Америкага кадәр барып җиткән микәнни? Хәер, гаҗәп түгел. Җитсә дә җитәр шул. Милләт өчен кулдан килгән кадәр эшләдек инде, Алла кабул гына итсен инде. Большевиклар гына кадерне белмәделәр. Әнә укыган, тәрбияле, абруйлы кеше Америкадан торып кадеребезне белгән. Ай, бу мәдәният бик зур нәрсә шул. Хуш. Бу хакта кызым белән сөйләшеп алырга кирәк. Хатын-кыз бит ул ахмак була. Дилбәр, Дилбәр кызым, монда чык әле. Әгәр дә эшләр теләгәнчә барып чыкса, Аллаһныкын белмәссең. Баба булып Америкага да барып куярсың шул. Әйе, әйе, һәр эш Хода кулында инде.

II. Муса, Дилбәр.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?

Муса. Кызым, якынрак кил.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?

Муса. Озакламыйча, кызым, безгә Америка профессоры киләчәк.

Дилбәр. Беләм, әткәй. Тиз килерме икән соң?

Муса. Берәр сәгатьтән килергә тиеш. Кызым, профессор хәзрәтләре өйләнмәгән кеше икән.

Д и л б ә р. Өйләнмәгән?!

М у с а. Әйе, өйләнмәгән. Монда килүеннән максаты тәрбияле, укыган милли туташка өйләнү булса кирәк. Менә инде башлап безгә кунак булып килүе дә сер булырга кирәк.

Д и л б ә р. Сер?!

М у с а. Әйе, сер.

Д и л б ә р. Соң ул...

М у с а. Сабыр, сабыр. Ул сер, минем уйлавымча, син булырга кирәк. Әгәр дә күңеленә ошасаң, бәлки...

Д и л б ә р. Әткәй, син мине оялтасың.

М у с а. Мондый чакта ата белән кыз арасында оят булмый. Мин бит, ахры, синең бәхетең өчен тырышам. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, бәлки, киявебез профессор белән миңа да Америкага китәргә туры килер. Менә шуның өчен профессор алдында үзеңне яхшы тот. Теге Петр Иванич кызыннан өйрәнгән тәртипләреңнең барысын да яса. Ул татар булса да, Америка зыялысы инде. Күрешкәндә ничек әле, болай итәсезме әле? *(Посып күрсәтә.)* Шулай посып күрешерсең. Йә, эшләп кара, кара әле.

Д и л б ә р реверанс ясый.

Яхшы, күркәм чыга икән. Башыңны бераз күтәрә төш. Йә, яңадан эшләп кара.

Д и л б ә р реверанс ясый.

Посканда менә шулайрак поссаң, матуррак чыгар төсле *(посып күрсәтә)*. Йә, тагын бер посып күрсәт.

Д и л б ә р реверанс ясый.

Әһә, бәрәкалла, яхшы, күркәм, милли булып чыга. Сөйләшкән чакта шулай кулларыңны күкрәгеңә куеп тот. Теге сурәттәге кызлар төсле. Күзләреңне зур итеп ачып, югарыга карап тор. Милли булсын. Ул, бердән, тәгъзыйм[1] галәмәте, икенчедән, килешле булып чыга. Күлмәгеңнең иң модныен ки. Хәер, өстеңдәге ярарлык икән. Энҗе, алтыннарыңны барысын да ас, ислемаеңны кызганма. Тешләреңне яхшылап щеткалап ю. Ис килмәсен. Алай болай... эһем... эһем...

Звонок.

Чү, килделәр бугай. Бар, чакырмыйча чыкма! Милли гадәтләреңнең барысын да кылырсың. Бар, бар!..

Д и л б ә р чыга.

[1] *Тәгъзыйм* — олылау, хөрмәтләү.

III. Муса, Искәндәр һәм Апуш.

Апуш. Профессор хәзрәтләре боердылар.

Муса. Хуш киләсез. Мәрхабә, таныш булыйк. Муса Мәхмүди — сабыйк[1] җәмәгать хадиме.

Искәндәр. Чикаго дарелфөнүненең профессоры. Нью-Йорк академиясенең әгъзасы, профессор Булат Сон.

Муса. Сезне ханәбездә күрү белән бәхетлебез, әфәндем. Боерыгыз! *(Урын күрсәтә.)*

Искәндәр. Рәхмәт. *(Төртә.)* Гафу итегез, мин шулай.

Муса. Әйе, әйе, тәкәллефсез булуыгызга бик шат... Профессор хәзрәтләре, сез безнең шәһәребездә озак калырга уйлыйсызмы?

Искәндәр. Эшләрем тәмам булганчы калырмын дип уйлыйм.

Муса. Гафу итегез, хөкүмәт эшләре беләнме, әллә?..

Искәндәр. Һәм хөкүмәт, һәм фән, һәм тарих, һәм... һәм...

Муса. Бәрәкалла, бик гүзәл, бик күркәм.

Искәндәр. Муса әфәнде, исемегез шулай шикелле.

Муса. Бәли, бәли.

Искәндәр. Муса әфәнде, мин сезне дә, гаиләгезне дә Америкада чагында ишетеп белгән идем.

Муса. Ә, әйе, бик рәхмәт. Мин бик шат. Мин үзем дә сез килер алдыннан гына шулай уйлаган идем.

Искәндәр. Муса әфәнде, мин сезнең әткәгезне дә беләм. Ягъни ишетеп беләм.

Муса. Әйе, әйе, мәрхүм шактый мәгълүм кеше иде.

Искәндәр. Мин сезнең белән якыннан дуслашасым килә. *(Торып кулын сузып төртә.)* Гафу итегез!

Муса. Бик рәхмәт. Мин бик шат.

Искәндәр. Шәһәрегездә Габдуллаҗан исемле спекулянт бар икән.

Муса. Әйе, бар. Карун дәүләтенә малик[2] кеше инде. Бик саран, ахмак бәндә.

Искәндәр. Менә шул Габдуллаҗан спекулянтта Арыслан ханнан калган тарихи ярлыклар бар икән. Сезнең шул хакта хәбәрегез юкмы?

---

[1] *Сабыйк (сабикъ)* — әүвәлге, электәге.

[2] *Малик* — милек иясе, ия, хуҗа.

Муса. Әйе, бар дип әйтәләр. Ләкин үз күзем белән күргәнем юк. Ул аларны һичбер кемгә күрсәтми.

Искәндәр. Шулай дигәннәр иде. Хәер, ул мәсьәлә минем өчен мөһим түгел. Минем башка зуррак эшләрем бар. Муса әфәнде, бер стакан кайнар су булса, мин бик шат булыр идем.

Муса. Бәлки, чәй эчәрбез?

Искәндәр. Лимон белән булса, мөмкин.

Муса. Була, була. Рәхим итегез, менә бу әфәнде сезне пәрәмәч ярата дигән иде.

Искәндәр. Аһ, бик, бик!.. Беләсезме, Муса әфәнде, минем иң яраткан ашым пәрәмәч инде. Һичбер риясыз, бик яратам. Шул яраткан ашымны егерме ел ашаганым юк. Россиягә килгәч тә берьюлы егерме пәрәмәч ашап бетерергә ант иткән идем. Үзегез уйлап карагыз. Егерме ел бит, егерме ел. Сөйгән ашым, милли пәрәмәчебезне ашаганым юк.

Муса. Сез Америкада егерме елдан бирле торасызмыни?

Искәндәр. Әйе, егерме ел. Мин унбиш яшемдә Америкага барган идем.

Муса. Кыяфәтегез, тфү, тфү, күз тимәсен! Бик яшь әле.

Искәндәр. Без, америкалылар, тиз картаймыйбыз. Һи-һи-һи... *(Төртә.)* Гафу итегез! Әйе, гимнастика белән бик нык маташабыз.

Муса. Сез бик күңелле кеше икәнсез, профессор хәзрәтләре. Гафу итегез, мин хәзер. *(Чыга.)*

Апуш. Сайрый беләсең, малай. Көлмичә чыдап булса ярар иде. Син ул корсакка төртүеңне куй. Килешми...

Искәндәр. Тес-с-с!..

Муса керә.

Муса. Менә, рәхим итегез, чәй. Сез, бәлки, кофе яисә какао тели торгансыздыр?

Искәндәр. Юк, рәхмәт. Мин үзебезнең Россиянең милли чәен сагындым.

Муса. Бәрәкалла, бәрәкалла. Газиз милләтебезне онытмаган икәнсез. Ә безнең эшләр монда тәмам чуалды. Бу әфәнде, шаять, үз кешебездер?

Искәндәр. Үз кешебез, сез аңар ышаныгыз.

Муса. Афәрин, афәрин. Дөньяда үз акылларында калган кешеләр дә бар икән әле.

Искәндәр. Ул да милли пәрәмәчебезне бик ярата икән.

Муса. Ә, әйе, пәрәмәч. Гафу итегез! *(Чыга.)*

А п у ш. Пәрәмәче җитәрлек булырмы икән? Бик ашыйсы килә бит, малай. Тамакны туйдыргач та тизрәк моннан сызарга кирәк.

И с к ә н д ә р. Тес-с-с!..

М у с а яңадан керә.

М у с а. Менә инде милли пәрәмәчебез... Рәхим итегез!

И с к ә н д ә р. Әйе, милли пәрәмәч. Мин инде тансыкка күбрәк ашармын. Сез гаепләмәгез. Апуш әфәнде, рәхим итегез. Миңа инде үз өемдәгечә иркенләп утырырга рөхсәт итегез. Сез миңа, Муса әфәнде, бик ошадыгыз. Пәрәмәчегез дә бик ошады.

М у с а. Рәхмәт илтифатыгызга. Сез дә миңа бик ошыйсыз. Никадәр күп ашасагыз, шулкадәр безне якын күргән булырсыз. Җитешегез.

И с к ә н д ә р. Рәхмәт.

М у с а. Сез Американың кайсы җиреннән, шәһәреннән сәфәргә чыктыгыз?

И с к ә н д ә р. Пәрәмәч шәһәреннән. Ә... ни, Чикаго шәһәреннән.

М у с а. Һавалар ничек калды?

И с к ә н д ә р. Яхшы.

М у с а. Сәяси хәлләр ничек?

И с к ә н д ә р. Яхшы.

М у с а. Профессор хәзрәтләре, бу бездәге Советлар хакында Американың фикере ничек?

И с к ә н д ә р. Төрлечә.

М у с а. Тиз бетәрләрме икән инде?

И с к ә н д ә р. Нәрсә?!

М у с а. Җитешегез, җитешегез!.. Ә, монда беткән икән. Кайнарын китерик.

И с к ә н д ә р. Рәхим итегез, бигрәк ләззәтле пәрәмәчләр икән.

М у с а. Милли нәрсәләр ләззәтле була инде ул, профессор хәзрәтләре.

И с к ә н д ә р. Шулай була икән.

М у с а чыга.

А п у ш. Ну, пәрәмәче, малай! Тагы бер егермене сыпырырмын, ахрысы. Әллә кунарга да калыйкмы икән? Яхшы кешегә охшый.

И с к ә н д ә р. Тес-с-с!..

Муса керә.

Муса. Менә кайнары да булды. Зинһар, сез ашый күрегез инде, ашагыз.

Искәндәр. Рәхмәт.

Муса. Профессор хәзрәтләре, шәһәребезнең могтәбәрләреннән сезнең белән танышырга теләүчеләр бар иде. Әгәр сез кабул итсәгез, бүгенге кичәбез бер гыйльми кичә төсен алыр иде.

Искәндәр. Комиссарлармы?

Муса. Юк, юк. Аларны без, әһем, әһем... Хода сакласын! Ул халык белән Хода каберләрне янәшә итә күрмәсен инде. Мин әйткән кешеләр — игътибарлы, абруйлы, чын кешеләр. Шәһәребезнең голямасы[1], могтәбәр милли байлары.

Искәндәр. Ярый, бик яхшы. Мин каршы түгел. Ләкин бүген кабул итә алмыйм. Шулай да иң якын һәм иң могтәбәр кешеләрегездән бер-икесен кабул итәрмен.

Муса. Ярый, ярый. Иң могтәбәрләреннән бер-икесен генә чакыртырмын. Әйе, алар хәзер килеп җитәрләр. *(Чыга.)*

Искәндәр. Ул бозау башларның эч серләрен белергә кирәк. Мин алар белән сөйләшкәндә, күз алдымда торма. Теге Габдуллаҗан бай нигә озак килми икән? Соң син аңар әйттеңме?

Апуш. Әйткән идем... Пәрәмәче җитәрме икән, малай?

Искәндәр. Җитмәсә, милли кабартмасын сорарбыз.

Муса керә.

Муса. Гафу итегез, сезнең чәйләрегез беткән икән. *(Стаканнарны алып чыга.)*

Апуш. Каеш кыса башлады, малай. Мин бу бичара мәхлукны кызгана да башладым инде.

Искәндәр. Зарар юк, зур эшләр корбансыз булмый.

Муса керә.

Муса. Рәхим итегез, профессор хәзрәтләре. Профессорлык хезмәтен күптәннән алып барасызмы?

Искәндәр. Биш елдан бирле.

Муса. Шактый бар икән. Бер дә ишетелмәгән иде.

Искәндәр. Бу соңгы елларда хәбәрләшү мөмкин түгел иде бит.

---

[1] *Голяма* — галимнәр.

Муса. Дөрес, дөрес, мөмкин түгел иде. Нинди фәннәрдән дәрес бирәсез?

Искәндәр. Һәммәсеннән дә.

Муса. Америкада сездән башка тагын мөселман профессорлары бармы?

Искәндәр. Хәзергә юк әле. Бер-ике елдан булырлар. Бер үзбәк, бер төрек, яңадан бер татар профессорлыкка хәзерләнә калдылар. Моннан сау-сәламәт кайтып булса, мин аларны профессор итәргә тырышачакмын.

Муса. Тырышыгыз инде, профессор хәзрәтләре, тырышыгыз, милләтебез профессорларга бик мохтаҗ... Ә-ә... Мин сезгә кайнарын китерим. *(Чыга.)*

Апуш. Туям бит, малай.

Искәндәр. Алаймы, әһе.

Муса керә.

Муса. Менә кайнарыннан рәхим итегез. Профессор хәзрәтләре, сезнең ата-анагыз исәннәрме?

Искәндәр. Мәрхүмнәр.

Муса. Нинди кәсептәге кешеләр иде?

Искәндәр. Әткәй мәрхүм инглиз флотында капитан иде. Ә әнкәй, әнкәй... Әнкәй әткәйнең хатыны иде.

Муса. Бик яхшы, бик яхшы, сезнең асылыгыз зат каннардан икән.

Искәндәр. Әйе.

Муса. Үзегезнең ничек, рәфикагыз бармы?.. Ягъни хатыныгыз бармы?

Искәндәр. Юк.

Муса. Туры килмәдемени?

Искәндәр. Әйе, чөнки, чөнки Америкада безнең татарлардан зыялы гаиләләр юк. Ә мин үземә милли рәфика, ягъни татар кызын рәфика итәргә ант иткән идем. Үзегезгә билгеле, антны бозу гөнаһ. Аннан соң мәрхүм әткәй белән әнкәйнең васыятьләре дә шулай иде. Хатының милли булсын, дип кычкырып үлделәр.

Муса. Бәрәкалла, бәрәкалла. Инабәтле[1] нәселдән икәнсез. Ә менә бездә сез эзләгән, ягъни сез теләгән милли туташлар бар инде.

---

[1] *Инабәтле* — ышанычлы.

Искәндәр. Тәрбияле, милли туташларга кияүләр дә күптер инде.

Муса. Юк шул, юк. Бирәү дә калмады, чөнки могтәбәр гаиләләрнең егетләре чехлар, колчаклар белән китеп беттеләр. Хәзерге вакытта бездә яхшы игътибарлы кияүләргә ихтыяҗ бик зур. Әйе, ифрат зур инде. Рәхим итегез, пәрәмәчтән җитешегез! Ә, профессор хәзрәтләре, минем бердәнбер кыз балам бар. Әгәр дә теләсәгез, мин аны сезнең белән таныштырыр идем. Бик тәрбияле бала инде. Профессорларга ихласы бик зур. Шигырьләр язарга да булдыра. Аш-суга да осталыгы бар.

Искәндәр. Шулаймы? Чыгар монда. *(Төртә.)* Ә... Гафу. Мин бик шат булыр идем. Милли туташларыбызның йөзләрен күрмәгәнгә егерме ел булды бит инде.

Муса. Алай булса мин хәзер. Хәзер... Дилбәр, Дилбәр, кызым, монда чык әле. Хиҗапны[1] ташлату турында бик каты көрәштем. Аны сезгә һәркем дә әйтер. Мин башта ук, туганда ук хиҗапка каршы идем. Бала чагымда ук әнкәй мәрхүмәнең яулыгын башыннан тартып ала торган булганмын. Һи-һи-һи!..

Искәндәр. Милләтебез сезнең шикелле зыялы аталар белән мактана торгандыр.

Дилбәр керә.

IV. Әүвәлгеләр һәм Дилбәр.

Дилбәр. Нәрсә, әткәй?.. Аһ, пардон, мусио, гафу итегез. *(Реверанс ясый.)*

Муса. Профессор хәзрәтләре, минем Дилбәрем шул инде, танышыгыз.

Дилбәр реверанс ясый.

Искәндәр. Мин бик шат. *(Дилбәргә төртә.)* Гафу итегез, туташ, мин шулай инде.

Дилбәр. Аһ, пардон, мусио.

Муса. Әйе, әйе, кызым, профессор хәзрәтләре сөйгән кешесенә шулай төртергә ярата икән.

Дилбәр. Аһ. *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Муса әфәнде, сезнеңчә ничек?

Муса. Нәрсә, профессор хәзрәтләре?

Искәндәр. Минемчә, шундый милли туташлары булган милләт яшәргә тиеш.

---

[1] *Хиҗап* — пәрәнҗә, пәрдә.

Муса. Яшәсен милләт!

Дилбәр. Яшәсен милләт! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Мадемуазель, Дилбәр туташ, утырыгыз!

Дилбәр *(реверанс ясый)*. Мерси...

Искәндәр. Сез, туташ, нәзакәт һәм спайлыгыгыз белән безнең Америка ледиләрен оялтачаксыз. *(Тәртә.)* Гафу итегез!

Дилбәр *(реверанс ясый, утыра)*. Мерси.

Муса. Без инде, профессор хәзрәтләре, азрак кызыбызга французча да укыттык. Кызым, хәерле көн французча ничек була?

Дилбәр. Бон жур, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Хәерле иртә ничек була?

Дилбәр. Бон матин, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Хәерле кич ничек була?

Дилбәр. Бон суар, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Мин Американы яратам ничек була?

Дилбәр. Жим бүлә Америк.

Искәндәр. А-а-а! Французчаны бик һәйбәт беләсез икән. Мин Америкада чакта үз илебездә милли туташларыбыздан французча белүчеләр булыр дип һич уйламаган идем, милләтебез бик тәрәкъкый иткән икән.

Муса. Тырыштык инде, профессор әфәнде. Кулдан килгән кадәр балаларыбызны милли рухта тәрбия итәргә тырыштык инде. Дөрес, бездә бик зур приданлы бай кызлары да бар, ләкин милли тәрбияләре бик зәгыйфь шул. Яхшы милли тәрбия байлыктан артык бит, профессор хәзрәтләре. Без инде кызыбызга французча да, русча да укыттык. Шуның белән бергә милли музыка белән дә таныштырдык. Кызым, Дилбәр, профессор хәзрәтләренә берәр милли көй җырлап алмыйсыңмы?

Искәндәр. Минем милли көй ишетмәгәнгә нәкъ егерме ел.

Муса. Кызым, ишетәсеңме, профессор хәзрәтләре нәрсә ди? Җырла, җырла, кызым, назландырма!

Дилбәр. Оялам, әткәй. *(Реверанс ясый.)*

Муса. Җырла дигәч җырла. Алай карышырга ярамый. Тәрбиясезлек була... «Әллүки, бәллүки» көен җырла. «Әллүки, бәллүки»не җырла.

Дилбәр «Әллүки» көенә тамак төбеннән европача тавышлар чыгарырга тырышып җырлый. Җырлап бетергәч, һәммәсе дә кул чабалар. Дилбәр кат-кат реверанс ясый.

Искәндәр. Үзебезнең милли көебезне милли туташыбыз авызыннан ишеткәндә, Европа, Американың опералары юк булып калдылар. Яшәсен милли көй! «Әллүки, бәллүки!»

Муса. Яшәсен милләт!

Дилбәр. Яшәсен милләт! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Бик һәйбәт җырлый иде, бүген бераз кабзыять[1] алган булырга кирәк. Ун яшеннән бирле балалар кичәсендә җырлап килә. Кызым, профессор хәзрәтләренә пианинода «Галиябану»ны уйнап күрсәт әле.

Искәндәр. Пианинода уйный беләсезме, туташ? *(Тәртә.)*

Дилбәр. Аh, пардон, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Муса. Белә, белә, бик һәйбәт, моңлы итеп уйный. Йә, кызым, назланма, белгәнне күрсәтү гаеп түгел. Шулай бит, профессор хәзрәтләре? Белгәнне күрсәтү гаеп түгел бит?

Искәндәр. Бик дөрес. *(Тәртә.)* Ә гафу... Безнең Америкада белмәгәнне күрсәтү дә гаеп түгел.

Муса. Әнә ишетәсеңме, профессор хәзрәтләре нәрсә ди?

Дилбәр. Нәрсә уйныйм соң? *(Реверанс ясый.)*

Муса. «Галиябану»ны, ул шәп чыга.

Дилбәр бер бармак белән «Галиябану»ны ялгыш-йолгыш уйнап чыга. Кул чабалар.

Искәндәр. А-а-а... Милләтебезнең, хосусән милли туташларыбызның шул егерме ел эчендә тәрәккъый итүләренә хәйран калам. Яшәсен пианино!

Муса. Яшәсен милләт!

Дилбәр. Яшәсен милләт! *(Һәр «яшәсен» дигәндә реверанс ясый.)*

Искәндәр. Яшәсен милли туташларыбызның имән бармаклары! *(Тәртә.)*

Барысы. Яшәсен!..

Дилбәр һаман реверанс ясый.

Муса. Шулай булгач, милләтебез бетмәс бит, профессор хәзрәтләре?

Искәндәр. Юк, һич бетмәс. Бетәргә рөхсәт юк. Әгәр дә милләтебез тагын биш-ун ел шул юлыннан аерылмыйча барса, һич шөбһәсез Американы узып китәчәк.

Муса. Американы дисезме?

---

[1] *Кабзыять* — каушау.

Искәндәр. Әлбәттә, һич шөбһә юк. Чөнки бездә аларда булмаган хосусыятьләр[1] бар. Милли пәрәмәчебез бар, милли «Галиябану»ыбыз бар, милли туташларыбыз бар, милли татарларыбыз бар. Кирәк-яракның һәркайсы бар. Ә аларда ул юк.

Муса. Аларда юк икән, профессор әфәнде?

Искәндәр. Аларда машина, автомобиль, һөнәрдән башка һичбер милли нәрсәләре юк.

Муса. Ишетәсеңме, кызым? Америкада юк, ди. Булмаса булган икән инде, профессор хәзрәтләре, Дилбәр туташтан милли бию биеп алуын үтеник.

Искәндәр. Милли бию дә беләсезмени?

Дилбәр. Уй, мусио!.. *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. А-а!.. *(Төртә.)*

Дилбәр. Аһ, пардон, мусио!..

Муса. Бик матур бии. Ун елдан бирле балалар кичәсендә биеп килде. Мактап гәзиткә дә яздылар. Бик һәйбәт бии. Кызым, кайда, биеп күрсәт. Профессор хәзрәтләренең күрәсе килә.

Искәндәр. Әйе, әйе, мин бик шат булырмын. Егерме елдан бирле милли бию күргәнем юк бит.

Муса. Ишетәсеңме, кызым, егерме елдан бирле, ди.

Дилбәр. Мин музыкасыз бии алмыйм. *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Менә Апуш әфәнде уйнар. Ул аз-маз шалтыраткалый бугай.

Муса. «Әпипә»не биесенме, «Әтнә»неме? Һәр икесен дә булдыра.

Искәндәр. Җаны эстәгәнен биесен.

Муса. Кызым, Әпипә, Әпипә!.. Йә, йә, бас, кызым Әпипә, син басмасаң, мин басам. *(Бию хәрәкәтләре ясый.)*

Дилбәр «Во саду ли» рәвешенчә «Әпипә»гә бии. Кул чабалар.

Искәндәр. Яшә, мең, миллион мәртәбә яшә, Дилбәр туташ! Бу милли биюебезне карап торганда, Американың балеты бөтенләй юкка чыга... Тагы бер мәртәбә яшә! *(Кул бирә.)* Син яшәсәң... *(Төчкерә.)* Син яшәсәң... *(Төчкерә.)* Борынга әллә ни булган. *(Төчкерә.)*

Дилбәр. Томау төшкәндер, пардон. *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Шулайдыр. *(Төчкерә, төртә.)* Гафу итегез, мин әйтмәкче идем... *(Төчкерә.)*

---

[1] *Хосусыять* — үзенчәлелек, аерымлылык.

Муса Искәндәр тәчкергән саен ярхәмәкялла дип тора. Соңыннан үзе дә төчкерә башлый.

Дилбәр *(төчкереп)*. Пардон! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр. Бәрәкәт.

Шәехмирза керә.

V. Әүвәлгеләр һәм Шәехмирза.

Шәехмирза. Кайда ул Америка профессоры, кайда?

Муса. Кызым, ир-ат бар, чык!

Дилбәр чыга.

Акрын, акрын, зинһар, акрын!.. Безнең сабыйк милли адвокатларыбыздан Шәехмирза Юкабашов әфәнде.

Искәндәр. Мин бик шат. *(Кулын бирә һәм төртә.)*

Шәехмирза. Ай, профессор әфәнде, минем бүсерем бар. Шуның өчен үтенәм...

Искәндәр. Миллидер инде ул.

Муса. Әйе, әйе, ышанычлы милләтчеләребездән.

Шәехмирза. Мин сезнең белән танышуыма, профессор әфәнде, бик шат. Гафу итегез, профессор әфәнде, мин сезгә бер сөаль бирәм.

Искәндәр. Рәхим итегез.

Шәехмирза. Сез большевикмы, түгелме?

Искәндәр. Америкада большевиклар юк.

Шәехмирза. Мин сезгә ышанам. Шулай буласын алдан ук сизгән идем, профессор әфәнде. Сез моны күрәсезме? *(Тазын күрсәтә.)*

Искәндәр. Шактый шома икән.

Шәехмирза. Мине таз диләр, ә мин әйтәм, мин әйтәм, ул мәдәнилек, галимлек галәмәте, дим. Сезнең пеләшегез бармы, кайда?..

Искәндәр төртә.

Ай, бүсерем!.. Менә Муса әфәнде, һәрбер мәдәни, галим кешенең башы пеләш булырга тиеш. Ә сез таз дисез.

Муса. Сезнең пеләш түгел, таз, Шәехмирза әфәнде.

Шәехмирза. Юк, ялгышасыз, пеләш!

Муса. Шәехмирза әфәнде, юкка кызмагыз. Сезнең атагызның да башы таз иде. Тазлык сезнең нәселдән килгән милли авыру инде ул.

Ш ә е х м и р з а. Милли булса булыр, ләкин мин таз түгел, пеләш.

М у с а. Шәехмирза әфәнде, сез милли тазлыгыгыз белән мактанырга тиешсез. Әйе, әйе, сезнең җиде буынга кадәр бөтен нәселегез таз.

Ш ә е х м и р з а. Нәсел тикшерергә калганда, Муса әфәнде, сезнең хәлегез начаррак булачак. Сезнең нәселегездә бирән авыруы бар. Сезнең атагыз бирән авыруыннан үлгән. Анагызның уң аягы ярты аршын кыска булган.

М у с а. Син үлгәннәргә тимә, энем. Синең атаң — миссионер Ильминскийга милләтне саткан кеше.

Ш ә е х м и р з а. Ә син үзең? *(Колакка.)*

М у с а. Кем әйтә аны, кем әйтә?

Ш ә е х м и р з а. Мин әйтәм.

М у с а. Юк, сез аны әйтә алмассыз!

Ш ә е х м и р з а. Әйтәм һәм әйтермен!

М у с а. Юк, син исбат ит! *(Якасына ябыша.)*

Ш ә е х м и р з а. Тотма якадан.

И с к ә н д ә р *(араларына кереп төртә)*. Әфәнделәр, сез икегез дә бик маһир ораторлар икәнсез. Әгәр дә Америкада булсагыз, шөбһәсез, бөтен дөньяга мәшһүр милли адвокатлар булыр идегез.

Ш ә е х м и р з а. Аңар тагын адвокат булырга! Мөәзин дә була алмады. Ә мин, әфәндем, факультет ярым бетергән кеше. Бу большевиклар булмасалар, мин үзем дә әллә кайчан профессор булган булыр идем... Минем гыйльми әсәрләрем дә бар.

М у с а. Профессор хәзрәтләре, ышанмагыз, ялганлый! Аның әсәрләренә кибетләрдә тоз тутырып саталар. Ахмак ул.

Ш ә е х м и р з а. Ахмак кешенең пеләше булмый. Менә ул!

М у с а. Пеләш түгел ул, таз!

Ш ә е х м и р з а. Юк, пеләш!

М у с а. Ә мин әйтәм, таз!

Ш ә е х м и р з а. Ә мин әйтәм, пеләш!

М у с а. Юк, таз!

Бер-берсенә кизәнә башлыйлар.

И с к ә н д ә р *(урталарына кереп, төртеп)*. Әфәндедер, сабыр!

Ш ә е х м и р з а. Синеңчә, профессор әфәнденең дә башы тазмы?

М у с а. Син таз!

Ш ә е х м и р з а. Ә син хәйләләп Америка паегы ашадың. Өстеңнән язып кына бирәсе бар.

М у с а. Бар, бар, әйт. Ә мин синең чехларга шпионлык иткәнеңне әйтермен.

Г а б д у л л а җ а н керә.

VI. Ә ү в ә л г е л ә р һәм Г а б д у л л а җ а н.

Г а б д у л л а җ а н. Әссәламегаләйкем! Америка профессоры кайда?

М у с а. Габдуллаҗан бай, рәхим итегез. Менә ул!

Г а б д у л л а җ а н. Исәнме? Кая, бер дога кылыйк.

Дога кылалар.

Сез, профессор әфәнде, Америкадан кайчан чыктыгыз?

И с к ә н д ә р. Апрельдә.

Г а б д у л л а җ а н. Америкада сәүдә эшләре ничек бара?

И с к ә н д ә р. Шәп.

Г а б д у л л а җ а н. Ничек, профессор әфәнде, Америкада акча алтын, диләр?

И с к ә н д ә р. Көмеше дә бар.

Г а б д у л л а җ а н. Көмеше дә бар, диең?

И с к ә н д ә р. Бар.

Г а б д у л л а җ а н. Юлга расход күпме чыкты?

И с к ә н д ә р. Йөз доллар.

Г а б д у л л а җ а н. Безнеңчә күпме була инде?

И с к ә н д ә р. Шул чама.

Г а б д у л л а җ а н. Кара аны, бөтенләй юк икән! Өй җәмәгатьләрегез сау калдылармы?

И с к ә н д ә р. Сау.

Г а б д у л л а җ а н. Үзегезнең җәмәгатегез бармы?

И с к ә н д ә р. Юк.

Г а б д у л л а җ а н. Юк, диең?

И с к ә н д ә р. Әйе, юк.

Ш ә е х м и р з а. Профессор әфәнде, сез кайсы шәһәрнең университетында эшлисез?

И с к ә н д ә р. Вашингтонда.

М у с а. Чикагода түгелмени?

И с к ә н д ә р. Чикагода да, Нью-Йоркта да, мин бөтен Америка шәһәрләренең университетларында эшлим.

Ш ә е х м и р з а. Профессорлыкка бирәр буш урын юкмы?

И с к ә н д ә р. Кем өчен?

Ш ә е х м и р з а. Үзем өчен. Мин факультет ярым бетердем бит. Гыйльми әсәрләрем дә бар.

М у с а. Таз башың белән кайда үреләсең инде син! Аларның үзләрендә дә синең шикелле әрәмтамаклар бетмәгәндер әле.

И с к ә н д ә р белән Г а б д у л л а җ а н үзара сөйләшәләр.

Ш ә е х м и р з а. Син, шәкерт хәлфәсе, ике галим сөйләшкәндә арага ботыңны кыстырма, яме?

М у с а. Синең гыйлемеңә сукыр анаңнан башка кеше ышанмый бит.

Ш ә е х м и р з а. Ә син шәкерт, шифырт, күмер карагы!

М у с а. Минем, әлхәмделилла, ундүрт әсәрем бар. Ә син гомереңдә бер әсәр нәшер иттең, аңар да кибетләрдә тоз тутырып саталар.

Ш ә е х м и р з а. Ә синең әсәрләрең кәгазь капчык ясарга да ярамый.

И с к ә н д ә р. Муса әфәнде, бик рәхмәт хөрмәтегезгә, безгә рөхсәт итегез.

М у с а. Юк, юк, профессор хәзрәтләре. Кунып китәрсез. Сез бу дивананың сүзләренә карамагыз. Ахмак, психопат ул!..

Ш ә е х м и р з а. Менә, профессор әфәнде, шаһит булыгыз, менә бу шифырт, хәлфә кисәге мине ахмак, психопат дип тәхкыйрь итте[1]. Мин аны иртәгә үк 173 нче статья буенча судка бирәмен. *(Чыга.)*

И с к ә н д ә р. Мин, бәлки, иртәгә үк Америкада булырмын.

М у с а. Ничек, әллә аэропланыгыз да бармы?

И с к ә н д ә р. Әйе. Милли пәрәмәчегезгә, лимонлы чәегезгә рәхмәт. Әгәр дә Америкага барсагыз, миңа кунак булып төшегез. Ниопост урамында. 16818 нче йортта, 84 нче катта, 9987 нче номерлы фатирда, 1189 нчы бүлмәдә мин булырмын.

М у с а. Юк, юк, мин сезне кундырмыйча һич җибәрмим. Минем сезгә үзегезгә генә сүзләрем, йомышларым да бар әле.

Г а б д у л л а җ а н. Профессор әфәндене кунарга мин үземә алып барам.

М у с а. Юк, бай, кеше кунагын алай тартып алып китәргә хакыгыз юк. Профессор хәзрәтләре бездә кала.

Г а б д у л л а җ а н. Юк инде, Муса хәлфә, алай үзеңә генә бөтен нәрсәне йомарлап тотмыйлар аны. Профессор әфәнде

[1] *Тәхкыйрь итү* — хурлау, мыскыллау.

иртәгә китәчәк булгач, мин аны үземә кунарга алып барам. Әйдә, профессор әфәнде.

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Кеше кунагын алып китәргә хакың юк.

Габдуллаҗан. Бик бар, менә дигән хакым бар. Син милләт хадиме булсаң, мин дә милләт бае. Алай үз ягыңа гына каерма.

Искәндәр *(төртеп)*. Әфәнделәр, мин үз номерыма кайтам.

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Бәхил түгел, миндә каласыз.

Габдуллаҗан. Муса хәлфә, син алай әрсезләнмә. Профессор әфәнде бездә кунар. Бездә мунча да ягылды. Махсус заказ — милли кабартма да пешерелде. Мунчадан чыгуга пирәш тә бар. Әйдә, әйдә, профессор әфәнде. *(Култыклый.)*

Муса. Юк, юк, рөхсәт юк. Бездә кунар. *(Култыклый.)*

Габдуллаҗан. Юк, безгә барыр.

Муса. Юк, бездә калыр.

Габдуллаҗан. Тартма, киемен ертырсың.

Муса. Нигә кеше кунагын талап алып китәсең!

Габдуллаҗан. Әйдә, профессор.

Муса. Кал, профессор.

Габдуллаҗан. Әйдә безгә!

Муса. Җибәрмим!

Соңгы сүзләрне тәкрарлап Искәндәрне як-якка тарткалыйлар.

Пәрдә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мещаннарча җыйналган кунак бүлмәсе.

I. Разия, Мәйсәрә бүлмә җыештыралар.

Разия. Кызым, тузаннарны яхшы сөрттеңме икән инде? Кунак ни җитте түгел, ди, америкaн, ди. Алла сакласын, шакшы торалар дип, бөтен дөньяга яман атыбызны таратыр.

II. Разия, Мәйсәрә һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Кайда, буласызмы инде? Кирәк-яракның барысы да булдымы инде?

Разия. Булды, атасы, булды.

Габдуллаҗан *(үчекләп)*. Булды, атасы, булды, атасы. Мин сиңа талчукчы да, читекче дә түгел. Сүз сөйләшә белмисез.

Һи, атасы, атасы... Кайчан гына шул тупаслыкларыгыздан котылырмын икән инде. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс, дигәннәр, дөрес шул. Һичбер төрле итеп тәрәккый пәрвәрләндереп[1] булмый үзегезне. Кара аны, Разия ханым, актык мәртәбә әйтәм, әгәр дә тагы атасы дип эндәшкәнеңне ишетсәм, билләһи газим дип әйтәм, яңагыңнан утлар чыгарырмын!

Разия. Яшьлектә өйрәнмәгәч, картайгач булмый икән шул. Онытып җибәрәм.

Габдуллаҗан. Онытмаска кирәк. Шул бер-ике сүзне өйрәнмәскә миегез черемәгәндер бит. Тупас дисәң тупас инде шул безнең татар хатыннары.

Разия. Ярый инде, сиңа әйтәм, юк өчен...

Габдуллаҗан. Нәрсә, ничек, ничек?..

Разия. Юк, болай гына, атасы.

Габдуллаҗан. Ә?..

Разия. Бәйләнмә инде, сиңа әйтәм...

Габдуллаҗан. Сиңа әйтәм?! Сиңа әйтәм! Әллә син мине авылдан базарга кәбестә төяп килгән гыйбди дип уйлыйсыңмы?! Яңадан шул сиңа әйтәмеңне авызыңнан чыгарсаң, телеңне кадак белән тишәрмен. Гыйбди дисәң гыйбди. Мужик, надан... Бу кадәр замананы аңламаган, тәрәккыйгә күнмәгән хайваннар булырсыз икән! Ат кәмитендә бит аюны да сездән яхшырак, сездән тәрәккый пәрвәррәк итеп нәзакәткә өйрәтәләр. Бу кадәр аңгыра булырсыз икән. Кара аны, Разия ханым, бүген кешеләр алдына чыгасы булма! Синең өчен бөтен планнарымнан колак кагар хәлем юк. Әнә ашханәдә дөмегеп тор. Кеше итәргә, кеше арасына кертергә тырышмадым түгел инде. Алла кабул итсен. Ә син һаман үзеңнең мокытлыгыңнан аерыла алмыйсың.

Разия. Ярый инде, ярый. Юк өчен дөнья кубарма. Теләсә генә ни эшләт, исемең белән эндәшеп гөнаһлы булыр хәлем юк.

Габдуллаҗан. Теләсәң шайтан дип эндәш. Әнә шул сиңа әйтәм белән атасы дигәнеңне генә ташла!.. Сиңа әйтәм, атасы, имеш... Кәнәфи менә шунда торсын. Әйдә тот!

Разия кәнәфине күтәрә.

Бисмилла диген, юньсез.

---

[1] *Тәрәккый пәрвәр* — алга китү яклы, прогресс яклы.

Р а з и я. Әгузе билләһи минәшшәйтан ирраҗим, бисмилләһи...

Г а б д у л л а җ а н. Кирәкмәгәндә артыграк юмартланып та китәсең. Әгузесен калдырсаң да ярый. Һаман шул иске остабикәләр тәрбиясе бетми үзегездә. Келәмнәрне кактыгызмы?

Р а з и я. Кактык, ата... сиңа... ә...

Г а б д у л л а җ а н *(җиһазларны, келәмнәрне яулыгы белән сыпырып карый).* Кайда, кызым, одеколон чыгар. Бүлмәнең һавасын тазартырга кирәк.

М ә й с ә р ә чыгып китә.

Ходаның хикмәте, шул ат мае исеннән кабергә кермичә качып булмас, ахры. Әллә инде сезнең тәннәрегезгә үк сеңгән... Никадәр тәрәккый пәрвәрләнмә, ат мае һаман үз эшендә.

Р а з и я. Милли ис, атасы, милли...

Г а б д у л л а җ а н. Милли дип инде комганыңны да шкаф башына китереп куй. Һәр нәрсә үз урынында килешә. Ат мае белән милләт тәрәккый итми.

Р а з и я. Ай Алла, үзең әле үткән ел гына: яшәсен милли ат мае, яшәсен аның исе дип, мәйданда нотык сөйләгән идең.

Г а б д у л л а җ а н. Кайчан, кайчан?..

Р а з и я. Теге, урамга бүрәнәләр тезеп, сабитларга каршы...

Г а б д у л л а җ а н. Тик тор, чүпрәк баш! Шул башың белән сәясәт тикшергән буласың тагын. Аны аңлый белергә кирәк әле сиңа!

Р а з и я. Ярый инде безгә, үзебезчә, мөселманча булгач, маеннан да җирәнмибез, исеннән дә чиркәнмибез.

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, шапылдама!

М ә й с ә р ә керә.

III. Р а з и я, Г а б д у л л а җ а н һәм М ә й с ә р ә.

М ә й с ә р ә. Атакай, булды.

Р а з и я. Атакай дип кайдан шул мишәр сүзләрен уйлап чыгардыгыз?

Г а б д у л л а җ а н. Дөнья күрмәгәнлек адым саен килә дә чыга. Театрларга да йөртәм ләсә үзеңне. Бар икән дөньяда аңгыралар.

Р а з и я. Әти, әткәй дип эндәшү нигә ярамагандыр үзеңә!

Г а б д у л л а җ а н. Әти, әткәй дип без үстек. Безнең аталар-бабалар үскәннәр. Заманасында ул ярагап. Хәзер заманасы

башка. Тәрәккый заманы. Нигә соң син, чүпрәк баш, чыра якмыйсың? Нигә электрик ягасың, ә? Кызым, теге өрдерә торган машинаны да китер. Кая, кызым, кая, мондарак кил әле! Бу нәрсә?

Мәйсәрә. Борын, атакай.

Габдуллаҗан. Тимерче кебек корымланып йөрмәсәң ярамас дип куркасыңмыни, чүпрәк баш!

Разия. Иртәдән бирле тузан эчендә бит, атасы.

Габдуллаҗан. Сорамаганга җавап бирү ахмаклык була ул, Биби Разия ханым, белдеңме? Әллә инде бүлмә дә җыештырмас идегезме? Әнә Германиядә менә дигән кызлар, гимназия бетергән кызлар, асраулар эшен эшлиләр, ди. Бар, кызым, әйткәнне эшлә.

Мәйсәрә. Ни эшлим, атакай?

Габдуллаҗан. Соң мин ни эшләргә куштым?

Мәйсәрә. Әллә тагын, оныттым, атакай.

Габдуллаҗан. Соң синең башың кайда? Миең черегән нәрсә!

Мәйсәрә. Беләм, атакай, беләм, әфәндем. Машина. *(Чыга.)*

Габдуллаҗан. Менә, юньләп тыңлагач була ул.

Разия. Кем... ни... әй... әй...

Габдуллаҗан: Айлама миңа. Мин эт тә, ат та түгел. Исемем бар минем.

Разия. Ярый ла инде... Американнан башка мәҗлестә тагын кемнәр булыр?

Габдуллаҗан. Беренчедән, американ түгел. Америка профессоры. Ишетәсеңме? Америка профессоры, чүпрәк баш. Икенчедән, мәҗлес түгел, зыяфәт, банкет... Мәҗлес белән банкет арасында никадәр аерма булса, американ бае белән Америка профессоры арасында да шулкадәр үк аерма бар. Бу ниткән сүз аңламас аңгыра булдыгыз сез! Син төне-көне тәрәккый пәрвәрләнергә, җәмәгать эшләренә керергә тырышып йөрисең. Ә болар монда сине иске базга, кадимлеккә өстериләр.

Разия сүзсез генә төртә.

Нигә мина төртәсең? Телеңә җен кагылмагандыр бит?

Разия. Аптырадым инде мин, аптырадым. Атасы дисәң ярамый. Сиңа әйтәм дисәң ярамый. Әй дисәң ярамый. Төртсәң тагы ярамый. Соң нихәл кылыйм инде? *(Елый.)* Тәрәккый пәрвәрлегең үзеңә булсын, нигә чәнчелмисең шунда! *(Елый.)*

Габдуллаҗан. Елама, елама, миңгерәү тавык. Үзең өчен тырышам бит. Банкетны да белмәскә, оят бит. Безнеңчә зыяфәт, Европача банкет дип бер кешенең шәрәфенә багышлап ясалган мәҗлескә әйтәләр.

Разия. Манкитында да барыбер мәҗлестәге шикелле үк тыгынырга җыелалар бит.

Габдуллаҗан. Ярый, ярый... Дорфа сүзләреңне үзеңнең чүпрәк башлар мәҗлесләреңә калдыр. Банкетның хикмәтләрен аңларга шомарасың бар әле. Банкет ул зур нәрсә, бик зур.

Разия. Алай булгач, мунча ягарга да кирәк булыр инде.

Габдуллаҗан. Кирәк, кирәк, ләүкәләрен һәйбәтләп кайнар су белән сабынлап юыгыз, Разия ханым. Теге утынлыктагы иске китапларның тузаннарын сөртеп монда кертегез. Аннан соң малайны базарга җибәреп, бик күп итеп, татарча һәм русча гәзитләр, журналлар алдырып, өстәл өсләренә куегыз. Берәр заграничный сурәтле журналлар табылмасмы, барысын алсын, акча кызганмасын.

Разия. Ярый, ярый, алдырырбыз. Әрәм булмаслар. Бәлеш асларына җәяргә дә яраарлар. Юкса йортта им өчен бер кәгазь кисәге юк бит.

Габдуллаҗан. Телефон шалтырыймы?

Разия. Әллә тагын, кагылган кеше булмады.

Габдуллаҗан *(шалтыратып)*. Шалтырый ич.

Разия. Бу американ бигрәк расходлы кунак булды.

Габдуллаҗан. Расходсыз гына синең ул аңгыра тавыгыңны... Йә, ярый, ярый, бар, ашларыңны кара. Пәрәмәч, кабартмаларың яхшы булсын. Пәрәмәчтә ихласы зур ди аның. Банкет булса да, бездә ул милли булыр.

Разия. Кунак ашы җирдә калмас, дигәннәр. Алла хәерле итсен инде. *(Чыга.)*

IV. Габдуллаҗан ялгызы.

Габдуллаҗан. Эшләнәсе эшләр, алынасы нәрсәләр алынып бетте бугай инде. Чынлап та, хатын әйтмешли, бу американ үзенең банкеты белән шактыйга төшәр төсле күренә. Хәер, эшләр уйлаганча барып чыкса, ун өлеш итеп кайтарырбыз әле. Син Америка профессоры булсаң, без дә үз эшебездә профессор, әфәндем. Алдатмабыз әле. Дөньяда көтелмәгән эшләр була. Көтелмәгәндә әллә ниләр эшләп ташлый ул, дөнья диләр аны. Башына тай типмәгән кеше дөньясында харап булмый ул. Бабайлар да, дөнья куласа, әйләнә дә бер баса, дип ялгыш-

каннар. Дөрес, дөнья куласасын куласа, әйләнүен дә әйләнә, анысы дөрес. Әмма әйләнеп басмый! Өскә чыгара. Җилкәдән тотып өскә чыгара. Бабайлар сүзе белән йөрсәң, авылда кара ипи кимереп, йә берәр шахтада күмер казып торыр идең. Ә монда эшләр бөтенләй башкача, Америка профессорының бабасы. Ә, һи-һи-һи, уйласам, йөрәкләр кытыкланып китә. Тукта әле, бу чүпрәк башларны шул хакта агаһландырып[1] куярга кирәк. Юкса көтелмәгәндә әллә ни эшләп ташламасыннар тагын. Акыл өләшкәндә кершән буянып калган халык бит алар. Анасы!.. Әй, тфү, Разия ханым, кызым, монда керегез!.. Тиз булыгыз инде. Имгәкләр! Шулай диген, көтелмәгәндә диген, җилкәдән тотып чыгара диген. Һи-һи-һи...

V. Габдуллаҗан, Разия, Мәйсәрә.

Разия. Син чакырдыңмы?

Габдуллаҗан. Килегез, утырыгыз... Кызым, син дә утыр.

Утыралар.

Разия. Ни бар?

Габдуллаҗан. Менә нәрсә, кызым, Мәйсәрә туташ. Хатыным, Разия ханым. Мин иске фикерле, тупас кара татар бае да түгел, ишаннарга кул биреп дөньямны ахирәткә алмаштыручылардан да түгел. Мин — замана кешесе, тәрәккый пәрвәр, милләтче татар углы татармын...

Разия. Мөселман диең, атасы.

Габдуллаҗан. Тик тор син, ишәк. Нәүбәтең җиткәч сөйләшерсең. Менә шулай, кызым туташ. Мин кара фикерле каткан татар түгел, замананың теләкләренә каршы килмим. Хәзер инде замана башка төрле. Ору, сугу, көчләүләр модада түгел. Хәзер эшне заманача, тәрәккый пәрвәрләрчә йөртү модада. Менә шуңа күрә мин сине үзең теләмәгән кешегә көчләп кияүгә бирү ягында түгел, кызым. Бүген безгә киләчәк американ бик зур могтәбәр кеше. Үзе профессор, үзе хак мөселман. Америкада тора. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, кызым, гомерең буенча автомобильдә генә йөрерсең. Төшендеңме, кызым туташ?

Мәйсәрә. Әбәү, мин аңар чыкмыйм!

Габдуллаҗан. Сөйләп бетергәнне көт, миең черегән нәрсә! Шулай, әгәр дә син аңар кияүгә чыксаң, җаның ни тели, шуны

[1] *Агаһландыру* — искәртү, белдереп, сиздереп кую.

алырсың, әбәзияннан сак[1] тектереп бирермен. Әйтәм бит, җаның ни тели, шуны алып бирермен.

М ә й с ә р ә. Әем, мин аңарга чыкмыйм!

Г а б д у л л а җ а н. Сөйләп бетергәнне көт дим, юкә баш! Менә мондый, иресеннән, менә шуның озынлыгы энҗе алып бирермен. Теге берлиант кашлы беләзекне дә бирермен.

Р а з и я. Тукта әле, кем, ни...

Г а б д у л л а җ а н. Тик тор, чүпрәк баш. Синнән акыл сораган кеше юк бит әле. Бу йортта син хуҗамы, минме?

Р а з и я. Юк, мин болай гына, ихтыяр үзеңдә.

Г а б д у л л а җ а н. Әгәр дә, насыйп булып, аңарга кияүгә чыксаң, Америкага китәрсез. Ел саен берәр кат без дә барырбыз. Сез аннан вагонлап-вагонлап мал җибәрерсез. Без монда сатарбыз да, алтынга әйләндереп, сандыкларга тутырып, сезнең янга Америкага торырга китәрбез. Бу тупас Рачы халкы арасында торуы да туйдырды инде. Төшенәсеңме, кызым, эшләрнең кая барганын?

М ә й с ә р ә. Яшьме соң үзе?

Г а б д у л л а җ а н. Менә килгәч күрерсең. Ул сиңа гашыйк булган. Ашым аш, суым су түгел, ди.

М ә й с ә р ә. Әй, аның ише... Һи-һи-һи!..

Г а б д у л л а җ а н. Аннан соң шуны да истә тот, кызым. Син аның аягы астында туфрак булырга тырыш. Минем өемнән чыгып киткәннән соң, тәрбияң аның кулында булачак. Кем ашын ашаганыңны һәрвакыт исеңдә тот. Яхшы булсаң, сый күрерсең, яман булсаң, ут күрерсең. Дөрес, синең гомереңә җитәрлек мин үзем дә сиңа придан бирермен, ләкин мөселман кешегә шәригать боерыгыннан чыгарга ярамый. Хатын ирнең колы булырга тиеш.

М ә й с ә р ә. Әем, алай ут йотарлык булгач, мин аңарга чыкмыйм.

Г а б д у л л а җ а н. Мин, кызым, тупас татар бае түгел. Әгәр дә күңелеңә ошамый икән, мин сине көчләп бирмим. Ә инде минем сүземә каршы килүең өчен яңагыңнан утлар чыгарырмын. Мин сине утыз яшькә кадәр ашатып түремдә тотмам. Хәзер заманасы ул түгел. Гомер буе кияүгә чыкмасаң да, мин сине һич берәүгә көчләп, елатып бирмәм. Ә инде башбаштаклыгың өчен яңагыңнан утлар чыкканны көт тә тор... Мин синең белән ике сөйләшмәм. Мин — замана кешесе. Син белгән

[1] Хатын-кыз пальтосының бер төре.

җәдидлекне мин дә беләм. Йә, ни әйтерсең, кызым?.. Дәшмисең?..

Разия. Дәшмәү ризалык галәмәте ул, атасы.

Габдуллаҗан. Син тик тор, әрәмтамак! Дәшмәү ризалык галәмәте дип эш кылырга мин кадим бай түгел. Миңа үз теле белән шартлатып әйтеп бирсен. Мин аны көчләп бирергә теләмим. Инде минем планнарымны җимерә икән, үзенә үпкәләсен. Яңагын кабыргалы бозау кәтлитеннән ким ясамам. Йә, кызым!.. Мин көтәм!..

Мәйсәрә. Риза.

Габдуллаҗан. Менә, бәрәкалла, кызым. Менә бу эш чын җәдид, зыялыларча булып чыкты. Үзеңә дә уңай, миңа да яхшы. Халык күзендә дә күңелле.

Разия. Миңа инде, атасы...

Габдуллаҗан. Синнән сорамаганда, син тик тор, яңадан шул тупас «атасы» дигәнеңне ишетсәм, кара аны... Кая, кызым, бар, һәйбәтләп борыннарыңны, йөзләреңне юып, теге мутный күлмәкләреңне киеп, рәтләнеп, хәзерләнеп тор. Озакламыйча килә дә башларлар. *(Одеколон өрдерә.)* Ә син, Разия ханым, ашларыңны кара.

Разия. Ярый, ярый... Кем... ни...

Габдуллаҗан. Ни бар?

Разия. Шулай ук бердәнбер кызыбызны...

Габдуллаҗан. Син ашларыңны бел. Башкасына катышма. Синең эшең түгел, бар, бар!

Разия. Ярый, ярый. Алла хәерле итсен иде инде. *(Чыга.)*

Габдуллаҗан. Ярый, бер яктан эш бетте. Инде профессорның җебен тотарга кирәк. Хәер, алай куркынычлы конкурентлар күренми әле. Өч-дүрт төргәк белән егерме-утыз каратны күрсәтсәң, күзе томаланыр әле. Беләбез без ул халыкны. Үзбәк әйтмешли, пүл булсын, пүл булса, барысын да кол итәргә була.

Звонок.

Әһә, килделәр бугай. *(Чыга.)*

VI. Габдуллаҗан, Нигъмәт.

Габдуллаҗан. Әйдә, әйдә, Нигъмәт әфәнде, рәхим итегез!

Нигъмәт. Профессор әфәнде юкмыни әле?

Габдуллаҗан. Вакыт бар әле. Ул халык бит сәгате-минуты белән йөри торган халык инде.

Н и г ъ м ә т. Дөрес, дөрес. Үзегез ниләр бетереп торасыз?

Г а б д у л л а җ а н. Яңа хәбәрләр сездәдер инде. Дөньяда ниләр бар? Гәзитләрендә ниләр язган булалар? Налоглар турында тагын берәр кәсафәт[1] тудырырга уйламыйлармы?

Н и г ъ м ә т. Тудырган кәсафәтләре дә җитәрлек булды инде. Ни эшләмәкче була торганнардыр инде. Менә Европа дәүләтләре белән килешүдән берәр хикмәт чыкмасмы инде.

Г а б д у л л а җ а н. Ничек, әллә берәр нәрсә чыгар төсле күренәме?

Н и г ъ м ә т. Күренергә тиеш. Чит дәүләтләр капиталы кергәч, җирле капиталга да юл ачылырга тиеш.

Г а б д у л л а җ а н. Соң гәзитләрендә ниләр язалар?

Н и г ъ м ә т. Иске мунча, яңа таш. Һаман шул бер балык башын чәйниләр. Тегеләй эшлибез, болай эшлибез дип мактанудан уза алмыйлар әле. Юньләп эшләгән бер эшләре юк. Мәмләкәт тоту бунт чыгару түгел икән шул.

Г а б д у л л а җ а н. Шулаен шулай да, кем, Нигъмәт әфәнде, көч алар кулында бит.

Н и г ъ м ә т. Тарих бер урында тормый, Габдуллаҗан әфәнде. Бүген алар булса, иртәгә эш башында безнең булуыбыз да бик мөмкин.

Г а б д у л л а җ а н. Әнә теге бүрәнә җөмһүрияте заманында нинди уңай вакыт туры килгән иде. Кулдан ычкындырдыгыз бит шуны.

Н и г ъ м ә т. Юк, Габдуллаҗан әфәнде, ул алай түгел. Без сезгә, милли байларга ышанып харап булдык ул чагында.

Г а б д у л л а җ а н. Ничек безгә ышанып харап булдыгыз? Киресенчә, без сезгә ышанып харап була яздык. Иләдегез инде, Нигъмәт әфәнде, иләдегез. Алла хәерле кылсын инде.

Н и г ъ м ә т. Ярый инде, үткән эшкә салават, дигәннәр бабайлар. Үткән беткән инде. Ул эшләр киләчәк өчен сабак булсын. Тарих ул йокламый. Һаман алга атлый. Бабайлар әйтмешли, дөнья куласа, әйләнә дә бер баса.

Г а б д у л л а җ а н. Менә ул хата фикер, Нигъмәт әфәнде. Дөрес, дөнья куласасын куласа, әйләнүен дә әйләнә, ләкин...

Звонок.

Профессор килде. *(Чыга.)*

---

[1] *Кәсафәт* — болганчыклык, ачык булмау.

VII. Габдуллаҗан, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт.

Габдуллаҗан. Әйдәгез, әйдәгез, рәхим итегез!

Шәехмирза. Килмәдемени әле? Исәнмесез, Нигъмәт әфәнде.

Күрешәләр.

Сәлим. Габдуллаҗан әфәнде, безнең бу мәҗлесебезне сизмәсләрме икән?

Габдуллаҗан. Мәҗлес түгел, зыяфәт, банкет, Сәлим әфәнде.

Шәехмирза. Бүредән курыккан урманга бармас, дигәннәр бабайлар. Куркырлык булгач килмиләр аны.

Сәлим. Сез, Шәехмирза әфәнде, зыялы адвокат булсагыз да, тәрбиягез барып чыкмаган.

Шәехмирза. Ә сез һаман татарлыктан чыга алмыйсыз. Мин — факультет ярым бетергән кеше. Һәрхәлдә, сезнең мәдрәсә тәрбиягездән артыграк. Мин тәрбия күргән кеше. Гаҗәп, безнең татар зыялылары нәзакәт дигән нәрсәне белмиләр. Менә, Нигъмәт әфәнде, мәдрәсәдә укыган шәкерт кенә булса да, ул бөтенләй башка.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, сөйләшәсе сүзегез булса, сөйләшеп бетереп куегыз, профессор алдында, зинһар, сынатмагыз.

Шәехмирза. Син, Габдуллаҗан әфәнде, бер сәүдәгәр генә. Зыялылар сөйләшкәндә тыңлап торырга кирәк.

Габдуллаҗан. Мин үз өемдә үзем хуҗа. Теләсәм сөйләшермен, теләмәсәм тыңлап торырмын.

Звонок.

Тес-с, зинһар, тавышланмагыз. Килде. *(Чыга.)*

Сәлим. Нигъмәт әфәнде, сез профессор хакында нинди фикердә?

Нигъмәт. Мин әле аны күргәнем юк бит. Һәрхәлдә, милләтебез өчен зур мактану инде, зур хәзинә.

Шәехмирза. Зур мактану, имеш. Менә мин факультет ярым бетергән кеше. Революция булмаса, әллә кайчан профессор булган булыр идем. Шулай инде. Ерактагы кояш якты була, ди.

Тавыш ишетелә, һәммәсе рәтләнәләр.

VIII. Әүвәлгеләр, Габдуллаҗан, Муса, Дилбәр.

Муса. Әле килмәдемени?

Габдуллаҗан. Хәзер килергә тиеш. Рәхим итегез!

Күрешәләр.

Нигъмәт. Муса әфәнде, ни эшләр куптарасыз? Әллә нигә картаеп киттегез бу арада.

Муса. Гомер уза бит.

Нигъмәт. Юк, революция картайтты сезне.

Муса. Анысы да бардыр инде... Газиз милләтебез сакчысыз көтү шикелле горбәттә[1] калды бит. Бала-чага эш башына менеп утырып безне бөтенләй читкә кактылар бит. Ни өчен? Милләткә утыз ел хезмәт иткән өчен. Менә шул утыз еллык хезмәтнең җилгә очканын күрү җиңел түгел шул.

Шәехмирза. Шулай була ул. Теге вакытта Учредительный собраниегә мине сайлаган булсагыз, бәлки, бу хәлләр булмаган да булыр иде. Ә сезнең ышанычлы вәкилләрегез нишләттеләр үзегезне? Сезне монда агач атка атландырып калдырып, үзләре заграницага тайдылар. Шулай була ул. Ә сез эшне өйләгә кадәр бетереп куйдыгыз.

Нигъмәт. Муса әфәнде, американ профессор сездә булган, ди.

Муса. Әй-йе, булды.

Нигъмәт. Нинди тәэсир калдырды?

Муса. Чын зур галим икәнлеге һәрбер сүзеннән, хәрәкәтеннән күренеп тора.

Шәехмирза. Миңа да ул бик ошады. Мин беренче күрүдә үк аның зур галим генә түгел, философ икәнлеген анык белдем.

Габдуллаҗан. Алланың хикмәте, ул профессор бер дә бездәге укыган кешеләргә охшамый. Бездә укыган кешеләр юләр сымаграк булалар бит, әйеме? Ә ул алай түгел, профессорларның да урта бармагы булырга кирәк.

Шәехмирза. Габдуллаҗан әфәнде, сез сәүдәгәр кеше, сез, бәлки, базар малын яхшы да таный торгансыздыр, әмма инде ученыйларга бәһа куюны сез безгә тапшырыгыз.

Габдуллаҗан. Юк, алай түгел, адвокат әфәнде. Кеше белән кешене без дә аера беләбез. Мин, сәүдәгәр булсам да, әлхәмделиллаһ, тәрәкъкый пәрвәр, милли сәүдәгәр. Мин профессор әфәнденең зур кеше, чын галим икәнлеген үзем аңладым.

---

[1] *Горбәт* — ялгызлык.

Муса. Профессор әфәнде инде милләтебез өчен бик зур мактану. Америка шикелле Америкада профессор булу бу инде җиңел эш түгел. Шуның өстенә, иң кадерлесе, профессор хәзрәтләре безнең мәсләктәге кеше икән. Һәрбер тәрәккыебезгә, милли эшләребезгә куанып тора.

Шәехмирза. Мин профессор хакында моннан биш ел элек ишеткән идем. Һәм үзенә бер хат та язган идем...

Сәлим. Әллә сез, Шәехмирза әфәнде, профессор белән якын мөнәсәбәттәме?

Шәехмирза. Ә, әй-йе, әй-йе... Мин аның философ икәнлеген тәгаен беләм. Европада миннән кала иң зур галимнәрдән саналырга тиешле. Әй-йе, әй-йе... Американың яшь галимнәренең иң зурысы инде.

Габдуллаҗан. Американың иң зур галиме безнең агай-энеләрдән бит ә, Сәлим әфәнде? Әгәр дә берәр үткен сәүдәгәребезне дә Америкага җибәреп алсак, андагы сәүдәгәрләрнең арт сабакларын укытыр идек без анда!.. Һи-һи-һи... Американың иң зур кешесе, диең...

Нигъмәт. Муса әфәнде, профессор сезгә шулай туп-туры үзе килеп төштемени?

Муса. Әй-йе, безнең профессор хәзрәтләре белән мәгънәви танышлыгыбыз күптән инде. Ул минем бөтен әсәрләремне укып чыккан. Мин дә аның хакында француз журналларыннан шактый гына нәрсәләр моталәгә[1] кылган идем. Аннан соң безнең мәрхүм әткәй белән профессор хәзрәтләренең әткәсе шәрик[2] булып укыганнар. Болардан башка профессор хәзрәтләре ана ягыннан безгә кардәш тә була икән.

Сәлим. Нинди уйлар, нинди максатлар белән ул монда килгән?

Муса. Гыйльми тикшерүләр өчен, аннан соң үзенең бәгъзе бер хосусый йомышлары да бар икән.

Сәлим. Нинди йомышлар?

Муса. Гафу итегез инде, анысын сер итеп саклавымны үтенде.

Сәлим. Бу Советлар хакында нәрсә ди?

Муса. Ул хакта озак сөйләшмәдек. Шулай да Советларга кире икәнлеге күренә.

---

[1] *Моталәгә* — уку, өйрәнү.

[2] *Шәрик* — иптәш.

Ш ә е х м и р з а. Галим профессор булсын да, имеш, кире карамасын.

С ә л и м. Юк, алай димәгез, Европада Советлар яклы профессорлар бар.

Г а б д у л л а җ а н. Советлар яклы булган профессорларның профессорлыклары да Шәехмирза әфәнденең адвокатлыгы шикелле генәдер инде.

Ш ә е х м и р з а. Габдуллаҗан әфәнде, сез, беренчедән, мещан, икенчедән, торгаш. Шуңа күрә, гыйлем-фән хакында сүз барганда, тыңлап кына торырга тиеш.

Г а б д у л л а җ а н. Сез, Шәехмирза әфәнде, юләр балык. Башка түгел.

Ш ә е х м и р з а. Ә син идиот...

Звонок.

Н и г ъ м ә т. Әфәнделәр, сабыр. Звонок бар. Профессор килде.

Г а б д у л л а җ а н. Ә, профессор!.. Хәзер!.. *(Ашыгып чыга.)*

Ш ә е х м и р з а. Менә койрык сөяге. Спекулянт, ул да сөйләшкән була бит.

Б а р ы с ы. Тесс-с-с!.. Профессор!..

Тавыш ишетелә.

IX. Әүвалгеләр, Габдуллаҗан, Насих, Сәлимгәрәй.

Н а с и х. А-а-а, татарның бөтен могтәбәрләре монда икән. Хәерле кич, әфәнделәр.

Күрешәләр.

Н и г ъ м ә т. Насих Николаевич әфәнде, сез соңга калдыгыз.

Н а с и х. Менә Сәлимгәрәй мирзаны көтеп тордым. Хезмәт кешесе бит, ахры, урынын ташлап чыга алмады.

Г а б д у л л а җ а н. Әфәнделәр, профессор хәзрәтләре килергә тиеш. Шуңар күрә милли банкетыбызны алып бару хакында берәр мәслихәт бирүегезне үтенәм.

Н и г ъ м ә т. Чынлап та, банкетның программасын төзергә кирәк. Шуның өчен, шул банкет программасын төзү хакында фикер алышу өчен, вакытлы гына бер рәис, бер сәркәтип сайларга кирәк.

Н а с и х. Сез, Нигъмәт әфәнде, соңгы вакытта тәмам кызыллашып киттегез. Нигә кирәк рәис! Банкет банкет ул. Сөйләрбез, тост күтәрербез. Шуның белән эш тә бетәр.

Муса. Юк, ул алай түгел, Насих Николаевич әфәнде. Профессор хәзрәтләрен милли эшләребез белән һәм сәяси карашларыбыз, планнарыбыз белән таныштырырга тиешбез. Бөтен татар большевик дип уйлап китә күрмәсен.

Нигъмәт. Минемчә, әфәнделәр, татарның рухын эченә алган бөтен җәмәгать хадимнәребез бергә җыелган җирдә мәсьәләне төплерәк кую мәслихәт. Без һәркаюыбыз үз специальностебыздан сөйләргә тиешбез. Менә, мәсәлән, мин татар зыялылары исеменнән сөйләрмен.

Габдуллаҗан. Нигъмәт әфәнде аны булдыра инде, тик әнә беркөнге, мәйданда сөйләгән төсле генә була күрмәсен инде.

Нигъмәт. Анысы бит аның күз буяр өчен генә иде. Минемчә, нотыкларны үзара бүлешеп куярга кирәк.

Муса. Ярый, мәслихәт. Мин бәйнәлмиләл[1] һәм шәрык сәясәтендә тоткан юлыбыз хакында сөйләрмен.

Шәехмирза. Мин фән һәм шәригать хакында сүз алам.

Нигъмәт яза.

Сәлим. Мин татар тарихы һәм аның имласы хакында мәгълүмат бирермен.

Муса. Мәслихәт, мәслихәт.

Насих. Мин инде большевиклар хакында нотык тотармын.

Сәлимгәрәй. Мин киләчәктә татар милләтенең тотачак хәрби тактикасы хакында рапорт бирермен.

Барысы. Мәслихәт, мәслихәт. Яхшы булыр бу.

Габдуллаҗан. Әфәнделәр, сез инде миңа да берәр сүз табып бирегез.

Муса. Әйе, әйе... Сез инде, Габдуллаҗан әфәнде, банкетны рәсми итеп ачарсыз һәм банкетның рәисе булырсыз.

Барысы. Мәслихәт, мәслихәт.

Шәехмирза. Менә монда мәсьәләнең иң зур ноктасы бар. Кемгә алдан сүз бирелергә тиеш?

Барысы. Чынлап та, бу мәсьәлә мөһим һәм зур!

Нигъмәт. Минемчә, бу мәсьәлә бик җиңел хәл кылынырга тиеш. Профессор зыялы кеше булганлыктан, беренче сүз зыялылар хакында сөйләүчегә, ягъни миңа бирелергә тиеш.

Муса. Минемчә, гомуми мәсьәлә хакында сөйләүче алдан сөйләргә тиеш. Бәйнәлмиләл, шәрык мәсьәләсе хәзерге вакытта

[1] *Бәйнәлмиләл* — халыкара, интернациональ.

бик зур мәсьәлә. Шуңа күрә миңа алдан сүз бирелсен. Аннан безнең иске татар гадәте буенча да миңа тиеш. Чөнки мин — милләтебез өчен барыгыздан да артык эшләгән, тырышкан кеше.

Сәлим. Минемчә, хәзерге вакытта татар милләте өчен нәрсә мөһим булса, шул хакта сөйләүче алдан сөйләргә тиеш. Тарих, имла мәсьәләсеннән дә зур эшебез юк бит безнең.

Сәлимгәрәй. Әфәнделәр, һәрвакыт банкетларда гаскәриләргә алдан сүз бирелә. Чөнки рапортсыз бернәрсә дә чыкмый. Минем рапорт. Шуңар күрә алдан мин рапорт бирергә тиеш.

Насих. Сез һәркайсыгыз аерым мәсьәлә хакында нотык тотасыз, ә минем нотыгым информация урынында булачак. Шуңар күрә, әлбәттә, баштан мин сөйләргә кирәк.

Габдуллаҗан. Ә минемчә, банкетның рәисе баштан сөйләргә тиеш.

Нигъмәт. Юк, алай түгел ул.

Габдуллаҗан. Синеңчә дә түгел.

Шәехмирза. Үзем баштан сөйлим, үзем.

Муса. Әфәнделәр, башлап мин сөйләргә тиеш.

Насих. Нигә мин түгел, син кем булдың соң?

Нигъмәт. Әфәнделәр, булмаса тавышка куйыйк!

Барысы. Мин, мин сөйләргә тиеш! Мин!..

Нигъмәт. Әфәнделәр, туктагыз!..

Барысы. Үзем сөйлим, үзем!..

Шау-шу башлана, Апуш керә.

X. Әүвәлгеләр, Апуш һәм Искәндәр.

Апуш. Әфәнделәр!.. Әфәнделәр!.. Әфәнделәр!.. Профессор хәзрәтләре боерды.

Барысы. Тес-с-с!

Һәммәсе телдән калып сафка тезеләләр. Шул ук вакытта Искәндәр керә.

Искәндәр. Әфәнделәр, сәлам!

Барысы. Мәрхаба, профессор хәзрәтләре!..

Башларын ияләр. Искәндәр баскан килеш кала.

Пәрдә.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук бүлмә.

I. Мәйсәрә һәм Дилбәр.

Мәйсәрә. Кара, кара, Америка профессоры да аракы эчә икән.

Дилбәр. Укыган халык эчәргә ярата, ди эткәй.

Мәйсәрә. Кара, кара, йөзе нинди кызарып китте. Яхшы гына төшергәндер, ахры. *(Дилбәрне култыклап.)* Кара әле, Дилбәр, кешегә әйтмәсәң, мин сиңа бернәрсә сөйләр идем.

Дилбәр. Ни эшләп әйтим. Алла сакласын. Сүз ташып йөрергә мин Чулак Фатыйма түгел ич.

Мәйсәрә. Әем, әйтмим. Кешегә сөйләрсең.

Дилбәр. Билләһи, сөйләмим. Сөйләр булсам, телем корысын.

Мәйсәрә. Сөйләмәссеңме?

Дилбәр. Юк, дим инде.

Мәйсәрә. Менә алайса нәрсә, әлеге Америкадан килгән мөселман профессоры бар бит, әйеме?

Дилбәр. Йә, йә?

Мәйсәрә. Ләкин, зинһар, кешегә әйтмә. Эткәй мине шул профессорга кияүгә бирә.

Дилбәр. Ә профессор ризамы соң?

Мәйсәрә. Нәрсәгә?

Дилбәр. Сиңа өйләнергә.

Мәйсәрә. Әй, ябалак, әйтәм ич, зур придан белән дип... Эти әйтә, акча барысын да эшли, ди.

Дилбәр. Кара әле, Мәйсәрә, син аңар кияүгә чыкма.

Мәйсәрә. Нигә?

Дилбәр. Ул бит сине ата-анаңнан, кардәш-кабиләңнән аерып әллә кая алып китә.

Мәйсәрә. Ә китсә ни? Эти әйтә, ел саен бер кат үзегез күрешергә килерсез, ди. Бер кат үзебез барырбыз, ди. Аннан ул тора торган Америка каласында большевиклар да, Советлар да юк, ди. Автомобильләрдә генә йөриләр, ди. Шулай булгач кызыктым шул... Алтын-көмеш, энҗе дә бик арзан, ди. Берлиянт шул Америка каласыннан чыга икән. Икмәк урынына анда шоколад кына ашап торалар, ди. Шоколад анда тауда үсә икән.

Дилбәр. Теләсәң ни эшлә, үзеңне чукындырсалар, соңыннан үкенерсең дә, кайтмас.

Мәйсәрә. Нишләп чукындырсыннар? Әти әйтә, әгәр дә, ди, шул профессорга барсаң, ди, ни генә сорасаң да кызганмам, ди. Әбәзиян сак тектерермен, ди.

Дилбәр. Әбәзиян маймыл була бит ул. Маймыл тиресе киеп йөрерсеңмени?

Мәйсәрә. Әбәзиян нишләп маймыл булсын ул! Мех ул, бик кыйммәтле мех. Әй, мескен, шуны да белмисеңмени? Маймыл булса, кем кияр иде соң аны? Әбәү, маймыл тиресен кияргә!

Дилбәр. Син ул Американың кайда икәнлеген беләсеңме соң?

Мәйсәрә. Хаждан да ерак түгелдер әле. Әнә кешеләр хаждан да кайталар. Әти әйтә, сез миңа Америка каласыннан вагонлап-вагонлап мал җибәрерсез, ди. Мин аны монда сатармын, бик күп кенә акча булгач, алтынга әйләндереп, үзем дә сезнең яныгызга торырга Америкага күчәрмен, ди. Шулай булгач, нишләп риза булмыйм?!

Дилбәр. Аның анда хатыны бар, ди. Көндәш өстенә сине алмакчымыни?

Мәйсәрә. Булса, мин аны баргач та куып җибәрермен.

Дилбәр. Хәер, теләсәң ни эшлә. Мин, синең урыныңда булсам, әллә нигә дә аңар кияүгә чыкмас идем. Монда бит сине теләсә кем алыр. Үзең матур, бай, укыган...

Мәйсәрә. Кем укыган, минме? Мин бернәрсә дә белмим. Валлаһи, басканны көчкә генә таныйм. Байлык булгач, укуның нигә кирәге бар? Ярлы кешеләр берәр җирдә хезмәт итеп тамак туйдырыр өчен укыйлар бит. Ә миңа ул нигә? Чү, чыгалар бугай!

II. Дилбәр, Мәйсәрә, Искәндәр, Габдуллаҗан, Насих, Шәехмирза, Сәлим, Нигъмәт, Апуш, Муса, Сәлимгәрәй.

Искәндәр. Әфәнделәр, сезнең белән бер мәҗлестә булуыма мин бик шат! *(Төртә.)* Гафу итегез, без, америкалылар...

Насих. Зарар юк,

Искәндәр. Сез мирзамы әле?

Сәлимгәрәй. Шулай, ваше превосходительство.

Габдуллаҗан. Рәхим итегез, утырышыгыз!

Искәндәр. Рәхмәт. Туташлар, рәхим итегез! *(Урын күрсәтә.)*

Дилбәр. Мерси... *(Реверанс ясый.)*

Мәйсәрә Дилбәрнең реверанс ясаганын күреп посып ала.

Н а с и х. Профессор әфәнде, Америкада безнең эмигрантлар күпме?

И с к ә н д ә р. Бихисап.

Н а с и х. Хәлләре ничек?

И с к ә н д ә р. Һәйбәт. Сезнең һәркаюгызга сәлам әйттеләр. Һәм, мөмкин булса, арыш сохарие җибәрүегезне үтенделәр.

Н а с и х. Нигә? Матди яклары начармыни?

И с к ә н д ә р. Юк, бик яхшы. Һәркемгә дә ватан кадерле бит. Аларның Русиядән килгән арыш сохарие бик ашыйсылары килә.

С ә л и м. Профессор әфәнде, татар тарихы хакында Америка голямасы нәрсә ди?

И с к ә н д ә р. Бик шәп, ди.

С ә л и м. Шул хакта Америка голямасы берәр нәрсә эшлиме?

И с к ә н д ә р. Бик нык эшли. Ул хакта, гомумән, эшләр бик кызу бара. Татар тарихын тикшерү өчен махсус алтмыш биш катлы бина төзелде. Һәм дә йөз дә сигез автомобиль хәзерләнде.

С ә л и м. Бик күп. Әллә татар тарихы хакында яңа кәшфиятлар[1]да бармы?

И с к ә н д ә р. Бик күп.

С ә л и м. Кара син аны, бик күп диең алайса. Ә татар имласы хакында мәсьәләләр ничегрәк?

И с к ә н д ә р. Хәтта әйтергә мөмкин, бихисап.

С ә л и м. Мәнбәгъләре әсаслымы[2] соң?

И с к ә н д ә р. Бик әсаслы, бик нык, тимер шикелле нык.

С ә л и м. Нәрсә соң ул алай Америка голямасын татар тарихын тикшерергә мәҗбүр итте?

И с к ә н д ә р. Мөһим бер ярлык. Ул ярлык хакында мондагы матбугат та бик шаулаган дип ишеткән идем.

С ә л и м. Теге бер мулланың бер мужиктан урлап алган ярлыгымы әллә?

И с к ә н д ә р. Әйе, мужиктан бер мулла, мулладан бер хәлфә, хәлфәдән бер газета мөхбире, мөхбирдән газета конторщигы, конторщиктан көтепханә назиры, назирдан бер урам каравылчысы урлаган ярлык. Аны аэроплан белән бер спекулянт Аме-

---

[1] *Кәшфият* — яңа ачышлар.

[2] *Мәнбәгъләре әсаслымы* — чыганаклары нигезлеме.

рикага китереп, миллион долларга сатты. Менә инде шул ярлык татар тарихына нык нигез ителеп алынды. Аннан соң иске Болгар ханнарының ярлыкларын, Арыслан ханның бөтинамәсенең бер нөсхәсен Һинд голямаларыннан берсе безгә, Америкага китереп тапшырды.

Габдуллаҗан. Болгар ханнарының ярлыклары дисезме?

Искәндәр. Әйе, һәм Арыслан ханның бөтинамәсе.

Габдуллаҗан. Ул ярлыклар һәм бөтинамә ике нөсхә булганмыни?

Искәндәр. Әйе, ике нөсхә булган. Аны моннан сигез йөз алтмыш биш ел элек Арыслан хан җыеп, ике нөсхә яздырып калдырган икән. Шуның бер нөсхәсен без таптык, икенче нөсхәсен Русиядә дигәннәр иде. Шуны эзләргә дип мин монда килдем.

Сәлим. Соң берсе булгач, аның икенчесе нигә кирәк?

Искәндәр. Дөрес, артык кирәге юк. Ләкин без аларны чагыштырып карамакчы булабыз. Сез, Габдуллаҗан әфәнде, шул ярлыклар хакында миңа берәр мәгълүмат бирә алмыйсызмы?

Габдуллаҗан. Юк, мәгъзур[1], бирә алмыйбыз. Миндә ул ярлыклар юк. Мин бернәрсә дә белмим. Аны дошманлык белән генә миндә дип әйтәләр. Миндә бернәрсә дә юк.

Искәндәр. Ә сез, мөәррих[2] әфәнде, шул мөһим ярлыклар хакында бернәрсә дә белмисезмени?

Сәлим. Мин... эһем... Мин... әйе... мин... Эһем. *(Габдуллаҗанга карый.)* Бу хакта Габдуллаҗан әфәнде рөхсәт итсә?..

Габдуллаҗан. Нәрсә син такылдыйсың? Кеше бар дип тә уйлар. Миндә, профессор әфәнде, ярлыклар юк. Әйе, без надан кеше. Без аның рәтен дә белмибез.

Искәндәр. Хәер, без бу хакта икенче вакыт яхшылап сөйләшербез. Шулай түгелме?

Габдуллаҗан. Сөйләшәсе-нитәсе юк, мин бернәрсә дә белмим.

Муса. Теге ишан бабаңнан калган ярлыклар кайда соң?

Габдуллаҗан. Тапты сүз! Мин каян белим. Әнә зиратка барып үзеннән сора. Шифырт дисәң шифырт. Мөгезсез сыер төсле чакырмаган җиргә килеп керә. Менә юньсез!

---

[1] *Мәгъзур* — гозер иясе.

[2] *Мөәррих* — тарихчы.

Искәндәр. Хәер, ул ярлыкларның хәзер безнең америкалылар өчен әһәмиятләре юк. Бездә бит алар бар инде. Мин болай гына сорадым.

Габдуллаҗан. Булмас, ышанмыйм. Аның чыннары сездә булмас! Әйе, профессор әфәнде, ашыйсыгыз килсә, бездә аш бар, эчәсегез килсә, пирәш бар, йоклыйсыгыз килсә, түшәк бар, әмма ярлык-марлык бездә юк.

Искәндәр. Шулаймы? *(Төртә.)*

Габдуллаҗан. Ай!.. Әйе, шулай.

Сәлим. Профессор хәзрәтләре, Чыңгыз хакында Америка голямасы нәрсә ди?

Искәндәр. Бик шәп, ди. Әле мин китәр алдыннан гына Чыңгыз гаскәрләренең Америкага килеп сугышканлыгы һәм Американы алуы турында бик зур гыйльми бәхәсләр булды.

Сәлим. Ничек, әллә Чыңгыз гаскәренең Американы фәтех итүе сабит[1] булдымы?

Искәндәр. Әйе, бик ышанычлы, төпле дәлилләр һәм ярлыклар белән Чыңгыз гаскәренең Шимали[2] Американы алуы фән белән беркетелде.

Сәлим. Хуш, хуш, бу хәбәр безнең өчен гаҗәп зур вакыйга һәм материал. Бу хакта иртәгә үк журналларга мәкаләләр җибәрәм. Ничек, ничек булган? Хода хакы өчен сөйләгез әле.

Искәндәр *(төртә)*. Гафу итегез! Туташларны зарыктыру булмасмы соң?

Дилбәр. Пардон, мусио!

Мәйсәрә Дилбәрчә кыланып поса.

Сәлим. Хуш, хуш, профессор әфәнде, ничек булган?

Искәндәр. Нәрсә ничек булган?

Сәлим. Америкадагы Чыңгыз гаскәре?

Искәндәр. Ә, әйе. Ул болай булган... Чыңгыз ханның Тимер Йөрәк исемле бер бик көчле батыры булган икән. Көннәрдән бер көн шул батыр үз янына кораллы йөз кеше алып, Американы сугышып алу максаты белән, зур сәфәргә чыккан. Алты ай сәфәрдән соң бик каты сугышлар соңында Шимали Американы алган. Шуннан соң әлеге батыр, исән калган юлдашлары белән Җәнүби[3] Американы алырга барганда, Кардил-

---

[1] *Фәтех итүе сабит* — яулап алуы ачык.

[2] *Шимали* — Төньяк.

[3] *Җәнүби* — Көньяк.

лери таулары арасындагы Җон даласына очрап, шунда бөтен гаскәрләре белән харап булган.

Сәлим. Җон даласы дисезме?

Искәндәр. Әйе, Джунгылы дигән мәшһүр җирне ишеткәнегез бармы?

Сәлим. Әйе, әйе.

Искәндәр. Менә шул Джунгылының асыл исеме Җон даласы икән. Аңар ул исемне башта татарлар кушканнар икән. Шуннан соң инде американлылар шул татар сүзе булган Җон даласын Джунгылы дип йөртә башлаганнар.

Сәлим. Профессор әфәнде, мөмкин булса, шул хакта сезнең белән яхшылап бер утырышасы иде.

Искәндәр. Бик мөмкин. *(Төртә.)*

Сәлим. Ай... Рәхмәт!

Мәйсәрә. Дилбәр җаным, кәрчитым кыса, үләм инде. Әйдә бауларын бераз бушатып керик.

Дилбәр. Мусио, пардон, безнең йомышыбыз бар.

Реверанс ясый. Мәйсәрә дә ясый.

Искәндәр. Рәхим итегез, рәхим итегез!

Дилбәр, Мәйсәрә чыгалар.

Сәлимгәрәй. Виноват, ваше превосходительство! Бездәге бу коммунистлар, Советлар һәм вак-төяк җөмһүриятләр турысында Америка җәмәгатьчелегенең фикере ничек?

Искәндәр. Бик һәйбәт. Быел мамык, шоколад, дөге, автомобильләр бик уңды.

Насих. Профессор әфәнде, менә бу безнең солтанәтле, көчле Рус иле төрле вак җөмһүриятләргә бүленүенә менә безнең ватан пәрвәрчеләрнең йөрәкләре бик әрни. Русның гали ханданы[1] хөкем сөргән вакытларда бөтен халыкка рәхәт иде, татарларга аеруча рәхәт иде. Поляклар, еврейлар алар инде борын-борыннан ихтилальчеләр[2] иде. Менә мәрхүм падиша хәзрәтләренең кучере, ат караучысы татар булган. Менә бит падиша хәзрәтләре дә татарларга ничек ышанган. Менә хәзерге Совет власте төрле халыкларга мохтәриятле[3] җөмһүриятләр биреп, утарларны талап алып, халыкны узындырды. Сез уйлап

---

[1] *Гали хандан (ханадан)* — бөек, өстен династия.

[2] *Ихтилальчеләр* — фетнәчеләр.

[3] *Мохтәриятле* — бәйсез.

карагыз, җөмһүрият төзегән булып, җыен бала-чаганы эш башына утырттылар. Менә Муса әфәнде, Шәехмирза әфәнде, Габдуллаҗан байларны һичбер җиргә сайламыйлар. Менә Сәлимгәрәй мирза штатский советник, полковник, хәзер конторщик булып тамак туйдыра. Бу бит мәсхәрәлек. Бу кешенең дәрәҗәсеннән, мәгълүматыннан көлү була. Әле аннан да куарга торалар, ди.

Сәлимгәрәй. Әле тагын көчләп татар телен укыталар.

Насих. Да, да, бусы инде бик зур ахмаклык. Мин французча, инглизчә, немецча, хәтта японча да укытуны аңлыйм, ә инде татарча өйрәтүне һич башым сыйдыра алмый. Безгә, татарларга, культура кирәк, ә алар татарча укытып маташалар. Безне, яшьлектә татарча укый алмаган картларны, татарча укырга мәҗбүр итәләр. Бу мәсхәрәлек, позор, издевательство! Нигә миңа кирәк татарча уку? Әйтсәгез лә, нигә кирәк? Менә сез мәдәни кеше, Америка профессоры, йә, әйтегез, Американда французча укыталармы? Укыталар. Японча укыталармы? Укыталар. Ә татарча укыталармы? Юк. Мең мәртәбә юк.

Сәлимгәрәй. Ерунда на постном масле! Менә нәрсә, ха-ха-ха...

Насих. Мәдәни һичбер мәмләкәттә татарча укытмыйлар. Ә монда болар татар теле укытырга уйлап чыгарганнар. Җитмәсә, урысларга да укытып маташалар бит.

Сәлимгәрәй. Мәҗбүр итәләр, ваше превосходительство.

Муса. Юк, татар телен бөтенләй онытырга ярамый. Милли тел сакланырга тиеш. Ләкин урысларга татар телен өйрәтүгә мин дә каршы. Минемчә, урысларга тел өйрәткәнче ислам динен өйрәтү артыграк булыр иде.

Искәндәр. Шулаймы?.. *(Төртә.)*

Муса. Ай!..

Искәндәр. Гафу итегез!

Габдуллаҗан. Бу Советлар, профессор әфәнде, сәүдә эшен бик кысалар. Менә Алла, хәзер суманы ашап ятабыз. Сез инде шул хакта безгә бераз ярдәм итегез. Чыдар хәл калмады бит инде, ахрысы.

Шәехмирза. Әгәр дә миңа Америкада профессорлыкка урын тапсагыз, валлаһи, бер көн монда тормас идем. Тәмам туйдырып бетерделәр.

Искәндәр. Габдуллаҗан әфәнде, сездә тарихи ярлыклар бар, диләр. Мөмкин булса күрсәтегез әле.

Габдуллаҗан. Миндә?! Миндә, профессор әфәнде, миндә ярлык юк. Миндә бернәрсә дә юк.

Искәндәр. Шулаймы? Әйе, бер мәртәбә сораган идем бугай... Русиянең аракысын мактыйлар иде, чынлап та шәп икән.

Габдуллаҗан. Аракы түгел, профессор әфәнде, коньяк.

Искәндәр. Ә, әйе, коньяк, каньяк, куньяк. Имлачы әфәнде, сез инде коньякны хәзер ничек итеп язасыз?

Сәлим. Авыздан ишетелгәнчә, профессор әфәнде.

Искәндәр. Куньяк дипме?

Сәлим. Әйе, куньяк.

Искәндәр. Әллә каньяк дипме?

Сәлим. Әйе, каньяк дип. Ишетелгәнчә инде.

Шәехмирза. Габдуллаҗан әфәнде, профессор әфәнде ялыккандыр инде.

Габдуллаҗан. Кунаклар, бераз ашап аласы иде.

Искәндәр. Ашадык бит инде.

Шәехмирза. Анысы аның банкет закускасы гына иде бит.

Искәндәр. Шулаймыни?

Габдуллаҗан. Сез дә, егет, әйдәгез, ә сез, профессор әфәнде?

Искәндәр. Рәхмәт, минем ашыйсым килми. Тәмәке булса бирегез.

Габдуллаҗан. Рәхим итегез, рәхим итегез, милли тәмәке.

Искәндәр. Рәхмәт, минем үземнең радио утым бар.

Насих. Бу Америка гаҗәп могҗизалар тудыра: таяк башында шырпы! Бик оригинальный нәрсә икән.

Искәндәр. Әгәр дә ул сезгә ошаса, мин аны сезгә бүләк итим. Минем хатирәм итеп тотарсыз.

Таягын суза. Насих алмакчы була.

Насих. Бик рәхмәт, сез галиҗәнап икәнсез, рәхмәт!

Искәндәр. Юк, бүген үк бирә алмыйм. Иртәгә яки киткәндә мин аны сезгә калдырырмын.

Насих. Бик рәхмәт!

Габдуллаҗан. Кызым, кызым, Мәйсәрә, кая югалдың, чүпрәк баш?

Мәйсәрә. Нәрсә, атакай?

Дилбәр чыгып ирләр белән китә.

Габдуллаҗан. Кызым, профессор абзаң белән сөйләш.

Барысы чыгып китәләр.

Кара әле, берәр нәрсә кирәк булса кычкырырсың! *(Чыга.)*

III. Искәндәр һәм Мәйсәрә.

Искәндәр. Туташ, утырыгыз!

Мәйсәрә. Рәхмәт! *(Посып ала).*

Бер-берсенә карашып, озак сүзсез торалар.

Искәндәр. Туташ, дөньяда сезнең иң зур теләгегез нәрсә?

Мәйсәрә. Иң зур теләкме?

Искәндәр. Әйе, иң зур теләгегез.

Мәйсәрә. Әем, әйтергә оялам.

Искәндәр. Оялмагыз, әйтегез, туташ. Хуш, дөньяда иң зур теләгегез нәрсә?

Мәйсәрә. Кияүгә чыгу. Һи-һи-һи...

Искәндәр. Бик яхшы. Рәхмәт, акыллы сүз әйттегез. Билгедә токан киявегез бармы?

Мәйсәрә. Бар.

Искәндәр. Кем?

Мәйсәрә. Электәгесеме, хәзергесеме?

Искәндәр. Теләсә кайсы булсын, хуш. Электәгесе кем?

Мәйсәрә. Электәгесе — энҗече Хәбибрахман улы.

Искәндәр. Ә хәзергесе?

Мәйсәрә. Хәзергесе — син.

Искәндәр. Мин?

Мәйсәрә. Әйе.

Искәндәр. Рәхмәт. Бу да акыллы сүз. Сез, туташ, бик акыллы икәнсез.

Мәйсәрә. Әти генә мине юләр дип тирги.

Искәндәр. Әткәгез сезне тиргимени?

Мәйсәрә. Бик тирги, тәмам туеп беттем инде үзләреннән. Шуның өчен тизрәк кияүгә чыгасым килә дә бит... Син мине тиргәмәссең бит?

Искәндәр. Юк, юк, мин сине автомобильдә генә йөртермен. Теләсәң, аэропланда очырырмын.

Мәйсәрә. Юк, аэропланда очырма син мине, мин куркам. Башым әйләнеп егылырмын. Автомобильдә генә йөртерсең, яме? Синең үз автомобилең бармы?

Искәндәр. Минем йөз дә биш автомобилем бар.

Мәйсәрә. Йөз дә биш? Бик күп икән. Без иртә белән берсендә, көндез берсендә, кич берсендә, төнлә берсендә йөрербез.

Искәндәр. Ярый, ярый.

Мәйсәрә. Син миңа бик күп итеп энҗе алырсың. Ә син миңа күптәннән гыйшык тотасыңмы?

Искәндәр. Биш елдан бирле.

Мәйсәрә. Мескен. Нигә соң сәлам хатлары бер дә язмадың? Ә туебыз кайчан булыр?

Искәндәр. Теләсәгез бүген үк мөмкин. *(Төртә.)*

Мәйсәрә. Пәрәмәч!.. Нигә төртәсең? Әле никах укылганы юк ич!

IV. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Нәрсә, ни бар?

Мәйсәрә. Әти, ул төртә.

Габдуллаҗан. Ә, эһеммм... Кирәк нәрсәгез булса сорагыз.

Искәндәр. Рәхмәт! Габдуллаҗан әфәнде, сезнең кызыгыз гаҗәп акыллы икән. Әгәр дә ул сөйләгән сүзләр дөрес булса...

Габдуллаҗан. Нәрсә, нәрсә?

Мәйсәрә. Әти, без туй хакында сөйләдек.

Габдуллаҗан. Ничек, профессор әфәнде, сез ризамы?

Искәндәр. Риза, ләкин бер шартым бар.

Габдуллаҗан. Приданы? Җаныгыз ни теләсә, шуны бирәбез. Әгәр дә акча кирәк булса, менә рәхим итегез. Хәзердән үк.

Искәндәр. Юк, бик рәхмәт. Минем акчага мохтаҗлыгым юк.

Габдуллаҗан. Соң нәрсә генә?

Искәндәр. Миңа сез придан итеп Болгар ханнарының тарихи ярлыкларын һәм Арыслан ханның бөтиен бирергә тиешсез.

Габдуллаҗан. Миндә һичбер төрле ярлык юк.

Искәндәр. Мин әйтәм, бар.

Габдуллаҗан. Юк, профессор әфәнде, миндә ярлык-марлык юк.

Искәндәр. Алай булса, гафу итегез. Мин Муса әфәнденең кызы Дилбәр туташка өйләнәм.

Габдуллаҗан. Хәерче бит ул. Өстенә кияргә күлмәге дә юк бит аның.

Искәндәр. Мин үзем бай. Шул ярлыкларны бирсәгез, бу көннән үк мин — сезнең киявегез. Берничә көннән Америкага

китәрбез. Теләсәгез, сезне дә алып китәрмен. Аннан товарлар алып кайтырсыз. Миндә кирәкле язуларның барысы да бар.

Габдуллаҗан. Юк, кияү, тфү... профессор әфәнде, миндә ярлыклар... Ничек дисез? Америкадан товар алып килеп булыр дисезме?

Искәндәр. Теләсәгез, ун вагон.

Габдуллаҗан. Ә, ун вагон? Ярлыкларны бирергә ярамый.

Искәндәр. Аннан соң сездә бит ул ярлыклар базда күмелеп яталар. Ә мине ул ярлыклар бөтен дөньяга мәшһүр итәчәкләр. Менә шулай, Габдуллаҗан әфәнде, бирсәгез, иртәгә туй. Бирмәсәгез, гафу итегез. Мин, бүген үк Дилбәр туташка өйләнеп, Америкага китәм.

Габдуллаҗан. Кияү, профессор әфәнде, теләсәгез җанымны сорагыз, жәл түгел, әмма ярлыкларны бирә алмыйм. Үзем үлгәч, сезгә калдырырмын.

Искәндәр. Димәк, бирмисез?

Дилбәр күренә.

Габдуллаҗан. Бирә алмыйм. Мирас ул.

V. Әүвәлгеләр һәм Дилбәр.

Искәндәр. Алай булгач, гафу итегез. *(Тәртә.)* Ә, Дилбәр туташ, рәхим итегез! Минем сезгә бик мөһим йомышым бар иде, рәхим итеп утырыгыз!

Габдуллаҗан белән Мәйсәрә яшеренеп каранып утыралар.

Дилбәр. Мерси, мусио! *(Реверанс ясый.)*

Искәндәр *(тегеләрнең караганнарын сизеп)*. Дилбәр туташ, әткәгез миңа сезнең фикерегезне ирештергән иде. Мин башта Мәйсәрә туташка өйләнмәкче идем, хәзер инде сезгә өйләнергә булдым. Сез ризамы?

Дилбәр. Мерси, мусио!.. *(Реверанс ясый.)* Риза!.. *(Тагын реверанс ясый.)*

Искәндәр. Алайса иртәгә...

Муса керә.

VI. Әүвәлгеләр һәм Муса.

Муса. Профессор әфәнде, сез мине бик хафага салдыгыз. Гүя сез Габдуллаҗан байның кызына өйләнмәкче буласыз, имеш, дөресме?

Искәндәр. Шулай уйлаган идем.

Муса. Сез ул эшегез белән бик зур ялгышлык эшлисез. Аның кызы юләр, шыр тиле, надан, тәрбиясез, авыру. Аның әбисе дә шашып үлде. Габдуллаҗан үзе дә урлашып кына баеды. Революция вакытында халыкны талап баеды. Жулик, карак ул, кызы дивана.

Габдуллаҗан *(чыдаша алмыйча атылып чыгып)*. Кем карак? Кем юләр? Кем жулик? Нәрсәңне урладым? Кем күргән, ә, кем күргән? Тоттыңмы? Ә?.. *(Бугазына ябыша.)*

Муса. Карак шул! Урлашып баедың.

Габдуллаҗан. Син үзең шифырт, син үзең күмер карагы.

Бугазга бугаз киләләр.

Мәйсәрә *(Дилбәргә барып)*. Мин юләрмени? Мин авырумыни? Минем әтием каракмыни? Сез үзегез мулла нәселе. Сорыкортлар!..

Дилбәр. Юләр шул, шыр тиле. Әтиең карак.

Мәйсәрә. Каракмы? Менә сиңа, менә сиңа!..

Дилбәр. Чеметмә! Җибәр, чеметмә, юләр!

Сугышалар.

Искәндәр. Туташлар!.. *(Төртә.)* Сабыр!.. Әфәнделәр!.. *(Төртә.)* Сабыр!..

Халык җыела.

Габдуллаҗан. Җәмәгать, менә шаһит булыгыз, менә бу күмер карагы мине карак дип атады!

Искәндәр. Җәмәгать, бернәрсә дә юк. Сабыр!.. Болай үзара гына. *(Габдуллаҗанны читкә алып.)* Габдуллаҗан әфәнде, ярлыкларны бирсәгез, хәзер туй итәрбез. Юкса, Дилбәр туташ минем хатыным дип хәзер игълан итәм.

Габдуллаҗан. Ә кем, профессор әфәнде, ни эшлибез соң? *(Мусага.)* У-у-у... сине, күмер карагы! *(Кизәнә.)*

Искәндәр. Эш сездә. Әгәр хәзер үк ярлыкларны бирсәгез, Мәйсәрә туташ минем хатыным дип хәзер үк игълан итәм. Теләсәгез, туйны да бүген үк итәргә мөмкин. Юкса...

Габдуллаҗан. Ярый. Аллага тапшырдым. Риза.

Искәндәр. Юк, кулга ярлыклар кермичә, мин риза түгел.

Габдуллаҗан. Бетте, бетте, риза. Хәзер алып килермен. У-у, сине, күмер карагы! Йә, Мәйсәрә минем хатыным дип игълан итегез!

Искәндәр. Әфәнделәр, хәзер мин сезнең алдыгызда бик зур эш ачачакмын... Әфәнделәр, мин өйләнәм...

Барысы. Өйләнәсез! Кемгә?

Искәндәр. Мин... *(Габдуллаҗанга карый. Дилбәргә карый.)*

Габдуллаҗан. Ярый, ярый, риза. Алып киләм... *(Чыгып барганда.)* У-у... сине, күмер карагы! *(Кизәнә.)*

Муса. Профессор әфәнде, зинһар, байлыкка кызыкмагыз, кызы юләр бит. Җырлый да, бии дә, пианинода уйный да, французча сөйләшә дә белми. Минем кызым милли алтын бит!..

Габдуллаҗан керә.

VII. Әүвәлгеләр һәм Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Менә, кияү, рәхим ит! Бөтен бәхетемне кызым белән сиңа тапшырам!.. *(Искәндәр алып язуларны карый.)*

Муса *(Муса белән Дилбәр бер читтә посып, боегып басып торалар)*. Кызым, әйдә, киттек. Дөньяда акчага сатылмаган нәрсә юк икән, Америка профессорлары да акчага сатылалар икән. Әйдә, кызым, үзеңә насыйп милли егет табылыр әле. *(Чыгалар.)*

Габдуллаҗан. Кияү, мунча ягарга кушмыйкмы?

Искәндәр. Кушыгыз!..

Шәехмирза. Профессор әфәнде, Америкага баргач, зинһар, миңа берәр профессорлыкка урын хәзерләп куегыз әле.

Искәндәр. Ничек, Мәйсәрә, бу кешегә профессорлыкка урын хәзерлимме?

Мәйсәрә. Хәзерлә.

Искәндәр. Ярый, профессор булырсың. *(Төртә.)*

Шәехмирза. Бик, бик рәхмәт!.. *(Кулын кыса.)*

Сәлимгәрәй. Профессор әфәнде, берәр полициядә урын табылмасмы?

Искәндәр. Табылыр.

Сәлимгәрәй. Рәхмәт.

Сәлим. Профессор әфәнде, миңа ярлыкларның читләрен генә, әз генә, ерактан гына күрсәтмисезме?

Искәндәр. Күрсәтермен. Әфәнделәр, мин бүгенге милли тарихи кичәне яңача үткәрмәкче булам. Шуның өчен картлардан бер биш минутка гына чыгып торуларын үтенәм.

Барысы. Чыгабыз, чыгабыз!..

И с к ә н д ә р. Мин чакырмыйча кермәгез!

Г а б д у л л а җ а н. Ярый, ярый, әйдәгез, кунаклар, кияү белән кызның саулыгына бераз пирәшләп ала торыгыз!

Чыгалар.

И с к ә н д ә р. Ә син, Мәйсәрә, барып, ак күлмәгеңне киеп чык. *(Төртә.)*

М ә й с ә р ә. Төртмә әле, юньсез, никах укылганы юк ич әле. Һи-һи-һи!.. *(Чыга.)*

X. **И с к ә н д ә р.**

И с к ә н д ә р. Мондагы халык үзләре тарихи ярлыклар икән. *(Ярлыкларны күтәреп чыгып китә.)*

XI. **М ә й с ә р ә**, соңыннан башкалар чыга.

М ә й с ә р ә *(кереп, Искәндәрнең киткәнен күреп).* Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм, кая киттең?! Качты, качты!.. Әткәй, әткәй, әткәй!..

Г а б д у л л а җ а н. Нәрсә, ни бар?

М ә й с ә р ә. Әткәй, киявең качты!..

Г а б д у л л а җ а н. Ә?

Б а р ы с ы. Тес-с-с!..

Г а б д у л л а җ а н. Харап булдык! Нәрсә карап тордың! Соң син, чүпрәк баш, ни карап тордың!..

Б а р ы с ы. Тес-с-с!.. Тегеннән булмасын.

Г а б д у л л а җ а н. Ә?

Б а р ы с ы. Утларны сүндер!..

Г а б д у л л а җ а н. Тес-с-с!..

Б а р ы с ы. Тес-с-с!...

Утлар сүндерелә.

Пәрдә.

1923

Фатих Әмирхан

ШӘФИГУЛЛА АГАЙ[1]

Хикәя

I

Ленин күмелгән көннең кичендәге митингтан кайтып кергәндә, Шәфигулла агайның күңеле соң дәрәҗәдә нечкәргән, күзләре яшәргән иде.

— Бүгеннең нинди көн икәнлеген беләсеңме син?—диде Шәфигулла агай хатыны Сәрвигә.— Владимир Иличне күмгән көн бит бүген,— диде дә мышкылдап елап та җибәрде һәм күз яшьле тавышы белән сүзен дәвам иттерде:

— Бөтендөнья эшчеләре үзләренең башлыкларын җуелткан көн бит бүген... Бөтендөнья эшчеләре ятим калган көн бит бүген... Бөтен җир, күк җыларга тиеш көн бит бүген...

Шәфигулла агайның моннан соңгы сүзләре аңлашырлык булмады: елаш, мышкылдаш, борын йомшару һәм күз яшенең көчәюе сүзләрне басканнар иде. Бераз тынычланган шикелле булгач, салмак кына селкенеш белән урыныннан торып:

Вы жертвою пали в борьбе роковой...

дип, «Күмү маршы» җырлый башлаган иде, ләкин аны да дәвам итә алмады, янә төелеп тукталды да урынына ташланды. Сәрви күптән инде иренең, партиясез булса да, Ленинга бик ихласлы икәнен белсә дә, аңа Шәфигулласының бүгенге бу кадәр йомшаруы көтелмәгәнрәк бер хәл иде: Шәфигулла агай, Ленинның үлүен ишеткәч, чын күңелдән кайгырган булса да, бу көнгә хәтле әле болай күз яше белән еламаган иде. Сәрви ире елаудан туктаганнан соң гына сүзгә кереште:

[1] Кыскартып алынды.

— Байлар бик куанырлар инде... Безнең фәкыйрь халыкка тагын көн калмас инде... — диде.

— Юк! — диде Шәфигулла агай, урыныннан сикереп торып, йодрыгы белән күкрәгенә сукты.— Юк, катын, байларга юл бирү юк инде ул!.. Рәхимов ибдәш әле генә менә шуны сөйләп кайтарды: Бладимир Илич үлгәнгә карап, ди, без буржуйларга юл бирмәмез, ди... Линин үлмәде ул: аның партиясе калды, ди... Инде Линин үлгәч, һәммә сазнателни рабучийлар партиягә керергә тиешләр, менә хәзер «линински набур» башлана: рабучи халык, партиягә язылып, бөтендөнья буржуйларының котларын чыгарсын, Линин үлгәнгә шатлануларын җимерсен, ди...

Шәфигулла агай Рәхимов иптәшнең сүзләрен кызыпкызып, гайрәтләнеп-гайрәтләнеп, кат-кат әйтә-әйтә сөйләде дә:

— Һәй катын! — диде.— Һәй катын, син дә сазнателни булсаң иде... — диде, ләкин сүзенең ахырын әйтеп бетермәде. Аның йөзеннән, күзләреннән бер татлылык, әгәр Сәрви дә сознательный булса, бик татлы булачаклык күренеп тора иде. (...)

— Бик әкәмәт кеше син, карт: тотасың да шулай дисең. Минем кайчан байлар яклы булганымны күргәнең бар? — диде Сәрви җәберсенү тавышы белән.

— Ул гына җитми тагы!.. Дурман бар синдә, рилигиузный дурман!.. Шул харап итә сине, шул! Тавариш Михайлов әйтә: «Сезнең хатыннарыгызда рилигиузный дурман бар,— ди.— Сез үзегез сазнателни рабучи булгач, Аллага, Исуска, Магуметкә, пупларга, муллаларга ышанмыйсыз инде, билгеле, ә менә сезнең катыннарыгыз, шуларга ышанып, сезгә чын сазнателни рабучиларча торырга, камунистларча «Красный быт» төзергә ирек бирмиләр»,— ди. Рәхимов ибдәш әйтә: «Татар рабучиларын да шул эш харап итә, аларның да катыннары дин белән агуланганнар,— ди,— дин — әфиун ул, агу ул,— ди.— Сазнателни рабучий Аллага, Мөхәммәткә, муллага ышанып, үз-үзен алдалап йөрмәс, сез үзеңез ул чипухаларга ышанмый торгансыздыр бит,— ди...— Күбегезнең катыннары нисазнателни, сез, ирләр, аларга аңлатырга тиешләр»,— ди...

— Әстәгъфирулла, диген, карт җүләр... Ходай орыр үзеңне...

— Менә, катын, дурманың тотылды хәзер! — диде Шәфигулла, аның йөзенә һәм күзләренә хәйләкәр булдыклылык төсе чыккан иде.— Синдә рилигиузный дурман бар. Ә үзең, нисазнателни дигәч, миңа ачуланасың... Нисазнателни син! Дурман син...

Шәфигулла теленә бүген әүвәл мәртәбә кергән бу «дурман» дигән сүз, мәгънәсе аңлашылмауга карамастан, Сәрвигә бик начар тәэсир итте: бу сүз «нисазнателни»гә караганда да авыррак шелтә сүзе, каты сүгенү сүзе шикелле тоела иде. Сәрви ачуланды:

— Дурман, имеш! Мин нишләп дурман булыйм, минем, Аллага шөкер, бер гаебем юк!.. Мине бер кеше дурман дия алмас!.. Син үзең менә карт башың белән Аллаһыга тел озайтып утырасың, менә шул кеше нисазнателни дурман була ул! — дип, шактый ярсыды.

Хатыны ярсыганнан-ярсый башлаганда, Шәфигулла сүз озайтып тормый, татлы көлү белән мәсьәләне борып җибәрә иде. Гадәтенчә, ул бу юлы да шулай итте: хатынының, религиозный дурманы тотыла торып, «дурман» дигәнгә ачулануы һәм моның үзен — инде динле булудан бөтенләй тәүбә итеп, дурманнан бөтенләйгә котылып калган сознательный рабочий Шәфигулланы — «син үзең дурман» дип сүгүе аның көләсен китерә иде...

II

Көннәрнең берсендә Шәфигулла агай төче шатлык һәм ләззәтле рух күтәренкелеге белән өенә кайтып керде. Сәрви өйдә булмаганлыктан, Шәфигулла агайга үзенең ләззәтле тойгыларын сөйләп бүлешергә насыйп кеше юк иде. Ул уйлап кына ләззәтләнеп утырмакчы булган иде дә, барып чыкмады.

— Шөкер Ходайга, партәйни дә булдык бит... — дип уйлана башлаган иде, кинәт куркынып китте һәм тиз-тиз генә: — Тфү, тфү! — дип, ике ягына икешәр мәртәбә төкерде.— Какуй чурт, мин сиңа әйтим, Ходайга шөкер булсын! Карт җүләр! Синең үзеңнең дә дурманың чыгып бетмәгән әле... Ячәйкәдә тәрбияләнәсең бар әле синең... Башыңдагы миеңнең дурманлы кисәген чокчып алырга кирәк әле... — диде дә үз каршындагы диварга эленгән иске рамлы шәмаилгә[1] карап тора башлады. Рамга куелган, инде саргая башлаган кәгазьгә чолгап-чолгап бисмиллалар язылган иде. Бисмиллага бераз карап торганнан соң, Шәфигулла хәйләкәр булдыклылык көлеше белән көлеп җибәреп:

---

[1] *Шәмаил* — рам эченә язып куелган дини эчтәлекле текст.

— Һһһәй! — диде.— Һһһәй, без рабучи халыкны шушы дурманнар хәзергә хәтле харап итеп тоттылар шул, шушы дурманнар: икуналар, бисмиллалар, пуплар, муллалар... — диде һәм, урыныннан серле генә кузгалып, тагы бер кат хәйләкәр генә көлеп җибәрде дә, рамлы бисмилланы дивардан алып, бераз вакыт нишләтергә белмичә кулында тотып торганнан соң, пөхтәләп кенә кәгазьне рамнан алды һәм, сигезгә бөгеп, кесәсенә салып куйды:

— Пример булыйм әле барсына! — диде.

Ярты сәгать үтәр-үтмәстән, Шәфигулла агай, бик ашыгып, завод капкасыннан барып керде һәм җыелышып йорт уртасында сөйләшеп тора торган эшчеләр төркеменә килеп җитте дә:

— Иптәшләр, минем сезгә бер гозерем бар иде,— диде.

— Тыңлыйбыз! — диделәр эшчеләр.

— Юк,— диде Шәфигулла агай,— юк, алай гына тыңларга уен эш түгел бу, егетләр. Мин барыгызга да пример булсын дип эшлим әле бу эшне. Сез миңа завкум прсидәтелен, ячәйкә сикритәрен, үземезнең эшче-хәбәрчемезне чакырып чыгарыгыз, шуннан соң мин сезгә сүземне дә әйтермен, эшне дә эшләрмен, ийе, уен эш түгел ул! — диде.

Чакырылган кешеләр табып китерелгәнче, Шәфигулла агай көтү сабырсызлыгы белән ары-бире йөренгәли торды, бер-ике мәртәбә үзенең күкрәге турысын өстән-аска таба сыпырып алды, өч-дүрт мәртәбә үзенең кәҗә сакалын учлап тотып сыпырды: ул ашкынып борчыла иде.

Килеп җиттеләр. Шәфигулла агай, үзенә серле төче бер төс чыгарып, уртага басты, татлы гына тамак кырды, тантаналы тавыш белән сүз башлады:

— Икуналар, бисмиллалар безнең эшче халыкны хәзергә хәтле бик күп изеп тордылар. Без, сазнателни эшчеләр, ул дурманнарны бетерергә тиешләр. Менә мин — сезгә примир!

Шәфигулла кесәсеннән бисмиллалы кәгазьне чыгарды да, аны җәеп тотып, торган урында түгәрәкләп әйләнеп, җыелганнарга күрсәтте дә:

— Күрдегезме дурманны? — диде.

— Күрдек! — диделәр.

— Мин бу бәдбәхетне, стинага элеп куелган җиреннән тартып төшереп, монда алып килдем,— диде дә урталайга ертты, тагы ертты, тагы ертты, вак-вак кисәкләргә тураклап бетереп, җиргә ташлап таптарга керешге:

— Менә! Менә! Менә! Менә!..

Биеп-биеп таптады. Рәхимов белән ячәйкә секретаре кул чабалар, «браво!» кычкыралар иде, тыңлаучылар арасыннан аларга иярүчеләр шактый булды. Таптап туктавына, шулар ук Шәфигулла агайны һавага да чөйделәр...

Заводтагы эшен тәмамлап өенә кайтканда да әле Шәфигулла агайның татлы тантаналы кәефлелеге кимемәгән иде. Бөтен йөзе һәм күзләре белән татлы елмаеп, ул Сәрвигә якын ук килде дә:

— Шәфигулла иптәшең кайтты, катын,— диде,— илле дүрт яшьлек сазнателни карт примир, мин сиңа әйтим...

Ачулы йөз белән каршы алган Сәрвинең шәмаиленнән алынган бисмилла өчен бәйләнә башлавы Шәфигулланың татлылыгы киңәергә ирек бирмәсә дә, ул бирешмәде:

— Һәй катын... — диде, төче көлеп җибәрде.— Безгә, партәйни кешегә, мөмкин дә түгел эш! Синең дурманыңны күз алдында күреп чыдап тору мөмкин дә түгел, катын! Кадеремне белергә тиеш, менә шуның аркасында бөтен эшче-крәстиәнгә примир булдым: кул өстендә чөеп йөрттеләр... Кем ире дигәндә, Сәрви ире диярләр бит, сиңа да йөз аклыгы, мин сиңа әйтим... Синең дурманың урынына мин Бладимир Илич партритын алып кайтып элеп куям: бөтен эшче-крәстиәнгә тагын бер примир, мин сиңа әйтим...— диде. (...)

III

«Кызыл тормыш» төзү турындагы митингтан Шәфигулла агай ячейка сәркятибе[1] һәм фабзавком рәисен ияртеп кайтты. Аның йөзенә чыккан татлы төчелек белән бергә күзләренә чыккан серле хәйләкәрлекне күрүгә, Сәрви, беркадәр куркынып:

— Ни булды, карт? — дип сорады.

— Юк инде, Сәрви ибдәш, карт-март дигән сүзләреңне хәзергә куеп тор инде... Иртәгә савитски никах укытканчыга хәтле, мин сиңа ир түгел, син миңа катын түгел,— дип, Шәфигулла серле төче көлеп җибәрде... Аптыранган Сәрви бу сүздән исәреп китте:

— Син акылдан шашасың мәллә, карт дурак? Егерме елдан артык катын булып торырга яраган Сәрви инде катын булырга

---

[1] *Сәркятип* — секретарь.

ярамый башладымыни? Инде марҗа кирәк булдымыни? — дип тавыш күтәрде.

— Һай наданлык, һай нисазнателнилек, Сәрви ибдәш,— дип, Шәфигулла агай, кет-кет итеп көлеп җибәрде.— Һәй аңсызлык! — диде. Аннан соң, алып килгән кунакларга карап:

— Сез, ибдәшләр, шаһит булыгыз: Сәрви миннән талак, талак, өч мәртәбә талак, мең мәртәбә талак! — диде, йөзе һәм күзләре белән төче елмаеп, Сәрвигә таба якынлаша башлады. Сәрви, елый-елый, ирен сүгәргә тотынды:

— Карт эт, котырынды бит... Егерме ел торган катыны ярамый башлады бит... балаларны ятим итә бит...

— Һәй наданлык, һәй нисазнателнилек, һәй аңламау,— дип, Шәфигулла, төче көлеп, Сәрви янына килергә тели. Ләкин Сәрви, елый-елый сүгенеп, читкә тартыла иде. Хатынының теләмәвенә карамастан, сүгенүенә карамастан, Шәфигулла мәсьәләне аңлатырга керешге:

— Мин сине иртәгә хәтле генә талак итеп торам бит: сәвитски никах укытканчы, сәвит кушканчалап, икәү барып теркәлеп кайтканчы гына талак итеп торам бит... Безгә, партәйни кешегә, дурманлы мулла никахы белән торырга ярамый бит — шуннан гына мин сине өч талак итәм бит... Менә иртәгә барып теркәлеп кайтамыз, яңадан син минем катын булып китәсең бит...

Шәфигулла агай, көч-хәл белән хатынын елаудан туктатып, көч-хәл белән аңар үзенең планын аңлатты.

— Без харам булдык бит соң,— диде Сәрви, яңадан йөрәксенеп.

— Һәй, нисазнателни соң син, Сәрвиҗамал,— дип, Шәфигулла аңар хәйләкәр караш белән карап тора башлады.— Шул кирәк тә шул. Безгә дурман буенча харам булу кирәк тә... Дурман буенча харам булып, сәвитски никах белән, чын-чын сазнателни никах белән, дурманнардан, икуналардан, муллалардан котылып, «красный быт» төзеп тора башлыймыз да шул. Шуның өчен мин сине партәйни ибдәшләрнең зурлары алдында талак иттем дә шул. Рәхимов ибдәш әйтә: «красный быт» төзеп тора башламыйча, иске симйәне җимермичә торып, сезнең һичберегез чын каммунист була алмый, чын сазнателни була алмый»,— ди... Менә мин хәзер тагы бер кат эшче-крәстиән ибдәшләргә примир булам. Илле дүрт яшьлек сазнателни карт! Мулла укыган дурманлы никахны бозып, чын красный никах укыттырам... Һәммәсенә примир, мин сиңа әйтим...

Икенче көнне «Гражданлык хәлләрен теркәү бүлеге»ндә никах теркәтеп кайткач, Шәфигулла агай Сәрвине яңадан «катын» дип йөртә башлады. (...)

IV

Икенче көнне эштән кайтышында, Шәфигулла агайны зур кызыл әләм тоткан хәлдә күрделәр: урта бер җирендә урак белән чүкеч сурәте төшерелгән кызыл әләм аның җилкәсендә тыныч җилферди, ул үзе, уйчан эшчәнлек кыяфәте белән эре-эре һәм солдатча «бер, ике, өч», «бер, ике, өч» үлчәвенә тигез басып, чит-читкә карамастан, вәкарьле һәм эре бара иде.

Өенә дә ул шул кыяфәтендә кайтып керде һәм, өендәгеләргә бер сүз дәшмәстән, әләмне, зур хөрмәт белән, карават өстенә яткырып куйды да:

— Катын, былбылны кичкә әзерләп куй! — диде. Сәрви аңлап җитмәде:

— Нинди былбылны, нәрсәгә әзерләргә? — дип сорады. Шәфигулла агай хатынының аңсызлыгына мөзахчән[1] көлеп җибәрде:

— Кемне булсын, Вәлиулланы әзерлә, дим. Син партәйни түгел, сиңа Вәлиулла дип йөртсәң дә, чуртулла дип йөртсәң дә ярый; ә безгә, партәйни кешегә, баланы андый юк-бар дурманлы исемнәр белән атап йөртергә булмый... Бүген кичкә, клупка алып барып, бөтен ячейка хозурында балага настояшши сәвитски исем куштырамыз...

Клубка барыр вакыт җиткәч, Шәфигулла алты айлык Вәлиулланы үз кулы белән кызыл әләмгә төрде дә, баланы Сәрвигә тоттырып, үзе әләмнең таягына тотынды:

— Бәхетле җаннар, мин сиңа әйтим; бәхете белән дөньяга килгән балалар, мин сиңа әйтим: алты айлык вакытларыннан кызыл әләмнәргә төрелеп, ячәйкә хозурларына баралар; телләре чыкмас борын, мин сиңа әйтим, сазнателнилеккә язылалар... Кече-кечедән, мин сиңа әйтим, йөз аклыгы белән үсәләр...

Клубка барып кергәндә, Шәфигулланың күңеле тантаналытөче йомшарган иде:

— Гает намазына барган шикелле, мин сиңа әйтим, — димәкче булган иде дә, кинәт аңына килеп алды:

---

[1] *Мөзах* — мәзәк, көлке.

— Гает намазларың, кадер кичәләрең бер тиен тормый моның янында, мин сиңа әйтим...— диде.

Клубта Шәфигулла, кәкре-кәкре басып, кешеләргә тантаналы-төче карап-карап, татлы тамак кырынгалап йөрде: тәмле иде. Рәхимов иптәш «кызыл тормыш» төзү турында вәгазь сөйләде: вәгазендә Ленин сүзләреннән, Маркс әсәрләреннән, Калинин нотыкларыннан гыйбарәләр китереп, «кызыл тормыш» төзүнең һәрбер коммунистка, һәрбер сознательный эшчегә лязим[1] икәнлеген, бер дә шик калдырмаслык итеп, бәян итте. Шәфигулла, чыдаша алмастан, хатынының кабыргаларына култыгы белән төртеп, кашын сикертеп җибәрде:

— Ишетәмсең, Сәрвиҗамал? Ишетәмсең, катын? Бладимир Илич белән Маркс ибдәш сүзләреннән генә алып сөйли бит... Авызыңны капладымы? — диде.

Сәрвиҗамал үз авызының капландымы, юкмы икәнен белми һәм ул турыда уйламый да иде:

— Җәдәтмә әле мине! — диде.

Вәгазьдән соң, Рәхимов иптәшнең кушуы буенча, «Интернационал»ны күмәк җырладылар; Шәфигулла агай Сәрвигә, җыр вакытында аяк өстенә басып, шәлен салып торырга кушты.

Бу эш беткәч, Шәфигулла һәм Сәрвине, баласын күтәргән хәлдә, сәхнәгә чыгардылар. Җыелганнар боларны бик каты кул чабып каршыладылар. Сәрви каушаган, Шәфигулланың күңеле йомшаган иде; шатлык һәм күзгә яшь килә башлау тавышы белән Шәфигулла:

— Ягез, ибдәшләр, тагын бер кат «Интернасианал»дан җырлап алыйк сана! — диде, кулы белән Рәхимов һәм Михайловлар төркеменә таба бер ишарә ясады. Җырладылар. Шәфигулланың күзләреннән шатлык һәм төчелек яшьләре тамдылар. Һич бер әсәрләнү күрсәтми торган Сәрвинең кыяфәтен күрү Шәфигуллага начар тәэсир итә иде.

— Синең җөрәгең таштандыр, Сәрвиҗамал... Һай нисазнателнилек... шушы эшләрне, бу шатлыкларны күрә торып... Һәй наданлык, һәй аңсызлык...— диде.

Әүвәлдән төзелеп куелган программа буенча тантаналы эшләр башланды.

Шәфигулла агай, кызыл әләмгә төрелгән Вәлиулланы кулына алып, сәхнәнең нәкъ бер урта җиренә килде. Халык төрке-

---

[1] *Лязим* — тиеш, мәҗбүри.

менә карап, артистларча бер баш иде, аннан соң баланы ячәйкә сәркятибенә китереп, төче тавыш белән, Рәхимов өйрәтеп керткән нотык сыман нәрсәсен сөйләде:

— ...Менә бу бәхетле җанны, раднуй баламызны, мин сиңа әйтим, бөтендөнья кызыл әләменә төреп, РКПның корыч ячәйкәсенә тапшырамыз... Бладимир Илич үлде, әмма аның партиясе үлмәде... Сезгә тапшырамыз...— диде. Күңеле йомшарганлыктан сүзен дә дәвам итә алмыйча, баланы тизрәк сәркятипкә таба сузды. Иң кирәклесе әйтелеп бетмәгән иде, шунлыктан аларын Рәхимов өстәде:

— Иптәшләр, бу сознательный семья балаларын Владимир Ильич кушкан юл белән алып барырга һәм РКПның корыч сафларына тагы бер сознательный эшче тәрбияләп үстерергә сүз бирә... Ура!..— диде.

— Сүз бирәмез, сүз бирәмез, менә Сәрвиҗамал да сүз бирә,— диде Шәфигулла агай; Рәхимов авызыннан сознательный дигән сыйфатны ишетү белән, ул очынырга хәзер тора иде: акрын гына, төче генә хатынының кабыргасына төртеп алды:

— Ишетәмсең?..

Балага исем сайлау мәсьәләсе ячәйкә әгъзаларына тапшырылгач, һәркем үзе мөкатдәс һәм коммунистлык өчен мөнасиб[1] санаган исемне, кыскача фазыйләтләрен[2] сөйләп, гарыз итә[3] башлады:

— Нинел! — дип кычкырдылар бернечә тавыш берьюлы.— Ленин фамилиясенең хәрефләре кире яктан төзелүдән хасил була,— диделәр.

— Ул исем бит күбәйде инде. Безнең ячәйкәдә генә кырык өч балага шул исем кушылды, балалар үзара бит саташтырылырлар,— диделәр бер-икесе.

— Саташтырылсалар, бигрәк тә яхшы. Коммунистически обществода берәм-берәм личностьләргә игътибар булырга тиеш түгел. Личность булмый, коллектив кенә була,— диде бер коммунистический университетның үзен үзе Колынбайский дип йөртә торган бер шәкерте.

Ячәйкәнең зурлары аның сүзләренә игътибар итмәделәр: аның укымышлылык күрсәтер өчен генә көчәнә торган талиб[4]

---

[1] *Мөнасиб* — яраклы.

[2] *Фазыйләт* — өстенлек, артыклык.

[3] *Гарыз итү* — хәлне аңлату.

[4] *Талиб* — укучы, шәкерт.

икәнен һәммәсе дә беләләр иде инде. Исем эзләү дәвам иттерелде:

— Икстурт! — диде бер кызыл армияле.— Иптәш Троцкий фамилиясенең хәрефләре кире яктан төзеп әйтелә...

— Нинилак! — диде бер картрак эшче.— Иптәш Калинин фамилиясе ахырыннан башына таба укыла...

— Чыф фахыт латта латтит! — диде үзен имажинист шагыйрь дип йөртә торган бер егет.— Яңа майланган машинадан чыга торган революционный тавыш. Чын коммунист машина тавышын мөкатдәс санамаска не может...

— Чыгыр тогы! — диде бер футурист.— Иске сүзләрне себереп түгеп, яңа сүзләр ясамасак, без бервакытта да «кызыл тормыш» төзи алмамыз, бервакытта да чын сознательни коммунист булалмамыз...

— Кызыл чүкеч! Хезмәт галәмәте һәм урак-чүкеч эмблимының бер кисәге...

Тагы бик күп шундый исемнәр гарыз ителде. Иң ахырдан гына вәкарь белән Михайлов урыныннан торды да:

— Владимир! — диде.— Әйдә, Владимир Ильич үлгән елда туган балаларның күбрәге һәм матур, һәм яңгыраш шәп булган шушы һәрбер коммунистка һәммә нәрсәдән кадерле булган исемне үз өстендә йөртсен; әйдә, бу исем күп миллионнар бәйнәлмиләл[1] эшчеләрнең исемнәре булсын, әйдә, бу исем эшчеләр арасында милләт аермасы бетүнең, шовинизм бетүнең галәмәте — символы булсын!..

— Ийе, Владимир! — диде Рәхимов.— Чынлап та, татар баласына әүвәл мәртәбә кушыла торган бу исем, һәр сәгатьтә, һәр минутта кадерле юлбашчымызны искә төшереп тору белән бергә, бөтендөнья сознательный татар эшчеләренең инде милли шовинизм һәм дин дурманнарыннан бөтенләйгә котылган икәнлекләрен күрсәтеп торачакдыр... Бу эш бөтен татар эшчеләренә коммунистлык үрнәге булыр...

Шәфигулла агай, канатланган кыяфәт белән халыкка карап, кулларын селкеде:

— «Интернасианал»дан, җәмәгать!..

Җырладылар. Владимир исеме кушуның «кызыл тормыш» өчен ярдәмен тәфсилләп сөйләделәр. Берәү, чыгып, Вәлиулла-Владимирның пионерлар сафына кабул ителгәнлеген сөйләп,

---

[1] *Бәйнәлмиләл* — интернациональ, халыкара.

аңар пионерлык билеты бирде. Берәү, торып, кечкенә Владимирның ячәйкә мәдәни шефлыгына алынып, фикри тәрбия ягыннан Михайлов нәзарәтенә[1] тапшырылганлыгын белдерде. Ячәйкә әгъзалары, бала янына килеп:

— Володя! Володечка! — дип, аны түчт иттерделәр. Баланың өстенә ячәйкәнең кызыл әләмен бөкрәйтеп тоттылар. Балага киемлек һәм чүпрәклек кызыл материя бүләк иттеләр. Ата-анасына завод хисабыннан 30 сум акча бирделәр һәм бала тәүсыясе[2] өчен айлык ун сум биреп барырга язу бирделәр. Шәфигулла белән Сәрвине һавага чөйделәр. Бу эшләр арасында берничә мәртәбә «Интернационал» җырлап алдылар...

V

— Балалар «Интернасианал»ларын җырламый ятканнардыр әле? — диде Шәфигулла агай, ячәйкә җыелышыннан соңга калып кайтып, балаларының инде йоклап яталар икәнен күргәч.

— Җырламасалар, күк җимерелмәс әле аннан! — диде йокысы бик килгәнлектән кәефсезләнеп утыра торган Сәрвиҗамал.

— Һай дурман баш! — диде Шәфигулла, кәефсезләнеп.— Ана нисазнателни булгач, бала бозылмый нишләсен соң...

Шәфигулла агай, йоклап ята торган балалары янына килеп, аларны уятырга тотынды:

— Балалар, былбыллар, торыгыз әле, бәбкәләрем, торыгыз әле, җаннарым, «Интернасианал»ларыгызны җырлыйк әле, бәгырьләрем...

Балаларның торасылары килми иде.

— Торыгыз, былбыллар, торыгыз, сезгә, камсамулларга, «Интернасианал»сыз йоклау оят була... Анагызга ярый, анагыз ул партәйни дә түгел, камсамул да түгел... Әмма сезнең белән миңа «Интернасианал»сыз булмый, безгә ярамый...

Балалар, бик авырлык белән генә уянышып, теләмәстән генә аяк өскә бастылар һәм, башка кичләрдәге шикелле, йөзләрен Ленин рәсеменә юнәлттеләр. Шәфигулла агай Володяны уятып, бишегеннән алып, кулына күтәрде. Сәрвигә дә аяк өстенә басарга кушты һәм, Сәрвинең урыныннан тормаганын күргәч, башындагы яулыгын тартып алып, аны ялан баш калдырды да

---

[1] *Нәзарәт* — күзәтеп тору, контроль.

[2] *Тәүсыя* — тәрбия.

төче генә, ләкин җитдиятле тавыш белән «Интернационал» җырларга керeште. Балалар да аның артыннан иярә башладылар, ләкин йокы исереклеге белән алар саташалар иде. Шәфигулла агай, аларның ялгышканнарын сизенеп, җырлауда бер тыныш ясады да, яңадан башыннан башлап җырлады. Бу юлда инде балалар ялгышмый очлап чыктылар.

— Менә маладис, менә шулай,— диде Шәфигулла, балаларын аркаларыннан сөеп.— Менә шулай, менә хәзер инде сезгә дә тынычлап йокларга ярый... Менә зурайгач әле үзегез дә миңа рәхмәт укырсыз... Мәңге йөз аклыгы, мин сиңа әйтим... Безнең әти бичара үзенең нисазнателнилеге белән һәр көнне кич безне, әгузе бисмиллалар укытып, дурман белән агулап яткыра иде. Атагыз сазнателни булгач, атагыз партәйни булгач, сезне дурманнардан издерүче юк, мин сиңа әйтим... Кадерен генә белеп үсегез инде...

— Харап булган икән! Балалар җыру җырламый йокыга ятканнар икән... күк җимерелеп төшмәсә ярар инде! — диде Сәрви мыскыл тавыш белән.

— Күк җимерелмәсә! Күк җимерелмәсә, имеш! — дип, Шәфигулла кызып китте.— Күк җимерелер дип исең киткән, күк җимерелүдән дә яман шул, ун тапкыр яман, йөз тапкыр яман, милиун тапкыр яман... Адәмнең, мин сиңа әйтим, партәйни абязәннәсте бар... Болай итеп торсаң, мин сиңа әйтим, «кызыл тормыш» төзү кайда да, партәйнилегең кайда?

Бу көннән соң Шәфигулла агай балаларыннан һәр кич вә һәр иртә «Интернационал»ны икешәр тапкыр җырлата торган булды:

— Үзем өйдә юк көннәрдә җырланмый кала торганнар өчен булыр...

VII

Шәфигулла агай балаларын артына тезеп өйгә кайтып кергәндә, Сәрви һәм бер кунак карчык үзара тыныч кына сөйләшеп утыралар иде. Шәфигулла агай артындагы төркеме белән аларның алларына килеп басты да балаларга егетләрчә команда бирде:

— Смирна!

Балалар, солдатча басып, хәрәкәтсез калдылар. Шәфигулла агай утыручы хатыннарга илтифат итмәстән, балаларга янә бер әмер бирде:

— Теге сүзегезне кычкырыгыз!

Балалар солдатча кычкырдылар:

— Мы всегда готовы!

Шәфигулла агай балаларның олырагын, алгарак тартып чыгарып, кунак карчыгының алдына ук китереп бастырды:

— Әйтеп күрсәт! — диде.

Комсомол бала, яхшы ятлаган догалыкны укыган шикелле, ярым сөйләп, ярым укып китте:

— Польша буржуазиясе вәхши җанварларга безнең баһадир иптәшебез Энгель иптәшне үтертте. Буржуазия яхшы белеп торсын, безнең иптәшләребез комсомолларны үтертеп кенә ул үзен коткарып кала алмас. Шәһит[1] булган бер Энгель иптәш урынына безнең сафыбызга меңнәр, миллионнарча эшче-крәстиән яшьләре тезелер. Без, комсомоллар, буржуазиягә каршы рәхимсез сугыш ачып, Энгель иптәшнең кан үчен алырбыз. Бер Энгель иптәш урынына без буржуа ялчыларының меңнәрен җир йөзеннән юк итәрбез. Яшәсен Польша комсомоллары! Яшәсен бөтендөньяның коммунист яшьләр союзы! Яшәсен III Интернационал!

Ахыргы сүз әйтелеп бетәр-бетмәс, башка балалар күмәк кычкырдылар:

— Мы все готовы!

Алар белән бергә, Шәфигулла агай үзе дә кычкырды:

— Мы пчи гатауи!

Балаларына мәхәббәт һәм иркәләш караводы белән карады:

— Һи кызыл былбыллар!.. Һи кызыл арысланнар!.. Үсәләр дә, мин сиңа әйтим, мәңге бәхетләре белән!..

Аннан соң кунак карчыкка сөйләргә кереште:

— Һи Мөхиб абыстай, уйласаң җыларсың; бәхетсез дә заманнарда, нисазнателни ата-ана кулларында бәхетсез җаннар булып кына үскәнбез лә: безнең яшь заманнарда бу эшләрнең исе дә булмады бит... Үстек лә, мин сиңа әйтим, гафиллектә[2]! Менә бу кызыл арысланнар хәзер, мин сиңа әйтим, сәвит бәйрәмнәрен бәйрәм итеп, изге диманстратсияләргә чыгып, бөтен буржуаларның, мин сиңа әйтим, котларын очырып, йөз аклыгы белән, мәңге бәхетле үсәләр... Ә без, мин сиңа әйтим, синең белән Беренче май көннәрен дә гафил уздырып, дурманлы

[1] *Шәһит* — дөреслек өчен сугышта үлүче.

[2] *Гафил* — сизми калучы, надан.

әгузе бисмиллалар укып, диманстратсия дигән нәрсәләрнең төсен дә күрмичә, мәңге хурлыкта үстек... Уйлап-уйлап торам да исләрем китә: безнең әти бичараны беләсең инде син... Үлгән кешене сүксәң яхшы түгел, ә сүкмәсәң, мин сиңа әйтим, үзеңә авыр... Ул дурак карт самый настаяшши нисазнателни дурман иде бит: карт көнендә, котырынып, ишанга кул биреп, әллә нинди дурманлы догалар укып, зикер[1] әйтәм дип, әллә нинди әкәмәтләр эшләп, зикер мәҗлесенә барам дип, бәйрәм кичләрендә ишаны авылына барып йөреп, эшен калдырып, бөтен хуҗалыгымызны эштән чыгарып йөрде... Безне, балаларны, шунда ишан янына алып барып, аннан өшкертеп, аннан (...) догалыкларын күңелдән ятлатып укытып, адәм хуры итеп йөртә иде, бичара... Иһи-һи, Мөхиб әби, көләрсең дә, җыларсың да бу эшләрдән... Атабыз бичараның партәйни булмавы аркасында, адәм хуры булып йөргәнмез икән... Ә менә бу кызыл арысланнар... Болар настаяшши бәхетле җаннар икән...

Шәфигулла агай кинәт балаларга юнәлде:

— Ягезче, җанкисәкләрем, ягезче, кызыл арысланнарым, тагы бер кычкырып күрсәтегезче әбиегезгә!

— Мы все готовы! — дип күмәк кычкырып җибәрделәр балалар шаккатып сүз дәшәлмәс хәлдә калган Мөхиб әби өстенә...

Кич җитүне Шәфигулла агай түземсезлек белән көтте:

— Изге диманстратсия сәгатьләре... Пүлшә буржуаларының котларын чыгарыр сәгатьләр, мин сиңа әйтим...

Кичке сәгать уннарда инде Шәфигулла агай бер кулына Володяны күтәреп, икенчесенә гөрләп яна торган факел тотып, пионерлар фиркасенең әүвәле сафында, алар белән берлектә әле «Күмү маршы», әле «Интернационал» җырлап баралар иде.

— Мы все готовы! — дип кычкырган вакытларда, ул да, гаять зур бер дәрт белән:

— Мы пчи гатауи! — дип кычкырып йөри иде.

Төннең яңгырлы, яшенле булуына карамастан, демонстрация мәйданы кулларына факеллар тоткан комсомол һәм пионерлар белән тулды; тиешле көйләр белән тиешле күмәк җырлар кат-кат җырланды; тиешле мөәссәсәләр[2] тарафыннан җибәрелгән хатиблар, тиешле сүзләрне тиешле тавыш һәм

---

[1] *Зикер* — искә алу.

[2] *Мөәссәсә* — оешма.

аһәң белән әйтеп-әйтеп, тиешле нотыкларны сөйләделәр. Интизамга[1] салынган балалар фиркасе тиешле урыннарда, тиешле аһәң белән:

— Мы все готовы! — дип кычкыра тордылар...

Яңгырлы яшен астында йокысыннан уянып, куркынган, һәм суыктан чыкайган шикелле көйсезләнә, җылый торган Володяның интизасызлыклар[2] ясавы башта Шәфигулла агайны бераз кәефсезләндерсә дә, ул рухын төшермәде:

— Һи мушинник, нәни әле шул ул!.. Төшенеп җитми әле шул ул... Зурайгач, үзе дә рәхмәт укыр әле...

Көйсезләнү, елаулардан соң Володя арып, ничектер бөрешеп, тавыш-тын чыгармаслык дәрәҗәдә изелеп киткән иде. Шәфигулла агай, аны шул хәлдә өйгә алып кайтып, Сәрвигә тапшырды:

— Мә кызыл былбылыңны!.. Атасының кадерен белеп үссен инде... Нисазнателни анасы кулына калса, бичаракаем, пианир башы белән диманстратсиягә дә чыкмый калыр иде әле!.. Ана җүнле булмаса, бала мәшәкате ата башында була икән инде ул!..

Демонстрациянең өченче көнендә, Володя үпкә шешү авыруы белән авыр хәлдә ята иде. Сәрви ничәнче мәртәбәдер инде Шәфигулла агайга бәйләнде:

— Син карт дурак кына харап иттең баламны! Үзеңнең котырынып йөрүең генә җитмәгән, бер гөнаһсыз балаларның тәкатьләрен корытып йөртәсең, карт дурак, акылдан шашкан...

Сәрви аналык ачуы белән сүгенә иде. Шәфигулла агай аның белән чынлап сүгешмәде, ул үзе дә бераз аптырап калган иде:

— Юк сүзне сөйлисең син, әнисе!.. Нисазнателнилегеңә барасың син... Язмышы шулай булгандыр дияргә кирәк син... Син партәйни түгел, сиңа ничек дисәң дә ярый... Диманстратсиягә чыкканга карап, бала авырыймы соң?.. Бөтендөнья камсамуллары, бөтендөнья пианерлары ул көнне диманстратсиягә чыктылар, берсе дә авырмадылар, һәммәсе арыслан шикелле йөриләр, мин сиңа әйтим... Әнә Энгель таваришны әле камсамул булып җиткәч, буржуазия үтертте бит... Әле безнең Бәлүдә пианир гына бит ул!.. Мәңге йөз аклыгы...

---

[1] *Интизам* — тәртиплелек.

[2] *Интизасызлык* — уңайсызлык, тәртипсезлек.

Бала гаргарә[1] хәленә килгәндә, Шәфигулла агай каушаган хәлдә аның бишеге янында утырып тора иде:

— (...) Дәвасын күбрәк итеп эчертеп карыйк әле, энисе...— дип, ул дәва шешәсен бала авызына таба китерде.

— Кырырсың инде бу хәл җиткәч! Исән вакытында азаплаганың гына җитмәгән төсле, тагы үлем хәлендә дә баланы азапламакчы буласың,— дип, Сәрви иренең шешә тоткан кулын баладан этеп җибәрде.

Шәфигулла агай аптырашта иде:

— Нишләтеп багыйк икән соң кызыл былбылымны?..— дип, ул урыныннан купты.— Ячәйкә сикритаренә барып әйтеп баксам, ничек булыр икән? Партия зурлары берәр юлын тапмый калмаслар иде әле...

Шәфигулла агай фикерен бик кызу эшләтеп карады:

— Һә! — диде ул.— Барыйм әле, ячәйкәгә барыйм әле... Зәгъфран[2] белән язып эчертергә берәр нәрсә бирмәсләрме?..

Аның фикеренә «тәлинкәгә зәгъфран белән «Интернасианал» язып эчертеп карасаң, шифасы булмас микән?» дигән сымаграк бер нәрсә килгән иде, ләкин ул аны Сәрвигә әйтергә җөрьәт итә алмады...

Баланың җан биргүе беленгәч, Шәфигулла агай тавышсыз гына елап җибәрде дә моңлы, күз яшьле тавыш белән, көен бик ригая[3] итмичә генә «Күмү маршы» җырларга тотынды:

Вы жертвою пали в борьбе роковой
Любви беззаветной к народу...

Елый-елый җырлады; бер-бер артлы өч мәртәбә җырлады...

Күмү мәсьәләсендә Шәфигулла агай үз юлын яңлышмады һәм хәленнән килгән кадәр бик тырышты:

— (...) «Кызыл күмү» ясап, тагы эшче-крәстиянгә примир булыйм әле... Үзем өчен дә. Бәлүдә өчен дә бөтен партия алдында йөз аклыгы булсын әле... — ди-ди тырышты: табут сатып алып, аны кызыл буяуга буяттырды; каберне мөселман каберстанына түгел, уртак каберләр каберстанына казыттырды; үзенең һәм балаларының җиңнәренә бәйләр өчен кызыл һәм кара чүпрәктән катыш бәйләвечләр тектереп алды; мәетне кабергә

---

[1] *Гаргарә* — үлем алдыннан гырылдау.

[2] *Зәгъфран* — үсемлек (шафран).

[3] *Ригая* — кайгырту, карау.

озата барыр өчен балалайкада «Күмү маршы» көен уйный белә торган ике комсомолны чакырды; табут эчендә Володяның күкрәгенә пионерлык значогын тегеп калдырды...

Мәетне озатканда, Шәфигулла агай да юл буе балалайкачылардан уйнатып, үзе бертуктаусыз «Күмү маршы» җырлап барды, тамагы карылып[1] беткәнче җырлады. Мәет кабергә төшкәч, туфрак ташлаганчы, ул шартын китереп нотык сөйләде:

— (...) Кадерле ибдәш Бәлүдә! Син, кече-кечедән эшче-крәстиәнгә примир булып, изге пианирлар эчендә, РКПның корыч сафларында үстең... Мәңге, мин сиңа әйтим, йөз аклыгы белән кече-кечедән, мин сиңа әйтим, дөнья эшче-крәстиәннәре өчен җаныңны да кызганмадың... Ерткыч буржуазлар, капиталистлар, байлар, банкирлар аркасында, мин сиңа әйтим, син дөньядан вакытсыз киттең... Синең гәүдәң безнең арадан җуялса да, ләкин, мин сиңа әйтим, синең исемең безнең арада мәңге яшәр, без, мин сиңа әйтим, сине мәңге онытмамыз... Син үлдең, ләкин синең эшләгән эшләрең, мин сиңа әйтим, үлмәде... Син үлсәң дә, мин сиңа әйтим, синең юлың, синең партияң мәңге калды... Без барымыз да, мин сиңа әйтим, шул юлда җаннарымызны корбан итәргә ант итәмез... Эшче-крәстиән яшьләре, меңәрләпмеңәрләп РКПның корыч сафларына язылып, синең исемеңне мәңге калдырырлар...

Мәет күмелеп беткәч, Шәфигулла агай балалары белән берлектә өч мәртәбә «Күмү маршы» җырлады, елый-елый, үксиүкси җырлады...

Өйгә кайткач, Шәфигулла агайга үз кайгысына гына бирелеп утырырга мөмкин булмады, аны Сәрви бик борчый иде:

— ...Син карт дурактан гына булды!.. Син генә харап иттең баланы...

(...) Ләкин Шәфигулла агай бирешмәде:

— Һәй әнисе... Бер уйласаң, куанырлыгың да бар әле... Мондый күмелүләр бик аз кешегә насыйп була ул... Юл буе «Күмү маршы» уйнап, җырлап бардык... Кабере, мин сиңа әйтим, изге ривалүтсиә шәһитләре белән беррәттән... Мәңге йөз аклыгы, мин сиңа әйтим, бөтен эшче-крәстиәннең күз өстендә кашы... Исеме мәңге кызыл тактада... Бер пианир үлсә, мин сиңа әйтим, аның урынына меңләп эшче-крәстиән яшьләре

---

[1] *Карылып* — карлыгып.

РКПның корыч сафларына... Һәй анасы, бәхетле җан иде ул безнең кызыл былбыл... Мәңге йөз аклыгы инде барымызга да...

VIII

— ...Барам дигәч, барам... Авылдагы йортымның каралтыларын сатам да барам! — диде Шәфигулла агай.

— Кире беткән карт дурак! — диде Сәрви.— Партәйни кеше бер син генә түгел, синнән башка бер кеше дә болай котырынып йөрми...

— Һәй нисазнателнилек... Һәй дурман башлык... — диде Шәфигулла агай, төче сыкранып.— Әле дә алты ай сабыр иттем инде... Алты айдан бирле инде төннәрен йокламый шуны уйлап чыгам: Мәскәү дигән калаларга барып, Бладимир Иличнең йөргән урамнарын, торган йортларын күреп, кабер туфракларына йөзләремне сурсәм иде, дим... Сиңа, бизпартәйни кешегә, мин сиңа әйтим, барсаң да ярый, бармасаң да ярый... Әмма ләкин безгә, партәйни җаннарга... Һәй катын...

Йорт-каралтыларын сатарга барган җиреннән, авылдан Шәфигулла агай бик ашыгып кайтты:

— Ашыгу белән каралтыларны очсызрак сатып ташладым инде...

— Ике-өч көн соңга калсаң, Мәскәүдәге бәлеш суынып иде шул! Әйтерсең лә хаҗга бара! — дип шелтәләде аны Сәрви.

— Һәй дурман баш! — диде Шәфигулла агай, кәефсезләнеп.— Хаҗга бару түгел, имеш! Хаҗга бару шул! Синең дурманлы хаҗларыңнан мең-мең мәртәбә, млиун мәртәбә изгерәк хаҗ шул. Партәйни хаҗга барам шул!..

Бераз вакытлар узып тынычлангач кына, Шәфигулла агай үзенең ашыгуының сәбәбен Сәрвигә аңлатырга кереште:

— ...Сезгә, бизпартәйниләргә, бернәрсә дә түгел, әмма безгә, партәйни җаннарга, һәрбер кыймылдавыңны да исәп-хисап белән йөртергә тиеш була... Менә июль числасының башларында Париж дигән илләрдән Мәскәү калаларына изге каммунарларның әләм шәрифләре[1] килеп җитә... Бөтен эшче-крәстиән өчен иң беренче шатлык көннәре! Менә шуны ишеткәннән бирле, мин сиңа әйтим, төн йокыларым йокы түгел. Бладимир Иличнең кабер шәрифләренә барган юлы шул шәриф

[1] *Шәриф* — кадерле, кадерләүгә лаек.

әләмнәрне күрсәң иде; шул изге җаннарны каршы алсаң иде, дим... Шул көннәрдә партәйни бәндәләр Каминтирнгә җыелган бөтендөнья эшче-крәстиәннәренең нурлы йөзләрен күрәчәк, аларның изге сүзләрен ишетәчәк... Һи, мин сиңа әйтим... Шул көннәрдә изге калаларда булып, шул бәхет-шатлыкларга ирешсәң, мин сиңа әйтим... Бер көн кичекми китәм! Бер сәгать кичекми китәм!..

Шәфигулла агай бу көннең кичендә, Сәрви белән берлектә, дүрт кызыл әләм хәзерләде:

— ...Болар барысы да, мин сиңа әйтим, бөтен эшче-крәстиәннәрдән бүләк инде: берсе бөтен эшче-крәстиәннәрдән Калинин ибдәшкә... Берсе, мин сиңа әйтим, бөтендөнья эшче-крәстиәннәреннән Зинабиов[1] ибдәшкә... Берсе, мин сиңа әйтим, әләм шәриф китергән бөтендөнья француз ибдәшләренә... Ә берсе, мин сиңа әйтим, бөтендөнья ибдәшләреннән үзебезнең бөтендөнья РКПсына... Глаунииларына булгач, кечерәкләре гаеп итмәсләр инде... Хәлдә бары белән бигайбә, диярмен...

Юл хәзерләнүе тәмам булгач, Шәфигулла агай хатыны һәм балаларына соңгы сүзләрен әйтте:

— ...Ерак сәфәрләргә китәм инде... Сау-сәламәт күрешсәк иде!.. Атагыз изге җирләрдә, изге туфракларда була инде... Бладимир Илич каберләре өстендә мин, сезнең өчен дип атап та, «Күмү маршы» җырлармын... йөземне кабер туфракларына сүрермен... Аның кабереннән изге чишмә чыкмыйча калмагандыр әле, сезгә, боерган булса, шул изге чишмәләрдән су да алып кайтырмын... Изге илләрдә үлә-нитә калсам, хәтерегездән чыгармагыз... Әледән-әле «Күмү маршы» җырлап, миңа багышлый торган булыгыз... Аналары! Син күз-колак бул, балалар көндәлек «Интернасианал»ларын җырлый барырга онытмасыннар!.. Бу бәхет, бу шатлыкларның бик кадерен белегез: мондый изге сәфәрләр сезнең ибдәшләреңезнең аталарыннан бик әз кешеләргә генә насыйп була... Һи кызыл арысланнарым, һи кызыл былбылларым, һи кызыл балакайларым...

Шәфигулла агайның күңеле йомшарган иде: ул артык сөйли алмады, аяк өсте басып, күз яшьле тавыш белән «Интернационал» җырларга тотынды... Җыр тәмам булгач, балалары һәм хатыны белән кочаклашып күреште дә, бүктәрен аркасына тагып, кулына озын таяк алып, өйдән чыгып китте:

---

[1] Зиновьев.

— Бу бәхетләргә дә ирешер көннәрем җитте бит!.. Һи, мин сиңа әйтим...

Өч көннән соң «Красный тыл» исемле гәзитәдә Шәфигулла агайның портретын басып, түбәндәге сүзләрне язып чыктылар:

РАБОЧИ-КРӘСТИӘНГӘ ТАГЫ БЕР ПРИМЕР

Массадагы сознаниянең артуы удивительни бер темп белән бара: почти 60 яшенә достигать иткән татарин рабочи Шәфигулла, әле недавно гына партиягә записаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к черту җибәреп, полный сознательность проявить итте: катынының бисмиллалы бумагасын кусокларга рвать итеп, рабочи публика арасына алып килеп таптады; новорожденный ребенкасына Владимир куштырды; татар буржуалары, муллалары, кулаклары праздновать итә торган праздникләрне к черту җибәреп, советский праздникләрне итә башлады (пасха праздниген дә новый стиль белән, җивая церковь иткән времядә праздновать итте); семьясендә «красный быт» төзеп, хатынына мулла укыган никахны бозып, по-коммунистически регистрация белән генә тора башлады; балаларын бөтен религиозный дурманнардан освободить итеп, полный коммунистически быт белән торырга привыкать иттерде; и наконец, товарищ Ленинның гробын зиарәт итәр өчен, авылдагы хәҗәйствосын сатып, Москвага поехать итте... Шәфигулла иптәш ЦИКа партиягә, Коминтернгә һәм Советский власть представителе товарищ Калининга бөтен рабочийкрәстиәннән Красный Знамя подносить итәчәктер... Бу сознательный картның станокта эшләвенә скоро пятьдесят лет туладыр. Фабрик ячәйкәсенең предложениясе буенча, фабрик администрациясе аны Герой труда итеп объявить итәчәктер...

1924—1925

ЭЧТӘЛЕК

Гаяз Исхакый

Сөннәтче бабай 3
Ул әле өйләнмәгән иде 35

Фатих Әмирхан

Хәят 91

Шәриф Камал

Акчарлаклар 139

Габдулла Тукай

Тәэссер 186
Ана догасы 187
Таян Аллага 187
Милли моңнар 188
Дустларга бер сүз 188
И каләм! 189
Шагыйрь 191
Бер татар шагыйренең сүзләре 192
Сәрләүхәсез 193
Сорыкортларга 194
Государственная думага 195
«Алтынга каршы» 196
Милләтә 197
Үз-үземә 199
Кичке азан 199
Китмибез! 200
Мөхәрриргә 201
Кызык гыйшык 202
Бәйрәм вә сабыйлык вакыты 203
Кыйтга 204

Дәрдемәнд

Каләмгә хитаб 205
Яз чәчәге 206
Шагыйрьгә 206

Без 206
Ни газизрәк? 207
Бүзләрем мана алмадым 207
Нәсыйхәт 209
Исемсез кыска шигырьләр 209

Сәгыйть Рәмиев

Таң вакыты 212
Алла 214
«Мин» 214
«Син» 216
«Ул» 216
Талдым 216
Хатыннар галәме 217
Дөньяга 218
Минем төн 219
«Мин үләм» 220
Минутлар 220
Авыл 221
Көлсеннәр! 222

Нәҗип Думави

Яз 223
Золым 224
Үтте, үтә........ 225
Мәхбүс дустыма 226
Сугыш 227
Син — Кеше! 228
Сугыш тәэссораты 229
Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында 230
Татар 231
Үтә яшьлек 232

Галиәсгар Камал

Банкрот 233

Гафур Коләхмәтов

Яшь гомер 266

Галимҗан Ибраһимов

Казакъ кызы 304

Һади Такташ

Газраилләр 391
Күктән сөрелгәннәр 392

Антым 395
Юану 395
Урман кызы 396
Эшлиләр 400
Мәңгелек әкият 401
Сагыну 403
Такташ үлде 404
Урман 407
Карт артист 409
Давылдан соң 410
Син дә үл инде 418
Әйдә, энем! 421
Җырланачак җырлар турында 423
Бүгенгә матурлык 425
Җырым сиңа булсын 426
Болай... гади җыр гына 428
Үтеп барышлый 430
«Айга күптән инде мең яшь тулган...» 432
Мәхәббәт тәүбәсе 433

Кәрим Тинчурин

Американ 444

Фатих Әмирхан

Шәфигулла агай 489

Учебное издание

Составители:

Ахмадуллин Азат Гильмуллович
Галимуллин Фоат Галимуллович

**ХРЕСТОМАТИЯ
ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ**

Для 10 класса татарской средней
общеобразовательной школы

Издание третье

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Төзүчеләре:

Әхмәдуллин Азат Гыйльмуллович
Галимуллин Фоат Галимуллович

ӘДӘБИЯТТАН ХРЕСТОМАТИЯ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныфы өчен

Өченче басма

Редакторлары *Т. Р. Шакирова, Г. Г. Мөхәммәтҗанова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Л. Р. Гатауллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.04.2005.
Форматы $60\times90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 32,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап
табагы 27,86 + форз. 0,39. Тиражы 16 500 д. Заказ А-259.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ААҖ «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Атам-анам йорты өчен
булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
соң тамчы каным фида.

Дәрдемәнд